Әмирхан Еники

# Әйтелмәгән васыять

*Повестьлар, хикәяләр*

Казан

Татарстан китап нәшрияты

2014

«Татар прозасы» сериясе 2012 елдан нәшер ителә.

Проект җитәкчесе һәм китапның төзүчесе – Ленар Шәех, филология фәннәре кандидаты

**Еникиев, Ә. Н.**

Әйтелмәгән васыять : повестьлар, хикәяләр / Әмирхан Еники ; [проект җит. һәм кит. төз. Л. Шәех]. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2014. («Татар прозасы» сериясе.)

ISBN 978-5-298-02648-2

© Татарстан китап нәшряты, 2014

© Шәехов Л. М., төзү, 2014

«Татар прозасы» сериясеннән дөнья күргән бишенче китапта Татарстан Республикасының халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әмирхан Еникинең «Рәшә», «Әйтелмәгән васыять», «Яз баласы» поветьлары, «Кем җырлады?», «Матурлык», «Бер генә сәгатькә» һ. б. классик хикәяләре урын алды.

Әмирхан Еникинең башлангыч чор иҗатына караган «Яз баласы» повесте, узган гасырның алтмышынчы еллар ахырында язылган «Бабайлар» хикәясе укучыларга шулай ук кызык булачак. Бу ике әсәр язучы җыентыкларына беренче мәртәбә кертелә.

## Повестьлар

### Яз баласы*

### I

Таң беленеп килә.

Тәрәзәләрнең түбән яклары, чит-читләре бозланып каткан. Урта бер җирләре парланып тора... Тыш күренми, тыш караңгы. Өй эче дә караңгы... Почмакларда нәрсәдер кыштырдаган төсле тоела. Мич кашагасында бишле лампа яна. Ул бары мич алды белән сәке өстен генә яктырта... Мич алдында иске чүпрәкләр белән басып куйган самавыр акрын гына җырлый. Аның челтәреннән ут яктысы сап-сары итеп юган идәнгә юл-юл булып сузылып төшкән.

Әнкәй аяк очына баскан, миңа ачулана, өстемнән чикмәнемне тарта.

– Тор, тор инде... Абзыең бая ук торып чыкты. Син һаман оялмыйча йоклап ятасың!..

Мин күзләремне уа-уа торам... Йокы һаман ачылып җитми. Кичә генә кызыл почмакта отрядның сборы булып, ул сәгать уникегә кадәр тартылган иде. Соң ятылды. Шуңар күрә йокы туеп җитмәгән.

Әнкәй безнең шулай телчән хатын инде, мин торам, ә ул һаман тиргәнә:

– Күсәк кадәр малайсың, – ди, – абзыеңнан оялырга кирәк, – ди. (Ул, бер сүз булды исә, абзыйдан оялырга куша. Чөнки абзый моннан бер ел элек кенә армиядән кайткан иде. Безнең каршыда да, халык каршында да зур кеше.) Фәлән, ди, төгән, ди. Менә бөтенләй колак итен чәйни... Минем ачуым килеп китә!

– Әнкәй, тукта инде, – дим, – бер әйткәч тә тыңлыйм бит. Менә тордым, хәзер киенеп бетәм! – дим. Ашыгып-ашыгып киенергә тотынам.

Чыннан да, абыйдан оялмыйча туры да килми. Ул бичара, көн дими, төн дими, һаман эшли, һаман чаба... Бигрәк тә менә колхоз оештырганнан соң ул башы-аягы белән эшкә чумды. Хәзер инде барысы өчен дә эшләргә туры килә. Колхоз бит ул общий көч, общий эш дигән сүз.

---

* Гарәп язуыннан кириллицага күчерүчесе Айгөл Латыйпова.

(Абзый колхоз оештырганда шулай сөйләгән иде!) Аннан соң, безнең колхоз – яңа колхоз әле. Анысы юк, монысы юк. Барысын да табарга кирәк. Абзый менә яңарак кына машиналар артыннан ике тапкыр калага барып кайтты. Эшләмичә, йөрмичә бернәрсә дә булмый шул!

Әнкәй молодец!.. Оекларны әле дә мичкә кибәргә куйган. Ишек яңагына суккалап көлен кактым да киеп җибәрдем.

Җылы тула оек белән яңа чабаталар киеп җибәргәч, әллә ничек, җаныма да, тәнгә дә рәхәт булып китә. Бөтенләй кош төсле җиңеләеп китәсең. Әле дә менә шатлыктан тыпырдап алдым.

– Тыпыр-тыпыр биергә тимер идәннәр кирәк!..

Әнкәй аптырап карый.

– Җүләрләндеңме әллә, мин сине биер өчен уяттыммыни? – ди.

Мин кабаланам.

– Бетте, бетте, әнкәй, мин чыгам, мин болай гына, – дим. Билне ныгытып буам да бияләйләрне кулга алам.

Ул арада тыштан әткәй килеп керә. Аның артыннан тышкы суык та, ак пар булып, идән буенча сузылып өйгә керә... Усал нәрсә!.. Түр башына ук уза.

Тыш суык булса кирәк. Әткәй дә, җылы өйгә килеп керүе белән, «ух» дип кулларына өреп куйды. Мине күреп алгач:

– Әле син, җегет кисәге, балалы хатын кебек, һаман өйдә маташасың икән, – диде. Миңа йомшак тавыш белән генә шелтә ясап алды.

Мин сүз кайтарып тормадым. Шешәдән очкан бөке кебек, тышка атылдым. Тыш караңгылы-яктылы. Үзе суык. Бөтен өйләрнең мөрҗәләреннән куе соры төтен чыга. Соры төтен туп-туры аяз күккә сузыла. Ә аяз күктә сирәк кенә йолдызлар җемелдиләр.

Күп өйләрнең туңган тәрәзәләре аша ут яктысы күренә. Димәк, барысында да торганнар, эшкә башлаганнар... Хәзер мартның беренче көннәре. Көндез кояш югары күтәрелә. Акрын гына кыздыра. Кар өсләре шадралана. Ишек төпләре эри. Ат юлында кар астыннан тизәкләр чыга. Түбәләрдән, кояш нурында җем-җем килеп, тамчылар тама.

Мондый вакытлар җиткәч, бик рәхәт булып китә. Бер дә тыштан керәсе килми. Гел урамда, йорт алдында, мал-туар тирәсендә чуаласың. Әллә ничек, җиңел була. Кул-аякны тик тотасы килми. Һаман эшлисе, йөрисе килеп тора. Мин, мондый вакытлар җиткәч, бер мин генә түгел, бөтен кешеләр, бөтен хайваннар шундый хәлдә була торганнардыр, дим.

Әнә кәҗә бәрәннәре дә бит, яз бетеп, карлар эри башлау белән, өй буенда сикерешеп-сикерешеп уйный башлыйлар.

Көндезләрен шулай булса да, әле төннәрен нык суыта, нык катыра... Өйнең кыегы буйлап озын «сөңгеләр» тезелгән, ишек төбендә эрегән кар шакырдап туңган. Һава суык. Сулаганда тешкә тия...

Абзар янында кемнәрдер чуала. (Бездә атлар общий. Бусы Шәвәлинең бурлы биясе, тегесе Мингалинең кырыкмыш тае дигән билгеләүләрне бетердек. Ләкин көздән бөтен атлар өчен бер зур, һәйбәт абзар салып өлгертә алмаганга күрә, быел кышны аларны һәрбер колхоз әгъзасының аерым абзарында кышлатырга булганнар иде.) Караңгы булгач, аерып күреп булмый. Берсе абзый инде аның!.. Калганнары кемнәр булыр?!

Ат пошкырган тавыш, аяк тавышлары, чана шыгырдаган тавышлар ишетелә. Берәрсенең авызында тәмәке булса кирәк. Бармак очы кадәр генә ут ара-тирә ялт-ялт итеп китә... Берәү акрын гына, моңландырып кына озын көйгә сызгыра.

Мин, чыккач, саф, суык һаваны бер-ике тапкыр күкрәк тутырып суладым. Тирә-якка каранып алдым да туры абзарга таба – абзыйлар янына йөгердем. Барсам, анда абзый янына Сәләхи белән Әделгәрәй абзыйлар да килгәннәр, абзыйга ат җигеп булашалар... Алар безнең күршедә генә торалар. Үзләренең эшләрен бетергәннәр дә безгә кергәннәр.

Мин баруга, Әделгәрәй абзый сызгыруыннан туктады да, миңа карап:

– Нихәл син, комиссар энесе. Әле торып та чыктыңмыни? – ди.

Мин эре генә:

– Әллә йоклап ятар иде дип уйлыйсыңмы? – дим. Үзем бик җитез генә чанадан дилбегәне алып сүтә башладым.

Абзый мине мактый башлый:

– Булган ул безнең Локман, барысына да өлгерә. Бүген әле ул безнең белән волостька да барачак, – ди.

Волостька бару дигән нәрсә мине бик куандыра. Кичә соңга калып кайтып яткач та, шуны уйлап йоклый алмыйча азапланып яттым.

Уйлап карагыз, куанмаслык та түгел бит!.. Мин әле унике-унөч яшьлек кенә малай. Шуңар карамастан, хәзер абзыйлар рәтенә кереп барам. Зурлар белән чуалам. Алар эшенә катнашкан булам. Зурлар да үземә кырын карамыйлар, үз итәләр. Эш булдыра ул, дип мактыйлар. Бик-бик күңелле ул зурларга катнашу. Ә зур булу ул үзе бик зур бәхеттер инде.

Бүген менә без шулай таңнан торып волостька орлык алырга барырга әзерләнәбез. Безнең колхоз – яшь колхоз. Үткән көз генә авылдан күчеп чыктык... Аңа кадәр үткән яздан элекке язны ук колхоз оештырырга кирәк дип, халыкны кыстап йөрүче комсомоллар бар иде. Картлар башта

колак салмадылар. Соңгарак хәллеләрдән кайберәүләр бөтенләй комсомолларны сүгә, колхоз дигән нәрсәгә каршы чыга башладылар. Кайберәүләр икеләнеп калдылар.

Көз көне абый, армиядән кайткач, бу эшкә җиң сызганып тотынды. Комсомоллар бар да аңар кушылдылар... Ә яз көне, май аенда, егерме биш йорт, үзебезгә тоташ җир кисәген алып, бергәләп чәчтек тә. Менә шушы урынга, Морадым дигән елга буена, каралтыларны күчерә башладык. Урактан соң шушы урында, ындырлар ясап, ашлыкларны суктык. Көз яхшы килде. Кыр эшләрен бетергәч тә, аяз көннәр озак булды. Безнең колхозчылар, вакытның шулай бирелүеннән файдаланып, бөтенләй күченделәр.

Колхозыбыз «Үрнәк» исемендә.

Быел кышны яңа җирдә «Үрнәк» тә кышлады. Быел яз колхозыбыз 200 дисәтинә сабан ашлыгы чәчмәкче булып тора. Волостьтагы әллә нәрсә «Союз» дигән бер союз безнең колхозга 400 пот орлык бирергә булган.

Бүген менә шунда 20 ат белән орлык алырга барабыз.

Кичә көндез читальныйда шул турыда колхозчыларның җыелышы булды. Җыелышта бу орлыкка бару турында, язгы чәчүгә хәзерлек турында да күп сүзләр сөйләделәр... Колхозга гел ярлылар гына күчкәч, атларыбыз хәзер күп түгел. Кешеләребез дә аз. Шуңар күрә орлыкка егерме ат белән унбиш кеше генә җибәрергә булдылар...

Аннан соң колхозда тимерлек ачу турында күп сөйләштеләр. Бездә бик оста ике тимерче (Мәрдан бабай белән Әделгәрәй абзый) бар. Тимерлексез кыен. Менә чәчү вакыты җитә. Машиналарны төзәткәләргә кирәк. Җыелышта иң күп сүз трактор турында булды. Үткән көз үк трактор алырга кирәк дип безнекеләр исәп куйганнар иде. Абзый ул турыда бер тапкыр калага да барып кайткан иде. Кичә шул турыда озак сөйләшкәч, абзый, Әделгәрәй абзый, Гыйльман бабай өчәүләп янә икенче тапкыр калага барырга булдылар... Алар анда трактор турында да сөйләшәчәкләр, бер уңайдан тимерлек өчен кирәк булган нәрсәләрне дә алып кайтачаклар.

Бүген безне озаткач, алар ике атта калага китәләр. Тагын әткәй белән Чуар Ибрай (бездә алар икәү, берсенә Яшел Ибрай диләр) иртәгә биш атта тегермәнгә барачаклар. Шулай итеп, шушы ике-өч көн эчендә колхоздан бөтен кеше таралып бетә. Шуңар күрә миңа да бер-ике көнгә дәресне калдырып булса да, абзыйның сүзен тыңлап волостька орлык артыннан барырга туры килә.

Дәрес кала дигәч, абзый әйтә:

– Дөрес, Локман, дәрес калдыру күңелле эш түгел. Ну шулай да волостька барырга туры килә. Аннан, ат карап торсаң да, зур файдаң тияр. Башкалар бер дә бушый алмаслар... Дәресеңне кайткач ныгытып укырсың, – ди.

Шулай дигәч, кыстатып тормадым. Аннан соң башкалар тирләп-пешеп эшләгәндә, минем дә эшлисем килә... Колхозда шунысы кызык икән: берәү эшләгәндә икенче берәү карап тора алмый, оят була. Уңайсыз була.

Атларны җигеп беттек. Сәләхи абзый лапас башыннан кар астында калган карлы печәнне тимер сәнәк белән каерып-каерып түбән ташлады. Без Әделгәрәй абзый белән икәү кочакларыбыз сыйдырган кадәр кочаклап алып чаналарга салдык.

Әделгәрәй абзый, безнең эштә сабыр булса да, уенчак кеше. Гел шаяруны ярата. Әле дә, биргән печәнне кочаклап алыйм дигәндә, арттан тезе белән төртеп екты. Башым белән карга кадалдым... Тагын үземне күтәреп алып, печән белән тупы чанага ыргытты да кытыклый башлады. Үзем көләм, үзем нишләргә белмим.

– Җибәр, җибәр, Әделгәрәй абзый, җибәр, үтерәсең! – дим.

Ә ул һаман:

– Әттә-тә-тә, эттә-тә, эттә-тә-тә, – ди. Зур куллары белән боттан да кыса, бөергә дә төртә. Мин бөтенләй көлә-көлә, чабалана-чабалана тирләп пешеп беттем. Авызыма, җилкәмә печән тулды... Ках-ках йөткерәм. Печән тамакка ябышкан төсле тоела.

Үзем дә, торгач, вак карны ике учлап алдым да, артыннан акрын гына килеп, җилкәсенә сиптем. Үчне алдым, малай! Куып караган иде дә тота алмады. Минем бәләкәй генә җиңел чабаталарым әйтерсең яхшы ат, үземне алып кына очалар.

Эшләрне бетергәч, атларны ишек төбенәрәк тарттырдык та җыйнаулашып өйгә чәй эчәргә кердек.

Әнкәйнең самавыры сәке өстендә, дөбер-дөбер кайнап, буларын чыгарып утыра. Киҗеле ашъяулык өстенә чәчәкләре кубып, анда-санда кызыл-яшел буявы калган иске поднос белән чынаяклар куелган. Күп итеп икмәк телеп ташланган... Тәрилкә белән бер йомарлак ак май да бар.

Без кереп сәке тирәсенә җыелышу белән, әнкәй мичтән өелеп торган бер таба беленне дә табынга алып куйды... Без ашык-пошык ашарга керештек.

Дүрткә кискән беленнең бер кисәген бөкләп ашый башлыйсың. Беленнең вак күзәнәкләренә тулган сары май тешләгән саен иреннәргә буялып, авыз эченә таралып китә инде менә, дөньяда майлы беленнән дә тәмле аш юктыр, дисең.

Тәрәзәгә алланып кына туачак көннең шәүләсе төшә... Әткәй әйләнеп карый да:

– Җәтрәк булыйк, балалар, соңга калмагыз! – ди.

Без дә бу соңгы чәшкеләребезне капылт-капылт йотабыз да, урыннарыбыздан кузгала башлыйбыз. Әнкәй дә, эчеп бетергән чәшкесен каплап, безнең урыннан кузгала башлаганны

көтеп тора да, самавыр артына яшеренә биреп амин тота. Элек мине амин тотарга кыстап йөдәтеп бетерә иде. Хәзер үзе дә куркып, качып кына тота инде.

Эчкә җылы чәй белән майлы белен тутырып чыккач, суык тыш та җылы була... Без, бияләйләрне билбауга кыстырып, карлы дилбегәләрне ялангач кулга алдык... Атлар акрын гына кузгалдылар.

Безнең каршыда Усман абзыйларның йорты... Аның ялан кадәр киң ишегалдында колхозның амбары... Шул амбарда колхозның бөтен иген байлыгы саклана. Ә ул амбарның үзен ике усал эт – Бүре белән Актырнак саклыйлар.

Орлыкка баручылар бар да шул амбар алдына җыелырга тиешләр. Без үзебездән чыктык та Усман абзыйлар капкасы төбенә туктадык. Анда баручыларның күбесе җыелган иде... Ерак юлга дип ныгытып, яхшылап җиккән атлар, печән белән тулы чаналар, бер-берсе белән аралашып, кузгалып китүне көтеп торалар... Абзый кешеләр бер төркемгә җыелганнар, үзара сөйләшәләр, тәмәке көйрәтәләр.

Без барып туктауга, Шәймәрдан бабай, минем абзыйга карап:

– Мансур энекәш, йә, безне озат инде. Вакыт бушка үтмәсен! – диде.

Абзый ашыга башлады.

– Ярый, хәзер кузгалырсыз. Кая, Усман абзый күренмәдеме, сезгә саласы нәрсәләр бар бит әле, – дип, як-ягына каранырга тотынды.

Ул арада Усман абзый үзе дә килеп чыкты.

Абзый, Усман абзый, тагын берничә кеше амбарга таба киттеләр. Миңа, Шәймәрдан бабай белән Ярулла абзыйга атларны амбар алдына тарттырырга куштылар.

Җәеп биргән салам өстендә бөгәрләнеп ятып торган этләр, абзыйлар якынлашкач, икесе дә тордылар... Бүре, арт аякларын артка сузып, бик яман киерелде. Актырнак Усман абзый янына килеп сикерә башлады... Зур йөнтәс эт, Усман абзыйның авызына сикерә-сикерә, өстен кар белән буяп бетерде.

Без атларыбызны амбар алдына туктаткач, Ярулла абзый белән Шәймәрдан бабай ике капчык солы чыгарып ике атка салдылар. Болар атларга ашатыр өчен иде. Аннан соң Усман абзый белән минем абзый бер зур тәпәнне, икесе ике ягыннан күтәреп чыгарып, өченче атка салдылар. Бу тәпәндә май... Безнең колхозда ике сепаратор белән бер май язгыч бар. Кыш көне күп сыерларның туктатуына карамастан, аз-маз җыела торгач, бер тәпән май җыелган... Шуны хәзер волость кооперативына илтеп биреп, бераз товар алып кайтырга уйлыйлар.

Амбарда эшне бетергәч, кире урамга чыктык. Анда барырга тиешле кешеләр барысы да җыелып беткәннәр иде.

Абзыйлар чыккач, халык дилбегәләренә тотынды, атлар кузгалышып куйдылар.

Абзый, Сәләхи абзыйлар, Шәймәрдан, Нуретдин бабайлар янына килеп:

– Ну, абзыйлар, хәзер кузгалырга да ярый. Анда баргач, шул барысын да кичә сөйләшкәнчә эшләрсез инде. Орлыкны алган вакытта эш итә торган бөтен язу-сызу эшләрен Сәләхи башкарыр... Аннан соң, Сәләхи, Шәймәрдан бабай, сез волком секретаре иптәш Хәкимов янына да кереп чыгыгыз әле. Ул теге Сафа байның конфисковать ителгән амбарын безгә бирдерү чарасын күрсен әле. Клубсыз, мәктәпсез яшибез. Быел үзебезгә салдырырга әллә көч җитә, әллә юк, диегез. Шуларны онытмагыз! – диде.

Шәймәрдан бабай, атын кузгата-кузгата:

– Ярый, ярый, шулай эшләрбез, Мансур энекәш, бар да син дигәнчә булыр. Тик үзең калага баргач, тракторны ничек тә кулга төшерергә тырыш! – диде. Чанасына менеп, ипләп кенә тезләрен бөкләп утырды.

Иң элек ул кузгалды. Аның артыннан мин иярдем. Әнкәй, бик алга чыкмагыз, улым, җил булыр, дисә дә тыңламадым. Мин нигәдер, юл йөргәндә, гел алдан йөрергә яратам.

Башкалар безнең артка тезелделәр... Без шулай, кыр казлары шикелле аллы-артлы тезелешеп, кызу гына юыртып, «авылны» чыгып киттек. Әткәйләр, абзыйлар капка төбендә безнең арттан карап калдылар.

Кырга чыккач, юл түбәнгә таба китә... Атлар шәп юырталар. Чаналар сикәлтәдә шап-шап итеп калалар. Кайчан салуга да барып сугылабыз... Ә алда Шәймәрдан бабай биясенең муенындагы кечкенә кыңгырау шылтыр-шылтыр килгән була. Таң яктырып килә... Алда куе караңгылык юк. Җир өстендә тонык яктылык. Еракта кар белән капланган таулар да, кара урманнар да – барысы да күгәреп кенә күренәләр. Күк йөзе аяз. Анда ярты айның ак шәүләсе бик юка булып сизелер-сизелмәс күренә... Йолдызлар сүнеп беткәннәр. Тик кояш чыгышы ягында бер тере матур йолдыз ялтырап яна... Ә алда ике ягына корыган чыбыклар кадалган зур юл еракларга сузылып күздән югалган.

Безнең төп авылыбыз Карамалы үзебездән бары өч кенә чакрым... Без, кызу юрта торгач, бик тиз аның очына да шаулап барып кердек. Авыл очында безгә каршы бер-ике эт өреп күтәрелгәннәр иде дә, тиз тындылар.

Авыл йоклый... Тәрәзәләр караңгы. Мөрҗәләр моң гына караеп торалар. Абзарлар, каралтылар әйтерсең буп-буш, бар да тып-тын... Иске мәчет чалшайган... «Җәмәгать!.. Картайдым, әҗәл көтәм», – дип, үлем түшәгенә ятарга хәзерләнгән карт төсле күренә. Мөрҗәсеннән сыек кына төтен чыга... Фәррах бабай һаман үзен ягып йөри, күрәсең!...

Без ташлап киткән йорт урыннары калын көрт астында калганнар. Көрт өстендә аркылы-торкылы сузылган эт аягы эзләре ярылып яталар.

Без авылны да чыктык... Аз гына баргач та, вак кына куаклык башланды. Юлның читендәрәк бик күп куян эзләре, куян тизәкләре күренәләр... Ахрысы, бер дә бу тирәдә аучы-фәлән йөрмәгән. Мин куян, төлке кебек җәнлекләрне күрергә бик яратам. Аларны тотудан бигрәк, кешедән курка-курка җан-фәрман качуларын карарга яратам... Алар да үлемнән бик куркалар, күрәсең. Кайчан юри куркытыр өчен генә кычкырасың, ә ул мәхлук шашып кача.

Әле дә мин, ак куянны күрәсем килеп, тирә-ягыма ялт-йолт каранып барам.

Чү!!!

Куак арасында нәрсәдер кыштырдаган кебек булды. Мин күрергә өлгерә алмадым, арттан килгән Гыйззәт:

– Әй, җегетләр, куян, куян! – дип кычкырып та җибәрде. Башкалар да бар да бердән акырырга, сызгырырга тотындылар.

– Һу... һу!.. Һайт... һайт!.. Их, үзен!..

Мин, нишләргә белмичә, һаман каранам-каранам – күрә алмыйм. Ахырда, юл буенча чабып барган куянның куак арасына борылып кереп киткән чагында, ак матур койрыгын гына күреп калдым.

Куаклык та артта калды... Тирә-якта кар белән түшәлгән ап-ак тигез алан...

Көн тәмам яктырды... Каршыдан гына зур булып кояш чыкты. Аның беренче нурлары җир буена сузылдылар, безнең йөзләребезгә, күзләребезгә төштеләр...

Кояш акрын гына күтәрелә, кечерәя. Нурлары җитезләнгән төсле күренә. Менә алар шадра кар өстендә җем-җем килеп уйный да башладылар... Ул нурларга хәзер карап та булмый, шундый шаяннар, йөзне кытыкландыралар, күзләрне чагылдыралар...

Кояш белән бергә җир өстенә матурлык, шатлык туды. Йөрәкләр сөенеч белән тулды. Уйныйсы, шаярасы килеп китте. Баручыларның күбесе чаналарыннан төшәләр, көлешә, сөйләшә башладылар.

Мин дә чанамнан төштем дә алар арасында йөгереп, уйнап бара башладым.

## II

Кызлар көләләр... Үзара пышылдыйлар да кычкырып көләләр... Ә җегетләр аларның көлүләреннән шикләнәләр... Һәркем үзенең өсте-башына карый, бер-берсенә карашалар. Кемдә гаеп, кем нәрсә эшләде, кем нинди ярамаган сүз ычкындырды?! Юк шикелле, бернәрсә дә сизелми!..

Үзләрендә бернинди дә гаеп сизмәгәч, җегетләр кызларның туктаусыз шырык-шырык көлүләренә тәмам аптырадылар.

Гыйззәт чыдамый, кызларның өстенә акыра:

– Туктыйсызмы, юкмы, ә?..

Кызлар тагын да ныграк шаркылдыйлар...

Әделгәрәй абзый Гыйззәткә кызмаска куша:

– Әйдә, көлсеннәр, юкка эчең пошмасын. Кызлар алар, кәефләре килгәндә, өелеп торган ат тизәгеннән дә көләләр, – ди.

Гыйззәт тиз генә басылмый, тегеләр өстенә кычкыра бирә:

– Бу ниткән көлү?.. Без сезне туктаусыз кешнәп торыр өчен чакырдыкмыни, йә?!

Кызлар бик азга гына көлүдән туктыйлар... Гайникамал апа сулы кисмәк өстенә иелеп торган җиреннән калка, сулы кулларын алъяпкычына сөртә-сөртә, сыңар кашын гына күтәреп, матур гына елмаеп, җитез тавыш белән:

– Гыйззәт, үткән атнаны гына бит әле син, безне читальняга җыеп, «Хатын-кызлар азат, хатын-кызлар үзләренчә яшәргә хаклы!» дип сөйләгән идең. Хәзер безне көлүдән көчләп туктатмакчы буласыңмы? – диде.

Мәхүб җиңги, аңа ялгап:

– Гыйззәт ул безнең теле белән йөрәгенә баш була алмаган кеше... Кичә «азат» диеп сөйләсә, иртәгә менә сине үк мунчак белән мич алдына бәйләп куяр... – диде.

Чак тыелып торган кызлар тагын шаркылдап көлеп җибәрделәр. Аларга ияреп, җегетләр дә көләргә керештеләр. Гыйззәт абзый үзе дә тыела алмады:

– Аңламыйм, җәмәгать! Әллә нәрсә булган бүген сезгә, хәерлегә булсын! – дип, кулын селтәп көлә башлады. Алар тирәсендә чуалган без ваклар да, Гыйззәт абзый шикелле бернәрсә аңламасак та, кешегә ияреп кет-кет көлгән булдык.

Мин, Мәхүб җиңгинең сүзеннән соң, Гайникамал апага күз төшердем. Мәхүб җиңги, бер дә белмәмешкә салышып, «Иртәгә менә сине үк мунчак белән мич алдына бәйләп куяр...» дигәч, ул оялып башын иде. Азрак кызарды... Акрын көлде.

Гыйззәт абзый белән Гайникамал апа яратышалар икән дигән сүз бар иде җиңгиләрдә, үзара сөйләшкәндә:

– Гыйззәт, игеннәр ишелеп уңса, үзебезгә клуб салып җибәрсәк, көз көне иң элек синең кызыл туеңны үткәрәбез! – дип, аны куандыралар иде.

Мәхүб җиңгинең сүзеннән соң, Гайникамал апаның шундый хәлдә калуын күргәч, мин аларның яратышуларына чын-чынлап ышандым. Үзем дә белмим, нигәдер сөендем... Гайникамал апаның оялчан шатлыгы миңа да күчте...

Гыйззәт абзый ул, Мәхүб җиңги әйткәнчә, җилкуар, усал кеше түгел. Мәхүб җиңги аны шаярып кына әйтә... Киресенчә, Гыйззәт абзый ул көлдерергә ярата торган простой кеше... Аның ачуланып маташуы да көлдерер өчен генә була...

Бүген бар да шат, бар да юктан көлә... Берсе көлсә, икенчесе берсенең нидән көлүен һич аңламастан ияреп көлә... Әйтерсең тегесенең бер шатлыгы бусының йөрәгендәге икенче шатлыкны кузгата, алар, бер-берсенә ияреп, тышка түгеләләр.

Ни өчен ул алай?..

Минемчә, бер теләк, бер дәрт белән бер эш өстендә күмәкләшеп эшләүдән андый кәеф туадыр. Минемчә, сулаган һаваның йөрәккә ягымлы җылылык, күзләрне камаштырган яктылык белән тулы булуыннан шулай, күкрәктәге шатлыклар ярларга сыймаган язгы ташу кебек ташып торадыр.

Бүген без язгы чәчү өчен орлык чистартабыз.

Киң йорт алды... Аның төрле җиренә язгы кояштан эреп, каралып торган кар өстенә такталар тезелеп, алар өстенә зур брезентлар, киндерләр җәелгән... Киндерләр өстенә кояш төшмәсен өчен, аларның дүрт почмагына дүрт казык кагылып, казыкларга аркылы киртәләр куелган. Киртәләр өстенә тагын брезент-киндерләр капланган... Һәр табын янында бер зур сулы кисмәк тора. Ул кисмәкләргә, орлыктагы ашлык гөмбәсе дигән авыруны бетерү өчен, формалин салынган.

Нәкъ амбар алдында орлык чистарткыч машина (веялка) тора. Аның астына да зур брезент җәелгән, янына ике зур ящик куелган.

Ике җегет амбарның бурасыннан тимер пудаукалар белән орлыкны чыгарып, веялканың өстендәге чокырга – ящиккә салалар... Берәү әйләндереп тора, веялканың эчендәге канатлары туктаусыз «текел-текел-текел» киләләр. Веялканың артыннан орлыкның чүп-чарлары, кибәкләре очып торалар. Алдыннан, янтыгыннан чиста орлыклар, эрегә, вакка аерылып, брезент өстенә шуып төшәләр.

Ул ике сорт орлыкларны без Габдерәхим белән, икәү зур җиңел агач соскылар белән веялка астыннан алып, әлеге ике ящиккә сала барабыз... Җегетләр, кызлар ящиктәге орлыкларны капчыкларга берәр-икешәр пот чамасы гына салып алып китәләр. Орлыктагы ашлык гөмбәсе дигән авыруны бетерер өчен әзерләнгән сулы формалинлы кисмәкләргә капчыклары белән илтеп тыгалар, бер-ике минут кына тоталар да, кире алып, суын саркыталар.

җәелеп куйган брезент-киндерләргә бушаталар... Кызлар, тизрәк кипсен өчен, орлыкларны тырма сырты белән тараталар, җәяләр.

Күләгә астында акрынлап кипкән орлыкларны җегетләр кире капчыкларга салып, амбарга ташыйлар. Чәчәргә дигәнен шул килеш капчыгы белән өеп куялар, башкасын бураларга бушаталар...

Шулай итеп, бер уңайдан ике эш эшләнә: орлык чүп-чарлардан чистартыла, орлыктагы ашлык гөмбәсе дигән авыру формалинлы су белән үтерелә...

Без боларның барысын да агроном киңәше белән эшлибез. Агроном, орлыкны чистартып, авыруларын бетереп чәчсәгез, игенегез тигез, чиста булып үсәр, башагы эре булыр, уңышны күп алырсыз, ди.

Без, авыл крестьяннарына һәр яктан, һәр эштә үрнәк булыр өчен, һичбер агроном киңәшеннән чыкмыйбыз. Аның кушканын минуты белән үтәп торабыз. Менә бүген-иртәгә үзебезнең эшне бетергәч, авылга барып, андагы ярлы агайларның орлыкларын үзебезнең машина белән чистартып бирәчәкбез. Орлыктагы авыруларны ничек үтерергә кирәклеген өйрәтәчәкбез...

Эш кайный... Куллар тик тормый... Кызлар очынып йөриләр... Җегетләр бер-берсе алдында, көчлелекләрен күрсәтер өчен, биш потлы капчыкны кеше ярдәменнән башка җирдән алалар, йөгертеп амбарга илтәләр. Безнең ише ваклар да, зурларның шатлыгы белән шатланып, алар нәрсә эшләсә, шуны эшләргә тырышып чуалып йөриләр. Ара-тирә орлыкка якын килгән тавыкларны пыр туздырып куып алып китәләр. Бүген орлык чистарту эшендә бары яшьләр генә... Картларга чуалмаска куштылар. Җиңел эш, үзебез дә күз ачып йомганчы башкарырбыз, диделәр... Шулай да әле барысы биш йөз пот орлык чистартасы бар. Бүген өч йөзе бетсә, иртәгә тагын көн буе маташырга эш кала...

Әткәй, авылдан килгән Гыйбад абзый икәүләп безнең эшләп яткан җиргә килделәр... Гыйбад абзый сары сакаллы, кечкенә буйлы бер кеше. Авылның чыкылдап торган ярлысы... Үзенең болай башы да бик зур, «Кушбаш Гыйбад» дип йөртәләр үзен. Шуңа карамастан, без колхозга күчкән чакта, «Җыен ярлы ялан уртасына кырылышып үләргә чыга торганнардыр» дип көлеп, бездән аерылып калган иде... Хәзер «ярлы» колхозга нинди йомышы төшкәндер, безгә килгән...

Әткәй, ерактан ук эшләүчеләргә дәрт бирергә теләгәндәй, күтәренке тавыш белән:

– Ничек, балалар, эшләр тәгәриме? – диде.

Кызлар аңарга ярым шаяру белән җавап бирделәр:

– Һу... Шәмсетдин абзый, эшләр шундый тәгәри, астында калып үлмәсәң генә ярар иде, дип торабыз.

Әткәй кетердәп көлде. Соңра кибәргә җәеп куйган орлык янына килеп чүгәләде дә, сап-сары ялтырап торган эре бодайны учына алып, борын төбенә үк китерде. Куанычыннан:

– Сөбханалла, кара, бигрәк тә һәйбәт була икән бу болай!.. – диде.

Гыйззәт, шул сүзләрне ишетүгә, җилкәсенә күтәргән капчыгын кире җиргә куйды да әткәйне сискәндерерлек итеп кычкырып җибәрде:

– Нәрсә, нәрсә дисең, карт, «сөбханалла» дисеңме?!

Әткәй каушады, уңайсызланды, тиз генә җавап бирә алмады. Гыйззәт аның сүзен көтеп тормады, әйтәсен әйтеп бирде:

– Син, карт, без эшләгән эш өчен Аллага рәхмәт әйтеп утырма... Без аны Алла кушуы буенча эшләмәдек, әйтәсе рәхмәтеңне безгә әйт... Менә болай диген: «Сөбханалла, Гыйззәтулла», – диген.

Җегетләр, кызлар бар да шаркылдап көлделәр. Әткәй дә кетердәгән булды, ләкин аның уңайсыз хәлдә калуы йөзенә чыккан иде. Сүзен әйтә алмый, ык-мык килә.

– Ә теге ни... Гыйззәт туган... әлеге шул иске гадәт буенча гына, – ди. Үзе, бүреген йөзенә төшереп, җилкәсен кашый.

Гыйззәт, аны уңайсыз хәлдән коткарыр өчен:

– Алаймы?! Шулай дип котыл... – ди дә борылып читкә китә.

Әткәй Гыйбад абзыйга әйләнә.

– Шулай менә, Гыйбадулла... Заманны мин әйтәм әле, үзгәрсә үзгәрә бит...

Гыйбад абзый салкын елмая. Ул җирдә яткан бодайга караган. Чырае күңелсез, кайгылы...

Әткәй аңарга тагын дәшә:

– Соң, ничек, Гыйбадулла, быел күпме чәчәргә уйлап торасың?

Гыйбад абзый авыр сулый.

– Бер дә белмим, Шәмсетдин абзый, аптыраган әле.

– Нишләп алай, сөргән җирең дә бар түгелме соң синең?

– Сөргән җир дә бар барлыкка... тик менә җиргә сибәргә орлыгы юк, Шәмсетдин абзый.

Әткәй аңарга ышанмыйча аптырап карый.

– Ничек ул алай, орлык өләштеләр бит үзегезгә... Алдыгыз бит?

– Алган идек алуын да...

– Соң?

Гыйбад абзый бераз дәшми тора. Ул нәрсәнедер яшерергә теләгәндәй күренә... Бер-ике секунд үтә. Соңра ул, гафу үтенгән гаепле кеше сыман, акрын тавыш белән сөйләргә керешә:

– Шул менә, Сиражи кайнагай Майтап балдызны түбән очның Таз Баһау малае Вафага биргән иде. Туй булды... Бердәнбер балдыз булгач, мин дә читтә торып калмадым, катнаштым. Ә ул туй байтакка төште... Сәвиттән алган орлык та, үземнең көздән бирле саклап килгән орлык та – бар да шунда китеп беттеләр... Таз Баһау ул хәлле кеше, кодалары күп иде. Алар каршында сер сынатмыйк дип, бүләк тә куйдык.

Әткәй тәмам гаҗәпсенә, башын селкә:

– Әй, Гыйбадулла, Гыйбадулла, чистый ахмак икәнсең, ә! Үз акылың җитмәгәч, кешедән киңәш сорарга иде... Соң шушы вакытта, кеше орлыгының бер бертеген күз карасы кебек саклаган чакта, син туйлап, эчеп, әрәм-шәрәм итеп бетергәнсең... Хәзер ел әйләнәсенә ач калдың бит инде?..

Гыйбад абзый дәшми.

– Соң сезгә ул туйны көзгә калдырганда ни зарар булыр иде... Син генә түгел, Сиражи кайнагаларың да синең кебек бөлгәннәрдер инде?..

Гыйбад абзый акрын җавап бирә:

– Шул шул... Ул да, күрше Шәрәп тә, Гата кияү дә минем көнгә калдылар... Мин туйны көзгә калдыру турында кайнагайга киңәш биргән идем бирүен, каршы як якын да килмәгән...

Гыйбад абзыйның сүзләрен җегетләр эшләрен туктатып тыңлап торалар иде. Әделгәрәй абзый түзмәде, ачуын белгертмәскә тырышып, сабыр тавыш, ләкин усалрак сүзләр белән:

– Ә ул туйга бөтенләй катнашмаганда, хәерчелегемә көч килмәс дип курыктыңмыни?.. Их, голова! – диде.

Гыйззәт бөтенләй кабынып китте:

– Йә, җегетләр, хөкүмәт «чәчсеннәр, җирләре буш ятмасын, үзләре ач калмасыннар» дип, аларга орлык өләшә... Ә алар бер кулак малаеның кәефе өчен алтыннан кадерлерәк нәрсәне әрәм-шәрәм итәләр. Болай итеп алар үзләре генә ач калу түгел, хөкүмәткә ничаклы зарар китерәләр бит, ә?!

Гыйбад абзый артык уңайсыз хәлдә калды. Ул әйтерсең сүгүчеләрнең күзләренә карарга курка – карашын һич җирдән алмый. Сары сакаллы авызының бер як читен туктаусыз кыйшайта... басып торышы белән атасы кулындагы чыбыркыдан курыккан баланы хәтерләтә...

Әткәй Гыйбад абзыйны азрак кызганды булса кирәк. Ачуын баса төшеп, сабыр тавыш белән сөйләргә керешә:

– Былтыр бит мин үзем, олы башымны кече итеп, ничә тапкыр үзеңә бардым. Әйдә, кушыл безгә, Гыйбадулла, кушыл, дидем. Ә син, юк, имеш, белер-белмәс эшкә тәвәккәлләргә ярамый, имеш. Болай да, Аллага шөкер, ач торганыбыз юк, имеш. Хәзер терсәкне тешләр идең дә, булмас, авызың җитмидер. Мактанып әйтү булмасын, быел менә без, авылча әйткәндә, йорт башына унар дисәтинә сабан ашлыгы чәчәбез. Колхоз шул ул аерым кешеләрнең кәефенә карап эш итми... Кемнең нәрсә эшлисе килми, күпчелек риза булмаса, авыз да ача алмыйсың... Шуңар күрә бездә эшләр яшен тизлеге белән алга тәгәри дә... Шул менә, Гыйбадулла, җилгә каршы төкерсәң, барыбер үзеңне генә буйыйсың, ди. Заманга, агымга каршы барып, хәзер эш чыгара алмассың...

Гыйбад абзый авыр сулый.

– Әйтмә инде, Шәмсетдин абзый, ул чактагы ахмаклыгым өчен хәзер үземне өзгәләрдәй булам. Оят миңа, бик зур оят, Шәмсетдин абзый, сезнең каршыда...

Гыйбад абзый кызгандыра торган карлыккан тавыш белән күп зарланды, күп сөйләде. Хәзер ярты авыл колхозга күчәргә исәпләп тора икән. Бер тапкыр авызлары пешкән Гыйбад абзыйлар шуның артыннан йөрергә керешкәннәр. Бүген дә ул безгә Мансур абзый янына кайбер нәрсәләр турында киңәш сорарга килгән, имеш... Әткәй аны озак тыңлады, киңәшләр бирде. Соңра алар икәүләп акрын гына капкага таба киттеләр. Алар китеп күздән югалгач та, Мәхүб җиңги җегетләр, кызларның барысына да ишетелерлек итеп кычкырып җибәрде:

– Таз Баһау малае сукыр Вафаның өйләнәсе килгән, ди.

Гыйззәт аңар ялгады:

– Биш потлы Майтапның кияүгә чыгасы килгән, ди.

– Хәзер аларга рәхәттер инде!..

– Ә Гыйбадулла абзыйга ничегрәк икән?..

Халык көлешә... Тагын шаян сүзләр башлана. Җегетләр-кызлар тагын да ныграк дәртсенеп, көрсенеп эшләргә тотыналар... Амбардан орлыкны пудаукалар белән кызурак чыгаралар. Веялка ныграк текелди. Кояш төшлеккә күтәрелә, кыздыра. Кар өсләре карала, шадралана... түбәләрдән тамган тамчылар нурда уйныйлар. Ишек төбенә җыелган суда үрдәкләр бокырдашалар. Тавыклар акрын атлап җырлап йөриләр...

– Һәркем үз эшендә!..

**III**

– Яз!!! Яз!!! Яз!!!

Күктә дә, җирдә дә, тышта да, өйдә дә яз...

Вак кына елгачыклар, кәҗә бәрәннәре кебек сикереп-сикереп, тамчыларын чәчрәтә-чәчрәтә чабалар. Алар, кайдадыр, ниндидер бәхеткә, шатлыкка таба ашыккан шикелле, иртәдән алып кичкә кадәр чабалар, вак-вак дулкыннар, кояш нурлары белән аралашып, елтыр-елтыр киләләр. Куанычыннан нишләргә белмәгән яшь кызлар шикелле чылтыр-чылтыр көләләр... Вак елгачыклар шундый күңеллеләр, кайчан сәгатьләр буенча өсләренә онытылып, сокланып карап торасың...

Менә вак елгачыклар бер-берсенә кушылалар, тыналар, сабыр агышлы дәү елгага әйләнәләр.

Ләкин аларда да ниндидер ашкыну була... Йөрәгенең ярсуы, канатлануы тәненә сыймаган нечкә, озын ботлы колын шикелле, үзләрен үзләре белештермичә алга чабалар. Тар урыннарда ярларга сыя алмыйча үкерәләр, киң урыннарда җәелеп китәләр... Ә елганың үзәге дулкын-дулкын булып яшен тизлеге белән алга йөгерә дә йөгерә... Әйтерсең зәңгәр күк түреннән җир өстенә елмаеп карап торган кояш балалары белән уйнарга ярата торган шаян ата кебек, бу вак елгаларны нурдан үрелгән йомшак камчы белән юри генә кыйнаган булып куа... Ә елгалар, аркаларына төшкән нур камчысыннан курыккан булып, көлә-көлә, сөрлегә-сөрлегә чабалар да чабалар.

Ярлардан ярларга сугылып аккан елга вак балаларга уйнар өчен уңай була... Менә алар шарлавыкларга «су тегермәне» коралар... Без чокып биргән көймәләрне аллы-артлы тезеп агызалар. Эчләренә су күтәрерлек итеп кенә берәр нәрсә салган булалар. Имеш, алар, кызыл кәрван оештырып, калага ашлык илтәләр. Үзләре, кулларына чыбык алып, тиресле суны балакларына чәчрәтә-чәчрәтә, көймәләре артыннан йөгерәләр. Су кызу аккан җирдә көймәләрнең кайберсе әйләнеп-әйләнеп, ярларга бәрелеп капланып китә... «Бәхетсезлекне» берәр нәрсәгә юрарга теләп, арадан берәү:

– Әхмәтнең аты арыды, малайлар! – дип кычкыра.

Башкалар кинәт бу сүзгә ышанып куйсалар да, аз гына уйлап алгач та, каршы төшәләр:

– Иң тәү колхозның аты арыймыни? Колхоз аты таза була ул, – диләр. – Аннан соң безнең көймәләр кызыл кәрван булса да, аларны бер дә атка охшатырга ярамый. Тагын арыды, дибез. Арыгач ул туктый бит, ә безнең көймә һаман бәрелә-сугыла ага да ага...

Ваклар шулай диләр. Үзләренчә көймәнең бәхетсезлеккә очравына җавап эзлиләр, таба алмыйлар. Соңра ул уенны ташлыйлар да икенчене башлыйлар.

Без аларның уйнауларына сокланып карыйбыз. Кайчан кушылып китәбез, бирелеп уйныйбыз, ләкин тиз туябыз. Сабырлык җитми... Күңел яңадан-яңа нәрсә күрергә теләп ашкына тора. Язгы су кебек, бер урыннан икенче урынга ташланасы килә... Акрынлап булса да зур

үсәбез бит инде. Мондый вак уеннарның елдан-ел безнең өчен кызыгы китә бара... Зуррак, күңеллерәк, матуррак нәрсә күрергә кирәк. Кызык та булсын, батырлык та бирсен!..

Без урамның вак елгаларын, бала-чагаларын ташлыйбыз да тау астына котырынып аккан Морадым буена китәбез.

Шунда батырлык та, шунда матурлык та!..

Менә Морадым... Бу инде урам елгалары кебек аяк астында түгел. Ул киң, ул тирән... Ул хәзер безгә, каршыдагы тау кебек, беркемнең дә көче җитмәстәй зур бер көч булып күренә... Ул куркыныч... Аның янына безнең кебек малайларга барырга кушмыйлар. Аягыгыз таеп төшеп китәрсез, диләр... Әйе, төшсәң, чыгу юк инде...

Морадым елгасы безгә бик ерак җирләрдән агып килә. Башы кайдадыр, белмим. Тик безне үтеп, егерме чакрым киткәч, Димгә коя... Үзенә багышлап көйләр дә чыгаралар, күрмәгәннәр күрергә ашкыналар. Күргәннәр сокланып караудан туймыйлар... Бер минем үземнең дә, әткәйгә ияреп Дәүләкән базарына баргач, аны күреп ис киткән иде. Яр башыннан әллә никадәр вакыт сокланып, онытылып карап торган идем.

Ул аның еракларга җәелеп киткән тугаенда билдән үскән яшел үләннең акрын гына дулкынланып торуы... Ул тугайдагы түгәрәк күлләрнең күккә карап, күктәге ак болытлар шәүләсен төпләрендә йөздереп, кояшка каршы ялтырап ятулары... Ул ярга үскән куе талларның су өстенә иелеп, су төбендәге шәүләләренә тыныч кына карап торулары... Ул су читендәге озын яшел камышларның, бөгелеп, сыгылып, үзара акрын гына шаулаулары... Ә Дим, Дим үзе... Читләре ак, сары төнбоек чәчәкләре белән бизәлгән Дим, шундый матур, шундый тыныч... Аның суы да шундый тонык... Өсте зәңгәрсу, төбенә кадәр үтәдән-үтә күренә, ә төбе караңгыланып тора. Анда ләм үләннәре агым түбәненә сузылышканнар. Акрын гына селкенәләр... Ул артык тыныч, акрын гына бөдрәләнеп кенә ага. Тик ара-тирә зур балыклар гына сыртларын кояшта елтыратып шапылдап чумалар – аның тыныч йөзен бозалар. Ә ераклардан, бик ераклардан күгәреп күренгән биек таулар, зур йортлар матур Димгә, тыныч Димгәниндидер бер олылык биреп торалар...

Озак карап тордым. Бөтенләй онытылдым. Ат эчерергә барган идем. Бик озак басып торгач, атым ялкауланып җиргә ята башлады. Шуннан соң гына «уянып» урынымнан кузгалып киттем... Киткәндә дә бер-ике тапкыр артыма әйләнеп карамыйча түзә алмадым...

Үзем дә белмим, күкрәгемдә ниндидер бер дулкын күтәрелде. Ул дулкын минем йөрәктә, күзләргә яшьләр китерә торган тирән бер сөенеч булдырып ашкыну кузгатты, тәнгә җиңеллек бирде.

Димне күреп кайтканнан соң, мин үзебезнең таулардан, урманнардан, сулардан матурлык эзли башладым... Матур җирләр күргәч, минем күкрәгемдә әлеге дулкын күтәрелә. Ә мин шундый хәлдә калуымны бик яратам. Безнең Морадым да ямьсез җирләрдән акмый... Аның ике ягында да биек ярлар, зур таулар... Безгә каршы як калын урманнар белән капланган таулар тезмәсе. Безнең як теге якка караганда тәбәнәгрәк. Морадым буена сөзәк кенә сузылып төшкән калку җир. Үзе бөтен иңе белән вак куаклар...

Мин үзебезнең якны теге якка караганда ярата төшәм. Җәй көне безнең яктагы вак куаклыкта җиләк бик шәп була... Төбә җирләр, тау битләре ак, сары, зәңгәр чәчәкләр белән түшәлә... Ак мамык башлы озын кылганнар үзләреннән үзләре акрын гына дулкынланалар. Бөтен җирдән хуш ис, чирәм исе аңкып тора...

Мондый матур җирләр әле чак кар астыннан чыгып киләләр... Куак араларында пешкән җиләк урынына көз көне коелган сары яфраклар... Ачык җирләрдә чәчәкләр, кылганнар урынына кыш буе кар астында ятып черегән үләннәр... Чокырлар карлы су белән тулганнар...

Тау битләреннән кар сулары ташларга бәрелеп, сикереп, шаулап түбәнгә, Морадымга агып төшәләр... Бик еракларлан, тирән чокырлар буенча агып килгән Морадым тауларның, яланнарның кая барып, кая сеңеп бетәргә белмәгән кар суларын үз эченә җыеп, котырып таша... Җәй көннәрендә чокырның төбендә генә вак ташлар өстеннән акрын гына елтыр-елтыр килеп аккан елга хәзер ике яр арасына сыймый. Ул ярларны юа, тәбәнәгрәк урыннардан җир өстенә чыга, җәелә. Юлында туры килгән бөтен нәрсәләрне агызып алып китә... Елга шундый куәт белән ага, аның өстенә карап торуы куркыныч. Озак карап торсаң, үзең дә агып киткәндәй буласың... Ул кайный, ул шаулый. Аның яры кырында басып торсаң, бер сажин читтәге кешенең кычкыруын ишетеп булмый. Аның тавышы көн-төн калын урманлы тау буйларында, яланнарда яңгырап тора...

Әйе, Морадым, урам елгалары кебек, кәҗә бәрәненә охшамаган. Ул соклангыч матур түгел. Сикереп, нурлар белән уйнап акмый... Ул ярлар ашый. Ул ташларны агыза, күперләрне җимерә, буаларны ера. Ул шундый көч, аның белән уйнавы куркыныч. Якын бармыйсың, читтән генә аның батырлыгына сокланасың, көнләшәсең...

– Их, шундый көчле булсаң иде! – дисең дә өстенә карап онытыласың... Үзеңнең аның каршында бер йомычка кебек кенә булуыңны уйлап күңелсезләнәсең...

Ләкин юкка күңелсезләнү!.. Тиздән тыначак көчле елга булганчы, акрын гына үсеп, зур акыллы кеше булу артыграк бит!..

Бу мине куандыра... Мин усал чырай белән кайнаган елга янында шашып уйнарга, йөгерергә, сикерергә, кычкырырга телим...

Без Морадым буена дүрт малай төшкән идек. Көн иртә булганга, күрәсең, елга буенда беркем дә юк иде... Без, төшкәч тә, иң тәү Морадымның ташуына бик озак сокланып карап тордык. Соңра аның ташуы колакка, күзгә ияләшкәч, без аңардан туя башладык, тирә-якка каранырга тотындык. Берәр башка нәрсә күрәсе, кызык уен табасы килә башлады... Елга буе кояшка каршы тау бите булгач, кары күптән эрегән, кара җир кеше аягы белән тапталып, тап-такыр булып кипкән... Кузна уйнар өчен бик әйбәт.

Көн дә шушында төшеп уйныйбыз. Бүген дә, башка уен тапмагач, такыр җирдә кузна уйнарга булдык. Тик дүртәү генә булганга эчебез поша. Кузна уенында нихәтле кеше күп булса, шулхәтле күңелле була иде. Тагын да берничә малай кирәк иде, дибез. Шулай дип күңел күтәрелмичә, теләр-теләмәс кенә уен башларга торганда, Габдерәхим:

– Әнә тагын да ике малай килә, – диде. Елганың үр ягына төртеп күрсәтте.

Барыбыз да карадык. Ике малай килми, ә ике малай елгага карап басып торалар иде... Берсе иелеп ташмы, балчыкмы ала да елгага бәрә, ала да бәрә...

Без Габдерәхимне шелтәләп алдык:

– Нигә алдыйсың, килмиләр ич, басып торалар... – дидек.

Ләкин бу сүз безнең беребезне дә тынычландырмый. Алар киләләрме, килмиләрме – эш аңарда түгел, эш аларның булуында. Алар бар. Димәк, кузна уйнарга кеше артты. Хәзер күңелле була. Бигрәк тә чит малайлар булса. Үзара берләшеп, аларны отарга тырышып уйнавы тагын да күңеллерәк булачак. Тик хәзер аларны чакырып китерергә генә кирәк. Без җиргә утырткан кузналарны кире җыеп бишмәт кесәсенә салдык та, тиз-тиз йөгерешеп, алар янына киттек.

Барсак, ике малай; икесе дә Түбән авылдан килгәннәр. Берсе – мулла малае Хәмит, икенчесе көтүче Шәвәли бабайның улының улы Вәли иде.

Вәли түбәсе ертылып, эчендәге чүбекләре чыгып торган колаклы бүректән, култык аслары сүтек озын билле бишмәттән, яланаяк. Киндер ыштанының балаклары пычракка катып беткән. Аяклары ябык, суыктан күгәреп, зәңгәрләнеп тора... Әле җир суык, пычрак. Күп җирдә кар, ишегалларында боз... Ә ул яланаяк йөри.

Хәмитнең башында чугы төшкән, читендәге укасы сүтелгән, каешланып каралып беткән иске кызыл түбәтәй. Өстендә бик тупас тегелгән яшел бишмәт... Атасының искереп, көя төшеп беткән бер яшел поставы бар иде. Әнисе, шул җиләннең эчен тышка әйләндереп, Хәмиткә бишмәт тегеп биргән булган. Бишмәт бик тупас, бик ямьсез. Җиңнәре кыска, кулбашы төшеп тора. Үзе, чамадан тыш озын булып, тубыкка кадәр төшкән. Бишмәт яңа булуына карамастан, боты-чабуы пычракка батып та беткән инде. Аягында иске ботинкалар. Йөзенә пычрак потлап өелгән.

Без, барып туктагач та, алардан безгә ни өчен килүләрен сорадык. Морадым буйлап йөри торгач, менә сезгә килеп чыктык, диделәр. Артык сөйләнеп тормадык, сүзне уенга күчердек. Боларның кузналары бармы, юкмы икәнен белергә теләдек. Сораша торгач, боларның икесенә дистәгә якын кузна барлыгы беленде.

Вәли безнең кузна уйнарга дигән сүзебезгә тиз кушылды. Ләкин Хәмит никтер азрак кыстатырга теләде. Ул азрак күңелсезрәк тә күренә. Безнең, әйдә кузна уйнарга, дигән сүзебезгә дә озак җавап бирмичә торды.

Безнең Хәсән усал, телчән малай. Хәмитнең киреләнеп торуын күргәч үртәргә тотынды:

– Кузналарыңны җелеген суырырга саклыйсыңмыни, әй, бирән корсак! – диде.

Хәмит авыз эченнән генә нәрсәдер мыгырдады. Бары мин:

– Йә, Хәмит, кыстатма, кузналарыңны талап алмабыз, отсаң, барысы да үзеңә булыр, – дигәч кенә, артык бер сүз дә дәшмичә, теләр-теләмәс кенә безнең арттан иярде.

Мин Хәмиткә гаҗәпләнеп карыйм. Авылда чакта безнең арада ут кебек бер малай иде. Бөтен уенга катнаша, бөтен этлекнең башында тора, малайлар белән кырылышып сугыша торган иде. Уенда комсыз, әрсез булган өчен, үзенә «Ач бүре» дигән кушамат та биргәннәр иде... Ә хәзер без колхозга күчкәннән бирле, ул малайда әллә нинди үзгәреш сизелә... Дөрес, аның белән күптән уйнаганыбыз юк иде. Көз, кыш үтеп, менә яз көне беренче тапкыр үзе белән уйныйбыз. Малайның элекке сәләте булырмы, юкмы? Күрербез... Ләкин ул быltыр көздән бирле, безнең белән очрашкан саен, күңелсез була. Чырае сытык. Күзләре тоныкн карыйлар. Сораган сүзгә тиз генә җавап бирми. Сүзгә аз катнаша, читтә тора. Малайлар бер җиргә өелеп талашкан, сүз көрәштергән арада, ул тиз генә әллә кая сыза.

Бу үзгәрешнең сәбәбе нәрсә?! Белмим!

Былтыр җәй аның атасы (Габделхак мулла) бер базардан исереп кайтып, урамга чыгып, Сәвитне сүгеп, силсәвит персидәтеле Нури абзыйның тәрәзәләрен таш белән бәреп ваткан иде. Шуның өчен үзен бер елга төрмәгә яптылар. Бу хакта бөтен авыл, бөтен тирә-як: «Мулланың бөтенләй ташы кызган икән», – дип шауладылар. Хәмитнең кая барса, шунда малайлар күзен ачырмадылар. Ирештереп, теңкәсен корытып, елатып бетерделәр.

Әллә шул хәл малайның телен кисте, куәтен суырды, әллә соңгы вакытлардагы ярлылыклары (атларын, кара-каршы салган өйләренең урам ягын саттылар) малайны бик басты... Белмим, нәрсә булды... Ләкин ни булса да булды, Хәмит үзгәрде. Усал, шаян Хәмит урынына хәзер салкын суга манып җибәргән, күшеккән тавык шикелле боек, сүзсез Хәмит калды.

Теләр-теләмәс башланган уенда да ул үзен күрсәтә алмады. Биш кузнасы бар иде, өч уенда оттырып бетте. Ике рәт Вәли кузнасы белән уйнап карады. Анда да Вәлинең дүрт кузнасына зарар гына китерде.

Ул, уеннан чыккач, бер сүз дәшмичә читтәге кыска юан бүрәнә өстенә барып утырды да безнең уйнаганны карап тора башлады.

Аңардан соң без дә озак уйнамадык. Малайларның кесәләрендәге бөтен кузналар тиз арада Хәсән белән минем кулга күчеп беттеләр. Безнең кесәләр кузна белән тулдылар. Йөргән чакта, асып куйган капчык кебек, ботка бәрелеп уңайсызлый башладылар.

Без дә бүрәнә башына җыелдык... Кузнаны күп откач, Хәсәннең кәефе шәп иде. Электән үк телчән малай, хәзер кәефе килгәч, кайдан сүз башларга белми тора... Бүрәнә янына килеп туктагач та, Хәмиткә бәйләнә башлады:

– Малайлар, Хәмит нигәдер бүген бик боек, сәдака бирик үзенә, кәефе ачылмасмы? – диде дә, ыштан кесәсенә тыгылып, акча эзләгәндәй бик озак кесә төбен капшап, акрын гына йодрыгын чыгарды да Хәмитнең борынына терәде.

Малайлар акырышып көлделәр.

Ә Хәмит бер сүз дә дәшмәде.

Хәмитнең дәшмичә калуы Хәсәнгә бер дә ошамады. Ул үзе кебек каршы әрепләшкән малайны ярата. Әле дә Хәмитнең дәшмичә калуына ачуы килде бугай, ныграк бәйләнергә тотынды.

– Бу бер дә атасына охшамаган икән. Атасы сәдака күргәндә дөньясын оныта торган иде, ә бу бөтенләй алмый да... Әллә безнең сәдаканы яратмады инде... Кара әле, атаң урынына мулла буласыңмы? Ул чакта сәдака итеп йодрык бирмәсләр, акча бирерләр. Бәлеш тә ашатырлар. Тамагың тук, корсагың зур булыр...

Габдерәхим, ашыгып, Хәсәннең сүзен бүлде:

– Ул каргаларга нинди бәлеш булсын, хәзер аларга үләксә дә юк...

Вәли, Хәмитне яклагандай:

– Каргалар дисең, нишләп каргалар булсын, кешеләр ич! – диде.

Габдерәхим, тотлыга-тотлыга, үз сүзен расларга кереште:

– Каргалар шул... Мин китаптан, әй, китап түгел лә... тукта... әллә ничек кенә иде... хәзер... хәзер менә... ә, исемә төште, журналда күргәнемне сөйлим. Абзый бер журнал алып кайткан иде. Шунда бер мал үләксәсе төшерелгән. Аның янында бик күп чалмалы кара каргалар... Кайсы үләксә өстендә чукый, кайсы очып килә... бик күп үзләре. Бар да чалмалылар... Сурәт астына «Муллалар үләксә янында» дип язып та куелган ишшу...

Хәсән бик кәефләнеп көлеп җибәрде:

– Чалмалы каргалар, чалмалы каргалар. Ну шәп исем биргәннәр дә соң үзләренә... Әй, кара әле, син дә чалмалы карга буласыңмы, үләксә чукырсың!..

Хәмит һаман дәшми. Ул, селкенүдән курыккан шикелле, бер килеш катып тора. Күзләре туктаусыз бер ноктадан икенче ноктага күчә. Ирен читләре калтырый, авызы ерылырга тора.

Хәсәннең Хәмитнең шундый нык тискәреләнеп дәшми торуына артык ачуы килде булса кирәк:

– Нигә дәшмисең, телеңне йоттыңмы әллә? – диде, ныгытып якасыннан тартты, аз гына эләгеп торган төймә очып ук китте.

Хәмит түзмәде. Авызын җәеп бераз гына торды да үксеп елап та җибәрде. Җиңе белән битен каплап артына әйләнде дә китә дә башлады. Барыбыз да, аптырашып, бер-беребезгә карадык. Һич көтелмәгән эш! Хәмиттә беренче тапкыр мондый хәл күрәбез. Сугыша-сугыша битләре тырналып, борыннары канап беткәндә дә ул еламый иде. Безнең арада моңарчыга кадәр каты бәгырьле усал малай булып танылып йөри иде. Әле дә артык юаш күренүенә карамастан, Хәсәннең бу усаллыгына башкачарак җавап кайтарыр дип көтеп тора идек... Бу бөтенләй әллә ничек булып китте. Бер дә ышанасы килми. Юри кыланамы икән әллә, дип, артыннан карыйбыз.

Ул акрын гына китеп бара. Башын түбән игән. Җиңе белән йөзен каплаган. Үксегәнгә, ахры, кулбашлары акрын гына сикерәләр... Башында иске түбәтәй. Өстендә – озын, ямьсез, кулбашлары төшеп торган яшел бишмәт. Чабулары пычракка катып беткән.

Ул миңа әллә ничек кызганыч булып китте. Үзе генә түгел, шул өстендәге килешсез киеме дә безгә рәнҗегән төсле тоелды. Минем кәеф бозылды... Хәсәнгә ачуланып:

– Нигә аны тиктомалга елаттың инде? – дидем.

Хәсән миңа аптырап карады. Ә Габдерәхим тотты да үземне сүгә башлады. Аптырап караган күзләрен елап китеп барган Хәмиттән алып миңа юнәлдергән башкалар да Габдерәхимнең сүзенә кушылып киттеләр:

– Тапкансың кызганыр кеше. Оныттыңмыни, әле быелтыр көз генә бит Искәндәр белән икесе көтүче Саттар абзыйның улы Тимергазыймны, атаң безнең сыерны әллә кайда адаштырып калдырган, ике атна буе эзләп һаман таба алмыйбыз, дип, чукмар белән кыйнаганнар иде. Алар шулай үзләренең үчен генә түгел, аталарының үчен дә кешедән алалар. Ялгызың барып чык әле син алар янына, кабыргаларыңны култык астыңа кыстырып кайтырсың. Ярый әле без аңардан иске үчләрне кайтармадык. Шуңарга рәхмәт әйтсен... – диделәр.

Миңа уңайсыз булды. Мин кызардым. Мин иптәшләргә каршы бер сүз дә әйтә алмадым. Алар дөрес сөйлиләр иде. Мулла, сатучы малайларының гадәте шул инде. Алар көчләргә

җыелалар да үзләре өчен дә, аталары өчен дә, кардәшләре өчен дә кешене эт итеп кыйнаудан тартынмыйлар. Беркөн дә кулак Хисам, Хаммат малайлары безнең арттан, колхозыгызның көле күккә очар әле, дип йодрык селкеп калганнар иде. Алар шул аталарының сүзләрен сөйлиләр инде. Югыйсә малай башлары белән колхозга шулкадәр дошман булырлар идемени?

Безнең абый да, җыелыш булган саен:

– Иптәшләр, хәзерге көндә кулактан сак булыгыз. Ул, әкияттәге юха җылан кебек, матур кыз сурәтенә дә, изге карт сурәтенә дә, аждаһа сурәтенә дә керә белә, – дип кат-кат әйтә.

Кем белә, мулла, кулак малайлары да, аталары кебек, төрле сурәткә керә беләләрдер. Хәмит тә шулай безнең алда гына боек, юаштыр. Үзләренең яннарына барсаң, ул да элекке кебек усал эт шикелле буладыр.

Кояш түбәнәя. Морадым һаман шаулый. Тау битендәге шарлавыклар хәзер соңгы кояш нурларына каршы чәчриләр, ут шарларыдай елтырап-елтырап, түбәнгә таба атылалар.

Без бүрәнә өстендә сөйләшеп утыра торгач, күпме көн үткәнне дә сизми калганбыз. Торып карасак, кояш баеп бара, имеш. Мин:

– Әй, малайлар, бик күп вакыт үткән бит. Әллә кайтабызмы? – дисәм дә, сүземә кушылучы булмады.

Бар да:

– Бу вакыт җиткәч кайтабызмы соң?! Хәзер җегетләр гармун белән төшәләр! – диештеләр.

Тамак ачса да, артык кайтасы килми иде. Иптәшләр белән су буенда кала бирдем.

Язның кичке һавасы артык суык та, җылы да түгел. Шундый саф, сулаган саен, йөрәккә җиңеллек бирә... Күк йөзе зәңгәр, аяз. Ул бик киң, чиксез... Әллә кайлардагы, ераклардагы күгәреп күренгән сыртлар, таулар гына аның белән тоташканнар... Ул сыртлар артында әйтерсең зур янгын бар, күкнең сыртларга тоташкан буйлары шул янгынның шәүләсе белән алсуланганнар, кызылайганнар...

Без, җегетләр, төшәргә бераз вакыт бар әле, дип, бүрәнә өстенә җайлабрак урнаштык. Вәли, кунаклаган тавык шикелле, бүрәнә өстенә чүгәләп, яланаякларын бишмәт чабуы белән урап, каплап утырды.

Мин Морадымга карап онытылдым... Ул ага. Аның агымына ияреп, минем уйлар да ага... Уйларым ерак киттеләр, Морадым шикелле тиз актылар. Хәмиттән башланган уйларым тиз арада каладагы Сарага да барып җиттеләр. Сара исемә төшкәч, мин бөтенләй онытылдым. Янымдагы иптәшләремне сизмәдем. Алар минем өчен юк булдылар. Морадымның кайнап

шаулавы минем күз алдымнан югалды. Тик аның югарыга чәчрәгән тамчылары арасыннан Сараның миңа елмаеп карап торуы гына күренде.

Сара – кала кызы. Унбер-унике яшьлек кенә пионерка. Былтыр көз, әнисенә ияреп, безнең авылга килгән иде. Әнисе аның безнең авылда сельсовет сайлауларын үткәрү өчен каладан килгән бер делегатка иде. Ул хатынның исеме Сәрби иде... Сәрби апа бездә кызы белән дүрт кич кунды.

Кызы Сара. Кара чәчле, зур кара күзле, шаян гына, тере генә пионерка. Әнисе кебек эшлекле дә үзе... Берничә тапкыр безнең мәктәпкә барды. Вожатыйга кушып, пионерларны җыйдырды. Әллә кайчангы бер иптәш кебек, аларның нәкъ урталарына кереп, төрле уеннар, җырлар өйрәтте. Бөтен бала-чагаларны яланнарга, су буйларына ияртеп алып чыкты. Анда ул җәй көне кояштан ничек файдалану турында һәм әлеге теге буржуй малайлары – скаутлар белән сугышкан чакта яраланган пионерларга ничек ярдәм итәргә кирәклеге хакында күп кенә кызыклы сүзләр сөйләде.

Аның шундый күп белүен, терелеген күргәч, безнең шикелле вакларның гына түгел, зур җиңгәйләр, әбиләрнең дә күзләре шар булган иде. Бездә торгач, инде мин аның белән башкаларга караганда ныграк якынайдым, дуслаштым. Ләкин никтер башта мин аның янында уңайсызлана идем... Ул шундый тере, минем кулларымнан тота, яшь бала шикелле җитәкләп йөртә башлый. Ә мин чабатам башына карыйм да чөгендер кебек булам. Үз гәүдәм үземә артык тупас булып тоела. Авызымнан сүзем чыкмый...

Башта шундый уңайсызлыклар белән җәфа чиктем... Ләкин соңгы бер-ике көндә мин аңарга бөтенләй ияләшеп беттем. Урамга чыксак та бергә, йортка керсәк тә бергә, мәктәпкә барсак та бергә булдык.

Мин башта кыюсызланып, оялып торган малай, хәзер борып җибәргән машина кебек сөйлим дә сөйлим... Ә ул туктаусыз көлә, кайчак шундый нык көлә, зур кара күзләренә яшьләр килә... Үзе, атлаган саен:

– Локман! Син бик кызык малай. Синең белән күңелле! – ди торган иде.

Ул китте... Ә мин аны озак вакытлар оныта алмыйча йөрдем. Көздән соң кыш үтте. Менә яз да җитте. Байтак вакыт!.. Сара истән дә чыга башлаган иде инде.

Ләкин күптән түгел генә булган бер вакыйга аны тагын минем күз алдыма китереп бастырды. Яңадан мин аны уйлый, сагына башладым.

Вакыйга шундый: әнә теге без орлык ташып йөргән вакытларда абзый, Әделгәрәй абзый, Мәрдан бабай калага барганнар иде. Абзый, кала урамында йөргән чакта, Сәрби апаны очраткан. Сәрби апа, абзыйны күптәнге дус кешедәй күреп, үзләренә кунакка алып киткән.

Абзый барганда, Сара өйдә булмаган. Менә бервакытны ул – ак башлыклы, ак шарфлы, суыктан алсуланган яңаклар, янар күзле кызый укудан күтәренеп кайтып кергән... Абзыйны күрүгә, муенына ташланган. Шундый куанган, һичбер баскан урынында тора алмый, ди. Бөтен авыл малайларын, кызларын, бигрәк тә мине сорашып, абзыйның теңкәсен корытып бетергән. Абзый китәргә җыенгач, Сара, әнисе белән базарга чыгып, бер дистә китап белән бер шахмат сатып алган. Шуларны абзыйга:

– Менә бу Локманга бүләк... Ә менә бу китаплар отряд көтепханәсенә... Алар да сезнең мәктәптәге пионер иптәшләргә миннән бүләк, – дип биреп җибәргән.

Бүләге белән хаты да бар иде. Хатында «Локман! Син элеккечә шатмы, уйныйсыңмы, көләсеңме, укуларың ничек бара?.. Мәктәптә ниләр эшлисез, пионерлар, дәрестән артта калмыйсызмы?.. Көз көне бергә уйнап йөргән Габдерәхим, Гали, Хәсән, Сабит, Разыя, Рәсиләләр хәзер ни эш бетереп яталар? Алар мине онытканнардыр да инде!? Менә бу китапларны отрядка илтеп биреп, мине исләренә төшер, яме!? Кара әле, Локман! Икенче тапкыр, абыең шәһәргә килгәндә, син дә ияреп кил. Безнең шәһәрне күрерсең, безнең эшләр белән танышырсың, күңелле булып калыр... Мин сине бер дә онытмыйм әле, ә син мине күптән оныткансыңдыр инде, шулаймы?! Мин менә сиңа шахмат җибәрәм. Шуңарда уйнаган саен, мине исеңә төшерерсең, яме!?» дигән. Бу сүзләрне укыгач эсселәнеп киттем. Яңакларым алсуланды. Ә йөрәкне кая куярга да белмим. Ул көнне көннең ничек үткәнен сизмәдем. Ләкин шул көнне ачуымнан үксеп җылап, үз-үземне өзгәләрдәй булдым.

Безнең әткәй дә, әнкәй дә иске кешеләр. Бигрәк тә әнкәй күгәргән бер тиен кебек... Алар яңалыкны аңлап бетермиләр. Ә әнкәй бөтенләй аңламый.

Абый бүләкне чыгарып салгач, әнкәй шахматны күрде дә:

– Бу нинди шакмаклы такта? – ди.

Абзый әйтә:

– Ул коры шакмаклы такта гына түгел. Ул шахмат дигән уен. Менә аның матурлап ясаган, өстенә тезә торган әйберләре дә бар, – ди.

Әнкәй кабатлап сорый:

– Нәрсә дисең?

– Шахмат, дим, шахмат.

Әнкәй авызын ачып тыңлый, ә шул бер сүзне отып алып кала алмый. Абый ничә кат кабатласа да, ул ота алмады. Ахырда үз исемен бирде.

– Ярый, мин сез әйткәнчә әйтмәм инде. Шәяхмәт кенә дип йөртермен, – ди. Һәм шуннан соң минем шахматны «Шәяхмәт» дип йөртә дә башлады.

Өйдә абзый белән озаграк уйнап утырганда, миңа ачуы килгән саен ул:

– Шул Шәяхмәтеңне пичкә ягармын әле, шул Шәяхмәтең белән башыңны сугып ярырмын әле, – дип кыза.

Әткәй белән абзый аңардан көләләр...

Әйе, болар бар да көлке... Ә менә миңа ул бүләкнең бик зур ачысын да татырга туры килде.

Шул ук көнне әткәй чәй янында әнкәйгә:

– Карале, карчык. Бу кала кызы безнең Локманга бүләкләр җибәреп, хатлар яза башлады бит әле. Әллә, мин әйтәм, безнең киленебез булырга чамалый микән, дим. Локманны кала кызына өйләндерсәк, первой сорт кешеләр булыр идек, – ди.

Әнкәй шул сүзгә күзләрен мөлдерәтә башлады.

– Ходай язган булса, ике сабыйның күңеленә мәхәббәт орлыклары чәчелгән булса өйләндерербез дә шул. Кала кызы хәзер безгә тиң түгелмени, менә дигән киленебез булыр, – ди.

Бу сүзләр миңа шундый начар, пычрак тоелдылар, әйтерсең, ашап утырганда, авызыма таракан эләкте... Мин әткәй белән әнкәйгә шашкан кебек акаеп карадым. Ачуымнан кара көйдем. Ашап утырган икмәгемне күтәреп бәрдем дә, сикереп торып, чәйле чынаякларны аударып, ишеккә ташландым, атылып чыгып киттем.

Лапас янына бардым да баганага сөялдем... Авызымны тыя алмыйм, ул җәелә. Керфек төпләрем кайнарлана, эре-эре яшьләр яңагым буйлап түбәнгә таба тәгәриләр. Кулбашларым сикерә башлый...

– Сара! Ул шундый матур, шундый акыллы. Мине дус күрә. Минем белән уйнарга, көләргә ярата. Әгәр дә бу пычрак сүзләрне ишетсә, гомердә әйләнеп тә карамас, минем өстемә төкерер... Килен, диләр. Шундый яшь кызны Мөхәммәтша абзыйның елак баласы хатыны итмәкче булалар... Ә мин, ә мин аны теләмим!..

Ул көнне мин озак еладым, ачыла алмадым. Әнкәй белән әткәйнең күзенә күренмәдем. Очраган хатыннардан, киленнәрдән читкә качтым. Ә Сара турында уйлаудан курка башладым. Аның турында уйлый башласам, әлеге кабахәт «килен» дигән нәрсә килеп бутала да минем уйларымның бөтен тәмен җибәрә.

Бераз вакытлар үтә.

Мин бу күңелсез хәлне акрынлап оныта башлыйм.

Кичә әле абзый белән икәү абзарга тулган суны канау казып агызып йөргәндә, ул һич көтмәгәндә Сара турында акрын гына сүз башлады:

– Син, Локман, Сараны бөтенләй оныттың, ахры, – ди, – ул сиңа хат язды, бүләк җибәргән булды. Ә син бер җавап та язмыйсың. Ул килешә торган эш түгел. Анасы Сәрби ападан да яхшы түгел... Без үз итеп, якын күреп торабыз, ә алар санга да алмыйлар, диярләр, үпкәләрләр. Аннан соң, Сара бик акыллы кыз бит ул. Аның белән хат язышсаң, үзеңә файдасы булыр... Әнкәйләрнең сүзенә син колак салма. Син бит кечкенә бала түгел инде. Аларның безнең өчен бер тиенлек әһәмияте булмаган кирәксез сүз сөйләүләрен аңларга кирәк, – ди.

Абыйның бу сүзләре миңа бик ошады... Мин үземне үзем ачуланырга керешәм: шушы көнгә кадәр мин шуларны уйлап та карамаганмын. Әнкәйнең үзеннән башка беркемгә яраксыз көлке сүзләреннән өркеп йөргәнмен...

Их җүләр, җүләр!!! Ә Сара чыннан да үпкәли булыр. Хат көтәдер, килмәгәч пошынадыр... Ә мин, җүләр, шуны сизмичә йөрим... Язам, язам, күп иттереп язам. Җәйгә үзебезгә – колхозга кунакка чакырам. Күрсен безнең колхозны. Күрсен андагы яңа эшләрне, яңа кешеләрне, яңа матурлыкларны. Тагын да безнең уртада булсын, кала кызы белән колхоз малайлары бер-берсенә карап сөенсеннәр!

Иптәшләр дә бик еш:

– Карале, Локман, теге көз көне килгән Сара тагын да килми микән, белмисеңме? – дип сорашалар. Алар да сагына булырлар.

Иртәгәдән соңга абзый тагын калага бара. Шуңарчы хатны өлгертеп куярга кирәк.

Их, нинди күңелле! Сара хатны алыр, ачып укыгач, күбәләк кебек очынып китәр. Шатланыр, туктаусыз елмаер, көләр...

Әле дә ул миңа елмаеп карап тора...

Мин уйларым белән бөтенләй онытылганмын. Хәсән бер-ике тапкыр дәшкән, ишетмәгәч, аркага төртә.

– Карале, Локман, йоклыйсыңмы әллә, нигә дәшмисең? – ди.

Мин сискәнеп әйләнеп карыйм. Малайлар көлешәләр.

Уйларымнан кире кайтам. Тирә-якка каранам... Кояш баеган. Җир өсте караңгыланып килә. Каршыдагы таулар, урманнар юка гына кара пәрдәгә төренгән төсле тоныкланып күренәләр... Морадым шаулый. Тик аның югарыга чәчрәгән тамчылары хәзер ут шарлары кебек елтырамыйлар инде.

Артта аяк тавышлары ишетелде. Әйләнеп карасак, Сәләхи абзый белән Кәрим абзый аллы-артлы таудан йөгерешеп төшеп киләләр. Кулларын җәйгәннәр, шундый каты йөгерәләр, бөтенләй җирне селкетәләр... Безнең янга килеп туктау белән, Сәләхи абзый, тынына буыла-буыла:

– Нәрсә сез, җир козгыннары, монда тезелешкәнсез, нишләп утырасыз? – ди.

Хәсән җавапка аптырамый:

– Морадымны саклап! – дигән була.

Алар бүрәнәгә утырып кесәләреннән тәмәке янчыкларын чыгарырга өлгерә алмадылар, арттан тагын көлешкән, сөйләшкән, гармун тарткан тавышлар ишетелде.

Таудан дүрт җегет төшеп килә. Фәхри белән Гыйззәт алдан, Фәхри кечкенә гармунының каешын кулбашына кигән. Үзалдына нindидер бер җиңел генә көйгә акрын гына, шаяртып кына тарта... Алар артыннан абзый белән Әделгәрәй абзый нәрсә турындадыр бик кызу-кызу сөйләшеп киләләр.

Алар төшүгә, без урыннарыбыздан куптык.

Абзыйлар, бүрәнә өстенә утырышкач та, кызу бәхәсләреннән туктамадылар. Аларның бәхәсләре гел бер нәрсә тирәсендә әйләнә... «Әлеге дә баягы, сукыр суфи таягы» дигәндәй, болар да шул тоталар да әлеге бер колхоз турында сүз көрәштерә, әрепләшә башлыйлар.

Әле дә минем абый белән Әделгәрәй абзый, һичкемгә карамастан, һичкем белән хисаплашмастан, икәү генә дөнья җимереп талашалар.

Үткән ел гына, «колхоз» дигәч, «Әллә шул!» дип җилкәләрен кашый торган агайлар быел барысы да «колхозга кучәргә кирәк» дип йөриләр икән. Безнең авыл бөтенләй аякка баскан. Агайлар барысы да, быел яз бөтен авылыбыз белән колхозга күчәбез, диләр, имеш. Абый белән Әделгәрәй абзый менә шул турыда талашалар.

Әделгәрәй абзый әйтә:

– Авылның тоташ колхозлашуы бик шәп эш, – ди. – Әллә кайчан кирәк иде. Ул турыда сүз дә булырга тиеш түгел... Син мине аңлап бетермисең. Эш менә нәрсәдә, – ди. Бармакларын тотып саный башлый: – Беренчедән, без – үзбашыбызга колхоз булып оешкан кешеләр. Без – егерме биш йортлык колхоз. Үзебезнең җиребезне кистереп алдык. Үзебез хәзер бер семья булып эшләп ятабыз. Колхозыбыз акрынлап байый, ныгый, исеме белән генә колхоз булмыйча, эче белән дә колхоз булып бара... Шуңар күрә без авылның колхозлашуына кушылмаска тиешбез. То есть без авылга кире кушылып, аннан яңа кешеләр алып, яңадан җирләр кистереп, өр-яңадан яңа колхоз булып маташмаска тиешбез. Алай итсәк, безнең эшебез акрынлый, кыенлаша. Аннан соң безнең арага таркаулык керә. Без хәзер менә, бер семья кебек, бер-беребезгә шундый якын кешеләр. Ә яңа кешеләр белән без алай була алмыйбыз. Алар безгә ияләшмәгәннәр. Алар безнең тормышка, эшкә таркаулык кертәләр. Икенчедән...

Абзый тыныч кына тыңлап утыра иде. Шулай да Әделгәрәй абзыйга «икенчесен» сөйләргә ирек бирмәде, аның сүзен бүлде:

– Тукта, икенчесен соңыннан сөйләрсең, иң элек беренчесенә җавап бирим әле, югыйсә син бөтенләй киртәдән чыга башладың. Дөресен генә әйткәндә, Әделгәрәй, син бер дә колхозчы сүзләрен сөйләмисең. Һаман да үзеңдә искелекнең шәүләләрен саклыйсың. «Мин», имеш, «без», имеш, «семья», имеш. Болар бар да үземчелек бит. Иң элек син шуны аңла: безнең колхозыбыз бервакытта да чын мәгънәсе белән колхоз булып бетә алмый. Һәркайчан, син әйткәнчә, бер тар «семья» гына булып кала. Ә тар семья ул бервакытта да күмәк тормыш та, яңа кеше дә тудыра алмый. Чөнки аның хуҗалыгы кечкенә, эшләүче көче аз. Ә эшләү көчең никадәр аз, зәгыйфь булса, аның тормышка йогынтысы да шулкадәр начар була... Аннан соң син, яңа күчүчеләр безгә ияләшмәгәннәр, арага таркаулык кертәләр, дисең. Колхозга күчкәч тә, әллә син үзеңне яңадан анадан тудым дип уйлыйсыңмы? Юк әле, җегет, барыбер шул кичәге Әделгәрәй әле син. Моннан алты ай элек Саттар көтүче белән бик тату күрше булып яшәгәнсез бит, хәзер дә яшәрсез. Сезнең әле берегез тычкан, берегез песи булып өлгергәнегез юк, икегез дә бер җәнлек... Тагын син авылның тоташ колхозлашуыннан читтә торып калырга телисең. Монысы бөтенләй ярый торган эш түгел... Без колхозчыларга бу эшнең башында торырга кирәк...

Әделгәрәй абзый салкын гына, ашыкмыйча гына абыйның сүзен бүлә:

– Башында торасың аны... Ләкин үзең яңадан колхозлашып маташмыйсың.

Абзый кызыбрак тотына:

– Ул башында тору булмый, ул койрыгында торудан да зарарлырак бер нәрсә... Әгәр дә син чын-чынлап колхозчы булсаң, менә шушы түбәндәгеләрне бервакытта да хәтереңнән чыгармаска тиешсең. Иң элек үзең колхозлашу белән генә җилкәдән бурыч төште дип уйлама. Үзең колхозлашу белән бергә башкаларны да колхозлаштыру юлында көн-төн эшләп тирең чыксын!.. Аннан соң һәрвакыт, һәр җирдә колхозлашкан чакта колхозларны эреләштерүне алга сөрергә кирәк. Эре колхозлар дөньяга тудырмыйча торып, без үзебезнең теләгебезгә ирешә алмыйбыз... Тоташ колхозлашу хәзерге көннең иң зур, иң беренче бурычы. Без бу эшнең башында торып, бөтен нәрсәне колхозлашучы масса файдасы күзлегеннән карап хәл итәргә тиешбез. Әгәр дә бөтен авыл, бөтен волость тоташ колхозлашканда, без, егерме биш йортлык колхоз, ялан уртасында ялгыз утырып, «безгә якын килмәгез, безгә тимәгез» дип торсак, ул көлке дә, ахмаклык та булыр иде. Безгә һәрбер төрле чикләнүне җимерергә кирәк. Шунсыз без үзебезне бу бөек эштә күрсәтә алмыйбыз.

Әделгәрәй абзый абыйга каршы тагын да нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачкан иде, сүз башыннан бирле эчләре пошып, сабырларын җыеп утырган Сәләхи, Кәрим, Гыйззәт абзыйлар, кулларын селтәп, аны ачуланырга керештеләр:

– Ташла, зинһар, җүләр саттырма... Биш яшьлек сабый түгелсең ләбаса!

Әделгәрәй абзый аларга каршы:

– Спорный эш бит, җегетләр, нигә сөйләмәскә?! – дип караса да, аңарга сөйләргә ирек бирмәделәр:

– Куй, юкны сөйләмә. Нинди спорный ди ул?.. Мансурның сөйләгәннәре акка кара белән язган шикелле дөрес нәрсәләр. Аны син түгел, Мәнди анасы да белә... Үзеңнең кирелегеңә барасың! – диделәр.

Гыйззәт, шуңарга ялгап:

– Йә, җегетләр, ташлагыз! Без су буена Мансур белән Әделгәрәйнең тәкә сөзештерүләрен карап утырырга төшмәдек лә, – дип өстәп куйды.

Абый кәефләнеп көлде.

– Дөрес, дөрес, Гыйззәт. Су буе дөнья уе түгел, йөрәк туе...

Гыйззәт бөтенләй җибәрелде:

– Әйтерең бармы, авызың-борының кыйшайтып, Мансур дус! Ә ну, син, Фәхри, тарт әле. Су буен уятыйк әле, бер булмаса. Кызлар уенына барыр вакыт та җитеп килә. Их, мать чисный! – диде, бармакларын шартлатып алды.

Фәхри гармунда моңландырып «Күбәләгем-түгәрәгем» көен уйный башлады. Ул бер кат уйнап чыкканчы бар да тып-тын булып тордылар.

Күктә тулган ай... Җирдә агач күләгәләре... Күләгәләр астында куе караңгылык, аз гына читкә китеп карасаң, ул караңгылыкта нәрсә бары күзгә күренми. Чак кына тыңласаң, нәрсәдер кыштырдаган төсле тоела...

Ай бик югары, бик якты. Җир өсте көндезге кебек, ләкин тып-тын. Шуңар күрә тонык, моңсу күренә.

Морадым – тыңласаң шаулый, уйласаң, әллә кая була... Әле мин аңарга карадым. Ул шундый кайный, аның төсен дә аерып булмый. Ай шәүләсе Морадымга аркылы сузылып төшкән. Суның караңгы, усал чырае ай яктысыннан яшен тизлеге белән елтырап-елтырап үтә... Үзе усал тавыш белән үкерә, әйтерсең, айның гамьсезлегенә ачуы килә...

Әйе, Морадымның ачуы килә... Ә табигатьнең аңа исе китми, ул үзенчә «көн күрә». Кояш белән терелеп кайнаган иде. Хәзер карт әби итәгендә оеп йоклаган бала кебек, айның моңсу карашы астында тирән тынычлыкка чумган...

Гармун тавышы рәхәтлеккә талган табигатьне сискәндергән төсле булды. Тирә-якка карандым. Ләкин тирә-як хәрәкәтсез иде. Ахры, үзем сискәнгәнгә күрә генә шулай тоелгандыр...

Ә гармун тавышы ул язгы суның җырлавына да охшап китә... Аның тавышы бик тиз, бик тиз, язгы елгадан да тизрәк еракларга йөгерә. Ләкин аның тавышы шундый матур, моңлы,

йөрәкне җилсетеп, дулкынлатып үтә. Кояшның җылы нуры кебек бөтен канга тарала. Йөрәктә генә түгел, бөтен тәндә дулкын башлана...

Гыйззәт абзыйның дәртчел булуын мин яратам... Менә ул гармун көенә бер тапкыр уйнап, икенче тапкыр башлауга җырлап та җибәрде:

Җегет бодай җилгәрә,
җил күтәреп җибәрә,
*Йөрәгенә чыдый алмый –*
*күбәләгем-түгәрәгем,*
*Асыл кошым, сандугачым,*
*җегет җырлап җибәрә.*

*Йөрәгенә чыдый алмый –*
*күбәләгем-түгәрәгем,*
*Асыл кошым, сандугачым,*
*җегет җырлап җибәрә.*

Сәләхи абзый Гыйззәткә дәрт бирә:

*Әйт шуны булмаса...*

Гыйззәт тагын башлый.

Башкалар аңар кушылалар:

*Апрель җитми агып бетми*
*Агыйделнең бозлары,*
*Авылыбызның матурлары,*
*күбәләгем-түгәрәгем,*
*Асыл кошым, сандугачым,*
*комсомолка кызлары.*
*Авылыбызның матурлары,*
*күбәләгем-түгәрәгем,*
*Асыл кошым сандугачым,*
*комсомолка кызлары.*

Җырлар артыннан җырлар тезелә. Көр тавыштан бөтен су буе яңгырап тора. Морадым бөтенләй онытыла.

Фәхри абзый, тоташтан берничә көй уйнап, бармаклары арыгач туктый. Кулларын селкеп, бармакларын шартлаткалап, җегетләрдән тәмәке сорый.

– Кая, кайсыгызда бар, чыгарыгыз әле. Булмаса, бер төтәсләп алыйк, сусын басылыр.

Сәләхи абзый белән Гыйззәт янчыкларын чыгаралар. Бар да тәмәке төрергә керешәләр.

Гыйззәт, кәгазен иренենә ябештереп, башкаларга тәмәке өләшә-өләшә:

– Җегетләр, давай кузгалыйк. Вакыт үтә бит, анда ду китереп уйныйлардыр инде. Кызларыбыз юксына башларлар, – ди.

Әделгәрәй абзый акрын гына:

– Ашыкма, өлгерерсең. Синең белән мине казан асып көтмиләрдер әле, – ди. Сабыр итәргә куша.

Сәләхи абзый, тәмәкесен кабызып, тирән генә бер суыра да икенче сүз башлый:

– Җегетләр, әле күптән түгел генә Каран авылының ызбачы, ВИК члены комсомол Латыйфның үтерелүен ишеткән идек бит?!

– Хуш, шуннан соң?

– Менә шул. Өченчекөн ВИКка баргач, Каран укытучысы, әлеге теге яшь җегет Касыймны очраттым. ВИК президиумының утырышына килгән икән. Бик озак сөйләшеп утырдык. Ул шунда Латыйфның ничек үтерелү вакыйгасын сөйләде... Үзләре бер йортта торганнар да икән.

Бар да бу яңа хәбәр белән кызыксыналар. Бар да Сәләхи абзыйга дикъкать белән карыйлар.

– Йә, йә, сөйлә тизрәк! – дип ашыктыра да башлыйлар.

Сәләхи абзый, сөйлисе сүзенең кадерен яхшы белгәнгә күрә, артык ашыкмый, тәмәкесен тәмләп кенә бер-ике тапкыр суыра. Читкә борылып төкерә. Морадымга текәлеп бераз карап тынып тора да, акрын гына сөйли башлый:

– Мин сезгә Латыйфның нинди сәбәпләр аркасында, кемнәр тарафыннан үтерелүен сөйләмим. Аны сез үзегез дә яхшы беләсез... Ул март башларында гына өч кулакны, советка каршы коткы таратулары өчен, авылдан кудырды... Күптән Латыйфка тешләрен кайрап йөргән кулаклар бу вакыйгадан соң сабырларын җуйдылар. Латыйф әнә шуларның корбаны булды... Да, бу кадәре сезгә билгеле бит. Мин сезгә бары Касыймнан ишеткән үтерелү вакыйгасын гына сөйлим. Кыскача гына итеп әйткәндә, эш болай булган. 30 мартка каршы төндә читальняда комсомолларның җыелышы булган, имеш. Җыелыш, гадәттәгечә, соң беткән. Халык таралган. Латыйф читальныйны җыештыра калган. Касыйм белән Кәримә дигән кыз аны көтеп торганнар. Кәримә үзләренең бер комсомоллары икән. Латыйф белән араларында азрак якынлык та булган, имеш, дип сөйлиләр. Так, шуннан соң Латыйф Касыймга: «Бар, син кайт, иртәгә дәрескә барасың бар. Мин Кәримәне озатып кайтырмын», – дигән. Касыйм, конечно, шулай дигәч

кайтып китә. Кәримә белән Латыйф икәү аның артыннан кайтырга дип җыенып калалар. Касыйм кайта, ашый, эчә. Байтак вакыт үтә. Ә Латыйф һаман юк. Касыйм «кызы белән утыра торгандыр» дип ята да йоклый. Иртән тора. Латыйф кайтмаган була. Касыйм азрак аптырый. «Кая кунып калыр икән бу?» – дип уйлана-уйлана, мәктәпкә китә. Укытып кайтышлый, читальняга сугыла. Читальняның ишегендә зур йозак асылынып тора, беркем юк. Урамда Кәриманы очрата. Көлеп: «Кая яшердең безнең Латыйфны?» – дип сорый. Кыз: «Нишләп яшерим, мине озата килде дә әйләнеп кайтып китте», – ди. Касыйм тәмам аптырый. Латыйфның кичә төнлә дә, бүген иртән дә кайтмавын әйтә. Кыз да аптырап кала. Икәү бергә Касыймнарның өенә баралар. Латыйф һаман кайтмаган була. Урамга чыгып тагын берничә кешедән: «Латыйфны очратмадыгызмы?» – дип сорыйлар. Һәркем: «Юк», – ди. Китәләр сельсоветка. Анда сельсовет председателе Шәрәфетдин абзыйдан иң тәү: «Латыйфны бүген күрмәдеңме?» – дип сорыйлар. «Юк!» – дигәч, аның кичә Кәриманы озата барганнан соң өйгә кайтмавын әйтәләр. Өчесендә дә әллә нинди бер шик туа. Шомлана башлыйлар. Замана шундый. Кулакларның Латыйфка теш кайрап йөргәннәрен беләләр. Ну шулай да андый-мондый уйга барып җиткәнче, «берәрсендә утыра булыр» дип, күңелләрен җуаталар да өчәүләп урамга сорашырга чыгалар...

Су буена төшә торган тыкрык яныннан үтеп барганда, Касыймның күзенә бияләй кадәр генә кан табы чагыла. Кәримә белән Шәрәфетдин абзый үтеп китәләр. Бу арткарак кала да канга карый, җирдәге тиресләрне аягы белән бер яккарак этәрә. Тирес астындагы бозда тармакланып-тармакланып сузылган, җәелеп торган кан таплары күбрәк күренә башлый. Бу тиресләрне тагын да читкәрәк этәрә. Караса, бер кушуч кадәр генә чокырда кан бөтенләй җыелып тора. Касыйм агарынып китә. Тегеләрне кычкырып туктатмакчы була. Ләкин, бердән, Кәриманы куркытудан курка, икенчедән, кем белә, может бу берәр хайван каныдыр, тиктомалга кеше куркытырга ярамый, ди. Ну җаны түзми, тегеләр артыннан барып җитә дә: «Кәримә, син фәләннәргә кереп чык, ә без эрегән җиргә барып килик әле», – дип, Шәрәфетдин абзыйны борып алып китә, Кәримә күздән югалгач та, тыкрык башындагы канны күрсәтә. Канга карагач, Шәрәфетдин абзыйның да йөзенә курку чыга. Икесе дә нык шикләнү белән шикләнәләр. Озак уйлап тормыйлар, канны тикшертергә булалар. Ләкин, волостьтан доктор килгәнче, кешегә сиздермичә генә саклап торырга кирәк табалар.

Касыйм тыкрык башында кала. Шәрәфетдин абзый тиз генә бер комсомолга барып, аны ат белән волостька доктор артыннан чаптыра. Бер-ике комсомолны Касыйм янына җибәрә.

Дүрт сәгатьтән соң волостьтан доктор белән бер милиционер килеп тә җитәләр. Доктор канны, сельсоветка алып кереп, тикшереп карый. Кан... кеше каны була. Тиз арада волостьтан

милиция начальнигы чакырыла. Калага телефон аша хәбәр итәләр. Икенче көнне үк тикшерүчеләр килеп җитәләр. Бөтен авылның астын өскә китереп тикшерә дә башлыйлар.

Бөтен яланнардан, таулардан, су буйларыннан Латыйфның гәүдәсен эзләргә тотыналар. Ә халык арасында, доктор килеп төшү белән, «Латыйф юк! Латыйфны үтергәннәр!» дигән хәбәр таралып та өлгерә...

Өч көннән соң Латыйфның гәүдәсен авылдан биш чакрым түбән бер яр буендагы ак балчык чыгара торган тирән чокырдан табып алалар. Үтерүчеләрнең Латыйф гәүдәсен ул чокырга илтеп салуларына сәбәп шул, имеш: ул ак балчык чыгара торган чокырлар Каран суының яры буенда икән. Яз көне ташу вакытында ул чокырларга су тула, күбесе ишелеп бетә икән. Ә ишелгән чокыр астында калгач, сине чуртым да таба алмый инде... Латыйфның гәүдәсен авылга алып кайталар. Ул бик ерткычларча үтерелгән була. Хатын-кызлар аның өстенә дә карый алмыйлар.

Гыйззәт Сәләхи абзыйны бүлә:

– Ә ничек үтергәннәр икән?..

Сәләхи абзый тыныч кына сүзен дәвам итә:

– Ашыкма, сөйләгәнне көт. Касыйм әйтә, тикшерү нәтиҗәсендә Латыйфның менә болай үтерелүе билгеле булды, ди. Латыйф Кәримәне озата баргач озак тормаган. Аз гына сөйләшкән дә борылып кайтып киткән. Болар икәү читальнядан кайтканда, беркем дә очрамаган. Урам буш, авыл тыныч булган. Ну шулай да ул төнне Латыйфны бик нык саклап йөргәннәр булырга кирәк. Чөнки үтерү бик шома эшләнгән.

Латыйф кире кайтышлый әлеге тыкрык башыннан үтеп барганда, дошманнар, качып торган җирләреннән чыгып, озын колгага беркетелгән ун кадаклы гер ташы белән маңгаена сукканнар. Латыйф шундук тавыш-тынсыз җиргә капланган булырга тиеш. Ун кадаклы гер Латыйфның маңгаен бөтенләй җәнчеп кергән. Аннан соң ике култык астыннан да йөрәгенә пычак буйлатканнар. Ул гына җитмәсә, атка салып чокыр янына алып баргач, эчен ярганнар.

Үтерү шулай булган. Латыйфны табып кайткан көннең өченче көнендә бик зурлап күмгәннәр. Аны күмгәндә, чистый мәхшәр булган. Халыкның чамасы юк иде, ди. Ну бит үзе дә бик эшлекле җегет иде инде. Бөтен тирә-як кулакларының йөрәгенә кадалган кылчык булып тора иде...

Җегетләр бар да тын булып торалар иде. Аларның күзләре җиргә кадалган. Күбесенең тәмәкеләре сүнгән иде. Сәләхи абзый сүзен бетергәч, бары Әделгәрәй абзый гына:

– Да! – дип куйды.

Тагын авыр тынлык урнашты.

Миңа бигрәк тә авыр... Бөтен эчемә тимер тулгандай бөкрәйдем. Басылдым. Аркам туңган төсле. Ә йөрәк төбемдә әйтерсең янгын бар, ул яна... Гәүдәм акрын гына калтырый. Калтыравымны янымда утырган Кәрим абзый сизмәсен өчен, тешләремне кыскан булам, алар шык-шык бәреләләр.

Латыйф абзый күз күне генә безгә килеп киткән иде. Киң маңгайлы, елмаеп торган зур битле, сөйкемле генә бер җегет иде. Хәзер менә күземне йомсам, аның киң маңгайлы елмайган йөзе тере вакыттагыдан да ачыграк булып алдыма баса. Күземне ачсам, тыныч, моңсу төн, сабый бала төсле кайгысыз, гамьсез төн. Тик каршыдагы урманнар гына кашларын җимергән усал кеше төсле, үз караларына каралып, өскә җимерелердәй булып торалар... Мин шул урманнарга карыйм да алар өстендә Латыйф абзыйның үлек гәүдәсен күрәм. Аның киң маңгае гер ташы белән җәнчелгән, гәүдәсе пычак белән телгәләнгән. Ул хәзер сөйкемле Латыйф абзый түгел. Ул – әллә нинди канга баткан, танымаслык бер кеше гәүдәсе...

А, авыр, авыр!.. Нинди ерткычларның мондый эшкә куллары барды икән? Их, белсәң иде!

Абзый авыр тынлыкны бозды. Аның тавышы карлыккан, акрын сөйли:

– Шулай, җегетләр, бу хәл артык гаҗәп тоелмасын. Кан белән корбан сугыш сафында гына булмый икән ул. Ул ике сыйныфның җир өстендә «хуҗа» булып калу өчен көрәшкән вакытында да була икән. Латыйф кебек корбаннарны быел без күп кенә бирдек. Ләкин Латыйф безгә якын дус та иде. Шуңар күрә аның үлеме безгә артык авыр. Сыйнфый дошман үзенең иң зур ерткычлыкларын кыла. Аңарга каршы берләшергә максат – бер генә адым да артка чигенмәскә, канга каршы кан белән җавап бирергә кирәк.

Абзыйның сүзләре авыр кургаш кебек, башкаларның күңелендәге уйларының, әйтергә теләгән сүзләренең өстенә генә төшә торды. Һәркем шуны әйтергә тели иде. Абый шуны әйтеп бирә барды. Тик Гыйззәт кенә урыныннан торды да, куллары белән әллә нинди хәрәкәт ясап:

– Дошман эләксә, менә шулай, и баста! – диде. Аның хәрәкәте кызык чыкты. Ләкин берәү дә көлмәде.

Сәләхи абзый шелтәле тавыш белән:

– Баста синең эшең түгел. Аны әнә безнең өч хәреф тә бик шәп башкара. Син җегет булсаң, үз тирәңне ачыграк күз белән карап йөр. Дошманнар безгә өлеш чыгарырга йөрмиләрме? – диде.

Аз сүзле Кәрим абзый да телгә килде:

– Дөрес, җегетләр, безгә кайбер кешеләрне сакларга кирәк. Менә безнең Мансурга кемнәр генә теш кайрамый дисең? Аны менә хәзер тотып ашарга торучылар бар. Безгә шуны

сизеп торырга кирәк... Беркөн тиречe Хикмәт Кыямнар капка төбендә: «Ул Мансур җир өстендә яши торган халыклар түгел, бүгенме, иртәгәме барыбер үләксәсен этләргә ташларлар», – дип сөйләнеп торган.

Абзый тагын баягыдай басынкы тавыш белән сүзгә катнашты:

– Куркыныч нәрсә турында сөйләгәчтен шүрли башламагыз, иптәшләр. Эшне эшләргә, сер бирмәскә, аз гына шүрләүне дә сиздермәскә, киресенчә, дошманның кыл кыймылдатуын да сизеп торырга кирәк... Кемне дә булса берәүне саклап йөрү эш түгел. Без, сугыштагы шикелле, барыбыз да бер-беребезне сакларга һәм һәркайсыбыз үзебезне сакларга тиешбез.

Фәхри абзыйның аркасыннан какты:

– Дөрес, Мансур, сүзләрең өчен генә сиңа красный орден бирерлек бар.

Абзый елмайды.

– Йә, йә, салам кыстырма, сөйләгән өчен генә красный орден бирсәләр, сиңа гармун тарткан өчен генә эшләмәскә, тик утырырга кушарлар иде.

Фәхри, гармун каешын кулбашына ныграк киеп, күкрәген киерә төште.

– Нигә исең китә? Социализм булгач, һәркем үзе яраткан эшне генә эшләп торыр, ди бит. Может мин дә гел гармун уйнап кына торырмын.

Кәрим абзый, урыныннан торып, кагына-кагына:

– Ну, әйдәгез, кузгалыйк. Сүз сүзне тартыр, ди. Болай утырсак, төн үтеп китәр, – диде.

Барда урыннардан кузгалдылар.

Гыйззәт, җиңелчә генә сулап:

– Их, мать чисный, кызларыбыз сагынып сары яфрак булганнардыр инде, – диде.

Берәү дә аңар җавап кайтармады.

Абзый миңа бармаска кушты. Минем үземнең дә бик барасым килми иде. Анда безнең ише вакларга җегетләр аяк астында буталып йөрүдән башка бернәрсә дә юк. Калуны артык күрдем.

Җегетләр су буе юлы белән үргә таба менеп киттеләр. Малайлар алар артыннан иярделәр.

Бераз тавыш-тынсыз баргач, Фәхри гармунын уйнап җибәрде. Гыйззәт аңар кушылды... Тагын гармун, җыр тавышы төннең үзәгенә, әллә кая, күзгә күренмәгән җирләргә, киң бушлыкка йөгерде. Тагын йоклаган җир өсте сискәнгән кебек булды... Морадымның шаулавы урынына колакка гармунның көмеш тавышы кереп, йөрәкне кытыклады.

Мин, бүрәнә яныннан кузгалмыйча, алар артыннан озак карап тордым. Алар бер сыртка менделәр, ерагайдылар... Тора-бара кешеләр урынына тонык ай яктысында кемнең кем икәнен

аерырга мөмкин булмаган шәүләләр генә селкенә башладылар... Гармун тавышы акрынайды, тынды...

Мин өйгә таба борылдым.

Безнең «Үрнәк» су буеннан бер өч йөз адымнар чамасы читтә, сырт өстендә. егерме биш өй барысы да беррәттән тезелгәннәр. Морадым буена карап торалар. Тик урта бер җирдә зур амбар белән Усман абзый йорты гына Морадымга арты белән караган.

Су буена караган тәрәзәләрнең берсендә дә ут юк. Димәк, барысы да йоклыйлар.

Мин кеше аягы белән генә салынган сукмак буйлап үзебезгә таба күтәрелдем. Тирә-як шундый тын. Шылт иткән тавыш юк... Өйләр дә, абзарлар да, әйтерсең эчләрендәге бөтен кешеләр, хайваннар бөтенләйгә катып калганнар, шундый бер авыр тынлыкка батып торалар... Ичмасам, йорт алдындагы этләр дә үзләренең барлыкларын белгертмиләр.

Ә Морадым шаулый... Аның тонык тавышы ерак, урманнарда, тауларда яңгырый... Ләкин мондагы тынлыкка аның шаулавы ай нуры кебек үзләшкән... Ул тынлыкны бозмый, бары шомландыра гына...

Урамдагы бик вак елгачыклар бөтенләй агудан туктаганнар. Зурракларының читләре челтәрләнеп туңган... Урталары акрын гына дулкынланып, тавыш-тынсыз ага... Мал тоякларына, кеше эзләренә җыелган сулар, сулы җирләр туңганнар. Атлаганда, бары аяк астындагы шул вак челтәр бозларның шытырдап ватылуларын гына ишетәсең. Ватылган боз кисәкләрендә, су читендәге боз челтәрләрендә ялкауланып кына ай йөри, уйный, тонык кына елтырата... Әйтерсең нурлар да чиксез дәрья кебек тирән тынлыкны бозудан саклаidалар...

Ялгыз калгач, мондый бер тынлык эчне пошыра, башка ямьсез уйлар кылә. Куркындыра... Мин Латыйф абзыйны хәтерләдем. Бәлки, ул да шушындый бер тын төндә үтерелгәндер?... Шуның кебек, шушындый бер төндә абзыйны яисә башка берәүне үтерсәләр?!

Минем тәннәрем кымырҗып китте. Кулларым салкыная, ике як чигәм доң-доң бәрә башлады.

Куркынам... Ашыгып атлыйм... Үз аяк тавышым үземә куркыныч тоела. Артка әйләнеп карарга шомланам. Гүя минә хәзер берәүнең каты тимер кулы җилкәмнән эләктереп ала... Каушыйм... Әллә берәр бәхетсезлек сизәмме?!

Менә мин үземнең өй янына җиттем. Капкадан кергәндә, артыма әйләнеп карадым.

Чү!!!

Каршыдагы амбар стенасында бөкрәеп кенә атлаган ике кеше шәүләсе күренеп калды... Ике шәүлә тизрәк амбарның артына, ай яктысы төшми торган караңгы якка борылдылар.

Мин баскан урынымда агач кебек катып калдым. Маңгаема салкын тир чыкты. Ә буыннарым калтырарга тотындылар... Егылудан куркып, капка баганасына таяндым...

Тизрәк көчне җыям, уйларга тырышам...

Кемнәр булыр? Нигә Бүре белән Актырнак өрмиләр? Юк, юк, болар йә карак, йә усаллар... Тукта, болар кая киттеләр? Су буена төшеп киттеләрме, амбар артында яшеренеп торалармы? Мине күрделәрме, юкмы? Нишләргә?..

Нәрсә эшләргә кирәклеген уйлап таба алмадым. Ниндидер бер көч белән урынымнан кузгалдым. Үз-үземә һич исәп бирмәстән, күршедәге Әделгәрәй абзыйларның йорт алдына чыктым. Койма янына бардым.

Аларның капкалары киртәдән генә булса да, коймалары тактадан, минем биекле генә... Үрелә биреп, амбар янын карый башладым. Күзләремне ялт-йолт йөртәм. Зур амбарның кайсы җирендә генә булса да теге шомлы шәүләләрне табарга тырышам.

Тукта... Менә ике кеше, амбар артыннан аллы-артлы акрын гына сакланып, амбарның башы ягына чыктылар...

Мин тагын бер туңа, бер яна башладым. Үрелеп карап торырга хәлем бетә, ике кулым белән коймага асылынам...

Ике кеше, үрелеп-үрелеп, тирә-якка караналар. Бер-берсенә сүз кушмыйлар булса кирәк, баш кына селкешәләр... Берсен танырга итәм, ләкин таныган кешеләремнең берсе дә хәтеремә килә алмый. Әйтерсең бөтен дөнья онытылган. Менә берсе, бик нык иелеп, амбардан кырык адымнар читтә торган лапаска таба йөгерә башлады. Икенчесе, амбарның алдына чыгып, бик нык тирә-якка каранырга тотынды...

Безнең күзләр очрашкан кебек булды. Ул мине үтәдән-үтә күрде шикелле. Мин шундый нык каушадым. Йөрәгем тибүдән туктады... Әгәр дә тавышым чыкса, үз-үземне белештермичә кычкырып җибәргән була идем... Мин, нишләгәнемне белмичә, кинәт җиргә бөгелдем...

Ләкин ялгышканмын... Ул мине күрмәде. Күзләрен минем турыдан алды да тагын уңга-сулга җентекләп каранды. Җир өстенең тынлыгына, «Үрнәк»нең тавыш-тынсызлыгына, бөтен йортларның, абзарларның тирән йокыга талуларына ныгытып ышанганнан соң, ул, батырланып, артына әйләнде. Зур адымнар белән кире амбарның башы ягына китте.

Амбарның башына җиткәч, тирә-ягына бер дә каранып тормыйча, итәк астыннан бер зур калай савыт чыгарды да, селкеп-селкеп, амбарның стенасына нәрсәдер сибә башлады... Бүрәнәләр аркылы аккан куе сыек нәрсәнең якты ай нуры астында ара-тирә елтырап куюы күземә чагылды. Мин моның нәрсә булуын уйларга өлгерә алмадым, икенчесенең лапастан салам кочаклап алып килүе күренде. Мин сискәнеп киттем.

– Ах, яндыралар!!!

Кулларым коймадан ычкынды... Куркыныч төшле йокыдан уянган кебек булдым. Чәч төпләремдә тир... Йөрәгем күкрәгемә сыймый, ул дулап тибә... Башыма куркыныч уйлар, буа җыртылып яланны кинәт су баскан шикелле, шундый күп булып кереп тулдылар...

– Амбарны яндыралар, бөтен орлыкларны, бөтен азыкларны яндыралар. Бөтен колхозны яндыралар... Бу артык куркыныч!..

Күзләремә ут кабынды. Башым әйләнде. Тәнем җиңеләеп киткән кебек булды...

Йөгереп барып өй буеннан бер зур таш кисәге алдым да бөтен көчем белән каршымдагы Усман абзыйның тәрәзәсенә җибәрдем.

Тирә-як тып-тын иде... Кинәт чылтырап тәрәзә коелды. Аңарга кушылып, мин бөтен тавышым белән кычкырып җибәрдем:

– Каравыл, яндыралар!..

Амбарны яндырырга маташучылар, өреккән атлар шикелле, артларына да әйләнеп карамыйча, савытларын, саламнарын ташлап, су буена таба бөтен көчләре белән чаптылар...

Мин, кычкыра-кычкыра, урамга йөгереп чыктым.

Ул арада ватык тәрәзәдә Усман абзыйның кулына мылтык тоткан ак шәүләсе күренде... Мин аңарга ташландым.

Мылтыгының көпшәсе миңа таба караган. Куркуымнан егылырга өлгерә алмадым, ахры, ул мине танып алды, көр тавышы белән:

– Нәрсә бар, нинди тавыш? – дип кычкырып җибәрде.

Мин тавышыма тыгылдым:

– У-у-усман абзый, амбарны яндыралар.

Аның куркудан күзләре акайган иде. Минем сүзне ишетүгә, ишеккә ташланды... Ишекне бәреп ачуга, ике тапкыр аллы-артлы атып та җибәрде.

Айлы төн урталайга ертылган кебек булды... Мылтык тавышыннан җир өсте бөтен урманнары, таулары, сулары белән яңгырады.

Бер минут.

Бөтен өйләрдән күлмәк-ыштаннардан гына зур абзыйлар урамга йөгерешеп чыктылар. Этләр дулап өрергә тотындылар.

Бер минут элек тирән йокыда булган колхоз, хәзер бөтен хатын-кызлары, бала-чагалары белән аякка басты. Әйтерсең көчле давыл чыкты... Урамга чыккан халыкларның барысы да минем янга йөгерешеп киләләр. Барысы да куркынган, аптыраган күзләре белән:

– Нәрсә бар, нәрсә бар? – дип, миңа карадылар.

Мин аларны, йөгертеп, амбар янына алып киттем... Сөйләргә итәм, тавышыма тыгылам. Шулай да тырышам:

– Менә... менә... яңа гына а-а-амбарны яндырырга иттеләр... Мин... мин кычкыргач, су бу... буена таба качтылар.

Халык өелеп торган саламны, керосинга манчылган стенаны, аунап яткан керосин бидонын күргәч шаша калды. Ачудан, ярсудан бар да шаулап кычкырынырга тотындылар:

– Нәрсә карап торабыз, иптәшләр, әйдәгез, артларыннан куа чыгыйк!..

Ул арада берничә кеше атларына атланып килеп тә җиттеләр. Усман абзый да, яшь кенә күк айгырын абзардан чыгарып, күлмәк-ыштаннан гына сикереп менде.

Ул, биеп торган айгырын көч белән тыеп:

– Кая, кайсы якка таба качтылар? – диде.

Мин, качучыларның нәкъ үзләрен төртеп күрсәткәндәй:

– Менә шушы юл белән Морадым буена, түбәнгә таба йөгерделәр!.. – дидем.

Көч-хәл белән тыелып торган атлар, бер аяк кагу белән тыпырдашып, су буена чаптылар. Алар артыннан җәяүлеләр йөгерделәр... Минем аякларымның хәле булмаганга, тыным кысылганга күрә, урынымда калдым.

Амбар янына колхозның бөтен бала-чагалары, хатын-кызлары җыелып өлгергәннәр иде. Алар мине сырып алганнар, бар да сорашалар... Ләкин аларның сүзләре колагыма кермәде... Кинәт Актырнак белән Бүре исемә төште... Мин бит җаннан артык сөйгән этләремнең тавышын да ишетмәдем. Яныма койрык болгап чабып килгәннәрен дә күрмәдем!

Берсенең-бер сораганына сүз кайтармыйча, хатын-кызлар уртасыннан чыктым да амбар буйлап киттем. Артымнан берничә малай иярде. Алар да, нәрсәдер сизенгән кебек, тавыш-тынсыз киләләр иде...

Амбарны үттек... Менә аларның әйбәтләп кыеклап салынган, эченә күп итеп салам түшәлгән такта оялары... Алар оялары янында юклар. Ояларының эченә карадым, юк, күренмиләр. Амбарның ары башына киттек.

Тагын никтер борчыла, хәлсезләнә башладым. Бөтен тәнем, йөрәгем нидер сизенә... Минем өчен авыр...

– Тукта, нәрсә бу?!

Амбардан биш адымнар гына читтә ике эт ята. Мин, аларны ерактан ук күреп, нәрсә дияргә белмәгән идем. Таныгач, йөгереп барып карыйм... Әйе, Актырнак белән Бүре... Тавыш-тынсызлар... Саклап кына аягым белән тибәрәм. Зур йөнтәс гәүдә акрын гына, авыр гына селкенә, берни сизми... Йөрәгем жу-у итеп китте. Тагын күкрәгемдә салкын боз сиздем.

– Үтергәннәр! – дидем, акрын гына кычкырып куйдым.

Актырнак амбар күләгәсе астында ята, күзләре йомык... Бүренең яртысы – баш ягы – ай яктысына эләккән, күзләре ачык... Мин аның баш очына тезләндем. Акрын гына калтыранган кулларым белән шома, соры башыннан сыйпыйм...

Ул нинди усал иде, күзләре ут кебек яна иде. Ә хәзер ул тере зур күзләр тонык, яшь аркылы моңсу гына айга текәлгәннәр. Гүя, «Нурлы ай, син дә карап, күрә торып безне сакламадың, харап иттердең!» дигәндәй, кызгандыру катыш үпкә белән карыйлар. Минем бу тонык күзле, соры, матур, акыллы башны яңагыма терисем килде. Күкрәгем кысылды. Бугазыма нәрсәдер килеп кысылды. Керфек төпләрем кайнарланып китте.

Белмим, артык хәлсезләнгәнгә күрәме, иреннәремне тешләп еламаска теләсәм дә, яшьләремне тыя алмадым. Алар керфек араларыма тулып ташыйлар. Әнкәй, килеп, аркама кулын салды. Йомшак тавыш белән:

– Йә, балам, юкка борчылма, тор әйдә! – диде.

Мин урынымнан үксеп тордым, акрын гына өйгә таба атладым...

Башка вакытта хатын-кызлар, иптәшләр алдында тиктомалга елап җибәрү зур оят булыр иде. Мин аны хәзер сизмим дә... Баядан бирле йөрәгемне нәрсәдер тыгызлап тора иде, бары шул сытылып күзләремнән агып киткән кебек кенә булды... Шулай ук мин минем елавымнан көләргә тырышучы малайны да, үртәргә теләүче кызны да, ачуланып калучы җиңгине дә сизмәдем. Алар бар да минем арттан тирән кызгану белән карап калдылар шикелле...

Өйгә кергәч тә, тиз генә җылавымнан тыела алмадым. Әнкәй иркә сүзләр, йомшак тавыш белән юатырга теләде. Мин аңар яшь аркылы ачу белән:

– Әнкәй, дәшмә миңа. Бер сүз дә ишетәсем килми, – дидем, ишегалдына ук чыгып киттем... Иркә сүзләр белән йомшак тавыш ул бары елауны көчәйтә генә!

Салкын һавада тиз басылдым, җиңеләйдем. Бушап калган кебек булдым. Тик ара-тирә үксеп, кулбашларымны гына сикерткәләп алам... Төннең салкын һавасын сизгәндәй, мин яңа гына булып үткәннәрне хәтерли, уйлый башладым.

– Нәрсә булды әле?!

Мин артык каушаудан, елаудан нәрсә булганын да уйларга өлгерә алмаган идем әле...

– Әйе, нәрсә булды?!

Бүгенге айлы төндә кемнәрдер безнең амбарны яндырырга иттеләр. Ә алар кемнәр иде, нәрсә өчен яндырырга иттеләр?..

Алар явыз ният белән килгән усал кешеләр иде...

Ә кемнәр тыныч төндә, кешеләрдән качып-посып, явыз ният белән безгә киләләр? Безнең колхозда аларның ние калган?..

Без колхозга күчәргә йөргән вакытта, авылның яшел, кызыл түбәле ике-өч атлы кешеләре җыелыш саен, урам чаты саен, капка төбе саен: «Җыен зимагурлыкта йөргән малай-салайлар авылны тараталар, халыкны аздыралар», –дип, күркә кебек кабарынып, очынып йөргәннәр иде. Без аларга сәлам дә бирмәдек, күчтек.

Күчкәннән соң авылга йомыш белән барып, урамнан үткән-сүткәндә малайлары арттан: «Көлегез күккә очар әле», – дип кычкырып йодрык селкеп калсалар, зурлары үзләренә якын торган кешеләрнең колакларына: «Җир өстендә яши торган халыклар түгел алар, көне җиткәч, үләксәләрен эткә ташларлар әле, Ходай кушса», – дип шыпылдадылар...

– Нигә алар безгә шулкадәр дошманнар?!

Чөнки алар колхоз аркасында үзләренең бетәчәкләрен сизәләр иде... чөнки ярлылар аларның кул астыннан чыгалар, үзбашларына яңа матур тормыш төзиләр, җир өстенә байлар урынына алар «хуҗа» булалар иде. Бу хәл кулакларны шаштыра, аларның каннарын кайната. Алар колхозларга, ярлыларга ачудан яналар, көяләр.

Бүгенге төндә явыз ният белән амбар яндырырга килүче усаллар – әнә шул колхозлар аркасында үзләренең бетәчәкләрен сизгән кулакларның кешеләре иде... Алар безнең үләксәләребезнең эткә ташлануын көн-төн теләп йөреп, ахырда ачулары чиктән ашкач, үзләре яшерен юллар белән безнең өскә ут җибәргә теләделәр...

Ләкин дошманнарның соңгы чаралары да уңышсызлыкка очрады.

– Колхоз исән, колхоз яши! Колхоз дошман өстенә ташланды.

– Тукта!

Дошман дигән сүзне ишетә идем. Дошманны күреп тә белә идем.

Ләкин дошманның безгә ачудан кан баскан усал чыраена, безне юк итәр өчен килгән ерткыч чыраена очраганым юк иде... Менә мин бүген, искәрмәстән, ул чырайга очрадым. Артык нык каушадым, хәлсезләндем, шулай да көчне җуймадым, дошманга колхоз өстенә ут җибәрергә ирек бирмәдем!

Ә соңыннан, кешеләр дошманнарны куа киткәндә, мин үземдә кузгалырлык көч тапмадым. Аякларым хәлсез иде. Калдым. Бүрене кызганып еладым...

Ә менә хәзер, менә хәзер мин дошманның үлем сизеп кара көйгән йөзенә, акайган күзләренә, җиңү шатлыгы белән көлеп яисә көчле үч алудан янып, ашардай булып карар идем. Мин күкрәгемә тыгызланып тулган үч алу ачуыннан тыела алмыйча, алар өстенә усал сүзләр

белән кычкырыр идем. Мин, яшь малай, колхозчы малай, зур абыйлар белән беррәттән үземнең тумыштан ук аларга дошман булуымны әйтер идем, күрсәтер идем...

Тукта... Мин нигә монда?! Ни өчен мин колхозда ялгызым, хатын-кыз, бала-чагалар белән берүзем? Бөтен ирләр дошман өстенә атылдылар. Ә мин күз яшьләремә буылып калдым...

Юк, юк... Хәзер мин дә, алар уртасында булып, дошман алдына басармын...

Өйгә атылып кердем.

– Әнкәй, мин киттем, мин авылга абзыйлар артыннан киттем, – дидем.

Әнкәй, аптыраудан эшен туктатып:

– Нәрсә дисең, Локман, нәрсә сөйлисең, бу вакытта, төн уртасында ялгызың авылга бару ни дигән сүз ул. Җүләрләндеңме әллә? – диде.

Артык сүз көрәштереп торырга теләмәдем, тизрәк чыгып сызу ягын карадым.

– Белмим, әнкәй, вакыт юк. Кайткач сөйләшербез, – дидем. Чөйдә эленеп торган тимер таякны саклыкка дип кулга эләктердем дә чыгып урамга атылдым.

Әнкәй арттан нәрсәдер кычкырып, үрсәләнеп калды.

Амбар яныннан үтеп барышлый, җыелып торган малайларга:

– Әйдә, кайсыгыз минем белән авылга бара, анда яндыручыларны тотып китерәләр, – дип кычкырдым.

Минем сәер тавышым, көтелмәгән сүзләрем шундагы кайбер хатын-кызларга гаҗәп тоелды шикелле. Арадан кайберәүләр:

– Саташамы әллә бу, төн уртасында малай башы белән курыкмыйча авылга бара?! – диештеләр.

Арада минем теләк белән янучы ике малай табылды. Алар берсүзсез миңа иярделәр.

Без өчәүләп көндез кояш белән эреп каралган, төнлә суыктан туңып ай нурында тонык кына елтыраган бозлы, сулы, атлаган саен шыгырдаган ат юлы белән авылга карап җибәрелдек...

**IV**

Дусларым, күп сүз ялыктыра булыр?!

Шуңа күрә мин апрель аеның айлы тын төнендә безнең амбарны яндырырга килүчеләрнең кемнәр булуын, аларның ничек тотылуларын, нинди җәза алуларын, ул вакытта үземнең нишләп йөрүләремне җентекләп язып тормыйм. Шулай ук яланнарда карлар эреп бетеп, яшел чирәмнәр баш калкыткан вакытта каладан безнең колхозга ничек трактор кайтып керүен, аның сырлы тәгәрмәченең иске авыл күкрәгенә нинди эз салуын, колхозның аны каршы алганда ничек җанлануын, ничек күктәге тиңсез кояшны көнләштерерлек дәрәҗәдә шатлануын да сөйләп тора алмыйм.

Алар үттеләр... Ул вакыттагы хәлләр, вакыйгалар миңа никадәр тирән эз салсалар да, хәзер мин аларны ул вакыттагыча бөтен җанлылыгы, нечкәлеге, матурлыгы белән күз алдына китерә алмам, дим... Ул вакыттагы шатлыкларым йөрәгемне язгы су кебек дулкынлатып, күзләремә яшьләр китерсә дә, мин аларны хәзер сезне дулкынлатырлык, сезне очындырырлык итеп бирә алмам, дим...

Миндә хәзер уйларымны еракларга, якты бәхетләргә, алдагы матур көннәргә сөйрәгән бер тыныч шатлык бар. Менә мин шул шатлыгымны хәзер сезнең белән уртаклашырга телим...

Бүген майның унынчы көне... Бүген көн җилсез, талгын... Кичә яңгыр яуган иде. Ә бүген күк йөзенә юка, бик юка пәрдә төсле үтәдән-үтә күренә торган аксыл болыт җәелгән... Аның ара-тирә уелып, ачылып торган җирләреннән ерак күкнең зәңгәр йөзе күренә... Кояш нурлары аксыл юка болыт аша зәгыйфь үтәләр, җир өстен тонык яктырталар... Шулай да җир җылысы белән кояш җылысы бергә кушылалар... Тыныч бер талгынлык туа... Үләннәргә, чәчәкләргә ул җылы талгынлыкта рәхәт төсле... Алар парланалар, яшәрәләр, үсәләр... Кешеләр дә бу талгынлыкта рәхәтлек табалар.

Без чәчү кырында... Трактор белән сөреп, ике кат тырмалап, йомшартылган кара җир бөтен иңе белән буйга – бер чакрым, аркылыга ярты чакрым яланны каплап ята. Без бүген, биш кеше, шунда бодай чәчә башлыйбыз. Орлыкларны өч атка төяп китердек. Сеялкага ике атны җигеп, көйләп куйдык. Хәзер башлап китәсе генә бар.

Сөреш җиргә Әделгәрәй абзый белән Сәләхи абзый трактор белән яңа чирәм ачар өчен килделәр. Бу җирнең һич сабан күргәне юк әле. Без башлап сөрәбез, тары чәчәргә уйлыйбыз.

Трактор җир өстенә безнең белән бергә килгән иде. Нигәдер һаман эш башламый тора. Ә Сәләхи абзый белән Әделгәрәй абзый, тракторның бер артына, бер алдына чыгып, нәрсәдер чуалалар.

Без яннарына бардык.

– Нәрсә, тракторның кәефе юкмы әллә? – дибез.

Әделгәрәй абзый пошынган тавыш белән:

– Кәефе юграк шул, – ди. Үзе, тракторның астына сузылып ятып, көчәнеп-көчәнеп нәрсәдер бора.

Без, машина нәрсәсенең рәтен белмәгән кешеләр, авызларыбызны ачып карап торабыз.

Ә Әделгәрәй абзый бер астына кереп ята, бер, тиз генә чыгып, өске капкачын ачып, нәрсәләрендер тотып, селкеп карый. Ул да булмый, тизрәк урынына сикереп менә дә, аягы белән бер нәрсәне басып, куллары белән түгәрәк тәгәрмәчне бора башлый... Трактор кинәт яман тавыш белән «тук-тук-тук» итеп ала, акрын гына кузгала. Аның яман тавышыннан җир

өстендәге каргалар көтүе, кинәт канатлары белән һаваны чыж-чыж ярып, югарыга күтәреләләр. Сабан тургайлары уңга-сулга пырх-пырх килеп очарга тотыналар. Ләкин аларның куркулары урынсызга була. Трактор бер-ике тәгәри дә тагын туктый.

Әделгәрәй абзый белән Сәләхи абзый озак маташтылар, тирләп-пешеп беттеләр. Без дә: «Нәрсә булды икән моңарга?» – дип пошына башладык. Ахырда Әделгәрәй абзый күтәренке тавыш белән:

– Булды, җегетләр! – дип кычкырып җибәрде. Тракторына сикереп менде, анысын-монысын борды.

Трактор тигез, куәтле тавыш белән ак парны һавага бәрә-бәрә кузгалып та китте.

Бераз китеп кире борылды да җир башындагы көйләп куйган сабаннарга барып тагылды.

Өч сабан, өчесе дә икешәр төрәнле, алар ике зур адым киңлегендәге яшел чирәмне кара җиргә әйләндереп барачаклар. Трактор тагылгач, Әделгәрәй абзый, артына әйләнеп, Сәләхи абзыйга:

– Булдымы? – диде.

Сәләхи абзый «әйе» дип баш селеккәч, ул тагын тракторны кузгата башлады.

Усал үгез аркасына чыбыркы төшкәч ачуланып башын селкегән шикелле, трактор да башта бөтен гәүдәсе белән дерелдәде. Куәтле тавыш белән текелдәде. Берле тәгәрмәчләре белән сабаннарның елтырап торган үткен төрәннәре җирне кисеп, май йомшаклыгы белән яңа яшәреп, матурланып килгән яшел чирәмне йөзтүбән каплап, аларның кара тупрак арасыннан җеп-җеп булып сузылган тамырларын якты көн астына әйләндереп салдылар.

Трактор акрын гына алга үрмәләде. Сабаннар ике адым киңлегендәге чирәмне буй-буй кисеп, әйләндереп сала бардылар. Үләннәр, әремнәр, шайтан таяклары йөзтүбән капланып, кара кәскә әйләнделәр. Әделгәрәй абзыйның бөкрәя төшкән гәүдәсе акрын гына селкенә-селкенә ерагайды. Без аның артыннан озак карап тордык.

Бүгенге көннең җылы, талгын, җилсез тын булуы минем йөрәкне хәрәкәтсез яткан тонык күл кебек иткән иде... Йөрәгемнең шундый тынычлыгыннан ниндидер бер рәхәтлек сизәм... Андый тынычлык акыл, хыял бирә... Мин бүген иртәдән бирле уйчан. Уйчанлыгым минем матур хыял... Уйларым минем шул хыялны киңәйтәләр, яктырталар.

Менә янибызда кырык дисәтинәлек тоташ сөреп ташланган җир. Ул җиргә хәзер бодай чәчә башлыйбыз. Менә биш дисәтинәлек чирәм ачыла. Анда тары чәчеләчәк...

Бүген көн ак кына, юка гына болытлар белән капланган. Кояш нурлары җиргә тонык кына төшәләр. Көн салмак, җылы, талгын... Тукта, менә бервакытны күк йөзе чиксез аяз, зәңгәр булыр. Кояштан нурлар, тере, җитез, йомшак нурлар җиргә бик күп, бик күп булып яварлар.

Яланнар сыртында бөтен иңнәре белән чәчелгән кара җирләр акрынлап яшәрерләр... Кара тупрактагы орлыклар акрын гына, зәгыйфь булып кына шытып чыгарлар да кояшка таба ашыгып-ашыгып үсә башларлар, тураерлар, матурланырлар, башакланырлар...

Куе булып, зур булып үсеп җиткәч, аларга кемнәр генә сокланмас! Кешеләр аларга карап сокланырлар, шатланырлар. Ә алар, кеше карашыннан оялган сыман, башларын селкерләр, дулкынланырлар.

Мин уйлыйм, менә без дә бит, яңа җирдән чыгып, якты кояшка карап үскән яшь үсемлек шикелле, алдагы бәхетләргә таба омтылып үсүче яшьләр. Без дә шулай сокланырлык булып үсеп җитәрбез. Тормыш, эш кешесе булырбыз. Картайган әтиләр, абыйлар өстендәге йөкне үз җилкәбезгә алырбыз, аны, таза гәүдәбез өстендә уйнатып-йөгертеп, алга илтербез. Без алдагы көрәшләрнең яңа өлгергән таза әрмиесләре булырбыз... Тормыш безнең кулга күчәр. Без аны яңа куәт, саф акыл белән яңадан төзербез, матурларбыз...

Алда эш, көрәш... Безнең алдагы бәхетләр әнә шул эш, көрәшләрдә... Мин шул бәхетләрне уйлыйм да шатланам. Уйлыйм да аларга таба язгы ташкындай бетмәс көч белән омтылам...

Әйе, минем күңелем хәзер зурлык тели!..

*1930*

## Рәшә

### I

Тугызынчы майның таңында Зөфәр Сабитов гаҗәеп бер төш күрде: имештер, ул ят бер дала буйлап ялгызы каядыр китеп бара. Дала буш, дала тын, үзе тип-тигез һәм очсыз-кырыйсыз. Үләннәре саргаеп кипкән, кара туфрагы, чатнаган чуендай, яргаланып беткән. Бик эссе, бик коры, төпсез күктән кызган тимердәй ап-ак кояш туп-туры аның күзенә карый... Кайсы якка гына борылмасын ул, бу тере кояш ни өчендер һаман аның каршысына чыга, үртәп көлгәндәй, күзләрен чагылдыра, берөзлексез яндыра, көйдерә, имеш.

Кая таба бара ул, мәгърипкәме, мәшрикъкамы – ачык кына белми дә, имеш, ләкин барырга кирәк, бармыйча ярамый, чөнки монда туктап калу һич мөмкин түгел. Һәрхәлдә, ул бу котсыз даланы ничек тә үтеп, күз күрмәгән, колак ишетмәгән ниндидер яңа бер дөньяга барып чыгарга тиеш. Шунда ул үзенең бәхетен табачак. Һәм берәүгә дә әйтмичә, берәүне дә ияртмичә ялгызы гына чыгып китүе дә бары шуның өчен генә, имеш.

Баштарак аңа тигез дала буйлап атлавы бер дә күңелсез, авыр булып тоелмады. Киресенчә, бу иркенлектә, бу тынлыкта бару рәхәт тә кебек иде. Аннары ялгызлык та аны артык

борчымый иде әле, ничек кенә булмасын, юлдашка эт шикелле аңа ияргән гамьсез кояш бар иде. Ләкин тора-бара очы-кырые күренмәгән үлек дала аны борчый, шомландыра башлады. Кайчан бетәр бу, кайчан бер чиге күренер, нигә бер кош, бер әрлән заты да очрамый?! Тагын бу шоп-шома күктән шым гына ияреп барган «юлдашы» да бик мәкерле, явыз булып чыкты. Хәзер ул Зөфәрнең нәкъ менә баш түбәсен кыздыра, шундый кыздыра, әйтерсең юри миен кайнатып чыгарырга тырыша... Зөфәр кипте, янды, хәлдән тайды, үлеп эчәсе килә башлады. Атлаган саен көчәя барган бу сусауга һич кенә дә түзәрлек түгел иде, коточкыч авыр иде, чатнап кара янган иреннәре бертуктаусыз: «Су... су... су!» – дип, үзлегеннән кыймылдый иде.

...Күпмегә сузылган булыр иде бу газап, чыдый алган булыр идеме ул, юкмы, әмма томаланган, шашарга җиткән күзләре алдында кинәт җем-җем уйнаклап яткан түп-түгәрәк, зур бер күл ачылды. Су, су, йа Ходa!.. Бу шулкадәр чын иде, шулкадәр якын иде, гүя менә суның йомшак дымы аның йөзенә килеп тигәндәй булды. Зөфәр кара көйгән иреннәрен ялап алды, тирән итеп, өзеп-өзеп сулый башлады һәм ашыгып-кабаланып атларга тотынды. Күл бик якын кебек иде, тигез җирдән үк башланып киткән сай читләре агарып, ә эчтәрәк, тирәнрәк урыннары зәңгәрләнеп тора кебек иде. Тик аның аргы чите генә ачык күренми; анда биек камышлармы, текә ярлармы бар кебек, ләкин алар барысы да күз үтә алмаслык күгелҗем томан белән өртелгән иде. Бәлки, шундадыр инде аны көткән сихри дөнья!.. Менә тиздән,тиздән ул барып җитәр, тукталып тормастан шабыр-шобыр күлгә кереп китәр, ут капкан башын суга тыгар, кушучлап якты суын, салкын суын эчәр, эчәр, көлә-көлә, елый-елый эчәр...

...Нәкъ шул чакта кемнеңдер урам яктан зал тәрәзәсен бик каты итеп кагуы ишетелде. Төш кинәт өзелде, Зөфәр, сискәнеп, күзен ачып җибәрде. Бу ни хикмәт, кем болай дөнья җимерә? Ул ни дә булса уйлап өлгергәнче, залда яткан әнисе Таибә абыстай торып тәрәзәгә барган иде инде.

– Кем ул, ни булды, пожармы әллә? – диде карчык, куркынган тавыш белән.

Урамнан бер хатынның бик кабаланып нидер кычкыруы ишетелде. Зөфәр күпме колагын салып ятса да, аның сүзләрен аера алмады, тик ахырдан көлепме, елапмы җибәрүен генә ишетеп калды. Ул да булмый, бүлмә ишегендә Таибә абыстай күренде. Аның йөзенә карау белән Зөфәр ниндидер гадәттән тыш хәл булганын сизеп алды.

– Улым, тор әле, – диде Таибә абыстай, әкрен генә, серле һәм сөенечле бер тавыш белән. – Әнә күрше Митриләрнең килене килгән, сугыш бетте, ди...

– Сугыш бетте?..

– Әйе, сугыш бетте, ди, хәзер генә радиодан әйттеләр, ди, нишләп ятасыз, ди... Йа Рабби мәүләм, бу көннәрне дә күрергә насыйп иттең, рәхмәтеңнән ташламадың бәндәләреңне...

Зөфәр шунда ук урыныннан сикереп торды һәм ашыгып киенә башлады. Төш онытылды, юкка чыкты. Сугыш беткән! Беткән! Точка! Зөфәрнең кычкырып көләсе килде, күкрәгендә тантана һәм ярсу тыгызлана башлады, ашыгудан кулларын күлмәк җиңенә кертә алмыйча азапланды. Әнисенә кычкырды:

– Әни, давай чәеңне! Тизрәк бул!

Киенеп бетәр-бетмәс залга чыкты, урам тәрәзәсенә барды һәм хәйран калды: урамда чуп-чуар халык иде. Капка төпләрендә төркем-төркем хатын-кызлар басып торалар, нидер сөйләшәләр, көләләр, күзләрен сөртәләр. Алар тирәсендә бала-чагалар сикерешәләр. Урам буйлап яшь-җилкенчәкләр тыз-быз йөриләр, каршы очрашканда кочаклашалар, үбешәләр. Ә вакыт бик иртә иде әле, кояш шәһәр өстенә яңа күтәрелеп кенә килә...

Менә ул көн, менә кайчан килеп җитте ул күпме курку-шомланулар, күпме яшерен өметләр белән көткән көн! Бетте, шушы минуттан курку да, шомлану да – барысы да бетте, җилкәдән әйтерсең Һималай тавы төште!

Зөфәр җиңел генә атлап кухняга чыкты. Җиңгәсе Сәкинәнең урыны буш иде, тик киң караватта биш яшьлек Фәрит кенә, бөек вакыйгадан хәбәрсез, кул-аягын ташлап, йоклап ята иде.

– Җиңги кайда? – диде Зөфәр.

– Кайда булсын, урамда...

– Ә балалар? Хөршид?

– Алар да шунда, тордылар да бәрелә-сугыла чыгып чаптылар. Күк капусы ачылганмыни, – диде Таибә абыстай, азрак сукранып; күрәсең, барысының да өй ташлап чыгып китүләренә аның хәтере калган иде.

– Күк капусы ачылудан да болайрак бу, әни!

– Анысы шулай инде, шулай, – диде Таибә абыстай, тизрәк килешеп. – Әйттем исә кайттым, көенечкә генә була күрмәсен!

Зөфәр чәйгә утырганчы радионы борып куйды. Шунда ук Левитан тавышы яңгырады. Менә ничәнче тапкыр инде ул Гитлер Германиясенең капитуляция шартларына кул куюын тапшыра иде. Һәм аның тавышы, гүләп торган чаң шикелле, көчле-дәһшәтле булып, һәр сүзе искиткеч ачык-тантаналы булып яңгырый иде. Тарихның бөек сәгате!

Шуның артыннан ук хөкүмәтнең тугызынчы май көнен —Җинү көне, бәйрәм көне итеп белдерүен тапшырдылар. Димәк, бүген заводлар, учреждениеләр эшләмәячәк. Аның каравы, Зөфәрнең эше тыгыз булачак, чөнки ул сәүдә кешесе, сәүдә белән җитәкчелек итүче, ә мондый көнне сәүдә точкалары, бигрәк тә азык-төлек магазиннары ачык булырга, шаулатып сату итәргә

тиешләр. Бу көнне көтеп, складларда саклап тоткан аракы-виноларны, азмы-күпме кондитер, бакалея нәрсәләрен тизрәк точкаларга чыгарырга кирәк.

Таибә абыстай кайнатып биргән чәйне Зөфәр кухняда гына утырып эчте дә бүлмәсенә кереп киенергә тотынды. Эшкә барса да, бәйрәмчә булсын дип, чиккән якалы ак күлмәген, элүдә генә торган соры костюмын, җәйге туфлиләрен киде. Барысы бер төстән, бер иштән диярлек, тик менә зәңгәр кепкасы гына күренешне шактый боза иде. Ярый инде, баштанаяк бертөследән киенер вакытлар алда әле...

...Капкадан чыгуга иң элек аңа сеңелесе Хөршид ташланды. Арык кыз нечкә беләкләре белән аның муенына үрелеп, артык дулкынланудан сүзләрен бутап, нидер әйтергә тырышты:

– Абыем җаным, бетте, котлыйм, абыем җаным...

Зөфәр аның көзге яфрак кебек калтыранган юка гәүдәсен сыңар кулы белән генә кочып алды:

– Бар, хәзер үк кереп, өстеңә киеп чык! Тәмам өшегәнсең бит.

– Мин янам! – диде кыз, абыйсына тагы да сарыла төшеп.

– Бизгәгең кузгала торгандыр, бар, бар, хәзер үк кер! – диде Зөфәр, аны куалап.

Бер читтәрәк, күрше хатыннар уртасында, иңенә шәлен салган Сәкинә җиңгәсе тора иде. Хатыннар бер-берсен бүлеп, барысы берьюлы диярлек, шаулап сөйләшәләр, кинәт кенә көлеп тә, хәтта елап та җибәрәләр, ә җиңгәсе исә башын кагып кына тора, ара-тирә күзен сөрткәләп ала, әмма аның йөзе яшь кызларныкыдай тәмам нурланып, алсуланып киткән иде. «Менә кемгә бәйрәм бүген!» – дип уйлап куйды Зөфәр. Ире, иркәе фронттан кайтачак бит аның!.. Шулай була күрсен инде. Зариф солдат, Зөфәрнең абыйсы, сугышның соңгы атналарына кадәр исән-имин иде әле. Герман җиренә кергәч тә, эшем әйбәт, трофейный ротада хезмәт итәм, дип язган хатлары һаман килеп торды.

Урам буйлап барганда капка төпләрендә басып торган кайбер хатын-кызлар яки олы яшьтәге ирләр Зөфәргә әдәп белән тыйнак кына: «Исәнмесез, күрше! Котлы булсын Җиңү бәйрәме!» – дип дәшеп калдылар. Зөфәр үзе дә аларга елмаеп, зәңгәр кепкасын күтәрә төшеп, баш иеп узды. Шулай ул бу дөнья! Әле кайчан гына шушы күршеләре аны, сәламләү түгел, бөтенләй күрмәмешкә салыналар иде яки яшерен бер дошманлык белән артыннан карап калалар иде. Янәсе, бөтен кеше тегендә, ут эчендә, ә ул тап-таза килеш монда йөри... Ни өчен коммерсантка мондый оҗмах, имеш? Билгеле, авыр иде бу ят итеп, дошман итеп карауларны күтәрүе, әмма тешен кысып булса да, аңа чыдарга туры килде. Ә хәзер бетте, бетәргә тиеш, хәзер фронт та юк, тыл да юк – бөтен кеше бертигез. Һәм ул бүгенге көннән берәүдән дә шүрләмичә, һәркемнең йөзенә туры карап йөри алачак.

Трамвай йөри торган зур урамга чыккач, Зөфәр тагы да ныграк гаҗәпләнә калды: монда инде халык, төркем-төркем булып кына түгел, ә тоташ бер елгадай, трамвай юлының ике ягыннан шәһәр уртасындагы мәйданга таба агыла иде. «Бу ни тамаша? – дип уйлады ул. – Эшкә дисәң, барысы да бер якка таба баралар, демонстрация дисәң, бернинди тәртип юк!» Ләкин бу чыннан да халыкның бернинди чакырусыз, өндәүсез, үзеннән-үзе туган, шуңа күрә сафларга тезелмәгән шатлык демонстрациясе иде.

Сугыш елларында тузып беткән тармвайлар бу иртәдә дә селкенеп, дөбердәп йөриләр иде. Зөфәр, шуларның берсенә утырып, эшләгән җиренә китте. Эшләгән җире —зур бер заводның эшчеләр тәэминаты идарәсендә. Менә шунда ул сәүдә бүлегенең мөдире булып сугыш башыннан ук эшләп килә иде.

Трамвайга утырып барган чакта Зөфәр бүген таңда күргән әлеге сәер төшен хәтерләде. Нинди төш булды соң бу? Көйгән дала, эссе кояш, сусызлыктан тәмам әлсерәп, интегеп, ялгыз баручы ул, Зөфәр – кайдан килеп керде бу аңа?.. Һәм нәрсәгә юрарга соң мондый куркыныч һәм куандыргыч төшне? Аның үләргә җитеп сусаудан тонган күзләре алдында җем-җем уйнаклап яткан гаҗәеп матур күл ачылган иде бит. Хәтта ул аның сусыл исен, салкынча дымын тоя башлаган иде. Тик, кызганычка каршы, төш иртәрәк өзелеп калды. Әгәр аны сискәндереп уятмасалар, ул барып җиткән булыр идеме икән, юкмы икән? Хәер, бу кадәресе әллә ни әһәмиятле дә түгел. Күл үзе – аның сусавын басачак саф, салкын сулы күл үзе бар иде бит, бик якын иде, димәк, төшне бары тик яхшыга, бәхеткә генә юрарга кирәк. Менә бүген туган көн шул төшнең дәвамы түгелме соң, теге күл шикелле аның алдында киләчәк бәхете кинәт ялтырап ачылды түгелме соң?!

Зөфәр килеп җиткәндә завод алдындагы мәйдан халык белән шыгрым тулган иде. Заводның эшләмәячәген белсәләр дә, монда, җитәкчеләрдән алып бөтен сменаларның эшчеләренә кадәр, барысы да җыелганнар иде. Мәйдан шау-гөр килеп тора. Әллә ничә җирдә баян уйныйлар, әллә ничә җирдә түгәрәкләнеп бииләр, җырлыйлар, төрле җирдә заводның карт эшчеләрен, фронттан кайткан кешеләрне шаулап-көлеп һавага чөяләр. Шундый төркемнәрнең берсендә Зөфәр дистәләрчә кулларның майор Симаковны мәтәлдереп чөюләрен күреп алды. Кыш уртасында гына фронттан кайткан бу кулсыз майор заводның кадрлар бүлеге начальнигы булып эшли башлаган иде. Ничектер тиз арада гына ул зур коллективның күзгә күренгән бер кешесе булды да китте. Моның сере фронттан күкрәгеген орден-медальләр белән тутырып кайтуында гына түгел иде шикелле, ә үзен идарә тирәсендәге ялагай бюрократлар арасында гаҗәп кыю, бәйсез тотуында иде булса кирәк. Шуңадыр, ахры, гади халык, батыр табылды дигәндәй, аңа авып та киткән иде.

Зөфәр аны чөйгән якка барып тормады (кулсыз майор белән очрашырга яратмый иде ул), ә халыкны ерып, туры гына завод идарәсенә таба узды. Ишек төбендә идарә кешеләре белән кул биреп күреште, һәркайсын бәйрәм белән котлады, аннары бер читтәрәк нindидер ят кеше белән сөйләшеп торган, таза гәүдәсенә иркен кара пальто, башына яхшы хәрби фуражка кигән завод директоры янына барып, түбәнчелек белән, аңа кулын сузды:

– Владимир Иванович, рөхсәт итегез сезне котларга, әйе, Бөек Җиңү белән, бөек бәйрәм белән!

– Сезне дә шулай ук, Зуфар Мубаракович! – диде директор, кулын биреп, ләкин янындагы кеше белән сүзен бүлеп тормады.

Шуннан соң Зөфәр идарәгә – үзенең бүлмәсенә кереп китте дә телефонга утырды һәм сәүдә точкаларына шалтырата башлады. Бәйрәм настроениесе гүя тышта торып калды, һәм ул гадәттәге рәсми эшчәнлек белән магазин директорларына төрле боерыклар бирергә, ә кайберләрен шелтәләргә тотынды. Үзе ул боерыксыз эшләргә өйрәнгән кеше, шуңа күрә бүтәннәрнең бер сүздән тел төбен аңламауларына ачуы килә. Нәрсә чыгарырга, күпме чыгарырга, күпмесен калдырып торырга – барысын да чәйнәп сал син аларга!

Менә директор да аның белән рәсми коры гына исәнләшкән булды. Ә бит ул Зөфәрсез – сыңар кулсыз! Зөфәргә бер ымлавы җитә, һәм Зөфәр аңа, кирәксә, күгәрчен сөтен дә табып китерә. Югыйсә ул аны, бронь бирдерә-бирдерә, сугыш буена саклап тоткан булыр идемени? Тот капчыгыңны! Ә җылы сүзе, якты чырае үзенә булсын. Зөфәр алар өчен чапмый. Эшенә күрә әҗере бар икән, аңа шул җиткән. Һәркемнең үз исәбе – дөньясы шул!

Ике катлы буш бинаның коридор очындагы бер бүлмәсендә ялгызы шактый утырганнан соң, Зөфәр урамга чыкты. Завод алдында халык калмаган иде инде. Киткәннәр. Мөгаен, шәһәр үзәгенә табадыр, анда бүген ни дә булса булмыйча калмас. Әнә башка заводларның да кешеләре урам тутырып шул якка таба баралар. Тиз кулдан гына язган лозунглар, юлбашчыларның май демонстрациясеннән калган портретларын күтәргәннәр – шуларны баш өсләрендә тибрәтә-тибрәтә нигәдер бик ашыгып атлыйлар. Зөфәр дә шул агымга ияреп китте. Ләкин аның ашыгасы килмәде. Ул тынычланып өлгергән иде инде. Тантанага катнашып китүдән бигрәк, шул тантананы күзәтеп бару аның өчен кызыграк кебек иде. Гомумән, ул кешегә ияреп кабынырга, очынырга, кыскасы, экстазга бирелеп китәргә яратмый иде. Һәр эштәге шикелле хиссият мәсьәләсендә дә үлчәү-чаманы ярата иде.

Дамбага җиткәч, ерак араны җәяү үтмәс өчен, ул шыгрым тулы трамвайларның берсенә эләгеп китте. Кремль астында төшеп калды, ашыкмыйча гына Бауман буйлап атлады... Монда халык, халык, ерып үтәрлек тә түгел. Ә Кольцода! Мәхшәр купкан диярсең! Бөтен мәйдан

чайкалып, өзлексез гү-ү итеп тора. Кешеләр балык косягы шикелле ышкылып, сугылып, һаман бер тирәдә уралалар, бер-берсен кочаклап алалар, үбеп китәләр. Зөфәрне дә ялгыш кына каршысына килеп чыккан әллә кемнәр кочып алдылар, колагына: «Туганкай, җиңдек, бетте!» — дип кычкырып уздылар. Ул бу мәхшәрдән ничек тә тизрәк ычкынырга теләде. Йорт стеналары буйлап, көч-хәл белән Куйбышев урамына үтә алды һәм Ирек мәйданына таба атлады... Филармониягә җитәрәк, кинәт җирдән калыккандай, аның каршысына Рәшидә килеп чыкты. Килеп тә чыкты: «Зөфәрем!» – дип, егетнең муеныннан кочып та алды. Бөтен гәүдәсе белән сарылып, күпмедер вакыт сеңеп торды. Аннары кинәт кенә артка каерылды һәм иртәнге чыктай дымланып елтыраган, исәрләнгән күзләре белән Зөфәргә төбәлде.

– Ник син көлмисең, еламыйсың, Зөфәрем? – диде ул, балаларча чын гаҗәпләнү белән.

Зөфәр көлеп куйды:

– Булды, Рәшидә, барысы да булды, ләкин без ирләр бит, туктый да беләбез.

Рәшидә тагын аның күкрәгенә капланып, юатуын теләгәндәй, еламсырап, кайнар пышылдап әйтте:

– Ә мин әллә нишләдем, Зөфәрем, әллә нишләдем. Шатлыгымнан тилерәм дип торам, ышанасыңмы? Бөтен дөнья бәхете кинәт өстеңә аусын әле!.. Үләрсең, хәсрәттән үлмәгәнне шатлыктан үләрсең!.. Йа, Ходай!..

Зөфәр аның тузгыган чәченнән сыйпап, ирләрчә салмак кына юатырга тырышты:

– Рәшидә, аңлыйм, ләкин тилерергә дә, үләргә дә ярамый. Алары күп булды инде, ә хәзер яшәргә дә яшәргә кирәк.

– Нигә син бу кадәр акыллы, Зөфәр! – диде Рәшидә, күтәрелеп, егеткә сәер генә бер карап алды, аннары кычкырып көлеп җибәрде: – Зөфәр, мин сиңа бер яңа хәбәр әйтимме?

– Йә, әйт.

– Сугыш бетте, сугыш! Ишетәсеңме?.. Безнең Җиңү белән, безнең Җиңү белән!.. Менә шуның өчен сиңа, менә шуның өчен...

Һәм ул аяк очларына басты да, үрелеп, Зөфәрнең иреннән, битеннән тиз-тиз үбәргә тотынды. Зөфәр бер мәлгә югалып калды, яннарыннан гына бәрелеп, сугылып узган кешеләрнең көлеп, шул ук вакытта бик аңлап карауларын тойгандай булды, шуңа азрак уңайсызланып та куйды. Җитмәсә, бер шаян егет: «Ныграк үзенә, ныграк, бәгыренә үтсен!» – дип тә узды... Ниһаять, Рәшидә үбүеннән туктады, күкрәген тибрәндереп, тирән итеп сулап торды, аннары, бәхетеннән бөтенләй онытылып булса кирәк, үпкә катыш назланып сорады:

– Ә син мине?

– Ә мин сине моның өчен ашап бетерермен әле,—диде Зөфәр, шыпырт кына, тирә-ягына каранып. – Әйдә, киттек, бергә йөрибез!

– Ә юк! – диде Рәшидә, аз гына чигенеп. – Без бүген халыкка җырлап йөрибез. Әнә машина да көтә.

Зөфәр аның кулыннан тотмакчы булды:

– Ә миңа кайчан җырларсың?

– Кара син нинди эгоист!.. Юк инде, дустым, бик тыңлыйсың килсә, әнә халык белән бергә тыңларсың... Ярый, мин киттем! – Һәм кинәт кенә борылып, халык арасына кереп тә югалды.

Ах, хәерсез, качты бит! Ә Зөфәрнең бүген Рәшидә белән бергә аулакта гына бик буласы килгән иде. Көне, көне —шатлыгын, мәхәббәтен, рәхәтен дигәндәй, икәүдән-икәү генә татый торган көн ич бу!.. Әллә артыннан барыргамы икән?

Зөфәр, үрелеп, халык аша урамның икенче ягына карады. Анда, ачык машина өстендә, кайберләре баян аскан, кайберләре авыл яшьләре булып киенгән, ә күбесе үз киемнәреннән, филармония артистлары күренәләр иде... Менә Рәшидәне дә берничә кул машина өстенә тартып алдылар. Бер кәләпүшле егет аны иңбашыннан кочаклады, бу якка карап, йодрык та селеккән шикелле булды. Чыр-чу киләләр, көлешәләр, шайтаннар!.. «Юк, ярамас, – диде Зөфәр, эченнән генә, – барсаң, буй күрсәтеп, сер сынатып кына калырсың». Ул башын иде дә акрын гына Ирек мәйданына таба китеп барды.

Ләкин кая гына барма, халык та халык – ерып йөрерлек тә, бернәрсә күреп булырлык та түгел. Ахырда бу шау-гөр килеп, чайкалып торган халык диңгезе эчендә бәрелә-сугыла йөрү Зөфәрне тәмам арытты. «Ярар, булды, җитеп торыр», – диде ул үз-үзенә һәм аулак урамнарның берсенә чыкты да Лядской бакча аша җәяүләп кенә кайтыр якка китте. Аның ашыйсы да килә иде, азрак ял да итеп аласы килә иде һәм бигрәк тә үзалдына гына уйланып кайтасы килә иде.

Сугыш бетүе һәркемнең, шул җөмләдән Зөфәрнең дә язмышын кинәт яшендәй урталай ярып узды. Берсе бетте, икенчесе туды. Кичәгенәк кенә әле башка тормыш иде, сугыш законы хөкем сөргән тормыш иде, ә бүгеннән бөтенләй икенче тормыш – тыныч заман тормышы башлана. Хәзер, берсеннән икенчесенә күчкәндә, киләчәк турында да ашыкмыйча тыныч кына уйлый башларга ярый иде.

...Киләчәк!.. Сугыш китергән иң авыр, иң газаплы бер заманда кешеләрнең бердәнбер юанычы, өмете, татлы хыялы иде ул... Әмма ничегрәк итеп күз алдына китерергә мөмкин соң бу киләчәкне?.. Башта ук Зөфәр өчен бер хакыйкать көн кебек ачык иде: бу сугыштан, көн саен меңнәрчә адәм баласын йотып торган бу гарасаттан котылып калган кеше, һичшиксез, бәхетле

булачак! Ягъни исән калу факты үзе генә дә кешегә: «Бәхетлемен!» —дип әйтергә хокук бирәчәк... Ләкин Зөфәргә хәзер бу бәхет кенә аз иде инде. Ул – реалист, аныңча, баш исән булу гына чын бәхет түгел әле. Исән калган баш ничек яшәр —менә хикмәт нәрсәдә. Ә ул моның серен белә инде: бәхет – үзең теләгәнчә яшәү, бәхет – матди һәм рухи бәйсезлек ул.

Бәс, шулай икән, Зөфәр дә киләчәк тормышын үзе теләгәнчә бәйсез, иркен, мул итеп корып җибәрергә тиеш. Һәрхәлдә, ул бөтен көчен, сәләтен җигеп, шуңа омтылырга тиеш.

Моның өчен хәзер аңа ике конкрет мәсьәләне тизрәк хәл итәргә кирәк булачак. Берсе – акчаны малга әйләндерү, ягъни йортмы-квартирамы сатып алу; икенчесе – аңа терәк һәм теләктәш булырлык әйбәт кенә кызга өйләнү... Беренчесе кыен булмас кебек, әмма икенчесе?..

Сугыш Зөфәр өчен артык рәхимле, юмарт булып чыкты. Башын да аяды, малын да бирде, өстәвенә аны сөйгән ярлы да итте. Бу – Рәшидә. Филармониянең ярлы, ялгызак бер артисткасы. Гаҗәеп бер хатын!

## II

...Рәшидә Сафина... Рәшидә Сафина... Шушы сылу-чибәр артистка белән һич уйламаган җирдә танышуын, гаҗәеп сәер бер шартларда әллә ничек кенә аның белән якын бәйләнешкә кереп китүен Зөфәр хәйран калып, ләззәт утында янып, менә күпме тапкырлар инде күз алдыннан кичерә... Гомумән, ул Рәшидә турында уйламыйча тора алмый. Бу кабынып уйлануда Рәшидәне сагыну да бар, аңа соклану да, аны теләү дә бар, тик уйлап-уйлап та нечкә күңелле артистканы аңлап бетү һәм беткәнче яратып китү генә юк. Җан тели дә, язык җибәрми дигәндәй, гел менә сагынып омтылу белән сагаеп тыелу арасында хәзергә кадәр яшәп килә ул. Ике ел тулып узды бит, ике ел!

Ә вакыйга менә ничек булды.

1943 елның январь ахырларында Зөфәр Бөгелмә юлы өстендәге кечкенә бер станциягә үзенең тәэминат эшләре белән командировкага килеп төште. Үтә салкын, шыксыз, караңгы бер көн иде. Җыен хәрбиләрне һәм бик аз санлы гына командировочныйларны төяп, фронтка таба ашыгып баручы эшелоннарга юл бирә-бирә, акрын гына өстерәлеп килгән поезд бу станциядә ничектер аз гына тукталып торды да китеп тә барды. Пассажирлар вагоннардан чыгып та карамадылар. Хәер, чыгудан ни мәгънә? Ул чакларда станция тирәләре бик җансыз һәм бик күңелсез була торган иде. Вокзал биналары ягылмый, утлар яндырылмый, буфетлар эшләми, рәшәткә буенда сөт, каймак, тозлы кыяр, пешкән бәрәңге сатучы хатыннар булмый һәм тирә-як авыллардан килгән атлар да җыелып тормый иде. Алыр нәрсә дә, күрер нәрсә дә, белер нәрсә дә юк. Чыксалар, шул яшь солдатлар гына чыгып, чибәр кызлар очрамасмы, шуларга бер җылы сүз

катып булмасмы, дип, станция тирәсеннән шыгыр-шагыр бер әйләнеп керәләр иде. Бу юлы алар да шыгырдап керергә өлгерә алмый калдылар.

...Поезд китте, вокзал алдында Зөфәр берүзе диярлек торып калды. Ни сәбәптәндер бу сәгатьтә монда бүтән бер поезд да, бер эшелон да юк иде; тезелешеп киткән буш юллар арасында мазут таплары җәелгән пычрак кар гына елтырап ята һәм салкын телеграф чыбыклары гына моңаеп өзлексез шаулый... Ник бер кеше, ник бер хәрәкәт күренсен... Һич югы, берәр олаучы-мазар күренмәсме, дип, Зөфәр рәшәткә буена да барып карады. Юк, олаучы түгел, адашып йөрүче эт тә юк. Шуннан соң ул кире борылып килде дә, бусагасы төбенә шадраланып тайгак-шома, пычрак кар каткан, тупса ярыкларына бәс утырган, юньләп ябылмый да торган авыр, зур ишекне көчкә ачып, вокзал эченә керде... Вокзал эче дә тыштан аергысыз салкын, караңгы, котсыз, буш иде. Ләкин шулай да Зөфәр анда дүрт кешене күрде. Аларның өчесе хатын-кыз, берсе ир кеше иде. Кызлар бер почмактарак, ягылмаган галанка мич тирәсенә бөрешеп утырганнар, ә ир кеше иңбашларын уйнаткалап, тире биячәйләрен бер-берсенә суккалап, әрле-бирле йөренеп тора иде. Кыяфәтләренә һәм өс-башларына караганда шәһәр кешеләре булырга тиешләр. Хәер, өс-башлары аларның бик чуар һәм бик иләмсез иде. Кызлар, салкынга бирешмәс өчен, бар булганнарын юка пальтолары астыннан өсләренә киеп бетергәннәр, ахрысы – барысы да тәпән шикелле юаннар, барысы да сырган чалбардан һәм киез итекләрдән, башларына кайсы шәл чорнаган, кайсы малахай бүрек игән... Әмма шулай да кызлар бик нык өшегәннәр булса кирәк, шәмәхә төсенә кергән иреннәре үзлегеннән калтыранырга гына тора. Тик ир кеше генә ул хәтле үк куырылып төшмәгән. Кием-салымы да аның тазарак, башында эче-тышы мех малахай бүрек, өстендә калын тышлы, сырган эчле, каракүл якалы пальто, аягында зур соры киез итек; бүрегенең колакларын төшереп бәйләгән, якасын торгызган, билен тар каеш белән ныгытып буган; шуңадыр инде ул: «Юк, бирешмибез әле!» – дигән төсле дәртләнеп йөреп маташа.

Зөфәр бер читтәрәк тукталып, болар кемнәр икән, дип, аларга карап торган чакта, шул тире бияләйле кеше үзе аңа килеп дәште:

– Агай-эне, кай тарафлардан килеп чыктыгыз әле сез монда?

Зөфәр аның болай шактый әрсез һәм дорфа итеп соравыннан гаҗәпләнеп, беравык ни әйтергә белмичәрәк торды. Аннары көлемсерәп кенә әйтеп куйды:

– Кай тарафтан килүем сезнең өчен барыбер түгелмени?

– Барыбер түгел шул. Әйтегез турысын гына – сез Казаннанмы?

– Әйе, Казаннан.

Моны ишетүгә,егет тиз үк бияләйләрен салды.

– Бик шәп. Алайса чыгарыгыз әле үзебезнең Казан дөкәнен!

– Нәрсә ул?

– Шуны да белмисезме? Ну махра, Маһиракай!..

– Мин тартмыйм бит.

– Их, Гитлерның анасын өшкерим! Нинди кеше сез?.. Әллә ир түгелме сез?

– Ирен ир, ну шулай да тартмыйм.

Егет «Китегезсәнә!» дигән шикелле, нәфрәтләнеп кулын селтәде дә бияләйләрен киде. Шул арада мич тирәсендәге кызлар да Зөфәргә игътибар итеп алдылар. Яхшы пальто, күн түбәле каракүл бүрек, эт тиресеннән озын кунычлы унты кигән һәм бер беләгенә зәңгәр тышлы бәрән толыбын салып, икенче кулына кара чемодан тоткан, бик тук кыяфәтле, таза егет берьюлы аларның кызыксынуын уятты булса кирәк, шунда ук ике кыз, торып, Зөфәр янына килделәр.

Кызларның бүрек кигәне, түгәрәк битен Зөфәргә күтәреп, елмаеп, балаларча сузыбрак аңардан сорады:

– Абый-й, сез Казаннанмыни-и?

– Әйе, Казаннан шул, – диде Зөфәр, аның тавышына көйләнебрәк.

– И-и, кара аны! Менә бәхет! Йә,ниләр бар соң Казанда, абый?

– Ни булсын... Бар да искечә.

– Анда да бик суыкмы?

– Бик суык.

– Ә фронттан нинди хәбәрләр бар?

– Кичә-бүгенгесен генә белмим. Ә гомумән алганда хәбәрләр бик яхшы. Идел буендагы хәлләрне ишеткәнсездер инде?

– Ишеттек, абый җаным, ишеттек! – диде кыз, бердән ялкынланып. – Шатлыктан тилерә яздык, еладык та, көлдек тә!

Зөфәр аңа бик җитди генә бер карап алды. Ә кыз үз нәүбәтендә: «Әллә ышанмыйсызмы?» – дигән төсле, аңа тагы да турырак, батыррак итеп карады. Зөфәр, уңайсызланып, сүзне икенчегә борды:

– Сез үзегез дә Казаннан, ахрысы?

– Әйе, Казаннан. Өч атна инде... Сагындык, кайтасыбыз килә.

– Шулаймыни? Ә нишләп йөрисез соң монда?

– Без филармониядән. Концертлар биреп йөрибез.

– Ә, алай икән? Артистлар, димәк? – Ул, таныргa теләгәндәй, кызларның әле берсенә, әле икенчесенә төбәлеп кенә карап алды.

Башына шәл чорнаган, какча битле, зур кара күзле икенче кыз шул чакта аңардан сорап куйды:

– Сез, абый кеше, кая барасыз?

– Ничек... кая барасыз?

– Шушы станцага килүегезме, әллә моннан бүтән җиргә китәсезме, дип соравым.

– Ничек дим. Монда да эшем бар. Ләкин миңа иң элек Турай авылына барырга кирәк иде.

– Турайга? – диде кыз, кинәт яктырып, аннары артына борылып, мич янында утырган өченче кызга кычкырып дәште: – Рәшидә апа, карале, менә Турайга барам, ди бу абый...

Рәшидә дигәннәре, торып, ашыкмыйча гына болар янына килде. Ул, күренеп тора, башкаларына караганда яшькә дә олырак, буйга да озынрак, өс-башы да аның пөхтәрәк иде. Килүгә иң элек ул баш кагып кына Зөфәр белән исәнләште. Аннары шешенкерәк кабаклары арасыннан елтыраган кечкенә коңгырт күзләре белән Зөфәргә бик туры-җитди итеп бер карады да, шунда ук тип-тигез тешләренең очларын гына күрсәтеп, сөйкемле генә елмаеп куйды.

– Турайга барасызмыни? Безгә дә нәкъ шул авылга бүген барып җитәргә кирәк бит, – диде ул, бик гади генә итеп.

Зөфәр бер мизгел аңардан күзләрен алалмыйча торды. Әллә ничек менә, кызның бер үк вакытта диярлек бик җитди-туры итеп каравы һәм матур-сөйкемле итеп елмаюы аны гаҗәпләнеп, югалып калырга мәҗбүр итте. Чибәр артистканың ирләр белән сөйләшкәндә күрсәтә торган, юри өйрәнеп алган бер сыйфаты идеме бу – моны тиз генә аңлау мөмкин дә түгел, әмма ничек кенә булмасын, аның ул сыйфаты Зөфәргә беренче караштан ук бик самими һәм бик табигый булып тоелды...

– Эш нидән тора соң? – диде ул, ниһаять, исенә килеп.

Рәшидә кара тарткан нечкә кашларын чак кына сикертеп куйды:

– Билгеле инде нидән торганы... Ат таба алмыйбыз.

Ул арада бая кулын селтәп киткән егет тә килеп сүзгә кушылды:

– Беда, брат! Бүген генә күрше станциядән товарный поездның тамбурына утырып килдек. Суы-ык, җилекләргә үтте!.. Мин, ат эзләп, авыл буенча чабарга тотындым. Юк кына бит... Мондагы колхоз председателенә бардым. Атыбыз бар, кешебез юк, ди. Мондый суыкта ат башына бала-чага утыртып җибәрә алмыйм, ди... Бер агач аякны тапкан идем, анысы илтеп кайткан өчен аракы сорый. Аракы! Аракы булса, мин үзем чанага җигелер идем әле...

Зөфәр көлемсерәп куйды:

– Инде нишләргә уйлыйсыз?

– Нишлик, утырабыз менә вокзал саклап...

– Без бик өшедек, – дип, балаларча еламсырап әйтеп куйды әлеге башлап килгән бүрекле кыз.

Рәшидә Зөфәргә якынрак килә төште:

– Карагыз әле, – диде ул, Зөфәрнең күзләренә тагын бик туры карап, – бәлки, сез табарсыз? Без үз өлешебезне түләр идек.

Зөфәр, бу әллә нинди менә акрын гына эчкәре үтә торган хәтәр караштан ихтыярсыз телсез калып, әмма бирешмәскә тырышкандай батыраеп, үзе дә аңа беравык текәлеп карап торды. Һәм гаҗәп хәл – кызның җитди карашы үзгәрмәстән йөзе тагын яктыра башлады, нечкә кашлары тибрәнеп куйды, тулы иреннәре әллә елмаерга, әллә нидер әйтергә теләп, кыймылдаган кебек булды. Ах, шайтан алгыры, уйный белә бит бу чибәр артистка!

Зөфәр, тирән генә сулап, башын читкә борды:

– Белмим шул, – диде ул, икеләнеп. – Читен мәсьәлә.

– Сез табарсыз, әгәр теләсәгез, – диде Рәшидә аңа, күптән белгән кешесенә әйткәндәй бик гади генә итеп.

Кызның бу сүзләре Зөфәрне гаҗәпләндерде һәм уйланырга мәҗбүр итте. Әлбәттә, ул табачак. Тик менә... кирәк микән болар белән юлдаш булырга? Үзе дә аңлап җитмичә, нәрсәдәндер, ни өчендер бераз гына шүрли кебек... Ул янында сүзсез генә җавап көтеп торучы күшегеп беткән кызларга, җилкәсен җыерып, бөрешеп төшкән егеткә бер карап алды (әмма Рәшидәгә караудан юри тыелды) һәм шунда ук ныклы карарга килде: һичшиксез алып китәргә кирәк боларны! Әйдә, миннән бер изгелек булсын! Эш белән йөриләр ич, мескеннәр!.. Һәм аңарда кинәт гаҗәеп бер энергия, кыюлык уянган кебек булды.

– Яхшы! – диде ул, өзеп кенә. – Мин хәзер бер җиргә барып киләм. Әйберләрне сезнең янда калдырып торырга ярыймы?

– Ә, пожалысты! – диде егет, өтәләнеп.

Рәшидә артык бер сүз дә әйтмәде, бары тик әлеге шул сихри елтыр күзләрен генә: «Менә сез нинди әйбәт кеше!» – дигән төсле, җылы бөркеп, сирпеп куйды. Кызлар исә куанычларыннан биешеп тә алдылар:

– Рәхмәт, абый җаным, рәхмәт!

– Рәхмәте соңыннан, әле атның табылганы юк бит,—диде Зөфәр һәм чемоданы белән толыбын кызларның мич буенда торган әйберләре янына илтеп куйды.

...Вокзалдан чыккач, ул туп-туры сельпо председателенә китте. Бу аның күз күргән кешесе. Әгәр өендә булса, Зөфәр өчен барысын да эшләргә тиеш, әлбәттә.

Ул чалбар кесәсен капшап карады: чиста спирт тутырган солдат флягасы тирән кесәдә бик әйбәт утыра икән. Председательгә бераз салып бирергә була. Дөрес, сельпо кешесе үзе дә алама сырецны таба торгандыр, ләкин бу түгел инде. Бу – әҗәл даруына йөри хәзер...

Зөфәр, үзе эчмәсә дә, заводның чиста спиртын юлга һәрвакыт берәр литр алып чыга. Чемоданында тагын бер савыты бар әле аның... Шул нәрсә акча яки сүз үтмәгән җирдә эшне көйләп җибәрергә ифрат ярдәм итеп куя бит, шайтан алгыры!

...Киң, буш урамнан салкын карны шыгырдатып атлый-атлый, Зөфәр вокзалда көтеп калган артистлар турында да уйлап барды. Нинди хәлдә йөриләр, мескеннәр! Кош оча алмаслык суык, өс-башлары юка, тамаклары да, билгеле, ач инде аларның... Быелгы, кырык өченче елның кышы бигрәк тә авыр килде, хәерсез! Сугышның беренче елында фронтта эшләр бик мөшкел булса да, тылда ярыйсы иде әле. Колхозларда икмәк бар иде, халыкның үзенең дә иске запасы, мал-туары бар иде. Хәзер киресенчә: фронтта хәлләр яхшырды, эш җиңүгә таба китте, әмма... тылның хәле бик начарланды. Колхозлар тәмам бөлде, ир-ат калмады, икмәк юк, халык ачыга яки бер бәрәңгедә утыра... Һәм менә бөтен ил сөремен коеп, тешен кысып яшәгән бервакытта бу бичаралар, халыкка культура хезмәте күрсәтәбез, дип, ачлы-туклы, өшеп-катып йөргән булалар. Йә, халыкта җыр кайгысымы соң хәзер! Шуны үзләре күрмиләр микәнни? Хәер, көчләп җибәргәч, йөри торганнардыр инде. Ләкин шунысы гаҗәп – бер дә сыкрау-сыктану сизелми үзләрендә тагын. Йөзләре күм-күк, күзләре ач, ә шулай да көлгән булалар, шаярган булалар, җитмәсә әле, катып-туңып бетүләренә карамастан, ерак юлга чыгарга ашкынып торалар... Ә ул Рәшидә дигәннәре тагын? Рәшидә... Рәшидә!.. Күпме мөлаемлык, җылылык, нәфислек, хәйләкәрлек, иркәлек бөркелеп тора аңардан!.. Һәм шулар, спектр аша үткән яктылык шикелле, төрле төсләргә кереп барысы берьюлы чагыла үзендә... Юк, чынлап та, нәрсә бу – аңа, Зөфәргә карата гына шулай юмартланып яктырдымы ул, әллә сүзен тыңлатыр өчен бары уйнап кына кылануы булдымы?.. Каян гына беләсең соң аны?.. Хәер, чибәр артистка юри кыланса да һич гаҗәп түгел! Токымнары белән шундый халык инде алар, ир дигән көчсез бәндәне үзләре өчен менә шулай йөгертә беләләр!

...Зөфәрнең бәхетеннән, сельпо председателе өендә булып чыкты. Ә бер сәгатьтән ике ат вокзал алдына килеп тә туктады. Чаналарның берсе җиңел кошевка, икенчесе киң үрәчәле гади чана иде... Һәркайсында икешәр толып та ята иде.

...Артистлар күтәренеп, шаулашып вокзалдан чыктылар.

Зөфәр аларга:

– Хәзәйкәнең самовары әзер, берәр стакан кайнар чәй эчеп чыгыйк, югыйсә юлда туңарбыз, – диде.

Ир артист, икеләнеп-пошынып:

– Бик шәп булыр иде дә ул, соңга калырбыз, чорт возьми! – диде. – Көтәләр бит безне анда...

– Ә без аяк өсте генә... Әйдәгез, толыпларны кимичә генә утырышыгыз!

Рәшидә, арада өлкәнрәкләре буларак, артлы чанага утырды. Калганнары үрәчәле чанага тезләнделәр. Зөфәр бер аягын читкә салындырып кына Рәшидә янына утырды. Самовар куеп торучы хәзәйкә өенә кузгалып киттеләр...

Анда, бик ашыкканга күрә, чишенмичә генә икешәр стакан сөтле кишер чәе эчтеләр. Берәү дә азык-төлеген чыгарып тормады. Булыпмы, булмыйчамы, Зөфәр моны белмәде дә. Дөрес, аның чемоданында шикәре дә, мае да бар, бер кирпеч икмәге дә бар иде, ләкин хәзер дүрт кеше алдына чыгарып куйсаң, валчыгы да калмаячак. Әлбәттә, ул мондый юмартлык күрсәтергә теләмәде.

Коры гына чәйдән дә бик хуп булып, аз гына җылынып, кызарып, безнең артистлар яңадан атлар янына чыктылар. Зөфәр аларга толыпларны өләшеп бирде, әйбәтләп, саламга күмелебрәк утырырга кушты. Рәшидәгә ул үзенең бәрән толыбын кидерде, чанага утырткач, аякларын салам белән күмештереп куйды. Рәшидә каршы сүз әйтү түгел, боларның барысын да нәкъ шулай булырга тиешле бернәрсә итеп кенә кабул итте... Зөфәр үзе, күп кенә җирдән эче иелеп беткән, тышсыз толыпны киеп, тар чанага кысылып һәм кызга борыла төшеп утырды да ат тотучыга кузгалырга кушты. Тимер табанлы чаналар сыкы кунган юл өстеннән, авыр ыңгырашып кына, кузгалып киттеләр.

Станция авылыннан чыгуга караңгы төшеп, күз тәмам бәйләнде. Җир өстен томанлы суык каплап алды. Тирә-юньдә нәрсә бар, үр менәләрме, сырт төшәләрме – аерырга һич мөмкин түгел иде. Тик аларның күз алларында, толып якасын баш түбәсенә хәтле күтәреп, кузлада утырган рус агаеның киң аркасы гына күренеп бара. Үле тынлык, әйтерсең салкын томан бөтен җанлы-җансыз табигатьне, тавыш-өнне, тирән су төбедәй, каплап-йотып алган... Бары ара-тирә чана табанының авыр итеп чыжылдавы һәм атның пошкырып-пошкырып куюы гына ишетелгәли. Алар үзләре дә сөйләшмиләр, толып якалары белән капланып, җылы тыннарын эчтә сакларга тырышалар. Шулай да Зөфәр күршесе турында гел уйланып, уйланып кына түгел, ничектер аны тоеп бара. Бик якын, янәшә генә бит!.. Бу тою аңа тансык, рәхәт, ул аны гүя эчтән җылыта һәм кызга отыры якынайта кебек... Шуңадыр инде Зөфәр суыкны бөтенләй сизми диярлек, хәтта вакыт-вакыт эсселәнеп китеп, толыбын җилбәгәй ачып җибәрәсе килә, тик астыртын суык битне-борынны өшетеп ташлар дип кенә курка.

Шактый юл киткәч, Зөфәр әллә ничә кат кием аша Рәшидәнең акрын гына калтырануын сизеп алгандай булды. Өши күрәсең, дип пошынып уйлады ул, һәм толып якасын кайтарып, кызга иелә төшеп сорады:

– Нәрсә, сезгә суык үтә башладымы әллә?

– Юк, сизмим әле хәзергә, – диде Рәшидә, толыбы эченнән генә. – Ә нигә?

– Шулай тоелды миңа... Калтырыйсыз кебек...

Рәшидә, бераз дәшми торып, акрын гына әйтеп куйды:

– Ул болай гына... Эчтә җылы калмаган бер дә.

Зөфәр дөрес чамалап алды бу сүзләрнең мәгънәсен: җылы юк – димәк, озак вакыт рәтләп ашаган-эчкәннәре юк! Бәлки, алар бүген әле валчык та капмаганнардыр. Бер кишер чәе белән генә тәндә җылы саклап булмый шул! Зөфәр артистканы кызганып куйды һәм, юлдашларча кайгыртучанлык күрсәтәсе килеп, әйтте аңа:

– Бик өши башласагыз әйтегез, Рәшидә, ярыймы? Берәр чарасын табарбыз.

– Рәхмәт, – диде Рәшидә, ишетелер-ишетелмәс кенә.

Мондый суыкта кышкы юл аеруча озын булып тоела. Барып җитә алмыйча күзләр тона. Күпме киттек, күпме калды икән, дип, юлчы гел шул хакта гына уйланып бара. Рәшидә акрын гына эчкә үткән рәхимсез суыктан бөтенләй оеган кебек булды, селкенмәде, тавышын чыгармады, ә Зөфәр, аның өчен борчылып һәм әледән-әле башын сузып, алга карый башлады. Ниһаять, бер өч сәгатьтән соң алар сирәк-мирәк кенә утлары күренгәләгән караңгы Турайга барып керделәр. Авыл уртасындагы зур гына бер иске йорт каршысына җитеп туктадылар. Бу колхоз идарәсе иде. Чанадан иң элек Зөфәр төште. Ләкин калган юлчыларның берсе дә нигәдер кыймылдамый, күрәсең, бик нык өшегәнлектән алар кузгалырга да куркып утыралар иде... Зөфәр, чаналарга карап, бераз таптанып торды да иелеп кенә Рәшидәгә дәште:

– Килеп җиттек бугай.

– Ә, шулаймы? – диде Рәшидә, авыр йокыдан уянган кешедәй сүлпән генә, һәм толып якасыннан башын чыгарды. – Алайса Яруллинны чакырыгыз әле монда.

Ләкин ул арада Яруллин дигәннәре, арткы чанадан төшеп, бөкрәеп һәм толып чабуларын җирдән сөйрәтеп, үзе Зөфәр янына килде.

– Кара әле, җаным, – диде Рәшидә аңа, – син үзең генә кереп әйт инде, безне иң элек фатирга илтеп куйсыннар.

– Ы, ыйе шыл! – диде Яруллин, өшегән авызын көчкә кыймылдатып, һәм алар Зөфәр белән идарәгә кереп киттеләр.

Унлы лампа белән тонык кына яктыртылган зур бүлмә уртасында аларны кыска тун, сырган чалбар кигән өлкән яшьтәге бер абзый каршы алды. Зөфәр сүзне үзе башлады:

– Председатель сез буласызмы?

– Мин булам.

– Исәнмесез! Менә артистларны алып килдем.

– Бик әйбәт. Көтәбез, – диде председатель, кул биреп.

– Башта аларны квартирага урнаштырасы иде.

– Һм... Клубта халык көтеп утыра бит... Нишлик икән, болай фатирыбыз әзер югыйсә.

– Безгә квартирага бармыйча ярамый, – диде Яруллин, сүзгә кушылып. – Әйберләрне куясы, өс-башны да алыштырасы бар, так што...

– Ярый алайса, түлке озак юанмассыз инде... Ничә кеше соң сез?

– Дүрт кеше, – диде Яруллин тиз генә, аннары Зөфәргә карап, сорап куйды: – Сез аерым төшәсездер бит?

Зөфәр беравык ни дияргә белмичә аптырап калды. Суйды бит бу юньсез үзенең урынсыз соравы белән!.. Нишләргә, ни дип әйтергә? Бер дә уйламаган иде Зөфәр бу турыда, дөресрәге, бергә килгәч, бергә булырбыз, дип, ничектер ваемсыз гына ышанып килгән иде... Инде менә чыга бел положениедән! Ә аның хәзер һич кенә ялгыз аерылып каласы килми иде, шуңа күрә ул аптыравын бер дә сиздермичә, кул селтәп кенә әйтеп куйды:

– Ярар, мин дә сыярмын әле шунда...

– Сыярсыз, өй иркен, – диде председатель һәм, караңгы почмакка борылып, дәште: – Мәчтүрә, бар, илт үзләрен Гыйззәт картларга.

Почмактан озын кара бишмәт, шәл өстеннән бүрек кигән бер апай күтәрелде. Якынрак килеп, егетләрнең әле берсенә, әле икенчесенә җәһәт кенә карап алды:

– Бүтәннәрегез кайда соң?

– Тышта, чанада яталар әле, – диде Яруллин.

– Әйдәгез алайса!

Өчәүләшеп чыгып киттеләр. Апай алгы чананың кучәренә аякларын салындырып кына утырды. Кузгалдылар. Бер тар тыкрыктан икенче урамга чыгып, кара-каршы салынган өйнең җилкапкасы төбенә килеп туктадылар.

Апай, капканың аркылы тыккан кендеген тартып, эчкәре узды да, болдырга менеп, ишекне дөбердәтә башлады. Шунда ук урамбаш өйдә басып кына куйган лампаны күтәрделәр булса кирәк, кечкенә тәрәзәсе сап-сары яктырып китте. Кемдер ишеккә чыкты.

– Мәликәттәй, кунакларны каршы ал! – дип кычкырды апай аңа.

Юлчылар, чаналарыннан төшеп, әйберләрен күтәреп, ашыга-ашыга ишеккә килделәр. Караңгы өйалдын узып, апайның: «Әйдәгез, монда», – дигән тавышына ияреп һәм әллә никадәр суык ияртеп, өйгә кереп тулдылар. Аларны кечкенә буйлы бер әби каршы алды:

– Әй, Алла бәндәләре! Шәйхулла әйткән әртичләр сезмени инде ул?

– Без, әбекәем, без! Рәхимегезне боерып, кабул итәсез инде, булмаса! – диде Яруллин, дәртле күренергә тырышып.

– Итмичә ни, итәбез! Әйдә, узыгыз,уз, мескенкәйләрем!

Кызлар өсләреннән салып ташладылар да тиз үк зур җылы мичкә барып сөялделәр һәм, куллары белән генә түгел, битләре белән дә сыланып, калтырана-чиркана, җылынып азапландылар. Ләкин Яруллин шунда ук аларны ашыктыра да башлады:

– Ягез, кызлар, тизрәк булыгыз! Мич кочаклап торырга вакытыбыз юк, председатель абзый озак юанмаска кушты.

– Тукта, ашыктырма ул хәтле... Аз гына җылы керсен эчкә! – диде кызларның берсе, түше белән мичкә терәлеп, ә икенчесе еламсырап әйтеп куйды:

– Капкалап аласы иде бит, эчем эчкә ябышты инде, Ходаем, күпме түзәргә кирәк.

– Түзәбез инде, сылуым, түзәбез! – диде Яруллин, аны юатып. – Башкача мөмкин түгел, сәгать менә сигез тулып киткән.

Мичтән иң элек Рәшидә аерылды:

– Киттек, кызлар... Тизрәк башласак – иртәрәк кайтырбыз.

Аннары ул, әби янына барып, аны иңбашыннан кочаклап алды:

– Әбекәем, бәгырем, – диде балаларча юмаланып,—без кайтуга өй җылы булыр бит?

– Җылы булыр, кызым. Сез киләсен белгәч, бүген ике тапкыр ягып уздырдым.

– Менә рәхмәт, әбекәем!.. Без кайтуга кайнаган самовар да булыр бит?

– Анысы да булыр, кызым!

– Чәй янына әле, бәлкем, берәр җылы аш та булыр, ә, әбекәем? – диде Рәшидә, тагы да юмалана төшеп, һәм Зөфәргә хәйләкәр генә күз кысып куйды.

– Әй, татлы тел! – диде әби, кәефле генә көлеп. – Әмәлләрбез инде берәр нәрсә, әмәлләрбез сезнең кебек иркә кунакларга.

Рәшидә аны кысып үбеп алды да, җиңеләеп, шатланып, әйберләрен барларга тотынды. Кызлар кече якка кереп, сырган чалбарларын салып чыктылар. Өс-башларын рәтләп, әзрәк төзәтенеп алдылар. Биш-ун минуттан бары да әзерләнеп, кечкенә чемоданнарын кулларына алып, ә Яруллин гармун тартмасын иңенә асып, ашыга-ашыга чыгып та киттеләр.

Чыгар алдыннан гына Рәшидә Зөфәрдән сорап куйды:

– Сез безнең белән бармыйсызмыни?

– Мин... соңгарак, – диде Зөфәр, дусларча баш кагып кына.

Бөтен күргән-ишеткәннәре аның күңелендә бу тыйнак һәм чыдам артистларга карата гаҗәпләнү катыш соклану хисе тудырып өлгергән иде. Тагын ни беләндер аларга, бигрәк тә Рәшидәгә файдалы буласы килә иде. Рәшидәнең әледән-әле аңа игътибар итүе һәм дәшүе аны ихтыярсыздан дулкынландыра башлаган иде инде. Ул һаман бер нәрсә турында уйлана: нидән икән бу игътибар, нидән килә икән бу үз иткәндәй җылы итеп карау? Әллә чынлап та алар арасында яшерен якынлык җебе бер-берсенә сузылып өлгердеме?.. Ничек моны аңларга, ничек моны белергә?

Артистларның җилкапкадан кызу-кызу чыгып киткән аяк тавышлары тынуга, Зөфәр карчык янына килде һәм иплән кенә сүз башлады:

– Мәликә әби... шулай бит әле?

– Ийе, улым, ийе.

– Мәликә әби, үзең дә ишеткәнсеңдер, кызларыбызның көне буе ашаган-эчкәннәре юк бит... Өшеп-катып килделәр, әнә тагын валчык та капмыйча чыгып та киттеләр... Клубтан кайткач, бик әйбәт кенә ашатырга кирәк булыр инде үзләрен.

– Кирәк инде, кирәк. Тик менә аптыраган әле, – диде карчык, уйга калып. – Үзебез дә бик өзелеп торабыз шул, улым! Нишләрбез икән соң?

– Син, Мәликә әби, рәтлә инде, рәтлә... Тап бер җаен!

– Булмаганны каян табасың. Әнә Шәйхулла председателебез, сезнең киләсене белгәч, бербөтен икмәк белән азрак май җибәргән иде... Ул гына ни, йөрәккә ятмас шул. Булмаса, үземнән берәр чуен бәрәңге пешерермен... Нишлисең, хәзинәдә бары белән инде.

– Менә нәрсә, Мәликә әби, мин сине буш итмәм. Үзеңә азрак чәй-шикәр бирермен. Акчасын да түләрмен... Син инде безгә итле аш пешер... Итең бардыр бит?

Чәй-шикәр дигәнне ишеткәч, карчыкның колаклары торды. Күптән инде аның чын грузин чәен күргәне юк, ә чәй карчык кешегә әҗәл даруы белән бер инде ул! Әмма ит тә бик кызганыч, әүвәлге шикелле чоланда түшкәсе белән асылынып тормый... Шулай да бераз ык-мык итебрәк торганнан соң, ул йомшара төште:

– Шулпа тәмләндерү өчен генә тоткан итебез барын бар да бит, нишлим икән соң? Үзебездән өзеп бирергә туры килә инде...

– Син кызганма, әби! Итсез тормассыз әле... Әйтәм ич, буш итмәм. Ә чәй белән шикәрне, теләсәң, мин сиңа хәзер үк биреп куям. Минем күчтәнәчем булыр. – Һәм ул чемоданын алып ача да башлады.

Карчыкның икеләнүе, ниһаять, юкка чыкты:

– Ярый алайса, – диде ул, бердән юмартланып.—Яхшы кешеләрдән газиз җан да кызганыч түгел дигәндәй, булмаса, бер чирек каз турап өйрә пешерермен үзегезгә.

– Менә рәхмәт, әбекәем, менә рәхмәт! – диде Зөфәр һәм карчыкның кулына илле граммлы бер төргәк чәй белән биш-алты зур шакмак шикәр тоттырды.

Бу эшне җайлагач, Зөфәр клубка барырга дип ашыкмыйча уйланып кына киенә башлады. Билгеле, барасы килә аның, тик шулай да бер нәрсә борчый аны: ул белә, клубта торганы хатын-кыз булачак. Менә шул ирләре яки уллары фронтка китеп беткән хатын-кызларның инде аңа: «Бу нинди әвендәй тап-таза ир монда йөри?» – дип гаҗәпләнеп, шикләнеп, ят күреп караулары мөмкин. Бу нәрсәне аның авыл җиренә чыккан саен сизгәне бар... Бер дә яратмый ул моны, һәм хатын-кызлар җыелган җирдән ераграк булырга тырыша торган иде... Әлбәттә, берәүнең дә аңарда эше булмаска тиеш, берәүдән дә ул куркып тормый торуын, ләкин шулай да ни өчендер борчылмыйча булдыра алмый иде. Менә хәзер дә ул шул хакта уйлап алырга мәҗбүр булды.

**III**

Клуб дигәннәре урамга кырынрак утырган, манарасы киселгән иске мәчет бинасы икән. Ихатасы-мазары юк, тирә-ягы ап-ак кар яткан буш ялан... Киң генә такыр сукмак, урам юлыннан аерылып, клубның шул ялангa караган болдырсыз ишегенә алып бара.

Зөфәр килеп җиткәндә аның тирәсендә кеше-кара күренми һәм хәрәкәт-тавыш ишетелми иде. Тик бозланып каткан кечкенә тәрәзәләрендә зәгыйфь яктылык, сары тап булып, тонык кына чагыла иде. Концерт инде күптән башланган булырга тиеш.

Зөфәр тышкы ишектән туп-туры тамаша «залына» барып керде. Ягылмаган, ярым караңгы бу «зал» халык белән шыгрым тулы иде. Бик еш итеп тезелгән озын, тар эскәмияләрдә туннан, сырмадан, шәл чорнаган, бүрекләрен батырып кигән, хәтта бияләйләрен дә салмаган хатын-кызлар, яшүсмерләр, бала-чагаларр тыгызланып утырганнар. Ара-тирә генә олы яшьтәге агайлар һәм карт бабайлар да күренә. Егетләр, ир уртасы кешеләр бөтенләй юк диярлек... Түрдәге тәбәнәк кенә сәхнәнең нәкъ алдында бердәнбер асылмалы калай лампа яна, бары шул гына сәхнә эчен һәм алгы рәтләрне азрак яктыртып тора...

Зөфәр килеп кергәндә сәхнәдә Яруллин, кыңгыраулы гармунын уйната-уйната, фашистлар турында такмак әйтә иде. Шуңа күрә Зөфәргә игътибар итүче дә булмады. Ул стена буйлап кына сәхнәгә таба узды да алгы эскәмиянең очына гына кысылып утырды.

Яруллин такмагын әйтеп бетерде, ләкин, ни сәбәптер, халык кул чапмады. Зөфәр аптырый калды: нидән бу, әллә ошатмадылармы? Алай дисәң, егет бик матур уйнап, бик дәртле җырлады бит! Халык шылт та итмичә тыңлап утырды. Хәер, моның сере бик тиз ачылды: монда

кул чабу гадәте юк икән, монда артистны киеренке бер җитдилек белән гаять бирелеп тыңлыйлар һәм шунлыктан кул чабуны хәзерге авыр шартларда килешми торган бер уен-балалык дип саныйлар икән... Әгәр артистның чыгышы ошаса һәм аны яңадан чыгарасылары килсә, моны төрле яктан кычкырып, туп-туры үзенә әйтәләр икән... Яруллин җырлап беткәч тә нәкъ әнә шулай булды – аз гына тынып торганнан соң, кешеләр тойгы-теләкләрен төрле яктан кычкырып әйтә башладылар:

– Рәхмәт, туганкай, рәхмәт!

– Ачтың күңелләребезне!

– Кабатла әле тагын бер генә, кабатла!

– Сорыйбыз, сорыйбыз!

...Яруллин бер-ике тапкыр баш иде дә, киерелә биреп, гармунын тартып куйды. Халык шунда ук тып-тын булды. Алар гаҗәп тыйнак, әдәплеләр иде.

Бу юлы артист, гармунына кушылып, бик моңлы гына бер авыл көен җырлады:

Борыламын да карыймын
Су юлы миләшенә;
Көтәрмен, бәгырем, карамый
Ятларның киңәшенә.
Коела миләш чәчәге
Чиләккә, суларыма;
Күзләрем алмый карыймын
Кайтасы юлларыңа.

. . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Зөфәрнең артында гына бер кызмы, яшь хатынмы бик тыелырга тырышып, ләкин тәкате җитмичә иелеп төшеп үкси башлады. Аңа ияреп тагын кайберәүләрнең ихтыярсыздан сулкылдап куюлары ишетелде. Ә бер олырак яшьтәге хатын йөрәгеннән бәреп чыккан тирән әрнү белән өзгәләнеп әйтеп ташлады:

– Ай, газизләрем! Тилмереп, кан җылап көтәбез шул, көтәбез!

Аңа каршы ниндидер бер агай басынкы тавыш белән акрын-йомшак кына: «Сабыр, килен, сабыр!» – дип куйды.

Җыр бетте. Караңгыда утырган халык бер мизгел тып-тын булып торды. Әйтерсең алар хыяллары белән бу иске мәчет эченнән бик еракка иң кадерле якыннарын, өметләрен, бәхетләрен эзләп киткәннәр иде. Һәм гүя әнә шул ерактагы фронтның карлы далаларына, бозлы

сазлыкларына, кара урманнарына барып тапкан, кавышкан газиз якыннарыннан аерыла алмыйча, кире бу салкын ялгызлыкка кайтырга кодрәтләре җитмичә утыралар иде.

...Әйе, мондый хәлдә ду килеп кул чабу мөмкин дә түгел иде. Күпмедер вакыт үткәч кенә хатын-кызлар рәхмәтләрен әйтеп, Яруллиннан тагын кабатлавын үтенделәр. Ләкин монда артист белән тамашачылар арасында бик табигый гади генә мөнәсәбәт урнашкан иде. Бернинди артык кысташу, шаулашу юк. Артист кулын күтәрдисә, барысы да шунда ук тыналар, ул ни әйтсә, шуңа берсүзсез риза булалар. Әле дә Яруллинның шаярып кына ялваргандай: «Апайлар, җиңгиләр, минем дә хәлемә әзрәк керегез инде, менә... эһем-эһем, тамагым чистый кипте бит, җитмәсә, безгә монда чиләк белән су да куярга онытканнар... Ләкин сез тыныч булыгыз, мин әле сезгә уйнармын да, җырлармын да... бүген кич безнеке ич!» —диюенә каршы, хатын-кызлар: «Ярый алайса, ярый, үзеңә кара инде, җаным!» – дип, шунда ук килештеләр һәм тынып та калдылар.

Хәер, бу ару-талуны белмәс артистның сәхнәдән чыгып торган чагы булмады диярлек – ул бер үк вакытта кемнең чыгасын әйтеп торучы да һәм чыккан берсенә алмаш-тилмәш ике гармунда уйнап торучы да иде. Хәзер дә менә ул сәхнә түренә таба бер-ике генә адым атлаган булды да, кире борылып килеп, үзенең яңа ролен үтәргә тотынды:

– Инде, кадерле апалар, җиңгиләр, сеңелләр, күңелләрне дә бер ачып җибәрик, башлар күтәрелә төшсен!.. Яшь артистларыбыздан Асия Биктимерова белән Зөбәйдә Саттарова. Төрле халык биюләре... Башладык!

Сәхнәнең ике як кырыена эленгән иске чаршау артыннан берсе авыл кызы, икенчесе авыл егете булып киенгән биючеләр йөгереп чыктылар. Башта куышып китеп, аннан кара-каршы торып, тыпыр-тыпыр бии дә башладылар. Бусы татарча булды. Шуннан соң, киемнәрен алыштырмыйча гына, егете бөеренә таянып, кызы иңбашын уйнаткалап һәм бармак шартлаткалап, икесе дә «ысс... ыс» дигән сәер бер тавыш чыгарып, башкортча биеп күрсәттеләр. Бусы да матур-шома гына килеп чыкты. Моңардан соң алар, чаршау артына яшеренеп кенә, берсе алъяпкычын салып, яулыгын косынка итеп бәйләп, икенчесе тиз генә камзулы белән түбәтәен ташлап һәм башына фуражка каплап чыктылар да, тузанлы идәнне бик яман дөбердәтеп, «эх, эх!» дип кычкыра-кычкыра биергә тотындылар. Бусы инде русча «Барыня» иде.

Яшь артистлар халыкның сораганын көтеп, кыстатып тормадылар – бөтен «репертуарларын» бер тоташтан күрсәтеп бирделәр. Һәм, чыннан да, кәефләрне беркадәр үзгәрттеләр дияргә ярый; тамашачыларның йөзләре яктыра төште, күзләрендә дәрт сыман нәрсә кабынды, хәтта биючеләр куптарган тузаннан клуб эче дә ничектер җылыныбрак киткән төсле булды.

...Биючеләрдән соң сәхнәгә, ниһаять, Рәшидә чыкты. Зөфәр бөтен игътибарын биреп, йотлыгып караган хәлдә аны каршы алды һәм, ул сәхнәдән чыгып киткәнчегә чаклы, аңардан инде күзләрен аера алмады. Шушы минуттан барысы да – караңгы, салкын клуб эче дә, янәшәсендә генә тыгызланып утырган тамашачылар да, хәтта гел күз алдында селкенеп торган Яруллин да аның өчен югалган кебек булды.

Рәшидәнең өстендә киң итәкле, тар җиңле, ябык якалы кара-зәңгәр озын күлмәк иде. Бу күлмәк аның билен бик нечкә, күкрәген тулы, иңбашларын йомры итеп күрсәтә иде. Әйтәсе дә түгел, артистка, ябыклыгына карамастан, нәфис-сылу гәүдәле иде – Зөфәр иң элек менә шуңа игътибар итте. Аннары бераздан ул чын гаҗәпләнү белән тагын шуны күреп алгандай булды: әлеге төрле хисләр чагылышы артистканың тиз үзгәрүчән ак йөзендә генә түгел, гүя менә сылу гәүдәсендә дә сизелә кебек, ничектер менә гәүдәсе дә аның хис белән тулы һәм һәрбер хәрәкәтеннән моны тоеп була кебек иде.

Менә ул, җиңел генә атлап, сәхнәнең кырыена ук килеп басты. Өшүдәнме, дулкынланууданмы, иңбашларын җыерып куйды, башын текә генә күтәреп, асылмалы лампага карап алды, аннары гадәтенчә туп-туры төбәлеп, шылт та итмичә көтеп утырган халыкка беравык карап торды, бары шуннан соң гына борыла төшеп һәм башын чак кына кагып, Яруллинга ишарә ясады.

Яруллин кычкырып: «Татар халык көе «Тәфтиләү» —диде һәм утырып зур баянын акрын гына суза башлады. Рәшидәнең күзләре берьюлы уйчанланып, ничектер эчкәре киткән кебек булды, йөзенә моңсу җитдилек чыкты – һәм менә һичкемне, һичнәрсәне күрмәс булып, саф, нечкә тавыш белән җырларга тотынды... «И мөкатдәс, моңлы сазым! Уйнадың син ник бик аз?» ...Бу көйнең моңын һәм бу сүзләрнең мәгънәсен телдән генә әйтеп биреп бетерерлек түгел иде. Бу көйгә, бу сүзләргә бөтен бер зур халыкның гүя барлык йөрәк зары, саф вөҗданы, ачы нужасы, авыр хезмәте, кара бәхете, якты өмете, кырлары-яланнары, таулары-урманнары, күлләре-сулары, сандугач-былбыллары, караңгы көзләре, язгы таңнары – барысы-барысы бергә җыелган, бергә үрелгән, бер киң дәрьяга әверелеп ага да ага иде... Тамашачы да гүя менә шуның дулкыннарында тирбәлә-тирбәлә агып китте. Барысы онытылды, барлык фани уйлар «дөнья читлегеннән» каядыр бик биеккә, бик еракка очты... Җырның беренче сүзләре үк инде тамашачы күңеленең иң нечкә кылына барып кагылды, исертте-сихерләде, һәм күпләрнең күзләреннән, үзләре дә сизмәстән, җылы яшьләре агып төште. Бу гади елау түгел иде, бу күңелләр төбеннән күтәрелгән бик изге, бик кадерле олы бер хиснең саф чишмәдәй саркып чыгуы иде.

Җыр беткәч тә кешеләр өнсез калгандай, һич селкенмичә, тып-тын утырдылар. Рәхмәт белдереп, яңадан кабатлауны сорап кычкыручы бер генә кеше дә булмады, хәер, бу кирәкми дә

иде. Шушы өнсез утыру, шушы яшьтән чыланган йөзләр һәм сихерләнгәндәй җырчыга хәрәкәтсез төбәлгән күзләр барысының да күңелләре ни белән тулганын бик ачык әйтеп тора иде... Һәм Рәшидә, көчле алкышка рәхмәтен белдергәндәй, аларга яктырып елмайды, хәтта аз гына башын да иеп куйды. Ул әле җырлаячак иде, дәртләнеп, шатланып җырлаячак иде.

...Яруллин торып: «Юксыну», – диде һәм, кире утырып, баянының нечкә телләренә басып кына тавыш бирде. Рәшидә яктыга үрелгәндәй йөзен күтәреп, бөтен гәүдәсе белән алгарак омтыла төште һәм уң кулын күкрәгенә якын китереп, шуннан сосып алгандай тирән сагыш-моң белән җырлый башлады:

Күз карашым нинди уйчанланды,
Син беләсең микән, юк микән?
Син киләсе юлдан күзем алмый
Сине көтәм, иркәм, кич-иртән.
. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Бу – соңгы вакытларда гына халык арасына таралган һәм бик тиз арада күңелләрне биләп алган җыр иде. Көе аның композиторныкы, сүзләре – шагыйрьнеке, әмма халыкның үз иҗаты шикелле телдән телгә күчеп, бөтен җирдә җырлана башлаган иде. Вакытның рухын, кешенең күңеленә тулганын әйтеп бирә белгән җыр гына мондый бәхеткә ирешсә ирешә торгандыр...

...Менә хәзер дә Рәшидә авызыннан чыккан «Юксыну» тыңлаучыларга аларның үз юксынуы, үз сагышы, үз зары булып ишетелде. Бердән алар җырга йотылдылар, бары бер кодрәткә – бер исерткеч тойгыга буйсынган шикелле җырчыдан күзләрен аера алмыйча, аның һәр сүзен аңлап, йөрәкләреннән кичереп утырдылар. Хатын-кызлар арасыннан тагын кайберәүләре, сагыш белән тулы күңелләре чайкалып түгелгәндәй, тәкатьсездән үкси башладылар.

Хәтта Зөфәрне дә бу җыр тетрәтмичә калмады. Дөрес, аның юксыныр кешесе юк иде, сугыш китергән михнәт-газап аның күңеленә авыр таш булып ятмаган иде, әмма шулай да янындагы кешеләрнең тирән кичереше аңа да күчте булса кирәк – берара бугазы төбенә каты төер килеп тыгылды. Ләкин бу төерне ул ничек тә йотарга тырышты, чөнки бу минутта Рәшидәнең акрын гына кыймылдаган тулы иреннәре, тирән илһамлану белән балкыган йөзе, аз гына дымланып каядыр еракка төбәлгән күзләре аның өчен үзе бер җыр, үзе бер сихер иде.

...«Юксыну»дан соң «Туган ил», «Хатлар язам», «Сибелә чәчәк», «Яз да була», «Арча», «Шомыртым», «Эрбет», «Фирдәвескәй», «Сания» – берсе артыннан берсе агылып кына торды. Рәшидәнең бу кадәр армый-талмый җырлавы гаҗәп иде. Киресенчә, яңа җыр башлаган саен үзе ул ничектер рухлана, дәртләнә, ә тавышы отыры көчәя, иркенәя барды. Инде соңгы җиңел

җырларга күчкәч, ул, тәмам канатланып киткәндәй, иңбашларын җиңел генә уйнатып, тибрәнеп, талпынып җырлады. Һәр җыры аның тыңлаучыларны беткәнче биләп алды; моңландырды да, уфтандырды да, кабындырды да һәм күз яше аша көлдерде дә ул аларны!

Иң соңгы җырын аеруча бер ялкынлану белән башын артка чөя биреп, кулларын җәеп, аяк очына күтәрелә төшеп җырлап бетерүгә, Рәшидә үзе дә исереп киткәндәй чайкалып куйды һәм күзләрен йомып, кулын маңгаена куеп, беравык хәрәкәтсез калып торды. Шул чакта халык аны рәхмәт-мактау сүзе белән күмеп ташлады:

– Яшә, чибәркәй, мең яшә!

– Безнең сынык күңелләребезне юаттың-куандырдың, рәхмәт төшсен үзеңә!

– Былбыл да син , син дә былбыл икәнсең!

– Безнеке кебек сугыш кырларында йөргән ярың булса, исән-сау кавышырга насыйп итсен!

Рәшидә сискәнеп уянгандай күзләрен ачты, ни ишетәм дигән төсле бер мизгел аптырап-югалып торды, аннары кичерү сорагандай нәүмиз генә елмаеп, ике кулын да күкрәгенә куеп, халыкка кат-кат башын иде... Һәм иң соңгы минутта гына, әллә сөенечен аңлатырга теләп, әллә бүтән бер серен сиздерәсе килеп, ул нурлы күзләре белән Зөфәргә ничектер җылы-якын да, аз гына хәйләкәр дә итеп карап алды. Бу караштан Зөфәр тагын эсселәнеп китте, тагын, ни уйларга да белмичә, аптырап калды.

...Концерт бетте. Халык, тар эскәмияләрдән торып, акрын гына тарала башлады. Бер төркем кызлар, турыдан гына атлап, сәхнәгә, артистлар янына менделәр. Колхоз председателе, карсак буйлы, зур башлы Шәйхулла абзый, Яруллин янына барып аның кулын кысты, ә Яруллин аңа, кызып, кулын болгап нидер сөйләргә тотынды.

Зөфәр, халыкның чыгып беткәнен көтеп, стена буенда ялгызы гына басып торды. Бик гаҗәеп һәм бик көчле тәэсир калдырды бүгенге концерт аңарда... Әлбәттә, Казанда аның сирәк-мирәк кенә концертларда булгалаганы бар иде, әмма моның кебекне гомерендә һич күргәне юк иде. Дөресен генә әйткәндә, сәнгатьнең нинди зур кодрәткә ия булуын ул бары менә шушы салкын, караңгы, иске мәчет эчендә генә күрде, аңлады, хәйран калды... Юньләп исемнәре дә билгеле булмаган, болай карап торырга йолкыш кына дүрт артист халыкны нишләтте? Гаҗәеп бит бу, гаҗәеп!.. Халык гүя ач булуын, ялангач булуын, нинди авыр михнәттә яшәвен тәмам онытты; елады, көлде ул, һәм иң гаҗәбе – тирән рухи бер канәгатьләнү алып, гүя эчләренә тагы да зур сабырлык, чыдамлык, батырлык җыеп таралды ул!.. Инде кайткач, һәркайсы коры чәен, иписез бәрәңгесен тыныч кына ашап-эчеп ятачак. Менә, нишлисең, рәхимсез сугыш китергән

нужаны күтәрер өчен һәм сыгылып төшмичә яши-эшли алыр өчен кайчагында кешегә үзебезнең җыр, гади халык җыры да искиткеч зур көч-кодрәт бирә икән.

...Кайтырга чыктылар... Чалт аяз күктә түп-түгәрәк һәм ап-ак тулган ай тора. Шундый якты-якын ул —өстендәге әлеге көянтә-чиләкле кызны хәтерләткән күксел шәүләсе ап-ачык күренә һәм, бик теләгәндә, шуңа ничектер менә барып җитеп булыр иде кебек тоела... Шыгырдап торган коры салкын... Авыл өсте зәңгәрсу-якты... Чатнап бүрәнә шартлаганы ишетелеп кала... Салкын тешкә тия, өскә сылана, әмма эчкәре үтәргә бик ашыкмый кебек... Атлавы җиңел, аяклар үзләреннән-үзләре йөгерергә торалар.

Алдан, өч артистканы озатып, кызлар төркеме китте. Алардан бер илле адым арттарак калып, Яруллин, колхоз председателе һәм Зөфәр шагыр-шогыр атлыйлар... Яруллин бияләе белән авызын каплабрак, председательгә бертуктаусыз сөйләп бара (клубта ук башланган сүзнең дәвамы булса кирәк):

– Анысы шулай инде аның, Шәйхулла абзый... Халык канәгать булып калса, безнең өчен дә зур шатлык ул, конечно... Артистны шул яшәтә, шул йөртә бит инде. Так что ул яктан без үзебез дә бик канәгатьбез... Ну шулай да, Шәйхулла абзый, син – председатель, ә мин шушы кызларны ияртеп, аларга баш булып йөрүче бер кеше: давай, ачык кына сөйләшик әле. Тыйнакланып, оялып тора торган чак түгел. Гаеп итмә! Озын сүзнең кыскасы, син инде безне, абзый кеше, коры рәхмәт белән генә сыйлап җибәрмә, ярыймы!

Председатель бияләй сырты белән бәсләнгән мыекларын сыпырып куйды:

– Нишләп коры рәхмәт кенә булсын! Түлибез, дидем ич, иртәгә акчасын сполна алырсыз.

– Һәй, Шәйхулла абзый, нигә инде юри аңламаган булып кыланасың? Ул хактамыни сүз? Акча, имеш! Ә беләсеңме, артистның шушы концерт өчен алган акчасы, Казанга кайткач, бер кәтелүк бәрәңгегә дә җитми бит. Шуның өчен өшеп-катып ачлы-туклы йөрсенмени ул?

Шәйхулла абзый нигәдер җавап бирмәде, Яруллин да бераз дәшмичә барды... Артистларны бәхилләтү мәсьәләсе хәзер генә булып үткән бик күркәм эшнең шактый күңелсез ягы иде, билгеле... Ләкин моның шулай булуына Зөфәр бер дә гаҗәпләнмәде, район тирәсенә чыккан һәрбер кешенең ничек тә азык табарга тырышуын ул бик яхшы белә иде, шуңа күрә Яруллинның да «теләнүен» бик хаклы дип тапты һәм аны яклыйсы килде:

– Әйе, халыкка мондый зур хезмәт күрсәтүчеләрнең бәясен белергә кирәк, – диде ул, житди генә. – Колхозның келәте бөтенләй бушап калмагандыр әле, Шәйхулла абзый, саранланып тору килешмәс!

Шәйхулла абзый авыр гына сулап куйды:

– Һи, туганнар, булса, кем саранланып торыр иде... Барысын да биреп бетердек бит, барысын да кырып-себереп... Үзегез дә беләсез хәлләрне... Дөрес инде, сезнең кебек тансык кунакларны буш кул белән генә озату килешеп бетмәс, анысын үзем дә уйлаган идем уйлавын, тик әле безнең крестьян гадәтен беләсез – алдан кычкырырга яратмый ул... Ярый, хәерле булсын, кәнсиртегез бик ошады, бәхилләтми ярамас. Түлке он өмет итмәгез, он юк, иллә-мәгәр ит-майдан бераз күчтәнәч куярбыз.

– Менә рәхмәт, Шәйхулла абзый! – диде Яруллин, бердән җанланып. – Безгә ни генә бирсәң дә бата, талымланып тормыйбыз, рәхмәттән башка сүз юк, вәт шул! Тик син гаеп итә күрмә инде, яме? Нишлисең, положение!

– Беләм, туган, беләм! – диде председатель, башын кагып.

Артистлар төшкән йорт каршына килеп туктадылар. Бу суыкта озак басып торырлык түгел иде, Шәйхулла абзый, ике куллап бүреген батыра төшеп, китәргә җыенды.

– Элекке чак булса, болай гына аерылышмас идек, әзер табынга кайтып, бераз чәйләп-мәйләп утырыр идек тә бит, ни, үзегез әйтмешли, плаженья! – диде ул, көлемсерәп. – Ярар, соңгы очрашу булмас әле, иминлек кенә кайтсын!

– Һии, дошманны җиңгәч – иминлек кайткач, балда-майда йөзәрбез әле, Шәйхулла абзый!

– Алла бирсә! Ярар, хәзергә хуш иттек!

– Хуш, Шәйхулла абзый, хуш!

Председатель китеп баргач, Яруллин өйгә керешли, Зөфәр алдында махсус акланырга теләгәндәй, ашыгып әйтеп куйды:

– Саран, чукынган карт! Сорамасаң, үзе белеп бирәсе түгел. Ә соңыннан кызлар мине битәрләргә тотынырлар. Үзем өчен генә булса, сорап та тормас идем.

Зөфәр моңа каршы бер сүз дә әйтмәде – егетнең хәйләсе бик өстә ята, шуңа күрә эченнән генә тынды.

Алар өйгә килеп кергәндә, кызлар өсләреннән салганнар, зур калай тазга яньчелгән җиз комганнан бер-берсенә җылы су коеп, кулларын юып торалар иде. Өстәлгә киҗеле ашъяулык ябылган, тәлинкә-кашыклар һәм түп-түгәрәк бөтен бер икмәк куелган иде.

Егетләр дә чишенеп ташладылар, кулларын юдылар, аннары барысы да өстәл янына уздылар. Яруллин утырмыйча ук кулына тизрәк пычак алды.

– Каяле, ипекәйне, күкрәккә терәп, үзем телим әле булмаса, – диде ул, изге бер эшкә тотынгандай тантана белән.

Ә кызларның берсе, балаларча түземсезләнеп, кулын чәбәкли башлады:

– Әбекәй безне ни беләндер сыйлый, ни беләндер сыйлый! Сизәсезме, исе таралган! Әллә каз маенда пешкән ботка инде?

Казан янында торган әби, сабыр гына елмаеп:

– Әз генә түзегез, кызлар, әз генә, – диде. – Хәзер белерсез.

Зөфәр барысыннан соң гына өстәл янына килеп утырды. Ничектер үзлегеннән аның урыны тагын Рәшидә белән янәшә туры килде. Гүя менә язмыш үзе алар турында кайгыртып кына тора диярсең!

Яруллин һәм кызлар ипи телемен тозлап ашарга да тотындылар. Тик Рәшидә генә сузылмады.

– Туктагыз әле, нигә коры икмәккә ташландыгыз? —диде ул. – Яруллин, безнең бит маебыз булырга тиеш.

– Ә, ийе, ийе, – диде Яруллин һәм, тиз генә торып, бер бәләкәй капчыктан ике төргәк алып китерде. Берсе аның кәгазьгә төргән атланмай кисәге, икенчесе – чүпрәккә төргән дуңгыз мае – шпик булып чыкты. Ләкин атланмай шакылдап туңган, пычак та үтәрлек түгел иде... Ә шпик туңмаган, Яруллин аны вак кына телемнәргә кискәләде.

– Менә инде, кызлар, телисезме-юкмы, шушы тырышып чаба торган хайванны авыз итеп карыйсыз. Коры икмәк кенә үтмәсә, конечно...

Зөфәр дә чемоданнан үзенең азыкларын – зур гына кисәк пешкән итен, савыты белән маен, кап белән шикәрен чыгарып, өстәл уртасына куйды.

– Һу, болай булгач, лафа! – диде Яруллин, кулларын угалап. – Бүген туй итәрлек сый бар икән бездә...

Кызлар чыркылдашып көлеп җибәрделәр – аларның кәефләре ни сәбәптәндер бик күтәренке иде, юктан да көләргә генә торалар иде. Зөфәр исә, нигәдер кызара төшеп, бары елмайган булды.

Шул арада Мәликә әби өстәлгә олы табак белән аш китереп куйды. Яруллин шунда ук кашык тыгып аны бутап карады.

– Өйрә! Валлаһигазим, өйрә! Җитмәсә, каз өйрәсе!

– Боты миңа, боты миңа! – диде әлеге түземсез кыз, сикергәләнеп.

– Синең үз ботың да бик шәп! – диде Яруллин аңа.

Кыз авызын сузып кына: «Һи, оятсыз!» – дип куйды, бер мәлгә нәүмизләнеп калды, ләкин чынлап ачулана белмәде тагын; дөрестән дә, бала табигатьлерәк иде бу түгәрәк битле, яшькелт-соры күзле биюче кыз... Ә Яруллин, аңа һич игътибар итеп тормастан, гаҗәпләнеп шаулый бирде:

– Юк, чыннан да нинди күк капусы ачылды соң әле бүген безгә, әбекәем, ә?

– Менә дәү абыегыз сезнең өчен тырыштырды инде,—диде карчык, күзе белән генә Зөфәргә ишарәләп. – Анның сые бу, рәхим итегез!

Барысы да Зөфәргә беркадәр аптырап та һәм шуның белән бергә ихтыярсыз куанып-яратып та карадылар. Рәшидә исә аеруча бер дикъкать һәм җылы соклану белән аңа бөтенесеннән дә озаграк карап торды шикелле... Кызның янәшәсендә генә кырын утырган Зөфәр бу карашны бик ачык тойды, әмма тынычлыгын сакларга һәм мәсьәләне уенга әйләндерергә тырышып:

– Барыгыз да ашыгып чыгып киттегез ич! – дигән булды. – Шулай итеп, теләсәм-теләмәсәм дә, әби белән эшне миңа җайларга туры килде... Рәхмәтебезне аңа әйтик, югын бар итеп дигәндәй, әзерләде менә.

– Рәхмәтебезне икегезгә бүлеп бирәбез, шулай дөресрәк булыр, – диде Яруллин, урыныннан торып. – Йә, кайсыгыз соса башлый?

– Үзең инде, үзең, – диделәр кызлар.

– Бисмиллә алайса! Тотыгыз тәлинкәгезне, кем, Зөфәр иптәш, шулай бит әле?

Зөфәр башын кагып кына раслады да Рәшидәнең тәлинкәсен алып сузды. Рәшидә, «кирәкми» дигәндәй, тәлинкәсенә үрелеп куйды, ләкин бер сүз дә әйтмәде.

– Эһем, эһем! – дип тамак кыргалады Яруллин.—Бусы да бик дөрес!

Бер уңайдан ул калган кызларга, шуннан соң гына Зөфәргә һәм үзенә аш салып чыкты. Шул чакта Зөфәр күптән күңелендә булган бер нәрсә хакында уйлап алды: тәкъдим итсәм, килешерме-юкмы, Рәшидә ни дияр? Аннары икеләнебрәк кенә әйтте:

– Беләсезме нәрсә: без инде юл килгән кешеләр, өшедек тә, ачыктык та, әллә, мин әйтәм, аш алдыннан аппетит өчен генә, теге ни, шифалы суны кабып алабызмы? Ничек уйлыйсыз?

Шунда ук күбесе сүзнең нәрсә турында барганын төшенеп алсалар да, бер мәлгә аптырашып калдылар. Бу алар өчен хәзерге шартларда артык дәрәҗәдә көтелмәгән бер тәкъдим иде. Яруллинның күзләре берьюлы түгәрәкләнеп китте, ә теге кыз чын гаҗәпләнү белән ашыгып сорады:

– Нинди шифалы су ул, абый?

– Улмы?.. Ул ни... спирт, чип-чиста спирт... бераз гына бар иде.

– Һии, агай-эне! – дип кычкырып ук җибәрде Яруллин, бөтен бите-күзе белән көлеп. – Сорап торасың тагын!.. Чыгар үзен, чыгар, дустым! Нәкъ инде менә шул зәмзәм суы гына җитми иде безнең бу табынга... – Һәм ул, учына төкереп, кулларын угалый да башлады.

– Син шауламале! – диде Рәшидә аңа, тавышын әкренәйтеп. – Әбидән яхшы түгел.

– Рәшидә, май кап!

Зөфәр, торып, пальто кесәсеннән флягасын алып килде. Анда юлчыларга эчергәннән соң калган яртыдан күбрәк спирт бар иде әле. Әбидән, «дару эчәргә» дип, чокыр һәм бер чүмеч салкын су сорап алдылар.

...Эчүне дә тагын Рәшидәдән башладылар. Зөфәр чокырга яртылаш спирт салды, Яруллин су белән тутырды. Рәшидә, «куркам» дип, җилкәсен генә җыерып куйды, ләкин карышып, кыстатып тормады. Әбинең кече якка узганын көтеп алды да, тиз генә чокырны күтәреп, бет-кәнче эчеп тә җибәрде... Ул чыраен сытмады, тик авызын ача төшеп, сулыш алмыйча торды, күзләренә мөлдерәп яшь килде һәм, ниһаять, ике куллап йөзен каплады...

Калган кызларга да шулай салып бирделәр. Бик батыраеп эчкән булдылар кызлар, ләкин эчүгә, кармак йоткан балык шикелле, сынсыз калдылар. Берсе хәтта «аһ!» дип тә куйды.

Яруллинга инде Зөфәр чокырны тутыра язып салып бирде. Артист, эчүнең югары классын күрсәтергә теләп булса кирәк, спиртны су кушмыйча гына бик тыныч кыяфәт белән эчеп җибәрде. Шунда ук чүмечкә капланды, чәчи язды, бөтен бите җыерылып килде һәм, борыны пешкән мәчедәй «пырых-пырых» итеп, башын чайкап торды... Кызлар, бөгелә-сыгыла, шаркылдап көләргә тотындылар:

– Утлы күмер йоттыңмы әллә, Яруллин абый-ый?

– Ничева! – диде Яруллин, сер сынатмаска тырышып, һәм кулы белән битен бер сыпырган иде – иске кыяфәтенә кайтты да куйды.

Артистның «пешүеннән» файдаланып, Зөфәр үзенә чокыр төбенә генә салды да шуны тиз генә су белән тутырды... Кызлар көлешеп туктагач, ул чокырын күтәреп, башлыча Рәшидәгә ымлап, ләкин барсына да әйткән төсле итеп: «Сезнең саулыкка, кызлар!» – диде дә ашыкмыйча гына эчеп бетерде... Шушы кечкенә нәрсә дә аның авторитетын кызлар алдында тагын да күтәрә төште: әйе, әдәпле дә ул, игътибарлы да ул, үзен әнә ничек тота да белә, эчә дә белә... Кыскасы, сабыр, тыйнак һәм бик акыллы булырга тиеш бу зур, таза, юмарт абый!

...Фляга төбендә аз гына калганын Зөфәр Рәшидәгә салмакчы булган иде, ләкин йөзе мәк чәчәгедәй кызарып, кечкенә күзләре томаланып киткән Рәшидә ике кулын берьюлы күтәреп каршы төште:

– Юк, юк, кирәкми!

Хәер, кызларга бик җиткән иде, ач карынга эчкән ярты гына чокыр спирт аларны кинәт кенә исертте дә куйды. Шулай итеп, калганын Яруллин кыстатмыйча гына эчеп бетерде.

...Бер тын каз өйрәсен бик тәмләп, йотлыгып ашадылар. Тәлинкәләре ялт иткәч, тагын өстәп салдырдылар. Көне буе үт җыеп буш яткан һәм спирттан котырынып киткән ач карын һич

кенә туя белмәс кебек иде... Тиз арада зур табакны «каплап» куйгач, Яруллин икмәк белән шпигын «бөгә» башлады, кызлар тарсынып кына булса да Зөфәрнең итен капкаларга тотындылар. Тик Рәшидә генә һаман тыелып маташты. Зөфәр аны гел кыстый торды, ахырда үзе бер кабырганы алып, аның кулына тоттырды.

– Менә бу кызларга ярый, ичмасам! – диде Яруллин, авызы тулы килеш. – Ату бот, имеш!

– Белмисең икән шул, – диде Рәшидә, сыңар кашын гына сикертеп. – Кызларга канат бирәләр.

– Ни өчен канат?

– Тизрәк кияүгә китсен өчен.

– Ә-ә! Ну, белмим, канат түгел, пропеллер куйсалар да тиз генә китә алырсызмы икән, ай-һай! Җәтмәдәге балык төсле сөзелеп калдыгыз бит.

Кызлар дәртсез генә көлештеләр, ә Рәшидә ваемсыз гына әйтеп куйды:

– Насыйбы табылыр әле.

Шушы сөйләшүдән күпмедер соңрак Зөфәр үзенең беләгенә Рәшидәнең, әллә юри, әллә ялгыш кына, иңбашы белән орынуын сизеп алды. Кинәт кенә егетнең йөрәгенә җылы кан йөгерде, бик рәхәт булып китте аңа... Менә шулай озак кына терәлеп, дулкынландырып торуын теләде ул аның... Үзе исә, гүя якын ук килгән асыл кошны куркытмас өчен, артык хәрәкәт ясаудан тыелып, тик кенә утыра бирде.

Әби тәлинкә-кашыкларны җыеп алгач, өстәлгә чәшкеләр тезде, Шәйхулла абзый җибәргән бер йомарлам майны да китерде, аннары кайнап торган самоварны китереп куйды... Әбинең үзен дә чәйгә утырттылар. Сөйләшә-сөйләшә чәй эчәргә тотындылар. Кәефләр яхшы иде, тамак туеп, күңелләр көрәеп, хушланып киткән иде. Сүзнең төрлесеннән гәп күп булды. Зөфәр бүгенге концертны искә төшереп, артистларны, аеруча Рәшидәне мактады. Шушындый авыр бер вакытта халыкның җырны, уенны искиткеч яратуына чынлап гаҗәпләнүен әйтте. Моның сере нәрсәдә икән, диде.

– Халыкта тормышка мәхәббәт бик зур, менә аның сере нәрсәдә, – диде Яруллин, мәгълүм бер хакыйкатьне әйткән төсле өзеп кенә.

– Яхшы, шулай да булсын, ләкин бит җыр тыңлап утырыр өчен кайгы-хәсрәт, авырлыкларны онытып торырга кирәктер, минемчә.

– Җыр үзе инде барысын да оныттыра ул.

– Ә минемчә, болай ул, – диде Рәшидә, уйланып кына, – җыр, бәлки, оныттырмый да торгандыр, хәтта кайгы-хәсрәтләрне көчәйтеп тә җибәрәдер. Җырның шундыйлары да бар бит.

Мин инде аны үзем беләм. Ләкин нинди генә җырны алма, ул барысыннан элек кеше күңелендә тормышка мәхәббәт уята, кешедә яшисе килү теләген көчәйтә... Шулай булгач, кеше, җыр тыңлаганда, кайгы-хәсрәтне дә ничектер менә татлырак итеп кичерә, еласа, күз яше дә аның ул хәтле әче булмый һәм барыбер җиңеләеп кала. Бүген мин менә «Тәфтиләү»не җырладым, «Юксыну»ны җырладым, ә халык миңа: «Рәхмәт, кызым, күңелләребезне бушаттың, хәсрәтләребезне җиңеләйттең!» – дип кычкырды. Нигә, дөрес түгелмени?

– Дөрес, дөрес! – диде Зөфәр, Рәшидәнең фикеренә кушылудан бигрәк, аның ягымлы һәм гади итеп сөйләвенә сокланып.

– Туктагыз әле, менә әбидән сорап карыйк, әби нәрсә әйтер бит әле, – диде Яруллин. – Йә, әби, чын дөресен генә әйтеп бир үзләренә!

– Ни әйтим мин, – диде әби, кыюсыз гына елмаеп, аннары бераз уйланып торды да өстәп куйды: – Авыл кешесенең юанычы ни, шул җыру инде, белеп сөйлисез.

Рәшидә шатлыгыннан кулын чәбәкләп алды:

– Бик тә дөрес сүз таптың, әбекәем! Әйе, юаныч шул, юаныч!

– Хуш, мин дә килешәм моның белән, – дигән булды Яруллин, киерелә биреп. – Әмма шулай да мәсьәләгә икенче яктан да килеп карыйк. Әйт әле, әби, ничә малаең Гитлерга каршы китте?

– Өчәү... өчне озаттык.

– Ә бабайны озатмадыңмы?

– Бабайларга чират җитмәде бит әле, – диде әби, Яруллинга туры һәм мәгънәле генә карап.

Кызлар ихтыярсыздан көлешә башлаганнар иде дә, ләкин нидер сизенепме, әллә килештермичәме, шунда ук тынып калдылар.

– Сөйләшә белмисең, Яруллин! – диде Рәшидә, коры гына, аннары үзе әбидән йомшак кына сораша башлады: улларыңнан хат-хәбәр киләме, исәннәрме, өйләнгән егетләр идеме, алар өчен бик кайгырып, ут йотып тормыйсызмы, картың кайда, исән-саумы, колхозда эшлимеюкмы?

Карчык татар хатыннарына хас бер тыйнаклык һәм сабырлык белән, самовар борыны өстеннән бармагын йөртеп, һәммә сорауларга да ашыкмыйча тыныч кына җавап биреп утырды: әйе, уллары хәзергә, Аллага шөкер, исән-саулар, хатлары килеп тора, тик Идел буенда сугышкан кече улыннан гына менә бер ай инде хат-хәбәр юк, шуңа бик пошынып торалар; улының зурысы гына өйләнгән егет икән, калган икесен өйләндерергә өлгермәгәннәр... Нишлисең инде, түзәсең, уфтанмаска тырышасың – ил белән килгән афәт ич!.. Тик явыз дошманның тизрәк муены

сынсын иде дә, балалар кайтып күзгә күренсеннәр иде – көн-төн ялварып теләгән, өмет иткән нәрсә шул гына инде, шул гына!

Картымы?.. Карты болай ару әле, аяк-кулы таза, каравылда тора, төннәрен колхоз амбарларын саклый...

– Ходай җан биргәнгә юнь бирә, – диде әби, кыскача хикәясен шулай уфтанусыз, тыныч кына тәмамлап. – Көн итү бик авырга калса да, барына шөкер итеп торабыз әле, мондый чакта зарлану язык булыр, нишлисең инде!

Шушының белән табын янында гомумән сүз бетте. Әбидән ишеткән, тормышның үзе кебек чын, гади, ләкин эчке киеренкелек, тирән мәгънә белән тулы сүздән соң хәзер инде бүтән нәрсә хакында гәп сатып яки шаулап-көлеп утыру килешми дә һәм кирәксез дә иде. Аннары вакыт та бик соң иде, ашагач-эчкәч авырайтып та җибәрде, гаять талчыккан тән һәм арыган баш, утырган җирдә үк калгып китеп, йокы сорый башлады... Шуңа күрә кунаклар, артык сүз озайтып тормыйча, әбигә зур рәхмәтләр әйтеп, өстәл тирәсеннән кузгалдылар. Яруллин, бая ычкындырган дорфалыгын төзәтергә теләп булса кирәк, әбинең аркасыннан кагып, сөеп алды:

– Мәликә әби, җаным, бездән сиңа бер генә теләк: өч улың да тап-таза килеш кайтып, синең шушы кечкенә гәүдәңне киң күкрәкләренә кыссыннар, яме!

Әби көлгәндәй итте, ләкин кинәт күңеле тулганга күрәме, акрын гына: «Рәхмәт, улым!» – диюдән башка сүз әйтә алмыйча, күзләрен йомгалап, башын гына кагып куйды.

Инде кемнәр кайда, ничек яту турында кайгырта башладылар. Өйнең зур ягында бер генә агач карават тора иде. Кече якта сәке бар икән, менә барлык урын шул гына иде. Ләкин аптырап калмадылар. Иң элек Яруллин мич башы белән кызыксынды: сыеп буламы, әгәр сыеп булса, аның өчен мич башыннан да рәхәт урын юк. Ул шунда май кебек эреп, изрәп йоклаячак.

Ике биюче кыз кече яктагы сәкегә ятарга булдылар. Зөфәргә караватны тәкъдим иттеләр, ләкин ул аңардан баш тартты: «Өй бик җылы, мин эссене бер дә яратмыйм, толыбымны җәеп, идәндә генә ятам», – диде ул... Шулай итеп, карават Рәшидәгә калды. Дөрес, башта ул кызлар белән сәкегә ятмакчы иде, ләкин анда, карчыкның савыт-сабалары да торганга күрә, өч кеше өчен тыгызрак булып чыкты.

Кыскасы, кем кайда яту мәсьәләсе шулай тиз генә һәм ансат кына хәл ителде. Әби мендәр, юрган, иске киемнәр өләшкән арада, кызлар ишегалдына чыгып, озак та үтми, суыктан өтелгәндәй, куырылышып керделәр. Тиз генә үзләренә һәм егетләргә урын җәйделәр. Шуннан соң, кызларга чишенеп ятарга ирек бирер өчен, Зөфәр белән Яруллин да тышка чыгып киттеләр.

Бераздан алар әйләнеп кергәч, әби дә иске өйгә чыгып китте. Кышын карт белән карчык шушы якта гына торалар икән, бүген инде кунакларга урын бирер өчен иске өйне дә ягып

җылытканнар. «Картның таң беленгәч кайтасы бар, аны ашатып-эчертәсе бар, кеше өстеннән йөрү килешми бит, сез иркенләп, тыныч кына йоклагыз», – диде әби чыгып китәр алдыннан.

...Яруллин мич башына үрмәләде, ә Зөфәр утны сүндерде дә, чишенеп, җылы күлмәк-ыштаннан гына калып, толып җәйгән һәм зур колакчын мендәр салган идәнгә сузылды. Әби биргән иске, әмма чиста одеял өстеннән пальтосын ябынды... Бер биш минуттан сәкедәге кызлар да, мич башындагы Яруллин да сеңделәр. Хәзер аларны туптан атсаң да уятып булмас кебек иде... Өйдә тирән тынлык урнашты... Ләкин Зөфәрнең йокысы, бик арыган булуына карамастан, ни сәбәптәндер тәмам качкан иде. Ул кулларын баш астына куеп, ачык күзләре белән түшәмгә карап, чалкан ята. Туңган тәрәзәләр аша өй эченә тулган айның сыек зәңгәр шәүләсе җәелгән һәм шушы көндезге су төбен хәтерләткән тонык-тын шәүлә тышта һаваның бик яман суык булуын сиздереп тора кебек... Ара-тирә генә өй бүрәнәсенең ыңгырашып ярылуы да ишетелеп куйгалый... Ләкин Зөфәр боларны күрми дә, ишетми дә шикелле – уйлары аның бөтенләй башкада.... Рәшидә, Рәшидә – менә кем аның хыялында, менә кем турында уйланып ята ул бу зәңгәр тынлыкта! Һич көтмәгән-уйламаган җирдән килеп очраган бу кызмы-хатынмы үзе дә, аның мөнәсәбәте дә серле табышмак булды Зөфәр өчен... Ярты тәүлек эчендә кеше шулкадәр тиз күңелне биләп, хыялны котыртып өлгерер икән – Зөфәрнең мондый хәлгә беркайчан да тап булганы юк иде әле. Чынлап та, кем ул Рәшидә: фәрештәме, гыйфритме? Аның үртәгәндәй көлемсерәп, дәшкәндәй назлап караулары, йә игътибарсыз гына, йә якын-җылы итеп әйткән сүзләре, әллә ялгыш кына, әллә үзе теләп аңа терәлеп утырулары нәрсәне аңлата, нәрсәгә ишарә ясый, уен гынамы бу яки чын бер хистәнме – ничек моны аңларга, ничек саф дөресен генә белергә?.. Ә иртәгә алар аерылышачаклар, Зөфәр үз юлы белән, алар үз юллары белән китәчәкләр. Һәм Зөфәр берни белми калачак. Ләкин белмичә калырга ярыймы соң, белмичә калу соңыннан күңелдә зур үкенеч тудырмасмы?

Менә ул, Рәшидә, ике адымда гына агач караватта йоклап ята.. Әмма... йоклыймы икән ул?.. Нигәдер бик тын ята... Тукта, әгәр аның да йөрәге Зөфәрнеке шикелле үк урыныннан купкан булса, күңеле аныкы төсле үк исәрләнгән булса, ул чагында... ул чагында, ихтимал, ул да йокыдан калып, тын алырга куркып, аны көтеп ята торгандыр. Килерме-юкмы, дип, әйе, килерме-юкмы, дип... Зөфәр хәтта эсселәнеп китте. Ничек ул мондый ихтималның булуын уйлый белмәде әле? Аның бит шушындый кыска очрашу вакытларында ир белән хатынның бер-берсен яратып, бер-берсен теләп кушылуларын ишеткәне бар. Йә, шуның кебек тиле бәхетнең менә хәзер дә булуы мөмкин түгелмени? Юк, чынлап та, мөмкинме, түгелме? Ничек моны белергә? Әллә янына барып карыйсы микән?.. Тәвәккәл таш йоткан, ди, аңардан гына ни булыр? Куса куар, әмма тавыш чыгармас, юк, чыгармас. Бөтен булып үткәннәрдән соң моны

хәтта күз алдына китерүе дә читен... Аннары ул аны җәберләргә бармый ич... Тик иелеп дәшер генә ул аңа һәм аның бер күз карашыннан барысын да аңлап алыр. Кит, дигәнен дә көтмәс, кире чигенер... Әлбәттә, бу кире чигенү бик авыр булачак, хурлыклы рәвештә куылу белән бер булачак, ләкин – нишләмәк кирәк – моның кебек уңай форсат бүтән беркайчан да туры килмәячәк бит!

...Менә Рәшидә караваты өстендә кузгалып куйды. Йокламый, йоклый алмый, күрәсең, ул да!.. Мөгаен, көтә торгандыр – шулай тоела Зөфәргә, нигәдер шулай тоела... Ниһаять, ул кыюланып торып утырды. Ләкин шунда ук үз хәрәкәтеннән үзе курка-шикләнә калды: юк, буламы соң, тузга язмаганны! Тилелек ич бу! Ни өчен ул аны көтәргә тиеш. Кайдан мондый ышаныч, кемгә саный ул аны?.. Барырсың, хур булырсың, оятыңнан керер урын тапмассың... Аннары, килешәме соң Зөфәр кебек үзен тыйнак, акыллы итеп таныткан кешегә мондый әрсезлек, түбәнлек?

Әмма шулай да ул кире ятмады, башын иеп утыра бирде. Үз намусы алдында акланырга тырышып, тирән уйга калып утырды... Рәшидә аның өчен хәзер очраклы бер хатын гына түгел иде, Рәшидә аның йөрәген җилсетте, нәфесен котыртты, көчле кызыксыну уятты, һәм Рәшидә үзе моңа сәбәпче булды. Бәс, шулай икән, Зөфәрнең чын дөресен белеп калырга хакы юкмыни? Ул бит шуның өчен генә барырга тели дә!.. Әгәр кумаса, әгәр иреннәреннән бер үптереп кенә яки берәр вәгъдәле җылы сүз пышылдап кына кире җибәрсә дә, ул барысын да аңлар иде, шуннан үзе өчен тиешле нәтиҗәне ясый белер иде.

Менә Рәшидә тагын кузгалып куйды... Юк, артык икеләнеп тору мөмкин түгел иде – Зөфәр бик сак кына торып басты. Өй эчендә тулган су төбедәй яшькелт-зәңгәр яктылыкта өрәк шикелле күпмедер вакыт тик кенә басып торды... Тынлык, бар да тирән йокыга киткәннәр. Бернинди хәвеф-хәтәр юк кебек... Шулай да Зөфәрнең тез буыннары хәлсезләнде, чигә тамыры нишләптер суга башлады... Болай торып булмый бит инде, ахырда ул җылы оекбашлары белән шуышып кына караватка таба атлады. Бер, ике, өч адым... Менә ул караватянында. Рәшидә ак маңгаен гына ачык калдырып, йөзен юрган белән каплаган килеш кырын яткан. Күзләре йомык, сулышы тигез – йоклый, ахрысы... Зөфәр аның йөзенә якын ук иелеп, чак-чак кына ишетелерлек итеп, бары бер сулыш белән генә пышылдап дәште:

– Рәшидә!

Һәм гаҗәп хәл – Рәшидә шунда ук, юрганын күтәрә төшеп, күзләрен ачты. Бер мизгелдә сискәнү, каушау һәм... сөенү чагылып үткәндәй булды бу кечкенә дымлы күзләрдә... Бер сүз әйтмәде ул, тик урын биргәндәй, такта стенага таба елыша төште... «Көткән!» дигән уй яшендәй

яктырып узды Зөфәр күңеленнән һәм, сак булырга кирәклеген дә онытып, тиз генә юрган астына керде.

...Керү белән кызны үзенә тартып, кочаклап алды. Рәшидә ничектер берьюлы аның киң күкрәгенә сыланып, кечерәеп, сеңеп калды. Йөзен күтәрде һәм аларның иреннәре, күптән бер-берсен көткәндәй, комсызланып кушылдылар... Зөфәрнең бу минутта зиһене гаҗәп айнык иде; кызга ул исенә килергә вакыт бирмәде...

...Аннары алар хәлсезләнеп озак кына тик яттылар. Зөфәрнең култык астына башын яшергән Рәшидә тәмам тынган-оеган иде... Аның хәлен бик беләсе килә егетнең, әмма сөйләшү мөмкин түгел... Ахырда ул сакланып кына Рәшидәнең чәчләреннән, битеннән сыйпый башлады... һәм аптырый калды: кызның күз төпләре, борын буйлары яшькә чыланган иде. Нидән бу, үкенәме, рәнҗиме әллә югыйсә?.. Зөфәр, күтәрелә төшеп, аның күзләренә карады. Әмма уелып калган, талчыккан бу күзләрдә ул тирән бер гаҗәпсенү аша чагылган бәхетле-оялчан сөю генә күрде... Һәм Рәшидә күзләрен яшерергә теләгәндәй тагын аңа сарылды, ә Зөфәр аның ияггеннән тотып, аз гына тоз татыган иреннәреннән үпте... Кыз акрын гына егетнең күкрәгеннән этәрде. Бу китәргә ишарә иде... Зөфәр, сак кына караваттан төшеп, үз урынына китте.

Вакыт бик соң иде инде, тәрәзәләрдә таң шәүләсе беленә башлады. Өй эче дә ничектер агарына төшкән кебек булды. Каяндыр, абзарлар эченнән, суыкта күшегеп беткән әтәчнең карлыгып кычкырганы ишетелде.

Зөфәр беркадәр вакыт булып үткән хәлгә хәйран калып ятты-ятты да акрын гына оеп, тирән йокыга киткәнен сизми дә калды.

**IV**

Ул иртәне арыган-йончыган артистлар, гадәтләре буенча, бик озак йокладылар. Кышкы көн кыстатып, иренеп кенә яктырды, кереп, борчып йөрүче булмады; алар өчен бу саваплы йокы иде.

Тик идәндә яткан Зөфәр генә иртә уянды. Аны мыштым гына суык кытыклый башлаган иде, хәер, электән иртә торып өйрәнгәнгә күрә, болай да аның уяныр вакыты җиткән иде инде.

Бик табигый буларак, ул күзләрен ачу белән Рәшидәне исенә төшерде. Хәтта аңарда шундый бер тойгы иде ки, гүя менә йоклаганда да ул аны онытып тормаган, ничектер үз янында аны гел хис итеп яткан кебек иде... Булган эшкә яңадан аның исе китте, яңадан бөтенесен күз алдыннан кичерде. Торырга кирәклеген дә онытып, селкенмичә уйланып ятты. Ләкин инде татлы хиссияткә бирелеп ятудан бигрәк, ул айнык акыл белән булып үткән хәлне ничек тә аңларга тырыша иде. Барысыннан элек күңеленә һаман бер сорау кат-кат килә торды: ничек

кенә булып чыкты соң бу? Ни өчен Рәшидә аны кабул итте? Чын яратуданмы, әллә... болай гынамы?.. Ире бармы аның, юкмы? Булса, кайда ул, кем ул?

Әлбәттә, бу сорауларның берсенә дә хәзергә җавап юк... Хәер, эш булып узганнан соң аларга җавап эзләп торуның кирәге дә юк шикелле... Ләкин Зөфәр уйламыйча, эзләмичә булдыра алмый, мөмкин түгел, чөнки Рәшидә аның өчен бер кич белән генә бетмәде әле, бу башы гына булды әле, искиткеч матур, ләззәтле, дәртле дәвамы булырга тиеш әле!.. Сизеп тора ул моның шулай буласын, югалтырга теләмәячәк ул аны, юк, теләмәячәк! Артистка аның өчен эссе якның хөрмәсе кебек гаять ят җимеш, сезонный җимеш, шуңа күрә дә ул аеруча кадерле, тансык булырга тиеш.

Ничек җырлый иде әле кичләрен кәләпүш сырганда әнисе Таибә абыстай?

Тәрәзә төпкәем рәва җимеш,

Рәва җимеш хәләл, имеш.

Рәва җимеш хәләл, имеш,

Хәләл җефтең булам, ди, имеш.

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Хәләл, имеш, димәк, өзеп-өзеп, тәмләп кенә капкаларга ярый дигән сүз!.. Ә менә инде «хәләл җефет» мәсьәләсенә килгәндә, бу бик читен, четерекле мәсьәлә, бик нык уйлануны сорый торган, хәер, уйлар өчен әле һич өлгермәгән, пешмәгән мәсьәлә... Рәшидәне бөтен җаны-тәне белән яратып киткән тәкъдирдә дә ансат кына чишеп булмаячак аны, чөнки ул мәсьәлә аның башка максат-хыялларына, уй-теләкләренә барып тоташа. Юк, хәзергә бу хакта баш ватуның һич мәгънәсе юк, хәзергә бары кабынган утны сүндермәү, саклау, көчәйтү турында гына уйларга ярый.

Шулай күпмедер вакыт уйланып, шуның белән бергә яңадан Рәшидә янына барасы килеп ятканнан соң, Зөфәр, ниһаять, торды, сак кына киенде һәм чыгып китәр алдыннан аяк очына гына басып, артистканың караваты янына барды. Рәшидә кулларын кушырып, шулар өстенә битен салып, бөтәрләнә төшеп тыныч кына йоклый иде... Каты йоклый иде,ахрысы, юрганы шуып, аркасы бераз ачылганын да тоймый иде... Зөфәр бик сак кына аның аркасын япты, иелеп кенә чәченнән үпте. Рәшидә берни сизмәде, селкенмәде.

Берәүне дә уятмыйча гына чыгып киткәч, Зөфәр туры гына колхоз идарәсенә барды, Шәйхулла абзый белән сөйләшеп утырды. Аның бу колхоздан наряд буенча күпмедер солы чыгартасы бар иде, башта менә шул солыны станциягә кайчан озату турында сөйләшеп, эшне өзеп куйды. Аннары инде, җаен туры китереп, кичәге концерт турында да сүз кузгатты. Артистларның җырларын, биюләрен мактап утырды, шуның белән бергә, Шәйхулла абзыйга

азрак басым ясау нияте белән булса кирәк, аларның авыр хәлләрен әйтергә дә онытмады. Шуннан соң тагын бераз анысын-монысын сөйләшкәләп алгач, күрше авылга китәр өчен бер-ике сәгатьтән ат җибәрүләрен сорап, фатирына кайтып китте.

...Ул кайтканда артистлар торганнар, юынып-киенеп иртәнге чәйгә утырырга әзерләнеп торалар иде. Зөфәр килеп керү белән сабырсызланып бары бер нәрсәне уйлады-көтте: Рәшидә аңа ничек итеп, нинди күз белән карар?.. Нишләп китәр ул күзләре очрашкач?..

Нәкъ ул килеп кергән чакта гына Рәшидә, урам як тәрәзә төбенә кечкенә көзге куеп, чәчләрен төзәтеп утыра иде... Керүченең кем икәнен шунда ук белсә дә, ул борылып карамады, эшеннән ихтыярсыз тукталып та калмады, гомумән, ни хәрәкәте, ни торышы белән берни дә сиздермәде. Тыныч кына чәчен рәтли бирде һәм эше беткәч кенә торып, ишеккә таба борылды... Аларның күзләре очрашты... Бер генә мизгел Рәшидә, «Сезмени бу?» дигәндәй, үтә җитди итеп бер карап алды, әмма шул секундта ук гадәтенчә елмаеп җибәрде.

– Менә яхшы булды бит әле... чәйгә кайтып җиттегез, – диде ул, бүтән һичбер кайгысы булмаган кешедәй, бик гади генә итеп.

Нәкъ кичә вокзалда очраган, юлда килгән, бергә ашап-эчеп утырган Рәшидә иде ул бүген дә! Һаман шул ук күзләрен кыса төшеп, бик туры итеп карау, көтмәгәндә генә яктырып китеп елмаю һәм менә шулай бик гади-үз итеп кенә дәшү – бары шул гына! Әйтерсең алар арарсында берни дә булмаган, әйтерсең аларның хәзер берсен берсенә бәйләгән, дөньяның иң якын кешеләренә әйләндергән, тиз генә онытырга да, юкка чыгарырга да мөмкин булмаган тирән серләре юк!.. Зөфәр аның бу кадәр үзен табигый тота алуын күреп, аптырап калу гына түгел, хәтта күңеленнән бераз шикләнеп-борчылып та куйды. Дөрес, ул хатын-кызны бик аз белә иде. Хәлбуки эчке хисләрен, бигрәк тә мәхәббәтләрен, хатын-кыздан да оста яшерә белүче юк бит ул дөньяда! Зөфәр, кемнәндер ишеткән Сөләйман патша сүзләрен исенә төшерде: «Һавада кош эзе, ташта елан эзе, хатыннарда ирләр эзе калмый», – имеш. Хатын-кызның йөрәген күрә белмәгән кеше өчен бу бик хикмәтле сүзләр иде.

...Өстәл тирәсенә утырыштылар. Әби олы табак белән булары чыгып торган чикмәнле бәрәңге китереп куйды. Рәшидә, яшь хозяйка сыман чәчәкле яулыгын урталай бөкләп, кашлары өстенә төшеребрәк бәйләгән килеш, самовар янына үзе чәй ясарга утырды. Көн яктысында алар барысы да аз гына бүтәнчәрәк, ачыграк күренәләр иде. Мәсәлән, әлеге тынгысыз биюче кызның кичтән шактый кара булып күренгән чәче хәзер бакыр сыман коңгырт-җирән булып чыкты. Рәшидәнең йөзе ул хәтле үк ак түгел, ә саргылтрак икән, күзләре дә алай бик кечкенә түгел, ә шактый зур да, яктырак та икән, тик әле кыса төшеп караганга күрә генә шулай сөйкемле кечерәеп кала икән. Әмма ул бүген аеруча чиста, нәфис иде. Тулы күкрәкле юка гәүдәсе дә, тар

гына йомры иңбашлары да, озынчарак ак муены да, тулы-алсу ireннәре дә ничектер менә аның тәмле-тансык хатын булуын сиздереп, назлап сөясе килүне котыртып, гел үзенә тартып тора иде. Зөфәр, бу вәсвәсәле тойгыны берничек тә җиңә алмыйча, гел янып, дулкынланып утырды.

Рәхәтләнеп йокы туйдырганнан соң, барысының да кәефләре бик әйбәт иде. Ашыкмыйча тәмләп кенә ашадылар-эчтеләр, авызлары бушап тормаса да, һаман җыен кызык сөйләшеп утырдылар. Ничектер сүз туры килеп, биюче кыз Зөфәрдән:

– Ә сез, абый, төнлә идәндә өшемәдегезме? – дип сорап куйды.

Әлбәттә, бу аның нидер сизенеп соравы түгел иде. Шулай да Зөфәр, аңа күтәрелеп карарга кыймыйча, чәен болгаткан булып кына:

– Юк, өшемәдем, – диде. – Аста толып, өстә пальто, рәхәтләнеп йокладым.

Яруллин шунда ук үзенең борычлы сүзен кыстырып өлгерде:

– Өшесә, барып сезнең уртага ятыр иде. Мин үзем андый чакта ике кыз арасына кереп җылынырга яратам.

– Абый  син түгел бит ул, – диде кызларның берсе, ә икенчесе өстәп куйды:

– Безнең арага Рәшидә апа да сыймады әле.

Рәшидә иптәшләренең бу гөнаһсыз сөйләнүләренә бер генә сүз белән дә катнашмады. Ул тырышып чәй ясау белән мәшгуль булды. Шулай да Зөфәр бераздан аңа күтәрелеп карагач, ханымның бер як авыз читендә сизелер-сизелмәс кенә серле елмаю чагылуын күреп алды. Нәрсә аңлата иде бу елмаю – моны белү мөмкин түгел иде... Чын борчылу белән Зөфәр эченнән генә: «Шулай ук берни дә белмичә китеп барырга туры килер микәнни, хәерсез?» – дип уйлап куярга мәҗбүр булды.

Чәйдән соң Яруллин, ашык-пошык киенеп, колхоз идарәсенә йөгерде. Шәйхулла абзыйның кичәге вәгъдәсен исенә төшереп, ул чыгып киткәндә генә:

– Кызлар, теләктә торыгыз! – диде, кабаланып. – Карттан бүген безгә гошер тияргә тиеш, тик берәр яры чыгып кына сызмасын!

– Бар, бар, председатель сине көтеп утырмас! – диделәр кызлар, аны куалап.

Бүген инде алар үзләре чыгып йөрмәскә, җылы өйдә генә ял итеп, вак-төяк эшләрен карап утырырга булдылар. Чәй урынын җыештыргач, кайсы кулына китап алды, кайсы энә-җеп алып, ертык-сүтеген типчергә тотынды.

Зөфәрнең Рәшидә белән бер-ике генә авыз сүз булса да сөйләшеп аласы килә иде. Ләкин ничек кенә эшләргә моны? Өйдә теге ике кыздан уңайсыз, тышка да чакырып чыгару кыен, мөмкин түгел... Ахырда ул, карават башында чемоданын ачып, әйберләрен актарып торган Рәшидәгә якын ук килде дә тавышын әкренәйтә төшеп әйтте:

– Мин тиздән китәм... Бәлки, Казанда очрашырбыз, сезгә үземнең телефонны калдырыйммы?

– Әйе, әйе, калдырыгыз! – диде Рәшидә, ашыгып.

Зөфәр блокнот битенә үзенең эш телефонын һәм фамилиясен язып бирде.

– Сез шәһәргә кайчан кайтасыз?

– Бер-ике атнадан.

– Мин сезнең шалтыратуыгызны көтәрмен.

– Әйе, әлбәттә...

Болай ашыгып, кыска гына итеп җавап бирүеннән Зөфәр Рәшидәнең эчке дулкынлануын сизмичә калмады. Шуның аркасында ямьсез шикләре бердән таралып киткәндәй булды, алай гына да түгел, бу әйбәт, рәхәт дулкынлану аның үзенә дә күчте кебек...

Озак та үтми, әби кереп, колхозның аты килеп җитүен хәбәр итте. Зөфәр киенә башлады. Киенеп беткәч, әбигә рәхмәт әйтеп, акча бирде. Аннары кызлар белән кул биреп саубуллашты, шуннан соң Рәшидәгә таба борылды. Ләкин ул да булмый, Рәшидә үзе аның каршысына ук килеп, һич каушамыйча һәм шик кузгатмыйча, бары гади кайгыртучанлык күрсәткән булып кына Зөфәрнең пальто якасын төзәтергә тотынды:

– Менә шулай кирәк, шулай итсәң, җылырак була! —диде ул, шушы гади генә сүзләренә гаҗәп җылы бер интонация салып һәм шул ук вакытта якты күзләре белән Зөфәрнең күзләренә: «Син! Син бит бу!» – дип әйткән төсле итеп, тутырып бер карады. Менә шулай һичкемдә шик кузгатмыйча, бары Зөфәрнең үзенә генә йөрәгендәге хисен аңлата белде ул!.. Зөфәр, рәхмәт әйтергә дә көче җитмичә, куанычлы елмаеп, башын гына кагып торды. Тик саубуллашкан чакта гына: «Син дә аңлап кал, җаным!» – дигән төсле, Рәшидәнең кулын ике тапкыр каты гына итеп кысып куйды. Аннары чемоданы белән толыбын алып, ишеккә таба атлады. Кызлар да, иңнәренә пальтоларын салып, аны озата чыктылар.

Кояшлы, коры салкын көн иде... Көннең никадәр суык булуын шул ук кояш үзе әйтеп тора: аның ике ягында ике колак... Мондый чакта авыл җирендә: «Бүген кояшка да колак чыккан, ай-һай суык икән!» – диләр тәҗрибәле агайлар.

Зөфәр борылып Рәшидәгә;

– Сез, бар, керегез инде! – диде һәм җиңел, кызу адымнар белән капка төбендә көтеп торган атка таба китте. Иске кошевка чана янында муенына ишеп шәл чорнаган, тире тун өстеннән соры чикмән кигән уналты-унҗиде яшьлек үсмер егет аны көтеп тора иде. Зөфәр толыбын киеп чанага утырды, үсмер егетне дә үз янына утыртты, һәм бик арык, зур туры ат

ялкау гына кузгалып, бары бер-ике тапкыр сыртына чыбыркы төшкәч кенә, дөя шикелле, алпан-тилпән юыртып китте... Болдырдагы кызлар юлчыларга кул болгап калдылар.

**V**

Зөфәрнең Турай авылында Рәшидә Сафина белән очрашып танышуы әнә шулай төгәлләнде... Әмма ләкин әүвәл-ахыры түгел иде әле бу, соңыннан Казанда аның шактый кызыклы дәвамы да булды.

Әйе, Рәшидә!.. Зәһәр суыктан качкан яз кошыдай килде дә керде бит Зөфәрнең тормышына... Керде дә бөтенесенә хуҗа да булып алды. Йөрәк тә әсир, акыл да богаулы, планнар да чуалды. Хәзер менә үзеңне шул татлы әсирлектән коткарып кара инде! Юк, мондый җәтмәгә беркайчан да эләккәне юк иде әле аның...

Дөрес, Зөфәр Рәшидәгә чаклы да хатын-кызсыз тормады. Бик мактанырлыктан булмаса да, үзенә күрә аның да «романнары» булгалады. (Утыздан узганчы ялгыз ир булып йөргән кеше өчен бу әллә ни гаҗәп эш түгел, билгеле...) Ләкин алар барысы да хәтәр-хәвефсез, эзсез-ярасыз дигәндәй үттеләр дә киттеләр. Чөнки андый «романнарда» ул үзе баш герой, үзе чын хуҗа иде, шуңа күрә бары тик аның хөкеме йөрде.

Мәсәлән, кайчандыр ул универмагта эшләүче Мәрьям исемле кара, чандыр гына бер хатын белән шактый гына вакыт якын бәйләнештә булып алды. Ләкин аның эчүдән башы чыкмаган ире, ниһаять, нидер сизенә башлагач, Зөфәр Мәрьям белән ике араны тиз генә өзде дә куйды. Бернинди кызганусыз һәм үкенүсез!

Яки менә шуннан соң буфетчы Вера белән булып алган «романны» искә төшерергә мөмкин. Вера төскә-биткә чибәр генә, гәүдәгә тулы-тыгыз гына, ирсез ялгыз гына, утызга да җитмәгән хатын иде. Баш-күз тонып, аңа тәмам капланырга да була иде. Ләкин Зөфәр буфетчы хатынның артык әрсезлеген, оятсызлыгын һәм эчкәләргә яратуын белеп алгач, ике дә уйламыйча, тотты да нокта куйды. Чөнки «романның» ахыры бик күңелсез булып бетәчәген вакытында сизде ул.

Кыскасы, Зөфәр бервакытта да, хатын кирәк бит, дип башын җуймады, нәфес тезгенен кулыннан ычкындырмады, ара-тирә берәрсе белән якын бәйләнешкә кереп киткән чакларда да, исеменә яки эшенә куркыныч туа башласа, шунда ук тыела белде һәм чигенә алды...

Тик менә Рәшидә белән генә бүтәнчәрәк килеп чыкты. Хәер, моның шулай булуы гаҗәп тә түгел, чөнки Рәшидә теге Мәрьям-Вералардан чагыштырмас дәрәҗәдә өстен тора, чөнки беренче очрашу минутыннан ук ул Зөфәрдә көчле тәэсир калдырды, ничектер аның күзенә саф, гүзәл, якты булып күренде. Ихтимал, шуңадыр инде Зөфәр гел бер нәрсә турында сабырсызланып уйлады: Рәшидәнең ире бармы-юкмы, ни өчен ул аны шулай ансат кына кабул

итте, яратуданмы, әллә болай гынамы?.. Турайдан ул Рәшидәнең үз авызыннан берни ишетергә өлгермичә китеп барды. Ә күңел дигән нәрсә су өсте кебек гел үзгәреп кенә тора: бер яктыра, бер караңгылана, бер тынычлана, бер дулкынлана, кыскасы, әллә ниләр уйлап бетәргә мөмкин иде. Дөрес, кайвакытта ул болай баш ватып азапланмас өчен үзенчә ачык кына нәтиҗәгә дә килгәндәй була иде; ягъни Рәшидә – артистка бит ул, ә артистка, Зөфәр карашынча, хис кешесе, ни кылансам да, миңа килешә, дип уйлаучы, шунлыктан инде ул үзе теләгән эштән тыелып тормый, кирәк икән, җиңел генә эшли дә куя, янәсе... Ләкин... чынлап та, Рәшидә нәкъ менә шундыймы – бу әле билгесез, бу әле яңадан раслануны сорый иде.

Озын сүзнең кыскасы, Зөфәр Рәшидәнең авыллардан кайтуын түземсезлек белән көтеп йөрде, җаны-тәне белән аны сагынып яшәде. Бу сагынып көтүдә Рәшидәне бик теләү, югалтасы килмәү генә түгел, аны тизрәк аңлау, тизрәк белү өчен ашкынып тору да бар иде. Казанга кайткач, Рәшидә аңа шалтыратырмы, аның күзенә күренерме-юкмы – Зөфәр өчен бу бик тә әһәмиятле иде. Әгәр шалтыратмаса, яңадан күзгә күренмәсә – ул чагында ни уйларга кала? Ә вакыт... вакыт үтә дә үтә, ике атнадан кайтырга тиеш иде, хәзер инде ай тулып килә. Шулай ук Рәшидә дә бер генә төнлек... Ләкин юк, ашыгып нәтиҗә ясарга һич ярамый икән!

...Нәкъ март башларында Рәшидә үзенең дөньяда барлыгын белдереп, ниһаять, аңа шалтыратты.

Зөфәр телефон трубкасын алып «тыңлыйм» диюгә, еракτан хатын-кыз тавышы ишетелде.

– Алло, миңа Зөфәр Сабитов кирәк иде.

Шунда ук ул тавыш иясенең Рәшидә булуын танып алды һәм, дөньясын онытып, ике кулы белән дә трубкага ябышты:

– Рәшидә, сезме бу? Тыңлыйм мин, тыңлыйм!

– Әйе, бу мин, Зөфәр абый! Исәнмесез!

– Исәнмесез, Рәшидә, исәнмесез! Кайчан кайттыгыз?

– Бер ун көн була инде...

– Шулай күптәнмени? Ә мин көтәм дә көтәм...

– Вакыт булмады, Зөфәр абый! Кайту белән төрле эш-мәшәкатькә тардым, хатын-кызның беләсез...

Рәшидәнең шундый сагындырган сөйкемле тавышы ерактан гүя җылы-назлы дулкын булып килә иде. Һәм шул дулкын әйтерсең Зөфәрнең йөрәгенә килеп кагыла иде.

– Мин инде онытгыгыз, ахрысы, дип курка да башлаган идем, – диде ул, аз гына үпкәле пошыну белән.

– Юк, нишләп онытыйм!.. Онытсам, шалтыратмас идем...

– Рәхмәт, Рәшидә, рәхмәт! – Зөфәр тавышын әкренәйтә төште. – Ләкин безгә тизрәк очрашырга кирәк бит, Рәшидә.

– Шулаймы?.. Белмим шул, ничек булыр икән!

– Нигә алай дисез, аңламыйм! Безгә бит очрашырга кирәк, шулай түгелме?

– Әйе, әлбәттә, – диде Рәшидә, аз гына көттереп.—Тик менә белмим: кайда, ничек...

Зөфәр «сез»дән «син»гә күчте:

– Анысы өчен борчылма! Тик әйт кенә, кайчан синең вакытың булыр?

– Минекеме?.. Ничек дим, мин хәзергә буш әле...

– Алайса болай сөйләштек, – диде Зөфәр, киеренке, әмма эшлекле тавыш белән. – Иртәгә син миңа тагын шушы вакытларда шалтырат. Мин шул чакта сиңа кайда очрашуыбызны тәгаен әйтермен. Ярыймы?

– Ярый, мөмкин...

Зөфәр тирән итеп бер сулап куйды һәм, аз гына тынып торганнан соң, моңарчы тыеп килгән дулкынлануын телефон аша җиткерергә теләгәндәй, учы белән трубканы ышыклап, акрын-йомшак кына итеп әйтте:

– Рәшидәм, тыңлыйсыңмы... мин сине бик-бик сагындым!

– Шулаймыни? – Трубкада кычкырып көлгән куанычлы тавыш яңгырады. – Һай, мескенем!

– Көлмә, Рәшидә! Саф дөресен әйтәм...

– Ышанам, ышанам!.. Йә, ярый алайса, хәзергә...

– Хуш, Рәшидә, хуш! Ләкин иртәгә шалтыратырга онытa күрмә!

– Юк, онытмам!.. Хуш!

Сөйләшү өзелде, әмма сөйләшү кабызган шатлык һәм өмет Зөфәрнең йөрәгендә отыры дөрләп кенә калды. Шул ук көнне ул, эшеннән бик соңга калып кына ычкынуына карамастан, туп-туры Хәмит дустына китте. Хәмит ялгызак бер егет ул, ләкин бик яшьтән түгел инде, шул Зөфәр чамасы – утыз ике-утыз бишләр тирәсендә булыр. Характерлары белән бер-берсенә капма-каршы булсалар да (ә ихтимал, шуңа күрәдер дә), алар, чынлап та, бик дуслар. Эш-хезмәтләре дә бер диярлек: Хәмит тә гел сәүдә тирәсендә чуалып йөргән егет. Ләкин ул, Зөфәр кебек, бер урында озак оялап утырырга яратмый, шулай ук зуррак эшкә, дәрәҗәлерәк урынга да һич исе китми. Аңа, кечкенә булса да, үз башына ялгызы гына эшли алырлык урын булсын. Шуңа күрә дә ул әлеге базар арасындагы тактадан гына корылган, прилавка астыннан гына кереп йөри торган вакларекларны бик ярата. Монда ул үзе хуҗа, теләсә ни вакытта ача, теләсә ни вакытта яба, теләсә кайда йөри... Яратып саткан товары – галантерея. Бу үзе күп, үзе вак, үзе

арзан товарны сатуның нечкә серләрен ул бик яхшы белә һәм Ходай бирмеш көн мул гына «чумараны» кесәсенә сала бара.

Ләкин бу кешенең иң гаҗәп ягы оста сәүдәгәр булуында түгел иде. Сәүдә өлкәсендә ул бик вак балык, мәсәлән, Зөфәр кебек җаен белән чагыштырганда чабак кына... Әмма шуңа карамастан аны шәһәрнең бөтен сәүдә галәме белә, сәүдә галәмне генә түгел, бик күп оешмаларның, учреждениеләрнең җитәкчеләре, министерство кешеләре аны беләләр. Ул ярты шәһәр белән таныш, бу танышлар арасында нинди генә кәсеп иясе юк, хәтта галимнәрдән һәм язучылардан да кемнәрнедер белә, шулар белән дә үз кешедәй кул бирешеп, исәнләшеп йөри, имеш.

Хикмәт нәрсәдә соң?

Аның исеменә тагылып йөри торган, кушамат дисәң —кушамат түгел, ләкин гаҗәп сәер бер өстәмәсе бар: «Әйттем-бетте». Ягъни Әйттем-бетте Хәмит! Кайсы Хәмит? Әйттем-бетте Хәмит!.. Һәм бөтен танышлары аны шулай дип кенә беләләр, шулай дип кенә йөртәләр.

Кайдан килеп тагылган бу колак ишетмәгән әкәмәт өстәмә безнең галантерейчы егеткә? Мәсьәлә шунда ки, безнең егетебезнең гаҗәеп бер сыйфаты бар: ул кешеләргә һәртөрле хезмәт күрсәтергә ярата. Сәүдәсенә караганда да ныграк ярата, бик теләп, рәхәтләнеп кеше йомышы артыннан чаба, шуңардан чынлап торып ямь, кызык таба. Тик моны ялагайлыктан килгән куштанлык, ягъни кем ни кушса, шуны урталай сынып үтәргә тору дип аңламаска кирәк. Юк, һич алай түгел, үз кадерен, үз дәрәҗәсен бик белә торган горур-һавалы егет ул Хәмит... Гадәттә аның алдына баш иеп киләләр. Гадәттә, килгән кеше үзе түбәнчелек белән генә: «Хәмит туган, зинһар, дип әйтәм, миңа шуны гына эшли алмассыңмы икән?» – дип сорый аңардан.

Хәмит карый әле: сораучы кем, кайдан килгән, кем җибәргән аны, киләчәктә аның үзеннән нәрсә көтәргә мөмкин? (Аның кагыйдәсе: хезмәткә каршы хезмәт, бүтән берни дә түгел.) Бары менә шуларны үзе өчен ачыклагач кына, бер дә ашыкмыйча, бәйсез, горур кыяфәт белән соңгы сүзен әйтеп куя:

– Яхшы, эшләрбез!

Күп вакытта үтенеч белән килгән кеше ышанып бетмәгәндәй кабатлап сорый:

– Эшләрсезме?

Менә шул чагында инде Хәмит үзенең телләргә кереп киткән мәшһүр сүзен, мөһер баскандай, өзеп кенә әйтеп ташлый:

– Әйттем – бетте!

И, вәссәлам! Кабатлап сорама, эшне генә бозарсың. Димәк, ул әйттеме – бетте, эш булачак! Моңардан да зур гарантиянең булуы мөмкин түгел.

Әнә шундый кеше ул Әйттем-бетте Хәмит! Ярым сәүдәгәр, ярым арадаш! Талантлы, үткен-зирәк, әмма чиктән тыш индивидуалист, үзенчә «хөрлек» сөюче һәм үз рәхәте өчен генә яшәүче оясыз-нисез бер ялгызак кеше... Зөфәр менә шул кешегә ашыкты.

Кольцодан ерак түгел Островский урамындагы таш йортның өченче катындагы бүлмәгә Зөфәрнең күп тапкырлар килгәне бар иде. Юлын бик яхшы белә, кирәксә, йомык күз белән дә караңгы баскычтан күтәрелеп, киндер тышлы ишекне таба ала иде... Күршеләрдән аерым, туры гына коридорга чыга торган бу бүлмәгә ул Мәрьямне дә китереп йөртте. Верочканы да еш кына ияртеп китерде, кыскасы, бу аның «гыйшык» эшләре өчен генә хезмәт итүче яшерен оясы иде. Төп хуҗа – Әйттем-бетте Хәмит исә, Зөфәргә бик бирелгән киң күңелле дус буларак, бервакытта да аңардан бүлмәсен дә, ятар урынын да кызганып тормады. Гадәттә ул: «Әйдә, алып килсәң килерсең инде, чукынган күпец!» – дип, ачусыз гына мыгырдана да бүлмәсен теләсә күпме вакытка калдырып китә торган иде. Үзе ул преферанс сугарга ярата, кайдадыр хәрбиләрдән һәм карт артистлардан якалашып уйный торган кешеләре бар, шулар янына китсә, тәүлекләп тә югала торган иде.

Зөфәр килеп кергәндә, Хәмит пружиннары, арык мал янбашыдай, аннан да моннан төртеп чыккан «турецкий» диванда тетелеп беткән «Шерлок Холмс»ны укып ята иде... Баш кагышып кына исәнләштеләр. Зөфәр түргә узып утырды, ә Хәмит диваннан, рәнҗегән тавышлар чыгартып, аякларын салындырды. Киерелеп, авызы каерылганчы бер иснәде:

– Ни... нишләп болай соң гына?

– Йомышым бар сиңа, – диде Зөфәр, пальто төймәләрен ычкындырып.

– Бик ашыгычмыни?

– Әйе, бүген сөйләшеп куярга кирәк, иртәгә мин сине әллә күрәм, әллә юк.

– Хуш, тыңлап карыйк, нинди ул хәтле килеп терәлгән йомыш икән?

Зөфәр аз гына дәшми торды. Аның бу юлы мәсьәләне уен-көлкесез, җитди итеп, йөрәк эше итеп, яхшылап аңлатасы килә иде. Чөнки сүз Рәшидә белән очрашу турында барачак, димәк, бу очракта Хәмит тә гадәтенчә бары алама итеп кенә уйламасын. Шуны истә тотып, Зөфәр сүзен дусларча җитди-сабыр гына башлады:

– Беләсеңме, Хәмит, мин сиңа бер серемне ачарга тиешмен. Моңарчы ул хакта әйтергә ничектер җае чыкмады. Ә хәзер менә... әйтәм, әйтмичә булдыра алмыйм. Тик син, зинһар, дөрес аңларга тырыш. Мин моннан ай ярым элек, командировкада чакта, бер бик әйбәт, бик... порядочный ханым белән таныштым...

– Бүлмә кирәкме? – диде Хәмит, ваемсыз гына аның сүзен бүлеп.

– Нинди кеше син! – диде Зөфәр, ачынып.—Сөйләгәнне дә көтмисең, сыразы әллә нәрсәгә борасың!

– Борып торасы калмаган монда, мәсьәлә ачык! Сиңа бит хәзер шул... порядочный хатынны алып килер өчен аулак урын кирәк, нигә, дөрес түгелмени?

– Ну, шулай да булсын ди, ләкин син аңла, утын булмасаң, сүз бик җитди эш турында бара. Миңа ул хатын белән чынлап аңлашырга кирәк, чөнки... чөнки бер ай буена мин аның турында гына хыялланып яшәдем. Әйтәм ич, ул бик интересный, бик яхшы хатын...

– Яхшымы-яманмы, карамы-җирәнме – минем өчен барыбер, – диде Хәмит, һич исе китмичә. – Миңа киләсе хатын түгел.

Зөфәр, ниһаять, өметен өзеп кулын гына селтәде:

– Ярар, сиңа сүз әрәм итеп торудан мәгънә юк... Эт таласын үзеңне! Тик иртәгә сәгать җидегә бүлмәң буш булсын, вот шул!

– Рәхим ит! Әнә запасной ачкычны алып китсәң дә була...

Зөфәр өстәлдә яткан ачкычны кесәсенә салды да урыныннан торды.

– Ник әле болай, начальниклар төсле, приказ биреп кенә качасың? – диде Хәмит, урыныннан кузгалмыйча гына.

– Ә сиңа шул приказ гына үтә дә инде, адәмчә сөйләшүне аңламыйсың син.

– Ялгышасың, җан Зөфәр! Миңа иң элек мәсьәләнең деловой ягын хәл итеп куярга кирәк иде, аннары инде, эш юктан, фәлсәфәсен дә тыңларга була. Кем ул интересный ханым, ничек таныштың, нәрсәсе белән ул сине болай тиз генә сихерләп өлгерде? Сөйләп җибәр, булмаса.

Зөфәр акрын гына башын чайкады:

– Юк, хәзер сөйли алмыйм инде, гайрәтемне чигердең... Тик шуны гына әйтәм сиңа: ул хатын турында мин начар уйлый алмыйм... гашыйк булдым шикелле мин аңа... Син шуңа ышанасыңмы?

– Ник ышанмаска?.. Син дә кеше ич, өстәвенә өйләнмәгән егет... Ләкин, минем белүемчә, син гашыйк булыр өчен хатын түгел, ә кул тимәгән кыз эзли идең шикелле...

– Эзләп кенә табылмый икән шул, көтмәгәндә юлыңа килеп чыга икән ул!

– Шулаймыни?.. Кара син аны!.. Хәерле каза булсын!.. Ансыз – дөнья сансыз дигәндәй, миннән фатиха алайса!

– Фатихаңны башыңа капла! Сиңа сөйләгән мин дурак! Ярар, киттем әле мин...

– Ну, бар, бар... Ләкин исеңдә тот – мин бүлмәмдәниләр булганын белеп торырга тиешмен... Кем белә, сез может монда ялган акча сугып ятарсыз?!

Зөфәр, кызарынып-бүртенеп:

– Иблис син! – диде дә, ачу белән кулын селтәп, ишеккә юнәлде, ә Әйттем-бетте Хәмит «турецкий» диванын шыңгырдата-шыңгырдата кычкырып көлеп калды.

Урамга чыккач та Зөфәр тиз генә тынычлана алмыйча барды. Менә шушы кешенең бүлмәсенә ул Рәшидәне алып килергә тиеш инде. Нишләмәк кирәк, бүтән чара юк. Әлбәттә, Хәмитнең үзен Рәшидә күзенә ничек тә күрсәтмәскә кирәк булыр. Ул сизенә, Рәшидә аның дус-ишләрен яратмаячак. Хәмит кебек кешеләр белән чуалуын белсә, аның үзенә дә шикләнеп, әллә ни уйлап каравы мөмкин. Гомумән, Рәшидә кебек бөтенләй икенче даирәдән килгән, нечкә табигатьле хатын белән ничек тә сак кыланырга, үзеңне тыйнаграк, акыллырак тотарга кирәк булачак.

Икенче көнне кич, алдан сөйләшү буенча бер кино алдында очрашкач, Зөфәр Рәшидәне Хәмит бүлмәсенә алып килде. Хуҗа кеше – уңган егет – бүлмәсен җылытып һәм җыештырып чыгып киткән иде... Зөфәр башта Рәшидәнең өске киемен салдырып элеп куйды, аннары үзе чишенде... Чишенеп беткәч, бүлмә уртасында басып торган Рәшидәнең каршысына килде дә, бер сүз әйтмәстән, аны иңбашыннан кочаклап үбә башлады. Рәшидә, башын читкә борып, акрын гына:

– Туктагыз! – диде һәм, Зөфәрдән аерылып, өстәл янына барып утырды.

Зөфәр урындык алып, аның каршысына урнашты. Һәм алар сүзсез генә бер-берсенә карап тора башладылар. Бу сүзгә кадәр күзләре белән бер-берсен сынау, бер-берсенең йөрәген укырга теләү иде. Әйе, асылда бит бу аларның беренче тапкыр икәүдән-икәү генә аулакта очрашулары һәм менә шулай күзгә-күз карашып танышулары иде... Була икән шул моның кебек гайре табигый хәл дә: башта кешеләр, үзләре дә аңламаган нindидер бер сукыр кодрәткә буйсынып, әллә ничек кенә якынаеп куялар, аннары инде бер-берсен аңларга, белергә тырышалар... Менә хәзер Рәшидә белән Зөфәр дә нәкъ шуның төсле бер хәл кичерәләр иде.

Теге вакытта, иске мәчет сәхнәсендә һәм Мәликә әби өендә, Рәшидә Зөфәр күзенә ничектер яшькә дә, төскә дә кызлар сыманрак булып күренгән иде. Хәзер исә бер дә шикләнмичә аны егерме биш-егерме алты яшьләрдәге ханым дип танырга мөмкин иде; кара чәчләрнең уртадан ачып таралган һәм артка өеп куелган булуы да, күз төпләренең уелыбрак торуы да, хәтта кызыл кофтасының өстендә иркен генә утыруы да аның кыяфәтен әнә шулай олысымак итеп күрсәтә иде... Әмма туры, ачык карый торган коңгырт-кара күзләре, яктырып китәргә торган чиста йөзе, тибрәнергә торган нечкә кашлары белән ул шул ук Рәшидә иде, сокландырып, дулкынландырып торучы җанга тансык Рәшидә иде.

Тик менә Зөфәр үзе бу минутта Рәшидә күзенә ниндирәк булып күренә икән соң? Егет өстендә таза-тулы гәүдәсенә бик килешле утырган зәңгәр бостоннан әйбәт костюм, ак күлмәк,

кара галстук... Аның муены-бите ап-ак шома, киң маңгае да ак мәрмәрдәй бик чиста, кыска гына калдырып китәргән коңгырт-аксыл чәчләре ефәктәй йомшак... Һәм Рәшидәнең җылы бөркегән күзләреннән сизә ул – ханымга аның бу кыяфәте бик ошый кебек, таза ирлек көче һәм басынкы-сабыр карашы ханымны да аңа тарта, дулкынландыра кебек... Юк, алар бер-берсе турында ялгышмаганнар шикелле... бер-берсенә ошыйлар, пар килгәннәр шикелле. Ләкин ни өчендер Рәшидәнең күзләре бүген уйчанрак та, моңсурак та кебек. Нидән икән бу?.. Зөфәр сакланып кына аның озынча ак кулларын үзенең зур учларына алды һәм йомшак-акрын гына:

– Рәшидә, ник берни дә сөйләмисең? – диде. – Безнең бит сөйләшер сүзебез күп булырга тиеш.

Рәшидә, җиңел генә, бер сулап куйды.

– Әйе, күп шул... Ахрысы шуңадыр, нидән башларга да белеп булмый... Сез сөйләгез!

– Миндә дә шул ук хәл! – диде Зөфәр, ханымның кулын сыйпап.

Тагын беразга тынып калдылар, аннары Рәшидә, күптән күңелендә йөргәнне беләсе килеп булса кирәк, кинәт кенә кыюланып сорап куйды:

– Зөфәр абый, әйтегез әле, сез кем?

Зөфәр ни өчендер пошынып аңа карады. Рәшидә ашыгып өстәде:

– Әллә ни уйлый күрмәгез! Кайда, кем булып эшлисез дип кенә соравым... Мин бит әле сезне бөтенләй белмим.

– Әйе, дөрес, безнең чынлап танышканыбыз юк шул әле... Мин, Рәшидә, бер заводның ОРСында эшлим. Сәүдә бүлегенең мөдире булып... Бу сезгә ошап бетмидер инде?

– Нигә алай дисез?

– Сез – искусство кешесе, ә мин әлеге берәү дә яратмаган сәүдә работнигы... Аралар бик ерак ич!

– Минемчә, аның һич әһәмияте юк. Тик кеше үзе яхшы булсын.

– Дөрес әйтәсез... Мин дә шулай уйлыйм, Рәшидә. Төрле профессиядә эшләп тә бер-береңне... аңларга мөмкин ич?

– Әйе, – дип кенә куйды Рәшидә, бүтән нәрсә турында уйга калгандай. Аны тагын нидер борчый иде шикелле... Ниһаять, ул йөзен читкә борып, акрын гына сорады: – Сез... ялгыз кешеме?

Бу юлы Зөфәр бик теләп җавап бирергә ашыкты:

– Әйе, мин ялгыз кеше, Рәшидә... Минем әнием бар, фронтта абыем бар, ләкин үзем хәзергә ялгыз әле.

Моңа каршы Рәшидә бүтән бер сүз дә әйтмәде, әмма аның йөзеннән шундук ниндидер бер соры пәрдә төшкән кебек булды. Зөфәр үз нәүбәтендә: «Ә сез ничек?» – дип сорамакчы булган иде дә, ханымның пәрдәдән ачылуын күреп һәм аннары үземә зарар итмим дигән бик яшерен бер уйдан чыгып, сорамыйча, тыелып калды. Аның исәбенчә, бу сорауны бирергә иртәрәк иде әле.

...Алар тагын шактый гына сүзсез тынып тордылар. Тагын Рәшидәнең ике каш арасы җыерылып, нечкә кашлары тынгысыз тибрәнеп куйды. Күрәсең, тагын ниндидер бер беләсе килгән нәрсә җанын борчып тора башлады. Ахырда ул, тәвәккәл иткәндәй, Зөфәрнең күзләренә туры гына карап, ләкин борчылуын сиздергән тавыш белән тотлыгыбрак сорады:

– Ә сез... сез минем турыда ни уйлыйсыз?

Зөфәр аның бу соравын дөрес аңлады: асылда бу Рәшидәнең үзе турында хөкем ишетергә теләве иде.

– Минме? Мин, Рәшидә, синең хакта бик яхшы уйлыйм, – диде Зөфәр, җитди, ләкин мөмкин кадәр йомшак итеп.

– Шундый... хәл булганнан соң дамы? – диде Рәшидә, күзләрен йомып, әкрен генә.

– Әйе, әлбәттә... Ни генә булмасын, мин синең хакта начар уйлый алмыйм, Рәшидә!

– Шулаймы? – Һәм Рәшидә сөенеп аңа елмайды.

Зөфәр кисәк кенә омтылып аңа үрелде, ләкин Рәшидә аның кулын туктатты:

– Кирәкми!

Егет үзенең ашыга төшүен бик тиз сизеп алды, шунда ук кире чигенде һәм озак кына тыелып утырырга мәҗбүр булды. Әйе, Рәшидә бүген бүтәнчәрәк иде шул! Ятсыну яки тарсыну кебек нәрсә һич сиздермәсә дә, киресенчә, бик мөлаем, җылы булып күренсә дә, ул бүген үзен Зөфәрдән беркадәр ерак тотарга тырыша иде. Күрәсең, беренче якынлык әле хатын-кыз өчен гел хиссияткә бирелеп, кочагын ачарга әзер тору дигән сүз түгел; күрәсең, теләмәсәләр, барысын онытырга да, яңадан кабатламаска да аларның кодрәтләре җитә...

Һәм алар күбрәк бер-берсенең күзләренә карашып, шул карашлары белән бер-берсен тикшереп-сынап һәм телдән әйтелмәгән кадәресен аңлатырга тырышып, озак кына сөйләшеп утырдылар. Зөфәр теге вакытта үзе Турайдан киткәннән соң, аларның кайсы авылларда булуларын, ничек йөрүләрен, кайчан кайтуларын сорашты. Бу, әлбәттә, бик әдәпле, бик тыйнак сөйләшү иде, әмма ләкин иң чынын, иң кирәген сөйләшү түгел иде, чөнки бу минутта аларның күңелләрендә бөтенләй икенче уй, икенче хисләр иде. Сүз хәзер бары мәхәббәт турында, бер-берсен сагыну турында барырга тиеш – шул гына аларның күңелендә хәзер, әмма... Һаман нидер тота, кыюсызлыкмы, ялган оятмы телләрен һәм хәрәкәтләрен бәйләп тора иде. Моны аеруча

тирән-үткен итеп Зөфәр сизеп утыра, һәм ничек кенә тыелып, әдәп саклап утырмасын, Рәшидә барыбер аны үзенә тарта, барыбер аның тулы иреннәре, күкрәкләре, тар юбкасы аша түгәрәкләнеп беленеп торган төз аяклары аны гел борчып-котыртып тора иде... Белә бит инде ул аны, татыды бит инде, шулай булгач, нигә кирәк бу тыелып азаплану, ялган әдәп саклап маташу? Рәшидә үзе дә сизми дисеңме?.. Юк, сизә булыр, сизәргә тиеш... Әнә бит Зөфәрнең тилмереп каравыннан ул да, барысын төшенгәндәй, исереп китеп, онытылып карый башлый ич!.. Чынлап та иң кадерлесен, иң сакларга тиешлесен кызганмады лабаса, асылда бит инде ул аныкы, йә, ни югалта ул хәзер?!

Шулай уйлады Зөфәр һәм үзенчә бик хаклы дип тапкан шул уй-хисен, тыелгысыз дәртен салмак-киеренке, әмма йомшак тавышы белән дә, ялварулы, әмма көйдергеч карашы белән дә Рәшидәнең йөрәгенә ничек тә үткәрергә, ничек тә аны үзенеке төсле үк хәлгә китерергә тырышты, һәм, ахырда, кара-каршы шундый бер «көйләнүне» сизеп булса кирәк, ул аның кулларыннан тотып, үзенә тарта башлады. Рәшидә зәгыйфь кенә каршылык күрсәтеп, ләкин «барыбер инде!» дигәндәй, ихтыярсыз буйсынып, акрын гына урындыгыннан күтәрелде. Зөфәр, тиз генә торып, аның иңбашыннан кочаклап алды. Ханым бер мәлгә хәлсезләнеп, гүя актык мәртәбә авыр, газаплы үкенүдән: «Нишләдем мин, нишләдем?» – дигән төсле, йөзе белән Зөфәрнең күкрәгенә капланып торды. Һәм шулай аз гына мескенәеп, онытылып торганнан соң кисәк кенә кыюланып башын күтәрде, батыраеп, дымлы күзләре белән егетнең күзләренә төбәлде һәм аяк очларына басып, кибеп киткән иреннәре белән егеткә үрелде.

Аннары алар урын өстендә озак кына тынып, уйланып, ара-тирә сөйләшеп яттылар. Шул чакта Зөфәр, шушы минуттан үзен ничектер өстен, хуҗа бер кеше итеп сизгән хәлдә, Рәшидәдән шәхси тормышы турында (дөресрәге, ире бармы-юкмы – шул хакта) сорашып алды. Рәшидә бу хакта сөйләргә бер дә теләк сиздермичә бераз уйланып, көттереп ятты, шуннан соң гына артык җәелмичә кыска гына сөйләп бирде: әйе, аның ире булган. Фин сугышы алдыннан ул бик яшьли генә берәүгә, ачыграк әйткәндә, опера театрының бер музыкантына иргә чыккан... Ленинградтан килгән кеше булган икән ул үзе.... Менә шул ире, фин сугышы башлангач, киткән. Ләкин ул аннан кире борылып кайтмаган, шактый вакыт хәбәрсез торганнан соң, мин монда урнаштым, Казанга кайта алмыйм, теләсәң үзең кил, дип хат кына язган... Рәшидә, билгеле, аның артыннан бармаган, чөнки ул татар артисткасы, татар сәнгатендә эшләргә тиеш.... Шулай итеп, музыкант белән аның арасы өзелгән... Үкенми ул үзе бу эшкә, оныткан инде ул аны, чөнки башта ук аларның бәйләнешләре ныклы була алмаган. Музыкант коточкыч эгоит булган, Рәшидәне

аңламаган, аңларга да теләмәгән, гомумән, аңа син кем дә мин кем дип бик югарыдан гына караган. Әйе, менә шул... Яшьлекнең үкенечле хатасы – газабын инде ул үзе генә белә!

Шулай тыелып кына, әрнүен-үкенечен эченә йотып кына сөйләп бирде Рәшидә башыннан кичкәнен. Авыр һәм ямьсез тәэсир калдырды аның бу сөйләгәннәре Зөфәрдә... Дөрес, башта кыска гына бер ара аның күңелендә Рәшидәне кызгану тойгысы уяна язып куйды. Ләкин бик тиз бу күбәләктәй зәгыйфь тойгыны ачу, нәфрәт, көнчелек кебек аюдай зур усал тойгылар басып китте. Көнчелек аның ирлек горурлыгын күсе кебек кимерә башлады, ә музыкантка җен ачулары кабарды: менә шул бурзай чәйнәп ташлаган чеби хәзер аның янында ята түгелме соң?! Әмма Зөфәр эчендәгесен тиз генә тышка чыгара торган кеше түгел, шуңа күрә бер сүз, бер хәрәкәт белән дә ул йөрәгендә купкан тойгыларын сиздермәде, тик салкын бүрәнәдәй кирәгеннән артык җансыз тын калып, иреннәрен кысып, чалкан ята бирде. Рәшидә, билгеле, аның хәлен ачык сизде һәм, үз нәүбәтендә, дәшмичә, орынмыйча ни булып бетәсен генә көтеп ятты. Зөфәр алдында ул үзен һич гаепле итеп тоймый иде, нәрсә өчен булса да акланырга кирәк дип тапмый иде, ләкин шуңа карамастан Зөфәрне нигәдер азрак кызгана да, ихтыярсыздан, аны югалтмыйм дип курка да иде. Әллә ничек менә шушы авыр сөйләшүдән соң ул аны бик бирелеп, бик саф итеп ярата иде кебек.

...Алар арасында бу хакта шул көнне дә, соңыннан да бүтән сүз булмады. Зөфәр Рәшидәнең үткәненә юри яңадан кайтырга теләмәде, вакчыл-көнче булуга караганда, искитмәгән горурлык күрсәтүне отышлырак дип санады, шуңа күрә эчен тырнаган ямьсез тойгыларны ничек тә басарга һәм Рәшидәгә мөнәсәбәтен үзгәртмәскә тырышты, әмма шуның белән бергә үзе өчен бик җитди нәтиҗәне ясап та куйды: юк, Рәшидә аңа лаек хатын түгел! Ул инде өйләнмәгән егет башы белән ниндидер бер килмешәк ташлап киткән шактый җилбәзәк хатынны үзенә гомерлек яр итмәячәк! Аның кебек кешегә, вакыты җиткәч, кул тимәгән чәчәктәй саф кыз да табылыр... Асылда бит бу аның күптән күңелендә йөрткән чын теләге, татлы хыялы – аны инде филармония артисткасы гына үзгәртә алмаячак.

Ләкин, әнә шундый нәтиҗәне ясап куюга карамастан, Зөфәр Рәшидәне тиз генә ташларга һич уйламый да иде. Ни өчен ташларга? Аның кебек ялгызакның бер «күңел юаткычы» булырга тиеш түгелмени? Ничек диләр әле, сөяркә, диләрме? Әйе, нәкъ менә үзе!.. Ә Рәшидә сөяркә булыр өчен бик тә уңай, бик тә кулай хатын инде. Үзе япа-ялгыз, үзе чибәр-сылу, үзе яшь артистка – мондыйны бит кешеләр махсус эзләп тә таба алмыйлар! Юк, ташлау түгел, аны ничек тә сакларга, саклау гына түгел, кадерләп тотарга да кирәк иде әле. Күпмегә кадәр бу сузылыр – ул хакта алдан юрап куймаска да мөмкин, вакыт үзе күрсәтер.

Алар Хәмит бүлмәсендә әледән-әле очраша торган булдылар. Рәшидә шәһәрдә чакта бу очрашу шактый еш кабатланды, ә гастрольгә чыгып киткән чакларында озак кына өзелеп тә торгалады. Мондый вакытларда Зөфәр аны бик юксынып, сагынып көтә иде. Ничектер ул аңа бик ияләште... Аның эштән башка бүтән бер кызыгы да булмаган шактый күңелсез тормышына Рәшидә ниндидер ямь-яктылык алып килә иде. Уйламыйча, сагынмыйча, теләмичә тора алмый иде ул аны! Һәм озак торып очрашкан минутларда «сайрар кошын» иркәләп-сөеп туймый иде ул... Ә соңыннан борчылып уйлана иде: бу ни хәл бу, бик тирәнгә китте түгелме соң бу, ахыры ни белән бетәр моның?! Хәер, мондый борчылу бик тиз яңадан сагына башлауга әйләнеп кала иде. Акыл исәбе түгел, йөрәк таләбе көчле чак иде шул әле!

Рәшидә исә Зөфәрнең кайнар «мәхәббәтеннән» тәмам сихерләнеп, шуңа чиксез куанып, беткәнче аныкы гына булып йөри бирде. Билгеле инде, ул үзен сөяркә итеп танудан бик ерак иде, хәтта андый нәрсә бер генә тапкыр булсын аның күңеленә дә килмәде... Киресенчә, бик сәер башланган бу якынлыкны ул ихтыяри, тигез, шунлыктан чын, саф мәхәббәт дип уйлый иде. Асылда бит ул Зөфәрнең нинди кеше булуын, нинди уй, нинди теләкләр белән яшәвен бөтенләй белми дә иде.

Менә шуңа күрәдер инде егетнең әледән-әле сынап: «Яратасыңмы?» – дип, соравына каршы Рәшидә балаларча бик самими итеп, гел бер үк сүзләр белән җавап кайтара иде:

– Әйе, яратам!

– Ни өчен яратасың?

– Ни өченме? Әллә тагын... Моны әйтеп буламы икән соң? – Ул, чыраена җитдилек бирергә тырышып, кашларын җыерган була, ә үзенең шук йөзеннән шат көлү пырхылдап очарга гына тора. – Син әнә нинди дәүсең, тазасың, ә үзең бик сабырсың, йомшаксың... мин бит тупас ирләрне бер дә яратмыйм... әйе, күңелең йомшак, мөгамәләң йомшак... миңа рәхәт синең белән... Менә ни өчен яратам шикелле мин сине, акыллы, сабыр, җирән кашкам! – Һәм шаркылдап көлеп, ул иркә песидәй егетнең киң күкрәгенә сыена иде.

Бу аның бәхетле минутларында шаярып сөйләнүе иде. Ләкин бер кечне нәрсәдәндер борчылып уйга калган чагында ул үзенең гамәлен Зөфәргә бик җитди-ачык итеп тә әйтеп бирде:

– Мин беләм, Зөфәр, синең миңа ничек каравыңны,—диде ул, әкрен-моңсу гына. – Ансат кына кулыгызга төшкән хатын-кызга сез, ирләр, гомумән, бик түбән карыйсыз... Аңламыйсыз сез аларны... Йә, ни өчен мин сине беренче килүеңнән үк... кабул иттем?.. Ир кирәктән дисең инде син, телдән әйтмәсәң дә, эчеңнән шулай уйлыйсың. Хәер, синең урыныңда кайсы ир дә шулай уйлар иде... Ә бит мин авыл-район җирләрендә һаман йөреп торам, төрле кешеләр белән очрашырга туры килде миңа, синең кебек мыштым гына үрмәләп килүчеләр аз булмады, ләкин

мин аларны тибеп кенә очыра идем... Ә бу юлы... бу юлы мин алай эшли алмадым... Ходаем, ни булды соң миңа, ничек соң мин шулай... онытылдым?.. Белмим, белмим!.. Тик шуны беләм: син беренче күренүдән үк әллә ничек менә күңелемне җилсеттең... яхшы кеше, ягымлы кеше булып күрендең син минем күземә, Зөфәр!.. Ләкин ул гына аз әле, ул гына җитми әле... Бер хатын да, кеше миңа ошады дип кенә, акылын җуймый, юк!.. Тагын нидер кирәк иде, әйе, нидер кирәк иде... Хәтерлисеңме, акыллым, Турай клубында мин җырлап бетергәч, халык миңа ни диеп кычкырды?.. «Безнеке кебек сугыш кырларында йөргән ярың булса, исән-сау кавышырга насыйп итсен», – дип кычкырды бит! Ә минем юк, көтәр беркемем дә юк, мин ялгыз!.. Ялгыз, ялгыз!.. Әгәр минем көтәр кешем булса иде, мин, намусыма түгел, кигән туфлиемә дә тузан бөртеге төшермичә, аны көтәр идем, биш ел да, ун ел да, гомерем буена да көтәр идем. Ләкин юк шул, юк, кәккүктәй ялгыз мин! Аңлыйсыңмы син шуны, Зөфәрем?! Акланырга тырыша дип уйлый күрмә, Зөфәр! Юк, мин акланырга теләмим, аклана белмим, тик шул чактагы хәлемне аңлатыр өчен, мин сиңа бөтенесен ачыктан-ачык сөйлим генә... Син бел, барысын да бел!.. Әйе, мин ялгыз хатын, миңа әле егерме дүрт яшь кенә, үзең күргәнчә, елның җиде-сигез аен авылларда йөрүче, кайткан чакларында бер карчыкның юеш почмагында торучы, ятарга үз караваты да булмаган билгесез бер артистка – менә мин кем. Әмма минем мәхәббәткә һәм бәхеткә хакым бар иде. Миңа җылы кирәк иде, юаныч көттем, күңелем эчкерсез дуслыгы кирәк иде... Мин көттем, күңелем белән бик күптән көттем... Ниһаять, син очрадың... Мин беренче караштан ук гашыйк булуга ышанмыйм, әмма салкын вокзал эчендә син каршыма килеп баскач, йөрәгем, сискәнеп, миңа: «Менә ул кеше!» – диде... Әйе, ниндидер бер тетрәнү, уяну, сагаю бөтен эчемне өшетеп, эсселәндереп узды... Менә ничек башланды ул... Ә син безнең белән ачык кына, йомшак кына сөйләштең. Авыр хәлебезгә кереп, тизрәк атлар да табып китердең... Өстемә толыбыңны бирдең, аякларымны салам белән урадың, юл буе салкыннан өшемиме бу, дип кайгыртып бардың. Һа, ир кешенең әнә шундый эчкерсез яхшылыгын хатын-кыз аңлый белә ул, бәяли белә, дустым!.. Әгәр шул чакта син бер генә хәрәкәт яки сүз белән үзеңнең берәр яшерен теләгеңне сиздергән булсаң, ант итеп әйтәм, безнең арада һични булмас иде. Алай гына да түгел, минем йөрәгем шунда ук йомылган булыр иде, син минем өчен югалган, беткән булыр идең... Ышанасыңмы?.. Ләкин син фатирга төшкәч тә, концерттан кайтып, ашап-эчеп утырган чакта да үзеңне гаҗәп тыйнак, әдәпле тота белдең. Миңа бик игътибарлы булдың, хәер, бер миңа гына түгел, безнең барыбызга да чын кешечә бертигез була белдең... Һәм минем күңелем шуңа балаларча сөенеп, сиңа һаман тартыла, якыная барды... Тик син моны дөрес аңла, Зөфәр, дөрес аңла, бу бик саф, гөнаһсыз, керсез хис иде. Юк, мин сиңа ир итеп кенә караудан, сине ир итеп

теләүдән бик, бик ерак идем. Мин гүя кеше таптым, кешегә сокландым, шул кешенең үзе, җылы-йомшак мөнәсәбәте миңа тансык иде, миңа кадерле иде...

– Ә соңыннан? – диде Зөфәр, сак кына.

– Мин беләм синең нәрсә уйлап соравыңны, Зөфәр,—диде Рәшидә, ашыгып; кинәт аның күзләренә яшь килеп тулды, һәм ул бугазына күтәрелгән төерне йотып куйды. – Ашыкма, мин сөйлим, барысын да... Син белергә тиешсең... Әйе, ул төнне мин дә йоклый алмыйча яттым. Синең йокламавыңны белеп, һәр кыймылдавыңа колак салып яттым... Көттемме мин сине? Әйе, көттем, яшермим. Мин бит үзем дә тынычлыгымны җуйган идем. Хәтта син миңа тиярсең дигән курку да күңелемә килмәде... Нишлим, үзе егылган еламас, диләрме, менә шул инде... Әйе, мин сиңа ачулана да, рәнҗи дә алмадым, чөнки ул син идең, син булганга күрә генә мин... синеке булдым... Әмма шул хәлдән соң минемниләр кичергәнемне белсәң иде!.. Әле кочагыңда чакта ук инде мин шул минуттан сиңа буйсынган зәгыйфь бер хатын булып калуымны тойдым. Кинәт үземне кызганудан күземә яшьләрем килде, һәм йөрәгемә авыр бер төер утырып калды... Хәзер дә ул төернең беткәне юк. Ләкин шул кичтән соң мин синең өчен яши башладым, Зөфәрем!.. Барысы да сиңа, барысы да синең аша гына. Хатын-кыз мәхәббәте шулай ул – үземә дими, аңа булсын, ди. Бәхетне дә, рәхәтне дә үзе биреп кенә таба ала... Тик... тик үкенечкә генә булмаса ярар иде!.. – Һәм Рәшидә әкрен-тирән сулап башын иде, тынды, бүтән кузгалмады.

Аның бу беренче һәм соңгы мәртәбә рәхимсез ачыклык белән сөйләгән сүзләреннән Зөфәр үзе дә ни әйтергә белмичә озак кына тынып утырды. «Әйе, мәсьәлә шактый катлаулы икән!» – дип, ихтыярсыздан уйланып калды ул һәм Рәшидәнең моңарчы күпме үкенү, икеләнү газаплары кичереп килгәнлеген үз күзе белән күргәндәй булды. Кеше кайгысын тыңлап, йөрәгенә якын алып өйрәнмәгән булса да, ул Рәшидәне чынлап кызганды һәм аңа тагын да йомшаграк, игътибарлырак булырга кирәк дигән фикергә килде... (Әйе, онытсын бичара үзенең бу әрнү-үкенүләрен, югыйсә икесенә дә кыен ич болай!) Шуның белән бергә, реаль уйлаучы кеше буларак, ул Рәшидәнең ялгызлыктан зарлануыннан икенче бер нәтиҗә дә ясап куйды: тормыш хәзер бик авыр, кытлык-мохтаҗлык бик зур, бигрәк тә артистка кеше бу мохтаҗлыкны авыр кичерәдер, димәк, аңа аз-маз ярдәм дә иткәләргә кирәктер... Ихтимал, Рәшидә үзе дә моны эченнән өмет итеп йөридер... Ничек кенә булмасын, хатын-кыз бүләк алырга ярата ул... Шулай хөкем итте Зөфәр. Элек тә бу хакта уйланганы бар иде, хәзер исә уңай форсат чыкты дип исәпләде.

Һәм озак та үтми бер очрашуларында ул Рәшидәгә маркизет күлмәклек китерде. Рәшидә моңа бик куанды, күктәй ачык зәңгәр маркизетны кат-кат тотып та, сүтеп тә, өстенә каплап та карады. Бик килешә икән, диде, выходной күлмәк тектереп була икән, диде, аннары, күпме тора

соң бу, дип тә сорады. Зөфәр аңа, ваемсыз гына, күпме торганын сорама, мин сиңа бүләк итеп китердем, диде. Рәшидә моны ишеткәч, берьюлы җитдиләнеп, хәтта караңгыланып китте.

– Юк, мин синнән бүләк кабул итә алмыйм, – диде ул, салкын-коры гына.

Зөфәр, артык гаҗәпләнүдән, бераз ни әйтергә белмичә торды.

– Туктале, – диде ул, күзләрен зур ачып. – Ни өчен алмыйсың? Мин бит шаярып әйтмим... Чын ихластан сиңа бүләк итеп китердем!

– Рәхмәт, ышанам, ләкин барыбер ала алмыйм! Әйтмәгән булсам, белеп тор: түләүсез мин синнән төймә дә алачак түгелмен!

– Бу ни өчен тагын?

– Шулай. Намусым кушмый. Хурланам... Бүләк түгел, түләү бу... Юк, юк, кирәкми...

– Гаҗәп, гаҗәп! – диде Зөфәр, шаккатудан кулларын җәеп.

– Бер дә гаҗәпләнер урын юк монда! – диде Рәшидә, нигәдер һаман кыза һәм гасабиләнә барып. – Без тигез кешеләр! Беләсеңме шуны – тип-тигез кешеләр!.. Мәхәббәтемне бирәм, мәхәббәтеңне алам, әмма өстәү кирәкми, түләү кирәкми... Андыйлардан түгел мин!

Аның кашлары тартылды, күзләре кинәт яшь белән тулды һәм, Зөфәр каршы бер сүз әйтте исә, һичшиксез, үксеп елап та җибәрер иде. Зөфәр нәкъ кирәк минутта тыела белде. Хәер, Рәшидәнең һич көтелмәгән яктан бу кадәр кинәт ачылып куюы аны шундый гаҗәп-хәйранга калдырды ки, гомумән ни дә булса аңлаудан һәм әйтә алудан ул ерак иде әле. Тик күпмедер вакыт үткәннән соң гына урындык аркасында эленеп яткан маркизетка ымлап, сорап куйды:

– Кире алып китиммени инде?

– Юк, нигә, калдыр... Мин акчасын түләрмен...

– Ә мин нинди йөз белән синнән акча алыйм? Шул хакта да уйладыңмы син?

Рәшидә килеп Зөфәрнең иңбашына кулын салды —ул инде бераз тынычлана төшкән иде.

– Үпкәләмә! Мин бит сине гаепләмим, акыллым! Беләм, син ихлас күңелдән мине куандырырга теләгәнсең... Рәхмәт моның өчен, рәхмәт! Ләкин син дә мине аңла инде: кабул итә алмыйм мин бүләк, бигрәк тә синнән, бигрәк тә хәзергедәй авыр чакта...

Зөфәр, кабаланып, аның сүзен бүлде:

– Ну, ярар, бүләк булмасын, бүләк түгел, ди, ярдәм... Ярдәм итәргә генә минем хакым бардыр бит инде?.. Моны җиде ят та бер-берсенә эшли...

Рәшидә, ихтыярсыз елмаеп, Зөфәргә бармак янап алды:

– Һай, хәйләкәр дә соң үзең! Ярдәм, имеш!.. Ярый алайса, дустым, ярдәмгә мин дә каршы түгел... Менә нинди әйбәт материя табып китергәнсең, бик кыйммәт тормаса, мин аны алып

калырмын. Шушы инде синең миңа зур ярдәмең булыр. Зөфәрем табып бирде, дип мин аны куана-куана киеп йөрермен! Дөресме?

Зөфәр артык бәхәскә кереп тормады, чөнки Рәшидәнең үз сүзендә нык торачагы көн кебек ачык иде. Уйлый белгән кешегә бу кечкенә вакыйгадан шактый гыйбрәтле нәтиҗәләр ясарга мөмкин иде: Зөфәрне иң нык гаҗәпләндергәне – Рәшидәнең үз абруен һәм горурлыгын саклауда искиткеч катылык күрсәтүе булды. Көтмәгән иде ул моны, һич көтмәгән иде... Әгәр артистканың тормышы шәптән булса, бер хәер иде. Югыйсә көнен көнгә чак ялгап, бик авырлык белән генә алып бара бит!.. Беренче генә очрашулары түгел – Зөфәр моны күптән сизеп-күреп өлгергән иде инде. Кайбер килүләрендә Рәшидә күңелсез, боек була, озак кына башын тотып хәлсезләнеп утыра. «Ни булды, әллә авырыйсыңмы?» – дигәч, тизрәк елмаерга тырышып: «Юк, авырмыйм, болай гына», – дип әйткән була торган иде. Ләкин, никадәр генә яшермәсен, бу хәлсезләнеп, боегып калуның сәбәбе, нигездә һаман шул авыр мохтаҗлыктан, туры гына әйткәндә, ачлы-туклы торудан килеп чыкканлыгын белү бер дә кыен түгел иде. Соңга табарак Зөфәр Хәмит бүлмәсендә икесе өчен генә сый да әзерли башлаган иде. Плиткада бик әйбәт төсле кофе кайнатып ала, табынга ак күмәч, май, шикәр, ит яки балык консервысы ачып куя һәм кунагын каршысына гына утыртып, сыйларга тотына иде. Шул чакта Рәшидә, бичара, нихәтле генә күңелсез булмасын, бөтенләй икенче кешегә әверелеп китә иде. Юк, ул ашка ташланмый, юк, бик әдәп саклап, матур итеп, нечкә бармаклары белән аз-аз гына алып ашый, әмма шул сыйларга кагылу белән аның кәефе нәкъ балаларныкы төсле булып үзгәрә иде. Шунда ук сөйләнә, көлә, шаяра башлый, ә ашап туйгач, хәтта: «Синең өчен генә!» – дип җырлап та куйгалый иде.

...Һәм менә шул хатын Зөфәрнең китергән бүләген алмады, катгый рәвештә кире какты!.. Әйе, гыйбрәт бу... Мәхәббәт уртак булырга мөмкин, сыныкны уртаклашырга мөмкин, әмма кешелек горурлыгын урталай бүлеп булмый икән. Кешенең үзенә куйган бәясе бар – шуннан бервакытта да төшмәячәк ул!

Рәшидәнең Зөфәрне әнә шулай гаҗәп-хәйранга калдырган чаклары аз булмады. Бриллиант кисәгедәй йә үзәге, йә берәр кырые белән кинәт нур чәчеп, чагылып куйгалый иде ул... Аеруча хыял матурлый торган иде аны...

Зөфәрнең юмарт мәхәббәтеннән һәм сыеннан кәефе бик яхшырып киткән минутларда ул үзенең кадерле хыялларын, хыял иткән максатларын дәртләнеп сөйләргә тотына иде... «Мин лирик героиня булырга телим», – ди иде ул Зөфәргә, бик зур серен ачкандай итеп. – Эстрада җырчысы булып йөрүдән тәмам туйдым, аннары ул мине һич канәгатьләндерми, минем сәхнәдә уйныйсым килә, төрле-төрле образлар тудырасым килә, аңлыйсыңмы?.. Бу минем хыялым,

сугыш кына бетсен, мин барыбер театрга күчәчәкмен... Әйе, менә әйтте диярсең! Миндә бит теге ни, әлеге драматический талант бар, беләсеңме син шуны?.. «Гроза»дан Катеринаны яки «Мәкер вә мәхәббәт»тән Луизаны мин сиңа шундый итеп уйнап күрсәтер идем, җанкисәгем... Һо! Чәчләрең үрә торыр иде!.. Ышанасыңмы, юк, әйт, ышанасыңмы?.. Алайса менә шул!.. Үзебезнең әйберләрдәнме?.. Үзебезнең әйберләрдән «Галиябану»ны бик яратам. Галиябануны уйнаганым да бар... Телисеңме, мин хәзер сиңа аны уйнап күрсәтәм, юк, телисеңме?»

Һәм ул, җавап та көтмичә тиз генә торып, кыек яулыгын татар кызларыча башына бөркәнеп, җиңел генә атлап тәрәзә кырыена бара. Шунда ук бөтен хәрәкәт-кыланышы белән нәфис-сылу Галиябануга әверелеп уйный да башлый. Искиткеч үзгәреш!.. Урамнан исемен атап җырлаучыларны ишеткәч, нәкъ менә кыр кәҗәседәй куркып-сагаеп та калган, сөенеп-очкынланып та киткән, борчылып-сабырсызланып та көткән унсигез яшьлек саф, садә авыл кызы күз алдына килә дә баса. Инде ул, тәрәзә яңагына ышыклана биреп, Хәлиленә каршы әкрен генә, дулкынланып, тибрәнеп кенә җырлап та җибәргәч – бетте, моның кебек тулы иллюзияне сәхнәдә дә сирәк күрерсең!.. Әйе, бар икән, бар икән үзендә илаһи, чын талант, кодрәтле талант!..

Рәшидә үзе дә шуны ачык тоеп, шуңардан әйтеп бетергесез сөенеп, Зөфәр янына атылып килә дә, алдына утырып, муеныннан кочып ала.

– Сәнгатьне яратасыңмы син? Театрны яратасыңмы син, абыем? Әллә артистканың үзен генә яратасыңмы? —ди ул, балаларча сыенып-сыйпаланып.

– Яратам, яратам, сине дә, театрны да, Галиябануны да – барыгызны да яратам! – ди Зөфәр, Рәшидәнең яшьләнеп киткән күзләреннән үбә-үбә.

Һәм иң гаҗәбе – һич риясыз әйтә ул моны, шушы минутта хис иткәнен әйтә, чөнки бу минутта ул үзе дә ничектер икенче төрлерәк кеше булып китә иде. Шушындый гүзәл, ак хыяллы, нечкә, пакь җанлы бер хатынның якын, ышанычлы кешесе булу аны ничектер үз күз алдында үстереп җибәрә, күңелен әйбәт бер горурлык белән тутыра иде. Алай гына да түгел, бүтән бервакытта да татырга туры килмәгән, бары чын матурлыктан, якты уйлардан гына килергә мөмкин булган аеруча тирән, олы бер бәхет кичергән кебек тә була иде ул...

Һәм менә шундый чакларында Зөфәр, артисткага «сөяркә» итеп кенә каравын онытып, әгәр сорасам, Рәшидә миңа иргә чыгар идеме икән, дип тә уйлый торган иде. Бу хакта алар арасында бер генә тапкыр да сүз булганы юк; егет кирәк тапмагач, кыз бервакытта да үзе башламый инде, билгеле... Ләкин, Зөфәр исәбенчә, Рәшидә аңа чыгар иде, бик теләп чыгар иде, чөнки Рәшидә аны ярата, аңа ышанып карый. Моны исбат итеп торасы да юк... Дөрес, Рәшидә «торгашларны» бер дә яратмый, сәүдә тирәсенә оялаган кешеләрнең күбесен жуликлар дип

саный, ләкин Зөфәрне ул «торгаш» дип белми иде. Киресенчә, Зөфәр зур заводның ОРСында бүлек мөдире булып эшләгәч, ул аны дәүләт ышанычын казанган җаваплы работник дип исәпли иде. Һич шикләнмичә, гадел, намуслы, яхшы кеше дип уйлый иде ул аның хакында... Бер дә гаҗәп түгел, чөнки Зөфәр, болай өстән караганда, әйбәт кеше иде, аннары, кирәксә, гомумән ул үзен иң уңай яктан күрсәтә дә белә иде. Рәхим ит, ул игътибарлы да, ачык йөзле дә, йомшак телле дә, тыйнак, сабыр да, кыскасы, милый человек!

Шуның белән бергә ул гаять сак кеше дә иде, бервакытта да артыгын сөйләмәс, күбрәк бик акыллы итеп дәшмичә торыр, шуңа күрә дә ул Рәшидәне рәхәтләнеп тыңлады, тәэсирләнде, сокланды, әмма үзенең уй-теләкләрен аңа һичкайчан сөйләмәде – иң яратып, нечкәреп, күңеле белән беткәнче ачыласы килеп якынайган чакларында да йомык-бикле булып калды... Акыл искиткеч уяу иде аңарда!

Әйе, тормыш схемаларны вата. Йөрәкләр бергә, тәннәр бергә, ә теләкләр үзгә, уйлар башка! Зөфәр өчен Рәшидә, күпме генә ул аны яратмасын, һаман шулай мәхәббәткә юмарт, уңай сөяркә булудан – узмады, чөнки аның идеалы Рәшидә түгел иде. Ә менә кешегә бик ышанучан, кеше турында бары яхшы итеп кенә уйлаучан, беркатлы садә-самими яшь ханым өчен исә Зөфәр бик әйбәт, бик сөйкемле егет иде, һәм ул аны ир итеп кенә түгел, күңеленә ошаган кеше итеп тә чын ихластан бирелеп яратты. Өйлән, ал мине, дип әйтергә кыймады, әлбәттә, ләкин шулай да эченнән генә һаман өмет итте булса кирәк...

1944 елның җәендә Рәшидә, башка артистлар белән бергә фронтка барып, ай ярым чамасы сугыш кырларында йөреп кайтты. Кайткач ул Зөфәргә фронтта күргәннәрен түкми-чәчми сөйләп бирде. Төрлесеннән —куркынычыннан, кызыклысыннан – бик күп нәрсә җыеп кайткан икән үзе дә. Тик кавышу шатлыгыннан булса кирәк, күбрәк кызыклысын, ул, мин сиңа әйтим, солдатларның аларны искиткеч сөенеп, кочаклап-күтәреп каршы алуларын, концертларны балалардай йотлыгып тыңлауларын, ул, мин сиңа әйтим, зур-зур командирларның, хәтта генералларның аларны гаять хөрмәтләп йөртүләрен, бик шәп сыйлап кунак итүләрен, инде шуның өстенә тагын аңа, Рәшидәгә, бер йөзләп кешенең гашыйк булуын, хәтта бер яшь кенә подполковникның болар киткән чакта, кап-кара куркыныч пистолетын чыгарып, моңа сузуын, «Нигә бу миңа?» – дигәч, тегенең кулын йөрәгенә куеп: «Ханым, ташлап киткәнче атып китегез!» – дип ялварып әйтүен – һәм башкаларын, һәм башкаларын, гадәтенчә ялкынланып, бик матур тасвирлап сөйләде ул... Һәм аның шушы эчкерсез ышанып сөйләгән сүзләреннән Зөфәр үзе өчен бары бер генә нәтиҗә ясый алды: «Юк инде, артистка белән башың бәйләнә күрмәсен! Гомергә уртак хатынның ахмак ире булып йөрерсең шунда!..» Күп кенә

ирләр төсле, чын мәхәббәтнең һәртөрле хыянәт-түбәнлекләрдән саклавын ул белми дә, аңламый да иде.

Сугыш беткән көннәрдә аларның мөнәсәбәтләре әнә шундый хәлдә иде. Ике төрле кеше, ике төрле мәхәббәт асылда, ләкин, ничек кенә булмасын, алар бер-берсенә бик нык бәйләнгәннәр иде инде. Сугышның бетүе исә алар арасындагы бу бәйләнешкә һичшиксез зур йогынты ясарга, аны теге яки бу якка үзгәртеп җибәрергә тиеш иде. Бигрәк тә Зөфәр, тыныч шартларга килеп эләккәч тә, үзенең күптәнге җитди планнары турында уйлана башлады. Рәшидә мәсьәләсе арткарак күчте. Ләкин якынлык өзелмәде, ул тик бераз сүрелә генә төште. Кыскасы, алар арасындагы тарихның башы булды, дәвамы булды, әмма ахыры юк иде әле.

**VI**

Сабитовлар Суконныйдагы аулак урамнарның берсендә, ике катлы бүрәнә йортның түбәнге катында барысы бер гаилә булып торалар иде. Ниндидер бер вак купецтан калган бу йорт, ишле халык тору аркасында һәм соңгы егерме биш-утыз ел эчендә һичбер ремонт-мазар күрмәгәнлектән, шактый нык тузган иде инде. Түбә калае тутыгып, күп җирдән тишкәләнгән, нигез өстендәге бүрәнәләре һәм тәрәзә аслары яртылаш черегән, ә болдыр баскычлары күптән череп, чалышаеп беткән иде. Йорт үзе дә, тезләнергә җыенган дөядәй, алга таба чүгә башлаган иде. Хәер, бу урамдагы эреле-ваклы агач йортлар барысы да диярлек йә алга, йә бер янтыкка таба чалышаеп торалар. Картайган, тузган иске Казан урамы! Мондый урамга килеп керсәң, ничектер, борынгы заманга әйләнеп кайткан шикелле буласың.

Зөфәр сугышка чаклы ук әле үзенә квартирмы, өйме сатып алу турында исәп тотып йөрде. Сугыш вакытында бу теләкне гамәлгә ашыру бик ансат иде, йортларын сатучылар күп булды, һәм азык бәяләренә нисбәтән арзан гына алырга да мөмкин иде. Ләкин Зөфәр, төрле исәпләрдән чыгып, мондый зур тәвәккәллек сорый торган эштән ул чагында тыелып торуны хәерлерәк күрде. Хәзер исә, сугыш бетү белән, йорт сатып алу мәсьәләсенә ул чынлап тотынды. Аныңча, бу эшне хәзер озакка сузарга ярамый иде. Бердән, йортларның бик кыйбатланып китүе мөмкин, икенчедән, кулда зур сумма акча асрап яту да файдалы эш түгел... Дөнья хәлен белеп булмый, акчаның малга әйләнә торуы хәерлерәк...

Җәйгә чыгу белән Зөфәр, абыйсының кайтып җитүен дә көтмичә, ышанычлы кешеләре аша йорт караштыра башлады. Сатарга теләүчеләр бар иде, аңа төрле җирдән йортларның төрлесен тәкъдим итеп карадылар. Ләкин Зөфәр күңеленә ошаганы һаман табылмады. Бигрәк тә ул күбесенең районын яратмады. Татар ягыннан яки Суконный тирәсеннән аның аласы килми иде. Татар ягында кайчандыр аларның матур, җыйнак кына үз өйләре бар иде, ләкин нәп

ахырында этиләренең түләнмәгән налогы өчен аны «чүкечтән» сатып җибәрделәр. Күп кенә авыр хатирәләр белән бәйләнгән җиргә Зөфәрнең яңадан әйләнеп кайтырга күңеле тартмый иде. Гомумән, ул сазлык буенда утырган Татар бистәсенең үзеннән дә һәм кайбер вакчыл, көнче кешеләреннән дә бик бизгән иде. Шулай ук Суконный тирәсе дә аның өчен кулай түгел. Монда да аларны белүче көнче күзләр һәм озын телләр шактый күп. Шуңа күрә ул булачак йортын шәһәрнең яшеллеккә бай югары өлешеннән, урыслар арасыннан эзләтте.

Зөфәр өчен бу эштә Курамшин дигән карт бик тырышып йөрде. Курамшин андый-мондый гына татар карты түгел иде. Чын булса, ул заманында коммерческий училище бетергән, Уралдагы бер татар миллионерында доверенный булып эшләгән кеше икән. Моны ничектер аның тышкы кыяфәтеннән үк сизеп була иде. Эре сөякле, озын буйлы бу кеше кайчандыр бик мәһабәт – таза булганга охшый; хәзер дә әле, йончып, шиңеп бетсә дә, һәм киң аркасы бөкрәеп чыкса да, гүя борынгы килбәтен сакларга теләп, гәүдәсен ничек тә туры, ә ап-ак чәчле зур башын текә тотып йөрергә тырыша. Тирән сызыклар ярып төшкән кызыл чырайлы битен һәм киң ияген шоп-шома кырып, ә җәенке борынын күмә язган ап-ак калын мыегын, борынгы генералларча, як-якка сузып, тарап йөртә. Тавышы көр, сөйләгәндә гөрелдәп чыга; үзе русчага шундый оста, шундый саф, чиста итеп сөйләшә – татар кешесе дип тә белмәссең. Гомумән, аңарда татарныкы дип әйтерлек берни дә юк иде.

Тик картның өсте-башы бик начар. Ел әйләнәсе диярлек бер пальтода йөри, ул да шул доверенный чагыннан ук калган булса кирәк, эче тәмам телгәләнеп, җиң очлары, чабулары кыршылып, зур төймәләре яртылаш сынып беткән. Әмма тышлыгы гомерлек бер драптан булганга күрә, һаман әле картның эчке ялангачлыгын яшереп, тышкы килбәтен саклап йөртә. Бу пальто картны, ахрысы, каберенә дә озатып куяр... Ләкин өс-башы никадәр начар булмасын, аны барыбер заманында бай да, шәүкәтле дә булган бер кеше итеп танырга мөмкин иде.

Карт Зөфәрләрдән ерак түгел, бер йортның ярым подвалында карчыгы белән генә тора. Аның бүтән беркеме дә юк. Дөрес, бердәнбер генә улы булган, ләкин гражданнар сугышы вакытында ул да яшьли генә аклар армиясенә алынып, Себер шәһәрләренең берсендә тифтән үлеп калган. Карт үзе дә, шактый икеләнеп торганнан соң, бигрәк тә улын эзләп табу өмете белән, ахыр чиктә генә акларга ияреп китеп барган, ләкин Читага хәтле барып җитсә дә, малаен да тапмаган, барлык малыннан да язган һәм мең бәла белән Казанга кайтып егылган... Менә шул заманнан бирле ул Казан шәһәрендә торып маташа. Баштарак аңа хезмәт итәргә мөмкинлек бирәләр, аннары тора-бара аның өчен юллар бикләнә. Чит элемент! Шуннан соң «чит элемент» ачтан үлмәс өчен Сорочий тирәсендә йөреп, иске-москы алып-саткалап, шуның белән «көн итә» башлый.

Зөфәрләрнең этиләре Мөбарәкша абзый исән чакта Курамшин карт аның белән дә шул Сорочийда танышып китә, һәм Мөбарәкша үлгәннән соң да ул Сабитовлар өчен күз күргән бер кеше булып кала. Сугыш елларында карт күбрәк Зөфәр тирәсендә йөреп туена. Хикмәт шунда, борынгы байлыкны күргән карт әйбер таныырга бик оста иде; асыл ташларның чынмы-ялганмы икәнен, фарфор, хрусталь кебек зат әйберләрнең чын сыйфатын һәм кайсы илдән чыкканлыгын, өй җиһазларының нинди агачтан һәм нинди стильдә эшләнгән булуын бер карауда әйтә дә бирә. Шәһәрдә әле иске өй байлыклары кулларында бераз сакланган борынгы сәүдәгәр яки чиновник семьялары һаман табылып тора, шул ук вакытта соңгы елларда гына күтәрелгән, акчаны күп тапкан, ләкин байлыкны күрмәгән дә, танымаган да яңа интеллигент семьялар һаман күбәеп бара. Курамшин карт менә шулар арасында, әйбер танучы буларак, арадашлык итеп, берәүләренә сатышып, икенчеләренә алышып йөри... Зөфәр дә картның нәкъ менә шул якларын бик оста файдалана: ОРС магазиннарыннан алып кайткан кыйммәтлерәк әйберләрен әлеге яңа «байларга» карттан илтеп саттыра, яки бөлгән иске байлардан үзенә кирәк зат нәрсәләрне таптырып ала.

Зөфәр бу картның тик бер генә ягын өнәп бетерми —карт салырга ярата. Кулына аз гына акча керде исә, ашаудан бигрәк, эчү ягын карый. Әгәр шушы кимчелеге булмаса, ул бу кадәр хәерчелеккә төшеп, тетелеп тә йөрмәс иде. Әмма шулай да Зөфәр аны үз яныннан кумый иде: ничек кенә булмасын, заманында коммерческий училище бетергән, доверенный булган, зур байлыклар белән эш иткән кеше бит ул! Хәтта кызганып та куйгалый иде. Бигрәк тә карчыгыннан шушындый бер кыска гына хикәятне ишетеп калгач, бу кызгану аңарда көчәйде: Курамшин картның яшь чагында төшкән бер рәсеме бар икән. Рәсемдә ап-ак катыргы яка, ак күкрәкчә өстеннән бик шәп кара фрак кигән, киң күкрәкле, тулы ак чырайлы, кап-кара кашлы һәм кап-кара мыеклы гаҗәп чибәр-сылу бер кеше басып тора, ди... Һәм менә карт исереп кайткан чакларында шул рәсемне каршысына алып утыра икән. Утыра икән дә, карап тора-тора, исе китеп: «Минме соң бу? Әллә мин түгелме? Минем дә шушындый чакларым булды микәнни?» – дип, чын күз яше белән еларга тотына икән.

...Карчыгы бу хикмәтне гади бер нәрсә итеп кенә сөйләсә дә, Зөфәрнең хәтеренә ул бик нык кереп утырды. Картлык, бәхетсез картлык әшәке нәрсә, моны бервакытта да истән чыгарырга ярамый.

Июль аеның эссе бер көнендә, төштән соң Курамшин карт әлсерәп, юан таягы белән шакылдап, Зөфәрләргә килеп керде. Аның өстендә чабулары сәленеп төшкән, керләнеп беткән киндер пиджак, тез башлары ямаулы кара чалбар, ә аягында җаен-кышын салмый торган тире оек белән эчсез галош иде. Ишектән керүгә, ул гөрес итеп табуреткага утырды һәм читләре

сәлперәеп төшкән фетр эшләпәсен салып, җилләнергә тотынды. Аның муенындагы һәм маңгаендагы буразнадай тирән сызыклары кара тир белән тулган иде.

Өйдә Зөфәрнең әнисе – Таибә абыстай үзе генә иде. Карт, бераз сулыш алганнан соң, читтәрәк сүзсез басып торган абыстайга дәште:

– Бикә! (Ул аңа әллә яхшатланып, әлә үзенчә мыскыл иткән булып, борынгы морзаларча гел шулай дип дәшә торган иде.) Бикә, берәр стакан гына чәең булмасмы? Киптем...

Таибә абыстай, ашыкмыйча гына кузгалып:

– Булыр, – диде, аннары чүпрәк белән кухня өстәленең клеенкасын сөрткәләде, – якынрак утыр!

Карт, табуреткасын тартып, өстәлгә якынрак килде. Абыстай ак самовардан юан корсаклы чәйнеккә су агызып, шуны плитә өстенә куйды. Чәй салды.

– Мондый эсседә нигә бу хәтле газапка тарып йөрисең? – диде абыстай. – Зөфәр дә бит әле тиз генә кайтмый.

– Эш, – диде карт, авыр сулап. – Срочный эш чыкты... Ә Зөфәр тиздән кайтыр, мин аңа шалтыраткан идем.

Абыстай карт алдына стакан белән чәй куйды. Карт эссене тоймас калын иреннәре белән шунда ук стаканга орынды. Бер-ике йотып алгач, тәлинкәгә салып, шапырдатып эчәргә тотынды. Дөресрәге, чәйне тәлинкәдән ул суырып кына алды. Абыстай икенчесен ясап бирде дә, җитәр сиңа дигән төсле, бер читкәрәк китеп утырды. Карт монысын артык кабаланмыйча гына эчеп бетерде, һәм шуннан соң аңа тәмам хәл керде булса кирәк – тураеп, бер җиңел генә сулап куйды, аннары кесәсеннән яулык сыман керле чүпрәк чыгарып, битен-муенын әйбәтләп сөртергә тотынды.

Картның чәй белән генә мәшгуль булуын сүзсез карап утырган абыстай, ниһаять, телгә килде:

– Нинди эш чыкты соң? Әллә йорт турындамы?

Биредә шуны әйтергә кирәк, алар күптәнге танышлар булсалар да, бер-берсе алдында бәйсез горурлык саклап маташалар иде. Карт үзенең кайчандыр Таибә абыстай кебек талчукчы хатыннарны чүпкә дә санамаган шәүкәтле чакларын исеннән чыгармый иде; ә абыстай үзенең хәзерге өстенлеген, картның алар кулыннан икмәк ашап йөргән бер хәерче булуын гел исендә тота иде. Ләкин алар арасындагы бу бер-берсенә карата булган эчке нәфрәт бервакытта да тышка бәреп чыкмый иде. Киресенчә, алар үзара мөнәсәбәттә бик әдәпле кыланырга тырышалар иде.

– Әйе, бикә, – диде карт, көр тавышы белән гөрелдәп. – Бер... дворец табылып тора бит әле... Әгәр насыйп булса!

– Йорт түгелмени?

– Йорт инде, дворец шикелле йорт!

– Алай икән. Хәерле булсын. Кайдарак инде ул?

– Шәп җирдә, бикә, бик шәп җирдә!.. Йорт үзе дә, утырган җире дә әйтерлек кенә дә түгел, шәп! Бүтән аның кебекне табу, ай-һай!.. Тик менә... – Карт башын селкеп куйды.

– Тик нәрсә?

– Охотниклар күп.

– Кемнәр?

– Ну, карап йөрүчеләр, алырга теләүчеләр.

Таибә абыстай, авызын бөрештереп, бераз тынып утырды. Ул кешеләрнең сүзләрен тиз үк чынга алырга ашыкмый иде. Аныңча, бер эштә дә, аеруча сату-алу эшендә, хәйлә шәргыйсез булмый, моны инде, Мәнди анасы да белә. Шуңа күрә абыстай, карт әйткәннәрнең күпмесе дөрес, күпмесе ялган, ялганы нәрсәдә икән дип, уйга калды. Ләкин шул чакта Зөфәр үзе кайтып керде... Ул килеп керү белән карт та, абыстай да урыннарыннан тордылар.

– Ә, Гайсә абзый, килеп җиттеңме? – диде Зөфәр, аңа кул бирмичә генә.

– Да, брат! – диде карт, йодрыгы белән мыегының бер очын гына сыпырып. – Карт алаша кебек абына-сөртенә булса да килеп җиттек әле.

– Йә, нишләп карт алаша? Руслар әйтмешли, боевой конь!.. Әйдә, узыйк миңа.

Зөфәр картны үзенең бүлмәсенә алып керде. Кара-каршы утырып, сүз башладылар. Карт Зинин урамында бер йортның сатылачагын әйтте. Зөфәр иң әүвәл йортның хуҗасы кем булуын, ни өчен сатарга теләвен сорашырга тотынды. Бу аның кагыйдәсе – кем белән эш итәчәген ул алдан белеп торырга тиеш.

Карт белгән кадәресен сөйләп бирде: йортның төп хуҗасы борын Казанда шактый дан тоткан Ушаков фамилияле бер адвокат булган. Ул үзе күптән үлгән инде. Аның варислары һәм йортның хәзерге хуҗалары булып карчыгы, ике кызы һәм бер улы калганнар. Кызларының берсе Саратовта тора икән, улы – врач, хәзерге вакытта хәрби хезмәттә икән әле. Йортта әниләре карчык үзенең кияүгә чыкмыйча картайган өлкән кызы белән икәү генә торалар. Дөрес, сугыш вакытында алар янына Мәскәүдән күчеп килгән бер-ике гаиләне керткән булганнар, ләкин алар инде кире кайтып киткәннәр. Бу җәһәттән бик уңай – сатып алучы буш йортка барып керәчәк.

Ә сатуның сәбәбе?.. Сатуның сәбәбе шул – әлеге врач уллары Киевта урнашып калачак икән. Казанга кайтмаячак, ди. Карчык белән карт апасы үзләре генә монда зур йорт биләп тора

алмаячаклар, әлбәттә. Менә шуңа күрә дә варислар, аталарыннан калган бу йортны сатып, акчасын үзара бүлешергә уйлаганнар. Карчыкны улы үз янына Киевка алып китәчәк, ә карт апалары Саратовка сеңелесе янына күчмәкче булып тора шикелле...

Менә Курамшин картның белгәннәре шул... Болар барысы да дөрес булырга тиеш, чөнки искедән калган мондый интеллигент кешеләрдә хәйлә-мазар һич булмый, имеш. Карт әйтә, алар Чехов геройлары кебек гаҗәп беркатлы, дөньяви эшләрдән тәҗрибәсез, бик гади, инсафлы кешеләр, ди.

Зөфәр авыз кырые белән генә елмаеп куйды. Картның борынгы интеллигентларны гел шулай мактавын аңа күп ишетергә туры килде. «Чехов герое» кебек дигәне дә шул итәгендә песи йоклатып, тузган роман укып утыручы карчык үзе генәдер иде. Ә аның улы-кызлары... болар башка ялан җимешләре булырга тиеш.

– Кем сата йортны, карчык үземе?

– Юк, карчык түгел. Главный наследник Сергей Леонидович үзе кайткан, – диде карт, бик мөһим хәбәр ирештергәндәй, горур-эре генә.

– Ул инде сез әйткән, кем, Чехов герое түгелдер, шәт?

Карт, кинаяле көлүне сизсә дә, җавапны җитди итеп бирде:

– Бик благородный кеше, Зөфәр туган. Дөрес, ул яшь әле, сезнең чамада булыр. Ну...

Зөфәр аның сүзен бүлде:

– Ярар, Гайсә абзый, вакыты җиткәч күрербез без аны. Ә йорт үзе ничегрәк?

– Йорт – шәп! Господин адвокат аны бик таза, бик чибәр итеп салдырган.

– Күптәнме?

– Әйтүләренә караганда, унынчы елларда салынган булырга тиеш. Ләкин йорт таза. Борынгы эш. Яңадан бер илле ел «әһ» тә итмичә торырлык әле.

– Алай икән.

– Менә үзегез дә күрәсез. Мин бит инде...

– Ышанам, Гайсә абзый... Что же, уйлап карарга кирәк булыр.

– Озакка сузарга ярамый, Зөфәр туган! Без болай да соңгарак калдык. Йорт тирәсендә дәртләнеп йөрүчеләр бар.

– Язганы булыр, Гайсә абзый! – диде Зөфәр, гадәтенчә, исе китмичә генә.

Карт Зөфәрнең бу ваемсыз тынычлыгыннан гаҗәпләнебрәк калган төсле булды, бераз дәшми торды, аннары икеләнебрәк әйтеп куйды:

– Анысы шулай... Ләкин, минемчә, сез тизрәк барып карарга тиешсез. Сүзне башлый торырга кирәк. Мондый эштә моментны ычкындырырга ярамый бит... Үзегез беләсез!

– Беләм! – диде Зөфәр һәм уң кулы белән тезен ышкып, беравык уйланып торды. Әйе, ул белә: яңа алучының килеп чыгуы, гадәттә, электән карап-сатулашып йөрүчеләрнең тәвәккәллеген арттырып җибәрә, алар тизрәк кул сугарга ашыга башлыйлар. Шул ук вакытта алучы күбәя башласа, хуҗаларның да аяк терәп маташулары көчәя. Мондый очракта эшне ничек йөртергә —яхшылап уйларга кирәк. Бәлки, сатучыны да, конкурент-алучыларны да саташтырыр өчен тагын берәр кешене «уенга» кертергә кирәк булыр. Һәрхәлдә, ул үзе ашыгып эш итмәскә тиеш. Син сатучының авызына карама, сатучы синең авызыңа карап, көтеп торсын!

Шуның белән бергә карт сүзе дә дөрес: карап-сөйләшеп йөрүчеләр бар чакта моментны ычкындырырга ярамый, нәкъ вакытында ике арага барып керә белергә кирәк. Әлбәттә, йорт аңа ошаган тәкъдирдә генә бу исәпләрне истә тотарга ярый.

Зөфәр йортның бәясен сорашып тормады. Сатылачак нәрсәне үз күзең белән күрмәс борын бәясен сорау күп вакытта саташтыра гына: йә гайрәтне чигерә, йә, киресенчә, ашыгырга мәҗбүр итә. Иң дөресе, әүвәл кичекмәстән барып карарга, әгәр ошый калса, сүзне башларга, хуҗаларны өметләндерергә кирәк... Һәм алар карт белән шулай килештеләр дә: иртәгә кичкә табан адвокат йортын барып карарга булдылар.

**VII**

Зинин урамы. Бер очы рус зиратыннан башлана, икенче очы ниндидер бор чокырга барып терәлә. Урам түшәлмәгән, канау буйларын куе үлән басып киткән, тик ике як тротуарга гына плитә-плитә ак таш җәелгән. Агач күп. Койма буйларында карт тирәкләр, юкәләр очрый, һәр йортның түрендә җимеш бакчасы күренә. Борынгы өяз шәһәрендәге шикелле аулак, тын һәм тыныч.

...Шәһәрне күп таптаган Гайсә карт Зөфәрне Суконныйдан җәяүләп кенә менә шушы Зинин урамына алып менде. Зөфәрнең моңарчы бу якларда бер дә булганы юк иде, шуңа күрә ул зур кызыксыну һәм игътибар белән тирә-ягына каранып бара. Әйе, урам аулак, тыныч, яшеллеккә бай. Монда күбесе бер яки ике катлы агач йортлар икән. Ләкин Суконныйдагы шикелле искереп, тузып, чалышаеп бетмәгәннәр. Әле бик таза, нык утыралар. Еш кына бик пөхтә-матур итеп салынганнары да очрый. Андыйларны күргәндә Зөфәр көнчелек, уфтану аша гаҗәп бер ләззәтләнү хис иткәндәй була. Әйтерсең билгесез-ят, шуңа күрә дә тансык-мавыктыргыч матур бер тормыш аның күз алдыннан беленер-беленмәс кенә чагылып уза. Гайсә карт әйтә, заманында бу урамнарда зур чиновниклар, бай интеллигентлар һәм шәһәрдә кыш уздыручы помещик-дворяннар торганнар, ди. Менә шулар яшәгән тормышның һаман да әле шушы йортлар тирәсеннән китеп бетмәгән зәгыйфь шәүләсе үзен ничектер сиздерә кебек. Алай дисәң, күптән, бик күптән аларның моннан эзләре суынды бит инде. Бик күптән бу йортларда

бүтән кешеләр – тегеләрне куып чыгарган кешеләр торалар. Моны инде һәрбер зуррак йорт янынннан узганда бик ачык күреп була; өйләрнең эчләрен вак тартмаларга бүлгәләгәннәр, ишегалларын иске такталардан корыштырган чалыш-чолыш кетәкләр, утын сарайлары белән тутырганнар, ә кайбер йортларның капка-коймаларын сугыш елларында каерып-сүтеп, ягып бетергәннәр. Бу кадәресе инде Зөфәр өчен шәүлә түгел, ә күзгә бәрелеп торган чынбарлык, һәм ул алар яныннан: «Иясез малны эт җыймас!» – дип, эченнән генә көенеп уза. Шулай да Зинин урамында Зөфәрнең күзен иркәләрлек, хыялын уятырлык йортлар да аз түгел иде әле.

Бара торгач, Гайсә карт аны шундый йортларның берсе алдында туктатты:

– Шушыннан гына үзенә бераз карап торыйк әле,—диде ул, нигәдер тавышын әкренәйтә төшеп.

Каршы якта ике катлы зур йорттан озын гына койма белән аерылган һәм үзенә башкарак утырган бер катлы агач йорт күренә иде.

– Шулмы? – дип сорады Зөфәр.

– Әйе, нәкъ үзе, әйбәтләп кара! – диде карт.

Биек кенә таш нигез өстендә такта белән тышлап, сарыга буяган, парадный ишеге һәм дүрт тәрәзәсе урамга караган йорт тора. Зөфәрнең күзе һәм игътибары менә шуңарда... Сүз дә юк, йорт бик таза, бик чибәр күренә. Беренчедән, шактый зур икән ул, тәрәзәләре дә зур, якты, эче дә бик иркен, якты булса кирәк; икенчедән, күптән салынган булуына карамастан, ул, нәкъ яңа йортлардай ничектер балкып, горур кыяфәт саклап, бик төз, туры утыра. Аннары йорт художество элементларыннан да мәхрүм түгел икән: кәрниз буйлары, тәрәзә башлары, артык чуарламыйча гына, челтәр өлге белән бизәлгән, ә болдыр баганалары нечкә билләп, гөмбәз чыгарып эшләнгән – болар һәммәсе йортка тыйнак бер нәфислек биреп тора...

Ләкин шулай да Зөфәр йортның кайбер искергән-тузган җирләрен дә күрмичә калмады. Мәсәлән, кайчандыр кызылга буяган калай түбәсе инде каралып, уңып беткән. Бәлкем, тишкәләнгән урыннары да бардыр әле. Аннары вакытында бик таза эшләнгән капка-койма да хәзер шактый тузган инде; капкасы бөтенләй артка таба авышып тора. Димәк, болар барысы да яңартуны сорый.

Шул рәвешчә, кулларын артка куеп, Зөфәр йортка озак кына карап торды, картка бер сорау да бирмәде һәм йорттан алган тәэсирен дә берничек тә сиздермәде. Бары кузгалырга вакыт җиткәнне аңлатып:

– Йә, күрдем... булды, – дип кенә куйды.

Шуннан соң алар, урам аша чыгып, йортның парадный ишегенә юнәлделәр. Карт звонокны баскач, шактый көттереп, берәү ашыкмыйча гына ишеккә килде.

– Кем ул?

– Мария Николаевна, бу мин, Гайса Мухаметович,—диде карт.

Ишек тавышсыз гына ачылды. Баштанаяк карадан киенгән озын, чандыр карчык аларны бик җитди чырай белән каршы алды. Карт түбәнчелек белән башын иде.

– Рөхсәт итегез, Мария Николаевна.

Карчык юл бирде. Карт белән Зөфәр тоташ челтәр тәрәзәле иркен коридорга уздылар.

– Мин сезгә яңа кеше алып килдем, – диде карт.

Карчык, бер сүз әйтмәстән, аларга кара клеенка белән тышланган өй ишеген ачты. Башта алгы бүлмәгә, аннары сул кулдагы ак ишектән зур гына залга уздылар. Карчык аларга кулы белән генә утырырга ишарә ясады. Кунаклар, рәхмәт әйтеп, ишек төбендәрәк торган урындыкларга утырдылар.

– Сәламәтлегегез, кәефегез ничек, Мария Николаевна? – диде карт, чын әдәп һәм кайгыртучанлык күрсәтеп.

Карчык, юка ireннәрен ачар-ачмас кына, кыймылдатып куйды:

– Рәхмәт, зарарсыз.

– Яхшы, бик яхшы. Бирсен Алла! Без картлар өчен сәламәтлек хәзер иң зур байлык бит инде... Ә Надежда Леонидовна белән Сергей Леонидович та, шәт, исән-саулардыр?.. Мин аларны күрмим.

– Рәхмәт, исән-саулар... Шәһәргә чыгып киткәннәр иде, тиздән кайтырга тиешләр.

– Бик хуп... Менә, хөрмәтле Мария Николаевна, әйткәнемчә, мин сезгә яңа кеше алып килдем. Ул да үзенә йорт эзли. Рәхим итеп, ышанып дигәндәй, кабул итегез!

– Безнең ышанмаска хакыбыз юк, – диде карчык, нидер аңлатырга теләгән коры рәсмилек белән.

– Әйе, әйе, бик дөрес. Сез беләсез, мин ни җитте кеше ияртеп йөрмим.

Шулай да карт, һавалы карчыкның соңгы сүзләреннән һәм, гомумән, бүген үзен шактый кырыс тотуыннан нидер сизенеп, шуңа бераз борчылып, Зөфәргә карап алды. Зөфәр исә, берни сизмәгәндәй, тыныч кына утырып тора иде. Хикмәт шунда, карт алып килгән кешесен, бу өйдәге күптәнге кагыйдә буенча, иң элек исем, фамилиясен, кем булуын әйтеп таныштырырга тиеш иде. Ул моны эшләмәде, чөнки Зөфәр баштан ук алай таныштыруны тыеп куйды. Соңыннан, эш барып чыгардай булса гына, үзенең кем икәнлеген әйтергә рөхсәт итте. Бу инде Зөфәрнең гадәттән тыш саклыгы иде. Ә менә карчыкның соңгы җавабы картка: «Мин бит әле сезнең кемне алып килүегезне белмим», – дигән мәгънәдә аңлашылды. Ләкин Зөфәрнең ваемсыз, тыныч кына утыруын күргәч, карт яңадан карчыкка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булды:

– Мария Николаевна, алайса Сергей Леонидович кайтканчы сез безгә йортны карый торырга рөхсәт итегез!

Карчык икеләнеп кенә иңбашын сикертеп куйды:

– Телисез икән, пожалуйста, рөхсәт!

– Әйе, әйе, күрсен, танышсын, тәртибе аның шулай инде, Мария Николаевна, – диде карт, һәм алар урыннарыннан тордылар. Зөфәр өйне иң элек тышкы яктан карап чыгарга теләвен белдерде. Өчәүләшеп ишегалдына чыктылар.

...Уртача гына зурлыкта ишегалды. Өйнең түр почмагыннан күрше коймага чаклы ук сары рәшәткә белән бүленгән. Рәшәткә эчендә куе бакча. Нәкъ каршыда, күрше ихатага арты белән, ике катлап тоташтан салынган берничә ишекле, өсте такта, асты бүрәнә озын каралы тора. Ишегалдында плитәләп ак таш җәелгән, ләкин, кеше аз йөргәнлектән булса кирәк, таш араларыннан юл-юл озын үлән бәреп чыккан.

Зөфәр, шул үләннәргә сокланыпмы, гаҗәпләнепме карый-карый, ишегалдының уртасынарак узды. Аның игътибарын шунда ук түрдәге куе бакча җәлеп итсә дә, ул аңа таба барудан юри тыелып, өйнең үзен карый башлады... Өй бу яктан шактый искергән, таушалган булып күренә иде. Хәер, өйнең төп бурасы түгел, ә аңа тоташтырып салынган озын коридорның такта стенасы һәм кухнядан чыга торган аерым болдырның баскычлары череп тузганга охшый иде. Бу, әлбәттә, тулай күренешне беркадәр боза, ләкин аңлаган кеше өчен әллә ни зур кимчелек юк монда. Иң әһәмиятлесе – өй үзе таза булсын. Һәм ул күрер күзгә чыннан да бик таза кебек иде. Цементлаган таш нигездә нык утыруы шуны күрсәтә. Аннары өй, бер урам яктан гына түгел, бөтен яктан да такта белән тышланган икән. Тик такта астындагы бүрәнәләр ничегрәктер инде? Мондый чакта берәр тактаны куптарып карау да ярый шикелле, ләкин Зөфәр менә хәзер үк ул хакта үз белдеге белән генә сүз кузгатуны килештермәде.

Йортны әйбәтләп караганнан соң, Зөфәр, ниһаять, бакчага таба атлады. Бакча, бакча!.. Күптән хыял иткән нәрсәсе түгелме соң бу аның?.. Моңарчы үзе торган өйләр тирәсендә ул бер агач та күрмәгән иде. Бала чагыннан ук табигатьне, үсемлекләрне белмичә үсте ул. Шуңа күрә дә бик тансык, бик кадерле ул аңа. Йорт алырга уйлагач та күңеле белән аның бакчалы яки, һич югы, бакча үстерерлек урнысы булуын теләгән иде. Һәм менә хәзер өйнең үзеннән дә ямьлерәк, кадерлерәк төсле булып аның алдында карт бакча күкрәп утыра.

Зөфәр ишегалдын аркылыга бүлеп узган рәшәткәнең кечкенә капкасына килде. Бик аз гына тукталып торды, аннары тәвәккәлләп капкадан эчкәре атлады. Карт белән карчык та аның артыннан иярделәр. Бу урында шуны әйтергә кирәк, алар Зөфәргә үзе теләгәнчә карап йөрергә

тулы ирек биргәннәр иде. Зөфәр үзе дә хәзергә һични турында сорашмыйча, шәхсиян нинди тәэсир алачагын белер өчен, бары үз күзе белән генә карап узарга тели иде.

...Бакча шактый зур гына икән, кимендә бер сигез сотый җир биләп тора булса кирәк. Ул өй почмагыннан башланып, арткы урамдагы йортларның бакчаларына барып терәлә. Рәшәткә капкадан кергәч тә, сулда өйнең сирень куаклары белән яртылаш капланган ике тәрәзәсе һәм шулар белән янәшә иркен генә терраса күренә. Террасадан чәчәк түтәлләренә баскыч төшә. Ә түтәлләрдән киң генә сукмак бакчаны буеннан-буена кисеп, иң түргә кадәр сузылып китә.

Зөфәр шул сукмакка чыгып басты да тирә-ягына каранып тора башлады. Ул, билгеле инде, бакчачы түгел, күп агачларны танып та җиткерми, ләкин шулай да бакчаның карт булуын, бик куерып киткәнлеген, гомумән карау җитмәгәнлеген сизмичә калмады. Монда чатлыботлы бик җәелеп үскән, яртылаш корып беткән, инде утынга гына ярарлык карт алмагачлар да бар иде, монда, әнә түр койма буенда, тәмам куерып, корыган ботаклары киселмичә тоташ чытырманлыкка әверелгән чиялек тә бар иде, урта бер җирдәге ачыклыкка утыртылган карлыган, крыжовник куаклары да күптән бер-берсенә тоташып, юанаеп, кара чыбыкка әйләнеп беткәннәр иде. Җитмәсә, бер почмакта карт юкә әллә никадәр җирне күләгәләп тора, ул гына да түгел, җимеш бакчасына аяк бастырырга ярамаган мәрҗән агачы да каралтыларга якынрак рәшәткә буенда рәхәтләнеп үсеп утыра иде.

Чын бакчачы килсә, ул, әлбәттә, бу бакчаның яртысын утап ташлаячак, чөнки шунсыз җимеш ашап булмаячак. Ләкин Зөфәр моны белми иде әле... Ул бары бу карт бакчаның шигъриятен генә күрде. Шушы искергән, картайган, ташландык хәлгә килгән тын бакчадан аңа ничектер борынгы дворян интеллигентының инде мәңге кире кайтмас тормышы аңкыгандай булды. Беркадәр моңсу сагыш белән шул тормышның югалуын кызганып куйды. Әгәр дә хуҗа була калса, ул үзе бу йортка, бу бакчага нинди тормыш алып киләчәк – шул хакта уйлап алды.

Моңарчы карар шәүлә төсле сүзсез генә ияреп йөргән карчык, аның бу минуттагы уй-кичерешләрен сизгәндәй, ниһаять, телгә килде:

– Сезне, кем дим, бакчаның хәзерге күренеше артык гаҗәпләндермәсен. Сугыш вакытында без өлкән кызым белән икәү генә калдык. Карарга көчебез җитмәде, хәер, карауның файдасы да юк иде. Бездә эвакуированныйлар тордылар... Югыйсә бакчабыз элек бик матур, бик тәртипле иде. Файдасын бик күрә идек. Хәзер дә әле уңган хуҗа, бераз тәртипкә китерсә, бу бакчадан зур доход алачак.

Зөфәр башын кагып:

– Шулайдыр инде, шулайдыр! – дип кенә куйды.

Ошамады аңа интеллигент карчыкның торгашларча әйткән соңгы сүзләре... Аныңча, Зөфәрне бары доход кына кызыксындыруы мөмкин, янәсе. Гафу итегез, ул әле доходтан башка кайбер бүтән нәрсә, мәсәлән, матурлык турында да хыяллана ала. Нәкъ менә шундыйрак хыял хәзер генә аның күңеленнән кичеп үтте түгелме соң? Юк, җиләк-җимеш сатып «доход» алу турында түгел иде бу хыял, зуррак иде ул, канатлырак иде...

Бакчаны күздән кичергәч, алар терраса аша яңадан өйгә керделәр. Зөфәр терраса алдында зур түтәл булып, тәмам ачылып, янып утырган ал, кызыл, зәңгәр, сары чәчәкләргә карап кына узды. Табигый, аның бу үзенә һич таныш булмаган матур чәчәкләр янында тукталып, һич югы исемнәрен генә сорап беләсе килсә дә, карчык, бу кеше чәчәк тә танымый икән әле, дип уйламасын өчен, дәшмәде.

...Ике якка ачылмалы пыяла ишектән зур гына бүлмәгә кергәч тә карчык үзе өйнең эче белән таныштыра башлады. Бу беренче бүлмәне ул столовая (аш бүлмәсе) дип атады. Монда бераз тукталганнан соң, каршыдагы ишекне ачып, икенче кечерәк бүлмәне күрсәтте. Бусы элек балалар бүлмәсе булган икән. Моннан кире чыгып, сул ишектән кухняга алып керде. Кухня зур, иркен, тик стена-түшәме бик каралган, – ахрысы, күптән аңа агарту-чистарту тимәгән. Шунда ук тагын бер кечкенә бүлмәгә күз салдылар. Бусы карчык горничная (асрау кыз) бүлмәсе дип атады.

Кухнядан прихожийга чыгып, каршы ишектән зур залга уздылар. Монда да уң яклап ике ишек тора; берсе —адвокатның элекке кабинетына, икенчесе – йокы бүлмәсенә алып керә. Аларны да карап чыктылар.

Шулай итеп, бу өйдә, кухнядан башка, алты бүлмә бар икән. Аларның тулы мәйданы, карчык дөрес әйтсә, йөз унике квадрат метрга җитә икән. Сарай димәслек тә түгел! Хәзерге шартлар күзлегеннән караганда бу инде күп, бик күп! Зөфәр чынлап торып гаҗәпләнде: ничек итеп адвокаттан калган дүрт кешелек гаилә шушы кадәр мәйданны үзләре генә биләп торганнар? Берәү дә тимәгән үзләренә, берәү дә кысрыкламаган – күрәсең, бай адвокат совет өчен дә файдалы кеше булгандыр инде...

Зөфәр, карап кына узган арада, өйнең эчтән ни хәлдә сакланган булуына да игътибар итәргә тырышты. Шик юк, өй эчтән дә шартына җиткереп, нык итеп, пөхтәләп эшләнгән иде. Идәне – имән паркет, түшәме – шкатурлы, стеналары – майлы буяу белән буялган, тәрәзә-ишекләре – бөп-бөтен, башта ничек утыртылган булсалар, шул килеш торалар. Тагын нәрсә? Зөфәр, күпме каранса да, өйнең бер генә почмагында да дым тарткан, каралган җирен күрмәде. Дөрес, бөтен бүлмәләрнең дә түшәм-стеналары бик керләнгән инде, ләкин буясын буяп, агартасын агартып җибәрсәң, өй эче яңадан көлеп торачак!

Карап йөрүне тәмамлагач, өчәүләшеп залдагы элекке урыннарына чыгып утырдылар. Шактый гына вакыт үтеп китсә дә, төп сөйләшер кеше – карчыкның улы ни өчендер һаман кайтып җитә алмады. Ә карчык утыргач та шуны белдерде:

– Мин сезгә әйтергә тиешмен ки, сатып алу шартлары турында бары Сергей Леонидовичның үзе белән сөйләшәсез!

Хәер, Зөфәр өчен сүзне хәзер үк шартлардан башлауның кирәге дә юк иде. Аңа, моннан чыгып, Гайсә карт белән киңәшергә һәм үзалдына әйбәтләп уйларга кирәк иде әле. Тик кайбер мәсьәләләрне ачыклар өчен генә аның карчыкка берничә сорау бирәсе килде. Шул теләген белдереп, рөхсәт алгач, ул сораша башлады:

– Минем белүемчә, бу – үзегез салдырган йорт, шулаймы?

– Әйе, шулай.

– Кайчан салдырган идегез?

– Мәрхүм ирем моны 1908 елны салдырды.

– Күптән икән инде...

– Әйе, тиздән кырык ел тула. Шушында гомер иттек, шушында картайдык, – диде карчык, аз гына көрсенү сиздергән горурлык белән.

– Үз ояңда тыныч картаю күңелле эштер инде ул,—диде Зөфәр, карчыкның сүзен куәтләп һәм көлемсерәп өстәде: – Ләкин йорт та, сезнең белән бергә, шактый ук «картайганга» охшый.

– Әйе, дөньяда картаймаган, тузмаган берни дә юк,—диде карчык, җитди тынычлык саклап. – Әмма сез белергә тиешсез, һәрнәрсәнең үз срогы була бит. Мәсәлән, бу йорт сезнең үзегезгә генә түгел, балаларыгызга да җитәчәк әле.

– Шулаймы?

– Күрдегез ич.

– Әйе, күрдек. Ләкин без әле сезне борчырга мәҗбүр булырбыз – тагын килербез, тагын карарбыз. Ә хәзер минем шуны беләсем килә: йортка төп варис кем?

– Төп варис мин, әлбәттә. Ләкин балаларымның да законлы өлешләре бар бу йортта.

– Алар барысы да сатарга ризалыкларын бирәләрме?.. Сез гафу итегез, бу минем өчен бик әһәмиятле.

– Аңлыйм, – диде карчык. – Тыныч булыгыз, без бу эшне үзара килешеп эшлибез. Соңыннан сезгә претензия белән килүче булмаячак.

– Яхшы, бик яхшы, – диде Зөфәр, башын кагып...—Рәхмәт, мин канәгать. Тик менә яшь хуҗаның үзен күрә алмадык. Минем дә вакытым чикле. Шуңа күрә мин сездән үтенер идем: йортның бәясен, сату шартларын менә Гайсә Мухаметович аша миңа тапшырсагыз иде. Икенче

очрашканда шуны алдан белеп килү безнең сөйләшүләрне ансатлаштырыр һәм тизләтер дип уйлыйм.

– Пожалуйста, телисез икән, алай да мөмкин. Гайса Мухаметович безнең өчен дә ят кеше түгел...

– Баш өсте, баш өсте, мин һәр ике якның да хезмәтен үтәргә, ышанычын акларга әзермен, – диде карт, баш иеп һәм кулын күкрәгенә куеп. Элекке доверенный өчен мондый зур эшкә катнашу үзенә күрә бер бәхет тә һәм горурлык та иде.

Зөфәр, урыныннан тормыйча гына, түбәнчелек белән:

– Ә хәзер безгә кузгалырга рөхсәт итегез! – диде.

Карчык аңа: «Бу нинди әдәп иясе?» – дигәндәй, шактый гаҗәпләнеп карады һәм беренче тапкыр юка иреннәре белән генә елмайгандай итте.

– Нишлим, сезне артык тотарга хакым юк.

Зөфәр башын иде.

– Хушыгыз!

– Хушыгыз!

Карчык аларны парадный ишегенә чаклы озата чыкты һәм артларыннан таза ишекнең тимер келәсен шылдырып калды.

Карт белән Зөфәр, урамга чыккач, азрак сулга киттеләр дә, урам аша үтеп, каршыдан йортка тагын бераз карап тордылар. Аннары акрын гына кузгалып, үз юллары белән атладылар. Карт таягы белән шакылдап, Зөфәр исә башын иебрәк, үзалдына уйланып, алар шактый гына ара сөйләшмичә бардылар. Тик берәр квартал чамасы киткәч кенә Зөфәр әйтеп куйды:

– Бу йорт белән мин нишләрмен?

Карт гаҗәпләнеп аңа карады – Зөфәрнең сүзләре: «Нигә кирәк ул миңа», – дигән мәгънәдәрәк ишетелде аңа.

– Моны син әйтәсеңме, Зөфәр туган? – диде ул, туктала биреп.

– Әйе, мин әйтәм, Гайсә абзый... Чынлап та, нишләрмен мин ул йорт белән?

– Соң, алай булгач, ни өчен әле без шәһәр бетереп йорт эзләп йөрдек? Кирәккә күрәдер бит?

– Әйе, кирәккә күрә, – диде Зөфәр, һаман уйланып барган килеш, ашыкмыйча гына. – Ләкин мондый кеше күзенә бәрелеп торган бай, зур йорт эзләмәгән идем мин. Кечерәк, гадирәк булсын, дигән идем.

Карт җиңел сулап куйды.

– Шул гынамы хәсрәтең?.. Юкка борчыласың, туган! Насыйп булып ала калсаң, бер дә үзеңнән артмас әле.

– Ала калсаң!.. Алуын алырсың, ә алгач нишләрсең? Бу заманда андый йорт хуҗасы булу – уен эш түгел ул... Керердән элек, чыгуыңны уйларга кирәк.

– Ул кадәресен үзең беләсең инде, – диде карт, килешкән сыман; аңа ничек тә йон уңаена сыпырырга кирәк иде: – Кара, кара, үкенечкә булмасын. Әмма, миңа калса, кечкенә йорт хуҗасы булдың ни, зурныкы булдың ни – барыбер, мужик әйтмешли, ике чабата бер кием. Аннары, нишләп әле бу йорт синең күзеңә ул хәтле бик зур булып күренде? Алты бүлмәле булгангамы? Һи, Зөфәр туган, элек заманда моның кебек йортта урта кул чиновниклар тора иде. Хәзер генә бит ул бер бүлмәгә алты кешене тыгалар...

– Менә шуңа күрә дә Зөфәр Сабитовның берүзенә генә алты бүлмәле йорт бик күп булыр шул, Гайсә абзый!

– Нигә алай дисең? Син берүзең генә түгел ләбаса! Солдаттан кайтасы абыең бар, сеңелең җитеп килә, үзеңнең өйләнәсең бар. Курыкма, бер метры да артып калмас.

– Метрын кеше башына бүлеп тормаслар, – диде Зөфәр, көрсенеп. – Сабитов әнә нинди йорт алган, каян килгән бай ул, дип шауларлар... Беләсең хәзерге кешеләрне, барысын да бик тиз күрәләр.

Бераз вакыт сөйләшмичә бардылар. Карт Зөфәрнең ни өчен, нәрсә уйлап борчылуын, әлбәттә, аңлый иде. Сәүдә-тәэминат кешесе бит ул. Капкынга эләгүдән курыккан төлке кебек гел генә тирә-ягына ялт-йолт каранырга, шомланырга, уяу булырга мәҗбүр. Киләчәкне алар беркайчан да хәтәр-хәвефсез генә күз алларына китермиләр, ахрысы... Һәм Зөфәрнең дә менә болай икеләнеп маташуы картның эчен чынлап пошыра иде. Йөреп-йөреп тә бу эш барып чыкмаса, ул сакал сыпырып калачак! Хәлбуки аның да үзенә күрә саклап йөрткән өмете бар: шушындый зур алыш-бирешне уңышлы төгәлләүдә катнашлык күрсәтеп, мул гына «комиссионный» каерып булмасмы дип хыяллана ул. Бары шуның өчен генә авыру аякларын көчкә сөйрәп, шәһәр таптап йөри бит... Ичмасам, карт көнендә үзенең дә, карчыгының да өс-башын рәтләп, ашау-эчүләрен бераз юнәйтеп калыр иде. Бәлкем, эчүдән дә тыелыр иде. Хәерче бер тиеннәре эчүгә китә бит ул, ишлерәк акчаны һәрвакытта саклыйсы килә, игелеген күрәсе килә. Сыналган нәрсә инде ул. Бай чагында авызына да алмады бит! Ах, бу хәерчелеккә калган көн, аракы түгел, агу эчәрсең!

Юк, Ходай үзе генә моның кебек өметле эшне өзә күрмәсен инде... Бу акыллы башның күңеленә тәшвиш салмасын иде дә аңа тәвәккәллек бирсен иде!

Шулай эченнән генә борчылып һәм уйланып алганнан соң, ул яңадан сак кына сүз башлады:

– Алла ни кушса, шул булыр, Зөфәр туган. Син шәригатькә яки законга сыймый торган эш эшләргә җыенмыйсың. Хәлең җитеп, тәвәккәллисең икән, берәү дә гаеп итмәс. Сатып торалар, алып торалар – тыйган кеше юк. Изге эш ул. Тик син миңа шуны әйт: йортны ошаттыңмы соң?

Зөфәр җавап бирергә ашыкмады. Картның ни өчен болай аны акрын гына көйләп-җайлап маташуын чамалый иде ул һәм менә шуңа ничектер каршы торасы килә иде. Хәер, карттан яшеренеп торуның мәгънәсе юк, шуңа күрә, бераз уйланган булып, ахырда, дөресен генә әйтеп бирде:

– Әйе, Гайсә абзый, йорт миңа бик ошады. Карап торырга, һичшиксез, таза, чибәр йорт. Шуннан яхшысын, бәлки, табып та булмас. Ләкин, Гайсә абзый, син карт, тәҗрибәле кеше, миңа саф чынын гына әйт әле: ышанып алырлык йортмы ул, тыштан гына шулай күренмиме, алданмабызмы?

Карт башта тамак кыргалап куйды, аннары үзенең чынлап та объектив, гадел икәнлеген күрсәтергә теләп, салмак кына сүзен башлады:

– Алла шаһит, Зөфәр туган, мин сиңа әйтсәм бары саф дөресен генә әйтәчәкмен. Бер бөртек тә шигең булмасын. Әйе, бик хаклы сорыйсың: тыштан чибәр, эчтән черек түгелме? Кайчакта шулай да була бит ул... Ләкин, Зөфәр туганым, күңелең тыныч булсын: бу – һич андый йорт түгел, менә сиңа чал чәчем!.. Күптән беләм мин аны, карчыкның иске-москыларын Сорочийга күп ташыдым, ә сатылу хәбәрен ишеткәч, эчен генә түгел, астын-өстен тикшереп, карап чыктым. Ышанасыңмы, егерме дүрт вершоклы шыңгырдап торган нараттан ике аршын тирәнлектәге таш фундамент өстенә салынган йорт ул! Ник бер чери башлаган яки корт төшкән җире булсын менә! Идән, түшәм такталары тора-тора какланып беткән, кадак та керерлек түгел. Ә идән астындагы базы, бәдрәф чокыры цементлап эшләнгән, белдеңме?.. Гомерлек инде, гомерлек! Ходай кушып, алырга язсын да, игелеген күреп торырга насыйп булсын!

Әлбәттә, картның бу әйткәннәре Зөфәр өчен көтелмәгән сүзләр түгел иде. Ул үзе дә йортның таза, яхшы икәнлегенә ышанып өлгергән иде инде, әмма шулай да карт кимчелекләре турында да әйтсә, аңа бәлки җиңелрәк булыр иде. Югыйсә йорт аның күңелен һәм хыялын бик тиз һәм бик нык били башлады. Ә ул болай бик ансат кына шуның колы булып китәргә теләми иде. Уйларга, айнык акыл һәм тыныч җан белән бик нык уйларга кирәк иде әле аңа...

Алар арасында бүтән сүз булмады. Чехов базарына җиткәч, карт Суконныйга төшеп китте, Зөфәр исә туры гына шәһәр үзәгенә таба китеп барды.

...Берничә көн узды. Шушы кыска гына вакыт эчендә Зөфәр каты бер сынау кичерде. Нәтиҗәсе шул: бер генә көн, бер генә сәгать тә ул Зинин урамындагы сарыга буялган, кызыл түбәле йорт турында уйламыйча тора алмый башлады. Хәер, бүтәнчә булуы мөмкин дә түгел иде. Барыбер ул йорт сатып алырга тиеш, бу аның өчен күптән хәл ителгән мәсьәлә, ә инде заманнан өркү, курку-сагаюлар, никадәр генә җитди сәбәп булмасын, аны хәзер тыя да, туктата да алмый иде.

Адвокат йортын ул әнисе Таибә абыстай белән дә бергә барып карады, тагын берничә ышанычлы кешесен илтеп, аларга да күрсәтте, барысы да йортны бик яраттылар, берсе дә Зөфәрнең гайрәтен чигерерлек нәрсә әйтмәде. Һәм йорт Зөфәрне, ниһаять, башы-аягы белән үзенә әсир итте. Хыялы аның котырып эшли башлады. Ул инде аңа хуҗа, ул инде аны яңадан өр-яңа хәленә китергән, эчен шәп җиһазлар белән тутырган һәм шунда рәхәтләнеп торып ята. Салмак йөрешле мәһабәт дивар сәгатедәй әйбәт итеп көйләнгән тук, тыныч тормыш ашыкмыйча гына ага да ага... Һәр көнне иртән бик пөхтә киенеп, Зөфәр Сабитов эшкә китә, туры гына эштән кайта, бакчада казына, террасада, үз җиләгеннән кайнаткан варенье белән, тәмләп кенә чәй эчә, газеталар караштыра, аннары иркен, чиста бүлмәдә рәхәтләнеп ял итә. Койма биек, капка таза, ишегалдында озын тимерчыбыкны шаулатып усал эт йөри, һәм хуҗаның дөньясында гаме юк, дөньяның аңарда эше юк! Менә бу хөрлек һәм бәйсезлек, ичмасам!

...Озак та үтми сөйләшүләр башланды. Гайсә карт йортның бәясен әйтә килде. Ул китергән бәя күпләрнең кайнар хыялын сүрелдерерлек, гайрәтен чигерерлек иде: Ушаковлар йортка дүрт йөз мең сорыйлар! Гади хезмәткәрнең төшенә дә кермәгән бу сумма Зөфәрне, башта хәйран калдырса да, чынлап торып куркыта алмады. Җаны теләгән – елан ите ашаган, ди, чынлап тәвәккәлләгәндә Зөфәрнең моңа көче җитәрлек иде. Шулай да ул хуҗалар белән аяк терәп сатулашырга булды.

Ләкин Гайсә карт мактап йөдәткән «иске заман интеллигентлары» сату-алу эшендә хәзерге заманның эт каешына әйләнгән коммерсантыннан бер дә ким булып чыкмадылар. Карчык, карчыктан да битәр аның военврач улы, йортларының нинди мөлкәт булуын, хәзерге акчаның чын бәясен белеп, әйткән бәяләрендә бик каты тордылар. Әлбәттә, тал токан җирдән генә сынмый, шуны аңлап, хуҗалар сөйләшкән саен биш-ун меңләп кенә төштеләр, ләкин Зөфәр әйткәнгә якын да килмәделәр, Зөфәр исә башта ике йөз мең бирде, аннары акрынлап ике йөз илле меңгә менде, ә хуҗалар өч ярымнан бер карыш та төшмәс булдылар. Шулай итеп, килешер өчен ара бик ерак иде әле.

Ә көннәрнең берендә Гайсә карт, тыны бетеп, Зөфәргә яңа хәбәр алып килде: Себердән кайткан кемнәрдер йортка «ике дә сиксәнне биргәннәр», имеш. Карт моның дөреслегенә ант

итеп ышандырды. Ул гына да түгел: «Ике дә сиксәнне биргәч, өчкә җиткерүләре көн кебек ачык, эш менә-менә очланырга тора!» – дип, бик нык кисәтеп әйтте... Хәзер инде Зөфәр йә чигенергә, йә күз йомып тәвәккәлләргә тиеш иде. Һәм мөмкин кадәр тизрәк.

**VIII**

Икенче көнне Зөфәр, алдан хәбәрләшү буенча, карчыкның улы военврач Ушаков Сергей Леонидович белән Хәмит дустының бүлмәсендә икәүдән-икәү генә очрашты. Бүтәннәр катнашыннан башка гына, күзгә-күз сөйләшеп, Зөфәр эшне, ниһаять, нәтиҗәле ахырына җиткерергә булды. Кара-каршы утырышкач, сүзне дә ул җитди, эшлекле төстә, әмма мөмкин кадәр гади, тәкәллефсез булырга тырышып башлады:

– Сергей Леонидович, биредә икәүдән-икәү генә очрашуның максатын сез дә, шаять, аңлыйсыздыр. Минемчә, безгә билгеле бер нәтиҗәгә килергә вакыттыр инде... Әйдәгез, чын джентльменнарча, ачык һәм туры гына сөйләшик.

– Рәхим итегез! – диде Ушаков, салкын әдәп белән.

Өр-яңа кительдән, иңбашына ак укадан тар гына погоннар таккан бу төскә шактый чибәр, ләкин озынча ак чыраенда һәм соры салкын күзләрендә әллә нинди генә бер кырыс тәкәбберлек сизелеп торган яшь кеше үзен гаҗәп һавалы һәм бәйсез тотарга ярата иде. Гомумән, бу Ушаковлар дигән халыкка ни сәбәптәндер әнә шундый чамасыз горурлык, йомыклык һәм тискәрелек бик хас иде. Зөфәр баштарак, бу миңа карата гына шулайдыр инде, үзләренчә мине сәүдә күсесенә санап, кимсетеп карауларыдыр, дип борчылып азапланды. Хәзер исә ул моңа игътибар итеп тормаска булды.

– Минем саф дөресен генә беләсем килә, Сергей Леонидович, – диде Зөфәр, тавышын-ниен бер дә үзгәртмичә генә. – Әйтегез әле, йортыгыз өчен соңгы мәртәбә сезгә күпме бирделәр?

– Моның ни әһәмияте бар? Сез үз бәягезне бирегез,—диде Ушаков.

– Бар, Сергей Леонидович! Әгәр без ачык сөйләшсәк, нәтиҗәгә тизрәк ирешербез.

– Яхшы! – диде Ушаков, аз гына дәшми торганнан соң. – Безгә ике йөз сиксән меңне бирделәр.

Зөфәр, урындык аркасына авыша төшеп, бертын аңа туп-туры карап торды. Ул: «Дөресме бу?» – дип кайтарып сорарга теләмәде, ул мондый зур эштә Ушаковның гадел, туры булуына бер шиксез ышанырга теләде. Шулай яхшырак. Бигрәк тә, хуҗаның әйткәне Гайсә карт китергән хәбәр белән бер булып чыкты. Шуны да исәпкә алып һәм үзе врач, үзе хәрби кешенең алдашу кебек түбәнлектән ерак торырга тиешлеген уйлап, Зөфәр һич икеләнмичә Ушаковка, ниһаять, әйтте:

– Рәхмәт, дөрес сүзегез өчен, Сергей Леонидович! Гәрчә сез әйткән бәһа гадәттән тыш зур булса да, мин ышанырга мәҗбүрмен... Инде рөхсәт итегез миңа да соңгы сүземне әйтергә: яшермим, йортыгыз миңа ошады, мин чын алу теләге белән карап-сатулашып йөрдем һәм менә хәзер арага килеп кергән икенче берәүләргә аның китеп баруын теләмәс идем. Кыскасы, Сергей Леонидович, сезгә актык сүзем шул: йортыгызга миннән төгәл өч йөз мең!.. Йә, ни дисез? Килештекме?

Ушаков, акрын гына, ләкин ничектер икеләнебрәк башын селекте. Аның шушы икеләнүен сизеп калу Зөфәрне бераз өметләндереп җибәрде.

– Ягез, йә, хөрмәтле Сергей Леонидович, баш селкеп тормагыз. Ышаныгыз, миннән дә артыгын бирүче булмас сезгә... Килешик!

Ушаков тагын башын селекте:

– Юк, булмый!

Зөфәр кашларын җыера төшеп аңа карады:

– Ә ничек була соң?

– Без үзебезнекен әйттек, – диде Ушаков, – өч йөз илле меңнән төшмибез.

– Мин моны күптән ишеттем, – диде Зөфәр, авыз кырые белән генә елмаеп. – Мин сездән яңа сүз көтәм, Сергей Леонидович!

– Бәя мәсьәләсендә нинди яңа сүз булырга мөмкин? Бәя һәрвакытта бер, тәгаен була ул.

Зөфәр, бу кешенең тискәрелегенә ачуы килә башласа да, тынычлыгын һәм йомшак мөгамәләсен сакларга тырышып, аңа таба иелә төште:

– Менә нәрсә, хөрмәтле Сергей Леонидович, хәтерегез калмасын, әмма сату-алу эшенең тәртипләрен мин сезгә караганда яхшырак беләм дип уйлыйм...

– Әлбәттә. Моңа мин ышанам! – диде Ушаков, ниндидер ямьсез кинаяне сиздергәндәй, башын чөя биреп.

– Юк, сез башта тыңлагыз әле... Һәрбер сату-алу эше билгеле бер килешүгә ирешү белән тәмамлана ул. Ә бу нәрсә сатучының гына түгел, алучының да теләгеннән тора. Шулай булгач, бәянең дә үзгәрмичә хәле юк. Тал да бит тоткан җирдән генә сынмый. Берәү арттыра, берәү төшә – бары шулай гына килешүгә ирешеп була. Йә, дөрес түгелме?

– Бәхәсләшмим, ихтимал, шулайдыр... Ләкин сез әйткән бу кагыйдә минем өчен закон түгел. Гафу итегез! Йортка без дүрт кеше хуҗа, бәя мәсьәләсендә үзара сөйләшеп куйган чигебез бар, төшәсен төштек, артыгы булмый!

– Димәк, сез алдан билгеләп куйган шул «чиккә» җиткерсәләр генә йортыгызны сатасыз инде, җиткермәсәләр —сатмыйсыз... Шулай аңларга кирәкме сезнең сүзегезне? – диде Зөфәр, хәйләкәр бер көлү белән Ушаковка туп-туры карап.

Ушаков көтелмәгән бу сораудан бераз аптырабрак калды. Аннары, җавап таба алмагач, аптыравын яшерер өчен генә әйтеп куйды:

– Без сата алуыбызга ышанабыз.

– Ышанырга була... Ләкин шулай да сез өмет иткәнне бирмәсәләр, нишлисез? Сатмыйсыз һәм Казаннан китмисез, шулаймы? Әгәр шулай икән, ул чагында сез хаклы – сөйләшеп, сатулашып торуның һич хаҗәте юк, йортыгызга үзегез генә хуҗа буласыз да каласыз.

– Ни өчен алай дисез?

– Ни өченме? Чөнки берәү дә сез көтеп яткан «чиккә» барып җитмәячәк. Юк, булмаячак ул!

Ниһаять, Зөфәрдә коммерсант усаллыгы һәм мәкерлеге уянды. Сүзләрен дә ул, үзенең һичшиксез хаклы булуына ышангандай, көлемсерәп кенә, әмма каты итеп, өзеп әйтә башлады. Шуның белән бергә тыштан һаман да бик әдәпле булып калды. Дөресен әйтергә кирәк, болай сөйләшү тәҗрибәсез Ушаковка тәэсир итмичә калмады. Ничектер, үзе дә сизмәстән, ул һавалы тискәрелеген һәм ныклыгын акрынлап кына җуя башлады. Шулай да әле аның һич бирешәсе килми иде:

– Сез бүтәннәр өчен сөйләмәгез, – диде ул, элекке кырыс тәкәбберлеген сакларга тырышып. – Бүтәннәр, бәлки, җиткереп кенә түгел, арттырып та бирерләр.

– Бирмәячәкләр! Менә ике кулымның берсен сайлап кисегез – бирмәячәкләр!.. Йортыгызның күренеп торган кырык-илле мең сумлык ремонты бар. Шулай булгач, нинди юләр аңа шулкадәр акча салсын, ди? Акчаны да бит түтәлдә үстермиләр... Аннары шуны да исегездә тотыгыз: сезнең йорт бер хуҗа өчен бик зур ул, ә ике хуҗага бүләрлек түгел. Менә шунлыктан карап йөрүчеләр күп булса да, тәвәккәлләп алырга торучы юк диярлек...

– Ник булмасын, бар.

– Кем? Теге Себердән кайткан кешеләрме? Ләкин алар да бит әле мин биргәнне бирергә тормыйлар.

– Алар бирәчәк...

– Их, Сергей Леонидович, гаҗәп беркатлы кеше икәнсез сез... Неужели, аларның хәйләсен сизмисез, уйлап карагыз әле. Ни өчен алар ике йөз сиксән меңдә туктаганнар? Чөнки сезнең дә ташлама ясавыгызны көтәләр. Сез төшмичә торып, алар арттырмаячаклар. Ихтимал, алар да мин биргән өч йөз меңгә чаклы акрынлап менәрләр, ләкин бу аларның «түшәме»

булачак. Егерме мең ул —сатулашыр өчен калдырган запаслары, бу минем өчен көн кебек ачык. Сез дә шуны бик яхшы белеп торыгыз.

Ушаков моңа каршы бер сүз дә әйтә алмады. Ул ачык бер гаҗәпләнү һәм кызыксыну белән Зөфәргә карап тора башлады. Бу караштa ихтыярсыздан Зөфәрнең шундый оста, ышандырырлык итеп фикер йөртүенә соклану да чагыла иде кебек... Зөфәр үзе дә, моны яхшы сизеп, беркадәр вакыт дәшмичә тыныч кына утырды. Аннары акрын-сабыр гына яңадан сүзгә кереште:

– Менә шулай, хөрмәтле Сергей Леонидович, аңлаштык шикелле, инде хәзер сүзне түгәрәкләсәк тә ярый торгандыр. Һәрхәлдә, мин әйтәсемне сезгә бик туры һәм ачык итеп әйттем... Ышаныгыз, максатым минем бернинди ялган-хәйләсез, иң гадел рәвештә сезнең белән килешү иде. Мөмкинме шундый килешү – хәзер бөтен эш сездән тора.

– Ни өчен миннән тора? – диде Ушаков, гаҗәпләнгән булып.

– Әйе, бары тик сездән тора, – диде Зөфәр, катгый рәвештә. – Соңгы сүз сезнеке. Ташлама ясасагыз, без, ихтимал, килешә алырбыз. Кабатлап әйтәм, килешә алырбыз!.. Юк икән, без аерылышабыз, һәм яңадан очрашу-сөйләшүләр булмаячак. Тик сез шуны белегез: алам дип дәртләнеп торган кешене ычкындыру һәрвакыт үкенечкә була ул.

Ниһаять, Ушаков Зөфәрнең тимер кулын чынлап торып сизде: кара син, әдәпле, сабыр гына сөйләшкән булып, ничек рәхимсез рәвештә акрын гына кыса белә ул! Гаҗәп, кайдан килгән, нинди кеше соң бу?.. Ушаков хәтта кайчандыр әтисе сөйли торган борынгы хәйләкәр астыртын купецларның нәкъ берсен ап-ачык күргәндәй булды. Ләкин безнең заманда кайдан гына мондый кеше килеп чыга, ничек итеп хәзерге шартларда яши ала ул, җитмәсә, менә ничә йөз мең акча түләп, аларның, бөтен шәһәргә билгеле Ушаковларның, йортын сатып алырга әзер тора?! Юк, чынлап та әллә нәрсә бу! Сугыш үтте, кешеләр дүрт ел буена кан, үлем эчендә йөрделәр, ә менә монда, аның каршында, шуларның берсен дә күрмәгән тук, таза коммерсант утыра!

Ушаковта кинәт Зөфәргә карата ихтыярсыздан тирән нәфрәт-ачу күтәрелә башлады, ләкин ул бу тойгыны ничек тә басарга тырышты. Моменты андый түгел. Язмыш кушуы буенча ул хәзерге минутта – йорт сатучы, ә бу кеше – сатып алучы, һәм сүз дә бик конкрет мөһим нәрсә турында бара. Димәк, шул хакта гына уйларга да кирәк. Ә ныклап уйлар өчен сәбәп җитәрлек. Беренчедән, Зөфәрнең көчле дәлилләре аңа шактый нык тәэсир итте, икенчедән, Зөфәр кебек килешергә бик теләп торучы, хәзергә аңардан да югарырак бәя бирүче чынлап та юк иде. Теге кешеләргә күпме ышанып торырга мөмкин, алардан өмет иткәнне ишетеп булырмы-юкмы –

хәзергә әле караңгы, билгесез. Менә шуларның барысын да ул тиз генә уйлап алды. Нишләргә? Әллә форсаттан файдаланырга микән?

Ушаков Зөфәргә күтәрелеп карады һәм аның тыныч кына, хәтта «ихтыярыгыз!» дигән төсле битараф бер кыяфәттә утыруын күргәч, ничектер, үзеннән-үзе тәгаен карарга килде.

– Беләсезме, кем, иптәш Сабитов, – диде ул, Зөфәргә туры карамаска тырышып, – мин сезнең дәлилләрегезне игътибар белән тыңладым. Аларның кайберләрен исәпкә алырга була, ләкин кайберләре белән һич килешеп булмый. Мәсәлән, сез, йортка без сораган бәяне бирәү дә бирмәс, дип ышандырырга тырыштыгыз. Мин моның белән килешә алмыйм, әлбәттә. Әгәр вакытым иркен булса, мин аны дүрт йөз меңнән дә кимгә сатмас идем, чөнки безнең йорт ул хакка гына торырлык. Ләкин, кызганычка каршы, бердән, минем вакытым чикле; икенчедән, сезнең бер дәлилегез белән килешмичә булдыра алмыйм: әйе, килешер өчен сатучы тарафыннан да бераз ташлама кирәк. Менә шуңа күрә генә мин, гәрчә туганнар ризалыгыннан башка булса да, бары сезнең белән килешергә теләп, беркадәр ташлама ясауны мөмкин дип саныйм. Кыскасы, минем соңгы сүзем шул: өч йөз утыз мең! Калганы, сезнең ихтыярыгыз!

Зөфәр җәелеп бер елмайды:

– Менә бу миңа ошый, Сергей Леонидович! Бу, ичмасам, чын егетләрчә эш итү! Димәк, без килешә алабыз. Ләкин минем тагын бер кечкенә үтенечем бар: әйдәгез, гадел булсын өчен, без илле меңне нәкъ уртага бүлик. Сез егерме биш меңгә төшегез, мин егерме биш меңгә арттырам, һәм без кулларны сугабыз! Ышаныгыз, өч йөз егерме биш меңне биргәч, миңа тагын биш меңне өстәү берни түгел. Сез дә шулай ук әллә ни югалтмыйсыз. Кабатлап әйтәм, мин моны бары гаделлек өчен генә сорыйм! Килештекме – һәм ул йомшак ак кулын сузды.

Ушаков, аз гына икеләнеп торды да, тәвәккәлләп башын какты:

– Риза! – һәм бармак очлары белән генә Зөфәрнең учына сугып алды.

...Нәкъ шул минутта бүлмә хуҗасы Хәмит кайтып керде. Ул боларны каршы алгач та, юри сылтау табып, чыгып киткән булган иде; инде менә Зөфәргә нәкъ кирәк чакта гына, ишек артында көтеп кенә торгандай, килде дә керде.

Керү белән ул:

– Йә, ничек, килештегезме? – дип сорады.

– Килештек! – диде Зөфәр, җиңелчә генә бер сулап.

– Котлыйм, котлыйм алайса! – диде Хәмит, кулларын уа-уа. – Бик әйбәт, бик изге эш эшләгәнсез! Хәере белән... Мондый чакта шампанский күтәрәләр шикелле. Ә, иптәш военврач?

Ушаков, бу елгыр кешенең кем икәнлеген тәгаен белмәгәнгә һәм аның кисәк кенә килеп керүен дә, ни өчен болай дәртләнеп шатлануын да аңлап җитмәгәнгә күрә, сагаеп кына җавап бирде:

– Белмим шул...

Зөфәр, моны сизеп, Хәмиткә сабыр итеп торырга кушты һәм Ушаковка мөрәҗәгать итте:

– Сергей Леонидович, безгә үзенең бүлмәсендә иркенләп сөйләшергә түбәнчелек белән рөхсәт иткән бу иптәш, Хәмит Нуриевич, минем бик якын дустым. Аңардан яшерен бер эшем дә юк... Сез дә, миңа ышанган шикелле үк, аңа һич икеләнмичә ышана аласыз.

– Яхшы, – дип кенә куйды Ушаков, баш кагып.

– Хәзер исә безгә, – дип, сүзен дәвам итте Зөфәр,—менә хөрмәтле хуҗа алдында, сөйләшүне тәмамларга кирәк булыр. Дөресрәге, безнең килешүне беркадәр рәсмиләштереп куярга кирәктер, дип уйлыйм. Сезнеңчә ничек?

– Минемчә дә шулай инде ул... Тик моның өчен нотариальный конторага барырга кирәк була торгандыр.

– Барырбыз, анысы качмас. Ләкин менә шушы сәгатьтә без, үзара гына булса да, килешүне беркетеп куярга тиешбез.

– Ничек итеп?

– Моны гадәттә задатка бирү-алу юлы белән эшлиләр. Димәк, мин дә сезгә задатка бирергә тиешмендер инде, шулай түгелме?

Ушаков иңбашын җыерды.

– Белмим, ихтыярыгыз. Әгәр сез алу-сатуны тиз арада нотариальный контора аша рәсмиләштерергә риза икәнсез, задатканы бирмәсәгез дә була. Мин сүземдә торачакмын.

– Моңа мин бик ышанам, – диде Зөфәр, кулын күкрәгенә куеп. – Ләкин сез дә минем тарафтан тыныч булып торсагыз иде дим.

– Алайса, пожалуйста, мин каршы түгел, – диде Ушаков, саран гына елмаеп.

Зөфәр дә елмайган булды.

– Задатканы гадәттә саткан кеше үзе сорый торган иде, ә монда киресенчә килеп чыкты. Ну, зарар юк! Барыбер мин бирәсе акча ич ул!.. Ә хәзер, Сергей Леонидович, рәхим итеп расписка язысыз. – Зөфәр аның алдына блокнот битен ачып куйды һәм авторучкасын чыгарып сузды.

Ләкин Ушаков ручканы кулына алырга ашыкмады.

– Сабыр итегез, – диде ул, Зөфәргә туры гына карап.—Иң әүвәл мин сезнең белән бер нәрсәне ачыкларга тиешмен: алу-сатуны рәсмиләштерү һәм исәп-хисапны өзү кайчан булачак?

Зөфәр өчен бу иң четерекле мәсьәлә иде. Ул әле аны үзе дә хәл итеп куя алмаган иде. Дөрес, аның бүгеннән үк акчаны тулысынча түләп, эшне өзәргә кодрәтеннән килә, әмма... бер бик җитди мәсьәләне уйлап хәл итәсе бар. Нинди мәсьәлә ул – Зөфәр аны бары үзе генә белә, һичкемгә әйтергә ярамый торган түгел, ләкин уйлап хәл итәр өчен вакыт кирәк. Шуңа күрә ул, сәбәбен әйтмичә генә, Ушаковтан өч атна мөддәт сорады. Ушаков моңа риза булмады.

– Юк, – диде ул, башын чайкап, – мин ул хәтле көтә алмыйм. Булмый. Мин монда вакытлы гына кеше.

Ахырда, сөйләшә торгач, унике көнлек вакыт билгеләделәр. Әгәр шул вакыт эчендә Зөфәр эшне өзмәсә, йорт хуҗасы Ушаков үзен килешүдән азат итеп санаячак һәм задатканы кире кайтарып бирәчәк.

Бу турыда сүзне шулай тәмамлагач кына Ушаков, ниһаять, расписканы язарга булды. Ручканы кулына алгач: «Күпмегә?» – дип сорады ул; Зөфәр, аз гына уйланып: «Кырык меңгә языгыз!» – диде.

Ушаков расписка язган арада, Зөфәр чалбарының эчке ягына тегелгән кесәсеннән зур гына төргәк чыгарды. Ике кат пергамент кәгазьгә, аннары кара материягә төреп, сары шнур белән аркылыга һәм буйга әйбәтләп бәйләгән төргәкне чиште дә, гел бишәр йөзлекләрдән генә торган һәм унар-унар итеп бөкләнгән акчаның төгәл сигез кисәген санап, Ушаков алдына салды. Калган ике кисәген яңадан төреп, шул ук кесәсенә тыгып куйды. Ушаков һәр кисәкне ашыкмыйча гына санап чыкты. Зөфәр белән Хәмит аның бу эшен бик игътибар белән карап тордылар; ахрысы, шуңардан военврачның бармаклары аратирә калтыранып та куйгалады, ләкин йөзе-чырае һаман да тыныч булып калды... Санап бетергәч, ул сигез кисәк акчаны ике-өчкә бүлеп, төрле кесәсенә тыкты һәм бары шуннан соң гына язылган распискага имзасын салып, числосын, елын куйды.

...Эш төгәлләнде, торып кул кысыштылар, расписка Зөфәрнең эчке кесәсенә кереп урнашты, һәм килешүчеләр арасында ничектер кинәт кенә сүз дә бетеп китте. Гүя аларның һәркайсы хәзер генә үтәлгән эшнең нәтиҗәсе турында үзалдына эченнән генә нидер уйлана иде.

Хәер, бу тынып тору озакка бармады. Өлгер Хәмит шундук урыннан сикереп торды да чын дәртләнү белән кычкырып:

– Ну, кадерле дуслар, – диде, – теләсәгез ни әйтегез, иллә мәгәр моның кебек зур эшне болай коры гына калдырырга ярамый. Юарга кирәк, обязательно юарга!

Тегеләр бер-берсенә карашып өлгергәнче ул инде кечкенә буфеттан өстәлгә өч бокал алып куйды һәм... чынлап та бер шешә шампанский чыгарды. Гаҗәп! Кайдан килгән бу, дүрт ел

буена күздән югалып торган, көмеш башлы алтын эчемлек? Моны инде, белсә, бер Алла да Хәмит үзе генә белә торгандыр...

...Менә ул сул кулының өч бармагы белән (ике бармагы аның төптән үк юк иде) шешәнең муеныннан иплəп кенә тотты да, уң кулы белән җитез генә тимерчыбыгын сүтеп, бөкесен сак кына кузгата башлады. Кинәт бөке шартлап атылды, шешә авызыннан сузылып ак төтен чыкты, ә Хәмит тиз генә бокалны күбек белән тутырды. Аннары калган икесенә дә, бер тамчысын да түкмичә, тутырып салды.

– Ягез! – диде ул, бокалны тантаналы күтәреп... – Бу зур килешү ике якның да бәхетенә булсын!

– Рәхмәт. Шулай булсын! – диде Зөфәр, акрын гына.

Чәкешеп эчтеләр. Ушаков, беренче кат дигәндәй, ачыграк елмаеп әйтеп куйды:

– Да-а! Казанга кайтып, шампанский эчәрмен дип уема да китермәгән идем. Кайдан таптыгыз моны?

– Безнең Казанда табылмаган нәрсә юк, – диде Хәмит, горурлана биреп.

– Шулаймы? Ләкин мин монда сырец-аракыдан башка нәрсә күргәнем юк иде әле.

– Һи, иптәш военврач, эзли белергә кирәк, эзли белергә... Эзли белсәң, күгәрчен сөтен дә табып була.

Ул кунакларының бокалына тагын бер кат салып чыкты. Шуны аягүрә генә эчтеләр дә хуҗага рәхмәт әйттеләр. Ушаков фуражкасын алды. Зөфәр белән алар яңадан каты итеп кул кысыштылар.

– Хәзер инде сезнең килешүне шайтан үзе дә боза алмас! – диде Хәмит.

– Ни өчен? Шампанский белән юганга күрәме?

– Юк, сез көлмәгез әле, иптәш военварч! Хикмәт бер шампанскийда гына түгел, хотя аның да эшне беркетеп куя торган көче бар... Главное, сезнең килешү минем алда, минем фатиха белән булды. Ә мин фатиха биргән эш бервакытта да сүтелмәс ул!

– А-а, алай икән, моңа мин бик шатмын! – дигән булды Ушаков, башын ия төшеп.

– Шулай шул менә, иптәш военврач! – диде Хәмит тә аның көенә тәкәллефле горурлык белән һәм кунагын тышкы ишеккә чаклы озата чыкты.

Зөфәр тәрәз каршына узды һәм, кулларын артка куеп, урамга карап тора башлады. Ләкин күзләре урамда булса да, уйлары һаман шул бер нәрсә тирәсендә сүлпән генә әйләнә иде. Әйе, менә ул, ниһаять, зур эш башкарды. Гаять зур эш! Әле кичәгенәк кенә бу хыял иде, ә бүген конкрет гамәлгә әверелде. Киләчәк язмышы өчен моның әһәмиятен хәзер генә күреп тә, аңлап та җиткерүе читен кебек. Бәхеткә, уңышка була күрсен!.. Ә шулай да ул, бик теләгән эшне үтәвенә

карамастан, нигәдер үзендә чын канәгатьләнү тоймый әле. Киресенчә, әллә нинди менә җан бушлыгы, җан сүлпәнлеге тойган кебек... Гаҗәп. Үз гомерендә ул нинди тәвәккәл эшләр эшләмәде, әмма артыннан һәрвакыт зур канәгатьләнү, үз-үзенә ышану һәм җиңеләеп калу татый торган иде. Ә бүген менә шулар юк. Нидән соң бу болай, хәерсез?

Хәмит әйләнеп кергәч тә ул тәрәзә каршында әнә шулай уйланып, иңбашларын салындырып, тын гына басып тора бирде. Хуҗа егет өстәлдән шешә белән бокалларны җыеп алды, урындыкларны стена буена күчерде, шуннан соң гына ул Зөфәргә төбәлеп бер карады да гаҗәпләнеп дәште:

– Син нәрсә, брат, канатларыңны салындырдың әле?

– Әллә тагын... Юк шикелле, – диде Зөфәр, ялкау гына. – Просто, арыдым бугай...

Ләкин Хәмит моңа ышанып бетмәде – дустының басып торышында ул бер арыганлык кына түгел, ничектер боегып калу да сизә иде. Шуңа күрә сорамыйча булдыра алмады:

– Үкенмисеңдер бит?

– Нәрсәгә?

– Нәрсәгә дип, менә хәзер генә эшләгән эшеңә?

– Нишләп үкеним, ди, юләр! Бала түгел лә мин!

Ул Хәмиткә йөзе белән борылды:

– Тик, беләсеңме, дускай, бу шундый зур эш, мин сиңа әйтим, уйланмас җиреңнән уйланырга да, даже... борчылырга да туры килә. Йорт, диләр аны!

– Беләм инде, беләм, конечно, шалаш түгел. Уйланырсың да, борчылырсың да, өч йөз егерме биш меңне чыгарып салгач... Тик син үкенә күрмә, дус кеше!.. Җенем сөйми үкенүне... Мин үзем берәр билгесез хатын янында кунып чыксам да үкенмим. Булган эш булган!

Зөфәр, әллә ничек кенә бик ясалма итеп, шаркылдап көлеп куйды:

– Ха-ха! Булган эш булган дисең, ә!.. Дөрес әйтәсең, чорт возьми, булган да беткән, чыгарган да җибәргән, чабуына ябышмаган! – Зөфәр бармак сырты белән күзен сörткәләде дә тагын уйланып, аз гына тынып торды. – Ә монда, брат, эшнең башы гына әле, ахыры ни булып бетәр – билгесез. Бу сиңа кунып кына чыгу түгел, ә гомерлеккә кереп утыру... Хәер, гомерлеккәме?

– Зөфәр, мин сине аңламый башладым әле! – диде Хәмит, чынлап гаҗәпләнгәндәй, аңа әрсез-туры гына карап. – Син бит моңарчы тоткан җирдән өзә торган егет идең, нәрсә булды? Күңелең тартмыймы, куркасыңмы, акчаңны кызганасыңмы? Алайса эш узмаган әле, тотасың да задатканны кире аласың, вәссәлам!

«Күңелең тартмыймы, куркасыңмы?» – бу сүзләре белән Хәмит Зөфәрнең үзенә-үзе дә икърар итәсе килмәгән шиген тотып алгандай булды. Ләкин Зөфәр күңеле төбендә кыймылдарга маташкан ул шикне, әлбәттә, һич сиздерергә теләмәде, юри батыраеп җавап бирергә ашыкты:

– Ялгышасың, дус кеше! Миңа берни дә булганы юк. Теләдем – алдым, кеше авызыннан тартып алдым. Алты бүлмәле, җимеш бакчалы йорт менә монда – минем куенымда хәзер! Нинди үкенү булырга мөмкин!

– Алайса бик әйбәт, сүзем бетте, игелеген күр! Сиңа бит шул кирәк тә инде – йорт-җирле, чибәр кәләшле, бала-чагалы солидный тормыш! Менә ирешәсең...

– Ә сиңа кирәкмимени?

– Юк, миңа кирәкми. Мин бервакыт та өйләнмәячәкмен, и йорт та алмаячакмын. Нигә ул богаулар миңа? Кайтып ятарга бер бүлмәм булса, миңа шул җиткән. Тик кесәмдә ике сберкенәгә йөрергә тиеш. Ике кенәгә – ике канат ул, менә шул чагында инде мин теге ни... ирекле кәккүк!

– Кәккүк! Шәп кәккүк, тик борын гына карчыганыкы...

– Теләсә кемнеке булсын, әмма ирекле кош ул!

– Ай-һай! Кычкыруына караганда, Ходай биргән «иректән» бер дә риза түгел шикелле... Юк инде, мулла Хәмит, мин кәккүк төсле бүтәннәр оясына күкәй салып йөрергә теләмим. Минем барысы да үземнеке булырга тиеш.

– Мин дә шуны әйтәм бит! Эш нидән тора? Ояң булды, ярың бар, тик әйдә...

– Кемне әйтәсең, нинди яр ул?

– Рәшидә соң?

– Ә син бит аны күргәнең юк.

– Һи, иптәш, мин шушы бүлмәмә килеп йөргән хатынны күрми тораммы соң!

Зөфәр, кашларын җыерып, шактый сагаеп калды.

– Ләкин ул сине белми бит.

– Анысы неважно... Так вот, ояңа күрә нәкъ үзе, алтын күкәй салып бирерлек асыл кош Рәшидә ханым Сафина!.. Шулаймы әле?

– Рәшидә, Рәшидә! – Зөфәр авыр гына сулап куйды.—Кадерен белерме икән соң ул мин үргән ояның?

– Җүләр, сорап торасың тагын, җәннәт итәр ул синең ояңны... Миңа туры килсә иде шундый хатын! —диде Хәмит, тәмам әсәрләнеп.

– Ий-е! – дип сузды Зөфәр, үзалдына гына. – Бик ансат кына этеп кертмәкче буласың син мине җәннәткә!

– Ә синең аяк терәп торасың килә инде, ә?

Зөфәр озак кына дәшми торды; Хәмиткә аның бик үк ачылып бетәсе килми иде, ләкин, бер сүз чыккач, дустына кайбер шиген азрак әйтәсе дә килә иде.

– Рәшидәне син белмисең, – диде ул, ниһаять, җитди генә. – Шуны онытма, ул – артистка, аның хыяллары бөтенләй башкада. Гаилә бәхетен аңардан көтүе читен, минемчә...

– Бәхет! Нинди бәхет турында хыялланасың син? Асравың шикелле буйсынып кына торса, чолгауларыңны юса, ел саен корсак үстереп йөрсә – шушымы синең өчен бәхет?

– Син алай бик упрощать итеп ташлама әле, егет! —диде Зөфәр, кызыбрак. – Асрау алу турында түгел, ә хатын табу турында сүз бара, өйләнү турында!.. Ә хатын ул синең җаныңа да, тормышыңа да кереп утыра, бөтенесенә үзең кебек үк хуҗа булып ала, вәт нәрсә ул өйләнү! Җаныңны да, малыңны да дигәндәй, белер-белмәс теләсә кемгә тапшырып булмый, иптәшкәй!.. Хәер, сиңамы соң, таз кәккүккә, өйләнүнең нәрсә икәнен аңлау!

Ләкин Хәмиттән болай кимсетеп-хурлап кына котылу мөмкин түгел иде. Бер усалланып китсә, ул да кызганып тора белми иде.

– Син – татар, просто татарлыгыңа барасың, – диде Хәмит, нәфрәт белән. – Икенче берәү булса, бөтен нәрсәсен – җанын да, байлыгын да – Рәшидә кебек хатынның аягы астына салыр иде!

– Ихтимал! – дип кенә куйды Зөфәр һәм яңадан тәрәзәгә борылды. Аның инде бу сүзне тизрәк бетерәсе килә иде. Ләкин Хәмит аның аркасына булса да үз сүзен әйтеп бетерергә ашыкты.

– Рәшидә дә бит байлыктан мәхрүм түгел. Причем, акчага табылмый торганы... Ул синең токмач белән йокыдан башканы белмәгән тормышыңа шатлык, матурлык, җыр, музыка алып килер иде.

– Һәм син шуның бәрабәренә чолгауларыңны үзең юып, үзең аңа асрау булып торыр идеңме? – диде Зөфәр, көлгән булып, кирәкмәгәнне әйтеп ташлаганын шунда ук сизде, ләкин соң иде инде.

– Дурак син, Зөфәр, вот нәрсә! – диде Хәмит, кулын селтәп. – Канат юк синдә, масштаб юк. Үзеңнең шул коммерсияңдә катып калгансың, бүтән тормышны күрмисең дә, белмисең дә... Просто, Рәшидәнең сукырлыгына гаҗәпләнәм.

– Шаярма, Рәшидә бер дә сукыр түгел ул.

– Шулай да сине яратамы?

– Нигә, мин яратмаслык кешемени?

Хәмит, ни әйтергә аптырагандай кулларын җәеп, иңбашын гына җыерды:

– Белмим инде, нәрсәң белән генә син аны әсир иткәнсеңдер?!

Зөфәр кинәт Хәмиткә таба борылды – аның йөзе агарган, күзләре эчке ярсудан зураеп киткән иде.

– Белмәсәң, әйтим алайса, – диде ул, буыла төшеп.—Мин үзем аны яраттым, өзелеп яраттым!.. Менә ни өчен Рәшидә миңа әсир булды, миңа мөкиббән китте... Мәхәббәт, диләр моны!.. Һәм мин теләсәм, Рәшидәне бүгеннән өемә җитәкләп китерә алам...

– Соң, шулай булгач, эт талаган юләр...

Ләкин Зөфәр Хәмиткә авыз ачарга ирек бирмәде, бу хакта сүзне шуның белән беткәнгә санап һәм тиз генә үзен кулга алып:

– Җитте, Хәмит! – диде. – Бүтән – ләм-мим! Вакыты ул түгел. Беләсең ич, минем башта хәзер нинди кайгы... Берьюлы ике куян артыннан чабып булмый!.. Тик синнән үтенеч шул: бу йорт мәсьәләсен берәүгә дә чишми тор. Аңлыйсыңмы, берәү дә белмәскә тиеш.

– Рәшидә дәме?

– Әйе, ул да...

– Кара, син аңардан куркасың да икән әле, – диде Хәмит, гаҗәпләнгән булып.

– Что значит, куркасың? – диде Зөфәр, гасабиланып. – Мәсьәлә куркуда түгел, ә алдан ук дөнья шаулатасым килми, менә шул!.. Вакыты җиткәч, белергә тиешле кешеләргә үзем дә әйтермен. Только синнән чыкмасын, кара аны!

– Ярый, ярый! – диде Хәмит, ике кулын да селтәп.—Моңарчы бит әле серләреңне чишмәдем, янамасаң да була.

– Янамыйм, ә дусларча сорыйм!

– Булды инде, булды! Безнең кендекләр береккән икән, нишлисең, «дусларча» соравыңны да үтәрбез!

Зөфәр үтә сынап Хәмиткә бер карап торды да, сүз әйтмәстән, кисәк кенә борылып, ишеккә атлады. Хәмит аптырабрак җилкәсен кашыды:

– Хуш дип тә әйтмисең, ә?

– Хуш, сау бул! – диде Зөфәр, ишектән чыгып беткәч кенә.

Менә шулай инде алар. Очрашкан саен ызгышып китмичә калмыйлар. Күп вакытта моңа Хәмитнең усал теле гаепле. Ләкин, үзе үк әйтмешли, аларның кендекләре чынлап та бик нык береккән. Сугыш вакытында күп эшләре бергә булды, бергә таптылар, бергә йоттылар... Шулай да Хәмит Зөфәр каршында күбрәк бурычлы. Сәүдә эшендә шактый түбән баскычта торганга күрә, ул Зөфәрнең ярдәменә һәрвакыт мохтаҗ булып килде. Зөфәр аның дуамал башын кайбер бәлаләрдән йолып алып калды, үз системасына кертмәсә дә, әйбәт кенә җирләргә дә

урнаштырды, акчалата да ярдәм иткән чаклары булды. Менә шунлыктан Хәмит, «дуслык» хакына, үзен аңа буйсынырга, аның таләпләрен үтәргә мәҗбүр дип саный иде.

## IX

Ушаковлар белән килешеп, задаткасын биреп куйгач та Зөфәр алдына гаять җитди бер мәсьәлә килеп басты: йортны кем исеменә яздырып алырга?.. Уйлап-уйлап та менә шуны хәл итә алганы юк әле. Һәм иң авыры – бу хакта ул ялгызы гына баш ватарга мәҗбүр. Эшләгән-йөргән җирләрендә дус-ишләре күп булса да, ул аларга бөтен серен дә ачып бетерергә җөрьәт итми, курка... Абыйсы әле фронттан кайтып җитмәгән, бердәнбер киңәшер кеше – әнисе карчык, ләкин моның кебек үтә катлаулы мәсьәләдә ул нәрсә генә әйтә ала? Ә мәсьәлә шундый ки, аны дөрес хәл итү белән киләчәк тормыш та, хәтта язмыш та бик нык бәйләнгән. Моны Зөфәр үзе генә аңлый, чөнки ул үзенең кем булуын, ничек итеп баюын бер генә минутка да исеннән чыгармый. Ул белеп тора: аның хәлендә ярты миллион сумлык йорт сатып алу, көне-сәгате белән дигәндәй, үзенә карата төрле сүз-шик тудыру булачак. Ә нигә кирәк бу, нигә шәһәр шаулатырга, нигә төрле кирәкмәс кешеләрнең (мәсәлән, Симаков кебекләрнең) шиген уятырга? Юк, мондый эштә җиде кат үлчәп, бер кат кисмичә һич тә ярамый. «Чукынган заман,—диде ул, эченнән ачынып, – курыкмыйча, яшеренмичә бер генә нәрсә дә эшләп булмый бит!»

Кыскасы, үзен шик астына, йортын куркыныч астына куймас өчен, ул, вакытлыча булса да, кемнеңдер артына посарга, кемнедер «хуҗа» итеп тотарга тиеш. Тик менә кемне? Аның иң якын, иң ышанычлы ике кешесе бар: әнисе һәм абыйсы. Менә шулардан ул кайсын сайларга белмичә аптырый. Мәсьәләнең җитдилеге һәм нечкәлеге шунда ки, аларның кайсысы беткәнче гадел булыр да Зөфәрне бердәнбер хуҗа һәм баш итеп таныр. Әйтик, абыйсы кайтып та өлгерсен, ди, ләкин Зөфәр аның белән уртак тел таба алырмы – әйтүе читен. Аннары ул риза булган тәкъдирдә дә аңа ышанып бетәргә мөмкинме? Ул үзе дә бит мал дигәндә акны-караны аермый торган кеше – соңыннан йортыңа чынлап торып хуҗа булып алмасмы? Кайда гарантия? Туганлык һәм намус печатьле кәгазь түгел, судка күтәреп илтә алмассың!

Инде бер әни карчык кала. Аңардан да ышанычлы кеше булырга мөмкинме соң? Уйлап торасы да юк кебек, әмма шулай да Зөфәр уйлана һәм тәгаен бер карарга килә алмыйча йөди-азаплана. Бөтен мәсьәлә шунда ки: әнисенең Зөфәрдән башка тагын ике газиз баласы – солдаттан кайтачак улы белән үсмер кызы бар; үз исеменә яздырылган Зөфәр йортыннан менә шуларга да ул өлеш чыгарырга теләмәсме?

Зөфәр шулай төрле исәпләр белән баш ваткан арада уйламаган, көтмәгән яктан дигәндәй, кызыклы гына хәлләр дә булып алды.

Ушаков белән сөйләшеп кайтканнан соң, икенче көнне үк, аңа ах-вах итеп, Гайсә карт килеп керде. Карт тау менгән ат шикелле бик кайнарланган иде:

– Карале, Зөфәр туган, сез тегеләр белән килешкәнсез икән ләбаса! – диде ул, утырыр-утырмас.

– Әйе шул, – диде Зөфәр, картның кыяфәтеннән һәм сүзеннән шактый гаҗәпләнеп. – Нигә? Әллә берәр хәл булдымы?

– Ә мин... мин? – диде карт, таягының башы белән күкрәгенә сугып... – Ничек итеп сез мине оныттыгыз, ә, миннән башка аны эшләдегез, ә?

Зөфәр тагы да ныграк гаҗәпләнә калды:

– Аңламыйм. Нигә, синнән башка эшләргә ярамый идемени?

– Мин бит посредник, аңлыйсызмы, посредник... Мин сиңа йорт табып биргән кеше, тегеләрне сатарга, сине алырга димләгән кеше... Йә, мине читтә калдырып, сез ничек килешә алдыгыз?

Зөфәр картның ни өчен болай дулавын, ниһаять, аңлаган кебек булды.

– Карале, Гайсә абзый, – диде ул, тынычланып, – берәүнең дә сине читтә калдырганы юк. Просто, шулай килеп чыкты. Миңа йорт хуҗасы белән аулакта, икәүдән-икәү генә очрашырга кирәк иде. Монда үземә алып килергә теләмәдем, синең подвалыңа да илтеп булмый бит инде аны... Читтә сөйләшергә туры килде. Менә шул. Юкка кызасың, картым, алучы белән сатучы килешкән чакта посредникның булуы бер дә шарт түгел бит.

– Нәрсә дидең? Шарт түгел, дидеңме? Ничек ул алай? —Картның зәгыйфь күзләреннән, еламаса да, яшь ага башлады. – Мин карт сөякләремне өстерәп нәрсә өчен йөрдем соң? Мин үз хакымны алырга тиешме-түгелме? Син бит, Зөфәр, мондый эшнең тәртипләрен беләсең, йә, әйт!

Зөфәр аз гына көттереп җавап бирде:

– Әйе, сиңа йөрүең өчен бераз комиссионный тияргә тиеш... Алырсың.

– Алырсың! Әйтергә ансат! Кемнән, кайчан, күпме? Моны бит әнә шул килешү вакытында сөйләшеп куялар. Ә хәзер чыпчык куып йөр инде... Кайсыгыз бирә?

– Комиссионныйны гадәттә саткан кеше бирә, Гайсә абзый, үзең беләсең...

– Ә-ә, алай икән!.. Һе, Ушаковлардан теләнеп йөрергә кирәк икән!.. Ә алар, знать не знаем, әнә алган кеше түләсен дип җибәрсәләр, ә?

– Җибәрмәсләр.

– Как җибәрмәсләр? Килешү юк, сөйләшү юк. Отказ, вәссәлам!.. Менә шуның өчен дә шул килешү вакытында посредник обязательно булырга тиеш. Кем күпме бирәчәк – шунда хәл ителә ул... Хәтта договорга аерым пункт итеп языла торган иде ул элек, беләсең килсә!.. Юк,

Зөфәр Мөбарәкович, начар эшләдегез, ямьсез эшләдегез... Рәнҗеттегез мин гарип картны, рәнҗеттегез!.. Бит мин шушы сәламәләремне өстемнән ташлый алмаммы дип, шул юеш, сасы подвалдан башымны алып чыга алмаммы дип йөргән булдым. Йа Хода! Мин дә бит заманында Ушаковларныкыннан да шәбрәк йортларда торган кеше... Шуны аңларга кирәк иде, һич югы...

Зөфәрнең йөзе бердән караңгыланып китте:

– Карале, Гайсә абзый, сине берәү дә рәнҗетергә уйламый. Ашыгып еларга тотынма әле... Җайларбыз. Үзем сөйләшермен.

Карт дәшә алмады, бары керле яулык белән битен-күзен генә сөртеп утырды. Зөфәр, бераз көтеп, сорап куйды:

– Син үзең соң күпме өмет иткән идең?

– Хәзер инде, эш узгач...

– Юк, шулай да?

Карт тагын кинәт батыраеп китте:

– Әйтим алайса: миңа, Зөфәр Мөбарәкович, килешү бәясенең өч проценты тияргә тиеш... Күпмегә килештегез? Өч йөз егерме биш меңгәме? Менә шуннан үзең исәпләп чыгар!

Зөфәр, көлемсерәп, башын чайкап торды:

– Сиңа, Гайсә абзый, андый акчаны берәү дә бирмәс!..

– Бәддогадан курыкмасагыз, бирмәссез! – диде карт һәм торып, ничектер, бик бөкрәеп, саубуллашмыйча чыгып ук китте.

Зөфәрнең картка шактый ачуы килеп калды. «Җан көеге, синең генә кайгың иде монда!» – дип, эченнән сүгеп ташлады ул аны... Әмма шул ук вакытта ихтыярсыздан картны кызганып та куйды. Ничектер менә аның яшен генә агызып тавышсыз елавы, рәнҗеттегез гарип картны, рәнҗеттегез, дип ачынып әйткән сүзләре, ниһаять, балаларча үпкәләп, олы гәүдәсен бөкрәйтеп чыгып китүе, вөҗдан шелтәсе сыман, гел күзе алдыннан китмичә торды. Шуның өстенә ул картның соңгы вакытта гомумән бик өшәнеп китүен, шуңа карамастан үзенчә һаман тырышып йөрүен һәм ни өчен, нәрсә өмет итеп йөрүен дә уйламыйча булдыра алмады. Болай да төрле шик-уйлардан борчылып, шомланып торган күңеле аның кеше каргышыннан, кеше бәддогасыннан чынлап та курка калды. «Юк, ярамас, язык булыр, картны бәхилләтергә кирәк!» – диде ул үз-үзенә, ниһаять.

Ләкин Гайсә карт җәнҗалын бик тиз арада икенче бер зур вакыйга күмеп китте. Хикмәт шунда, моннан ай ярым чамасы элек үк Зариф абзыйдан: «Безнең елларны җибәрә башладылар, иншалла якын атналарда миңа да чират җитмәсме дигән өмиттә торам, сез дә бер Алладан шуны сорагыз!» – дип язган хаты килгән иде. Билгеле инде, аның кайтуын өйдәгеләр барысы да бик

зарыгып, шатланып, борчылып көтәләр иде. Һәм менә нәкъ беренче августта Зөфәрнең күз күргән бер танышы килеп, аларга: «Зариф абзый Юдино станциясендә вагон саклап, кайта алмыйча ята», – дип хәбәр итте. Бу гаҗәп сәер хәбәрне ишетү белән Зөфәр, Сәкинә җиңгәсен ияртеп, шунда ук Юдинога китте. Барсалар, чынлап та Зариф абзый ниндидер начальникның Германиядән немец җиһазлары төяп җибәргән вагоны белән Юдинога кайтып җиткән, ләкин зур станциянең бер тупигына эләгеп, шуннан ычкына алмыйча ята икән. Керләнеп-тузып, сакал-мыек басып беткән солдатны иң кырыйдагы юлларның берсеннән эзләп табалар һәм шатланышып, елашып күрешәләр. Ярый әле, Зөфәрнең кая барса да белешләре очрап тора – ул шулар ярдәмендә абыйсын вагоны-ние белән тиз генә тупиктан чыгарып, Казанга алып кайта.

...Сугыш кырыннан мондый «азаплар» белән кайтып кергән Зариф солдат өендә нинди зур шатлык, нинди зур бәйрәм булганын әйтеп торасы да юк. Зөфәрне исә абыйсының аяклы-куллы, мал-мөлкәтле булып күзгә күренүеннән дә бигрәк, нәкъ менә кирәк чакта кайтып җитүе аеруча нык сөендерде. Хәзер инде алар, ике туган, бергәләп сөйләшә дә, киңәшә дә, кирәк икән, хәрәкәт тә итә алачаклар.

Ул абыйсына мунча кереп, ял итеп, хатыны, бала-чагалары белән сайрашып үткәрергә бер генә көн ирек бирде. Икенче көнне үк инде аны аулакка чакырып, алда торган зур эш хакында сүз кузгатты... Озак бикләнеп утырдылар алар. Өч ел буена фронтта, дөресрәге, тыловой частьларда, башын саклап калу хәсрәте белән йөргән, хәзер исә дөньяны кочагына җыеп алырдай булып кайткан Зариф акыллы энесенең ашыкмыйча гына, төпле итеп, шома итеп сөйләп биргән ниятен бик хуплап каршы алды һәм үзе дә бу йорт мәсьәләсе белән бик кызыксынды. Бүгенгене иртәгәгә калдырмый торган кешеләр буларак, алар шул ук көнне йортны барып та карадылар. Баштанаяк гражданскийдан бик пөхтә киенеп барган Зариф (энесе аңа капитан Ушаков күзенә гади солдат булып күренергә киңәш бирмәде), бик эре генә кулларын артына куеп, башын кырын салып, йортның эчен-тышын җентекләп карап чыкты. Хуҗаларга берни сиздермәде ул, әмма урамга чыккач, Зөфәргә туп-туры әйтте:

– Шәп, бик шәп йорт тапкансың, Зөфәр туганым! Үзе таза, үзе чибәр, игелеккә язган дәүләт була күрсен! Зурлыгы да ике семьяга полный җитәрлек, урыны-җире дә бик матур, бик иркен, әлхасыйль, килмәгән җире юк моның...

Ләкин йортның бәясе Зарифның котын ала язды:

– Атакай гынам, өч йөз егерме биш мең! – диде ул, шаккатып. – Бу бит... бу бит Пралумныйда магазин ачып җибәрерлек капитал! Китче, зинһар, бер йортка шулкадәр түлиләрме соң!

Аның башта болай исе-акылы китүе бер дә гаҗәп түгел иде. Өч елдан артык армиядә буш ашап, буш эчеп йөргәнлектән, абзый кеше тылдагы чамаларны бераз онытып җибәргән иде. Хәер, аңа хәзерге мең сумның элекке йөз сумга да тормаганлыгын, ә яхшы йортларның бүгенге көндә биш-алты йөз меңнән дә кимгә табылмаганын төшендереп бирү Зөфәр өчен әллә ни авыр булмады.

Кыскасы, йорт килешенгән, задаткасы бирелгән – сүз ул хакта түгел хәзер. Сүз Зөфәр куйган мәсьәлә турында барырга тиеш: нишлибез? Ул, Зөфәр, үзе генә алсынмы йортны, әллә икәүләп алу хәерлерәк булырмы? Үзе генә алган тәкъдирдә йортны кем исеменә яздыру дөресрәк булыр?

Озак киңәштеләр алар. Зөфәр абыйсын акрынлап өлешкә керү ягына аударырга тырышты – ник дисәң, ул берәүне дә, бигрәк тә Зарифны семьясы белән, бары вывеска өчен генә, өенең түренә бушлай кертеп утыртырга теләми иде. Зариф үзе дә, исәпли-уйлый торгач, өлешкә керү ягына таба ава башлады. Барыбер аңа да, иртәме-соңмы, йортлы булырга кирәк, ә моның кебеген әллә табып була, әллә юк. Җыеп алып кайткан төрле алтын-көмеш әйберләре, кием-салымнары, машина энәсе кебек вак-төяк нәрсәләре аңа шактый акча китерергә тиеш, хатын кулында сакланып ятканы да бар әле, һәрхәлдә, тәвәккәлләсә, көче җитәчәк. Җитмәсә, алар ике туган ич, килешә алырлар.

Шулай итеп, һәрьяклап сөйләшеп аңлашканнан соң, Зариф риза да булып беткән иде, ләкин нәкъ менә шул чакта һич уйламаган кеше кинәт кенә бөтен эшне бозды да куйды. Бу – Зарифның хатыны Сәкинә иде.

...Электән дә ишле семьяда үзен бик итагатьле итеп, юаш, сабыр гына тоткан, ә Зарифы кайткач, бәхетеннән майдай эреп-сөенеп, кемгә ничек кенә ярарга белмичә йөргән хатын, иренең ниятен белеп алгач, пәри алыштыргандай, ана поши кебек усалланды да китте. Зариф йорт алу турында беренче кат сүз ачкач та, ул ничектер бердән ярсып: «Юк, бу эш булмас! – диде. – Мин моңа асла риза түгел, – диде. – Миңа алтын сараең да кирәкми, балаларым белән шушында калам, чыкмыйм»,—диде... Аның кинәт болай ярсып, кырт кисеп әйткән сүзләре Зарифны бөтенләй таңга калдырды. Бу ни хикмәт, бу ни тамаша, нишләп әле бу, койрыгы ишеккә кысылган мәчедәй, котны алып күтәрелде дә бәрелде? Ләкин моның сере бик тиз ачылды. Баксаң, бичараның бөтен өмет иткәне, бөтен күңеле-җаны белән теләгәне – каенанасыннан, каенесеннән аерылып, ниһаять, үзләре генә бер гаилә булып яшәү икән. Һәрбер килен шикелле, ул да хадимәлектән котылу, үз башына үз ирке белән яшәү турында гел хыялланган икән... Һәм ул, бичара, үз хокукын яклар өчен усалланып каршы тору гына түгел, кичләрен йокларга яткач, иренең муенына сарылып елый-елый да һаман шул ук нәрсәне

Зарифына тукыды: «Үзебез генә бер иркенләп торыйк инде, үз көнебез, үз рәхәтебез өчен генә бер торып карыйк инде... Кайчанга чаклы мин каенана көен көйләп, энеләреңә бил бөгеп яшәрмен? Килен генә булып торыр өчен яшь чакларым үтте бит инде, үз балаларым җитеп килә, алар өчен торасым килә минем... мин дә кеше ләбаса!»

Зариф, аны тынычландырырга теләп: «Менә Алла бирсә, яңа йортка күчкәч, Зөфәр үзе дә өйләнер, синең өстән эш-мәшәкать төшәр, карт килен булып, командовать итеп кенә торырсың!» – дип тә карады. Ләкин Сәкинә моның кебек юатып маташуларны ишетергә дә теләмәде. «Һи, сөйлисең тагы! – диде ул, ачынып.—Зөфәрне мин белмиммени? Зөфәр аксөяк бит ул, аның үзен карарга бер кеше кирәк. Аннары, үзеңә генә әйтим, аның әртискәсе бар дип сөйлиләр, өеңә шул әртискәсен китерсә, нишләрсең? Тагын шуның асравы булыргамы? Юк, җаным, булмый, булмый, кыстама мине, рәнҗетмә! Бөтенесенә хезмәтче булырга теләмим мин, җитәр, көчләмә, риза-бәхил түгелмен!»

Шулай ялварды, шулай куркытты ирен Сәкинә... Абзый кеше бик нык уйга калды. Дөрес, баштарак ул, ир-хуҗа буларак, ачуланып-боерып кына хатынын сындырмакчы булып карады, ләкин Сәкинә сыну түгел, отыры ныграк каршы торды. Болай эш чыкмагач, яхшылык белән күндерергә тырышып карады, ләкин Сәкинәгә бу да һич тәэсир итмәде. Хәер, дөресен генә әйткәндә, Зариф Сәкинәнең йөрәгеннән чыккан сүзләренә каршы торырлык үз дәлилләрен китерә дә алмады. Хак сүзгә җавап юк, дип белмичә әйтмәгәннәр, күрәсең! Шуның өстенә яңа кайтып кушылган чагы да булгач, яңа хатын кадерле, тансык иде, кызганмыйча һәм хисаплашмыйча мөмкин түгел иде, кыскасы, абзыебыз акрынлап йомшара-йомшара, ахыр чиктә хатынының таләбенә буйсынырга мәҗбүр булды.

Соңрак, өйдәгеләр бу хәлне белеп алгач, бик аптырашып калдылар. Әниләре Таибә абыстай килененең иренә баш бөкмичә шундый зур эшкә аяк чалуын һич аңларга да, кичерергә дә теләмәде. Ачуланып-каргап та, сыкранып-рәнҗеп тә ул киленен ничек кенә битәрләмәде; ир хакын санламауның бик зур гөнаһ булуын да әйтте, бәддога белән дә куркытты, кешеләрдән оялырга да өндәп карады, үлгәндә бәхиллегемне бирмәм дип тә какшатырга тырышты, ләкин боларның берсе дә Сәкинәгә тәэсир итмәде. Ул үз сүзендә таш кебек какшамас булып калды.

Тик Зөфәр генә, җиңгәсенең каршы килүенә бик кәефе кырылса да, бу бәхәс-низагыга тыгылуны кирәк тапмады. Җиңгәсе белән аның арасы алай бик җылы да, бик салкын да түгел иде, гомумән, ул аңа сүзсез-нисез бер мәхлук итеп югарыдан карарга өйрәнгән иде, һәм менә шул йомыкый гына хатынның кинәт үз хокукын мондый батырлык белән яклавы аны чынлап торып гаҗәпләндерде һәм борчуга салды. Ул сизде: өч бала анасын елата-елата, муенчаклап

дигәндәй, яңа йортка өстерәп илтү хәерлегә булмаячак, әлбәттә. Шуңа күрә ул бәхәскә тыгылмады, абыйсын котыртып маташмады, уйлап торды да кулын гына селтәде.

Ахырда, тагын бер кат уйлашып киңәшкәннән соң, йортны Таибә абыстай исеменә алырга булдылар. Карчыкның фани дөнья белән артык алыш-биреше юк, билгесез һәм гөнаһсыз бер кеше, бәс, шулай булгач, төрле гайбәт-сүзләрдән, хәтәр-хәвефләрдән курыкмаска да мөмкин. Эш юридик яктан ныгытылгач, кешеләр теләсә ни сөйләсеннәр, тик законга сыйсын!

Шундый карарга килгәч тә Зөфәр әнисе алдына үзенең таләбен куйды. Ягъни йортны алу белән бер үк вакытта Таибә абыстай үзенең васыятьнамәсен язып, улы Зөфәрне йортка бердәнбер тулы хуҗа итеп калдырырга тиеш... Карчык, әлбәттә, моны аңлый иде, моңа риза булырга тиешлеген белә иде, тик улының яңа йортка барып кермәс борын ук васыятьнамә язарга ашыктыруы аңа бер дә ошамады. Бик хәтере калып, хәтта рәнҗеп ул Зөфәргә: «Нигә, син мине тизрәк кабергә илтеп тыкмакчы буласыңмыни? – диде. – Ашыкма, вакыты җиткәч үзем дә Ходай каршына китәрмен. Ә син иң әүвәл эшеңне бетер, өеңә күч, аннан соң да васыятемне алырга өлгерерсең. Миңа ышана torгансыңдыр бит?»

Ләкин Зөфәр әнисенең бу сүзләрен колагына да эләргә теләмәде. Барысының да дәгъвасын тыңлау аны, ниһаять, туйдырып бетерде. Җитәр! Болай да күп чигенде. Ә бу мәсьәләдә инде ул бер карыш та чигенмәячәк. Мал —бәгырь ите, диләр!.. Һәм ул бәхәскә кереп тормыйча, әнисе исеменнән васыятьнамәне бер таныш юристыннан яздырып алды да, китереп, карчык алдына салды. «Әни, мин сиңа яңадан йөз ел гомер телим, – диде ул, салкын-тыныч кына, – әмма шушы кәгазьгә кулыңны куясың!.. Шунсыз – йорт юк!» Таибә абыстай беравык ни әйтергә дә белмичә улына шаккатып карап торды, аннары Зөфәр сузган каләмне, бисмилла әйтеп, калтыранган кулына алды.

...Менә Ушаковлар белән вәгъдәләшкән көн дә килеп җитте. Инде бөтен эш тә хәл ителгән иде, кирәкле документлар барысы да әзерләнгән иде, һәм Зөфәр вәгъдәләшкән көннең кичендә бер чемодан акча күтәреп, Хәмит дусты белән абыйсын ияртеп, Ушаковларга барды да шаһитлар алдында алар белән исәп-хисапны өзеп кайтты.

Ниһаять, күптәнге хыялына иреште шикелле ул... Зинин урамындагы таза, матур, бакчалы йорт аныкы хәзер!

## X

Сентябрь башында Ушаковлар кырык ел торган өйләреннән чыгып киттеләр... Инде яңа хуҗалар килеп керергә тиеш... Йорт – җансыз нәрсә, ул – дәшми, берни дә дәшми, җиргә үскәндәй тик кенә һәм тын гына тора... Әмма бөтенләй үк җансыз микән ул?

Менә иске хуҗалар чыгып китүгә өч таза хатын килделәр дә Ушаковлардан утырып калган гомерлек тузанны себереп чыгардылар, каты киндер белән бусага-баскычларына хәтле әйбәтләп юдылар, ишек-тәрәзәләрен ачып, бөтен бүлмәләрен җилләтеп киптерделәр. Ә икенче көнне Таибә абыстай иртә таңнан торып, урамда кеше-кара очраганчы, буш өйгә бер бөтен икмәк белән бер чирек сөт китереп куйды. Аннары Камәретдин мулланы чакыртып, өйнең түрендә Коръән укытты. Шуннан соң гына Зөфәр (ул мулланың күзенә күренмәде дә) ике атта йорт әйберләрен ташыта башлады.

...Күченү ярты көндә тәмам булды, кичкә табан булышкан кешеләр дә, Зариф белән Сәкинә дә ашап эчкәннән соң үзләренә кайтып киттеләр, һәм ялан кадәр өйдә Зөфәр дә Таибә абыстай һәм Хөршид кенә торып калдылар. Бер кич кундылар, ике кич, өч кич кундылар һәм акрынлап яңа урында торып киттеләр... Ләкин, шуны әйтергә кирәк, башта алар бик сәер хәл кичерделәр... Алты бүлмәгә өч кеше, ә китергән җиһазлары бер залны тутырырга да җитмәде. Шуңадыр, ахры, беренче көннән үк аларны ниндидер бер ят, өнсез, әмма колагын салып торган авыр бушлык чорнап алды. Моңа ияләшүе бик читен иде. Хәтта алар вакыт-вакыт бер-берсен югалталар иде. Таибә абыстай еш кына: «Хөршид, кайда син?» – дип, бүлмәдән бүлмәгә кыштыр-кыштыр кызын эзләп йөри, ә Зөфәр исә өй эче аеруча тынып калган чакларда: «Болар нишлиләр икән?» – дип, әнисе белән сеңелесен күрер өчен үз бүлмәсеннән әле кухняга, әле аш бүлмәсенә чыгып карый иде... Шактый гына вакытлар шулай яңа урынга, ялгыш килеп эләккән кешеләр төсле, җайлаша һәм ияләшә алмыйча йөдәделәр. Гүя менә Ушаковлар өе яңа хуҗаларны юри таныырга теләми кебек иде.

Өчесе дә өйдә чакта әле бу ят, өнсез бушлыкка артык игътибар итмәскә дә мөмкин иде, әмма инде Таибә абыстай үзе генә торып калган чакларда аңа бик тә авыр була торган иде. Һәр көнне иртән иртүк Зөфәр парадный ишектән чыгып, салмак кына атлап эшенә китеп бара. Аннары бераздан пөхтә генә киенгән унөч-ундүрт яшьлек арык кына кыз Хөршид шул ук ишектән чыга да, кечкенә портфелен селкә-селкә, мәктәпкә йөгерә... Аның артыннан ишекнең келәсе шалтырап бикләнә, һәм зур, буш өйдә биш-алты сәгать буена Таибә абыстай япа-ялгыз гына торып кала... Килгән кеше юк, киткән кеше юк, күршеләрдән берәү дә аяк атлап керми, җитмәсә, урамы да тып-тын, әллә нидә бер генә кеше-кара узып китә —шуңадыр инде өй, эчтән генә түгел, тыштан да ничектер үлек, ташландык булып күренә иде. Таибә абыстай күбрәк үзенең бүлмәсендә, сандык өстендә аякларын бөкләп, тәсбих тартып утыра. Ул куркак хатын түгел, өрәк, өй иясе кебек нәрсәләрнең булуына ышанып та бетми, гомумән юк-бар нәрсәләр турында уйламаска тырыша, әмма шулай да шомлана, шомланмыйча булдыра алмый... Зур өйнең әле бер башыннан, әле икенче башыннан ниндидер кыштырдау, ниндидер сәер өн

ишетелгән кебек була яки аргы бүлмәләрнең берәрсендә кемдер йөргән шикелле тоела – карчыкның йөрәгенә әкрен генә салкын үрмәли, аркасы буйлап әледән-әле кымырҗу йөгереп уза, һәм ул кузгалырга, төшәргә куркып, эченнән бөтен белгән догаларын кабатлап, сандыгы өстендә утыра да утыра...

Әлбәттә, мондый хәл озакка барырга тиеш түгел иде. Моңа Зөфәр дә бик борчыла иде. Бигрәк тә ул, көн буена җан әсәре барлыгын сиздермәгән өйгә жуликлар кереп, карчыкны чүкеп чыга күрмәсеннәр дип курка иде. Моның кебек эшләр шәһәрдә ара-тирә ишетелгәләп тора, Алла сакласын, уйламаган җирдән әллә ни булып куюы бар... Шуңа күрә карчык янына иптәшкә тизрәк берәр кеше табарга кирәк иде. Кыскасы, озак та үтми, Сәкинә ярдәмендә Яңа бистәдән олы гына яшьтәге бер хатынны Таибә абыстай янына табып китерделәр... Ләкин бу вакытлы чара, Таибә абыстай моңа гына һич канәгать түгел, аның күптән уйлап йөргән бик җитди үз исәбе бар иде әле...

Көзге салкын явымлы кичләрнең берсендә ул, намазлыктан гына торып (бу өйгә күчкәч, абыстай нигәдер бик диндар булып киткән иде), улы Зөфәр янына кереп утырды. Ниндидер кәгазьләр актарып утырган Зөфәр әнисенә сәерсенеп кенә карап алды; ак батист яулыгын ияк астыннан китереп бәйләгән карчыкның йөзендә зур сүзгә керешер алдыннан гына була торган басынкы-сабыр, җитди бер чырай иде. Күлмәгенең озын, киң җиңнәрен тарткалап, бераз дәшми торганнан соң, ул акрын гына сорап куйды:

– Мин синең эшеңне бүлмимме?

– Юк, әни, юк, – диде Зөфәр, тыңларга әзер торуын аңлатып.

– Алайса минем сиңа сүзем бар иде.

– Сөйлә, әни, сөйлә! – Зөфәр кәгазьләрен бер читкәрәк этәрде дә әнисенә борыла төште.

Таибә абыстай әүвәл бер кулын өстәлгә салды, аннары алдына карап кына сүзен башлады:

– Ни әйтәсемне, улым, үзең дә сизенә торгансыңдыр инде... Беренче кузгатуым гына түгел, моңарчы да әйтә килдем, хәзер инде, шаять, Алладан вакыт җиткәндер...

Зөфәр дөрестән дә сүзнең нәрсә турында баруын сизеп алды, ләкин шулай да бераз гаҗәпләнә төшеп, юри сораган булды:

– Сүз ни турыда соң, әни, нәрсәгә вакыт җиткәндер дисең?

– Соң инде белгән өстенә сорамасаң... – диде карчык, үпкәләгән сыманрак итеп, аннары туп-туры гына әйтте дә бирде: – Өйләнергә вакыт, дим, өйләнергә!.. Кайчанга кадәр сузмакчы буласың? Ярамый бит болай, Аллага шөкер, ир уртасы булып җиттең бит инде... Һәр җимешнең

үз вакыты дигәндәй, моның да бит бер чиге булырга тиеш ләбаса! Кызлар гына утырып кала дип уйлама. Егет кеше дә, вакытын бер уздырып җибәрсә, ямен-кызыгын югалта...

– Анысы шулайдыр да бит, әни, – диде Зөфәр, маңгаен ышкып, – ләкин һәр эшнең үз җае бар ич! Әле кайчан гына, күпме акча салып, шушы йортны алдык... Өсте-өстенә булмый бит. Азрак баш-күз алыйк, хәл җыйыйк, аннары инде бу хакта да уйлашырбыз.

– Уйлашырбыз! Ходаем, әле һаман уйламакчы гына буласың икән!.. Юк инде, Зөфәр улым, уйланудан эшкә күчәргә вакыт җитте, бик җитте... Моңарчы болай да, әле сугыш бетсен, әле нигезебез булсын дип, төрле сылтау белән сузып килдең. Хәзер эш нидән тора? Менә, игелеген күрергә насыйп итсен, гомерлек нигезгә хуҗа булдың. Инде шушы нигездә әйбәтләп оя үрергә кирәктер ләбаса, ата-бабадан калган йола ич ул!.. Югыйсә үзең ятим, өең ятим, караучың юк, хезмәтчең юк, йә, нигә ярый бу?.. Ничек асрарсың син бу йортны?.. Аннары минем хәлемә дә керергә тиешсең син. Күпмегә чаклы бу казармы хәтле өйдә мин ялгыз башым каңгырап утырырмын...

– Әни, син хәзер ялгыз утырмыйсың ич, әнә үзеңә иптәшкә Мәймүнә апаны китердек.

– Мәймүнә!.. Мәймүнә кем ул хәтле миңа! Бүген бар, иртәгә юк дигәндәй, аңа исәп тотып булмый бит. Сиңа хатын, безгә килен кирәк монда. Сине тизрәк өйләндерү турында сүз бара, аңлыйсыңмы шуны?

– Аңлыйм, әни, аңлыйм!

– Аңласаң шул!.. Чарасына керешик. Әгәр үзеңнең күздә тоткан кешең булмаса, без табышып бирербез. Кызларга кытлык заманы түгел, менә дигән җирдән берәр яхшы ата-ананың инсафлы баласын бик җиңел табарбыз, Аллаһы бирсә! Тик эш сиңа гына терәлеп калмасын... Әйткәнемне тыңла, улым, тыңла!

Зөфәр, маңгаена таянып, шактый гына вакыт уйланып утырды. Бу кузгатылган мәсьәлә турында аның бик тирән яктан үз теләге, үз фикерләре булса да, хәзергә әнисе белән бәхәскә керүне ул кирәк тапмады. Тирән генә бер сулап куйды да, ниһаять, әнисенә йомшак кына болай диде:

– Әни, әйткәннәреңнең барысы белән дә килешәм, каршы килмим... әйе, миңа өйләнергә кирәк. Әмма ләкин бу минем өчен гаять җитди мәсьәлә, хәзер генә өзеп тәгаен сүз әйтүе бик читен... Шуңа күрә син миңа уйланырга вакыт бир, уйлыйм әле мин, аннары бер җай белән үзем сиңа соңгы сүземне әйтермен. Шулай килештекме?

Таибә абыстай, бик үк канәгать булып бетмәсә дә, килешмичә булдыра алмады. Шулай да ул торып чыгар алдыннан сукраныбрак әйтмичә түзмәде:

– Һай, артык нечкәлисең, улым! Өйләнү кебек эштә бераз күзне йомыбрак тәвәккәлләү дә кайчак хәерлегә була ул! Үзең генә очына чыга алмасаң, Аллага тапшырырга кирәк. Ярый...

Әйе, әгәр дә ул, Зөфәр, күзен йомып тәвәккәлли алса, яраткан кешесе күптән аның янында булыр иде инде. Әмма... күзне йомып та, тәвәккәлләп тә булмый шул! Хәтәр, рискованно!.. Ихтимал, Рәшидә кебек якты, нәфис хатынны ул бүтән таба да алмас. Әгәр аңа өйләнә калса, теге иблис Хәмит әйтмешли, сылу артистка үзе белән бу йортка шатлык, җыр, музыка алып килер иде. Аның үзе кебек уен-көлке, җыр-музыка яратучы ваемсыз артист халкы өеңә килеп тулыр иде. Көн дә кәеф-сафа китәр иде. Табып, китереп, сыйлап кына өлгерт!.. Йә, шулмы ул хыял иткән тормыш? Нәрсә белән бетәр иде моның ахыры?..

Ярый, алай ук булмасын да ди. Хәзер заманы да, кешеләре дә бөтенләй башка. Рәшидә үзе дә андый җиңел тормышка өйрәнмәгән, нужа әчесен шактый күп эчкән хатын... Ир җилкәсенә салынып, курчак булып, эшсез рәхәттә генә яшәргә теләмәвен кат-кат әйткәне дә бар. Башы-күзе шул сәхнәсе, уены, җыры белән томаланып беткән. Кыскасы, җилкәңә менеп атлана торган хатыннардан булмаячак.

Ләкин, икенче яктан, аның әнә шулай үз дигәнчә яшәргә, бәйсез булырга омтылуы куркыта. Ышанып, яныңа алырсың, тормышыңа кертерсең, ә ул сине аңламас, син дигәнчә яшәргә риза булмас. Һәрхәлдә, синең хөкемеңә буйсынып, синең теләкләрең белән килешеп, итагатьле хатын булып кына торуны аңардан көтүе читен, бик читен... Үзенә күрә түгел, ниндидер гаделлек, тигезлек сөюче ярлы бер тәкәббер бит ул!

Юк, яратам дип, аңа башны бәйләү шактый рискованный эш булыр иде. Җитмәсә, кешедән калган хатын бит әле ул. Бик эчне тырный торган күңелсез нәрсә бит монысы да... Инде, күзне йомып ала башласаң, әнисе дә, барлык туганнары да мондый хәл белән һич килешергә теләмәячәкләр, теш-тырнаклары белән каршы торачаклар.

Димәк, Рәшидәгә исәп тотарга ярамый. Өйләнер өчен бүтәнне эзләргә кирәк булачак. Күптән инде аның бу мәсьәләдә хыял иткән, ягъни үзенә һәр яктан да кулай булырлык яшь, чибәр кыз табу теләге бар иде – менә шуңа ирешергә кирәк. Ә моның өчен ул иң элек Рәшидә белән ике араны ничектер җайлап кына, авырттырмыйча гына өзәргә тиеш. Ләкин ничек итеп?.. Рәшидә бит ул!.. Ничек итеп?..

## XI

Яңа йортта Сабитовларга күңелсезрәк, бушрак булса да, ниһаять, беренче озын кыш та үтеп китте. Яз килде. Тыныч, хәвефсез яз иде инде бу... Халык, арба басып киткән түмгәкне яңадан өяргә керешкән кырмыска күчедәй, мәш килеп үзенең илен-көнен торгызырга, рәткә кертергә тотынды. Зөфәр дә тормышка аеруча бер сусау һәм дәрт тоеп, яңа нигезен үзе

теләгәнчә әйбәтләп, матур, нык итеп кору уе белән яна башлады. Иң элек ул, кар китеп, җир кипкәч тә, йорт-җирен төзәтү, тәртипкә китерү эшенә кереште. Башта ике оста яллап, капка-коймасын өр-яңадан эшләтте; койма буй җитмәслек биек, капка бик таза булып чыкты. Сабитовларның эчке дөньясын хәзер берәр ярыктан сыңар күз белән дә карау мөмкин түгел иде. Аннары малярлар китертеп, капка-коймасын сарыга, өй түбәсен яшелгә буятып җибәрде. Йорт бердән яктырып, матурланып китте. Зөфәр эшкә барышлый да, кайтышлый да ихтыярсыздан тукталып, сөенеп-сокланып карап торудан тыела алмый иде – аның йорты бөтен урамына ямь биреп тора хәзер!..

Ихтимал, күрше-тирәне һәм үткән-сүткәннәрне йортның матурлыгыннан да бигрәк моның хуҗасы кем, кайдан таба ул барысын да дигән сорау кызыксындырадыр. Ләкин бер дә гаҗәпләнерлек нәрсә юк монда: дәүләт заводы һәм аның меңләгән эшчеләрен тәэмин итәргә тиешле ОРСы, сугыш китергән бөлгенлеккә карамастан, бик бай иде әле. Андый байлыктан бер тәэминатчының, әйтик, түбәсен буярлык кына олиф белән буяу табу ни тора ул?! Диңгездән бер тамчы гына!

Бер үк вакытта Зөфәр каяндыр бер бакчачы карт табып китерде дә шуңа җимеш бакчасын рәткә кертергә кушты. Мулла кыяфәтле, чиста, йомры гына карт башта бакчаның түренә хәтле узып, игътибар белән бөтенесен бер карап чыкты; чыккач, кулларын артка куеп: «Ай-һай, тәмам хәшәрәтләр оясына әверелгән икән бу!» —дип, башын селкеп торды; бары шуннан соң гына бишмәтен салып, җиңен сызганып һәм саплы пычкы, кәкре пәке белән коралланып, эшкә тотынды. Һәр агачка ул ни өчендер «мәхлугым» дип дәшә иде, нидер сөйләнә-сөйләнә аны әйләнеп карап чыга иде, шуннан соң һич кызганмыйча «мәхлук»ны ботарларга тотына иде. Бер-ике көн эчендә карт кисеп ташлаган ботаклардан рәшәткә буенда зур бер өем хасил булды. Зөфәр баштарак, бу мөселман бакчаны утынга кисеп бетерә бит, дип, чынлап курка калды. Ләкин иртәрәк борчылган икән, картның ботарлавыннан соң һәр агач, һәр куак җыйнакланып, бер-берсеннән аерылып, бөтен бакча эче иркенәеп, яктырып китте. Карт кечкенә ак сакалын кәкре бармаклары белән астан өскә тараштырып, Зөфәргә әйтте: «Менә, кем, Зөфәр туган, бакчаңда хәзер җил дә йөрер, кояш та күп, җимеш тә мул булыр, Алла насыйп итсә!» – диде һәм тагын агачларны ничек карарга, кайчан ашларга, кайчан сугарырга кирәклеген әйткәләп төшендерде дә, шуның белән эшен беткәнгә санап, тиешле акчасын алып китеп тә барды.

Зөфәр, билгеле, өенең эчен дә җиһазларга онытмады. Шәп-шәрә алты бүлмәне тутырырга күп кирәк иде әле, шулай да комиссионный магазиннардан төрле мебель алгалап, аннары Гайсә карт аша да кайбер нәрсәләр тапкалап, өен төрле иштәге җиһазлар белән бераз тутырды.

Әлбәттә, Зөфәр күреп тора, бу әле зәвыклы, культуралы итеп җиһазлау түгел, өе аның антиквар кибетенә охшабрак китте, ләкин хәзергә башка чара юк, заманасына күрә ярап торыр, диде.

Таибә абыстай улының берьюлы бу хәтле эшләр актарып ташлавына эченнән генә бик сөенеп йөри иде. Ул моны егетнең, ниһаять, өйләнергә җыенуыдыр инде дип, үзенчә яхшыга юрады. Тик менә улының күздә тоткан берәр кызы бармы-юкмы, булмаса – кайдан, кемне табарга – шушы хакта борчылып уйлана иде. Бу турыда ул зур улы Зарифка да сүз салып куйды. Таибә абыстай фикеренчә, мондый йортка ни җитте кызны гына җитәкләп китерергә ярамый, тапкач-тапкач, яхшы нәселдән, мал кадерен белердәй тырыш, уңган, инсафлы кыз табарга кирәк.

Зөфәр үзе өйләнү мәсьәләсендә тәгаен бер фикергә килмәгән иде әле, шулай да вакыт җиткәнлеген сизә иде инде. Менә күпме эшләр башкарды, күпме акча тотты, йорты эчтән дә, тыштан да әнә ничек матурланды, әмма шуңа карамастан Зөфәр чын канәгатьләнү тоя алмый, чөнки аңа һаман нидер җитми кебек, йорты да элеккечә һаман буш, җансыз кебек иде. Күрәсең, бу зур йортка җан өрер өчен, бу йортта чын тормыш татып яшәр өчен тагын бер яңа кеше – җанга якын яшь, чибәр хатын кирәктер инде. Шунсыз тормышы да, күңеле дә түгәрәкләнмәячәк, ахрысы.

Ләкин шушы уйларга бирелеп йөргән чакта гына Зөфәрнең аяк асты кинәт кенә бер тетрәп куйды. Хикмәт шунда, Зөфәр йорт тирәсендәге эшләрен бетерүгә, һич көтмәгән җирдән госконтроль кешеләре килеп, ОРСның бөтен системасында зур ревизия үткәрергә керештеләр. Билгеле инде, көне-сәгате белән дөнья мәшәкатьләре, өйләнү кайгылары Зөфәрнең башыннан берьюлы очтылар. Дөрес, коелып төшмәде ул, ревизияләрне күргәне бар, ләкин, бердән, бу юлы аның бик капыл булуы, икенчедән, заводтагы «актив» саналып йөргән, бик күпне белүче һәм бик төпченергә яратучы кайбер кешеләрнең ревизия эшенә тартылуы Зөфәрне шактый нык борчуга салды. Болар инде мондый чакта, җәнлек ауларга катнашучылар шикелле, гаҗәп зур тырышлык күрсәткән булалар. Аннары алар, шушы җирдәге кешеләр буларак, әллә кайчангы эшләрне дә исләрендә тоталар һәм казып чыгарырга әзер торалар. (Ә казып чыгарырлык эшләр юк түгел иде.) Шуның өстенә тагын алар, шул ук активистлар, Зөфәр кебек кешенең мәгыйшәтен дә яхшы ук беләләр бит; аның былтыр гына зур йорт сатып алуын да, быел шуны яңартып йөрүен дә ревизия ясаучылар колагына бик әйбәтләп тукыячаклар, билгеле.

Зөфәр үзе материаль җаваплы кеше түгел, аның эше —ОРСның сәүдә точкаларына гомуми җитәкчелек итү, шул точкаларны товар белән тәэмин итеп тору; теге яки бу точкада растрата, җитмәүчелек ачылса, аны Зөфәрдән таптырмаячаклар. Моның өчен җавап бирүче «точка» мөдире яки директоры бар. Ләкин шул директордан: «Кая куйдың, кем белән ашадың?»

– дип буып сораулары мөмкин. Зөфәр өчен һәртөрле күңелсезлекләрнең менә шул яктан килеп чыгуы ихтимал.

Әлбәттә, вак-төяк растрата, җитмәүчелекләр генә аны куркытмый. Тик менә күмәкләшеп «ашау» бик хәтәр нәрсә. Мондый нәрсәне ача калсалар, эшне, һичшиксез, тикшерү органнарына бирәчәкләр. Мәсьәлә бик җитдиләшеп китәчәк. Дөрес, эшнең аңа кадәр барып җитмәве дә мөмкин, чөнки, бердән, ОРС җитәкчеләре үзләре үк моңа юл куймаска тиешләр, ник дисәң, алар үзләре дә кардан ак, сөттән пакь түгелләр; икенчедән, әлеге точкалардагы материаль җаваплы кешеләр дә, ямьсез эшләр ачыла калса, бөтен гаепне бары үз өсләренә алырга тиешләр, ник дисәң, совет законы үзе үк ялгыз ашаучыларга – җәзаның рәхимлерәк, ә күмәкләп ашаучыларга катырак булуын кисәтеп тора. Аннары сәүдә работниклары арасында язылмаган бер кагыйдә бар: бәлагә юлыккан кешене исән калучылар һәрвакытта йолып алырга тырышалар. Һәм, әйтергә кирәк, күп кенә очракта бу тырышып йөрүнең теге «бичара»га шактый зур файдасы да тиеп куя: йә ул бөтенләй котылып кала, яки инде, китеп барса да, «сәфәре» бик кыска булып чыга.

Ләкин шулай да бу исәпләргә генә таянып, бөтенләй үк гафил булып торырга ярамый иде. Зөфәр ревизия килгән көнне үк кичен, абыйсы аша, Хәмит дустын үзенең өенә чакыртып алды. Түр бүлмәгә бикләнеп утырдылар. Зөфәр дустын ОРСтагы хәлләр белән кыскача гына таныштырды һәм аның алдына ике төрле бурыч куйды: беренчедән, ревизия ясарга килүчеләрнең баш кешесенә берәр төрле юл табып булмасмы? Ягъни ниндирәк кеше ул, кемнең сүзе үтә аңа, гомумән, җайга килердәй кешеме?

– Кыскасы, үзең аңлыйсың инде, – диде Зөфәр, – ревизиянең нәтиҗәләре бик каты булмаган тәкъдирдә, без ул иптәшне бервакытта да онытмас идек. Икенчедән, промтовар магазины директоры Сөнгатуллинны һәм азык складының мөдире Волковны бүгеннән калмый кисәтеп куярга кирәк: кулларында запас акча тотсыннар, ревизиянең нәтиҗәләре тәмам ачыкланмыйча торып, аңлатма бирергә ашыкмасыннар, гомумән, телләрен тешләп кенә йөрсеннәр. Алар моны үзләре дә белергә тиеш, әлбәттә, ләкин исләренә төшермичә ярамый, чөнки каушап бутала һәм бүтәннәрне бутый башласалар, соңыннан эшне төзәтүе авыр булачак. Әйләнгән саен минем янга йөгереп килмәсеннәр, ә сүзләре булса, синең аркылы гына җиткерсеннәр. Мин, положением буенча, ревизиягә булышучы кеше хәзер – шуны онытмасыннар. – Сүзен тәмамлап, Зөфәр ахырдан гына әйтеп куйды: – Только син, дус кеше, ревизор мәсьәләсендә сак була күр, яме!

– Өйрәтмә син мине, – диде Хәмит, дорфа гына. Аннары бераз уйланып торгач, дәртле генә башын күтәрде.—Ярый, миннән эш калмас. Конечно, ревизорга юл табу ансат булмаячак,

ну ничево, сукыр тычкан эзеннән йөреп карыйк әле, шәт, берәр йомшак җирен капшарбыз. Ревизор да чуеннан түгелдер әле.

Зөфәр, көлемсерәп, кулын сузды:

– Алайса әйттем-бетте?

Хәмит аның учына сугып алды:

– Әйттем-бетте! Мать якасын!

Һәм ул, сугышчан задание алган оперуполномоченный төсле, такыр башына зәңгәр кепкасын каплады да, кәкре аяклары белән нык-нык басып, җитез генә чыгып та китте.

Зөфәр ревизия барышында үзен бик тыныч тотты. Башта ул ревизия кешеләре белән, дәрәҗәсен саклап, әмма ачык йөз күрсәтеп, әйбәт кенә сөйләште, аларга кулыннан килгән ярдәмне күрсәтергә әзер торуын белдерде, исәп-хисап эшләрендә булышыр өчен үзенең аппаратыннан кешеләр дә бирде.

Ревизия өч көн дәвам итте. Барлык точкаларда да товар калдыгын исәпкә алдылар, соңгы ярты ел эчендә күпме товар кайткан, күпмесе сатылган, күпме акча тапшырылган – шуларны исәпләп чыгардылар. Ләкин ревизияне алып бару бик авыр иде, чөнки сугыш шартлары аркасында сәүдә-тәэминат эшләре гаять катлауланган иде. Азык-төлек белән тәэмин итү карточный система буенча бара, товарларга ике төрле бәя яшәп килә. Шуның нәтиҗәсендә бухгалтерия исәп-хисабы да бик катлауланып, чуалып беткән иде. Әмма шуңа карамастан өч көнлек ревизия дә ОРСның сәүдә точкаларында шактый зур кимчелекләр ачып өлгерде. Монда бозу да, әрәм-шәрәм итү дә, читкә тарату да, турыдан-туры урлау да бар иде. ОРС җитәкчеләренең шул точкалар аша үз-үзләрен тәэмин итү белән чамасыз шөгыльләнүләре дә бик ачык күренеп тора иде. Кайбер материаль җаваплы кешеләрнең өстенә зур гына суммаларга барып баскан җитмәүләр дә чыкты. Әмма бу кешеләр югалып калмадылар: каяндыр ниндидер документлар, актлар табып чыгардылар, шуның белән өсләренә чыккан җитмәүләрне киметә алдылар, ә калган кадәресен шунда ук акча кертеп капладылар.

Кыскасы, ревизия башта бик каты тотынса да, соңга таба аның эше акрынлап йомшара барды. Нәтиҗәдә, беркем өчен дә баш китәрлек зур куркыныч тумады. Ревизиянең йомгакларын бер генә сүз белән болай дип әйтергә мөмкин: кимчелекләр күп, ОРС малын ашау бар, әмма зур җинаятьләр юк.

Дөрес, ревизия озаграк һәм тирәнрәк казынса, тотып судка бирерлек җинаятьләрне дә тапкан булыр иде. Ләкин аңа алай озак казынырга вакыт бирмәделәр: югарыдан кемнеңдер боерыгы буенча эшне кызу тотарга мәҗбүр булдылар. Бу Хәмитнең «сукыр тычкан эзеннән йөрү» нәтиҗәсе булырга тиеш иде.

Шулай итеп, ОРСның кайбер җитәкчеләре һәм сәүдә работниклары өстенә җыелган куе кара болыт яшьнәмичә-күкрәмичә генә таралды. Берәүне дә чатнатып сукмады. Тик Зөфәр өчен генә ул бөтенләй үк хәвеф-хәтәрсез үтеп китмәде. Әле ревизия башланмас борын ук аның, ниһаять, фаш ителүен, януын көтеп торучылар булган иде. Егет бөтен сугыш буенча ОРСны имеп ятты бит, бу юлы койрыгына басарлар дип уйлаганнар иде. Аннары ревизия барышында әлеге завод оешмаларыннан катнашучылар да аның берәр кыек эшен чокып чыгарырга тырышып карадылар, ләкин тырышып та берни таба алмадылар. Дөресен генә әйткәндә, андый нәрсә Зөфәрнең гамәлендә юк та иде, чөнки ул бервакытта да үз инициативасы, үз кулы белән дәүләт малына үрелмәде. Нигә ул? Сәүдә бүлеге мөдиренә, бигрәк тә аның кебек оста коммерсантка, сугыш шартларында үзен тәэмин итәрлек кенә юллар булай да, Аллага шөкер, җитәрлек иде.

Инде теге яки бу точкада зур гына товар җитмәү фактлары ачылган икән, моны да аңардан таптырып булмый. Моның өчен җаваплы кеше – точканың директоры, бары аңардан гына сорап була. Ә директор ОРС малын кая куйган, кем белән ашаган – ул аны инде үзе генә белә. Ул әйтмәсә, син аңардан келәшчә белән дә тартып алалмыйсың.

Кыскасы, Зөфәр Сабитовның ОРСны имеп килүе, күпләр фикеренчә, бәхәссез булса да, аңа тотып бәйләнерлек сәбәпләр табылмады.

Ләкин шулай да берише каныгучылар ревизия ачкан бөтен кимчелекләр һәм җитешсезлекләр өчен барлык гаепне аның өстенә генә аударып, ахыр чиктә шул сылтау белән аны урыныннан бәреп төшерергә чамалап карадылар. Әйе, Зөфәр, сәүдә бүлеге мөдире буларак, сәүдә точкаларындагы хәлләр өчен мораль җаваплы кеше, бу хакта ревизия актында да бик ачык әйтелгән, һәм шунлыктан аңа куркыныч юк түгел иде. Дөрес, завод һәм ОРС җитәкчеләренең аңа мөнәсәбәтләре яхшы, аңа зур белгеч итеп карыйлар һәм аның белән бик хисаплашалар иде. Юкка гына бит аны сугыш буена броньнар биреп, саклап тотмадылар. Бу юлы да алар аны якларга һәм сакларга тиешләр, чөнки, бердән, ул аларга бик кирәк кеше, икенчедән, кимчелекләр өчен бары бер ул гына гаепле түгел икәнлеген бик яхшы белеп торалар.

Ләкин тормыш бик катлаулы һәм четерекле нәрсә. Кайчагында кешеләр берәүгә дә әйтергә ярамаган эчке исәпләрдән чыгып, бәлагә таручыга кинәт кенә мөнәсәбәтләрен үзгәртәләр һәм, ярдәм кулын сузасы урында, аны төпкә үк батырып җибәрәләр. Төрлесен көтәргә мөмкин.

Шуны әйтергә кирәк, Зөфәргә каныгучылар арасында аеруча бер килешмәс усалы, үткен тешлесе бар иде. Бу кеше сугыш ахырында гына фронттан кайтып, заводның кадрлар бүлеге начальнигы булып эшли башлаган сыңар куллы майор Симаков иде. Аның кыяфәтендә үк инде

утны-суны кичкән чын хәрбиләргә хас кырыс бәйсезлек, кискенлек һәм кыюлык сизелеп тора иде. Тыныч хезмәт кешесе булып алгач та ул, гел баштанаяк хәрби формада, погоннарын да салмыйча, күкрәгенә барлык орден колодкаларын тагып йөрде. Тик китель кесәсенә тыгып йөргән буш җиңенә карап кына аның сугыш белән, ниһаять, алыш-бирешен бетергән кеше булуын белергә мөмкин иде.

Менә шул кеше Зөфәрне беренче күрүдән үк яратмады, ничектер беренче караштан ук ул аның кем икәнлеген сизеп алгандай булды. Иң элек ул Зөфәрне күргәч тә: «Бу ак калач төсле егет монда ничек сакланып яткан», – дип бик гаҗәпләнде, аннары, якыннанрак белгәч, сәүдә бүлеге мөдире турында бик катгый һәм бик ямьсез нәтиҗә ясап куйды: «Тыл күсесе! Халуй!..» Билгеле инде, ул Зөфәрнең гадел, намуслы кеше булуына тамчы да ышанмады һәм бөтен җирдә, бөтен кеше алдында аны әнә шулай – «Күсе! Халуй!» дип кенә атап йөртә башлады.

Зөфәр үзе дә сыңар куллы майорның аңа ничек каравын бик тиз белеп алды, әмма артык гаҗәпләнмәде – мондый начар карауларны аның татыганы бар иде инде. Әлбәттә, кадрлар начальнигының аңа бүредәй каравы бик ямьсез, бик күңелсез нәрсә, эчне бик пошыра бу, ләкин Зөфәр, моңа артык игътибар итмәскә тырышып, элеккечә тыныч кына йөри бирде. Ул хәтта эченнән генә, усалланып: «Бу герой фронттан алып кайткан гадәтләрен куып маташа, бөтен кешене дә үз аршынына үлчәмәкче була, тукта, менә безнең мондагы казанда ныграк кайнасын әле, үзе үк тиресен алыштырыр», – дип тә уйлый иде. Әмма, шулай уйласа да, сөлек булып эченә оялаган ямьсез шомлану аңа барыбер тынгылык бирми иде.

Ревизия нәтиҗәләрен партбюро утырышында тикшергәндә Симаков Зөфәрнең чын йөзен үзенчә бик нык фаш итәргә тырышты. Хәрбиләрчә бик туры басып, йодрыклаган таза кулы белән һаваны кисеп-кисеп сөйләде ул:

– Солдат йөрәгем белән сизеп әйтәм мин, сезнең ул Сабитов дигән кешегез ОРСны имеп ятучы бер торгаш булырга тиеш. Ревизия ачкан безобразиеләрне ул белмәгән, аның катнашы юк, дигән сүзгә мин һич ышанмыйм. Белмиме соң!.. Белү генә түгел, директорлар белән бергәләп ашаган ул! Фактлар юк, дисез. Ә өч йөз егерме биш меңгә йорт сатып алу факт түгелмени? Шушы үзе генә дә аның кем икәнлеген фаш итмимени? Һәм, гомумән, ул, минемчә, ышанычлы кеше түгел, җинаяте булса да, булмаса да, аны ОРСта калдырырга ярамый, алыштырырга кирәк. Берәр честный коммунистны куярга кирәк аның урынына. Безнең ОРС системасында халык малын имеп, баеп ятучыларга урын булмаска тиеш!

Майор Симаковның бу кискен, әмма дәлилләргә бик йомшак сүзләренә кушылучылар булды, дәшми калучылар булды, каршы чыгучылар да табылды. Дөрес, Зөфәр Сабитовны берәү дә честный кеше ул дип якламады, ләкин күпләр фикеренчә, аны партиясез булган өчен генә яки

йорт сатып алган дип кенә урыныннан алып ташлауны таләп итүе дә читен иде. Кеше күптән эшләп килә, күренеп торган җинаяте юк, димәк, тотылмаган – карак түгел!..

Кыскасы, сүзләр күп булды, фикерләр икегә бүленде, һәм менә иң ахырдан гына, ниһаять, завод директоры телгә килде. Моңарчы мәсьәләгә үзенең мөнәсәбәтен берничек тә сиздермичә, йончыган кыяфәт белән, күзләрен яртылаш йомып утырган бу аттай зур гәүдәле кеше салмак кына сүзен башлауга һәркемнең игътибарын биләп алды:

– Мин Зөфәр Мөбарәкович Сабитовның, – диде ул, – безнең ОРСта ничек эшләвен дә һәм, иптәш Симаков әйткәнчә, күпме «имүен» дә беләм. Һәм мин моны чагыштырып, икенче төрле әйткәндә, балансировать итеп карыйм: кайсысы шуның, яхшы хезмәтеме, начар гадәтеме, кешенең эшчәнлегендә алдан йөри? Кайсысы безгә күпме файда, күпме зарар китерә? Бары шуннан соң гына нәтиҗә ясыйм. Бераз үткән хәлләргә кайтып карыйк. Менә 1942 ел. Цехта эшчеләр ачтан егыла. Заводның нормаль эшләве өчен, фронт заказларын вакытында үтәү өчен, беренче чиратта, азык кирәк... Корыч та бар, энергия дә бар, станоклар да әйләнеп тора, әмма азык җитми, азык җитмәгәч, производительность юк, заданиеләр үтәлми. Менә шундый гаять авыр бервакытта Зөфәр Мөбарәкович безне азык белән тәэмин итүдә гаҗәп зур уңганлык, тырышлык, оперативность күрсәтте. Бу, иптәшләр, патриотик хезмәт иде, һич арттырып әйтмим. Чөнки азыкның вакытында табылып, кайтып торуы безгә фронт заказларын срогында үтәп барырга бик зур ярдәм итте. Ләкин шул ук вакытта каяндыр районнардан вагонлап азык китерткән кеше үзе өчен берәр түшкә ит яки күпмедер анда он алып калмаган дисезме? Юк, алган ул. Тотмасак та без моны беләбез. Җинаятьме бу? Әлбәттә, җинаять. Ләкин хикмәт шунда, тәэминат эшендәге кешеләрнең күбесе, үз кулларында булгач, алмыйча, ашамыйча түзмиләр. Чөнки шартлары шундый. Ә менә аның урынында бүтән бер кеше Сабитов шикелле үк эшли белер идеме – монысы икенче мәсьәлә. Кайберәүләр ашыйлар да эшеңне дә харап итеп китәләр – без андыйларны да күп күрдек. Шулай булгач, безгә нишләргә: Сабитовны куаргамы яки сакларгамы тиеш идек? Әлбәттә, сакларга тиеш идек, чөнки ул безгә бик кирәк кеше иде.

Директор зур шәрә башын артка таба сыпыргалап, аз гына тынып торды да янә салмак кына сүзен башлап китте:

– Менә хәзер кайберәүләр Сабитовны урыныннан бушатуны таләп итәләр. Беспартийный, диләр, ышанычлы кеше түгел, диләр, ОРСны имеп ята, диләр. Билгеле, үз кулында булгач, имә дә торгандыр, безнең хәзерге сәүдә системасында моның өчен мөмкинчелекләр бик күп әле... Ләкин Сабитов үзе, конкрет алганда, күпме ашаган, без моны белмибез, кулыбызда материал юк, һәм без аны тотып судка бирә алмыйбыз. Ә болай гына, фәлән-фәсмәтән дип кенә чыгарып җибәрсәк, аны ун җиргә чакырып алачаклар. Беспартийный

дип тормаячаклар. Хәер, аның беспартийный булуы яхшырак та, чөнки партийный башы белән «ашаса» тагы да әшәкерәк булыр иде, – диде директор, мәгънәле генә елмаеп. – Менә ни өчен мин иптәш Симаков таләбе белән һич килешә алмыйм. Юк, Сабитов кебек тәҗрибәле работникны чыгарып җибәрергә ярамый. Ул әле безгә бик кирәк. Ләкин мин моның белән Сабитовның кимчелекләренә күз йомыйк, гаепләрен кичерик дип әйтергә җыенмыйм. Һич юк... Менә ревизия ачкан җитешсезлекләр турында без аңа нык кына кисәтү ясарга тиешбез. Мин әле үзем бу хакта аның белән сөйләшәчәкмен. Ә инде безнең ОРСта, гомумән, законсыз «ашаулар», урлаулар бетсен өчен җәмәгать контролен көчәйтергә кирәк. Сәүдә работникларын куып бетерү ул иң ансат юл, ә менә аларны тәрбияләү, аларның эшенә көн дә күз-колак булып тору – бусы инде шактый авыр юл, әмма бердәнбер дөрес юл...

Билгеле инде, берәү дә аңа каршы чыкмады, хәтта Симаков та, чыраен сытып, телен тешләргә мәҗбүр булды. Завод директорларының авторитетлары һәм хокуклары гаять зур иде, аларның әйткәннәре закон булып йөри иде, һәм Симаков, яңа кеше булса да, моны бик яхшы белә иде. Әлбәттә, директорның әйткәннәренә карап кына аның Зөфәр турындагы фикере һич үзгәрмәде, ләкин бюрода утыручылар барысы да, ихластанмы-түгелме, «хуҗа» сүзенә кушылгач, хәзергә аңа да тыелып калудан башка чара юк иде. Бөтен хикмәт шунда ки, директорның ашыкмыйча, җайлап кына, әмма бик төпле итеп сөйләгән сүзләренә каршы куярлык дәлилләре аның җитәрлек түгел иде – ә Зөфәр кебек оста яраша һәм яшеренә белгән карьеристны ялангач кул белән генә якасыннан алып булмаячак икән. Димәк, вакыт кирәк, факт-лар кирәк... Ләкин бу ихтыярсыз чигенү Симаковның солдат табигате өчен бик авыр иде булса кирәк, гүя менә бөтен кырыс кыяфәте белән ул: «Туктагыз, мин сезгә әле мактаулы коммерсантыгызның кем икәнлеген бер килеп күрсәтермен!» – дип әйтеп тора иде.

Шулай итеп, майор Симаковның кисәк кенә сикереп сугарга азаплануыннан Зөфәр Сабитовка берни дә булмады, директор үзе аны яклап калдырды, куркыныч үтте, яңадан тыныч көннәр килде. Билгеле инде, ул соңыннан барлык тәнкыйть-кисәтүләрне берсүзсез кабул итте, эшен яхшыртырга вәгъдәләр бирде, ләкин шуның белән бергә үзе өчен генә тиешле нәтиҗәләрне дә ясап куйды: моннан соң бик сак булырга, Симаков кебекләр тирәсендә бик уяу йөрергә, «хуҗаларга» тагы да ныграк елышырга, үз кулы астындагы кешеләргә катырак торырга, ә чамасыз комсызлана башлаган кайберәүләрдән котылырга да кирәк булачак. Кыскасы, эш интересы белән баш интересын гел бергә килештереп барырга тиеш ул. Оста җитәкчелекнең сере шунда бит!

Асылда исә егетнең корган планнары, теләк-уйлары берсе дә үзгәрмәде. Һичшиксез, моннан соң да аның тормышы иске эздән барачак, ягъни әйбәт кенә эшләп, үз рәхәте өчен яшәргә тиеш булачак.

Зөфәр уенча, бу бер аның гына кагыйдәсе түгел. Барлык кешеләр дә тормышта шул кагыйдә буенча яшиләр. Уку, белем-һөнәр алу, зур урынга, карьерага омтылу —барысы да кешенең иркенрәк, мулрак, рәхәтрәк яшәргә теләвеннән килә. Хәтта кайберәүләр, денем өчен түгел, көнем өчен, дип, партиягә дә керәләр – Зөфәр андый бәндәләрне дә белә. Кыскасы, тырыша-тырмаша, этләшә адәм баласы.

Билгеле инде, Зөфәр, кешенең яхшы тормышка омтылуын, шуңа ничек тә булса ирешүен бары аның үз эше, үз сәләтеннән, үз тырышлыгыннан гына килсә килә ала дип карый иде. Барлык кешеләр өчен дә ниндидер бертигез бәхетнең булуына һәм шул уртак бәхетне бергәләп табаргамы яки ясаргамы мөмкин булуына ул ышанмый иде.

Ләкин ул бер нәрсәне бик яхшы белеп тора: яшәр өчен, тормышны үзең теләгәнчәрәк корыр өчен, һичшиксез, агым уңаена агарга кирәк, заманга аркылы килүдән сакланырга кирәк, һәрвакытта уяу, тыйнак, мыштым булырга кирәк. Бу, аныңча, үзең өчен яшәүнең иң дөрес юлы!

Зөфәр, көн яктысы күрми торган ярканат кебек сукыр булса да, төлкедәй сизгер кеше иде. Аңардагы бу сизгерлек заманга да яраклашып, үз максатына ирешергә дә тырышып яшәү аркасында гаҗәп камилләште. Эшен бик шома йөртте, куркынычны алдан күрә белде, хәтәр-хәвефләрдән тайпылып кала алды.

Менә хәзер дә бит куркыныч узып китте. Димәк, ул эшен оста алып бара белгән, үзен яхшы яктан күрсәтә алган. Киләчәктә дә әнә шулай акыллы булырга кирәк. Хезмәте аның әйбәт, бәрәкәтле урын, тик артык комсызланып кына китәргә ярамый. Үзара гына әйткәндә, совет сәүдәсенең мөмкинчелекләре бик зур аның; мәсәлән, теге яки бу товарга кытлык булып торган чагында сәүдә работнигының килер чыганагы һәрвакытта иркен булачак. Аннары бит инде аның, крепость шикелле, нинди чибәр, зур йорты бар. Бу йорт хакына нәфесне бераз тыярга да була. Тик менә шул таза йорт эчендә аңа, удельный князь шикелле, үзе теләгәнчә рәхәтләнеп торырга гына язсын иде.

**XII**

Беркөнне Зөфәрләргә эштән кайтышлый Зариф абыйсы килеп керде. Зөфәр залдагы түгәрәк өстәлдә ниндидер эш кәгазьләре карап, счет салып утыра иде. Зариф зал ишеген ачып, башын сузып кына исәнләште:

– Нихәл, туган?

– Ә, абый, исәнме, әйдүк! – диде Зөфәр, урыныннан кузгала башлап.

– Юк, син утыр, утыр, – диде Зариф, ашыгып. – Мин әни янына кереп чыгам әле.

Һәм ул, елт итеп, эчке бүлмәләргә таба китеп тә барды, Зөфәр аның кулындагы һәрвакыт үзеннән калдырмый йөртә торган кара сумкасын гына күреп калды.

Зөфәр, бу сумканы абыйсы кулында гел генә күрсә дә, аңа һич игътибар итми иде. Хәлбуки кара сумка бервакытта да буш килми – Зариф аңа ни дә булса салып китерә һәм әнисе кулына биреп калдыра иде. Моны алар бары икесе генә беләләр, хәтта Зөфәрдән дә яшерә торганнар иде. Бүген дә Зариф кара сумкасына дүрт баш каракүл тиресе салып китерде һәм, шуларны әнисенә тапшырыр өчен, тизрәк Зөфәр яныннан узып китте. Ә Таибә абыстай бу тиреләрне, элек китерелгән бүтән әйберләр янына кушып, яшереп куярга тиеш... Шулай итеп, абзый кеше Зөфәр өенә, хуҗаның үзенә сиздермичә генә, динамит ташыган шикелле, хәрәм мал ташый иде.

Бер ун-унбиш минут вакыт узгач, Зариф яңадан энесе янына әйләнеп керде:

– Аптырыйм мин сиңа, Зөфәр! – диде ул, кәефле тавыш белән кычкырып. – Өеңә кайткач та баш ватып утырасың. Нигә кирәк ул, төкер син аларга, кантор эше канторда калсын. Монда менә дәүләтеңнең рәхәтен күр!

– Булмый бит, абый! – диде Зөфәр, ялкау гына елмаеп. – Канторда тынычлык бирмиләр, кайбер эшләрне менә шулай өйгә алып кайтып, аулакта карап, тикшереп утырырга туры килә.

– Анысы шулайдыр инде... Ә нәрсә тикшерәсең соң?

– Ревизия материалларын өйрәнеп утырам. Бездә күптән түгел ревизия булып узды бит, әйткән идем шикелле.

– Ие, әйткән идең, бугай. Йә, ничегрәк узды соң ревизия? Алай-болай сиңа кәсәфәте тимәдеме?

– Ничек дим? – Зөфәр җиңелчә генә иңбашын җыерып куйды. – Бераз тиде инде, ләкин алай аяктан егарлык булмады.

– Бирсен Алла!

– Күбрәк кеше аркасында, билгеле.

– Һе, шулаймы? Кара син! Нәрсә, сиңа төртеп күрсәтүчеләр табылдымыни?

– Андыйлар да булды. Аннары кайбер точкалардагы директорларның зур гына гөнаһлары да ачылды.

– Нишләгәннәр алар?

– Нәфесләренә хуҗа була белмәгәннәр, менә шул. Ә миңа алар өчен җавап бирергә туры килде.

Зариф хәйләкәр генә күзен кысып һәм көлемсерәп энесенә бер карап куйды:

– Ие, – дип сузган булды ул. – Нәфес – шайтани нәрсә инде ул. Аны тыю бик читен шул!

– Читен булса да тыярга кирәк. Шайтан муенына бер атланып алса, базга да илтеп төшерүе бар.

– Сиңа әйтүе ансат ул, менә мондый йортка хуҗа булып алгач ни... Аннары нәфес дигәнең кешедән күрмәли котыра бит әле ул!

– Син, абый, әллә уйнап, әллә чынлап сөйләшәсең, аңламыйм! – диде Зөфәр, җитди генә. – Ни дигән сүз ул, кешедән күрмәли? Юк, кешегә карап түгел, заманга карап эшне йөртә белергә кирәк. Менә мин сиңа да саграк булырга, итәгеңне җыебрак йөрергә киңәш бирер идем.

– Ә мин сак булмыйча нишләгән?

– Ул кадәресен үзең беләсеңдер инде... Тик шуны исеңдә тот: сугыш тудырган «хөрлекләр» бетәчәк, хөкүмәт сәүдә эшендә дә тәртип урнаштырачак, ә ревизияләр моннан соң отыры ешрак һәм катырак булачак.

– Бик әйбәт, без аңа каршы түгел, – диде Зариф, исе китмичә генә. – Әмма ләкин мин бит комиссионныйда эшлим, дәүләт сәүдәсенә бер катнашым да юк.

– Комиссионныйны да син үзең ачмагансың, аның да хуҗасы бар. Шул ук дәүләт. Так что, без барыбыз да бер хуҗа алдында җаваплы.

Зариф җилкәсен кашып алды:

– Анысын беләбез инде, безнең совет җаныңа да, малыңа да хуҗа инде ул. Аның күзенә чагылудан Ходай үзе сакласын! Ярый, киңәшең өчен рәхмәт! Ә хәзер тераска чыгып, бер хозур кылып утырыйк әле, сиңа әйтәсе важный сүз дә бар иде.

– Нинди сүз? Шушында гына әйтеп булмыймыни?

– Әни анда чәй хәзерли калды, ә минем сүзем табында гына сөйлисе тәмле сүз ул!

Зариф абзый, мыек очын бөтереп, энесенә хәйләкәр генә күз кысып куйды. Зөфәр, торып, кәгазьләрен газета белән каплады да, абыйсына ияреп, террасага чыкты.

Бакчаның чынлап та бик хозур чагы иде. Ул тәмам куерып, матурланып өлгергән. Аның беренче җимешләре – чияләр кара-кучкылланып, кура җиләкләре тулып, кызарып килә инде. Иртә өлгерә торган алмаларга да сусыл сарылык йөгерә башлаган. Хәзер шуларның чак сизелерлек хуш исе бөтен бакчага җәелеп бара. Менә күп тә үтмәс, бу татлы хуш ис күрше йортларга, урамга да тарала башлар... Әйе, Зөфәр бакчасының көннән-көн көчлерәк җимешләнә, пешә, аңкый торган чагы җиткән хәзер.

Зариф абзый террасага чыккач, бакчага бер күз салу белән, кычкырып: «Сөбеханалла!» – диде һәм пиджак төймәләрен ычкындыра-ычкындыра ашыгып җиргә төште, сукмак буйлап китте. Әүвәл карт әнис төбенә туктап, аякларын аера биреп, инде бер як бите түгәрәкләнеп кенә

кызара башлаган алмаларга сокланып карап торды. Аннары койма буенарак узып, чия агачы янында тукталды. Владимировский сорт дип йөртелгән бу шактый биек агачны итәгеннән очына кадәр чия сырып алган иде. Уңса да уңар икән! Абзый, хәйран калып, башын селкеп торды, мәшалла, диде, күз генә тия күрмәсен, диде, шуннан, чияләрнең кара-кучкылланып өлгергәннәрен генә озын-нечкә сабакларыннан өзеп-өзеп, бисмилла әйтеп, капкаларга һәм авызына килгән әче су белән бергә тәмләп-тәмләп кенә йотарга тотынды. Төшләрен, әрәм булмасын дигәндәй, учына гына төкереп барды. Шулай бераз авыз иткәннән соң, җирән мыекларын сыпыргалады да, Зөфәргә борылып, гаҗәпләнү катыш серле генә итеп сорады:

– Нишләтәсең инде син бу байлыкны?

Зөфәр көлемсерәп ике кулын җәйде:

– Нишләтим? Тозлап булмас инде. Ашарбыз, вареньесын кайнатырбыз, киптерербез, ә калса тагын, бәлки, сатарбыз да.

– Сата калсаң, башта миңа әйтергә онытма, яме! —диде Зариф, энесенә ничектер мәгънәле генә карап.

– Что син, абый! – диде Зөфәр, нигәдер бераз кызарып. – Кем дип белдең мине? Рәхим итеп кил, теләгән кадәр җый, аша, барыбызга да җитәр әле монда.

– Ә, шулаймы? Монысы өчен рәхмәт!.. Мин дә бит сине сынар өчен генә әйткән булдым. Бая нәфесне тыярга кушкан идең, тукта, мин әйтәм, моның үзенеке ничегрәк икән, дим, шуны гына беләсем килде. Үпкәләмә тагын!

– Юк ла! Вак мәсьәлә, сынарлык та, сынатырлык та эш юк монда!

– Алай димә. Кеше бит баеган саен комсызлана бара.

Зөфәр дәшмәде. Алар кире өйгә таба борылдылар. Зариф җиңел адымнар белән алдан китте, ә Зөфәр, кулларын артка куеп, аның артыннан иярде. Ул абыйсының тап-такыр кырган башына һәм кызыл җилкәсенә карап, уйланып барды. Абыйсы аңа бик шәбәеп, җиңеләеп, хәтта яшәреп тә киткән төсле күренә иде. Өсте-башы аның һәрвакыт чиста һәм пөхтә, бите гел ит кенә ашап торган кешенекедәй кызыл да шоп-шома, майлы иреннәрен шәрә калдырып кырган нечкә җирән мыекларын егетләрчә бөтереп кенә йөртә, кыскасы, бөтен торыш-кыяфәте яхшы аранда солыда гына торган тук, уйнак алашаны хәтерләтә – күрәсең, абзыйның комиссионный магазинда эшләре чынлап та бик шәптән бара иде. Ләкин Зөфәрне бер нәрсә гаҗәпләндерә: аерым тора башлагач, абзый кеше ни өчендер аңа үзенең эше-гамәле турында бер дә сөйләмәс, элеккечә киңәш-уңаш итмәс булды. Үзенчә сер сынатмаска маташуымыдыр инде? Аннары, очрашып сүз чыкканда да, менә бүгенгедәй, гел төрттереп тә үчекләп сөйләнә башлады. Ахрысы, абзыйның эчен, үзенә сиздермичә генә, көнчелек кимерә иде. Борынгылар сүзе – җан

кардәш булса да, мал кардәш түгел, шуның зәхмәтедер инде бу, дип, Зөфәр борчылып уйланырга мәҗбүр булды.

Террасада сеңелләре Хөршид чәй урыны әзерләп йөри. Өстендә аның кыска итәкле ситсы күлмәк, аягында озын оек белән үкчәсез туфли. Тасмасыз, калын гына итеп үргән ике толымының берсен алга, күкрәге өстенә салындырып куйган. Аны әтиләре мәрхүмгә охшаган, диләр. Күзләре дә, кашлары да, чәчләре дә чем-кара. Матур, сылу булмакчы. Ләкин бик чирләшкә ул, шуңа күрә үзенә һаман әле бер дә ит кунмый. Гомумән, абыйларының игътибарын үзенә һич җәлеп итмичә, өнсез-мыштым гына үсеп килә бу кыз бала. Кышын укый, җәен әнисе яныннан китми, тик бу йортка күчкәч, бакча түренә китеп, шунда ялгызы китап укып утырырга гадәтләнде.

Өйдән Таибә абыстай бик борынгыдан сакланып килгән, шуңа күрә үзе генә тотып йөртә торган, авызы җиз кыршаулы, зәңгәр пыяла шикәр савытын күтәреп чыкты. Карчык чыгуга, Зариф аңа кычкырып дәште:

– Әни, чия-кураларыгыз тәмам өлгереп җиткән икән ләбаса, мин сиңа әйтим! Биргән икән Ходай үзе дә уңышны, ничек җыеп бетерерсез?

– Ие шул, – диде Таибә абыстай, сабыр-тыйнак кына. – Аллага шөкер, үзебезнең җиләк-җимеш өлгергән көнне дә күрдек... Син менә киленне балалары белән безгә җибәрер идең. Килеп, җыешып, вәринҗә кайнатышып китсен иде.

– Үләт җыксын ла килененңне, – диде Зариф, кинәт кызып. – Аның аркасында шушындый дәүләтнең өлешенә керә алмыйча калдым.

– Хатын сүзенә иярмиләр аны... Хатынның, ни аның, чәче озын, акылы кыска – белмичә әйтмәгәннәр.

– Дурак булдым шул, дурак булдым! Теге вакытта әйтми-сөйләми генә, шалт Хупҗамал дигәндәй, кул сугып, эшне өзеп кенә куясы калган да бит, ни, дурак булдым шул!

– Үкенмә ул хәтле, абый! – диде Зөфәр дә, сүзгә кушылып. – Бәлкем, хәерлегәдер. Йортсыз тормассың әле.

– Тормыйм, Аллаһы бирсә, тормыйм! – диде Зариф, урындыгы өстендә киерелә биреп. – Бераз мая гына җыйыйм. Ие, менә шул... Канешно, синеке кебек пулат кирәкми миңа, иллә мәгәр, шушындый бакчалыны эзләп табачакмын.

Таибә абыстай – диндар карчык, пошынып кына әйтеп куйды:

– Алладан сора, игелеккә язганы булсын, диген.

– Анысы шулай инде, әни, шулай... Алланы да онытмыйбыз аны... Ие, э-э!

Чәйгә утырдылар. Эссе көн инде сүрелеп, сүнеп бара. Кояш каршыдагы кыеклар өстеннән генә сузылып карый, агач башлары талгын гына яна, терраса алдындагы георгиннар, нәркизләр, резедалар да, хәл кергәндәй, иелгән башларын күтәрә төшеп, ачылыбрак киткәннәр, алар әйләнәсендәге кичләрен генә терелә торган ак тәмәке чәчәкләреннән искиткеч хуш ис тарала башлаган – бал урынына чәйгә кушып эчәрлек! Тик бөтенләй тынып, оеп калган һава гына шактый бөркү иде, шуңадыр инде куе чәй аеруча тәмле, эчкән саен сусын ачыла гына бара. Маңгайга, муенга, беләкләргә таза тир бәреп чыга... Башта ук пиджагын салып утырган Зариф абзый, ниһаять, изүен чиште, подтяжкасының ике ләмкәсен дә төшерде, җиңнәрен тартып куйды. Таибә абыстай да яулыгын чишеп, артка кайтарып бәйләде, тир белән чигәсенә ябышкан чал чәчләре аның көмешләнеп елтырады. Тик Зөфәр генә тирләмәде, киндер күлмәгенең чиккән якасын да ычкындырып тормады, ул чәен суытып кына эчә иде.

Бер-ике чынаяк эчкәч тә, Таибә абыстай кызына әйтте:

– Хөршид, сиңа җитеп торыр, кызлар чәйне күп эчмиләр. Бар, әнә бакчада йөр! Ятканда мин сиңа каймак бирермен. Болай да кибеп барасың.

Зөфәр шунда ук чамалап алды: димәк, җитди сүз булачак. Чөнки әнисе берәр сүз башларга уйласа, иң элек Хөршидне шулай табыннан озата иде.

– Әни, алайса мин Люсяларга керәм, китап алыштырасым бар, – диде Хөршид, кыюсыз гына урыныннан торып; аңа табын яныннан куылгандай китү һәрвакыт бик уңайсыз, кыен була торган иде.

Таибә абыстай аның артыннан каты гына әйтеп калды:

– Озак торасы булма!

Хөршид өйгә кереп киткәч тә, Зариф абзый сорап куйды:

– Лусә дигәне кем?

– Күршедәге инвалид кызы, – диде Таибә абыстай, авыр гына көрсенеп. – Болай ипле, юаш кына кыз үзе, тик атасы, мәлгунь, бик эчә... Хөршидне бер дә кертәсем килми дә бит, нишлисең, күршедә бүтән тиңнәре булмагач...

– Эчә дигәннән, Гайсә картның эше кәкәй бит, – диде Зариф абзый, ияк астын кашып.

– Ни булган аңа тагын?

– Ни булсын, бер эчеп кайтуында подвал баскычыннан мәтәлеп төшкән. Хәзер кан косып ята икән... Сәкинә хәлен белергә кергән иде. Базлары караңгы, карчык сукыр, картын карый алмый, прәме харап, ди эшләре...

Зөфәр борчылып абыйсына карады.

– Ник больницага салмыйлар, тизрәк больницага салырга иде...

– Врач килгән, караган да киткән. Кузгатырга ярамый, дип әйтә, ди... Салып торуның кирәге калмаган, ахрысы... Убшем, очлый тормышын бывший доверенный!..

– Менә сезгә гыйбрәт! – диде Таибә абыстай, улларына алмаш-тилмәш карап.

Зөфәрне бу хәбәр шактый пошынып уйланырга мәҗбүр итте. Йорт алганда арадаш булып йөргән картка ул, вәгъдә иткән акчаның яртысын гына биреп, калганын соңыннан бирермен, дигән иде. Ә карт яңадан килеп, соранып йөрмәде – әнә ни булып киткән икән үзе белән... Кеше кайгысы – киштәдә. Шуңа Зөфәрнең вөҗданы кузгалып, ничектер эче сызланып куйды.

Аз гына уңайсыз тынлыктан соң Таибә абыстай, ниһаять, Зөфәргә карап сүз башлады:

– Менә абыең бик мөһим бер хәбәр белән килгән бит әле, тыңлыйк үзен.

– Кемгә? Сиңамы, миңамы? – диде Зөфәр, сүлпән генә.

– Ишеткәч, белерсең! – диде Таибә абыстай, коры гына. – Йә, сөйлә, улым!

Зариф, урындык аркасына ята биреп, тамак кыргалап куйды:

– Ыһ-һым. И-е... Мин бит әле сиңа бик шәп бер кыз димләмәкче булып торам, туганкай!

– Рәхмәт! Ләкин мин синнән кыз сораганым юк шикелле.

– Йә, сез адәм төсле генә сөйләшегез әле. Көлке эш түгел бу, – диде Таибә абыстай, ачулана башлап.

– Дөрес, әни, – диде Зариф, шунда ук килешеп, һәм Зөфәрнең тезенә орынып алды. – Менә нәрсә, туган, син башта әйбәт кенә тыңла, аннары инде үз сүзеңне әйтерсең.

– Пожалысты, мин тыңларга әзер, – диде Зөфәр, башын кагып, ә Зариф ашыгып сүзен дәвам иттерде:

– Сиңа бит инде башлы-күзле булырга бик вакыт. Өйләнү синең алда торган иң важный бер эш хәзер, шулай түгелме?.. Менә без дә әни белән гел шул турыда кайгыртабыз. Монда синең әйтеп торуың да кирәкми, әниең белән бертуган абыең сиңа бу эштә булышмаса, кем булышыр!.. Синең кайгың – алар кайгысы, менә ничек бит ул! Дөрес әйтәмме?

– Ышанам. Ләкин син мәсьәләгә якынрак кил әле, абый! – диде Зөфәр, каядыр бакча түренә карап.

– Мәсьәләгәме? Мәсьәлә шул инде: өйләнер өчен кыз табарга кирәк. Дөрес бит?

– Дөрес булса кирәк.

– Бигрәк тә синең кебек асыл егеткә кызның да асылын табарга кирәк. Шулай түгелме?

– Монысы белән дә килешәм.

– Менә инде, алайса, мин сиңа кызның нәкъ әнә шундый җәннәт хурыдай асылын таптым да, беләсең килсә!

– Кем ул?

– Гамбәр. Гамбәр туташ! – диде Зариф абзый, ничектер серле-тантаналы итеп.

Зөфәр, башын чайкап, ихтыярсыз көлемсерәп куйды:

– Гамбәр?! Да-а! Беренче ишетәм мондый сәер исемне...

– Кругом килгән инде! – диде Зариф, кулларын җәеп. – Кругом! Төс-баш ягыннан да, әдәп-әхлак ягыннан да, әти-әнисе ягыннан да – ну, менә бер генә дә килмәгән җире юк туташның! Ышанасыңмы?

– Кайдан таптың соң син аны?

Зариф абзый урындыгын Зөфәргә якынрак тарта төште.

– Аның әтисе, Җиһанша абзый, безнең системада эшли. Әнә теге Татсоюз астындагы зур комиссионныйда, алтын-көмештән приемщик булып... Бик кәттә кеше. Күп сөйләмәс, әмма дөньяны күп күргән, бик күпне белә үзе... Әле теге елларны торгсинда, аннары сугышка чаклы ювелирторгта эшләгән. Череп аккан бай булырга тиеш... Ийе... Менә беркөнне мин моның янына кергән идем. Канторкага таянып, сөйләшеп торабыз. Магазинны әбидкә яптылар. Шул чакта өф итеп киенгән яшь кенә бер сылу кыз килеп керде... «Әти, менә сиңа ашарга китердем»,—ди бу Җиһанша абзыйга. Зур сумкасыннан ап-ак эскәтергә төргән кечкенә кәстрүлне алып, әтисе алдына куйды... Карап торам мин бу кызга, ну менә, Зөфәр туган, шундый да чибәр, шундый да сөйкемле булыр икән адәм баласы!.. Күзләре чем-кара, кашлары нечкә, керфекләре озын, түбән генә карап тора үзе... Ә буе-сыны – гөл сабагы инде, гөл сабагы! Килмәгән бер генә җире дә юк!.. Озак тормады кызый, әтисеннән күпмедер акча сорап алды да чыгып китте. Кәстрүлдә күпереп торган пәрәмәчләр булып чыкты. Җиһанша абзый мине дә кыстады... Ие, э, э! Кыз чыгып киткәч, Җиһанша абзыйга әйтәм, күз тимәсен, бик матур туташыгыз бар икән, мин әйтәм. Әйе, ди Җиһанша абзый, төпчегебез бусы, менә үстереп җиткердек инде, ди... Шул чакта кылт итеп син искә төштең, Зөфәр, син!.. Карале, дим, эчемнән генә, әгәр сиңа насыйп кыз булып куйса бу туташ, дим, ә, шайтан алгыры?! Моңардан да шәпне эзләп торасы да юк ич!.. Дөресме?.. Шулай да Җиһанша абзыйдан читләтеп кенә сорашам: укыймы, эшлиме, әнисе янында гына торамы?.. Әтисе әйтә, урта мәктәпне бетерде, ди, аннан частный рәвештә музыкага өйрәнде, ди, хәзергә әле өйдә генә тора, ди. Мин әйтәм, җиткән кызны озак асраудан мәгънә юк, Җиһанша абзый, берәр әйбәт кенә кеше кулына тапшырырга кирәк, дим. Анысы шулай инде, ди Җиһанша абзый, үзебез дә ул хакта уйлаштырабыз, язганы тагын ни булыр, ди... Һи, уйламыйлармы соң инде, тим паче ир затына менә мондый кытлык бер заманда?.. Беләсеңме, Зөфәр туган, бу эшкә чынлабрак тотынганда, берьюлы ике куянны атып булачак монда. Кызлы да, маллы да булып калырсың, валлаһи! Төпчекләре бит, бүтән юк, уйлап-чамалап кара!.. Вәт менә сиңа шул!

Зариф абзый тавышын бер көчәйтеп, бер әкренәйтеп, дәртләнеп һәм тирләп бу озын сүзен, ниһаять, сөйләп бетергәч, ике куллап битен-күкрәген кат-кат җилләде дә суынган чәенә иелде. Зөфәр абыйсының сүзләрен тыштан артык кызыксыну күрсәтмичә тыңлады, сораулар бирергә ашыкмады һәм ни уйлаганын сиздермичә тыныч кына утыра бирде. Таибә абыстай, шуңа бераз пошынып булса кирәк, дәү улының сүзләрен куәтләргә ашыкты:

– Улым, абыең әйткәннәрне ишеттең инде, – диде ул, җитди генә сүзен башлап. – Син яхшы гына колак салсаң иде. Аллаһы Тәгалә үзе безгә шулай туры китереп, юл ачып тормыймы? Белмәссең, тәкъдиргә язылган булса. Мин үзем дә белешеп-сорашып карадым. Бер дә күңелгә ошамас нәрсә ишетмәдем. Бик әйбәт гаилә, бик әйбәт кешеләр икән. Кызның әнисе, кем, Мәфтүхә ханым да бик җитеш гаиләдән чыккан, бик уңган, бик акыллы бер хатын икән. Ире Җиһанша турында менә абыең әйтте инде. Андый дөнья күреп, бөтенлек белән торган кешеләрнең баласы да, билгеле, күркәм, инсафлы булырга тиеш. Йә, ни дисең, улым?

Зөфәр, иңбашын җыерып, сүз таба алмыйчарак торды:

– Ни диим? Кайгыртуыгыз өчен рәхмәт! Ләкин бу мәсьәләдә әти-әнисенә карап кына хөкем итеп булмый ич! Ул кыз минем өчен, руслар әйтмешли, капчыктагы мәче бит әле. Күрмичә-нитмичә!

– Сөйләп бирдем ич инде: кыз – мировой, үзе шундый нәгызь!..

– Анысы тагын ничек була?

Зариф абзый куллары белән нидер ишарәләп күрсәтмәкче булган иде дә, әнисенә карап алгач, тыелып калды.

– Юк, шулай да әллә ничек кенә килеп чыга әле бу,—диде Зөфәр, ихтыярсыз елмаеп. – Борын заманның байбәтчәсен өйләндерергә җыенган шикелле...

Таибә абыстай, хәтере калып, улының сүзен бүлде:

– Берәү дә сине алай өйләндерергә җыенмый. Ә димләү ул ата-бабадан килгән йола. Кыз сайлаганда әти-әнисенә дә, нәсел-нәсәбенә дә караганнар борын акыллы кешеләр. Оясында ни – очканында шул, дип белми әйтмәгәннәр.

– Ярый, әни, үпкәләргә торма. Мин бит аларның берсенә дә күз йоммыйм. Тик кызны күрмичә торып, мин сезгә бернәрсә дә әйтә алмыйм.

– Алайса син кызны карап карарга ризасың? – диде Зариф, ашыгып.

– Ничек инде ул «карап карарга?» – диде Зөфәр, чыраен сытыбрак. – Сыер яки кәҗә түгелдер бит ул?.. Минемчә, танышып карарга кирәк. Анда да бик уңай җае чыкса гына...

– Май кап! – диде Зариф һәм әнисенә, дәшмә дигәндәй, күз кысып куйды. – Мин моны шундый итеп җайлармын, ничек танышканыңны үзең дә сизмичә калырсың, энекәш!

– Әлбәттә, Гамбәр туташ өчен дә бу шулай булырга тиеш!

Һәм Зөфәр: «Ярый, җитеп торыр бу хакта!» – диясе килгәндәй, кисәк кенә урыныннан торып, бакчага төшеп китте. Зариф аның артыннан кычкырып калды:

– Һи, туган, аны гына беләбез инде. Курыкма, бөтенесе шито-крыто булыр!

Зөфәр, бакча түренә узып, тәбәнәк кенә бер эскәмиягә утырды. Әйтергә кирәк, бу өйләнү турындагы сөйләшү аңа шактый авыр-ямьсез тәэсир итте. Ничектер, менә әнисе белән абыйсы аның үтә шәхси эшенә дорфа рәвештә тыгылалар, аны ирексезлиләр кебек тоелды, һәм аңарда үзлегеннән диярлек каршы торасы, тыңлыйсы килмәү хисе уянгандай булды. Ләкин бу мондый очракларда тумыйча калмый торган, әмма иртәме-соңмы үтеп китәчәк вакытлы бер хис иде. Асылда исә Зөфәр бүгенге сөйләшүнең әһәмиятен дә, кирәклеген дә бик яхшы аңлый иде. Өйләнү – аның алдында торган зарури бер мәсьәлә ул. Аңардан качып булмаячак.

Бакча түрендә ялгызы гына утырып, бераз тынычлангач та ул ихтыярсыздан Гамбәр туташ турында уйлана башлады... Гамбәр туташ! Бу исемнең үзендә үк ниндидер хыялны котырта, күңелне тарта торган бер сихер бар кебек. Мондый исемле кыз чынлап та бик оригинальный булырга тиештер инде ул... Абыйсы да үтереп мактады бит: хур кызы кебек, диде, күзләре зур, керфекләре озын, диде, түбән генә карап тора, диде, аннары авызына сулар китереп: «Бик нәгызь», – дип тә җибәрде. Нәрсә була икән ул... нәгызь? Бик җиткән, бик пешкән дип әйтүе булдымы инде, Ходa белсен!..

Төпчек кенә кыз икән, музыкага да өйрәнгән икән. Бәлки, чынлап та гөлчәчәктәй гүзәл, нәфис, оялчан, назлы бер туташтыр ул, Гамбәр?! Юк, аңа игътибар итмичә һич мөмкин түгел.

Шулай ук әти-әнисе турындагы сүзләр дә игътибарга бик лаек. Торгсин, ювелирторг, алтын-көмеш – боларның берсен дә исәптән чыгарырга ярамый, әлбәттә. Һичшиксез, уйларга, чынлап уйларга кирәк бу көтелмәгән димләү турында. Ихтимал, табылырга торган бәхет шул үзедер инде...

Шулай уйлады, шулай хыялланды Зөфәр, һәм күңеленнән, Гамбәр, Гамбәр дип акрын гына кабатлап утырган чакта кинәт бик ачык булып, йөрәген сискәндереп, аның күз алдына Рәшидәсе килеп басты.

## XIII

Ул аны күптән күргәне юк иде инде. Соңгы тапкыр алар апрель ахырында – Рәшидә язгы чәчү өстендә концертлар биреп йөрер өчен филармония бригадасы белән авылларга чыгып китәр алдыннан очрашканнар иде. Хәзер июль уртасы, димәк, өч айга якын вакыт үтеп киткән. Рәшидә, билгеле, әллә кайчан ук кайткан булырга тиеш. Ә Зөфәр моңарчы аны табарга да,

күрергә дә тырышып карамады. (Рәшидә исә соңгы вакытларда үзе башлап шалтыратмый иде инде.)

Шуны әйтергә кирәк, Зөфәр Рәшидәне үзе өчен лаек хатын дип тапмагач һәм аңа өйләнү дигән нәрсә күңелендә булмагач, ике арадагы мөнәсәбәт шулай акрынлап өзелер дигән өметтә йөри иде. Ул моны, билгеле, бик тели дә иде, шуңа күрә, күпме генә озак вакыт узмасын, ничек тә очрашудан, күрешүдән тыелырга тырыша иде. Ләкин шуның белән бергә ул аны һич оныта алмый иде, сагына иде һәм менә вакыт-вакыт, бөтен салкын исәпләрне бер читкә ташлап, тизрәк Рәшидәне табарга, аның белән бергә булырга ашкына иде.

Рәшидә Зөфәрнең болай бер ераклашып, бер якынаеп йөрүен ничектер сизеп бетерми иде. Иң элек ул үзе, еш кына гастрольләргә чыгып киткәнлектән, икешәр-өчәр ай югалып тора иде. Аннары очрашкан чакларда Зөфәр аны чын сагыну белән иркәли-сөя иде, ә озак вакыт күренмичә торуын эше-мәшәкате бик күп булу белән аңлата иде. Шулай итеп, Рәшидәнең күңелендә уяна башлаган бөтен шикләре, үпкәләре тарала да бетә иде. Ләкин шулай да яшь ханым соңгы вакытларда беркадәр үзгәрә төште; электәге кебек очрашу шатлыгыннан күбәләктәй очынып тормый ул, Зөфәрнең сөюләрен артык дәртләнмичә ничектер эчке бер тыелу белән кабул итә – гомумән, күңелендә гел борчып торган авыр уе бар шикелле, үзен шактый моңсу-басынкы тота иде. Зөфәр аңардагы бу үзгәрешне сизмичә калмады, әмма барыбер киселәсе сынык булгач, ул хакта борчылып та тормады.

Инде менә горизонтта Гамбәр туташ күренүгә, ул кинәт Рәшидәне исенә төшерде. Алай гына да түгел, яшь туташ юньләп күзенә дә чагылырга өлгермәс борын, каршысына, гүя аны каплап, бөтен сокландыргыч килбәте белән Рәшидәсе сүзсез-тын гына калкып чыкты. Бу хәлгә Зөфәр үзе дә гаҗәпләнә калды. Ләкин сәбәбен эзләп тормады, бары тизрәк аны күрәсе килде... Билгеле, салкын акыл белән уйлаганда Зөфәр моны теләмәскә, теләгән тәкъдирдә дә күрү-очрашудан һичшиксез тыелырга тиеш иде. Чөнки Гамбәр туташ белән танышырга торганда Рәшидәне күрү һәм сүнеп барган ялкынны яңадан көйрәтеп җибәрү аның өчен хәерлегә булмаячак иде. Әмма шуны сизсә дә, ул күрергә теләде, йөрәге белән генә түгел, хәтта акылы белән дә теләде, гүя менә Рәшидәне күрмичә торып, ул Гамбәрне дә дөрес аңламас, дөрес бәяли белмәс кебек иде.

Һәм кинәт туган бер тәвәккәллек белән ул филармониягә шалтыратып, Рәшидәне эзли башлады. Бары икенче көнне генә туры китереп, аның белән гадәтенчә җылы-йомшак кына сөйләште һәм сәгать өчләрдә Ленин бакчасында очрашырга сүз куешты.

Ул көнне Зөфәр эшеннән бик иртә кузгалды. Кечкенә кабинетын бикләп алды да, ишек төбендә утырган секретарь-машинисткага үзенең точкаларда буласын, аннары шәһәргә кайбер

эшләр белән китәсен, шуңа күрә бүген, ихтимал, кире әйләнеп килә алмавын әйтеп, чыгып китте.

Берничә сәүдә точкасында булып, андагы кешеләр белән сөйләшеп, тиешле киңәшләрен, боерыкларын биреп чыккач, ул ахырдан гына азык кибетенә кереп, аның мөдире аша үзенә бер шешә портвейн һәм бераз конфет, печенье кебек нәрсәләр төрдереп алды да, сәгать икеләр тирәсендә ОРС машинасына утырып, шәһәр үзәгенә китеп барды... Ни өчендер аны менә хәзер Рәшидә белән булачак очрашу беркадәр дулкынландыра иде. Сагынуы бик җиткәнгә күрәме, әллә бүгенге очрашуга аеруча бер әһәмият биргәнлектәнме, ул юл буенча шул хакта гына уйланып барды. Рәшидә бүген аның күзенә ничегрәк күренер, үзен ул ничегрәк тотар, аңа, Зөфәргә, ничегрәк карар? Күрешмәгәнгә шактый вакыт үтеп китте бит, ачуланмасмы, үпкәләмәсме икән?.. Тик менә очрашкач, Рәшидәне кая илтергә? Зөфәр моны уйлап-уйлап та хәл итә алмаган иде әле. Хәмит дустын кичә таба алмады, бүген дә эшкә барышлый иртән иртүк аңа керсә дә, туры китерә алмады – ялгызак егет өендә бөтенләй кунмаган булып чыкты. Ачкычын да калдырып китмәгән. Димәк, Рәшидәне бүген ияләшкән урынга алып барып булмаячак. Ә каядыр алып барырга кирәк.

Кольцога килеп җиткәч, Зөфәр машинадан төште дә, шоферга кире кайтырга кушып, үзе җәяүләп кенә Ленин бакчасына таба менеп китте. Көннең нәкъ үзәге – бик эссе вакыты иде, таш стеналардан, тротуардан бөтенләй ут бөркелеп тора. Зөфәр күләгә яклап кына атласа да, бакчага җиткәнче тәмам әлсерәп, тирләп чыкты. Юк, мондый җәһәннәм эссесендә шәһәр таптап булмас, дип уйлады ул, пошынып... Чынлап та, кая алып барырга соң?.. Әлбәттә, ул, өйләнмәгән ялгыз егет, яратып йөргән кешесен үзенең иркен, бай йортына алып кайтса да әллә ни гаеп эш булмас иде. Ләкин аны өйгә алып кайту, бигрәк тә әнисе карчыкка күрсәтү – бу мәсьәләгә җитди төс бирү, ә яшь ханымны ни беләндер өметләндерү булып чыгачак. Юк, болар берсе дә ярамый иде, билгеле... Аннары ул, Зөфәр, гомумән Рәшидәгә кайда, ничек торуын да ачып бетерергә теләми иде. Гамбәр туташка күрсәтү мөмкин булыр иде, ә Рәшидәгә юк, ярамый әле... Бик четерекле, идеалист хатын, әллә ни уйлавы мөмкин. Иң яхшысы —читтә, аулакта, күзгә-күз генә очрашу инде, әлбәттә.

Бакчага килеп кергәч ул, ерак китмичә генә, агач күләгәсендәге бер эскәмиягә барып утырды. Сәгатенә карады. Өч тулырга унбиш минут вакыт бар әле. Әгәр Рәшидә филармониядән туры гына килсә, әнә шул Куйбышев урамына караган капкадан килеп керергә тиеш. Тик соңга гына калмасын иде. Шәһәрдә Зөфәрне белүчеләр күп, йә берәрсе очрап, янында туктала башлар. Үткән-сүткәннәргә йөзен бик үк күрсәтмәс өчен ул, тезләренә таянып, иелебрәк утырды. Шул ук вакытта аның теге капкадан да күзен бер дә аласы килми иде. Кинәт борчылып

уйлап алды: әгәр шуннан Рәшидә, берәр сәбәп аркасында, килмичә калса, нишләр ул? Андый хәл була гына күрмәсен, югыйсә яңадан шалтыратырга, эзләргә, икенче бер вакыт билгеләргә туры киләчәк.

Юк, әнә ул үзе түгелме соң?.. Әйе, шул ич, шул, Рәшидә!.. Өстендә кыска җиңле, ачык изүле юка гына күлмәк, башында чуар ефәк косынка, аягында кызыл чүәк – үсмер кыздай кулындагы сумкасын селкә-селкә, вак-вак атлап, җиңел генә килә ул!

Зөфәр аны урыныннан торып каршы алды. Кызның сузган кулын кысып күреште дә, җибәрмичә сак кына тотып, янына утыртты һәм бер сүз әйтмәстән бик текәлеп, аның күзләренә, йөзенә, ачык муенына карый башлады. Рәшидәнең йөзе дә, муены да, ялангач беләкләре дә тигез генә булып шактый нык каралган иде – авыллар арасында озак йөреп кайтканга күрәдер инде бу... Хәтта ул ничектер ябыга да төшкән кебек иде. Тик шуңарданмы, әллә тар, юка күлмәк кигәнлектәнме, түшләре генә тагы да тулыланыбрак киткән төсле иде.

Зөфәрнең болай бер сүз дәшмичә, юри тикшереп чыккандай, бик сынап-текәлеп каравыннан Рәшидә уңайсызланып бер кызарды, бер елмайды, ахырда түзмәде – учы белән аның күзен каплагандай итте:

– Карамагыз инде ул хәтле... Миңа уңайсыз ич!

– Карыйм... Карамыйча булдыра алмыйм!

– Нишләп алай?

– Сагындым! – диде Зөфәр, тирән-татлы сулап.

Рәшидә кискен генә башын чайкады:

– Юк, ышанмыйм мин моңа!

– Ни өчен?

– Ни өчен дип... үзегез дә беләсездер инде... Сагынган кеше айлар буенча югалып тормый бит.

– Их, Рәшидә бәгырем! – диде Зөфәр, авыр көрсенеп. – Гаепләргә ашыкма син, менә сөйләрмен, үзең дә аңларсың!.. Ә хәзер безгә, вакытны әрәм итмичә генә, берәр җиргә бару турында уйлашырга кирәк.

– Нигә, шушында гына сөйләшеп утырсак ярамыймыни? – диде Рәшидә, ни өчендер Зөфәрдән күзләрен яшереп.

– Куйсана, Рәшидә, әллә нидә бер очрашып, моның кебек кеше йөреп торган җирдә ничек утырмак кирәк!.. Синең вакытың бардыр бит?

Рәшидә, туры җавап бирергә кыенсынган төсле, иңбашын җыерып куйды:

– Мәсьәлә вакытта түгел.

– Ә нидә соң?

Рәшидә башын тагы да ия төште, ә Зөфәр аның каралган ябык кулын зур учы белән йомшак кына сыйпап торды:

– Йә? – диде ул, әкрен-сак кына.

Рәшидәнең нечкә кашлары тартышып куйды, йөзе сытылыбрак киткәндәй булды:

– Беләсеңме, нигәдер күңелем тартмый, Зөфәр! – диде ул, ниһаять, ниндидер бер пошыну белән. – Шушында гына сөйләшеп утырыйк инде...

– Юк, булмый, акыллым! – диде Зөфәр, шунда ук аның газаплы икеләнүен сизеп. – Без монда сөйләшеп тә утыра алмыйбыз... Ярамый миңа монда... Аңла!.. Китик, сөеклем!

– Ә... кая соң?

Яшен тизлеге белән Зөфәрнең күңеленә гаҗәеп шәп бер уй килде:

– Беләсеңме кая? Идел аръягына. Киттекме? Минем бүген синең белән рәхәтләнеп бер йөрисем, су буенда, яланда буласым килә. Бәйрәм итәсем килә. Кич булганчы, төн узганчы, күпме теләсәң, шулкадәр! Мин бит сине сагынып үлә яздым, ышанасыңмы?.. Киттек!..

Һәм ул Рәшидәнең ризалыгын да көтмичә, көчләп дигәндәй, аны кулыннан тартып торгызды. Рәшидә карыша алмады, юк, карыша алмый иде инде ул Зөфәргә... Бигрәк тә Зөфәрнең бүгенгедәй чын ихластан якын итүен, бу хәтле кадерләргә, назларга, сөяргә ашкынып торуын ул бик сирәк күрә иде. Һәм менә төрле шикләрдән, кимсенүдән моңарчы газапланып йөргән, инде бүгенге очрашуда үзен салкынрак, тыйнаграк тотарга уйлап килгән Рәшидәбез, эченнән генә сыкранып булса да, аңа буйсынды, аңа иярде.

Бакчадан чыгып, аз гына киткәч тә Зөфәр узып баручы бер кара машинаны туктатты. Шофер белән бер-ике авыз сүз сөйләшү җитте – алар, шуңа утырып, Устьега таба китеп тә бардылар. Икесе дә бераз дулкынланганнар иде, һәркайсы эченнән генә үзенекен уйлый иде, шуңадыр инде, юл буенча сөйләшмичә бардылар, аннары шофер татар булып чыкмасын дип тә шикләнделәр, ахрысы.

Устьега барып төшкәч, Зөфәр әйтте:

– Карале, Рәшидә, безгә капкаларга да тегесен-монысын алырга кирәк булыр бит. Югыйсә ачыгып бетәрбез. Минем менә бу төргәктә вак-төяк нәрсә бар барын да, ул гына җитмәс. Әйдә, караштырыйк әле, берәр нәрсә тапмабызмы икән?

Алар азык-төлек сата торган лапаска таба киттеләр. Анда кыяр, помидор, йомырка алдылар. Зөфәр водниклар кибетенә кереп, аннан ярты кирпеч икмәк белән бер ит консервысы да алып чыкты. (Зөфәргә үз эшеннән канәгать булмыйча һич мөмкин түгел, чөнки кая гына

кермәсен, аны беләләр, ни генә сорамасын, шуны биреп чыгаралар иде...) Рәшидәнең сумкасында сеткасы бар икән, шуңа барысын әйбәтләп салдылар да яр буена юнәлделәр.

Халыкны Маркиз атавына кечкенә буксир сөйрәп йөрткән бердәнбер паром ташый иде. Паром яңарак кына аргы якка кузгалып киткән булып чыкты. Аны көтеп, вакыт әрәм итмәс өчен, Зөфәр берәүнең моторлы көймәсен яллады. Бу иске генә, озын гына, буялмаган бер көймә иде, нәкъ уртасында Нух заманыннан калган, майга-мазутка катып беткән чуен моторы тора иде. Шуның койрыгына Зөфәр белән Рәшидә сакланып кына кереп утырдылар. Көймәнең хуҗасы – ялангач өстенә брезент чалбар гына кигән яшь егет моторын терелтеп җибәрергә азаплана башлады: ниндидер бер тәгәрмәченә каеш бау урап, шуны бөтен көченә кинәт кенә бер тартты, ике тартты, өч тартты, шуннан соң гына мотор төтен атып төчкерергә, калтырарга, зырылдарга тотынды... Ниһаять, кузгалып киттеләр. Һәм көймә тип-тигез су өстеннән, чуртан шикелле, борынын сузып бара башлагач, Зөфәр белән Рәшидәнең дә кәефләре ничектер бердән күтәрелеп, җиңеләеп, яктырып киткәндәй булды. Аларга рәхәт, хозур иде. Рәшидә, нәкъ менә яңарак кына кимсенеп елаган балага сөенеч-шатлык кайткан төсле, бөтен күңеле белән аз гына моңсу, әмма рәхәт-куанычлы чын юану татый иде – Ходаем, янәшәндә генә сине яраткан кешең, аның җылы игътибары, бу якты, тыныч Идел, ниһаять, шушы әкәмәт иләмсез көймә – барысы, барысы да аңа бик тансык, кадерле түгелмени соң!.. Ә Зөфәрнең кәефен әйтеп торасы да юк; аеруча ул, юлга чykканнан башлап, гел уңышка гына очрап торуларына эченнән бик сөенеп бара иде. Юк, бу сәфәр, аныңча, бик әйбәт, күңелле булып бетәргә тиеш.

Маркизның эссе, ак комында кызынып ятучы яшь-җилкенчәкләр шактый күп иде. Шуңар күрә бу тирәдә тукталып тормыйча, алар атауның түренә үк уздылар. Шактый ерак китеп, куе таллыклар аша узып, ниһаять, бер ялгыз тирәк төбендә тукталдылар. Бик тыныч, аулак урын иде бу; кечкенә ачыклыкның тирә-ягы таллык, утырыр җире сирәк кенә үлән үскән такыр комлык — менә шунда, тирәк күләгәсенә газеталар җәеп, урнаштылар. Тик монда шактый бөркү иде, Зөфәр утыргач та кепкасын салып ташлады, бил каешын чиште, ак күлмәгенең кыек якасын чишеп җибәрде. Ул Рәшидәгә дә бераз «бушанырга» кушты. Рәшидә бары күлмәк путасын гына ычкындырды. Шуннан соң Зөфәр, Рәшидәнең тарсынып маташуын берьюлы бетерергә теләп булса кирәк, сүзсез генә аны иңбашыннан кочаклап алды да, башын артка каера биреп, иреннәреннән үбәргә тотынды. Рәшидә башта каршылык күрсәтмәде, тик бераздан гына Зөфәрне үзеннән этәреп, тураеп утырды. Ул нигәдер бик кызарды, күзләре дә дымланып киткәндәй булды, ләкин бер сүз дә әйтмәде.

Аннары, шулай ук сүзсез генә, алып килгән төргәкләрен чишеп, азык-төлекләрен уртага таратып салдылар. Бары Зөфәр портвейн шешәсен чыгаргач кына Рәшидә көлемсерәп әйтеп куйды:

– Син эчми торган кеше бит, ничек әле бу алай булды?

– Их, гүзәлем, сахрага чыгып та эчмәсәң, җир йотар!.. – диде Зөфәр, егетләнеп; аның бүген ваемсыз-шат буласы һәм Рәшидәне дә шул ипкә көйлисе килә иде. – Синең хакка – бик рәхәтләнеп! Тик менә нәрсәгә салып эчәбез, вот проблема!

Алар, бер-берсенә карап, көлешеп алдылар.

– Безнең әле консервыны ачарга пычагыбыз да юк,—диде Рәшидә.

– Ә анысы бездә бар, – диде Зөфәр һәм чалбарының арткы кесәсеннән сөяк саплы, әллә ничә җәпле, өр-яңа пәке чыгарып сузды.

– Һу, болай булгач, барысын да эшли алабыз, – диде Рәшидә, ихтыярсыздан балаларча куанып. – Ачып бир әле миңа... Хәзер мин «бокал» ясыйм.

Ул арадан зуррак кыярны сайлап алды да, шуның бер башын кисеп, эчен чокып чыгарды.

– Менә бу сиңа булыр!

– Ә үзеңә?

– Хәзер үземә дә ясыйм! – Һәм җитез генә икенче кечерәк кыярның да эчен чокып ташлады. – Тик утыртып кына булмый, – диде ул, көлеп.

– Ничево, без «бокалларны» кулдан төшермәбез!

Рәшидә калган кыярларны, помидорларны, икмәкне турады, бер-ике йомырканы әрчеп, Зөфәр алдына куйды. Зөфәр исә, аның иплe-өлгер эшләвенә соклангандай, бераз карап торды да пичәтле шешәдән «бокалларга» портвейн салды.

– Йә, нәрсә өчен эчәбез, уңганым? – диде ул, «бокалын» күтәреп.

Рәшидә, нечкә кашларын җыера төшеп, аз гына уйланып торды.

– Нәрсә өченме?.. Әйдә, күңелләрнең шушы аяз күк төсле саф, керсез булуы өчен эчик!

– Һо, син бик биеккә сикердең, җанкисәгем! – диде Зөфәр, көлеп. – Ну что ж, күккә дә менәргә була. Ә шулай да мин, практичный кеше буларак, башта синең саулыкка эчәргә телим. Ярыймы?

– Ихтыярың. Рәхмәт!

Кыярларны чәкештерделәр дә эчеп җибәрделәр. Аннары бик тәмләп ашарга тотындылар. Ачykканнар да икән, бер дә бер-берсеннән тарсынып тормадылар. Бераздан Зөфәр тагын «бокалларны» тутырды. Эчтеләр. Тагын бертын ашадылар. Эчми эчкән Зөфәргә җитә калды – тамырлары буйлап рәхәт җылы таралды, йөзе аз гына алсуланып кызарды, күзләре чак кына

томанлана төште, ә башында, әйтерсең төрле төстәге күбәләкләр очкаларга тотынды – әллә нинди гаҗәп матур, акыллы уйлар килә башлады. Аңа бик рәхәт, бик күңелле иде. Каршысындагы Рәшидәгә – аның каралган йөзенә, уңа төшкән кашларына, кайтарылыбрак торган керфекләренә, ялангач беләкләренә, сузып утырган төз аякларына, кыскасы, бөтен-бөтен җиренә – ул сөеп, кабынып һәм бәяләп карый иде. Йә, бу беткәнче бирелеп, онытылып сөймәслек хатын түгелмени? Нәфис, сылу, ягымлы, әрсез түгел, дорфа түгел, аз гына үпкәләүчән, аз гына киреләнүчән, әмма иркә, назлы, татлы, шайтан алгыры! Аннары ул бөтен барлыгы белән аныкы бит, хуҗа бит ул аңа! Бер сүзенә, бер теләгенә дә каршы килә алмый бит ул аның!.. Йә, рәхәт-бәхеттә йөзәр өчен тагын ни кирәк?

– Ә хәзер күккә дә ашарга була! – диде Зөфәр, өченче тапкыр «бокалын» сузып.

Рәшидә каш астыннан күз сирпеп кенә аңа карады, уйчан-сөйкемле генә елмайды, ләкин сүз әйтмичә башын гына кагып куйды. Кыярына да ни өчендер иренен генә тидереп алды. Зөфәр аның янына шуышыбрак кырын ятты һәм беләгеннән сыйпап, пошынып сорады:

– Сөеклем, нигә син бүген тын утырасың, сөйләмисең бер дә?

– Синнән көтәм әле мин, – диде Рәшидә аңа.

Зөфәр белә аның нәрсә көткәнен. Аклануы читен, билгеле, ләкин бүгенге рәхәтлек хакына ялганны чын итеп, үзең дә шуңа ихластан ышанып сөйләргә мөмкин иде. Һәм ул кырын яткан җиреннән Рәшидәнең әле беләгеннән, әле аркасыннан йомшак кына сыйпап, әкрен-киеренке тавыш белән үзенең аны, Рәшидәне, никадәр сагынуын, гел генә аны уйлап йөрүен, тик соңгы атналарда эшенең бик күп булуын, төрле мәшәкать-борчулар кичерүен, менә яңарак кына бераз шулардан бушануын һәм бушагач та тизрәк аны күрергә ашкынуын, бүгенге очрашудан әйтеп бетергесез шат, бәхетле булуын сөйләп бирде. Әлбәттә, ул нинди эш, нинди мәшәкатьләргә таруын җентекләп сөйләп тормады – бу кадәресе, аныңча, кирәксез, артык иде. Рәшидә исә бүтән хатыннар кебек төпченә белми иде, кешедән шикләнергә, кешенең ялганын тотарга яратмый иде. Бигрәк тә яраткан-якын кешесенә аның бик ышанасы килә иде. Менә хәзер дә ул Зөфәрнең һәр сүзенә ышанып утырды, аның өч ай буена югалып торуын бүтән бер сәбәптән булыр дип күңеленә дә китермәде. Ул нәкъ элеккечә, балаларча беркатлылык белән, Зөфәр мине ярата бит дип уйлады, шуңа эченнән генә куанды һәм йөрәгендә күптән төерләнеп торган сызлавыгы бераз кими төшкән кебек булды... Ә нинди сызлавык соң бу? Хикмәт шунда, Зөфәр мине ярата дип ышанса да, ул аның ни өчен яратуын, нинди максат белән, озаккамы, әллә вакытлы гынамы яратып йөрүен белми иде, һәм бу билгесезлек аны бик борчый, бик уйландыра иде. Айлар буенча күрешмичә тору нәтиҗәсендә бу уйлану-борчылулар аның йөрәгендә әнә шулай сызлавыклы бер төер булып укмаша иде.

Ләкин менә очрашкач, ул Зөфәрнең җылы, йомшак мөгамәләсенә, гүя ихластан сөйләгән сүзләренә эри дә китә һәм аның дәртләнеп назлавына, аның теләгенә бер дә каршы тора алмый иде. Дөрес, соңыннан ул еш кына бу йомшаклыгы өчен әрнеп үкенә, бик кимсенә, хәтта үз-үзеннән нәфрәтләнеп тә куя иде. Хатын йөрәге белән ул, мондый йомшаклыгым өчен ир кеше миннән бер бизәр, дип сизенә һәм шуңардан бик курка да иде. Ләкин нәкъ менә хатын булганга күрә дә ул яраткан кешесенең сагынуын аңларга, тоярга, аңа карышмаска, аңа буйсынырга мәҗбүр иде.

Рәшидә беләкләре өстенә башын салып, күзләрен йомып, бик озак хәрәкәтсез чалкан ятып торды. Йомык күзләрендә ерак нурлы күкнең яшькелт җылы яктысы кытыкландырып йөзә, акылы оеган, күңеле бушап калган, бөтен тәненә хәлсез-рәхәт талчыгу җәелгән иде. Зөфәр дә тынычланып калган иде, ләкин бераз хәл алып ятканнан соң ул, терсәгенә таянып, күтәрелеп Рәшидәгә карады – аның бу кадәр хәрәкәтсез-тын ятуы аңа әллә ничек бик сәер тоела башлады. Шулай дәшәргә дә, орынырга да кыймыйча ул карап торган чакта, Рәшидәнең йомык күзләреннән ике генә бөртек яшь сытылып чыкты.

– Ни булды сиңа, кошчыгым? – диде Зөфәр, пошынып, һәм бармак бите белән сак кына аның яшьләрен сөртеп алды.

Рәшидә озак көттереп, йөзен читкә борып, көчкә генә җавап бирде:

– Авыр миңа! – Һәм тавышы аның өзелә язып куйды.

– Гаҗәп! – диде Зөфәр, көләргә итеп. – Нидән әле ул алай кинәт авыр булып китте?

Рәшидә тагын озак кына дәшмичә ятып, ниһаять, күзләрен ачты. Һәм бу яшьле күзләр салкын бер ятсыну белән Зөфәргә төбәлделәр.

– Кинәт түгел бу... күптән миңа авыр инде, тик син генә күрмисең! – Аның иреннәре калтыранып куйды, ләкин тавышы сынмады. – Кем син, Зөфәр, кем? – диде ул, кинәт тирән әрнү белән өзгәләнеп. – Мин бит сине бөтенләй белмим... Менә өч елдан артык вакыт узды, ә мин берни дә белмим, син сөйләмисең, яшерәсең, качасың, син минем белән дә һич кызыксынмыйсың, сорашмыйсың... Нәфесеңне басар өчен генә мине әллә нидә бер эзләп табасыңмыни, яратуың бары шуның өчен генәмени?.. Ходаем, бары шуның өчен генәмени?..

Һәм кисәк кенә аркасы белән борылды да, йөзен куллары белән каплап, еш-еш калтыранып үкси дә башлады. Зөфәр бер мәлгә аптырап, югалып калды: Рәшидә үксеп елый! Шат, ваемсыз, иркә, кочагын-назын аңардан һич кызганмаган һәм моңарчы шуңа үкенүен һич сиздермәгән Рәшидә кинәт, мәсхәрәләнгән яшь кыздай, бөгелеп-калтыранып үкси, җитмәсә, нинди сүзләр әйтеп! Юк, һич тә көтмәгән иде ул мондый хәлне... Беренче минутта ни әйтергә,

нишләргә белмичә аптырап торды, курка калды, аннары Рәшидәнең иңбашыннан кочып, чәченнән сыйпап ничек тә юатырга тырышты:

– Куй, Рәшидә, куй, акыллым! Ярамый болай, бетермә үзеңне, тукта! – Ул аның кулларын көчләп йөзеннән аерды, башын үзенә таба борды, күкрәгенә кысты. – Йә инде, йә, бала булма, тынычлан! Гаеп миндә икән, кичер! Только җылама, зинһар, җылама, яме!

Рәшидә аның күкрәгенә капланып тыела алмыйча тагын күпмедер үксегәннән соң, ниһаять, акрынлап тынычлана башлады, ә бераздан бөтенләй тынып калды. Шул хәлдә аз гына онытылып торганнан соң ул пышылдап кына сорады:

– Сумкамны алып бир.

Зөфәр читтә яткан сумканы алып бирде. Рәшидә шуннан кечкенә зәңгәр кульяулыгын алып, битен, күзләрен сөртте. Аннары торып утырды, күлмәгенең алгы төймәләрен каптырды.

Бу минутта Зөфәр тәмам айнып, исен-акылын җыеп өлгергән иде инде. Башта ул Рәшидәне чынлап кызгангандай булды, ә хәзер менә аңа бераз шелтә белдерәсе килде: ярыймы соң болай урынсызга кешенең котын алып, истерикага төшеп еларга? Ни өчен бу? Алдаган яки көчләгән что ли ул аны?

Әйе, ул, Зөфәр, үзен Рәшидә алдында нәрсә өчен дә булса гаепле, күпме дә булса бурычлы итеп санамый иде. Аннары, гомумән, ул хатын-кызның зарын, үпкәсен тыңларга яратмый иде. Мондый «ирекле» бәйләнештә булган чакта андый претензияләрне урынсыз, артык нәрсә дип саный иде.

Ләкин шулай да ул шелтәсен белдерергә ашыкмады; чөнки, беренчедән, сүзне тирәнгә җибәрәсе килмәде, икенчедән, ничек кенә булмасын, Рәшидәнең күз яшьләрендә хаклык барын сизмичә калмады. Ихтыярсыз вөҗданы аның бераз кузгалып, борчылып куйды. Ихтыярсыз үзен беркадәр аклыйсы, ә Рәшидәне юатасы килеп китте.

– Тынычландыңмы инде? – диде ул, Рәшидәнең кулын ике учына алып. – Менә ярый, менә бик әйбәт, мин бик шат... – Ул аз гына тынып торды да, көрсенеп, сөйләнергә тотынды. – Әлеге бер сүз инде, сөеклем! Эш, мәшәкать, төрле борчылулар, шуның аркасында үзеңне дә, иң яраткан кешеңне дә онытып җибәрәсең... Просто баш-күз әйләнеп бетә. Эшем минем шундый инде. Ләкин мин моны сиңа акланыр өчен генә әйтмим, дустым, әгәр минем гаебем бар икән, син кичер мине, яме!

– Ярый, үтте инде, – диде Рәшидә, тирән-хәсрәтле сулап.

Зөфәрнең сүзне тизрәк икенчегә борасы килде:

– Әйт әле, – диде ул, соңга калган кайгыртучанлык белән, – синең театрга күчүең ничегрәк тора, күчәсеңме инде, алалармы?

Рәшидәгә хәзер үзе хакында ни дә булса сөйләү авыр иде. Хәтта Зөфәр аның хәле белән кызыксынамы-юкмы, хәзер инде барыбер иде. Күз яшьләре белән барысы да —үпкәсе дә, хәсрәте дә, әрнүе дә – чыкты да бетте. Күңелендә бары көзге кыр өстедәй тын, моңсу бушлык кына торып калды. Уйлыйсы да, сөйлисе дә, хәтта кузгаласы да килми иде. Шулай да Зөфәрнең соравын җавапсыз калдыруны килештермәде һәм үзен көчләбрәк булса да акрын гына сөйләргә тотынды.

– Юк шул әле, – диде ул, башын иеп кенә. – Йөреп карадым. Министерствога да бардым, театр җитәкчеләренә дә кердем, ләкин берсеннән дә ачык кына җавап ишетмәдем. Директор: уйлап карарбыз, ди, баш режиссер: сезнең амплуа бездә җитәрлек, танылган артисткаларга да эш юк әле, ди. Шул ук вакытта, сезнең данныйларыгыз миңа ошый, ди, бәлки киләчәктә берәр җаен табарбыз, ди... Менә шулай йөртәләр. Мин ни, ялына белмим, протекция эзләмим, кирәк кешегә ярарга тырышмыйм. Бәлки берәрсе миннән шуны көтәдер... Ә мин... ә мин... бервакытта да... – һәм ул сүзен әйтеп бетерә алмады.

Зөфәр Рәшидәнең бөгелеп, катып калган аркасына карап, аның елап җибәрүдән никадәр зур көч белән тыелып утыруын ачык сизде. Шуңа күрә дәшмәде, кагылмады.

Инде кояш баеган иде, агачлар арасына кичке зәңгәрсу караңгылык акрын гына иңә башлаган иде. Алар, ниһаять, урыннарыннан тордылар. Өс-башларын рәтләделәр. Рәшидә, урыныбыз чүпләнеп калмасын дип, газеталарны җыеп алды, азык-төлек калдыкларын җыештырып, агач төбенә салды: «Төнлә берәр җәнлек килеп ашар әле»,—диде ул, шуңа алдан ук сөенгәндәй.

Алар яр буендагы басмага килеп җиткәндә, караңгы тәмам төшеп өлгерде. Соңгы паром киткән иде инде. Зөфәр ары барып, бире килеп шактый вакыт көймә эзләп йөрде. Ахырда бер балыкчы картны очратып, шуның белән бик үтенеп сөйләшкәч кенә, карт боларны шәһәр ягына чыгарып куярга риза булды. Ишкәкле тар көймәгә чайкала-чайкала кереп утырдылар һәм пристань утларына карап кузгалып киттеләр.

...Төн гаҗәеп бер төн иде. Әйтерсең бөтен җир өсте йомшак-калын кара бәрхеткә төренгән – шундый караңгы, шундый җылы һәм шундый тын иде ул! Һични күренми, һични селкенми, су салкыны да сизелми, бары ишкәкләрнең тигез-салмак чапылдап алуы гына ишетелә иде. Көймә, күзгә күренмәс дегеттәй кара суны авыр ерып, акрын гына бара шикелле, ләкин каршы якка бер дә якынаймый төсле иде. Әллә ничек менә җир дә, кешеләр дә моннан бик-бик еракта кебек, һәм аларга барып җиткәнче бик күп вакыт үтәр кебек иде. Әмма алар кайдадыр бар, алар сизелә, шуңа күрә куркыныч түгел, шомлы түгел иде.

Бераз киткәч тә көймәнең түр очында утырган һәм кулын җылы суга тыгып барган Рәшидә, гүя үзе өчен генә, тавышын көчәйтмичә тыелыбрак, ләкин гаҗәп тирән бер моң белән җырлый башлады:

Ялан да гына җирләрдән болан килә, Зөлхиҗҗә,

Уйсу гына җирләрдән ай үтәм дип, Зөлхиҗҗә,

Төн уртасы җиткәч, бер кыз елый, Зөлхиҗҗә,

Яшь гомерем заяга, ай, үтә дип, Зөлхиҗҗә.

Юк, бу гади җырлау гына түгел иде, бу гүя йөрәгенең иң нечкә, иң сизгер-моңлы кылларына акрын гына чиртеп уйнау иде... Һәм каршысында утырган Зөфәр аны таңга калып тыңлады. Ул кузгалырга да, дәшәргә дә курыкты, бары аның менә шулай онытылып, өзелеп-өзелеп җырлавын гына көтте. Рәшидә җыры аны исертеп, сихерләп кенә калмады, ә ничектер менә йөрәген урыныннан кузгатты, сызландырды, җан тынычлыгын алды. Һәм исе китеп уйлады ул: нинди кодрәтле талант, нинди саф, нечкә күңел, нинди якты, кешелекле хатын бу Рәшидә!.. Йә, шуны ташла, шуны югалт, имеш!.. Мөмкинме соң бу?.. Шушындый алтын бәясенә торырлык хатынның сөелергә, бәхетле булырга, үзенең асыл теләкләренә ирешергә хакы юкмыни?

Ә бит ул, Зөфәр, теләсә аңа ярдәм итә ала, аны бәхетле итә ала. Иң элек аңа әнә шул театр җитәкчеләре белән бер сөйләшү җитә, һәм Рәшидә үзенең күптән ашкынган сәхнәсенә менәчәк. Чөнки Зөфәрнең үтенечен кире какмаячаклар, чөнки Зөфәр сугыш елларында театрга шактый күп ярдәм итте, һәм хәзер дә ул анысын-монысын табып бирүдә аларга бик кирәк кеше.

Менә хәзер үк аның Рәшидәне бер-ике генә сүз белән булса да юатасы, өметләндерәсе килде, ләкин... ләкин сак булырга өйрәнгән акылы аңа ашыгырга кушмады. Вөҗданын тынычландырыр өчен ул, нигә алдан ук әйтеп куярга, эшлим дигәндә моны бит Рәшидәнең үзенә әйтмичә генә дә эшләргә мөмкин ләбаса, дип уйлап азапланды.

Ә Рәшидә җылы-йомшак төн эченнән үзалдына һаман акрын гына җырлап барды. Гүя һичкемгә зарланмыйча, үпкәлмичә генә ул үзенең ялгызлыгын җырлый иде. Шунлыктан ахры кызгандыру хисен ничектер уятмыйча гына тирәнтен сыкрата, уйландыра, борчый иде аның җыры... Зөфәр хәтта үз хәлен бераз җиңеләйтер өчен Гамбәр туташны исенә төшереп, аны күз алдына китерергә тырышып карады, әмма көн яктысында йолдыз кабына алмаган шикелле, Рәшидә белән янәшә билгесез туташ та һич туа, күренә алмады.

Ахырда алар пристань ярына килеп җиттеләр. Көймәдән төштеләр, ярга менделәр һәм шалдыр-шолдыр селкенеп йөргән трамвайга утырып, шәһәргә кайтып киттеләр.

Кольцога җиткәч, Зөфәр, гадәтенә каршы, Рәшидәне өенә чаклы озата барды. Һәм, гадәтенә каршы, якын көннәрдә тагын шалтыратырга вәгъдә биреп, ханымны үбеп, кулын кысып аерылышты. Рәшидә өч катлы иске таш йортның астындагы капкадан, башын иеп, сүзсез генә караңгы ишегалдына кереп китте.

**XIV**

Бу соңгы атнада Зөфәргә вакыйгаларның төрлесен —кечкенәсен-зурысын, күңеллесен-ямьсезен кичерергә туры килде. Тормыш шулай бит ул, кайчак тыныч кына аккан җиреннән, бусагалар өстенә барып менгәндәй, бәргәләнеп-суккаланып каядыр ашыга башлый. Һәм күпмедер ара котырып чапканнан соң, яңадан иске юлына төшеп, элеккечә тыныч-салмак кына агарга тотына... Тормыш шуның белән кызыклы да ул!

...Беркөнне Зөфәр өенә кайтып керсә, коридорда сеңелесе Хөршид елап утыра. Бу ни хәл?.. Хөршиднең болай елавын аңа бик сирәк күрергә туры килә иде.

– Ни булды сиңа? – диде Зөфәр, аның янына тукталып.

Хөршид дәшмәде, тик арык иңбашларын калтыратып елавын гына белде.

– Ник дәшмисең? Берәр җирең авыртамы, әллә берәрсе тидеме, йә?

Кыз абыйсының соңгы сүзләрен ишеткәч, тагы да катырак еларга тотынды. Зөфәр аның өстенә бераз карап торды, иелеп башыннан сыйпамакчы булды, ләкин кыз «тимә!» дигәндәй, кисәк кенә иңбашын сикертеп куйды.

– Менә юләр! – диде Зөфәр, аптырагач, аннары өйгә кереп китте.

Өйдә Таибә абыстай да, кемгәдер нәрсә өчендер бик хәтере калгандай, турсаеп, сөремен коеп йөри иде.

– Хөршидкә ни булган, ник елый? – диде Зөфәр, керү белән.

– Ахмак булганга күрә! – диде Таибә абыстай, кырт кисеп кенә.

– Юк, шулай да?

Зөфәрнең басып соравына абыстайның ачуы килде булса кирәк, бераз дәшми йөрде, аннары гасабилануын яшерә алмыйча өзеп-өзеп кенә сөйләп бирде. Эш болай булган икән: Хөршид янына әлеге шул күршедәге инвалид кызы Люся кергән. Ахирәт, янәсе!.. Китапларына төртелеп кенә утырсалар, бер хәер иде, юк, утыралармы соң! Безнең Хөршид, тиле, йокы бүлмәсенә тегене алып кергән дә, зур шифоньерны ачып, кием-салымнарын күрсәтә башлаган. Бер дә киелмәгән өр-яңа туфлиләрен Люсяның тузанлы аякларына кидереп караган... Моны күреп алгач, Таибә абыстай түзмәгән инде, орышып, бүлмәдән куып чыгарган үзләрен... Шулай итмичә ярыймы соң!.. Ә теге пумала баш Люся, үзенә күрә түгел, чынлап үпкәләгән булып, бөтенләй үк чыгып киткән... Китсен, алдыннан арты чибәррәк!.. Ә безнең Хөршид шуңа

җенләнеп, әнә баядан бирле коридорда елап утыра. Җитмәсә, энисенә авыр, каты сүзләр әйтеп бетергән: имештер, бездән кешеләр кача, безгә берәү дә керми, имеш, аңа бу өйдә ямь дә юк, кызык та юк, имеш, без аңардан иптәшләрен качырып бетерәбез... Кара син аны, явызны, бөтенләй шайтан коткысына бирелеп бара бит!

– Их, әни, ялгыш эшләгәнсең, ялгыш! – диде Зөфәр, чын-чыннан ачынып.

Таибә абыстайның гаҗәпләнүдән күзләре түгәрәкләнеп китте:

– Ничек инде ул ялгыш? Нәрсәсе ялгыш? Өеңне актарсалар да дәшми торыргамыни?

– Юк, иплэп кенә кирәк иде, каты бәрелмичә генә...

– Ярар, янарал кызы түгел әле, – диде Таибә абыстай, нәфрәт белән кулын селтәп. – Олы башым белән шул өтекнең хәтерен саклап торыйм ди тагын...

– Әх, аңламыйсың, әни!

– Аңламыйсың? Ачуыңнан үләрсең! Син бик аңласаң, әнә сеңелеңә нык кына әйтеп куй: җыен ач күзгә, юмартланып, эчке дөньясын ачарга тормасын. Өйнең серен саклый белсен. Бездә ни булмас. Болай да көнчеләрдән көн юк.

– Менә шуңа күрә дә кеше белән сак булырга кирәк, әни! – диде Зөфәр, ничек тә сабырлыгын җуймаска тырышып. – Без бу урында яңа кешеләр, барысы да безгә сынап карыйлар, шулай булгач, күршеләргә ачыграк, йомшаграк тору безнең үзебез өчен кирәк ләбаса!

– Һай, син бик акыллысың инде, үтә акыллысың! Әниеңне генә өйрәтәсең калды... Әниең бит кеше дә күрмәгән, күршеләр белән дә яшәмәгән! Вәт син, ә!.. Кем өчен диген, бер исерекнең ыштансыз кызчыгы өчен бит, йа Рабби!

Таибә абыстай бу сүзләрен чын рәнҗү белән ярсып әйтеп ташлады. Зөфәргә моны ишетү бик авыр булды... Кайтарып, аның, үзе төсле, каты итеп җавап бирергә уйлаган иде дә, ничектер тыелып калды: әни бит! Һәм кисәк кенә борылды да үз бүлмәсенә кереп китте.

Озак тынычлана алмады ул, бүлмәсендә ишекле-түрле һаман йөреп торды. Кирәк бит, кайтып керүенә шундый мәгънәсез скандал!.. Әнисенә дә, сеңелесенә дә аның чынлап ачуы килде... Дөрес, әнисе үзенчә хаклы да иде — өйдә ул хуҗа, ул монда күз-колак булырга, үзе әйтмешли, өйнең серен сакларга тиеш. Инде олы кеше теге юньсез кызларга катырак әйткән икән, бик дөрес эшләгән дип акларга да мөмкин булыр иде. Ләкин бөтен бәла шунда, әнисе бер хакыйкатьне – күршеләрнең аларга никадәр кырын карауларын аңлап җиткерми. Ә сеңелесе менә яшь кенә булса да, ничектер шуны йөрәге белән сизгән. Һәм нинди сүзләр әйтеп ташлаган ул!.. Бу бик хәтәр, бик шомлы нәрсә бит. Бу – семьяның үз эчендә фаҗигале каршылык бөреләнеп килә дигән сүз бит! Ничек итеп моны күрмәскә яки моңа игътибар итмәскә мөмкин ди?

Зөфәргә бу хәлнең сәбәбе ачык. Ул үзе дә яңа күршеләрнең (искеләрен әйткән дә юк!) аларга ничегрәк карауларын, тиресе белән дигәндәй, сизеп йөри. Әнә шул үпкәләп чыгып киткән кызның әтисен генә искә төшерү дә җитә. Зөфәр белә аны, эшкә барышлый яки кайтышлый еш кына очрата үзен... Әйе, сугыштан кайткан инвалид ул, бот төбеннән бер аягы юк, култык таякларында йөри. Әйе, бик эчә булса кирәк, чөнки бите-күзе аның һәрвакытта кызарып шешенгән була... Менә шул кеше аңа, Зөфәргә, ничегрәк карый?.. Дөрес, Зөфәр очрашканда үзе башлап аның белән исәнләшә, һәм инвалид беркайчан да аның сәламен алмыйча калмый. Әмма шул чагында Зөфәр инвалидның юри кыса төшеп караган боздай салкын-тоныкк күзләрендә нәрсә күрә? Бары бер генә нәрсә: нәфрәт, ачу, усаллык – гүя никадәр дошман итеп каравын яшерергә дә теләми... Тагын шунысы гаҗәп, кайчагында ул, исерек баштан ялагайланасы килепме, Зөфәрнең исәнләшүенә каршы түбәнчелек белән баш иеп, җәелеп елмайган да була, ләкин барыбер күзләрендәге усаллык сүнми, ә елмаю ничектер зәһәрле килеп чыга... Һәм Зөфәр мондый чакта аеруча бер чиркану, шомлану тоеп, аның яныннан тизрәк узып китәргә ашыга.

Әлбәттә, ул – Хөршид түгел, инвалидның ни өчен алай каравын бик яхшы аңлап тора. Бер хакыйкать бар: дөньяда кешеләрнең тормышлары да, язмышлары да бертигез түгел. Шулай булып килгән, һәм хәзергә шулай бара әле ул. Ләкин, гафу итегез, моңа ул, Зөфәр Сабитов, гаеплемени?

Шуңа күрә Зөфәр һәртөрле көнче, усал карашларга игътибар итмәскә, намусын тыныч тотарга тырыша. Әмма җиңел түгел бу... Кайчагында кешеләрнең кырын карашлары аны борчый, аны шомландыра. Менә ни өчен ул өйдәгеләрдән дә сак булуны таләп итә.

Бервакытны кемдер аңа, казларны котыртмаска кирәк, дип әйткән иде. Бик дөрес сүз! Әйе, «казларны» котыртырга ярамый.

Ул көнне Зөфәр әнисе белән дә, сеңелесе белән дә бүтән сөйләшмәде. Кичкырын, кәеф бераз төзәлмәсме дип, киногa барып кайтты. Иртә ятып йоклады, иртә генә торып эшенә китте.

Кабинетына барып утыргач та аңа сәүдә министрының урынбасары Әхмәтҗанов шалтыратты. Зур начальникның сүзе кыска булды: бүген үк үз янына килеп чыгарга кушты, сезнең белән бер җитди мәсьәлә турында сөйләшәсе бар, диде, ләкин нинди мәсьәлә икәнен әйтеп тормады.

Сәгать уникеләрдән соң Зөфәр министрлыкка китте. Юл буенча нәрсә хакында булыр икән бу җитди сүз дип уйланып барды. Азрак кына борчылып та куйды —гадәттә бит начальник кеше күбрәк йә наказ, йә шелтә бирер өчен чакыра. Алай дисәң, Әхмәтҗановның аңа, ОРС системасында эшләүчегә, нинди мөнәсәбәте бар.

Зөфәр министр урынбасарын танып, күреп белсә дә, моңарчы якыннан очрашырга да, сөйләшергә дә туры килгәне юк иде әле. Нindirәк кешедер инде. Хәер, аның кул астында эшләүчеләрнең әйтүенә караганда, ул болай «ярыйсы гына мужик», имеш! Фәлән Фәләновичның көенә тора белсәң, ничево, эшләргә була дип әйтәләр. Күбрәк ул акыл сатарга, вәгазьләргә ярата икән. Ләкин югарыдан үзен кыса башласалар, бик усалланып китә торган гадәте дә бар икән.

Фәлән Фәләнович. Тукта, Зөфәр бит аның исем-отчествосын да ишетеп белә иде. Ничек кенә соң әле, аты коргыры?.. Әһә, тапты: Вилдан... Вилдан... Гыйльманович!.. Хуш, Вилдан абзый Гыйльманович, нимә турында гына гәп корырсың икән?

Әхмәтҗанов – тәбәнәк, юан гәүдәсенә кайтарма якалы күк гимнастерка киеп, салына төшкән корсагын киң каеш белән күтәреп буган, сакал-мыексыз, итләч битле, олы гына яшьтәге кеше – Зөфәрне ачык йөз белән каршы алды.

– Хуш киләсез, иптәш Сабитов! – диде ул, зур өстәл артыннан торып, һәм кул биреп күрешкәч, урын тәкъдим итте: – Утырыгыз!

Зөфәр шунда ук уйлап алды, болай булгач, сүз күңелсездән булмаска тиеш.

– Йә, саулык-тазалык, эшләр-уңышлар ничегрәк соң, иптәш Сабитов? – диде Әхмәтҗанов, елмая төшеп.

– Рәхмәт, Вилдан Гыйльманович! – диде Зөфәр, беренче сүзеннән үк үзен ничектер иркен, кыю хис итеп.—Хәзергә зарланырлык түгел.

– Сәүдәләр барамы?

– Бара, әйбәт бара!

– Шулайдыр шул. Завод ОРСына фондны күп бирәләр, товар булгач, сәүдә бара инде ул.

– Дөрес, Вилдан Гыйльманович, безне товар ягыннан алай кысмыйлар, ләкин без үзебез дә тик ятмыйбыз, эзлибез, табабыз, кыскасы, завод халкын ничек тә яхшырак тәэмин итәргә тырышабыз.

– Ә сез беләсезме, – диде Әхмәтҗанов, чак кына пауза ясап, – завод ОРСлары бетәчәк бит.

Зөфәр өчен бу өр-яңа бер хәбәр иде, ләкин ул сыңар кашын да селкетмичә гамьсез генә әйтте:

– Ишеттек, шундый сүз йөри, только тиз булмас әле ул. Без, мәсәлән, алдагы елда товар оборотын ике тапкыр арттырырга уйлап торабыз...

– Юк, тиз булачак. Мин моны сезгә бик белеп әйтәм, иптәш Сабитов... Бөтен сәүдә хәзер үзенең төп хуҗасына – сәүдә министерствосына күчәчәк. Шулай ул! ОРСлар сугыш

шартларында кирәк иде, ә хәзер нигә алар?.. Сату итү заводлар эше түгел, безнең эш ул! Хөкүмәт бу мәсьәләне бик белеп, бик дөрес хәл итә.

– Бәхәсләшмим, Вилдан абзый! – диде Зөфәр.—Хөкүмәт, әлбәттә, дөрес хәл итәр.

Бу юлы инде Әхмәтҗанов бик канәгатьләнеп елмайды:

– Менә шул шул! Анда, брат, мудрый башлар утыра! – Һәм шунда ук җитди кыяфәткә кереп, кисәк кенә сорады: – Ә беләсезме, мин сезне ни өчен чакырдым?

– Юк, Вилдан Гыйльманович, белмим...

Әхмәтҗанов беравык Зөфәргә төбәлеп карап торды, аннары креслосының аркасына ята төште, учы белән өстәленә бер-ике тапкыр суккалап алды.

– Эш менә болай тора, иптәш Сабитов! – диде ул, ашыкмыйча гына сүзен башлап. – Без тиздән шәһәрдә зур универмаг ачабыз. Центрда, элекке люкс бинасында, хәзер аны оборудовать итеп яталар... елына өч йөз миллион сум оборот белән, сизәсеңме?.. Бу әле башта гына, тора-бара ул миллиардка да җитәр. Совет сәүдәсенә хәзер киң юл ачыла, ә товар булачак. Моңарчы корал эшләгән заводлар да мирный продукциягә күчәләр. Кыскасы, перспектива бик шәп!..

...Без менә хәзер шул ачылачак магазинга кадрлар җыябыз. Иң яхшыларын, честныйларын, культурныйларын... Кеше күп кирәк. Универмаг – үзе бер комбинат бит ул, ә киләчәктә төрле җирдә аның филиалларын ачу да күздә тотыла. Менә шундый зур сәүдәне культурный итеп, бай итеп оештыра белүче бер специалист, икенче төрле әйткәндә, коммерческий директор кирәк булачак безгә. Да. Без монда һәм тагын кайбер җирләрдә уйлашып киңәшкәннән соң, сезнең кандидатурага тукталдык. Деловой качестволарыгызны без беләбез. Сезнең специальный образованиегез дә бар бит, шулаймы?

– Әйе, бар.

– Бик яхшы. Безгә шундый кеше кирәк тә... Хуш, әгәр без сезне шул булачак универмагка коммерческий директор итеп чакырсак, ни диярсез? Условиесе начар түгел, төп оклад ике мең ике йөз сум. Шуның өстенә тагын премиальный... Йә, ничек карыйсыз бу тәкъдимгә?

Зөфәр бик тыныч утырды, дулкынлануын берничек тә сиздермәде һәм җавап бирергә дә ашыкмады. Бары кирәк кадәр уйланып торганнан соң гына, дәрәҗәсен саклап, әдәп белән:

– Рәхмәт тәкъдимегез өчен, Вилдан Гыйльманович! —диде. – Сез миңа зур честь ясадыгыз! Ләкин, беләсезме, мин урыннан урынга күчеп йөрергә яратмыйм. ОРСтагы эшемнән канәгатьмен, күптән эшлим...

– Мин сезгә әйттем ич: ОРСлар бетәчәк!

– Кайчан бетәр бит әле ул. Ә сезгә кеше хәзер үк кирәктер?.. Так что, китим дисәм дә мине ОРСтан җибәрмәүләре мөмкин.

– Эш бары сезнең теләктән тора. Әгәр риза булсагыз, без сезне аннан ала белербез, борчылмагыз! – диде Әхмәтҗанов, мәгънәле генә итеп.

– Анысына ышанам, ләкин...

– Сез беспартийный бит әле? – диде Әхмәтҗанов, кинәт кенә Зөфәрнең сүзен бүлеп.

– Әйе, беспартийный.

– М-да! – дип куйды Әхмәтҗанов үзалдына гына, аннары Зөфәргә туры карап, үпкә белдергәнрәк тавыш белән сорады: – Ни өчен моңа кадәр партиягә кермичә тордыгыз?.. Үзегез әйбәт работник, белемегез, развитиегез бар, политиканы аңлыйсыз, күптән керү кирәк иде, туган!

Бу сүзләр Зөфәрнең җан сөяленә барып тигәндәй булды, ләкин ул бер генә хәрәкәт белән дә үзенең читен, авыр хәлен сиздермәде, бары гаепсез генә елмайган булып әйтте:

– Ничектер туры килмәде шул моңарчы, Вилдан абзый! Бик җаваплы эш бит... Әзерлегем җитәрлек түгел дип курыктым инде, дөресен генә әйткәндә...

– Әлбәттә, партиягә керү мәсьәләсенә җиңел карарга ярамый... Достойный булып керергә кирәк... Ну, зарар юк, без сезгә болай да ышанабыз... Йә, ничек соң, мин әйткәнгә ризамы сез?

– Вилдан Гыйльманович, – диде Зөфәр, кулын күкрәгенә куеп, – рөхсәт итегез, сезгә яңадан зур рәхмәт белдерергә, ләкин мин менә хәзер үк бер сүз дә әйтә алмыйм, миңа уйларга кирәк.

– Ярый, уйлагыз... Ләкин, учтите, мин сезгә уйлар өчен вакытны күп бирә алмыйм.

– Шулай да күпме?

– Ну, күп булса, бер атна. Безгә ведущий кадрларны алдан комплектовать итеп куярга кирәк. Ә коммерческий директорның эше, үзегез беләсез, магазин ачылганчы ук башланырга тиеш.

– Аңлыйм... Ярый, Вилдан Гыйльманович, мин сезгә җавапны бер атна эчендә бирермен.

– Бик хуп!

– Тик... бер нәрсәне алдан белергә мөмкин түгелме?

– Именно нәрсәне?

– Универмагның директоры кем булачак? Билгеләндеме әле ул?

– Приказ юк әле, ну билгеләп, согласовать итеп куйган кешебез бар: Комаров Павел Петрович, министерстводан.

– Ә, Комаров... Беләм... Ну, что ж, бик әйбәт.

– Работник ул ярыйсы, энергичный, тырыш, дөрес, күбрәк аппаратта утырган кеше, үзе сату итеп караганы юк әле... Зато сез – специалист, сез сәүдәне яхшы беләсез... Берегездә –

җитәкчелек, икенчегездә – коммерция, начар булмас ул!.. Минемчә, сез аның белән килешеп эшли алырсыз.

– Мин, Вилдан Гыйльманович, теләсә кем белән дә эшли алам, – диде Зөфәр, тыйнак кына көлемсерәп.—Рөхсәтме?

– Әйе, пожалысты!

Алар, торып, кул кысыштылар.

– Мин уңай җавап бирерсез дип ышанам, – диде Әхмәтҗанов, Зөфәрнең кулын аз гына җибәрмичә торып.—Белегез, кеше юктан без сезне чакырмыйбыз, ә деловой качестволарыгыз өчен...

– Аңлыйм, Вилдан абзый, аңлыйм. Рәхмәт!

– Ну пока алайса!

– Хушыгыз!

Министрлыктан чыккач, Зөфәр ни өчендер бик кызу атлап бара башлады. Хәтта бераздан үзе дә аптырап: «Тукта, кая бу кадәр чабам соң әле мин?» – дип уйлады һәм... ихтыярсыздан елмаеп куйды. Баксаң, аны эченә сыеша алмаган эчке бер дәрт, рухи күтәренкелек ашыктырып куа икән. Әйе, канатланып очмаслык та түгел шул! Иптәш Әхмәтҗанов, министрның беренче урынбасары, үзе чакырып алып, каршысына утыртып, нинди тәкъдим ясады! Сез – специалист, сез безгә кирәк, рәхим итегез! Беләләр, таныйлар бит, шайтан алгыры!

Ләкин хикмәт анда гына да түгел әле. Тәкъдим ителгән эш үзе аңа, Зөфәргә, бик ошады. Зур универмагта коммерческий директорлык вазифасы – бу аның эше, бу эштә инде ул үзенең сәләтен тагын да шәбрәк күрсәтә алачак. Һәрхәлдә, ОРСның вак точкалары арасында чабып йөрү булмаячак.

Дөресен генә әйткәндә, ОРСта эшләү аны соңгы вакытларда туйдыра да башлаган иде инде. Сугыш елларында завод канаты астында эшләү әйбәт булса да, хәзер кызыгы бетеп бара иде. Әхмәтҗанов әйтмешли, чын сәүдә урынымыни ул? Аннары халкы да бик тынгысыз, бәйләнчек – һәртөрле сүз, шик, гайбәттән башың чыкмый... Әлеге шул дошманың Симаковтан котылыр өчен генә дә әллә кая качарсың... Гомумән, сәүдә работнигына бер урында бик озак утыру, врачлар теле белән әйткәндә, противопоказано ул!

Шуңа күрә Зөфәр, җае туры килсә, берәр сылтау табып, ОРСтан китү турында уйланып та йөри башлаган иде. Һәм менә уйлап таба алмаслык җай үзеннән-үзе килеп тә чыкты. Сылтауны эзләп торасы да юк. Минис-терство аны үзе ОРСтан бик әйбәт кенә сорап алачак... Әлбәттә, ул Әхмәтҗанов тәкъдименә ике куллап риза. Тик дәрәҗәсен төшермәс өчен генә

уйларга вакыт сораган булды. Ә инде Әхмәтҗанов аның җавабын көтәчәк, һичшиксез, көтәчәк!.. Сабитов кебекне тиз генә таба алачак та түгел ул!.. Тукта!..

«...Кем син, Зөфәр, кем?»

Бу ни хикмәт, иң якты хыялларга бирелеп киткән чакта да шушы сүзләр әллә каян гына аның исенә төшеп, кинәт йөрәген өтеп ала, кәефен боза, дөньясын караңгылатып җибәрә. Ачу китергеч хәл!.. Неужели, ул үзенең нинди әйбәт, шәп кеше булуын шул бала табигатьле, наивный хатынга гына аңлата алмас? Юк, булмый, ярамый болай! Ике ара бөтенләй өзелгән чакта да ул аны тәмам үзенә әсир итеп, үзенең кодрәтенә тәмам ышандырып, гомере буена үкенеп, сагынып яшәрлек хәлдә калдырып аерылырга тиеш!.. Аерылырга? Ә ни өчен аерылырга? Мөмкинме бу, кирәкме бу? Шайтан белсен, нигә ул бары шушы Рәшидә мәсьәләсендә генә катгый бер карарга килә алмыйча йөри торгандыр?!

Ә вакыйгалар, әйткәнебезчә, бер-берсен кысрыклый, ашыктыра башладылар. Озак та үтми, Зөфәр өчен тагын бер мөһим вакыйга булып алды. Эш шунда, Зариф абыйсы аны теге Гамбәр туташ белән таныштыру чарасына чынлап торып керешкән икән. Моның өчен ул тоткан да дүшәмбе көнгә кызның эти-әнисен һәм кызны үзенә кунакка чакырган. Менә шул мәҗлескә Зөфәр дә, билгеле, барырга тиеш. Абзыйның планы болай: башта өлкәннәр үзләре генә киләчәк, ә кыз соңгарак калачак, чөнки йоласы аның шулай икән. Димәк, Зөфәр дә «эштә тоткарланган» булып, соңгарак калырга тиеш. Менә шулай эшләгәч, ашап-эчеп туйган өлкәннәр алданрак кузгалачак, ә яшьләр, соңрак килү сәбәпле, беразга калып торачаклар.

Зөфәргә абыйсының планы һич тә ошамады. «Шито-крыто» булыр дигән иде ул, ә монда бөтенесе шәрран яра: булачак «кияүне» дә күрсәтү, булачак «киленне» дә карау нәкъ татарча апачык, тупас итеп оештырылган. Башта Зөфәр бу рәвешчә танышуга кул-аягы белән каршы торды. Ләкин аңа: «Эш узган, кунаклар чакырылган, әгәр кыз килеп тә син килмәсәң, бөтен эш сүтеләчәк», – диделәр. Шуннан соң гына Зөфәр кулын селтәп, ниһаять, риза булды. Бигрәк тә аны Гамбәр туташның менә болай мәҗлескә килеп, эти-әнисе алдында егет белән танышырга риза булуы гаҗәпләндерде. Ниндирәк туташ икән соң инде ул?!

Дүшәмбе көнне Зөфәр яхшырак киенеп эшенә китте һәм сәгать бишенчеләрдә ОРСтан туры гына абыйларына барды. Өйалдында самовар яңартып йөргән, бәйрәмчә киенгән, ничектер шактый тазарып та, матурланып та киткән Сәкинә җиңгәсе аны өтәләнеп каршы алды:

– Һәй, Зөфәр җаным, килдеңме, әйдә, әйдә... Көтәләр! – диде ул, серле генә итеп.

Зөфәр, кепкасын салып, чөйгә элде, кечкенә тарак белән чәчен тараштырды һәм алгы бүлмәгә таба узды. Тәрәзә төпләре гөлләр белән тулы тәбәнәк-җыйнак кына залның ишегеннән керүгә, Зариф абыйсы аңа каршы урыныннан сикереп торды.

– Ну, туган, саргайттың бит безне, ни булды, нишләп болай соңга калдың? – диде ул, чынлап та көтә-көтә йөдәгән кешедәй.

– Эш бит, абый... Гафу итегез инде! – дигән булды Зөфәр, йомшак кына елмаеп.

– Шулайдыр дип уйлаган идем үзем дә... Синең кебек нәчәлникнең эше бетәме соң!.. Әйдә уз, әнә түрдән!

Зөфәр күрсәткән урынга керергә кыймыйчарак торгач, абыйсы эшне сизеп алды:

– Ә, әйе, ни, Зөфәр, таныш бул: бу, немец әйтмешли, минем белән бер сүстимдә эшләүче Җиһанша абзый була, ә бу аның җәмәгате Мәфтүхә ханым инде...

Камыр ашлары, конфет, печенье, чикләвек, вареньелар белән тулы өстәлнең түр башында икәү янәшә утырган кызыл чырайлы, чал мыеклы, аска таба бөгелеп килгән зур борынлы, чандыр-эре сөякле Җиһанша абзый һәм ап-ак түгәрәк йөзле, май баскан кечкенә күзле, кара бәрхеттән киенгән симез-юан Мәфтүхә ханым белән Зөфәр сузылып кына күреште һәм шуннан соң гына күрсәткән урынга кереп утырды.

Зариф абзый Зөфәрнең аркасыннан кагып:

– Менә шушы була инде, Җиһанша абзый, минем брат! – диде. – Зөфәр Мөбарәкович Сабитов! Ийе, э-э!

Кунаклар башларын кактылар:

– Яхшы, бик әйбәт!

Абыйсының, мал базарында чегәннәргә тай күрсәткәндәй, тәкәллефсез рәвештә аркасыннан кагып, кунакларга тәкъдим итүе Зөфәргә бер дә ошамады, уңайсызланды, һәм ул ирексездән кызарып куйды... Аз гына пауза булып алды.

– Исән-сау, сәламәт кенә йөрисезме? – диде Җиһанша абзый, ниһаять, Зөфәргә дәшеп.

– Рәхмәт! Хәзергә зарланырлык түгел. Ә үзегез?

– Без дә, шөкер, бер көе исән-имин генә йөрибез әле.

Тагын сүз өзелеп калды. Кунакларның дүрт күзе Зөфәрдә иде, шунлыктан ул үзен ничегрәк тотарга да, нәрсәдән сүз башларга да белми иде әле.

Сәкинә җиңгәсе яңадан кайнатып чыгарган самоварын өстәлгә җиңел генә китереп куйды.

– Син, – диде ул иренә, – кунакларны кыста әле, кыста әле, кыста. Үз эшеңне онытып утырма. Ягез әле, кунаклар, рәхим итегез әле яңа чәйдән.

– Булган иде инде безгә, – диде Мәфтүхә ханым, гүя кыстатыр өчен генә.

– Эчәрсез әле, эчәрсез, менә яңа килгән кунак белән бергәләп.

– Яңа килгән кунакка син аш-суыңны тизрәк китер,—диде Зариф абзый. – Коры чәй белән генә туйдырып булмас аны, хе-хе-хе!

– Ашыкма, һәр нәрсәнең үз җае бар. Берәр чәшке эчә торсын... Нишләптер менә Гамбәр туташ бик соңлады.

– Әйттем мин Мәфтүхә ханымга, үзегездән калдырмагыз, дидем.

Мәфтүхә ханым, бер дә сер сынатмыйча һәм Зөфәрдән күзен алмыйча, төче генә елмаеп:

– Гамбәргә ахирәте килеп калды шул, – диде. – Ташлап китәргә яхшысынмады инде... Ахирәте белән бит алар парлап, дүрт кулдан пианинода уйныйлар. Музыка булса, ипи дә кирәкми инде безнең Гамбәргә... Бәлки, килеп тә җитәр әле.

Зариф абзый кунакларның чынаякларына куе итеп чәй ясады, рәхим итегез, диде, өстәлдәге сыйларның әле берсенә, әле икенчесенә кулы белән ишарәләп күрсәтте. Кунаклар рәхмәт әйтеп, чынаякларын алдылар, балкашык белән генә чәйләрен капкаладылар. Күрәсең, алар чынлап та туйганнар иде инде... Аннары Зөфәрдән сүз көтәләр иде шикелле. Ләкин Зөфәр, авызына йозак салынгандай, һаман телгә килә алмыйча, бары тыштан ничек тә бәйсез тынычлык саклап, кашыгы белән чәен болгаткалап, тик кенә утыра бирде.

Ахырда Зариф абзый, ниндидер өзелгән сүзне ялгап җибәргәндәй, кинәт кенә:

– Ну бу Американы, мин әйтәм, баеп калды да соң, каһәр! – диде. – Башта сугыш буена безгә сатып ятты, хәзер Германга сата башлар, йөртә белә эшне үзе дә! Бездән күп көчледер инде ул хәзер, ә Зөфәр?

Зөфәр, таптың сорар нәрсә дигәндәй, кашын җыерды һәм иренеп кенә җавап бирде:

– Бәлки, хәзерге вакытта шулайдыр да... Сугыштан имгәнеп калмады бит ул. Ләкин байлык бездә дә бар, хәтта артыгы белән.

– Ә син җир-суының күплеген әйтәсең инде, беләм! Ул бит әле мертвый капитал, ә тегенең бөтенесе худта. Аннары аның кулында атом бит, атом!.. Шутишь син!

– Дәүләтнең көче байлыкта, Зариф, – диде Җиһанша абзый, сабыр гына. – Байлык булса, акрынлап атомы да, барысы да булыр.

– Белмим шул, Җиһанша абзый... байлыгын байлык та бит, әмма ләкин атомның сикрите тегенең кулында ич! Әллә ул сикритен безгә сатар дип уйлыйсыңмы? Җитмәсә, үлгән аюның тиресен үзара бүлешә алмыйча ызгышырга торган бер чакта!

Зөфәр абзыйларның политика турындагы сүзләренә бүтән катнашмады, колак салып кына утырды. Җиһанша абзый аз сүзле, төпле кешегә охшый иде. Акылы сүздән алда йөри булса кирәк. Ничектер үзен тотышында ук чын ирләргә хас тыныч сабырлык аңарда сизелә иде. Кыскасы, булачак «бабай» Зөфәргә ошады. Ә менә булачак «әби» ни өчендер аны бераз гына

борчый, тынычсызландыра иде. Ихтимал, бу Мәфтүхә ханымның ачыктан-ачык бары аңа күзләрен елтыратып карап утыруыннан килә торгандыр. Әйтерсең ул аның тышкы кыяфәтен генә түгел, эчен дә күрергә, капшарга тырыша иде... Мондый «әбидән» бер адымыңны да яшерә алмассың, дип уйларга мәҗбүр булды Зөфәр.

Ирләрнең бер дә кирәксездән чит мәсьәләгә кереп китүләре Мәфтүхә ханымны да туйдырды булса кирәк, ахырда түзмәде, үзе башлап Зөфәргә дәште:

– Сез каядыр Арча кырында торасыз шикелле?

– Әйе, Зинин урамында торабыз.

– Үз йортыгызда, шулаймы?

– Әйе.

– Кайчан алган идегез?

– Былтыр гына әле.

– Зариф абый сөйләгән иде шул. Бик зур, бик матур йорт икән. Рәхәтен күреп торырга насыйп булсын инде.

– Рәхмәт!

– Без үзебез жакт йортында торабыз, – диде Мәфтүхә ханым, сүзне өзмәс өчен генәме, әллә бүтәнрәк бер максат беләнме. – Аркылы Тукай урамында. Квартирабыз болай бик әйбәт, икенче катта, өч бүлмә, дүртенчегә —аерым кухня... Без бит үзебез дә өчәү генә. Җитә, бик җитә.

– Жакт йортында тору бер яктан уңайрак та ул, мәшәкате азрак.

– Белмим инде. Халык хәзер йорт ала да йорт ала. Мин дә Җиһаншага әйтеп караган идем, шәһәрнең шул югары, чиста ягыннан үзебезгә берәр йорт эзлик дип... Ирем әйтә, нигә кирәк ул, ди, без олаеп барабыз, кемгә калыр ул, ди. Аныкы да дөрес инде.

Зариф абзый тагын кунакларның чынаякларына үрелде. Ләкин Җиһанша абзый чынаягын учы белән каплады:

– Булды, Зариф, рәхмәт! Безгә рөхсәт итегез инде.

– Туктагыз ла, бу нинди сүз, күңелле генә сөйләшеп утырганда... Өлгерерсез әле.

Мәфтүхә ханым бала ботыдай ак беләгендәге кечкенә алтын сәгатенә карап алды:

– Юк, чыннан да безгә вакыт икән... Рәхмәт, бик зур рәхмәт сезгә... Инде үзегез безгә рәхим итегез, менә Зөфәр... әфәнде белән бергәләп.

Әфәнде!.. Зөфәр хәтта куырыла төшеп, маңгаен ышкырга тотынды.

Шул арада өйалдыннан кеше сөйләшкәнгә охшаганрак ниндидер тавыш ишетелеп калды. Ул да булмый, гадәттән тыш бернәрсә бар шикелле, бик ашыгып, залга Сәкинә килеп керде.

– Кызыгыз килде... Гамбәр туташ килде!

Зариф абзый урыныннан сикереп торды, икәүләп алгы бүлмәгә чыктылар, икесенең берьюлы килгән кунакны шатланып каршы алулары, кыстап чакырулары ишетелде:

– Һа, хуш килдегез, Гамбәр туташ! Менә рәхмәт, менә яхшы иткәнсез!

– Әйдә узыгыз, уз, Гамбәр җаным, рәхим итегез!

– Ягез инде, йә, тарсынып тормагыз! Бездә ят кеше юк, үзебез дә эти-әниегез генә...

Ә шул чакта залдагылар тып-тын калып тордылар. Җиһанша абзый белән Мәфтүхә ханымның йөзенә азрак кына уңайсызлану билгесе дә чыккандай булды, ләкин алар моны сиздермәскә тырышып, горур гына, киеренке-тыныч кына утыра бирделәр.

Ниһаять, зал ишегендә Гамбәр туташ күренде.

Иң элек Зөфәрнең күзенә ташланган нәрсә шул булды – кыз буйга кечкенә, гәүдәгә бик җыйнак – миниатюрный иде. Аңа әле «туташ» дип дәшергә дә иртәрәк кебек иде. Әмма ул яшь ханымнардай бик бай, бик зәвыклы итеп киенгән иде. Өстендә аның, фигурасына ыспай ятып, туры гына төшкән, шунлыктан буен озынрак та, нәфисрәк тә итеп күрсәткән бик затлы яшел йон күлмәк. Аякларында биек үкчәле, көзгедәй кара «лодочкалар». Колакларында җем-җем уйнаган кечкенә бриллиант алкалар, ә ап-ак муенында вак кына энҗеләрдән өч рәтләп тезгән кыйммәтле муенса. Һәм болар барысы да аңа бик килешеп, ничектер бөтен кыяфәтен яктыртып тора иде.

Хуҗалар Гамбәр туташны нәкъ Зөфәр каршысына утырттылар. Аз гына киеренке тынлыктан соң, Мәфтүхә ханым кызына йомшак кына дәште:

– Нигә болай бик кичектең, кызым? Без китәргә тора идек инде.

Кыз, түбән карап, кызарып кына җавап бирде:

– Дустым озак утырды... Ул гына киткән иде, Алма апа килде.

– Алма апаң килде?

– Әйе.

– Ай Аллам! – дигән булды Мәфтүхә ханым, борчылып. – Онытып та җибәргәнмен, килермен дигән иде шул! Киткәндер дә инде?

– Юк, бездә калды әле...

Мәфтүхә ханым урыныннан ук тора башлады.

– Әйдә, картым, кузгалыйк! Безне кеше дә көтә икән.

– Утырырга иде дә бит әле, кешене көттерү уңайсызрак шул! – диде Сәкинә, аптырабрак калгандай.

Кунаклар тагын бер кат рәхмәт әйтеп, урыннарыннан тордылар. Шул чакта Гамбәр туташ кыюсыз гына әйтеп куйды:

– Мин дә алайса... калмыйм.

– Ә юк, сеңелем! – диде Зариф абзый, гаҗәп бер өлгерлек белән. – Кузгалмыйсың, рөхсәт итмибез! Синең кебек соңга калган кунагыбыз бар әле, менә бергә-бергә ашап-эчәрсез, Алла бирсә!

Мәфтүхә ханым да гүя икеләнебрәк кенә әйтеп куйган булды:

– Килеп кергәч тә кузгалу килешмәс инде, кызым, азрак утыр, булмаса!

Хуҗалар кунакларны озата чыктылар. Зөфәр башын игән чәчәк төсле каршысында утырган туташка карап, эченнән генә: «Кыз белән очраштыру менә ничек була икән ул! – дип уйлады. – Ә шулай да таныштырырга оныттылар...»

– Гамбәр... Сезнең исемегез Гамбәр икән!

Кыз сискәнгәндәй керфекләрен тибрәтеп, Зөфәргә бер карап алды.

– Әйе! – диде ул, пышылдап кына.

– Бик оригинальный исем, матур исем.

Кыз елмайды, кызарды, ләкин сүз кайтарып әйтә алмады.

Зөфәр һич тартынусыз кызны җентекләп карарга тотынды. Абыйсы бераз арттырып җибәрсә дә, гомумән, дөрес сурәтләгән икән: кыз сөйкемле-чибәр генә иде. Кашы-күзе кара, керфекләре озын, йөзе бик чиста-ак, тик аңа гаҗәп тиз кызыллык йөгерә һәм тиз үк кире дә кайта; борыны төз генә, кечкенә генә, авызы да уймактай кечкенә, ә ияге... Зөфәр хәзер генә шәйләп алды: ияге очлы һәм озын икән. Менә ни өчен ул, бичара, башын гел түбән иеп утыра, имеш! Шулай утырганда сизелми диярлек, ә йөзен күтәр дисә, очлы озын ияк алга таба сөзә дә чыга. Һәм бу нәрсә аның матур-нәфис йөзен нык кына боза иде. Кызганыч!

Зөфәр кызның буй-сынына да игътибар итте; әйткәнебезчә, кыз буйга кечкенә булса да какча-ябык түгел иде. Һәр җире бик чамалы, бик килешле, тулы-йомры гына иде... Абыйсының: «Нәгызь», – дигәне менә аңлашылды хәзер...

Кыскасы, Гамбәр туташ Зөфәргә ошады. Ничево, зарарсыз, кабул итәрлек, әгәр ияге генә эшне бозмаса, бер караудан гашыйк та булырга мөмкин булыр иде дип уйлады ул.

Ашыгып кергән Сәкинә җиңгәсе:

– Көттердем сезне, кунакларым, хәзер була, бөтен нәрсәм дә әзер, – диде һәм кунаклар алдына тәлинкә,кашыклар куя башлады.

Зариф абзый бик кәефләнеп, кулларын уа-уа килеп керде.

– Менә сезгә, яшьләргә, мин әйтәм, олыларның китүе әйбәт тә булды бит әле. Аулакта, ичмасам, бер иркенләп утырырсыз.

Буфет алдыннан кызыл вино салган графин белән ике рюмка алып, өстәлгә куйды, аннары тәкәллефләнеп торуны хәзер артык нәрсәгә санап булса кирәк, Зөфәргә туп-туры әйтте:

– Син, Зөфәр, үзең кунак та, хуҗа да бул инде. Туташны бик әйбәтләп сыйла!

– Ә син?

– Ә мин китәм, – диде Зариф абзый, ваемсыз-тыныч кына. – Барасы җирем, күрәсе кешеләрем бар.

Зөфәр, абыйсының хәйләсен ачык сизеп, авыз кырые белән генә елмаеп куйды: әйдә, көйлә инде, көйлә!

Сәкинә җиңгәсе кунакларның тәлинкәләренә пилмән сосып чыкты. Зөфәр рюмкаларга вино салды.

– Ягез, Гамбәр, болай булгач, икәү генә сыйланыйк әле... Күтәрегез!

Гамбәр туташ каш астыннан гына аңа карап елмайды, ләкин рюмкасына үрелмәде.

– Ягез инде, көтәм!

– Ягез, йә, туташ! – диде Сәкинә дә. – Аз гына эчкәннән берни дә булмас.

Кыз сузылырга куркып, һаман тик кенә утыра бирде.

– Алайса мин дә эчмим, – диде Зөфәр, рюмкасын кире куеп.

Шуннан соң гына Гамбәр туташ, ияк очына кадәр кызарып, рюмкасын кулына алды. Зөфәр чәкәштерер өчен үзенекен аңа сузды:

– Сезнең саулыкка!

Кызның кулы калтырады, виносы чайкалды һәм рюмкасын ирененә тидереп кенә алды. Пилмәнгә дә ул юньләп кагылмады – бик кыстагач кына бер-ике кашык капкан булды. Сәкинә пилмәннән соң кара җимеш салып пешергән пылау китерде – кыз аны да әз-мәз генә капкалады. Аннары өрек суы килде...

...Зөфәр туташка карап тыелып тормады инде, алдына килгән берсен ашап бетерә барды, чөнки ул бик ачыккан иде. Шул ук вакытта ул кунагын игътибарсыз калдырмаска тырышты, кыстап, ашларны мактап, һаман сүз ката торды. Әмма шуннан артыгына көче-сәләте җитмәде, чөнки үзен махсус күрсәтергә килгән туташыбыз артык тыйнак, артык йомык, артык киеренке хәлдә иде. Ул, бичара, егет алдында үзен гүя менә витринадагы манекен шикелле хис итә иде. Хәрәкәт тә юк, сүз дә юк, тик шунда эчтән калтырап, тыштан янып һәм бөтен зиннәтләре белән ялтырап утыра иде.

Чәйдән соң алар кузгалдылар. Зөфәр Гамбәр туташны озата барды. Суконныйдан Кабан буена чыктылар, аннары Болак күпере аша узып, күлнең икенче ягына борылдылар. Кыз егеткә бераз иялəшеп өлгерде, ахрысы, юл буенча алар ашыкмыйча гына анысы-монысы турында

сөйләшеп бардылар. Билгеле, күбрәк Зөфәр инициатива күрсәтергә тырышты, сорашты-нитте, шулай итеп кызның да беркадәр телен ачты.

Аркылы Тукай урамының очына җиткәч, кыз тукталды. Зөфәр аңлады – туташ үз өйләренә чаклы ук барып җитәргә теләми, уңайсызлана иде. Саубуллашкан чакта Зөфәр аның кулын каты итеп кысты, күзләренә карады, ничек тә җылырак итеп:

– Ышанам, бу безнең соңгы очрашуыбыз булмас, шулаймы, Гамбәр? – диде.

Туташ гадәтенчә кинәт кенә кызарды, мескен генә елмайды, озын керфекләрен тибрәтеп, башын кагып куйды.

Аерылып киткәч, Зөфәр кыз турында уйланып кайтты. Менә өйләнергә дип мактый-мактый димләгән туташны аңа күрсәттеләр. Ни дисең, ярамаслык кыз түгел, билгеле. Начар хатын булмас, бәлкем. Гомумән, кечкенә хатыннарны бик тәүфыйклы, бик ир җанлы була дип сөйлиләр. Аннары моңа өйләнүе дә бик ансат булыр шикелле... Тик шунысы гына аяныч: кыз Зөфәр күңелендә хәзергә бер генә төрле дә хис уята алмады. Сәбәбе нәрсәдер инде моның?

**XV**

Зөфәр шәһәрдә яңа ачылачак универмагка коммерческий директор булып барырга ризалыгын бирде. Хәзер аны күчерү турында Сәүдә министрлыгы белән ОРС арасында сөйләшү бара. Тоткарлык булмас кебек, чөнки Зөфәр ОРС җитәкчеләренә үзенең китәргә теләвен ачык белдерде. Һәрхәлдә, берәр атнадан ул яңа урында эшли башларга тиеш.

Яңа эш – киләчәккә яңа юл. Зөфәр мәсьәләгә әнә шулайрак карый. Иң элек ул үзенең хезмәт эшчәнлегендә югарырак баскычка күтәрелә, дәрәҗәлерәк кешегә әверелә, шулай итеп аның алдында яңа мәйдан, яңа киңлекләр ачыла. Шуңа карап инде ул эшен-гамәлен дә, көнкүрешен дә ничектер бүтәнчәрәк, яңа шартларга яраштырып, көйли белергә тиеш. Кем белә, бу сәүдә эшендә ул бәлки тагы да югарырак үсәр. Моның өчен аның бөтен мөмкинчелекләре бар. Әгәр эш партияле булу-булмауга килеп терәлә башласа, анысын да уйлап карарга ярый. Иптәш Әхмәтҗанов үзе үк өндәп тора бит... Дөрес, Зөфәр моңарчы нисбәтән кечкенә кеше иде, партиясез көенә дә бик әйбәт эшләп килде, кыскасы, урын өчен генә курка-шикләнә партиягә керүнең кирәге булмады. Инде киләчәктә кирәк була икән... хәер, бу хакта алдан ук баш ватмыйча да торырга мөмкин. Башны ваттыра торган икенче, ашыгычрак мәсьәләләр бар әле монда...

...Бу – Рәшидә – Гамбәр мәсьәләсе. Зөфәр өчен менә шул төенне, ниһаять, чишәр вакыт җитте. Һәм ничек тә озакка сузмыйча.

Дөресен генә әйткәндә, Гамбәр мәсьәләсе аны артык борчымый да, уйландырмый да иде. Аңа җиткерделәр инде – ул кызның үзенә дә, əти-әнисенә дә бик ошаган. Әгәр Зөфәр

тарафыннан әйбәтләп, чынлап сорау булса, шик юк, ике куллап бирәчәкләр. Ә кыз ярамаслык түгел. Шуңа күрә Гамбәрне ул кесәсенә кергән мал кебегрәк итеп саный иде инде.

Әмма Рәшидә... Рәшидә икенче мәсьәлә. Рәшидә турында ансат кына уйлавы да, тәгаен бер карарга килүе дә бик-бик читен. Тик бер генә нәрсә ачык: аның йөрәгендә Гамбәр туташ Рәшидә урынын ала алмады, хисләре аның Рәшидәдә, һичшиксез, ул Рәшидәне ярата... Ияләшкән, күнеккән дә инде ул аңа – кинәт кенә аерылуы, югалтуы бик авыр булачак.

Соңгы көннәрдә Зөфәрне, бөтен корып йөргән исәпләренә каршы килеп дигәндәй, бер уй бик нык били, борчый башлады: әгәр ул Рәшидәгә өйләнеп куйса, ә?.. Тузга язмаган тиле, кысыр бер хыял түгелме бу?.. Мөмкин эшме, кирәкме, хәерлегә булачакмы? Ул бит күпме генә яратып йөрмәсен, Рәшидәгә өйләнү дигән фикерне моңарчы башына да китермәде. Киресенчә, иртәме-соңмы ике ара өзелергә тиеш дигән уй белән йөрде, шуңа исәп тотты, хәтта артык якынаеп китмәс өчен мөмкин кадәр сирәгрәк очрашырга тырышты. Башта ук бит ул аны кемнәндер калган хатын дип, артистка дип, үзе өчен һич лаек булмаган кешегә санады.

Ә хәзер аның уйлары – гаҗәп хәл! – бөтенләй икенче юнәлеш ала башлады: хуш, Рәшидә хатын кеше, ди, ләкин аңардан ни зарар? Өйләнер өчен кыз гына булсын дигәнмени?.. Гамбәр әнә өлгереп кенә җиткән кыз да бит, әмма ләкин булачак хатыныңның бөтен яме-тәме бары шуңарда гынамыни?.. Ә соңыннан ул Рәшидәдәге төсле нәфислекне, нечкәлекне, хисләр дәртен аңарда табармы, Рәшидәне яраткан кадәр үк аны яратып китә алырмы —бу кадәресе бик шикле!

Ләкин хикмәт анда гына да түгел әле. Иң мөһиме, шуларның кайсысына – Рәшидәгәме, Гамбәргәме өйләнү аның өчен отышлырак булачак? Дөрес, Гамбәргә өйләнү хәвефсезрәк, ә Рәшидәгә өйләнү куркынычрак, чөнки Рәшидә эше-тормышы белән аңардан шактый ерак кеше. Ләкин бу хәзергә генә шулай тоелмыймы икән, бергә кушылгач, бәлки пар күгәрчендәй яраклашып торып та китәрләр. Кешеләрне уртак тормыш бик нык бәйли бит ул.

Аннары мәсьәләнең бу ягы да бар: ни өчен ул үзен бөтен яктан да бары сәүдә кешеләре белән чорнап алырга тиеш? Ул бит хәзер дәрәҗәле кеше, үсеп бара торган кеше, бәс, шулай булгач, сәүдәгәр абзыйлар, сәүдәгәр бабайлар киләчәктә аның аягына тагылган авыр герләргә әйләнмәсләрме? Коммерческий директор тирәсендә кемнәр чуала, кемнәр белән ул аралаша-йөри, туган-тумачасы, агай-энесе кем – моны бит исәпкә алып торучылар булачак. Онытырга ярыймы соң!.. Ә хатының башка эш кешесе, әйтик, артистка булса, халык күзенә дә, начальниклар каршында да аның өчен бик уңай, бик отышлы булып чыгуы мөмкин. Чынлап та, Зөфәр Сабитовның хатыны яшь кенә артистка – бу, русчалап әйтеп җибәргәндә, что-то стоит, шайтан алгыры! Үзе төскә чибәр, сылу, кыланышлары сөйкемле, акыл да, сизгерлек тә юк түгел, чөчеп карауфылар аз булмас иде аңа... Искусство әһеле почетта хәзер, тик бер ялтырап,

күтәрелеп кенә китсен!.. Әлбәттә, ул үзенең Рәшидәсен иң модный, иң затлы киемнәргә генә төреп, кадерләп кенә йөртер иде... Һәм алар алдында нинди генә түрәләрнең ишекләре ачылмас иде!

Менә шундый хыяллар Зөфәрне соңгы вакытта котырта һәм мавыктыра башлады. Ә Рәшидәгә килгәндә инде, Зөфәр артык шикләнми иде, тәкъдим ясый калсам, риза булыр, чыгар, дип ышана иде. Юк, чыннан да, нишләп риза булмасын ди ул?.. Бердән, Рәшидә аны ярата, икенчедән, менә өч ел инде болай да аңа хатын булып йөри, өченчедән, Рәшидәнең дә бай, рәхәт тормышта яшисе килмимени? Артистка ич ул!

Кыскасы, Зөфәр Рәшидә белән яңадан бер очрашып, ачыграк һәм чынлабрак сөйләшеп карарга булды. Әлбәттә, ул аңа туп-туры: «Мин сиңа өйләнәм!» – дип әйтергә ашыкмас, чөнки бу җиде кат үлчәп, бер кат кисүне сорый торган мәсьәлә. Башта кылын тартып карар, бераз өметләндереп куяр, аннары инде... күз күрер!.. Шулай уйлап, бераз баш ваткач, ул Рәшидәне туры үзенең өенә чакырырга булды. Әйдә, килсен, күрсен, белсен Зөфәрнең ничек яшәвен!.. Шушы үзе үк яшь хатынның йөрәген һәм хыялын әсир итмәсме?

...Инде бу карарга килгәч, тагын бер бик четерекле мәсьәләне хәл итәсе калды: Рәшидәнең килүен әнисе Таибә абыстай күрү түгел, сизми дә калырга тиеш. Шулай итмәгәндә бер хикмәт тә чыкмаячак. Бүтәнен әйткән дә юк, хәтта юньләп сөйләшү дә мөмкин булмаячак... Соң, билгеле инде, Гамбәр туташны димләп кенә йөргән чакта улы янына яшь бер ханымның килеп керүен карчык, керпе шикелле, бөтен энәләрен торгызып каршы алачак. Мондый вакытта үтә сизгер, үтә уяу булалар бит ул әни карчыклар!.. Димәк, аңардан котылырга кирәк. Ләкин ничек итеп, нинди генә хәйлә белән үзен берәр яры чыгарып җибәрергә!

Төрлечә уйлап, озак кына баш ватканнан соң, Зөфәр, ниһаять, исенә төшерде: әнисе күптән зиратка барып кайту турында сөйләнә иде. «Бу йортка күчкәч, барып әтиегезнең рухын шатландыра алганым юк, көтәдер, бичара, бетмәде бу дөнья мәшәкате дә!» – дип, еш кына зарлана иде. Менә шәп тә булыр иде әгәр карчыкны шул Яңа бистә тарафларына озатып булса! Ләкин моны бик оста, шома эшли белергә кирәк.

Җомга көн кичке чәй янында Зөфәр газета караштырып утырган җиреннән әнисенә гүя болай гына әйтеп куйды:

– Әни, күптән зиратка әти янына барып кайту турында сөйләнә идең... Бара алмадың ахрысы инде...

– Кирәк иде, бик кирәк иде дә бит, – диде Таибә абыстай, авыр гына көрсенеп, – дөньясы, һич кенә менә бушый алмыйм.

– Әйе, эшең күп шул... Әллә шулай да, мин әйтәм, бу якшәмбедә Хөршид белән икәүләп барып кайтасызмы? Җәй дә үтеп бара...

– Бик әйбәт булыр иде дә бит, йортны ничек ялгыз калдырасың?

– Ә мин ул көнне көн буена өйдә утырачакмын, эшләрем бар... Чын, уйлагыз әле, бүтән минем өй саклап утырырлык көнем әллә булыр, әллә юк. Аннары үзеңнең дә җаның бер тынычланып калыр иде.

– Әйе шул, әйе шул! – диде Таибә абыстай, тәмам килешкән шикелле.

Ә шимбә көнне Зөфәр, Рәшидәгә шалтыратып, аны әйбәтләп кенә үзенә чакырды, адресын бирде, сәгать уникеләрдән калмыйча килеп җитәргә кушты. Рәшидә бу чакыруга бик гаҗәпләнде шикелле, башта ни әйтергә дә белмичәрәк торды, ләкин Зөфәрнең чын ихластан үтенеп чакыруын ишеткәч, килергә риза булды.

Августның соңгы якшәмбесе бик матур килде, элекке кичтән шактый җилләп, төнлә яңгыр ява башласа да, иртән тагын аязып җибәрде. Көн бик җылы һәм тымызык иде... Таибә абыстайның да мондый көнне әрәм итәсе килмәде: иртәнге чәйдән соң тәһарәт алып, озак кына җыенып, ниһаять, Хөршидне ияртеп, зиратка китеп барды. Кичәдән бирле әни кире уйлый күрмәсә ярар иде дип, эченнән бик борчылып торган Зөфәр аларны тыныч кына озатып калды. Хәерле сәгатьтә!

Рәшидә килеп җитәргә дә вакыт күп калмаган иде инде. Зөфәр тагын бер кат үзенең йокы бүлмәсен тиз генә күздән кичерде, тәрәзә пәрдәләрен төшереп куйды, аннары өстен алыштырды. Шартына махсус яхшы да, килешле дә булсын дип, ул өстенә кыек якалы бик иркен ефәк күлмәк һәм чесуча ак чалбар киде. Сары ботинкаларын өйдә генә кия торган кызыл чүәкләр белән алыштырды.

Залдагы биек көзге каршына барды: юк, бик әйбәт, бик килешә икән!.. Йә, кызларның һушын алмаслык егетмени ул? Буе-сыны директорларныкыдай мәһабәт, йөзе сөттә югандай чиста да шоп-шома, ә аксыл чәчләре... Рәшидә сөеп сыйпарга ярата торган чәчләре... кылган чугыдай йоп-йомшак... Хәер, үз-үзенә болай сокланырга ярамый ул. Ирләр эше түгел.

Унике туларга ярты сәгать калды. Зөфәр, бер урында гына тора алмыйча, бүлмәдән бүлмәгә йөри башлады. Ишек-капкалары бикле ялан кадәр йортта япа-ялгыз кеше көтеп утыру, гомумән, җиңел түгел инде ул, ә монда... таш та урыныннан кузгалыр. Беренче тапкыр килә бит, беренче тапкыр аның бусагасыннан атлап керә. Һәм бу минут һаман якынлаша, һаман якынлаша...

Зөфәр атлаган саен сәгатенә күз төшерде, ләкин еш кына ничәне күрсәтүенә игътибар итә алмады, һаман йөренә торды, ахырда, зал тәрәзәсенә килеп, урамга карап тора башлады. Унике

тулып, биш минут үтте, ун минут үтте, ә Рәшидә юк та юк. Чынлап борчылу Зөфәрне, ниһаять, биләп алды: бу ни эш бу, шулай ук килмәве булдымыни инде бу?

Беренче звонокны ул ничектер ишетми дә калды шикелле, ләкин икенче тапкыр шалтырагач, ихтыярсыз сискәнеп куйды һәм ашыгып ишеккә китте. Кем дип сорамыйча гына парадный ишеген ачып җибәрде. Аның каршында күк жакет, ак берет кигән Рәшидә үзе басып тора иде. Зөфәр бер сүз әйтмәстән аны, кулыннан тотып, эчкәре тартып кертте. Ишекне япкач кына дулкынланудан пышылдап:

– Карап торып күрми дә калдым бит, карап торып! – диде.

– Кемне?

– Сине инде, сине! Күзем урамда, ә хыялым әллә кая киткән. Менә нинди хәлгә төшердең син мине...

– Аңламыйм, – диде Рәшидә, коридор уртасында туктала биреп. – Ни өчен аңа мин гаепле?

– Килмисең дип торам, аңлыйсыңмы, шуңа борчылып!.. Унбиш минут узды бит!

Рәшидә җиңелчә генә иңбашын җыергандай итте.

– Минем вәгъдәмдә торуымны беләсең ич! Ә соңга калуга... мин гаепле микән? Беренче тапкыр эзләп киләм бит.

– Әйе шул! – диде Зөфәр, ашыгып һәм Рәшидәне беләгеннән тотып, өйгә алып керде.

Зур залның ишегеннән керүгә Рәшидә тукталды, сәерсенеп тирә-ягына каранды һәм шундук бер урындыкның кырыена гына утырды. Зөфәр дә утырырга мәҗбүр булды.

– Менә килеп бик яхшы иттең бит әле, Рәшидә! —диде ул, нидән сүз башларга белмәгәндәй.

Рәшидә эченнән сиздермичә генә сулап куйды.

– Килдем шул... Чакырган җиргә бар, куган җирдән кит, диләр бит...

– Нигә алай дисең, Рәшидә? Мин сине куар өчен чакырмадым.

Рәшидә дәшмәде, түшәмгә карады, стеналарга карады, аннары башын кырынайтып, нәрсәгәдер колак салыбрак торды.

– Әллә өйдә берәү дә юк?

– Юк шул.

– Нишләп?

– Шулай... китеп беттеләр, – диде Зөфәр, тотлыгыбрак.

Рәшидә, гүя эченнән генә нидер уйлап, башын кагып куйды. Зөфәр аның кулыннан тотмакчы булды.

– Мин үзем синең белән ялгыз гына калырга теләдем, – диде ул, сер әйткәндәй, пышылдап кына.

Рәшидә кулын акрын гына читкә алды. Елмаймады, кызармады, сын шикелле текә-туры гына утыра бирде. Зөфәр шундук сизде: Рәшидә бүген йомык, Рәшидә бүген салкын. Менә ни өчен алар арасында элеккечә гади-җылы якынлык туа алмыйча тора. Ләкин нидән бу? Ятсынамы, уңайсызланамы, әллә исе китеп калдымы? Хәмит бүлмәсе түгел шул монда!.. Әмма, ничек кенә булмасын, бу салкынлыкны, бу ятсынып маташуларны тизрәк бетерергә кирәк иде. Ул үзе дә әллә ничек каушабрак калды шул, хәерсез!

– Рәшидә, син өстеңне салыр идең, – диде ул, яңадан аңа кыю гына үрелә башлап.

Рәшидә, кулын суза төшеп, аны туктатты:

– Кирәкми.

– Ни өчен?

– Миңа болай да яхшы.

– Куй әле, Рәшидә, үз өеңдәге шикелле генә бул әле... Бу нинди ятсынып тору, килешмәгәнне!

– Мин ятсынмыйм, тик...

– Нәрсә «тик»?

– Сәер, әллә ничек... Менә килдем, ә ни өчен килдем – үзем дә белмим.

– Үкенәсең?

– Үкенмим дә... – Рәшидә сүзен әйтеп бетермәде.

Зөфәр пошынып һәм үпкәләгән сыман аңа беравык карап торды, аннары җитди генә итеп, ләкин ничек тә йомшак булырга тырышып әйтте:

– Рәшидә, мин сине бүген танып җиткермим! Валлаһи!.. Нигә син болай... күңелсез... салкын? Әллә кәефең юкмы?.. Мин бит сине бик теләп чакырдым. Менә үз өемдә сине күрәсем килде... Йә, начармыни бу?

– Юк, мин алай димим, Зөфәр... Син чакырдың —мин килдем... Тик... бу чакыруның, ничек дим, максатын аңлап бетермим әле мин... күпме вакыттан соң беренче мәртәбә бит... Әллә ничек...

Зөфәр бик аз гына иреннәрен кысып торды.

– Мин сиңа, Рәшидә, шуны әйтергә тиешмен: бу йортны мин былтыр гына сатып алдым... Аңарчы без ике семья бер кечкенә квартирада тордык... Алгач та әле моның эше күп булды. Ремонт, тегесе-бусы... Ну вот хәзер аны кешегә күрсәтергә дә ярый. Ә минем сиңа кайда, ничек торуымны күптән күрсәтәсем килә иде... Чын әгәр!

– Рәхмәт!.. Ә шулай да син, Зөфәр, яшерен кеше икәнсең... Бер генә тапкыр да әйтмәдең бит...

– Ә нигә алдан шауларга? – диде Зөфәр, көлгән булып, һәм урыныннан торды. – Ә хәзер, дустым, мин сиңа... апартаментларымны күрсәтим әле. Иң элек бакчага чыгыйк.

Рәшидә сүзсез генә аңа иярде. Аш бүлмәсе аша террасага чыктылар. Зөфәр, туктала биреп, Рәшидәне алгарак уздырды. Бакча!.. Карт, зур бакча!.. Түрдә кып-кызыл алмаларын көчкә күтәреп торган терәүләр салган карт алмагачлар... Ә монда, терраса алдында гына, балкып янган куе кызыл, ак, сары геогрин, астра (йолдыз) чәчәкләре... Һәм шуларның барысыннан Рәшидәгә бөтенләй билгесез, ләкин укыпмы-ишетепме хыялында сакланган нindидер борынгы дворяннар тормышы кинәт аңкыгандай булды... Ул бик азга гына тукталып калды һәм ихтыярсыз бер тыннан әйтеп ташлады:

– Мату-ур!

Шунда ук аның күзләрендә балаларча самими, якты сөенү кабынды. Җиңел генә түбән төште, түтәл тирәсен әйләнә-әйләнә чәчәкләрнең әле берсен, әле икенчесен иелеп исни башлады. Зөфәр, аңа карап, куана калды – ул белә инде, Рәшидә болай сөенеп, рухланып киткән чагында аңа бик ышанучан, назлы һәм күндәм була торган иде.

– Рәшидә, чәчәкләрнең матурларын гына өзеп биримме? – диде ул.

– Юк, юк, кирәкми, – диде Рәшидә, ашыгып.—Җәлләмичә өзәргә ярыймы соң!

Зөфәр кыстамады, ул үзе дә чәчәкләрне өзәргә яки өздерергә яратмый иде... Бакчаның түренәрәк уздылар. Рәшидә әле бер, әле икенче агач янында тукталды, күтәрелеп карады, тирә-ягына каранды һәм гаҗәпләнеп сорады:

– Бу бакчаны кем карый соң?

– Күбрәк әни, сеңелкәш карыйлар, үзем дә буш вакытта казынам, – диде Зөфәр. – Дөрес, башта бер карт килеп, тәртипкә китереп, безне өйрәтеп китте. Безнең өчен яңа эш бит әле бу... Йә, ничек соң, ошыймы сиңа бакча?

– Ошый, бик матур!

– Аңа әле карау җитми. Әнигә авыр, сеңелкәш рәтен белми, үзем бушый алмыйм. Караучы кирәк.

– Кеше ялла.

– Юк, ни өчен ялларга?.. Ялларга ярамый... Монда тагын... бер хуҗа кирәк.

– Нинди хуҗа?

– Менә минем үзем кебек.

Рәшидә, аңлап җитмәгәндәй, Зөфәргә күтәрелеп карады һәм шунда ук күзен түбән төшерде. Гүя үзен көчләп кенә әйтте:

– Анысын да табарсың.

– Ә кемне? – диде Зөфәр, сак кына.

Рәшидә алгарак узып, исе киткән булып, карт алмагачка карап тора башлады. Зөфәр моның җаваптан качу икәнен сизде. Алмагачның кып-кызыл алмалар сырган өстәге бер ботагын Рәшидә алдына бөгеп төшерде.

– Йә, иң әйбәтләрен генә үз кулың белән өзеп ал әле!

Рәшидә үзе дә ни өчендер алмадай кызарды, аз гына кыюсызланып торды, аннары сайламыйча гына берсенә үрелде.

– Анысын түгел, менә боларын.

– Барыбер инде.

– Барыбер түгел шул. Зуррагын, пешкәнрәген.

Рәшидә Зөфәр күрсәткән алмалардан берсен генә өзеп алды.

– Нигә берне генә, – диде Зөфәр. – Өз әле, өз!

– Юк, җитте, мин алманы берьюлы күп ашый алмыйм, тешем камаша.

– Кесәңә салырсың.

– Кесәм юк, – диде Рәшидә, ничектер бик уңайсызланып.

Зөфәр алмагач ботагын кире җибәрде. Рәшидәнең уңайсызлануына юри игътибар итмәскә тырышып:

– Ярый алайса, – диде, – киткән чагында мин сиңа пакетка салып бирермен.

...Алар өйгә таба борылдылар. Зөфәр Рәшидәнең култыгыннан алды. Ничек тә яшь ханымны юатасы, юмалыйсы килә иде.

– Сиңа ничектер, сөеклем, ә миңа бик рәхәт бит әле,—диде ул, Рәшидәнең беләген үзенә ныграк кысып.

– Нидән ул? – диде Рәшидә, акрын гына.

– Нидәнме?.. Синең белән аулак бакчада менә шулай икәүдән-икәү генә йөргәнгә күрәдер инде... Беләсеңме, көн дә мин сине бу бакчада култыклап кына йөртер идем.

Рәшидә уйчан-боек кына елмайды, ләкин кайтарып бер сүз дә әйтмәде. Бу бакчага чыгу белән аңарда кабынган балаларча сөенү нишләптер акрын гына сүнә башлаган иде инде.

Өйгә керделәр. Зөфәр, бүлмәдән бүлмәгә күчеп, Рәшидәгә өен күрсәтте. Рәшидә аңа ияреп, якты, зур, ләкин җиһаз җитмәгәнлектән күбесе шактый шәрә күренгән бүлмәләрне сүзсез генә карап йөрде. Инде Зөфәр аны үзенең өр-яңа никель караватт куелган, стенасына һәм идәненә

кыйммәтле келәмнәр түшәлгән йокы бүлмәсенә алып кергәч, Рәшидә ишектән ерак узмыйча тукталып калды. Әйтерсең аны нидер куркытты. Ә Зөфәр, аны-моны абайламыйча:

– Бу инде минем спальный була, – дип сөйләнде.—Ялгыз ир бүлмәсе, сиңа бераз шыксыз күренәдер инде... Уютный итәр өчен хатын-кыз кулы кирәк шул, дөресме?

Рәшидә, нидер уйланып, башын гына кагып торды. Зөфәр исәбенчә, бу бүлмәдән күз йөртеп кенә кире борылырга ярамый иде. Бу бүлмәдә алар арасындагы менә хәзерге һич аңлашылмаган әллә нинди киеренке салкынлык бетәргә, яңадан элекке җылы якынлык туарга тиеш иде. Моның өчен күп тә кирәкми, сынаганы бар, әгәр шушы урында ул Рәшидәне кочагына алып, юмалап-сөеп кенә бер назласа, ханым балавыз кебек йомшарып калачак. Әйе, бары шулай гына... Һәм ул Рәшидәнең алдына басты да кинәт кенә биленнән кочып, иелеп, кайнар пышылдап: «Син генә җитмисең монда, син генә!» – дия-дия аның битеннән, иреннәреннән кызу-кызу үбәргә тотынды. Рәшидә бер мәлгә онытылып, сеңеп калды, ләкин Зөфәрнең, аны кочаклаган килеш, караватка таба чигенә башлавын күргәч, кинәт башын артка ташлап, ике кулы белән дә егет күкрәгенә терәлде.

– Җибәр! – диде ул, куркуыннан хәтта тавышсыз калып.

– Йә инде, Рәшидә, бәгырем, йә инде!

– Юк, юк, җибәр! – диде Рәшидә, бөтен көченә карышып.

Зөфәр аны таза кулларыннан ычкындырмыйча аз гына тукталып, тәмам исе китеп, кайнарланып сорады:

– Ни өчен соң, йә, ни өчен?

– Юк, юк, булмый, мөмкин түгел! – Һәм Рәшидә, кисәк кенә чүгеп, егетнең кочагыннан шуып чыкты да бер адым артка чигенде.

Зөфәрнең йөзе берьюлы бүртенеп китте, күзләре кысылып калды, яңак сөякләре уйнаклап куйды. Көчкә тынын алып, усалланып әйтте ул:

– Ә тегендә... Островскийда ярый иде?

– Әйе, анда ярый иде, анда без бертигез идек, – диде Рәшидә, кабаланып һәм ярсып. – Ә монда юк, монда теләмим, монда мин хурланам, хурланам, аңлыйсыңмы?.. Ходаем, кемгә генә санныйсың соң син мине?! – Һәм кычкырып елап җибәрмәс өчен ул бүлмәдән атылып чыгып китте.

Зөфәр беравык, үгездәй башын иеп, уң чигәсен ышкып торды. Берни уйлый алмаса да: «Тынычланырга кирәк, тынычланырга!» – диде ул үз-үзенә, аннары авыр гына кузгалып, Рәшидә артыннан залга чыкты.

Рәшидә урамга караган тәрәзә янында басып тора иде. Иңбашлары салынган, ләкин кызларныкыдай нечкә фигурасы, оеп калгандай, ничектер бик тын-хәрәкәтсез күренә. Юк, еламый булса кирәк... Зөфәр аның артынарак барып басты. Гаҗәп авыр тынлык һәм бушлык. Шактый сүзсез торганнан соң, Зөфәр акрын гына әйтеп куйды:

– Аңламыйм, һичнәрсә аңламыйм! Әллә ни булды...

Рәшидә дәшмәде, селкенмәде. Зөфәр аның аз гына бөгелә төшкән тигез аркасына, чәч бөртекләре арасыннан күренгән нечкә муенына, яңадан орынасы килеп, карап торды.

– Бик ачуландыңмы?

– Юк, – диде Рәшидә, көттереп, сүлпән генә.

– Чынмы?

Рәшидә тирән итеп бер сулады:

– Үзем гаепле, белеп килдем бит...

– Нәрсәне?

– Ни өчен генә чакыруыңны... Ярый, мин китим инде.

Рәшидә тәрәзәдән борылды – йөзе бик боек, күзләре тәмам сүнгән иде аның.

– Тукта, Рәшидә, ашыкма! – диде Зөфәр, аңа юл бирергә теләмичә. – Безгә сөйләшергә кирәк.

– Тагын нәрсә турында инде?..

– Бар әле, бар... Сөйләшмичә булмый... – Ул Рәшидәгә урындык алып куйды. – Утыр әле шунда, утыр!

Рәшидә, аз гына икеләнеп торганнан соң, урындыкның читенә генә утырды. Зөфәр, икенче урындыкны тартып, аның каршысына утырды да... тезләренә таянып, уйга калды. Нәрсәдән, ничек кенә итеп сүз башларга да авыр иде аңа. Рәшидәнең һич көтмәгәндә бу кадәр кинәт һәм кискен рәвештә каршылык күрсәтүе аны тәмам аптырауга төшерде, киртәсеннән чыгарды, бөтен исәп-планнарын аударып ташлады. Искиткеч мәгънәсез, ямьсез, читен бер хәлгә куйды ул үзен! Һәм шушы хәлдән ничектер чыгарга кирәк. Алай гына да түгел, менә хәзер тагын да ныграк суына, ераклаша, читләшә төшкән Рәшидәгә үзенең асыл теләген ничек тә ышандырырлык итеп аңлата белергә тиеш ул. Читен мәсьәлә. Гомумән, ул бүген, роленә керә алмаган артист шикелле, ни үзен, ни сүзен таба алмыйча азаплана – гомердә булмаган хәл.

– Рәшидә, – диде ул, ниһаять, иелгән килеш кыенсынып кына, – иң элек син мине кичер, яме! Минем хәлемә дә кер. Мин бит сине... яратам, сиңа бик ияләштем, ну... ачык кына әйткәндә, сине теләмичә тора алмыйм мин... Моны үзең дә беләсең бит. Минем генә гаеп түгел ич!.. – Ул куркынып Рәшидәгә күтәрелеп карады һәм аның, теше авырткандай, чыраен сыта

башлавын күреп, тизрәк сүзен дәвам иттерде: – Ләкин, Рәшидә бәгырем, әгәр син бу мине бары шуның өчен генә чакырган дип уйласаң, бик нык ялгышасың. Әйе, ялгышасың!.. Аңла, бер дә аның өчен генә түгел. Бөтенләй икенче максат белән чакырдым мин сине... Бик зур сүз әйтү өчен... Әйе, бик җитди мәсьәлә турында, беләсең килсә! – Ул, Рәшидәдән берәр сүз ишетергә теләп булса кирәк, тагын бер генә мизгелгә тукталып калды. Ләкин Рәшидә, куркып очарга торган кош шикелле, ничектер бик текә-киеренке утыра иде. Зөфәр сак кына аның кулын алды: – Әйтим алайса... Мин... өйләнергә булдым, менә сиңа өйләнергә, аңлыйсыңмы, Рәшидә, сиңа!

Рәшидә ток бәргәндәй сискәнеп китте һәм тирән әрнү белән өзгәләнеп әйтеп ташлады:

– Уйнама, Зөфәр!

– Юк, нишләп уйныйм, ди. Алла сакласын! Мин сиңа чынлап әйтәм, Рәшидә!

– Юк, юк, ышанмыйм!

– Ни өчен?.. Тукта, син иң элек тынычлан әле, тынычлан! Хәзер барысын да аңлатып бирермен.

Рәшидә, ике кулы белән битен каплап, күпмедер тынып торды, аннары йөзен ачты, турайды һәм шик, өмет, газап тулы күзләре белән үтә җитди итеп Зөфәргә карап тора башлады.

– Син беләсең, – диде Зөфәр, бу караштан ихтыярсыз борчылып, – мин ялгыз кеше, миңа өйләнергә кирәк. Бу бик аңлашыла торган нәрсә бит инде... Тик мәсьәлә —кемгә?.. Иң читене шул бит? Бу турыда мин бик күп уйландым. Синнән яшерәсем килми, сайларга кызлар бар иде... Ләкин мин ашыкмадым, күңелемә ошаганны эзләдем. Һәм таптым. Ул – син, Рәшидә, син, ышанасыңмы?.. Өч ел бит инде мин синең белән йөрим, сине беләм, җитәрлек өйрәндем, чынлап яраттым...

Рәшидә иңерәнеп куйды:

– Ходаем, өч ел буе йөреп, ник бер сүз әйтсәң иде! Нинди кеше син?!

– Алай димәле, Рәшидә! Һәр эшнең үз җае, үз вакыты бар. Иң элек мин ныклы бер карарга килмичә торып, алдан шауларга яратмыйм. Икенчедән, өйләнүгә мин җиңел генә карый алмыйм. Сүз бит семья кору турында бара. Моның өчен мин булачак семьяның башта, ничек дим, материаль нигезен салырга тиеш идем. Ә бу күп көч, күп вакыт сорый торган нәрсә. Былтыр менә шушы йортны сатып алдым, быел аны төзәттердем, яңарттым... Җиһазлар алдым... Хәзер ул яктан кайгы бетте диярлек. Инде менә...

– Димәк, барысы да план белән?

– Әйе... Нигә, начармыни ул?

– Юк, начар димим... Хәер, белмим, аңламыйм мин берни дә.

– Син бер генә нәрсәне аңларга тырыш, җанкисәгем! —диде Зөфәр, аның кулын йомшак кына сыйпап. – Мин сиңа өйләнергә телим, мин сине шушы йортка чакырам. Бергә торырга, яратышып, бәхетле булып торырга... аңлыйсыңмы?

Рәшидә әкрен һәм тирән итеп сулый иде. Аның хәтта куллары да суына төште, тезләре дә акрын гына калтырый башлады... Зөфәр, өч ел буена аның җанына һәм тәненә хуҗа булып килгән Зөфәр, менә аңа өйләнергә тели! Ярабби!.. Бәлки, бу аның өчен бердәнбер мөмкинлектер, әйе, ир хатыны, семья кешесе булыр өчен бердәнбер кабатланмас мөмкинлектер? Бәлки аның бәхете шушы йортта, шушы кеше кулындадыр? Аңа ялгызлыктан, нужадан йөдәгән билгесез артисткага тагын ни кирәк?.. Әмма мөмкин эшме бу?

Зөфәр көлемсерәп әкрен генә сорады:

– Йә, ни дисең, сөеклем?

– Белмим, күзем җитми, ышана алмыйм мин бу эшкә!

– Гаҗәп!.. Ничек ышанмыйсың? Мин әйтәм ич сиңа моны, мин әйтәм, чынлап торып... Ишетәсеңме?

Рәшидә гүя хәлсез бер гаҗизлектән кинәт үксеп җибәрде:

– Газап... газаплама мине, Зөфәр!

Зөфәр җитез генә үрелеп, аны аркасыннан кочаклап алды:

– Чү, ярамый болай!.. Тынычлан, иркәм, тынычлан!.. Менә шулай!.. – Ул якынрак шуышып, Рәшидәне күкрәгенә кысты. – Җүләрем, газаплаумыни бу?.. Бәхет турында сөйлим ич мин сиңа, бәхет турында! Мин... мин... сине көне-төне менә шулай назлап-сөеп кенә торырмын, рәхәттә йөздерермен мин сине... Бер кайгың, бер нужаң булмас синең... Менә бу йорт, менә бу җиһазлар, әнә теге гөлбакча – барысы да синеке булыр... Хуҗа булып, хуҗа гына түгел, бикә булып торырсың!.. Йә, бу бәхет түгелмени, сөеклем?

– Куркам мин бу бәхеттән, – диде Рәшидә, Зөфәрнең күкрәгенә пышылдап кына.

– Тиле, тиле! Бәхеттән куркалармыни?! Бәхетне аны тилмереп эзлиләр, аулыйлар, кирәксә, сугышып, тартып алалар!

Һәм ул, яңадан кабынып, тагын да ныграк елышып, Рәшидәнең түшләренә кулын салды, Рәшидә айнып киткәндәй булды.

– Тукта, кирәкми, җибәр! – диде ул, тизрәк Зөфәрдән тайпылып.

Зөфәр кисәк кенә көлеп куйды:

– Никахтан соң дисеңмени инде?

Үткен пычактай телеп җибәрде бу сүзләр Рәшидәнең йөрәген, тирән сызланудан йөзе сытылып китте:

– Көләсең?

– Юк, юк, бетте! – диде Зөфәр, ашыгып. – Мин болай гына, шаяртып кына... Ачуланма!.. Соң бит инде син минем хатыным, фактически хатыным, шулай түгелмени? Нигә дөреслектән куркырга? Ә тиздән законный хатыным булырсың! Мин шуны телим, бик телим, син дә теләргә тиешсең!.. Үзең өчен бит? Йә, ник дәшмисең?

Рәшидә әллә аптыраудан, әллә килешә алмаудан сүзсез, акрын гына башын чайкап торды.

– Нигә башыңны чайкыйсың? Мин әйткәннәр дөрес түгелмени?

– Дөрес, – диде Рәшидә, авыр көрсенеп. – Кызганычка каршы, дөрес!.. Синең өчен мин бары хатын гына булдым шул, хатын гына... шуңардан башканы син миндә күрмәдең дә, белмәдең дә... Хәер, бүтәнчә булуы мөмкин идемени? Синең үз дөньяң, минем үз дөньям!..

– Башта ук ул шулай иде бит, Рәшидә!.. Ләкин шуңа карамастан без якынаеп киттек ләбаса!

– Зинһар, үткәнне искә төшермик инде...

– Юк, шулай да, – диде Зөфәр, Рәшидәнең гаебен тоткандай кыюланып, – әйт әле, ни өчен башта син безнең дөньялар башка булуы турында уйламадың?

Рәшидә үпкә-рәнҗү тулы күзләре белән Зөфәргә күтәрелеп карады:

– Нинди йөз белән син моны әйтәсең, Зөфәр? Нигә минем ярама кагыласың?.. Беләсең ич... ничек булганын!.. Әйтерсең мин генә гаепле!

– Мин сине гаепләргә җыенмыйм, Рәшидә. Тик шуны гына исеңә төшерәсем килә: мин һаман шул ук кеше бит!

– Әйе, син шул ук кеше... шул ук кеше, – диде Рәшидә, ничектер уйга калып... – Хәер, белмим тагын... шул укмы син, түгелме?.. Тик бер нәрсәне тоям: без... ерак кешеләр.

– Ни өчен ерак?

– Шулай инде... Хәтерлисеңдер, соңгы вакытларда мин синнән: кем син, Зөфәр, кем? дип өзелеп сорый торган идем. Тикмәгә түгел бит ул, төрле шикләрдән аптырап йөргәнгә күрә бит ул... Дөрес, моңарчы мин сине яхшы кешегә, саф кешегә санап килдем. Әгәр моннан бер ел элек кенә син миңа өйләнергә теләвеңне әйткән булсаң, минем түбәм күккә тигән булыр иде. Мәхәббәт дияр идем мин моны, без бергә булырга тиешле кешеләр дип, чын күңелемнән ышанган булыр идем. Ә хәзер... мин ни әйтергә дә белмим... Менә йорт кадәр йорт алгансың — аны миннән яшергәнсең; ни өчен, ни сәбәптән – моны мин, үтер, аңлый алмыйм. Йорт мине кызыксындыра икән дип уйлый күрмә, һич юк, мин аның кирәклеген дә белмим, тик әле шушындый зур эшне дә яраткан кешеңнән яшереп була микәнни дип шаккатам!.. Аннары, сүзең чын булса, миңа өйләнергә күптән уең булган, имеш —аны да яшереп килгәнсең... Ходаем, бу

ни хәл соң бу, өч ел буена яратам дип йөр, өч ел буена минем мәхәббәтемнән файдалан, ә чын теләгеңне бер генә мәртәбә дә, ичмасам, ялгыш кына да әйтмә, белдермә, имеш! Нинди генә кеше болай эшли ала, Зөфәр, әйт, нинди генә кеше?!

– Тукта, Рәшидә, нигә син боларның барысын да шулхәтле куертасың әле! – диде Зөфәр, чын-чыннан тынычсызлана башлап. – Ярый, мин сиңа моңарчы отчет биреп бармаганмын, ди, бу минем зур хатам, ди, ләкин менә хәзер мин сиңа барысын да әйттем бит, ачып салдым, руслар әйтмешли, товар лицом! Тагын ни кирәк?

– Миңа сине аңлау кирәк, Зөфәр, беткәнче аңлау кирәк! – диде Рәшидә, газаплы бер җитдилек белән.—Югыйсә мин ышана алмыйм, миндә шик кала, авыр шик!.. Синең бүген миңа өйләнергә телим, дип әйтүең чын ихластанмы ул, әллә берәр коры исәптән генәме? Өйләнгәннән соң да синең миннән яшерен гамәлең, яшерен тормышың булмасмы?.. Алла сакласын, әгәр шулай була калса, син вәгъдә иткән бәхетле тормыш ул минем өчен далада уйнаклап югалган кайнар рәшәгә әйләнер иде!.. Син беләсеңме рәшәнең нәрсә икәнен? Мин күп йөргәч, беләм аны, күргәнем бар... Тип-тигез дала түрендә менә бервакытны ялтырап яткан күл ачыла. Чын күл бу, хәтта җем-җем уйнаклаган вак дулкыннарына кадәр күренә. Менә шуңа карап барасың, барасың, ләкин күпме генә барсаң да теге күлгә барып җитә алмыйсың. Чөнки ул юк, ул рәшә генә, коры далада алдап-котыртып уйнаклаган эссе шәүлә генә. Менә шулай ул, дустым, кайчагында кешенең нигезсез, булмас өмете дә рәшә төсле юкка чыга...

Зөфәр, иреннәрен кысып, алга иелде. Аңа хәтта эссе булып китте. Кылт итеп, теге вакытта, Җиңү көне таңында күргән төше хәтеренә килде. Рәшә! Аның сусаудан шашынган күзләре алдында кинәт ачылып киткән күл – чын күл түгел идемени, ул да рәшә генә идемени? Булмас, булмас! Алай юрамаган иде ул газаплы, әмма куанычлы төшен!.. Бәхеткә юраган иде, бәхеткә!.. Рәшә, юк, бу мөмкин түгел! Аның күңелендә хәтта, Рәшидәне өенә чакырып, менә хәзер аны өйләнергә кыстап утыруы өчен үкенү кебек бер нәрсә дә кыймылдап куйды. Ләкин ул чигенергә теләмәде, чигенү ярамый иде... Эченнән сиздермичә генә сулап:

– Үткән эшкә салават! – Ә киләчәк турында алдан ук начарга юрамыйк әле, Рәшидә. Тормышны матур итеп кору безнең кулда. Кыскасы, Рәшидә җаным, мин сиңа үземнең чын теләгемне әйттем. Хәзер синең җавабыңны көтәм, йә, ни дисең?

Рәшидә уйланып, кечкенә йодрыгын башына терәп торды:

– Белмим. Хәзергә берни дә әйтә алмыйм. Миңа уйларга кирәк, уйларга, уйларга!

Зөфәр, борчылып, аның бик йончып киткән йөзенә карады.

– Алай... җитди мәсьәлә. Азрак уйларга кирәктер шул... Ләкин син, Рәшидә, мине озак зарыктырмассың бит?

– Киткәнче әйтермен.

– Киткәнче? Кая киткәнче?

– Минзәләгә.

– Минзәләгә? Ни өчен Минзәләгә?

– Минзәлә театры чакыра мине...

– Туктале, Рәшидә! Әллә ни сөйлисең! Кеше, Казанны ташлап, Минзәләгә китәме соң?!

– Миңа сәхнә кирәк, – диде Рәшидә. – Сәхнә өчен мин җир читенә китәргә дә риза!

– Ә монда?

– Монда алмыйлар, урын юк, диләр.

– Сабыр ит, Рәшидә! – диде Зөфәр, җанланып. – Мин үзем сөйләшәм. Театр җитәкчеләренең миңа һәрвакыт йомышлары төшә, мин сорасам – берсүзсез сине алачаклар.

Рәшидә башта гаҗәпләнгән, хәтта куанган төсле булды, аннары нидер чамалагандай кинәт җитдиләнеп, кашларын җыерып беравык Зөфәргә текәлеп торды.

– Аңламыйм мин сине, Зөфәр, аңламыйм, – диде ул, ниһаять, акрын гына. – Ни өчен син менә хәзер генә бу турыда әйтәсең? Ни өчен элегрәк, сүзең үтәрдәй булгач, сөйләшергә уйламадың?.. Кайчаннан бирле минем театрга керергә теләп, хыялланып, азапланып йөрүемне белдең бит, белдең!

Зөфәр бер генә секундка бик уңайсызланып китте, ләкин бу читен хәлдән тизрәк чыгар өчен елмайган булып, башын селкеп әйтте:

– Һе, син, ни, дустым, миннән гаеп табарга гына торасың. Бигрәк!.. Ярамый бит болай... Элегрәк ни, хәзер ни – эш узмаган ич әле!

– Юк, эш узган! – диде Рәшидә һәм капыл гына урыныннан торды. – Бел, үзеңә кирәк булгач кына күрсәтергә теләгән ярдәмеңне мин кабул итә алмыйм!

– Рәшидә, акыллым, ул хәтле кырт кисмәле!.. Ну, ярый, үзем өчен дә ди, ләкин минем протекция барыбер синең файдага ич ул!

– Юк, юк, үзең дә, протекцияң дә кирәкми миңа... Булмый, теләмим, әллә нинди кеше син!.. Ышанмыйм мин сиңа!

Зөфәр берьюлы үзгәреп, кисәк кенә аңа таба омтылды.

– Тукта, тукта...

– Орынма миңа! – диде Рәшидә, агарынып, һәм кинәт борылып, ишеккә атлады.

– Рәшидә!!

Ләкин Рәшидә, җилдәй, залдан, аннары өйдән үк чыгып китте... Бер мәлгә аптырап, катып калган Зөфәр, кинәт урыныннан кубып, аның артыннан ташланды. Парадный ишеге янында артыннан җитеп, беләгеннән тотып алды.

– Рәшидә, тукта, качма! – диде ул, көчкә тынын алып.

Рәшидә тирләгән, ярсыган, тешләшергә торган кечкенә җәнлектәй аңа шундый бер ялвару, куркыну, нәфрәт белән карады ки, Зөфәр ихтыярсыз аның беләген ычкындырды... Шап итеп парадный ишеге ябылды, һәм Рәшидә яшьләрен йота-йота, шак-шок атлап, тын урам буйлап китеп тә барды.

...Зөфәр, ябык ишеккә маңгае белән терәлә язып, күпмедер вакыт өнсез, хәрәкәтсез басып торганнан соң акрын гына кузгалып, өйгә керде. Ләкин монда калу мөмкин түгел иде, әйтерсең тып-тын, буш өйнең эчендә шак-шок, шак-шок ераклашкан аяк тавышы яңгырый иде... Зөфәр ава-түнә террасага чыкты һәм, хәлсезләнеп, башын учлап, аның баскычына утырды... Китте... өзелде... бетте...

Рәшидәнең качуы Зөфәрне чынлап та тамырыннан кискәндәй итте. Атна-ун көн ул, яңгыратылган балык шикелле, әйле-шәйлерәк бер хәлдә йөрде. Кая барса да, нишләсә дә аны Рәшидәнең соңгы минутта шундый бер җан өшеткеч ачу-нәфрәт белән аңа каравы һич күз алдыннан китмичә азаплады. Нинди тирән упкын алар арасында яткан икән!.. Ул шуны, артисткага ышанып бетмичә йөрүенә карамастан, ничектер алдан күрә белмәгән. Коточкыч сукырлык!.. Хәзер инде аңа көн кебек ачык: Рәшидәгә өйләнергә теләве бөтенләй нигезсез, кысыр бер хыял гына булган икән. Менә шул хыял җимерелде дә төште... Китте, югалды Рәшидә аның өчен – бөтенләйгә, мәңгегә!..

Хәер, Рәшидәнең югалуы белән килешергә дә, акрынлап аны онытырга да мөмкин булыр иде, тик шунысы яман – сизгер күңелле яшь артистка ничектер аның иманын да какшатып китте. Гомерендә беренче мәртәбә ул үзенең киләчәгенә шикләнеп, шомланып карарга мәҗбүр булды. Рәшидә бит аның үзеннән генә түгел, ул вәгъдә иткән тормыштан да гүя куркып качты. Рәшә булып чыкмасын, диде. Рәшә – менә нәрсә куркыныч икән. Һәм Зөфәр күбрәк шуны уйлап борчылды, шуңардан шомланып йөрде, кайчандыр күргән төшен түгел, ә реаль киләчәген юрап азапланды, кыскасы, рәшә дигән шул алдакчы томанны ничек тә күз алдыннан куарга тырышты.

Әйе, юкка гына аны Зөфәр Сабитов димиләр. Күпмедер вакыт үтүгә ул үзенең «реаль» уйлый торган салкын акылына кайтты. Моңарчы гел бер юнәлештә эшләп килгән логикасы яңадан сәгать механизмы кебек эшли башлады. Ни өчен әле мин бу кадәр каушап калдым, диде ул, үз-үзенә ачуы килеп. Шул хыялый бер хатынның киртә җимерүеннәнме? Ни белә ул, нәрсә күргән ул?.. Гади бер хакыйкатьне аңламый ич ул: һәркем үз бәхете өчен көрәшә, һәркем

тормышын үзе теләгәнчә корырга омтыла. Баерак, иркенрәк, рәхәтрәк яшәргә теләүче әллә бер мин генәме? Юк, алар күп, бик күп, бөтен дөнья, бөтен галәм! Бәс, шулай булгач, ни өчен мин үземнең теләкләремнән баш тартырга тиешмен? Ни өчен мин дә бу дөньяда үзем теләгәнчә яшәп калмаска тиешмен?! Әллә минем кулымнан килмәсме ул?.. Юк, килер, Алла бирсә, килер, рәтен-җаен табарбыз без аның... Өркетмәсеннәр!

Шулай диде ул үз-үзенә тискәре бер үҗәтлек белән һәм шушы иманында ничек тә ныгып калырга тырышты. Аның юлы сызылган, кая гына алып барып чыкмасын, ул инде аңардан чигенмәячәк, юк, чигенмәячәк... Әмма күпме генә ул шулай батырланмасын, теге электән үк күңеле төбендә яткан, шуның өстенә Рәшидә дә көчәйтеп киткән курку-шомлану барыбер бетмәде. Бу курку-шомлану аның тырыш, уңган, хәйләкәр, ялагай табигатенең астарлыгы булып кала бирде.

Ә ике айдан соң Зөфәр Гамбәр туташка өйләнеп ташлады. Кыз, ичмасам, диде ул үзен юаткан булып... Гамбәр туташ та бәхетле иде. Очлы иякле мөлаем йөзен кечкенә көнбагыштай күтәреп, Зөфәренә, «хуҗам!» дигәндәй, карап кына тора иде ул. Ләкин Зөфәр аңа беренче көннәрдән үк шаярткан булып әйтеп куйды: «Сиңа, орчыгым, башыңны түбән иеп кенә тору килешә!» – диде.

Шау-шулы зур мәҗлесләрне Зөфәр артык яратмаса да, туйны бик шәп үткәрде. Ниндидер ярсыну һәм үчләнү белән дөньясын бер селкетеп алырга теләде. Әүвәл-ахыры шул булсын диде бугай... Кыз квартирасында яшерен никах укытып, бер мәҗлес үткәргәч, ул үз өендә өч көн рәттән шаулатып туй ясады. Кичләрен зур йортның барлык тәрәзәләре ялт итеп торды. Соңгы мәҗлескә үзе белән элек эшләгән һәм яңа урында танышкан иң мөхтәрәм кешеләрне генә чакырды. Ләкин бу мәҗлесләрнең берсенә дә ул – ни гаҗәптер – Хәмит дустын чакырмады. Моның сәбәбе, билгеле, бик тирән һәм катлаулы булырга тиеш иде. Шушы биләмче, ялгызак егетнең көннәр буе буш яткан бүлмәсендә ул Рәшидә белән хәзер инде айга карап уласаң да кире кайтмас, иң бәхетле минутларын кичерде; ихтимал, шул минутларны исенә төшерүдән куркып, якын дустын Гамбәр туенда күрәсе килмәгәндер; ихтимал, яңа тормыш башлар алдыннан Хәмит шикелле аның бөтен үткәнен белеп торучы кешедән котыласы килгәндер... Бик мөмкин, әмма болар өстенә тагын бер җитди сәбәп бар иде: ул да булса – Әйттем-бетте Хәмитнең рәхимсез усал теле!.. Шушы теле белән ул Зөфәр дустын, бритва тидереп алгандай, һаман кисә генә торды. Бигрәк тә соңгы вакытларда аеруча бер каныгу белән Зөфәрнең һәр хәрәкәтенә, һәр эшенә тамга салгандай үзенең кара мөһерен баса барды. Хәтта, Зөфәргә авыр булсын дип, Гамбәр туташны да аяп тормады: – Гамбәр килен – алтын чебен! – диде ул, юри көйләгән булып кына, әмма ниндидер бер ямьсез нәрсәгә ишарә ясап.

Һәм Зөфәр түзмәде, күтәрә алмады, үзенең кара күләгәсеннән качкан шикелле, иң якын сердәшче дустыннан качарга мәҗбүр булды.

...Озак кына уйлаганнан соң, Зөфәр туй мәҗлесенә шулай ук иптәш Әхмәтҗановны да чакырмаска булды. Әлбәттә, бу инде Әйттем-бетте Хәмит түгел, иң югары начальник, гаять кирәкле кеше, ләкин шулай да аны чакырырга иртәрәк иде әле. Кем белә, бәлки киләчәктә аңардан рекомендация сорарга да туры килер... Тормыш бу... Исәп белә торырга кирәк!.. Әйе, бары тик исәп белән, исәп белән, исәп белән, кадалып киткере!

## ӘЙТЕЛМӘГӘН ВАСЫЯТЬ

*Баязит Бикбайга*

### I

Йомшак кына җәйге җил исә... Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә. Ефәк чукларын еш-еш кына селкеп, акрын гына кыштырдап, бик тырышып һәм бик кабаланып йөгерә кебек алар... Колын булып уйнаклап, шул кылганнар артыннан чабасы да чабасы килә. Дала буш, дала киң, җир җылыкай, шаян җилкәй биттән сөя... Рәхәт, һәй, рәхәт тә соң!.. Һәм ямансу. Нигәдер бик ямансу да шул! Шагыйрь әйтмешли, йөгереп уйныйсы, ятып елыйсы килә бу тын, буш, моңсу башкорт даласында!

Әнә көмешләнеп дулкынланган кылганнар арасында ак яулык бөркәнгән, алъяпкыч бәйләгән, күлмәген ыштан бөрмәсенә кыстырган кечкенә буйлы арык кына бер әби кизәк җыеп йөри. Сул беләгендә аның иске чиләк, уң кулында нечкә таяк. Шул таягы белән ул кизәкне чирәмнән куптарып әйләндерә дә аннары иелеп алып чиләгенә сала. Тагын як-ягына каранып эзләп китә. Тагын кизәкне, чирәмнән куптарып, чиләгенә алып сала... Шулай да бу авыл кырындагы чирәмлектә хәзер кизәк аз табыла, колхоз терлекләре монда йөрмиләр, ә бәләкәй генә авылның үз бозаулары салып калдырган «беленнәр» күпме генә соң ул! Далада утын дигән нәрсә бик кадерле булгач, ялгыз әби, ике-өч көндә бер чыгып, иске чиләге тулар-тулмас шул «беленнәрне» җыеп кайта. Борыннан килгән бер гадәт. Аннары кизәк казан астына бик килешә, ашны әкрен генә кайната, ә үз җае белән әкрен генә кайнап пешкән аш бик тәмле була ул. Әйтерсең чирәм исе керә ашка.

Тик соңгы вакытта әбинең хәле бик үк әйбәт түгел әле. Картлыгы җиткәнме, берәр чир зәхмәтеме шунда, ләкин гел менә бөтен тәне авыраеп, кул-аяклары сызлап, йөрәгенең хәле китеп тора. Ара-тирә өшетеп тә җибәрә, яки тиктомалга яндыра да башлый. Үзенчә, мәтрүшкәсен-ниен эчкәләп, ятып караса да, бер дә юнәеп китә алмый. Менә бүген дә, кояш

шактый нык кыздыруга карамастан, аның зәгыйфь тәне, эчендә боз яткандай, гел туңып тора; аркасы буйлап әледән-әле салкын кымырҗу йөгереп уза, шул ук вакытта күз төпләре яна, иреннәре бөрешеп кибә, һәм ул гер таккандай авыраеп киткән аякларын көчкә генә сөйрәп йөри... «Булмас, ахрысы, кайтырга кирәк», – ди ул үз-үзенә иренеп кенә һәм, чиләге кизәк белән тулмаса да, авылга таба борыла.

Читән буйларында котырып кычыткан үскән тар тыкрыктан узып, бәбкә үләне түшәлгән киң урамга килеп чыккан чакта гына аңа Миңлебай карт очрый. Торна шикелле нечкә озын аяклы, какланып беткән бу чандыр бабайны авылның иң карт кешесе диләр. Туксанның өстендә үк түгел микән? Хәер, тәгаен ничә яшьтә булуын ул үзе дә белми. Былтыр гына аның җитмештән узган Миңлегәрәй исемле улы үлеп киткән иде. Хәзер бабай Миңлегәрәйнең зур улы Миңлегалидә тора. Миңлегалинең дә өйләнгән улы, кияүгә чыккан кызлары бар. Миңлебай карт менә шуларның балаларын, ягъни үз токымының дүртенче буынын күрде. Дүртенче буын әкәмәт икән ул, бер дә бабай дигәнчә түгел. Ул хәтта аларның исемнәрен дә отып ала алмый. Вилне Вилдан дип, Эмманы Әсмабикә дип тик йөртә шунда...

Дөньяда чамасыз озак яши торгач, кайчандыр паровоз тавышын да ишетмәгән бабай тракторын да күрде, автомашинасын да, самолетын да, радиосын да күрде; алар аның авылына һәм өенә килеп керделәр, ләкин картның берсенә дә исе китмәде. Чөнки бу заманның барышына ис китеп өлгерерлек түгел иде.

Ләкин былтырмы икән, өченче ел микән, кемнәрнеңдер бу тирәләргә очып килеп, самолеттан бүре атып йөрүләрен ишеткәч, картның моңа шулай да исе китте. Кара син аны. Бүрене самолеттан гына «сугалар» диген, ә?.. Кайчандыр, бик күптән инде, ул үзе ир-егет чагында камчат бүрек, ак чикмән киеп, билен кызыл билбау белән буып, камыт күрмәгән сөлектәй яшь айгырга атланып далага чыгып китә иде дә, йөри-йөри бүренең эзенә төшкәч, аны уктай сузылып очкан бурзаеннан өсләтеп һәм ун-унбиш чакрым куа барып, озын саплы чукмары белән сугып ала торган иде. Менә бу, ичмасам, бүре сугу иде! Ә хәзер һавадан атып йөриләр, имеш. Моның ни кызыгы да, ни комарлыгы бар? Юк, әллә нишләде бу замана! Машина да машина, ә кешенең үз йөрәгенә, үз кулына ни кала?!

Миңлебай картның дөньяда да, колхозда да хәзер бер эше дә юк. Ул какланып беткән тәнендә бары җан асрый. Алдына куйганны утырып ашый, ястыгын тәгәрәтә дә ятып йоклый, шулай итеп гомерен суза да суза. Аның хәзер бер генә эше бар – ул ялан таптарга ярата. Һәр көнне иртәнге чәйдән соң ул, озын карагай таягын тотып, торнаныкыдай нечкә аякларын сыгылдырып кына буш урамнан уза, кырга чыга һәм күзе караган якка таба китеп бара. Берәр түбә җиргә менгәч, озын таягын ике учлап, ерак кырларга тик кенә һәм озак кына карап тора. Бу

күз җитмәс Юлкотлы яланының бөтен ягын, андагы түбәләрнең, үзәннәрнең, чокырларның бөтенесен исемнәре белән белә. Хәзер инде ул исемнәрнең күбесе онытылып бара. Хәзер, мәсәлән, Каракош басуы яки Атчабар кыры дип түгел, ә фәләненче бригаданың да төгәненче бригаданың участогы дип кенә йөртәләр. Юлкотлы яланнарын тоташтан сөреп бетерделәр. Иске чикләр, иске исемнәр барысы да күмелеп калды шунда...

Карт түбәдән төшеп китә, үзәнлекләрдән уза, иген басуларын буразна буйлап кисеп чыга, шулай итеп әллә никадәр җир әйләнеп, күп вакытта авылның икенче очыннан кайтып керә. Юлында очраган кешегә үзе башлап дәшми, ә берәрсе: «Саумы, Миңлебай бабай?» – дип дәшсә, «Ару әле» яки «Шөкер!» дип кенә узып китә. Ни уйлап, нәрсә карап йөри торгандыр карт – белүче юк.

Менә бүген дә карчык, йөзгә-йөз очрашкач дәшмичә китүне килештермичә, үзе башлап, аңа:

– Нихәл, арумы, Миңлебай агай? – диде, авызын учы белән генә каплый төшеп.

– Ә, синмени әле бу, Акбикә килен? Шөкер! – диде карт, тукталып. Җитмештән узган карчык аның өчен һаман да килен иде әле, һәм Акбикә дип тә бары ул гына дәшә, югыйсә авыл халкы карчыкны күптән инде Акъәби дип кенә йөртәләр.

– Каян кайтып киләсең болай? – диде карт.

– Менә кизәк җыярга чыккан идем.

– Ә, ярый, ярый... Казан астында утның өзелмәве яхшы. Йә, үзең ару гынамы соң?

– Шөкер иде әле, тик менә бу көннәрдә генә әллә нишләп хәлем китеп тора, – диде карчык һәм тирләгән битен яулык очы белән сөртеп алды.

– Авырма инде, син – ялгыз карчык, карар кешең юк.

– Алладан вакыт җитмәгән булса, үтәр әле.

– Үтәр, Алла боерса, үтәр, бик күпне үткәрдек, – диде карт, ияк очында гына ябышып торган берничә бөртек ап-ак кылдай сакалын селкетеп. – Ярый, карчык, юлыңда бул! – Һәм карт, озын аякларын сыга биреп, китеп тә барды. Ул карчыклар белән күп сөйләшеп торырга яратмый иде.

Акъәби, үзенең җилкапкасына җиткәч, туры читән алачыкка узды. Бу эчтән балчык белән сылаштырылган җир идәнле алачыкта аның барлы-юклы савыт-сабасы да тора, шунда аш-суы да пешә иде. Җирдән аз гына күтәртеп салынган, калай морҗасы туры гына кыектан чыгарылган учагы алдына карчык кизәкләрен бушатты. Казанына өч-дүрт чүмеч су салды да учагына күп кенә итеп чыбык-чабык сындырып тыкты, ут төртеп җибәрде. Чыбыклар күмерләнеп төшкәч, алар өстенә иплән кенә кизәкләр өештереп куйды. Аның исәбе башта су җылытып, табак-

савытын юу, аннары әзер казанда үзенә бер-ике генә уҗау буш умач пешереп алу иде. Нигәдер күңеле бүген сызык йөгерткән буш умачны корот катып кына ашарга теләп тора иде. Ләкин карчык сизә, пешерә дә, ашый да алмас төсле; хәле бөтенләй бетеп бара, көчкә генә йөреп азаплана, гәүдәсе менә гел ятарга гына сорап тора... Ахырда түзмәде, казан астыннан кизәкләрне алгарак тартып, учагын сүрелтә төште дә бераз ятып торырга булды. Алачыктан өенә узышлый күрше ишегалдында йөргән яшь хатынга читән аша гына дәште:

– Гарифә кызым, минем казан астын гына кереп караштыра тор әле, әз генә ятып алмакчы булам, бер генә дә хәлем юк.

– Әә, ярый, ярый, Акъәби, карармын, борчылма, ят! —диде уңган хатын, әбинең төсе качкан чыраеннан авыру булуын шунда ук чамалап.

Акъәби урам тәрәзәләре ябык, әрем себеркесенең исе аңкыган салкынча өенә керде, сәке түренә бөкләп куйган ястыгын җәйде дә, бисмилласын әйтеп, сырган юрган белән ябынып, бөгәрләнеп кенә ятты. Аның бик җылынасы килә иде. Ятып күзләрен йомуга, ул, салкын бер чоңгылга баткандай, башта туңып китте, кымырҗып, акрын гына калтырана башлады. Күпмедер вакыттан соң бераз гына җылынган кебек булды, ләкин тәмам эреп, изрәп китә алмыйча, ярым уяу, ярым йокылы хәлдә һаман бөрешеп кенә ята бирде. Бераздан Гарифә кереп хәлен белде, ашыйсың-эчәсең килмиме, дип сорады. Әби: «Локма да кабасым килми, кайнар чәй генә эчәр идем»,—диде. Гарифә алачыктан утлы көл өстендә генә пешергән куе чәй китереп, чынаягына карлыган кагы салып, шуны сыек бал белән генә аңа эчерде. Әбинең җыерчыклы ябык куллары һәм кипкән ирennәре калтырый иде. Шулай да ул тәлинкәне үз кулы белән тотып эчте, Гарифәгә күп итеп рәхмәт әйтте, тирләп бер йокласам, иртәгә, Алла боерса, аякка басармын, диде, тик бүген инде көтү кайткач, кәҗәсен савып, сөтен баз өстенә генә куярга кушты. Гарифә барысын да эшләргә булды, тыныч кына ятарга кушты һәм карчыкның өстен әйбәтләп ябып чыгып китте.

Ләкин карчык икенче көнне дә, өченче көнне дә аягына баса алмады. Күрәсең, авыруы аның болай бер-ике көн генә ятып үткәзеп җибәрерлек түгел иде. Ниндидер җитди чиргә охшый. Карчык үзе алай дип уйларга тырышмаса да, әллә Ходайдан вакыт җитүе шушы микән дип, шомланып та куйгалый иде.

Күршеләре кереп аның хәлен һаман белә тордылар, Гарифә исә ашау-эчүен кайгыртып, йорт-җирен һаман карый йөрде. Шулай да карчыкның хәле бер дә алга бармагач, аңа әллә улларыңа, кызларыңа хәбәр итикме, болай яту ярамас бит дия башладылар. Ләкин Акъәбинең өмете зур иде әле, ерак каладагы балаларын бер дә борчыйсы килми иде. Аннары болай да берәрсе кайтып китмәсме дигән өмете дә юк түгел иде. Кайткалыйлар иде әле аның уллары яки кызлары, инәләрен онытып бетермиләр иде, исән генә була күрсеннәр инде.

Карчыкның соңгы еллардагы гомере шул балаларының кайтып китүләрен көтеп яшәү белән генә уза башлады. Дөрес, моннан ун ел элек, карты үлгәннән соң, балалары карчыкны калага тартып караганнар иде каравын, ләкин Акъәби гомер иткән нигезен ташлап китәргә теләмәде инде. Шушы Юлкотлыда туган ул, үскән ул, шушы Каһарман карт өенә килен булып төшкән, шушында илле биш ел яшәгән, уллар-кызлар үстергән. Шушы Юлкотлы туфрагында аның атасы, анасы, күпме туганнары, яшьли үлгән сабыйлары, гомер иткән карты ята —йә, ничек шуларның барысын да ташлап китәсең?.. Күп торасы да калмагандыр, ят җирнең туфрагына барып ятканчы, шушында үзенең ата-анасы, карты, сабыйлары янында булыр – шулай уйлаган иде карчык ул чакта. Һәм, һичнигә карамастан, хәзергә чаклы ул шушы ниятендә нык торды.

Шулай да карчыкка җиңел түгел иде. Туган туфрак никадәр генә үзенә бәйләмәсен, авыл артындагы канау белән әйләндереп алган зиратта ятучы әрвахлар нихәтле генә якын булмасын, әмма болар гына аның тормышын тутыра, ялгызлыгын җиңеләйтә алмыйлар иде. Ялгыз башын монда асраса да, күңеле белән ул һаман шул балалары янында иде. Шуларны уйлап, шуларны сагынып, шыксыз озын көзләрне дә, салкын кышларны да уздырып җибәрә; сабыр гына җәйне көтеп ала, ә җәен берәр улымы яки кызымы балалары белән кайтып китәргә тиеш аның... Шулай көйләнде инде карчыкның тормышы: асылда җәйнең бер атна-ун көне өчен генә яши ул һәм ел буе диярлек тик шуңа әзерләнә. Маен-күкәен дә шул көнгә дип җыя, итен-казылыгын да балаларым өчен дип каклый, шомыртын, эремчеген, коротын да шулар өчен киптереп куя. Бигрәк тә оныкларын бик сагына карчык. Шулар кайтса инде, куанычы эченә сыймый, бөтен дөньясын оныта, үзе дә бер бәйрәм итеп кала, бичара. Тик бу бәләкәчләрнең әти-әниләре карчык янына гадәттә бик кыска вакытка гына кайталар. Алар, ни хикмәттер, гел ашыгалар. Кайсының эше көтә, кайсының курортка китәсе була, аннары балаларыбыз авыл җирендә авырып-нитеп китә күрмәсен дип куркалар да булса кирәк, кыскасы, бер атна торгач та, карчыкның бик тилмереп соравына карамастан, юатыр өчен кулына мул гына акча тоттырып, вәгъдәләр биргән булып, китеп тә баралар. Шулай итеп, ел буе көтеп алган санаулы көннәр төш кебек кенә үтә дә китә. Аннары тагын шул кыска гына тансык төшнең яңадан иңүен көткәндәй, озын йокыга охшашлы ялгыз гына яшәү башлана.

Нишлисең, заманасы шулай туры килде инде. Акъәбинең сабый чактан исән калган балалары үсә тордылар, күрше авылның урта мәктәбен бетерә тордылар, һәркайсы, канат чыгарган кош кебек, Юлкотлыдан еракка оча торды. Хәзерге вакытта бер улы белән бер кызы Өфедә яшиләр. Тагын бер кызы, врач булып чыкканы, Пермь өлкәсендә тора, ә иң кече малае,

институтны бетергәч, Казакъстанга җибәрелгән иде, шунда, исеме дә билгесез бер шәһәрдә, кемдер булып эшли.

Өфедәге иң зур улы Суфиян хәзер инде отставкага чыккан полковник, ә кызы Гөлбикә фәнни институтларның берсендә гыйльми эштә, кияве исә аның, Чакмагош башкорты, зур, җаваплы урында утыра. Кыскасы, барысы да зур кешеләр булып беттеләр. Кайсы галим, кайсы инженер, кайсы врач... Борын заманда бер ата-анадан түгел, бөтен өязеннән бу кадәр укымышлы башкорт чыкмагандыр. Акъәби үзе кыз чагында башкорттан яки татардан доктор барлыгын ишеткәне дә юк иде. Әле дә хәтерли, элек авылда берәрсенең теше сызласа, моннан унсигез чакрымдагы чуваш авылына, тәмәке алып кайтыр өчен, ат мендереп кеше чаптыра торганнар иде. Булган заманнар. Юк, аның балаларына килде инде бәхет, килде, әйтәсе дә түгел!

Тик менә бик бәхетле булып киткән балалары аңардан ничектер шактый ераклаштылар шикелле. Зарланса язык булыр, карыйлар, ярдәмнәреннән ташламыйлар, рәхмәт үзләренә, тик шулай да карчык борчылып уйламыйча булдыра алмый: туган җирләрен дә, кечкенә Юлкотлыны да, аталарыннан калган нигезне дә алар бөтенләй онытып баралар кебек. Уйлары да, күңелләре дә бүтәндә булса кирәк... Менә зур улы Суфиян. Күпме ил гиздe, нинди зур дәрәҗәгә иреште, олайды, үзенең дә ул-кызлары үсеп җитте, инде хәзер беркайда да эшләми, зур пенсия ала, машинасы бар – аңа бит Юлкотлыга ешрак кайтса да була хәзер... Ләкин, нишләтәсең аны, һаман вакытым юк дип зарлана, ниндидер комиссияләрдә эшләп йөри, кышын бер-ике айга курортка китә, йә булмаса үзе кебек погоннарын салган полковниклар белән төннәр буе карта сугып утыра, ә җәйгә чыккач, машинасына хатынын, бала-чагаларын утырта да йә Кырымга, йә хатынының урыс туганнарына – Саратовка китеп бара. (Суфиян сугышка чаклы ук әле, Саратовта хезмәт иткән чагында, марҗа кызына өйләнгән иде, һәм Акъәбинең ул чакта моңа күңеле бик тә сыкранган иде.) Ә каладан йөз егерме чакрымда гына торган Юлкотлы читтә кала, әнисе-карчыкның алар өчен генә дип саклаган казлары келәтендә шул килеш эленеп тора. Полковникның кереп туган авылын күрергә һәм әнисен куандырырга вакыты да, җае да табылмый. Ничек моңа күңел сыкранмасын ди.

Шулай да быелтыр җәй Суфиянның җиткән улы Геннадий үзләренең машинасында «бабушканы» күрергә дип кайткан иде. Өч көн торды, өч көн Акъәби бер кәлимә башкортча белмәгән оныгы алдына барлык сыйларын куйды, сүзсез генә аңа моңсу һәм назлы итеп карап утырды. Егет җирән чәчле иде, таза иде, физкультурник иде; урам буйлап чыгып киткән чакларында карчык аның чуар күлмәк кигән киң аркасына читән аша гына карап кала иде. Егет беркөн эчендә Юлкотлының бөтен тирә-ягын йөреп чыкты; машинасына ыбыр-чыбыр

балаларны төяп, әллә кайлардан үзләрен йөртеп кайтарды, аннары колхоз келәтендә аунап яткан ике потлы гер ташын табып кайтты да иртә-кич гел шуны күтәреп-чөеп уйный башлады.

Кечкенә авылда егеткә аралашыр өчен үз тиңнәре бөтенләй юк диярлек иде – кызлар җәйләүдә яталар, егетләре каядыр таралышып беткәннәр – һәм Акъәбинең моңа бик эче поша иде. Оныгының күңелен табар өчен, ул әледән-әле аңа башкортча нидер әйткән була, ләкин Геннадий, берни аңламыйча, «бабушкасына» бик юмарт елмаеп карый, җавапсыз калмас өчен генә:

– А, да-да, точно! – дип, баш кагып куя иде.

Әби белән онык арасында бер кызык хәл дә булып алды. Шулай иртәнге чәй янында оныгын сары майда гына йөзгән әче коймак белән сыйлаган чакта Акъәби «безнең башкорт халкы...» дип нидер сөйли башлаган иде, Геннадий, шуны үзенчә аңлап булса кирәк, көтмәгәндә генә баш бармагы белән күкрәгенә төртеп:

– Я – башкирин, бабушка, башкирин! – диде һәм, җитмәсә әле «борчылма!» дигәндәй, әбисенә күз дә кысып куйды.

Акъәби уйчан гына аңа карап торды, үзалдына гына көрсенгәндәй итте, аннары моңсу-назлы итеп кенә елмайды: нишлисең, бу җирән чәчле егеттә аның каны, башкорт каны ага иде шул!

Менә шулай Акъәби ялгыз башы шушы көнгә кадәр улларын, кызларын көтеп, оныкларын сагынып, алар турында үзенең күңелле һәм күңелсез уйларын эченнән генә уйлап, исән-имин генә яшәп килде. Җәйгә чыгу белән, һәрвакыт өметләре уяна торган иде, бәйрәм көннәрен көткәндәй рухланып, шуңа бер дә иренмичә әзерләнә башлый иде. Әмма быел, Ходайдан вакыт җиткәнме, җәйгә аяк басу белән, үзен начар сизә башлады һәм бирешмәскә тырышып йөрде-йөрде дә ахыр чиктә менә урынга ук ятарга мәҗбүр булды.

Башта торып китәрмен дигән өмет белән ятты, күршеләренең калага улларыңа хәбәр итик дигән сүзләрен дә кире какты, әмма ләкин хәле аның отыры начарлана барды. Биш-алты көн эчендә ул күзгә күренерлек булып суырылды, саргайды, ашаудан калды. Күршеләре, карчыкның болай начарлана баруын күреп, хәвефкә төштеләр, нишлик икән дип, үзара киңәшеп тә алдылар, ахырда Юлкотлыдагы колхоз бригадиры Сәетгалигә хәбәр итәргә булдылар.

Колхоз идарәсе моннан алты чакрымдагы Сыртлан авылында иде, шунлыктан Сәетгали кечкенә Юлкотлыда бердәнбер хуҗа һәм баш кеше. Һәр көнне иртән иртүк ул, мотоциклының сиртмәле биленә атланып, такыр юлдан пырылдап, тирбәлә-тирбәлә Сыртланга китеп бара, ә кич белән тагын шулай җен кебек машинасында тумырылып кайтып җитә иде. Гарифә барып әйткәч тә, Сәетгали икенче көнне үк, Сыртланга узышлый, үзенең мотоциклында пырылдап,

Акъәбинең капкасы төбенә килеп туктады. Акъәби шунда ук кем килгәнен белеп алды һәм ни өчен икән бу дип борчылып уйлап куйды. Ул арада ишектән, иелә биреп, тузанлы күн итекләрдән, бригадир белән председательләр өстендә генә очрый торган, капчыкланып беткән зәңгәр пинжәктән Сәетгали үзе дә килеп керде.

– Саумы, Акъәби? – диде ул, таза кешегә дәшкәндәй юри кычкыра биреп. – Бәй, ни булды, әллә авырып калдыңмы?

– Авырыйм шул, Сәетгале, – диде карчык, гаепле кеше сыман итеп.

– Куй, юкны сөйләмә, гомердә авырмаганны... Синең кебек корткага килешәмени ул!

Сәетгали, килеп, сәке кырыена гына утырды, карчык юрганын үзенә таба җыя төште.

– Килешми дә бит, нишлисең, Ходайдан вакыт җиткәч...

– Җиткән ди сиңа... Болай гына, салкын-фәлән генәдер әле... Кай җирең авырта соң?

– Авырткан җирем дә юк кебек... Тыным кысыла, сулавы авыр... – диде Акъәби, бугазын һәм күкрәген сыйпап.

Сәетгали карчыкның суырылган, саргайган йөзенә беравык сынап карап торды.

– Йә, нишлибез, Акъәби, доктор чакыртыйкмы?

– Кирәкмәс, Сәетгале улым, иншалла, болай да үтәр әле...

– Үтә күрсен! – диде Сәетгали, карчыкка тагын да сынабрак карап. Юк, шулай да карчыкның хәле бер дә шәпкә охшамый, йөзе лимон кебек сары, күзләре тоныкланып тора. – Әллә, мин әйтәм, – диде бригадир сак кына, – калага хәбәр итикме? Суфиян агай, йә булмаса, Гөлбикә апай килеп китсә, зарар итмәс... сөйләшерсез...

– Юк, кирәкмәс, сабыр итик әле, алар да эшле кешеләр, – диде карчык, эченнән генә үзенекен уйлап.

– Анысын куй, – диде Сәетгали, урыныннан торып, бер әсәйләре өчен вакыт табарлар әле. Ярый, идарәгә баргач, мин Гыйльман агай белән сөйләшермен. Берәр чарасын күрербез. Ә син, әбекәем, тыныч кына ят. Терел.

– Иншалла!.. Рәхмәт керүеңә, Сәетгале улым.

Сәетгалигә ияреп, Гарифә дә өйалдына чыкты. Алар анда пышын-пышын гына нидер сөйләшеп тә алдылар. Аннары мотоциклның каты гына пытыр-пытыр итеп кузгалып китүе ишетелде, һәм озак та үтми, аның тавышы ераклашып, ниһаять, бөтенләйгә тынды.

Ә берничә көннән соң Сыртлан ягыннан Юлкотлыга таба тузан уйнатып килгән өр-яңа яшел «Волга» машинасы күренде. Һәм, озак та үтми, киң урамның күк үләнендә ярылып яткан кара эз калдырып, Акъәбинең капкасы төбенә килеп тә туктады. Машинадан җәйге габардин пальто, күк эшләпә кигән зур, таза гәүдәле бер ир белән ефәк плащ кигән, зәңгәр косынка

бәйләгән озын буйлы ябык кына бер хатын чыктылар. Болар Акъәбинең кызы белән кияве иделәр.

Алар урам тәрәзәләре ябык караңгырак өйгә килеп кергәч һәм кызының: «Әсәем!» – дип дәшүен ишеткәч, йокылы-уяулы хәлдә яткан Акъәби сискәнеп күзләрен ачты, бер мәлгә өнемме, төшемме бу дигәндәй аптырап, каушап калды, аннары куанычыннан онытылып китеп, капыл гына урыныннан тормакчы булды.

– Кызым, Гөлбикә! – диде ул, өзелеп.

Кызы, шунда ук килеп, аның өстенә иелде, маңгаеннан үпте, һәм алар тотынышып икесе дә елап җибәрделәр. Мәһабәт кияве дә, килеп, карчыкның кипкән ябык кулын зур, таза кулларына алды, иелә төшеп, күтәренке тавыш белән: «Нихәл, әби җаным, авырып киттеңмени? Ничево, ничево, берни дә булмас!» – диде һәм, пальто чабуын кайтарып, аз гына читкәрәк, сәке кырыена утырды. Кызы да чажлап торган плащы белән әнисенең аяк очына чүкте. Алар икесе бертавыштан карчыкка кузгалмаска куштылар. Ләкин карчыкка кияве белән кызы алдында болай авырып ятуы гаҗәп уңайсыз иде, һичнигә карамыйча, аның тизрәк торасы, кадерле кунаклары өчен әүвәлгечә бөтерелеп йөрисе килә иде, әмма тик, нишләсен, ятарга чарасыз мәҗбүр иде. Шулай да ул түшәк өстенә торып утырды һәм Гарифәгә урам тәрәзәсен чыгып ачарга, тизрәк самовар куярга кушты.

Тәрәзә капкачы ачылгач, өй эче яктырып китте. Акъәби шәһәрчә бик пөхтә киенгән кадерле кызы белән кадерле киявенең чиста, шома йөзләрен күрде. Күрде дә үз хәленнән тагын бер уңайсызланып, елыйсы килеп, авыр сулап куйды. Үз нәүбәтләрендә алар да бик ябыккан, тәмам кечерәеп калган әниләренең зәгъфрандай саргайган, сулган йөзен күрделәр. Күрделәр дә, сүзләрен оныткандай, бер мәлгә тынып калдылар һәм яшерен генә карашып алдылар. Болай ук булыр дип көтмәгәннәр иде алар. Хәер, колхоздан калага шалтыраткач та, алар карчыкның чынлап авырып китүен белеп, башта ук тәгаен бер ният белән юлга чыкканнар иде. Хәзер исә ике төрле сүз булырга мөмкин дә түгел. Эшләре тыгыз, вакытлары юк, шуңа күрә сүзне озынга сузмыйча, карчыкка шул ниятләрен әйтергә булдылар.

– Әсәем, – диде кызы, әнисенә үрелеп. – Без сине үзебез белән алып китәргә дип килдек. Калада докторларга күрсәтербез, әйбәтләп карарбыз, анда тизрәк терелерсең.

Кияве дә шунда ук өстәде:

– Дөрес, әби, бездә сиңа әйбәтрәк булыр, монда доктор да юк, караучы да юк, ялгызың нишләрсең?

Карчык тиз генә җавап кайтара алмады, аның кинәт күңеле тулды, шул ук вакытта нигәдер бик борчылып та куйды.

– Рәхмәт инде, балалар! – диде ул, бераздан әкрен генә. – Юкка мәшәкатьләнгәнсез, үз өемдә дә терелер идем әле, Ходай насыйп итсә.

– Юк, әсәем, сине хәзер монда калдырып китеп булмый, – диде кызы, кабаланып. – Алып китәбез. Яхшылап дәваларга кирәк сине...

– Өй ялгыз кала бит.

– Калсын, берни дә булмас, күршеләрең карый торырлар.

Карчык бүтән бер сүз дә әйтмәде, авыр сулап кына куйды, монда доктор каравыннан башка, мәтрүшкә-фәлән эчкәләп кенә терелеп китмәсен үзе дә аңлый иде булса кирәк. Аннары япа-ялгыз яту да аны шомландыра иде. Ә тегендә, калада, бөтен балалары диярлек, Ходайдан вакыт җитеп, алай-болай булып китсә, алар аның янында булачаклар. Әмма шул ук вакытта нәкъ менә шушы «алай-болай булып», ягъни үлеп китүен уйлап, ул үзенең гомер иткән почмагыннан чыгып китәргә дә теләми иде. Чит җирдә үлү, чит җир туфрагында ятып калу аны һәрвакытта куркыта иде. Юк, аның шушында, карты җан биргән кечкенә өендә үләсе, авылдашлары кулы белән кечкенә авыл зиратына – карты һәм яшьли үлгән сабыйлары янына куеласы килә иде. Ләкин ничек итеп менә хәзер ул алырга дип килгән кызы белән киявенең ихтыярына каршы тора алсын? Чыкмаган җанда өмет бар дигәндәй, бәлки, алып китеп, чынлап та терелтеп, аякка бастырып кайтарырлар, шуның өчен килгәннәр бит. Юк, авыр иде карчыкка бу төенне чишү, бик авыр иде!

Чәй урынын карчык янына, сәке өстенә әзерләделәр. Карчык, яткан җиреннән генә, Гарифәгә кушып, үзенең сыйларын – баздан сөтен, маен, чоланнан кәрәзле балын, каклаган казылыгын табынга китертте. Ярлырак та бит, нишлисең, таза чагы булса, үзе тиз генә берәр кайнар аш та өлгертер иде, ә болай кешегә кушып кына буламыни ул. Аннары кызы белән кияве дә: «Борчылма, әсәй, бик әйбәт, бик җиткән», – дип кенә торалар. Ашыгалар, күрәсең. Алып китәргә дип килгәч, алар үзләре дә бу юлы күчтәнәчләр төяп кайтмаганнар иде. Шулай да кызы берничә лимон белән бер кап шоколад конфет китергән икән, шуны табынга чыгарып куйды. Лимон авыру карчыкның нәфесе бик теләп торган нәрсәсе иде, ул аңа бик сөенде, хәтта кулына алып иснәп-иснәп тә карады.

Табын әйләнәсенә утырыштылар. Гарифә чәй ясый башлады. Карчыкка берьюлы рәхәт тә, күңелле дә булып китте. Менә Ходаның рәхмәте, көтмәгәндә генә ул иң кадерле якыннары белән бер табында утыра бит әле. Аның өчен елына бер генә килә торган бәхет бит бу, гел шуны көтеп яши иде бит ул, тик менә, кызганычка каршы, урын өстендә каршы алырга туры килде үзләрен. Шуңадыр, ахры, бу минутта аңа никадәр генә рәхәт булмасын, нечкәргән күңеле нидер сизенгәндәй ирексездән ямансулап та, шомланып та куйгалый иде. Хәерлегә була күрсен инде...

Чәй янында сүз дә гел китү белән бәйләнгән эшләр турында барды. Карчыкка авыр иде бу сөйләшү, китүенә бер дә ышанасы килми иде шикелле, шуңа күрә күбрәк кызы бу турыда кайгыртып утырды. Аның соравы буенча карчыкның кәҗәсе белән тавыкларын Гарифә карап торырга булды. Келәтнең үз йозагы бар икән, өйне бикләргә дә бер иске богау йозагы бар икән әле, Гарифәгә шуның белән өйне бикләп, ачкычын үзендә сакларга куштылар. Боларны тыңлап утырганда, карчыкның рухы акрынлап һаман сүнә барды. Ахырда түзмәде, өзелергә торган тавыш белән еламсырап әйтте:

– Ходаем, гомер иткән өемә йозак салып китәрмен дип уйлаган идеммени мин...

– Әсәем, бу ниткән сүз? – диде кызы, гаҗәпләнгән булып. – Бөтенләйгә ташлап китмисең бит, менә тиздән терелеп, үзең дә кайтып җитәрсең.

Карчык: «Юат инде, кызым, юат!» – дигәндәй, үзалдына моңсу-зәгыйфь кенә көлемсерәп куйды, әмма кайтарып бүтән бер сүз дә әйтмәде.

Чәйдән соң юлга да әзерләнә башладылар. Кияү кеше ашыга иде, аңа ниндидер бер кичке җыелышка кайтып җитәргә кирәк икән. Ул машинасы янына чыгып китте. Тузан кунган яшел «Волга»ны бала-чага сырып алган иде. Аягына чак тәпи басканы да ава-түнә килеп җиткән. Зурраклары машинаның бөтен ялт иткән нәрсәләрен тотып-сыйпап, әйләнеп йөриләр, тик түбәсенә генә менеп китмиләр. Зур, таза абзый чыккач, алар башта куркып читкә сибелделәр, ләкин тиз үк яңадан машина тирәсенә җыела башладылар. Аларның тынгысыз елтыр күзләре бу шәп агайга, машинасында бер йөртеп килмәсме дигән яшерен өмет белән, гел чекерәеп карап кына торалар. Хәтта бер кап-кара башлы малай әрсезләнеп һәм юмаланып сорап та куйды:

– Агай, ә, агаем, безне анавы очтан гына бер йөртеп килсәң ине!

Мәһабәт агай башын кагып, телен шартлаткан булды:

– Юк шул, малайлар, булмый хәзергә, ашыгабыз. Менә Акъәбиегезне китерә килгәч, мин сезне рәхәтләнеп бер йөртеп кайтарырмын, ярыймы!

Малайлар, Акъәби дигәнне ишеткәч, шунда ук тындылар, артык бәйләнеп тормадылар. Кайчагында алар мәсьәләнең җитдилеген зурларга караганда да тизрәк аңлый беләләр иде.

Шул арада читтәге капка төпләрендә җыелышып торган корткалар, хатын-кызлар да акрынлап килә башладылар. Акъәбине алып китәләр дигән хәбәр кечкенә авылга бик тиз таралып өлгерсә дә, хатын-кызлар каладан кайткан кадерле кунакларга ашап-эчкәндә комачауламас өчен шулай әдәп саклап, көтебрәк торганнар иде. Хәзер инде менә килделәр, олыраклары өйгә үк кереп киттеләр. Акъәби аларга бик якын кеше, гел бергә яшәгәннәр, аңа бик ияләшкәннәр, шуңа күрә аны ерак юлга, билгесез сәфәргә озату алар өчен шактый зур вакыйга иде. Йөзләре дә аларның җитди-уйчан иде, нидер сизенәләр иде, ахрысы, һәркайсында

корткабызны яңадан инде күрә алмабыз дигән уй ята иде шикелле... Гаҗәп бит ул – кеше берәүнең дә үлүен теләми, әмма шул ук вакытта ничектер ихтыярсыздан шул үлемнең буласын сизеп, көтеп тә тора кебек.

Бераздан кара бишмәтен, оек-калушын кигән, чәчәкле зур шәлен ябынган Акъәбине кызы белән Гарифә ике ягыннан култыклап, акрын гына өйдән алып чыктылар. Алар артыннан бер хатын зур мендәр күтәреп чыкты.

Кияү машина ишеген ачты. Карчыкны иплəп кенә утырттылар, мендәрен, таяныр өчен, янтыгына салдылар. Кызы янәшәсенә кереп утырды. Машина тәрәзәсенә хатын-кыз башлары иелде.

– Акъәби җаным, хуш, сау бул инде!

– Акъәби, бәгырем, терелеп кайта күр!

– Хуш, безне онытма, без көтәбез сине! – диделәр аңа.

Ә таякка таянган бер кортка:

– Хуш, яшьтәш, бәхил бул, ахирәттә күрешергә насыйп итсен! – диде, бик тыныч, әмма чын күңелдән бик ихлас итеп.

Гөлбикә иренә тизрәк кузгалырга кушты. Машина алдында торучыларга кыска гына бер гудок бирде дә шома гына кузгалып китте.

Аз гына китүгә, Акъәби кинәт урыныннан кузгалып.

– Һай, кәфенлегемне онытканмын лабаса! – диде, нишләргә белмәгәндәй бик борчылып.

Кызы бу көтелмәгән сүздән сискәнеп киткәндәй булды һәм чыраен сытып:

– Куйсана, әсәй! – диде, үпкә катыш рәнҗү белән.—Таптың искә төшерер нәрсә!

Карчык дәшмәде, күзләрен йомып, хәлсезләнеп башын гына иде.

Яшел машина йомшак кына тирбәлеп һәм тузан уйнатып, Юлкотлыдан зур калага таба чыгып китте. Кечкенә өйнең капкасы төбендә җыелышып калган хатын-кызлар бөтерелеп тузан сузылган юл буена, машина күздән югалганчы, тик кенә карап тордылар.

**II**

Менә Акъәби ялгызы кечкенә бер бүлмәдә, сиртмәле тар караватта, ак түшәмгә карап һәм каяндыр түбәннән тоник кына ишетелгән зур кала гөрелтесенә колак салып, тыныч кына ята. Урыны йомшак, астында чип-чиста ак җәймә, өстендә сатин юрган – ипле, рәхәт аның арык-җиңел гәүдәсенә... Рәхмәт инде киявенә дә, кызына да – аны менә шулай кадерләп, аерым бүлмәгә урнаштырдылар. Дөрес, аларны бер дә тыгызлыйсы килмәгән иде килүен, ләкин кияве белән кызы бу хакта авыз да ачтырмадылар. Хәтта элек бу бүлмәдә торган асрау кызларын да

кухняга чыгардылар. Тик бераздан гына сизде карчык: монда авыру кешенең яткан җире генә түгел, ашаган-эчкән савыт-сабасы да аерым булырга тиеш икән.

Гомумән, карчыкка башта игътибар бик зур булды. Беренче көнне үк шәһәрнең икенче читеннән отставкадагы полковник улы белән килене дә аны күрергә килеп җиттеләр. Чүкечтәй нык, базык гәүдәле, зур йомры башлы, кыска имән муенлы полковник Суфиян, әйтергә кирәк, кәкре аякларындагы тар кунычлы хром итекләре белән генә түгел, бөтен кыланыш-гадәтләре белән дә чын «янарал» булырлык, беткәнче хәрби бер кеше иде. Кычкырып, кырт кисеп сөйләшә ул, берәүдән дә тартынмыйча киерелеп, шаркылдап көлә һәм, иң мөһиме, үзен бик хаклы рәвештә дөньяның хуҗасы санап, бернигә исе китмичә, рәхәтләнеп яши иде. Квартир менә дигән, машина бар, пенсия җитәрлек, шуның өстенә аучылар җәмгыятендә нидер эшләп тә шактый акча төшергәли, кыскасы, әле чак иллесен тутырган полковникның тормышы бал да май, ал да гөл иде.

Әнисе карчык янына күрешә килгәч тә, ул карлыкканрак тавышы белән бүлмәне яңгыратырга тотынды:

– Һай, әсәй, әсәй, әсәем! – диде, әнисенең кипкән кулын каты учларына алып. – Ни булды сиңа, авырып киттеңмени, ике күзем?.. Ну, ничево, түлке син паникага бирелмә. Безнең генерал әйтә торган иде: солдатны пуля түгел, паника үтерә дип...

– Нәрсә соң ул... пәникә дигәнең, улым?

– Улмы, ул ни... курку, әсәем!

– Мин бер дә курыкмыйм, улым, – диде карчык, тыныч кына. – Тәкъдирдән узмыш юк, барысы да Алла кулында.

– Һи, әйттең тагын! Барысы да безнең кулда! – диде полковник, һаман шаулап. – Менә мин сиңа докторның иң шәбен үзем алып килермен, әсәй!..

– Рәхмәт, улым, рәхмәт!

Карчыкның килене, өч башкорт бичәсенә торырлык юан, мәһабәт, ап-ак Мария Васильевна, каенанасы белән ике куллап, бик җитди итеп күреште. Караватъ кырыена урындык алып утырды да, авыруның хәленә керергә теләгәндәй, аңа чын кызгану белән карап тора башлады. Юрган астында бала шикелле сизелер-сизелмәс кенә яткан бу каенана дигән сап-сары йөзле карчыкка аның нидер әйтәсе дә, кайгыртып нидер сорыйсы да килде, ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, тел юк – карчык бер кәлимә русча, ә килен бер авыз башкортча белми иде. Шулай да Мария Васильевна ире аркылы булса да берничә сорау бирде.

– Әсәй, киленең менә синнән, кай җирең авырта, дип сорый.

Карчык уйчан-моңсу гына әүвәл улына, аннары килененә карады.

– Тыным кысыла, – диде ул, күкрәген күрсәтеп.—Хәлем бер дә юк.

– Күптәнме?

– Тыным бетүен кыштан ук сизә башладым. Ә хәлсезләнүем күптән түгел.

Суфиян карчыкның сүзләрен русчага әйләндергәч, Мария Васильевна иреннәрен мәгънәле генә кысып, башын селкеп торды. Аннары ашыкмыйча гына нидер әйтте.

– Әсәй, киленең әйтә, – диде Суфиян, – опасный берни дә булмас, бронхлары ниткәндер, борчылмасын, ди.

Карчык дәшмәде, тик күзләре белән генә рәхмәтен белдереп, килененә бер тутырып карап алды.

Икенче көнне карчык янына күрешергә дип Суфиянның зур улы Геннадий да килде. Геннадий инде Юлкотлыга барып, әбисендә кунак булып кайткан егет, шуңа күрә ул карчык белән бик үз булып: «Ха, бабушка!» —дип шатланып күреште һәм, урындык алып, караваты янына утырды. Акъәби сөенеп-яктырып, башкортча: «Улым, килдеңмени, рәхмәт төшкерем!» – диде, ә егет аның ни әйткәнен аңлагандай, елмаеп башын какты. Әйе, карчык бу дәү, сары егетне, үз нәселенә һич охшамаса да, чынлап ярата иде – барыбер аның токымы ич, аның каны!.. Нишлисең, якын шул, бик якын!.. Тик егет үзе «бабушкасының» йөрәгендә аңа карата нинди тирән һәм газаплы мәхәббәт ятканын сизәме икән?.. Юк, сизәргә тиеш, әнә килгән бит әле ул, әнә елмаеп әбисенә нидер әйтә дә бит әле... Ах, бу тел юклыгы!.. Карчыкның тел өйрәнер вакыты күптән үткән шул инде, әмма ник бу Суфиян, юньсез, балаларына, ичмасам, әбиләренә дәшә алырлык кына үзебезчә берничә дистә сүз өйрәтмәде икән соң?!

Егет әдәп кушкан кадәр утырганнан соң кузгала башлады, торып, әбисенең кипкән ябык кулын сыйпады һәм: «Пока, бабуся!» – дип баш какты да чыгып китте. Карчык аңардан бик шат, риза булып калды.

Шул ук көнне тагын Суфиянның өч кызы – Татьяна, Светлана, Рита – белән кече малае Борис та әбиләре янына килделәр. Кызлары да суеп каплагандай әниләренә охшаганнар, әниләре кебек барысы да эре сөякле, җирән чәчле, зур соры күзлеләр... Тик Боря (Борис) гына атасына охшаган, атасы кебек зур башлы, зур битле, арыш чумарыдай кап-кара бер малай иде. Бусын инде бер дә икеләнмичә Суфиян малае Шәяхметов дип йөртергә була.

Кызлар әбиләрен сырып алдылар, шаулап: «Здравствуйте, дорогая бабушка!» – дип күрештеләр, алып килгән чәчәкләрен караватянындагы тәрәзә төбенә утыртып куйдылар, урындыгына шоколад конфетларын салдылар һәм, инде ни әйтик дигәндәй, күзләрен елтыратып, әбиләренә карап тора башладылар. Шушы икән инде ул папаларына мама тиешле

әби-карчык! Үзе кечкенә, үзе арык, өстенә киң җиңле әкәмәт кенә күлмәк кигән, башына вак кына чәчәкле сары яулык бәйләгән, в общем, типичная башкирка икән.

Ә Акъәби, үз нәүбәтендә, бу җитеп килгән таза, зифа кызларга уйга калып, исе китеп, селкенмичә карап ята. Аннары зәгыйфь кенә елмая, иреннәрен кыймылдатып куя – нидер әйтергә тели, ахрысы... Менә ул күзләрен Боряга төби, әкрен генә кулы белән ымлап, аны якынрак килергә чакыра. Боря курыккандай башын сөзеп, каш астыннан гына карап, кузгалмыйча тора, тик апалары «иди, иди» дип аркасыннан этәргәч кенә, әбисенә якынлаша. Карчык, бердән яктырып, малайның аркасыннан сөеп: «Бәбкәчем, – ди, – зур егет бул, Алла тәүфыйк бирсен үзеңә!» – ди... Малай берни аңламыйча, кызарып, әбисе яныннан тизрәк китә, ә кызлар, нидер әйтеп, шаулап көлешәләр... Карчык исә һич үпкәсез, әмма боек-сагышлы итеп, тирән генә бер сулап куя. Әйе, бу балалар, никадәр ят-сәер күренмәсеннәр, аның үзенеке шул, үзенеке!.. Улының кемгә өйләнүенә, ничек яшәвенә бәгыре күпме генә сызланмасын, әмма оныклары аңа бик якын, бик газиз шул!.. Минем байлыгым дип кенә йөртә ул аларны...

Бер-ике көннән соң кызы Гөлбикә доктор чакыртып китерде. Урта яшьләрдәге таза, мөлаем хатын доктор Акъәби белән бик ачык сөйләште, күп сорашты, аннары күкрәген алдан да, аркасыннан да әйбәтләп тыңлады, тик ни өчендер карчыкның үзенә авыруы турында бер сүз дә әйтмәде. Кызы белән залга чыгып, шунда икәүдән-икәү генә сөйләштеләр.

Тагын берничә көн үтте, һәм менә шул ук хатын доктор олы яшьтәге озын, чандыр, күзлекле бер ир кешене ияртеп китерде. Моны шәһәрнең бик атаклы профессоры дип әйтәләр. Үзе татар икән... Шул профессор карчыкны игътибар белән тыңлады, сорашты, вакыт-вакыт иреннәрен кысып, авыруга озак кына уйланып карап та торды, аннары яңадан сорашты, яңадан тыңлап карады. Карап беткәч, тураеп һәм сүзләрен үлчәп кенә: «Әби, үпкәгездә авыру бар, ләкин ул картлык белән бәйләнгән булырга тиеш, без биргән даруларны эчеп, тыныч кына ятыгыз!» – диде. Шуннан соң барысы да залга чыгып, үзара тагын нидер сөйләштеләр.

Акъәби, күңеленә ни генә килсә дә, сабырлыкка өйрәнгән гадәте буенча артык борчылмыйча, шомланмыйча, тыныч кына ята бирде. Ләкин докторларны озатканнан соң янына кергән кызының бик җитдиләнеп киткән йөзенә карап, ул эшнең серен сизенгәндәй булды. Дөрес, кызы аңа берни әйтмәде, әмма бу киеренке хәрәкәтсез чырай, бу юри аңа карамаска тырышкан борчулы күзләр хәлнең ничек икәнлеген һәртөрле сүздән дә ачыграк әйтеп торалар иде кебек... Ә хәлләр чынлап та бик шомлы-куркыныч иде: докторлар карчыкның үпкәсендә яман шеш (рак) таптылар. Алар фикеренчә, җитмештән узган карчыкка операция ясап торудан мәгънә юк, иң яхшысы – үзенә әйтмичә юатып, тыныч кына яткыру да авыру газабын төрле дарулар белән җиңеләйтергә тырышу —бары менә шуны гына эшләргә мөмкин. Хәер, үзенә

әйтмәсәләр дә, карчык бу авыруның әҗәленә тигән авыру булуын күптән инде сизеп тора иде. Күпме яшереп маташмасыннар, монда ул бары вакытлы мөсафир гына...

Докторлар килеп киткәннән соң, карчыкка игътибар һәм тәрбия тагын да көчәя төште. Кызы белән кияве генә түгел, улы белән килене дә башта әсәйләренә бик йомшак булдылар, гел кайгыртып кына тордылар. Кирәк даруларын да табып китерделәр, күңеле теләгән ризыкны да алдыннан өзмәделәр. Гүя алар көннәре санаулыга калган әсәебез алдында соңгы бурычыбызны үтик дип тырышалар иде. Һәм шушы хәл үзе генә дә инде карчыкка күп нәрсә турында сөйли иде кебек... Билгеле, ул балаларыннан бик риза, күңеленнән аларга рәхмәтен укып кына тора, әмма шулай да аларның бу соңгарак калган яхшылыклары вакыт-вакыт карчыкка аны фани дөньядан юатып озатыр өчен генә эшләнгән шикелле булып тоела, шуңа йөрәге сызланып куя, һәм чыкмаган җанда өмет бар дигәндәй, иң элек бер Алласына сыенып, тыныч кына ята бирә иде.

Акъәби калага килеп урынга яту белән, Казакъстандагы кече улын һәм Пермь өлкәсендәге зур кызын чакырып язуны үтенә башлады. Аны менә язабыз, инде язабыз дип гел юатып тордылар, ләкин шулай да язарга ашыкмадылар. Бу шактый читен мәсьәлә иде. Карчыкның кече малае кайтып-китеп йөрмәслек бер җирдә эшләгәнгә күрә, аны, гомумән, чакырып маташудан мәгънә юк иде. Ә зур кызы Пермь өлкәсенең эчкәре бер районында балалар врачы булып эшли, җәй көне эше аеруча тыгыз була, шуңа күрә аны да вакытлы-вакытсыз борчырга ярамый иде. Кыскасы, карчыкның хәле бер көерәк торган чакта чакыру белән ашыкмаска булдылар.

...Көннәр үтә, гүя алар зур каланың түбәндәге шау-шуы кебек тонык кына гүләп, читләтеп үтә. Колакка сеңгән бу шау-шуның башы-ахыры булмаган кебек, үтеп торган көннәрнең дә исәбе һәм билгесе юк. Ә рәхимсез авыру карчыкны астыртын гына кимерә, акрынлап кына ул эри-сыза...

Озакка сузылган өметсез авыруның бик күңелсез бер ягы бар: авыручы үзе дә, аны караучылар да акрынлап ялыга башлыйлар. Бигрәк тә соңгылар өчен бу бик читен хәл: алар үз-үзләренә икърар итәргә курыксалар да, ничектер ихтыярсыздан «ахырын» көтә башлыйлар. Акъәби моны әле сизми иде, элекке кебек игътибар да бар, карыйлар да үзен, әмма шулай да нәрсәдер, җан җылысымы, борчылып торумы, кимеде кебек. Һәрхәлдә, кайгырту-карау гадәткә кергән мәҗбүри бер мәшәкать төсен алды шикелле. Аннары кызы да, кияве дә бик эшле кешеләр, һәр көнне үзләренең хезмәтләренә йөриләр, шулай булгач, аларның авыру әсәйләренә бөтен игътибарларын биреп бетерә алмаулары бик табигый иде.

Карчыкның берәүгә дә зары юк, ул барысын да аңлый, һәммәсеннән риза-канәгать, тик ул көне буе ялгыз ятудан бик туя һәм берәрсенең кайтып керүен зарыгып көтә. Кеше тансык, кеше кирәк аңа. Бигрәк тә кызының ике баласын – алты яшьлек Равиле белән дүрт яшьлек Гүзәлне бик сагына иде ул. Аларны балалар бакчасына йөртәләр – иртән илтеп куялар, кичкә табан алып кайталар. Алар кайткач, зур квартир тулып, җанланып киткәндәй була. Бүлмәдән бүлмәгә йөриләр, такы-токы нидер сөйләнәләр, һәм Акъәби ишектән күзен алмыйча аларны көтеп ята. Равиле – малай кеше – әбисе тирәсендә күп чуалырга яратмый, керсә дә, тизрәк чыгып китү ягын карый, әмма Гүзәле, кыз бала булганга, ахры, авыру әбисеннән бер дә ятсынмый, аңа гел сырпаланып кына тора. Бары шушы бала гына аңа бик матур, бик мөлаем итеп: «Әбекәем!» – дип дәшә. Бичара карчыкның күзләре яшь белән тулып китә бу җанга якын, тансык, кадерле «Әбекәем»не ишеткән чакта. Бик ярата, өзелеп ярата ул шушы түм-түгәрәк битле, кап-кара күзле йомшак, пакь, татлы оныгын! Үз йөрәгедәй якын ул аңа.

Хуҗаларга кунаклар да еш кына килгәлиләр иде. Өйдә, билгеле, ыгы-зыгы башлана. Гөлбикәнең кадак үкчәле туфлиләре белән шак-шок басып, ашыгып йөргәне ишетелә, тәлинкә, чәнечке-пычак, рюмкалар чыңлавы ишетелә, шуннан залдагы кунакларның шаулап сөйләшүләре, көлүләре ишетелә башлый. Карчык шуларның барысын да ничектер балаларча кызыксынып тыңлап ята.

Кызы Гөлбикә, вакыты тыгыз булса да, кергәләп: «Әсәй, хәлең ничек, берәр нәрсә кирәкмиме?» – дип сорап чыга. Карчык, күңеле булып:

– Рәхмәт, кызым! Кунакларыңны кара, кунакларыңны! – ди аңа.

Ә залда мәҗлес матур гына дәвам итә. Сөйләшеп-көлешеп арыгач, берәрсе пианинода уйный башлый, аңа кушылып, кемдер җырлап та җибәрә. Ә кайчагында исә кунакларның тавышы бөтенләй тына, аның урынына ят бер хатын-кызның ашыгыбрак сөйләгән ясалмарак тавышы ишетелә. Бу инде телевизор дигән нәрсә булырга тиеш. Карчыкның аны әле күргәне юк, ләкин шундый әкәмәт бер әйбер барлыгын, өйдәгеләрнең аны бик көтеп, бик яратып карауларын ул инде белә. Вакыт-вакыт шул «тилевәзир» дигән нәрсәдән бик моңлы курай тавышы да, бик борынгы башкорт җыры да яңгырый... Шул чакта карчык ишекләрне ачарга куша һәм җанына тансык бу җыр-моңны тәмам эреп, хыялларга китеп тыңлый. Гүя ул ефәк кылганнар йөгерешкән даласына, авыр чулпыларын чыңлатып йөргән кыз чакларына кайткандай була.

Әмма кайвакытта бу «тилевәзир» бик әкәмәт нәрсәләр дә күрсәтеп куя, ахрысы. Шундый әкәмәтләрнең берсен өйдәгеләр «футбол» дип атыйлар. Нәрсәдер инде ул футбул дигәннәре, Хода белсен!.. Ләкин шуны күрсәтә башласалар, хуҗалар да, килгән кунаклар да ашау-эчүләрен

дә, дөньяларын да оныталар. Бервакытны шул хәерсез футбул аркасында Акъәби бичара чак җаныннан аерылмады. Тик кенә уйланып ятканда, залдагы бер ханым кинәт:

– Керде! – дип чинап җибәрде.

– Гол! – дип үкереп салды җитмәсә тагын бер ир кеше.

– Әстәгъфирулла, тфү, тфү! – диде карчык, тәмам агарынып.

Кунакларның күбесе читтәге кечкенә бүлмәдә авыру карчык ятканны белмиләр дә иде шикелле... Һәрхәлдә, авыру бар дип борчылучы яки аның хәлен белергә керүче булмый диярлек – утыралар, көләләр-шаулыйлар, ашыйлар-эчәләр дә таралышалар... Шулай да ешрак килеп йөрүче бер кунак Акъәби янына кергәли торган иде. Бу – тәбәнәк буйлы, ашыкмыйча, елмаеп кына сөйләшүче, исеме шактый билгеле булган олы яшьтәге бер шагыйрь иде.

Залда кунаклар шаулап утырган чакта гына, ул карчык янына мыштым гына килеп керә, керә дә: «Саумы, әбекәем!» – дип ике куллап күрешә, аннары урындык алып, караватк ырына утыра. Ул күп сөйләшергә яратмый иде, күбрәк тезләренә таянып тик кенә утыра һәм ара-тирә берәр хикмәтле сорау гына биреп куя торган иде. Карчык аның эчкәнме-түгелме икәнен дә аера алмый, чөнки шагыйрь һәрвакытта гел бертөсле була торган иде. Ләкин, ничек кенә булмасын, ул бу уйчан, сәер кешене көтеп ала иде. Ничектер алар, аз сөйләшсәләр дә, бер-берсенә бик тизияләшеп киттеләр.

– Акъәби, Акъәби! – ди шагыйрь, үзалдына әйткәндәй әкрен генә. – Ә ни өчен Акъәби, ни өчен Кара әби түгел?

– Минем исемем Акбикә, – ди карчык, бу көтелмәгән сорауга бераз пошынып. – Кыз чагымда мине Аксылу дип йөртәләр иде, кияүгә чыккач, Аккилен булдым, аннары Акҗиңгә, ә хәзер менә Акъәби...

– Димәк, син гомерең буена ак кеше булгансың икән. Ак күңелле, пакь күңелле кеше... Менә миңа да шундый әсәй кирәк иде.

– Ни сөйлисең, улым, синең үз әсәең бардыр бит?!

– Юк шул, юк... Күптән оҗмахта инде ул... Ә әсәйсез авыр, әсәй сабый балага гына түгел, менә минем кебек сакалы агарган кешегә дә кирәк икән ул!

– Рәхмәт, улым! – ди карчык, нигәдер ирене калтырый башлап.

Шагыйрь, тезләренә таянган килеш, бераз уйланып утыра, аннары тагын сорап куя:

– Юлкотлыны сагынасыңмы?

– Сагынам, улым!

– Әйе, халык матур уйлаган, авылына, җиренә, суына матур исемнәр бирә белгән. Юлкотлы! Юлың котлы булсын, Акъәби! – дип әйтәсе килеп тора.

– Безнең ерак бер бабаебызның исеме Юлкотлы булган диләр. Аның кышлавын «Юлкотлы кышлавы»* дип йөрткәннәр. Тора-бара авылга да шул исем күчкән.

– Ә, шулаймыни? – ди шагыйрь, кызыксынып, һәм карчыктан иплəп кенә аның кыз чакларын, кайчан, ничә яшендә кияүгә чыгуын, туйларның ул заманда ничек узуын, шул чактагы йолаларны, уеннарны, җырларны сорашырга тотына. Акъәби, еш кына тыны кысылса да, үзенең истәлекләрен, күргән-белгәннәрен иренмичә сөйли, ә шагыйрь аны бик игътибар белән тыңлап утыра... Карчык сөйләп беткәч тә әле, ул ни дә булса әйтергә ашыкмый, тик бераздан гына үзенең берәр эчке уен раслагандай әйтеп куя:

– Ийе... узган гомер кире кайтмый, сулар үргә акса да!.. Шулай ди җыр, сулар үргә акса да ди, усал әйтә! Берсе дә – узган гомер дә, үтеп киткән тормыш та кире борылып кайтмаячак. Син дә, әбекәем, моның белән килешә торгансыңдыр?

– Килешмичә нихәл итәсең инде...

– Юк, син дөресен әйт, син олы кеше, бәлки борынгы тормыш сиңа кадерлерәктер, син аны сагына торгансыңдыр?..

– Хәзергесе начар булса, сагыныр идем, – ди карчык, уйланып кына. – Хәзергесе, Аллага шөкер, әйбәт бит.

Шагыйрь аңа күзләрен тутырып карый.

– Шулаймы?.. Син дөньяны таный беләсең икән, әбекәй, яшә, яшә!.. Ләкин сагыныр нәрсәләр дә юк түгел бит. Әнә шул син сөйләгән халыкның матур йолалары —бәйрәмнәре-туйлары, уеннары-җырлары – берсе дә онытылмаска тиеш, минемчә... Халыкның буыннан-буынга күчеп килгән рухи байлыгы бит алар барысы да... Дөрес, яңа заман яңа байлыклар тудыра, ләкин искенең дә яхшысын саклый белергә кирәктер ләбаса!

– Борчылма, улым, – ди карчык, сабыр гына. – Халыкныкы халыкта саклана, югалмас, Алла бирсә!

– Гаҗәп сүз әйттең, әсәй бәгырем, гаҗәп сүз!.. – Һәм шагыйрь, кинәт кенә тураеп, бер аягы белән идәнгә акрын гына суга-суга җырлап җибәрә:

Аппак микән, йомшак микән йәнкәемнең куллары,

Салават күпере кү-ү-үк суга барган юллары.

Онытып кара син бу җырны, онытып кара, мөмкинме соң!..

Шагыйрь тавышы өзелгәндәй шулай ук кинәт кенә тынып кала, башын артка чөя һәм күз төбендә аның тәгәрәп төшә алмаган яшь бөртекләре күренә. Тик бераздан тынычлангач кына, гафу үтенгәндәй әйтеп куя:

– Син мине тилегә санама инде, яме!.. Нишлим, мин шагыйрь кеше, халык җырын, бөек Тукай әйтмешли, рәсүлнең тырнагыдай йөрәгемдә саклап йөртәм.

– Ә мин Тукайны беләм, – ди карчык, һич көтмәгәндә.

– Китче! – ди шагыйрь, шаккатып. – Кайдан беләсең син аны?

– Суфияннар мәктәптә укыган чакларында: «И туган тел, и матур тел», – дип бер җыр ятлап йөриләр иде, шуннан хәтеремә кереп калган.

– Суфиян агай «Туган тел»не җырлап йөрдеме?.. Кызы-ык! – Һәм шагыйрь, бөгелә төшеп, тавышсыз гына көләргә тотына: – Их, генерал, генерал!..

Ләкин Акъәбинең җитдиләнеп китүен күргәч, ул көлүеннән шунда ук туктый, иелеп чәчләрен сыпыра, аннары баладай юаш кына әйтә:

– Син мине кичер инде, әсәй, синнән бернәрсәмне дә яшерә алмыйм шул...

– Бик яхшы, улым, – ди карчык, тыныч кына. – Күңелең кешеләргә көзгедәй һәрвакыт ап-ачык булсын!

– Рәхмәт, әсәй, рәхмәт!.. Җиңел, рәхәт миңа синең янда... Тик күп лыгырдап ялыктырам бугай үзеңне... Ярый, кузгалыйм, булмаса, син дә ял ит инде, ял ит, безгә карама, без – әрсез кунаклар!.. – Һәм шагыйрь, торып, карчыкның юрган өстендә яткан сап-сары кулын йомшак кына сыйпый да исерә төшкән кешедәй аз гына чайкала биреп чыгып китә.

«Сәер кеше! – дип уйлана карчык аның артыннан,—ләкин әйбәт кеше үзе, кече күңелле, тик күңелендә нindидер сызлавыгы бар шикелле, җанына урын таба алмыйча, шуңа сызланып йөри, ахрысы, бахыркаем!» Һәм күп вакытта ул аны ятим баладай күреп, чын ихластан кызганып кала торган иде.

...Бер ике-өч атна үтүгә, карчыкның хәле шактый авыраеп китте. Бик ябыкты ул, тамагына бернәрсә капмас булды, шуның өстенә тавышы да бетә башлады. Яңадан врачлар килде, карадылар, юаткан булдылар, тагын нindидер яңа дарулар язып калдырдылар. Хәер, карчык өчен боларның берсе дә кирәкми иде инде. Ул барысын да белеп ята. Шулай ук аның хәлен уллары-кызлары да бик яхшы белеп торалар... һәм эчләреннән генә куркып, шомланып үлемне көтәләр. Карчык хәзер моны үзе дә сизә, карчыкның сизгәнен алар да беләләр.

Ләкин шуңа карамастан һаман: «Әсәй, борчылма, үтәр, терелерсең!» – дип аны да, үзләрен дә алдарга тырышалар.

Карчык соңгы көннәрдә бик уйлана башлады. Көндезләрен барысы да хезмәтләренә китеп беткәч һәм асрау кыз да, карчыкның өстеннән бикләп, базарга китеп баргач, Акъәбигә ялгызы ак түшәмгә карап, теләсә күпме уйланып ятарга мөмкин иде. Уйлар күп, уйлар төрле-төрле, өзлексез килә торалар, китә торалар... Башта ул чынлап та Юлкотлысын сагынып йөдәде.

Бөтенесе – яланы-кыры, авылы-урамы, кешеләре, маллары – бер генә минутка да исеннән чыкмый... Бөтенесе – өе, алачыгы, келәте, кәҗәсе, тавык-чебешләре – күз алдында тора, бөтенесен ап-ачык ишетә, күрә... Менә кәҗәсе көтүдән кайткач, ишек төбенә килеп, Акъәбине дәшкәндәй, тавышын калтыратып кычкыра торгандыр. Җавап булмагач, тык-тык басып, өйалдына ук керә башлыйдыр... Тавыклары да тибенеп йөргән җирләреннән туктап: «Нигә әле безнең әбиебез күренми?» – дигәндәй, башларын кырын салып, җелт-җелт карана торганнардыр. Казлары да, күл буеннан кайткач, ишегалдында озак кына каңгылдаша торганнардыр да, чыгучы, дәшүче булмагач, боек кына чирәмгә чүгәләшеп, башларын сыртларына салып, йокыга талалардыр... Әйе, алар барысы да әбинең юклыгына гаҗәпләнә торганнардыр, күңелсезләнеп, боегып, моңаеп йөри торганнардыр... Шуларны уйлагач, Акъәбигә гаять авыр булып китә, алар да, үзе дә аңа бик кызганыч булып тоела һәм ихтыярсыздан кайнар яшьләре мөлдерәп агып төшә... Юк, күрмәс инде ул аларны – туып-үскән Юлкотлысын да, гомер иткән өен дә, күршеләрен дә, терлекләрен дә – берсен дә яңадан күрә алмас инде!

Шушы котылгысыз аерылышуны сизеп торганга күрә дә булса кирәк, карчыкның күңеленә еш кына башка уйлар – җитдирәк, тирәнрәк уйлар да килә башлады. Әйе, аның көннәре санаулы, соңгы сәгате якынлаша... Ул курыкмый, ул тыныч көтә бу серле, рәхимсез сәгатьне, тик бер Ходаеннан җан биру газабын җиңеләйтүне генә сорый... Ул әзер булып торырга тиеш, әйе, зиһене ачык, теле бар чакта ул үзенең соңгы теләген, соңгы васыятьләрен әйтеп калырга тиеш. Аннары инде... китәргә дә була.

Иң элек аның уен, билгеле, үлгәннән соң ничек итеп күмәрләр дигән нәрсә гел борчып тора. Ул белә: кайда, кемнәр кулында ятуын, әмма ул, гомере буена башыннан яулыгын салмаган мөселман карчыгы, Алла хозурына барам дип ышана, шуңа алдан әзерләнеп килгән һәм бөтен керсез күңеле белән үлгәннән соң гәүдәсен бары мөселманча итеп җирләүләрен тели: «Инде, мулла-мәзин чакырып, тәхлил әйттерү кебек зур мәшәкатьле эшне сорамыйм да, анысын эшләмәсәләр дә ярый. Әмма ләкин гәүдәмне әйбәтләп юып, ак кәфенгә төреп, ләхетле кабергә куйсыннар иде. Аннары, берәр карттан гына булса да, баш очымда Коръән укытсыннар иде...» Авылында булса, аны шулай күмәрләр дә иде, аның алып куйган кәфенлеге дә, чәчеме өчен җыеп тоткан тәңкәләре дә, гәүдәсен ләхеткә куючылар өчен саклап килгән сөлгеләре дә бар иде, ләкин, нихәл итмәк кирәк, барысы да сандыгында торып калды шул... Ничек кенә булмасын, улы-кызы аның бу үтенечен тыңларга тиешләр. Үзләре ышанмасалар да, кирәксез нәрсә дип тапсалар да, ул кушканча эшләргә тиешләр – бу бит газиз аналарының соңгы васыяте! Васыятьне үтәмәү мөмкинме соң?!

Һәм кызы бер кичне анның хәлен белергә кергәч, Акъәби аңа якынрак килеп утырырга кушты.

– Гөлбикә кызым, сиңа сүзем бар, – диде ул, чак ишетелерлек зәгыйфь тавыш белән. – Алладан вакыт җитә шикелле, шулай сизәм... Менә исемдә чакта әйтеп каласым килә... – Аңа сөйләве авыр иде, әледән-әле тыны кысыла, авызы белән көчкә генә өзеп-өзеп сулышын ала.— Ух, ух, Тәңрем, җиңеллек бир... Э-э, әйе... кызым, ишетәсеңме, мин үлгәч, гәүдәмне берүк...

Гөлбикә, кызганудан йөзен чытып, шунда ук анның сүзен бүлде:

– Әсәй, әсәем, нигә ул хакта сөйлисең әле... Куй, кирәкми, борчылма, уйлама ул турыда...

– Һай, кызым, ничек уйламыйсың ди, килә бит ул әҗәл, килә, күрмисеңмени?.. Ух, уф... Соңгы сүземне әйтеп калыйм...

– Әсәем, бәгырем, ярамый сиңа сөйләшергә, – диде кызы, кат-кат башын селкеп. – Хәлең юк, тавышың беткән, нигә үзеңне азаплыйсың... Тыныч кына ят, кирәгеңне генә сора!..

Карчык бераз күзен йомып торды, аннары ничектер хәл кергәндәй тыныч кына әйтте:

– Мин, кызым, нәкъ менә иң кирәген сорыйм да шул... Сез, яшьләр, шәригать йолаларын белмисез, үзем әйтеп калдырмасам, кем мине мөселманча җирләр?.. Яшнеккә салырсыз да илтеп куярсыз...

Кызы урыныннан ук торды – ул, гадәтенчә, каядыр ашыга иде.

– Юк хәсрәт төшкән башыңа, әсәй!.. Ярар, бу хакта сүзне бетерик... Врачлар киңәшен тыңларга кирәк. Хәзер менә шушы даруыңны эч, бераздан Фатыйма кайнар чәй кертер... Онытма, ямьсез уйларга бирелеп яту синең өчен бик зарарлы ул... Ярый, хәзергә, сөйләшербез, минем барып киләсе җирем дә бар иде...

Карчык дәшмәде, тик «бар!» дигәндәй башын гына каккандай итте. Һәм бик озак күзләрен йомып, берни уйламагандай, тын гына ятты. Әмма анның зиһене бер генә секундка да эшләүдән туктамаган иде. Нәрсәнедер, үзе өчен бик мөһим, бик яңа бер хакыйкатьне аңларга тырышып ята иде кебек... Алай, әнә ничек икән ул!.. Үләсе кеше белән каласы кеше тиз генә уртак тел таба алмыйлар икән! Бик кыен икән аларга сөйләшүе... Ни өчен соң бу шулай? Бөтенләй кирәксез, юк нәрсә турында кайгыртып ятамыни ул – дөньядан китәсе ана кеше? Балалары белән анның арасы шулай бик ераклашты микәнни? Алай дисәң, карыйлар, дәвалыйлар, кызганып, борчылып та торалар кебек, ә менә әсәйләренең соңгы сүзен, соңгы үтенечен тыңларга, йөрәген аңларга теләмиләр. Нидән соң бу болай?

Әлбәттә, карчыкка моның җавабын табу бик читен иде. Тик ул күңеле белән генә сизенә: балалары анның бүтән кешеләр, бик нык үзгәргән кешеләр. Авыр аңа, ямансу аңа, ничектер кинәт бик ятим, бик ялгыз калгандай хис итә ул үзен... Ләкин шулай да анның балаларына үпкәлисе,

рәнҗисе килми. Җәнлек үзенең ярасын ялап төзәткәндәй, ул да җәрәхәтле йөрәген сабыр акылы белән тизрәк тынычландырырга, юатырга ашыга: ярамый болай, язык булыр, ди, балаларымны бәхилләп, ризалыкларын алып китәргә тиешмен, ди. Шәт, алар да мине аңларлар, сүземне тыңларлар, кадерләп озатырлар... Әйе, аның өмете зур һәм әйтер сүзе дә күп әле, күп...

Җитмеш алты ел буе дөньяда яшәгән карчык бит ул. Гомер иткән нигезе бар, нужа белән тапкан күпме-азмы мал-мөлкәте бар, яшь килен чагыннан ук саклап килгән үзе өчен бик кадерле кием-салымнары бар – шуларның барысын да ул бик теләп, бик куанып балаларына калдырып китә. Өен, абзар-курасын, кәҗә-сарыкларын соңыннан теләсә нишләтсеннәр – колхозга бирәләрме, сатып акчасын бүлешәләрме – алар эше.

Ләкин кайбер бик кадерле нәрсәләрен ул балаларына исемләп, атап биреп калдырырга тели. Сатар өчен дә түгел, чит кешеләргә бирер өчен дә түгел, ә аның төсе итеп, саклап тотар өчен бүләк итәргә тели. Мәсәлән, үзенең акука тоткан, якут каптырмалы сары бәрхет камзулын Гөлбикәсенә, вак мәрҗәннән җыеп эшләнгән, әдрәс астарлы кашмау белән чәчкабын Пермьдәге олы кызы Сылубикәсенә, картыннан калган камчат бүрекне улы Суфиянга билгеләп тора. Аннары бик борынгы тәңкәләр һәм төрле төстәге ташлар белән бизәлгән бөяте (хәситәсе) бар, шуны, кабул итсә, марҗа килененә бүләк итәр иде. Улының хатыны булгач, ул аңа да якын бит, бәлки, Мария килен дә каенанамның төсе дип бөятне үзендә саклар иде.

Билгеле, кызы – кашмауны, килене бөятне киеп йөрмәсләр, ул кадәресен генә Акъәби аңлый инде. Ләкин бит аларны бер әсәйләре генә түгел, әсәйләре кебек бик күп башкорт кызлары, башкорт җиңгәләре кигәннәр. Шуның өчен генә булса да, алар ул киемнәрне ничектер сакларга тиешләр. Югыйсә бетә бит инде барысы да, югала, онытыла... Ярый, шушы көнгә кадәр ул, Акъәби дигән кортка, яшәп килде. Ул менә аларны моңарчы туган җирләре белән, андагы тормыш, андагы кешеләр белән бәйләгән бердәнбер җеп булды. Хәзер шушы бердәнбер җеп тә өзелә инде... Нишлисең, тәкъдирдән узып булмый шул, узып булмый!.. Ләкин, ни кызганыч, тере җеп өзелү белән бергә туган-үскән илгә юл да киселәчәк. Кылганлы далада утырган Юлкотлы үзе дә, аның кешеләре дә акрынлап онытылачак. Әмма киселергә тиешме соң, Ходаем, туган илкәйгә юл, онытылырга тиешмени соң ата-бабадан килгән андагы тормыш, андагы кешеләр? Юк, Акъәби үзе мондый хәл белән һич тә килешә алмый. Аның өчен туган ил – туган туфрак дигән сүз. Шул туфракта ата-бабаларының сөякләре ята, шунда аның гомердәшләре Миңлебай картлар, Минҗиһан корткалар, шунда аның күз алдында үсеп җиткән яшь ирләр, яшь киленнәр, шунда аның тирәсендә чуалган бала-чагалар, һәм ул аларны, кая гына китмәсен, актык сулышына чаклы онытачак түгел. Менә шул хакта аның үз балаларына да бик нык әйтеп каласы килә:

– Суфиян улым, Гөлбикә кызым, балакайларым! Сез икегез дә укыган, белемле, дәрәҗәле, зур кешеләр булдыгыз. Икегезнең дә түгәрәк кенә тормышыгыз бар, бер-бер артлы балаларыгыз үсеп килә, үзегез дә инде олыгаеп барасыз. Хак Тәгалә барыгызга да тигез гомер биреп, шул балаларыгызның игелеген күрергә насыйп итсен! Амин!.. Ләкин сезнең дә сабый чакларыгыз бар иде. Сез «Аслы күл» әйләнәсендәге киң, тигез далада утырган Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылында тудыгыз. Сөттәй йомшак, көмештәй саф сулы «Аслы күл» Юлкотлыдан өч кенә чакрымда... Аның шифалы суында коендырыр өчен атагыз мәрхүм сезне, арбага тезеп утыртып, еш кына шунда алып бара иде. Ә «Аслы күл»нең Нора тавына менсәң, шуннан инде еракта ялгыз утырган, нәкъ түбәсенә куш каен үскән Балкан тавы да күренә. Сезнең «Зыятүләк белән Сусылу» әкиятен ишеткәнегез бар инде, шул көзгедәй уйнаклап яткан күл белән еракта басып торган биек таудан туган әкият ул, ә тауның түбәсендәге куш каенны Зыятүләк белән Сусылуның кабере диләр, каеннар төбеннән бәреп торган чишмәне Сусылуның озын, кара толымнарыннан саркып чыккан су диләр. Әнә шулай әкиятләргә кергән гаҗәеп якты, иркен, матур җирләр бит ул безнең «Аслы күл» яклары! Һи, ниләр генә сөйләп булмас иде безнең башкорт илләре, башкорт җирләре турында!..

...Мин бераз читкәрәк киттем шикелле, балалар! Әйтәсе килгәнем бүтән иде... Зиһенемне азрак җыйыйм әле... Әйе, менә шул... Сез Юлкотлыда тудыгыз, аның киң урамында чабышып йөрдегез, чирәмендә ятып аунадыгыз... Үсә төшкәч, сез Юлкотлының ак кылганлы яланнарында, тау-чокыр буйларында йөрдегез, бозау көттегез, кизәк җыйдыгыз, әрлән кудыгыз... Бүтәннәрдән бер аермагыз да юк иде, бүтәннәр шикелле үк сез дә ситсы күлмәк, бөрмәле ыштан киеп, ялантәпи йөрүче кап-кара балалар идегез, үскәч кенә менә кем булып киттегез!

...Җиде-сигез яшегездән Юлкотлының кечкенә мәктәбенә сабакка төштегез. Шунда тел ачкычы таптыгыз, шунда күңел күзегез ачылды... Икешәр-өчәр көн рәттән котырган кышкы бураннарда үзем сезне җитәкләп мәктәпкә илтә торган идем... Атагыз Әлшәй базарыннан, куенына кыстырып, сезгә китаплар, дәфтәрләр алып кайта торган иде... Бик ипле, бик бала җанлы кеше иде ул, мәрхүм!..

Юлкотлы мәктәбен бетергәч, Сыртлан мәктәбенә йөреп укыдыгыз... Аны да бетергәч, калага китәбез дидегез,—каршы тормадык. Гәрчә сезне бер-бер артлы яныбыздан җибәреп тору авыр булса да, уку – изге эш, без күрмәгәнне балаларыбыз күрсеннәр, безгә насыйп булмаган аларга насыйп булсын дип, хәлебез җиткәнчә һәркайсыгызның өс-башын юнәтеп, акчасын да аннан-моннан табып, сезне ерак юлга озаттык. Сездән аерылгач, безгә бик ямансу була иде, атагыз, ир кеше, сиздермәсә дә, минем ашарга утырган саен кашыгыма яшьләрем тәгәрәп төшә

иде... Сез киттегез, әмма ул чакларда әле сез Юлкотлыны онытмый идегез, Юлкотлыны сагына идегез, бала кошлар шикелле очып-очып кайткалый идегез... Ләкин ни өчен сез аны соңыннан оныттыгыз? Чакырып-дәшеп тә еллар буе кайтмый башладыгыз?.. Ике сүзнең берендә «туган ил» дисез, ә Юлкотлы нәрсә соң? Туган илнең сезгә иң якын, иң кадерле бер өлеше түгелмени ул?

...Сез бик еш кына «халык» дисез, ләкин Юлкотлыдагы кешеләр дә халыктыр бит инде. Бер тамырдан чыккан, бер ыруглан үрчегән халык, шуңа күрә ул сезгә якынрак та, туганрак та булырга тиештер ләбаса!.. Кайчандыр сезнең башыгыздан сыйпап узган агайларның, апайларның кайберләре хәзер дә әле исәннәр. Менә кайтып, шулар белән ике куллап бер күрешсәгез, олылап бер җылы сүз әйтсәгез, сез аларны күпме сөендерер идегез. Һәм күпме рәхмәт, күпме изге теләк сез алардан ишетер идегез. Һай, ярата безнең халык зур укыган кешенең кече күңелле булуын, мактап бетерә алмый, ә тәкәббердән кача, тәкәбберга бервакытта да йөзен дә, телен дә ачмый ул...

Яки атагыз мәрхүмне исегезгә төшерегез. Ул да бит халыкның бер бөртеге... Сезгә җан биргән, сезнең өчен тир түккән, сездән күпме өметләр көткән ата кеше бит әле ул сезгә! Йә, сез аның алдында бер дә бурычлы түгелмени соң?.. Авыл читендәге канау белән генә әйләндереп алган кечкенә зиратта аның гәүдәсе ята. Баш очында ташы юк... Аның каберен мин дә, тагын берничә авыл карты гына белә. Бездән соң белүче булмаячак, кабер җир белән тигезләнәчәк... Йә, сезнең җаныгызны бер дә борчымыймыни бу нәрсә?.. Машиналар сатып алырга хәлегездән килә торып, атагызның каберенә бер ком таш кына яздырып куярга сезнең кулыгыздан килмимени? Килә, бик килә, тик күңел саранлыгыннан котылырга кирәк, тик кемгә бурычлы булуыгызны онытмаска кирәк!.. Имештер, яшь чагында көтү көткән, соңыннан бик баеп киткән Өфенең бик зур бер куписы үзенең шул кайчандыр киеп йөргән иске чабаталары белән озын чыбыркысын намаз бүлмәсендә генә элеп торткан, ди. Күрәсез, ул да, бахыр, намаз укыган саен шуларга карап, элек кем булуын онытмаска тырышкан. Менә сезгә гыйбрәт!

Әйе, сез зур кешеләр булдыгыз, илгә, дәүләткә кирәкле, файдалы кешеләр булдыгыз, хәзер шуның әҗерен күрәсез, рәхәтен чигәсез!.. Ләкин сезне менә без, Сәлимҗан белән Акбикә дигән гади башкорт кешеләре, дөньяга китердек, Юлкотлы дигән кечкенә башкорт авылы сезне үзенең туфрагында үстерде, башкорт халкы сезне бүгенге югарылыкка күтәрде – сез шуны онытмагыз, балаларым, ишетәсезме? Сезнең онытырга хакыгыз юк, аңлыйсызмы?.. Бу минем күңелем түреннән чыккан иң кайнар, иң зур, иң соңгы васыятем сезгә!

Һәм шушы васыятен әйтеп калырга Акъәби берничә тапкыр омтылып карады. Бу аның өчен бик тә кирәк иде, әйтмичә китәсе килми иде, хәтта үлгәннән соң да әйтә алмыйча калган

васыяте өчен каберендә борчылып ятар кебек иде. Ләкин ул авызын ачты исә, аңа: «Һәй, әсәй, юкка борчылма әле син, кирәкмәгән нәрсәләр уйлап ятма әле», – диделәр. «Сиңа күп сөйләргә ярамый, врачлар кушмый», – дип гел тыйдылар һәм аны юатыр, тынычландырыр өчен тамчылап даруын эчерделәр, лимонлап чәен китерделәр, тәлинкә тутырып алмасын, чиясен китереп куйдылар.

Аптырап-уйланып ята торгач, кайчагында Акъәбинең үзе янында сырпаланган кечкенә Гүзәлгә нидер әйтәсе килә, бик сак кына, бик гади сүзләр белән генә күңелендәге шул сабыйга аңлатасы килә. Шул ук вакытта баланың йөрәгенә шом салмыйм дип тә курка ул... Ничек кенә дип әйтергә аңа? Бераз икеләнеп ятканнан соң, баланың аркасыннан сыйпап, гүя болай гына әйтеп куйган була:

– Бәләкәчем, мин тиздән китәрмен инде...

– Китәсең... Кая китәсең? – ди бала, зур күзләре белән әбисенә тутырып карап. (Ә берни сизә, берни төшенә белмәгән, бары тик ышана яки курка гына белгән сабый күзләреннән дә бәгырьне телгәләрлек нәрсә бар?!)

– Ни инде... үзебезнең Юлкотлыга, – ди карчык, көчкә генә телен әйләндереп.

– Юк, китмисең, китмисең!.. – ди бала, шунда ук үпкәли дә башлап.

Акъәби үксеп җибәрмәс өчен иреннәрен кыса һәм озак кына дәшә алмыйча ята. Бары бугазына килгән төер кире киткәч кенә, тагын әйтеп куя:

– Мин сиңа, кошчыгым, аннан бүләк җибәрермен.

– Бүләк? Нинди бүләк, әбекәем?

– Сиңа билгеләп куйган бик матур чулпыларым бар, шуларны җибәрермен.

– Ә нәрсә ул чулпы? Нигә син аны алып килмәдең?

– Онытканмын.

Бала, ышаныргамы, юкмы дигәндәй, әбисенә карап тора-тора да, нидер сизенгәндәй, башын селкеп куя.

– Син алдыйсың, – ди ул, сузып кына. – Бездән китәр өчен генә әйтәсең...

Акъәби йөзен тизрәк читкә бора. Юк, булмый, сөйләү мөмкин түгел... Сабыйның күңеленә кагылырга ярамый, ярамый, аярга кирәк аны, аярга!.. Кем белә, бәлки, соңыннан бу әйткәннәрне исенә төшереп, әнисеннән: «Әбекәем кая китте, нигә миңа чулпы җибәрми?» – дип сорап йөдәтер. Һәм карчык сабыйны тынычландырыр өчен, аның күңелендә бернинди шик-шомлану калдырмас өчен, көлгән булып, баланы юатырга ашыга:

– Юри генә әйттем, бәбкәчем, юри генә! Сине калдырып китәмме соң?.. Юк, юк, беркая да китмим, күз нурым!..

...Гаҗәп хәл! Бала белән шушы гөнаһсыз гына сөйләшүдән соң Акъәби гомумән васыятьләрен кемгә дә булса әйтергә тырышудан шактый вакыт тыелып торды. Әллә ничек шунда һичнәрсәгә исе китмәстәй, һичнәрсә турында уйлыйсы килмәстәй булып калды. Тик өзлексез җанын борчыган бер генә нәрсә аны һаман уйландыра иде. Һәм бары шуны гына ул үз янына ашыгып кына кереп чыккан улы Суфиянга ишетелер-ишетелмәс тавышы белән тагын бер тапкыр әйтеп карады:

– Улым, үтенәм сездән, мине, зинһар, үзебезчә, мөселманча җирли күрегез инде.

Улы Суфиян уйлап та тормыйча:

– Һи, әсәй, обязательно шулай эшлибез аны! – диде гаҗәеп бер җиңеллек белән: – Менә әйтте диярсең, мөфти хәзрәтнең үзен чакыртам янына... Только син, әсәем, үләргә ашыкма әле, яме! Торыйк әле, торыйк, Алласына, мулласына үч итеп дигәндәй...

– Көфер сүз сөйләмә, улым! – диде карчык, сабыр, җитди генә.

Ләкин Суфиян авыру кешегә бердәнбер кирәк нәрсә, ул да булса (үз сүзе белән әйтсәк), бодрость дип белә иде. Шуңа күрә ул һәр сүзне уенга бора, үзенчә шаяртмакчы-көлдермәкче була. Һәм күп вакытта утырып та тормыйча, авызына ни килсә шуны сөйләп, бүлмәне бер шаулатып, тизрәк чыгып та китә иде. Ә карчык, бичара, ни уйларга да белмичә, аның артыннан башын гына чайкап кала. Чынлап әйттеме ул, юри генә әйттеме, нигә утырып, әйбәт кенә сөйләшмәде соң, кая ашыга, кая чаба ул? Гаҗәп бу шәһәр халкының гадәте – барысы да каядыр ашыгалар, ашыгалар, ашыгалар!..

Үлем дә ашыга иде шикелле. Соңгы көннәрдә карчыкның хәле бөтенләй начарланып китте. Тын алуы бик авырлашты, кислород мендәреннән бер дә аерылмас булды. Бала шикелле тәмам кечерәеп калды, күзләрен дә инде йөртә алмый башлады.

Врачлар кызы белән киявенә карчыкның тиздән өзелеп китү ихтималын әйттеләр – торса, тагын бер атна-ун көн генә тора алыр, диделәр. Бу хәбәр аларда зур борчылу тутырды. Димәк, әсәй карчык китә!.. Һәм бик ачык, котылгысыз булып алларына килеп баскан бу гаять авыр, хәсрәтле үлем аларны тәмам аптырауга төшерде. Хикмәт шунда, үлем дигән нәрсә аларның өенә беренче мәртәбә керә әле, моңарчы аларның мондый фаҗигале хәлне күргәннәре дә, кичергәннәре дә юк иде әле... Борчылмыйча, уйланмыйча һич мөмкин түгел. Иң элек карчыкның үлеме балаларга бик авыр тәэсир итәчәк, куркытачак бу нәрсә аларны... Аннары мәетне юу бар, җыештыру бар, озату бар, ә алар үзләре бу эшләрнең тәртипләрен һич тә белмиләр. Кемнән эшләтергә, ничек эшләтергә боларны? Түбәндәге дворник хатыны Сәрбиҗамал апага әйтсәң, ул бик теләп боларның барысын да оештырыр иде... Юарга, кәфенләргә карчыкларын да табар иде, бәлки мулласын да чакырып китерер иде. Ләкин болар барысы да гаять мәшәкатьле эш бит, әллә

ничек күңелсез эш. Кияве, бу хакта сүз чыкса, теше сызлагандай, чыраен сыта башлый. Мөселманча булсын дип әллә нинди карчыкларны, муллаларны үзенең квартирасына бер дә китерәсе килми аның.... Килешми аның хәлендәге кешегә бу нәрсәләрнең берсе дә. Ничектер бүтән юл, бүтән чара табарга кирәк бу положениедән чыгар өчен...

Кияве белән кызы арасында шушы хакта берничә көн буена сүз барды. Гаять четерекле мәсьәлә турында алар мөмкин кадәр әдәп, такт саклап сөйләштеләр, ләкин шулай да ара-тирә үпкәләшеп, талашып та киткәләделәр. Хәер, асылда аларның фикерләре бер иде: карчык квартирада үлсә, бик авыр, бик күңелсез булачак.

Ахырда кияве әйтте: «Гөлкәй, бүтән чара юк, әбине больницага салырга кирәк, – диде. – Больницада әле аңа яхшырак та булыр, урын-җире чиста, врач көн дә карап тора, сестралар һәрвакыт янында, үзебез дә чиратлашып янына баргалап торырбыз... Нишлисең инде, үләргә булгач, кайда да барыбер... Аның каравы, балалар кадерле әбиләренең үлемен күреп, тетрәнеп калмаслар, куркып елашмаслар... Аннары больницада мәетләрне әйбәтләп юындырып, киендереп озатучы махсус кешеләр дә бар. Ә без үзебез монда нишли алабыз?.. Юк, иң яхшысы – больницага салу инде...»

Гөлбикә бу эшнең күңелгә авыр, оят, килешмәгән ягын белсә дә, уйлый-тора ахырда риза булды. Шулай сөйләшеп килешкәннән соң, алар үзләренең бу карарларын, уңайсызланыбрак булса да, Суфиян белән Мария Васильевнага да әйттеләр. Башта Суфиян бик кайнарланып каршы төште.

– Што сез, – диде кычкырып, – кадерле әсәебезне өйдә үлмәсен өчен генә больницага илтеп салмакчы буласыз! Оятын ничек күтәрерсез, хурлыгын кая куярсыз?.. Юк, юк, мин моңа асла риза түгел!

Ләкин кияү кеше кызмыйча гына, әйбәтләп кенә аңа төшендереп бирде:

– Каенагай, оят мәсьәләсендә синең безгә бер сүз әйтергә дә хакың юк. Әсәебезне авылдан без барып алдык, без аны өебездә ай ярым буена кулыбыздан килгән кадәр тәрбияләдек, карадык, терелмәсме дип бөтен чараларны күрдек... Әсәй үзе моның өчен безгә рәхмәтен әйтер, дип ышанабыз. Инде больницага салу мәсьәләсенә килгәндә, бу синең өчен авыр икән, тотасың да үзеңә аласың... Сиңа да ана бит ул!.. Әмма мин әсәйнең үлгән чагын балаларга күрсәтеп, аларның йөрәкләрен җәрәхәтләргә теләмим. – Һәм шунда ук, каенагай тагын дулап китмәсен дип булса кирәк, иплә, йомшартып кына әйтте: – Без, Суфиян, дәү кешеләр, мәсьәләгә айнык карарга тиешбез. Авыруны больницага салуның һичбер гаебе юк. Беркем бер сүз әйтмәячәк. Инде анда үлеп китә икән, без әсәебезне шуннан гына бик әйбәтләп,

бөтен шартын җиткереп, соңгы юлына озатырбыз. Ә өйдән мәет озату бик авыр, бик мәшәкатьле эш ул, син безнең хәлебезне аңларга тиешсең, Суфиян!

Бу сүзләрдән соң Суфиян шактый аптырауга төшеп, үзенә терәк эзләгәндәй, алмашлап бер сеңелесенә, бер хатынына карады. Ире артына посыбрак, бөрешеп кенә утырган сеңелесе гүя бөтен кыяфәте белән: «Миңа карама, мин арыдым, мин берни дә эшли алмыйм», – дип әйтеп тора иде. Ә юан ак беләкләрен зур күкрәкләре өстенә кушырып салган хатыны, бу мәсьәлә аңа һич кагылмагандай, йомык бер битарафлык саклап утыра иде. Суфиян акрын гына җилкәсен кашырга тотынды.

– Шулай, каенагай! – диде кияве, аның хәлен җиңеләйтергә теләгәндәй. – Борчылырлык урын юк, барысы да бик әйбәт булыр, менә күрерсең!

Һәм Суфиян бу мәсьәләдә үзенең ялгыз калуын гына түгел, бигрәк тә көчсез булуын сизеп, ниһаять, килеште.

Инде моны карчыкның үзенә җиткерергә кирәк иде. Кияү, билгеле, бу эштән читтә калырга теләде, чөнки ул, нинди генә якын кеше булмасын, карчыкның үз баласы түгел... Шуңа күрә улы белән кызы әйтергә тиеш булдылар: «Әсәй, җаным, – диделәр алар аңа иплән кенә,— докторлар сине бер атна-ун көнгә больницага салып торырга куштылар, анда дәвалап карамакчы булалар. Син борчылма бер дә, хәлең яхшыргач та, кире алып кайтырбыз үзеңне...»

Акъәби моның чын сәбәбен сизгәндерме, юктырмы, әмма «болнис» дигән сүз үзе генә дә аның котын алды. Тәмам куркып, рәнҗеп һәм ялварып ул: «Балакайларым, зинһар, кузгата күрмәгез, шушы җылы урынымда тыныч кына үлим, миңа берни дә кирәкми, вакытым җитте, аңлагыз шуны!» – диде.

Ләкин улы белән кызы, ташка әйләнеп булса да, аны үгетләп, юатып, хәтта азрак кына көчләп тә урыныннан кузгаттылар, киендереп чыгардылар һәм «Волга» машиналарына кырын яткырып, алдан кияве сөйләшеп куйган бер больницага илтеп салдылар.

...Өч тәүлек үтүгә, төнлә белән Акъәби шул больницада вафат та булды. Җан биргәндә, янында кеше булмаган. Берәүне дә борчымыйча, күбәләктәй тавыш-тынсыз гына киткән дә барган. Әйтерсең үзенең Юлкотлысына...

Иртән иртүк әбинең үлгәнен телефон аша кызына хәбәр иттеләр. Кызы белән кияве шунда ук машинага утырып больницага киттеләр. Алар килгәндә, Акъәбине үлекләр ята торган цемент идәнле таш бүлмәгә төшереп куйганнар иде инде. Тиздән улы Суфиян белән килене Мария Васильевна да килеп җиттеләр. Ак җәймә астында яткан әсәйләренең йөзен ачып карадылар. Йөзе бер дә бозылмаган иде, киресенчә, ничектер авыр газапларыннан котылып,

тынычланып калган кебек иде. Әмма күзләрендә ни торып калгандыр, анысын күрмәделәр — күзләрен кемнеңдер бармагы сак кына йомдырып куйган иде.

Аннары больница бакчасына чыгып, шунда гына карчыкны ничек итеп җирләү турында үзара киңәш корып алдылар. Мулла чакыру, җеназа укыту кебек нәрсәләрне эшләмәскә булдылар. Шулай да әсәйләренең Аллага ышанган карчык кеше булуын исәпкә алып һәм аның үзенең дә бик үтенеп соравын исләренә төшереп, гәүдәсен кәфенгә төреп күмәргә булдылар. Ләкин, гөнаһ шомлыгына каршы, больницадагы мәетне юып, киендереп озатучы марҗалар кәфен дигән нәрсәне бөтенләй белмиләр дә икән. Ә читтән кеше чакыртып, дини йолага бәйләнгән нәрсәләрне эшләтү монда рөхсәт ителми икән. Шулай итеп, чарасыздан, Акъәбине «заманча гына» әзерләргә мәҗбүр булдылар. Бер чиста күлмәген китереп өстенә кидерделәр, башына «мөселманча» итеп ак батист яулык бәйләделәр, шуннан соң гәүдәсен кечкенә кызыл табутка салдылар. Табут әйләнәсенә чәчәкләр тезделәр, күп итеп ислемай сиптеләр, һәм Акъәбиебез хәйран матураеп китте. Ул бичара, хәтта көлемсерәп яткандай күренә башлады.

Зиратка табутны машинага куеп илттеләр. Озата баручылар күп түгел иде; иң якыннары да аларның кайбер дус-ишләре һәм шулар арасында әлеге кечкенә буйлы шагыйрь дә бар иде. Ләкин ул бүген дә кызмача иде шикелле.

Табутны кабергә төшергәндә, кызы Гөлбикә бик каты елады, килене Мария Васильевна да елады, аның кызлары да «бабушкаларын» кызганып елашып алдылар. Ләкин ирләр түзделәр... Кияве, иреннәрен кысып, читкәрәк китте. Ә улы Суфиян, әсәен озату шәрәфенә, бөтен орден-медальләрен өр-яңа кителенә тагып килгән, башына соры папахасын сындырыбрак кигән полковник, кабер кырыенда таш сындай басып торды. Үлемне күп күргән, елауны күптән оныткан кеше булуына карамастан, аңа бу минутта яшьләрен йотып калу гаять авыр иде шикелле.

...Күмеп бетергәч тә, борылып китү ничектер кыен иде, шуңа күрә шагыйрь, ак балчык өеме янына басып, мәрхүмә турында берничә сүз әйтергә булды:

– Кадерле дуслар, без менә шушы биек тау башындагы, инде үләннәре дә корыган, чәчәкләре дә шиңгән җир куенына Акъәбиебезне бирдек, – диде ул, ашыкмыйча, салмак кына. – Ак күңелле, пакь күңелле әсәебездән мәңгегә аерылдык... Әйе, ул барыбызның да уртак әсәебез иде. Алай гына да түгел, мин, һич икеләнмичә, аны башкорт халкының изге җанлы анасы дияр идем... Әмма нәрсә беләбез без аның хакында?.. Күрә белдекме без аның шул изге җанын, пакь күңелен, ак уйларын!.. Менә сез, аның уллары, кызлары, кияүләре, нәрсә генә әйтә аласыз гомере буе сезнең өчен өзелеп яшәгән бичара әсәегез турында?.. Юк бит, әйтә алмыйсыз бит...

Шунда ук Суфиян кычкырып аның сүзен бүлде:

– Син ни сөйлисең, ә?! Ташла, кирәкми...

– Безобразие бу! – диде кияве дә, кызарып-бүртенеп.

Шагыйрь аларга һич игътибар итмичә тагын нидер әйтә башлаган иде, шул чакта кемдер аны беләгеннән эләктереп, кабердән җилтерәтеп читкә алып китте. Телгә батыр булса да, гәүдәгә бик җиңел иде шагыйрь...

Бу күңелсез тамаша аркасында озата килүчеләр яңа гына кабергә куелган Акъәбине ничектер онытып җибәрделәр. Берәүләр шагыйрьне тиргәргә тотындылар, икенчеләр, киресенчә, аңа әһәмият бирмәскә, сүзне уенга борырга тырыштылар. Һәм үзара сөйләшә-шаулаша кабер яныннан тарала да башладылар. Иң ахырдан кузгалган Гөлбикә зират капкасы төбендә утыручы карт-корыларның учларына тиз-тиз генә акча салып чыкты...

Киттеләр... Агыйдел, Дим буйларына караган биек тау башында Акъәби берүзе генә торды да калды.

Әмма ләкин Акъәби биек тау башындагы зиратта әнә шулай ялгызы гына торып калса да, үзенең фани дөнья белән аерылып бетмәвен тагын бер тапкыр балаларының исенә төшерде. Хикмәт шунда, кызы Гөлбикә Юлкотлыда карчык өен карап торучы әлеге күрше хатыны Гарифәгә кыска гына хат язып, әсәйләренең август ахырында вафат булуын хәбәр иткән иде. Озак та үтми, Гарифәдән дә Акъәбинең үлүенә бик хәсрәтләнеп, күрше-тирәнең аны бик кызганып елауларын әйтеп, инде бахырның өе ятим калды, аны нишләтергә уйлыйсыз, дип борчылып язган хат килә. Хат артыннан ук карчыкның колхоз машинасына салып җибәргән иске яшел сандыгы да килеп төшә. Күрәсең, яхшы күңелле Гарифә үзенчә бер изгелек эшләргә теләгәндер инде, ләкин монда ул сандыкны берәү дә әле көтми иде. Яңа гына кичергән кайгы-мәшәкать аркасында, гомумән, Юлкотлыда калган өй-нигез турында да, башкасы турында да уйлашырга өлгермәгәннәр иде. Инде менә әсәйләренең үзе белән бергә картайган, буявы да уңып беткән иске сандыгы: «Мин сезнеке, мине нишләтәсез?» —дигәндәй, Гөлбикә квартирына килде дә керде. Гөлбикәгә бу сандык бик таныш иде, кайчандыр аның шушы сандык өстендә курчак уйнаган чаклары да бар иде, кинәт күргәч, әллә нишләп китте, бер мәлгә аптырап-каушап калгандай булды. Аннары исенә килеп, тиз генә агасы Суфиянга шалтыратты. Шул ук көнне кичкә таба агасы белән җиңгәсе Мария Васильевна, зур уллары Геннадийны да ияртеп, аларга килеп тә җиттеләр.

Барысы да җыелып беткәч, сандыкны идән уртасына куеп ачтылар. Ачып җибәрүгә, алар өстә генә яткан ак бәз кәфенлекне күрделәр. Һәм, күреп, берәр сүз әйтү түгел, хәтта бер-берсенә күтәрелеп карарга да ничектер кыймадылар, тик ак материяне сак кына бер читкә алып

куйдылар. Аннары бөкләп салган кием-салымнарны чыгарырга тотындылар. Менә әсәйләренең тәңкәле кара җиләне, читләренә ука тоткан сары хәтфә камзулы, алтынга манган тәңкәләр һәм төрле ташлар тагылган бөяте (хәситәсе), вак мәрҗәннән эшләнгән кашмавы белән чәчкабы, беләзек, муенса, чулпылары, кыз чагында үз кулы белән чүпләп суккан кызыл башлы сөлгеләре килеп чыкты. Шулай ук аталарының кызыл сәдәпле кара кәзәкие белән камчат бүреге дә килеп чыкты – карчык шушы көнгә кадәр аларны да саклап торган икән, бичара!.. Актарына торгач, тагын бер хикмәтле әйбер табылды: бу аталарының яшь чагында тотып йөргән кыска саплы, күн чуклы, өч җәпле, һәр җәбенең очына көмеш пластинка бөкләп кидерелгән бик шәп камчысы иде.

Хикмәтле камчы шунда ук барысын да бик кызыксындырды.

– Һай, атаемның төлке куганда тотып чапкан камчысы бит бу! – дип кычкырып ук җибәрде Суфиян һәм элмәгеннән киеп селтәнеп тә, бот буена сугып та карады.

– Да-а, менә бу, ичмасам, реликвия! – диде кияве дә, сокланып. – Тик кем саклар аны?

– Ә аның хуҗасы бар, – диде Суфиян, катгый рәвештә, һәм улы Геннадийга борылып, тантаналы итеп әйтте: – Мә, улым, Гена, ал бабаңнан калган чуклы камчыны... Белеп тот, Шәяхметовлар кулында йөргән камчы булыр бу!..

Һәм Геннадий Шәяхметов баш кагып, елмаеп кына өч җәпле камчыны кулына алды.

...Инде калган әйберләрне нишләтү, ничек бүлешү мәсьәләсе кузгалды. Белгәнебезчә, әсәйләренең бу хактагы теләген алар тыңламыйча калдылар. Шулай да һәркайсы үзенә ошаган нәрсәне алырга хаклы иде. Ләкин бу тәңкәле җилән, хәтфә камзул, бөят, кашмау, чәчкаплар белән алар нишләрләр икән?.. Төс итеп кенә саклаудан башкага ярамый инде боларның берсе дә, аунап йөри торгач, череп-тузып кына бетәрләр... Шул чакта кияүләренең башына бик шәп бер идея килде. Ул болай диде:

– Менә нәрсә, Гөлбикә, каенагай! Без бу әйберләрне бүлешеп, әрәм-шәрәм итеп бетермик. Барыбер файдаланып булмаячак бит!.. Без лучше тотыйк та бөтенесен театр гардеробына тапшырыйк. Анда мондый нәрсәләрне саклый беләләр, борынгы тормышны уйнап күрсәткәндә, киеп файдаланырлар, ә безнең тарафтан театрга бу бик әйбәт бер бүләк булыр. Чын, уйлагыз әле!

Бу фикергә шунда ук Мария Васильевна да кушылды:

– Бик дөрес әйтәсез, Сәхип Карамович, безгә нигә алар, артистлар кисеннәр.

Ләкин Суфиянга да, Гөлбикәгә дә мондый тәкъдим белән тиз генә килешүе авыррак иде. Ничектер күңелләре тартып бетерми иде. Әллә ничек менә әсәйләреннән яхшы түгел кебек –

алар өчен саклаган, аларга дип калдырып киткән бит әле ул... Инде тот та бөтенесен кочагы белән театрга илтеп ташла! Килешерме, оят булмасмы?

Шул ук вакытта кияүләренең сүзендә дә дөреслек бар: бүлешеп алсалар, әрәм-шәрәм булып кына бетәчәк, нишлисең, тәңкәле җиләннәр, укалы камзуллар заманы үтте шул инде!.. Ахырда, уйлаша торгач, башта Суфиян, аннары Гөлбикә дә яшел сандыктан чыккан бөтен кием-салымны театрга илтеп тапшырырга риза булдылар. Гөлбикә шулай да әсәенең төсе итеп, уртасына кызыл якут куеп, саф көмештән челтәрләп эшләнгән ике зур чулпыны үзенә алып калды.

Көннәр уздылар. Хәсрәт иртәнге томандай бик тиз таралды. Эш, мәшәкать белән тулы иркен, мул тормыш үзенең иске эзеннән ашыгып һаман алга таба тәгәрәде. Акъәбинең балалары өчен бу кызу чапкан тормыш бик тансык та һәм бик мавыктыргыч та иде.

Дала буйлап кылганнар йөгерә, кылганнар йөгерә... Куыша-куыша йөгергән кылганнар арасыннан, озын карагай таягын җир үлчәгәндәй алга ташлап, Миңлебай карт кайтып килә. Ыштан балагын эчкә тыгып кигән ак оекбашларына чәчәк тузаны кунып, билчән уралып, бакра сырышып беткән, әйтерсең Юлкотлы яланнарын үзе белән ияртеп кайта ул...

Авылга кереп, Акъәбинең тәрәзәләре кагылган өе янына җиткәч, карт күрше Гарифәдән гел кычкырып сорап уза:

– Аккилен кайтмадымы әле?

Гарифә ни дип җавап бирергә дә белми – ул бит инде аңа былтыр ук берничә мәртәбә Акъәбинең калада вафат булуын әйткән иде. «Балалар акылы керә башлаган, ахрысы, бу картка», – дип уйлый ул эченнән генә һәм, аптырагач, ачулана биреп әйтә:

– Куй, Миңлебай бабай, үлгән кеше кайтамыни, ничек телең барып сорый.

Ләкин карт аның сүзләрен гүя колагына да элми.

– Алдама, – ди ул, таягының башын селкеп. – Аккилен үлмәде ул, китте генә... Китте генә... Кайтыр, насыйп булса, кайтыр... Ә син учагын карый тор, учагын... Учагында ут сүнмәсен.

Һич аңламассың, әллә чынлап, әллә үчекләп, әллә саташып әйтә бу бернигә исе китми торган, әҗәлгә дә күптән кулын селтәгән, ялан таптаучы йөзьяшәр Миңлебай карт!

*1965*

**Бала**

*Сөекле кызым Резедага*

*багышлыйм*

Лейтенант Иванов ротасы урман эче буйлап зур саклык белән алгы позициягә таба китеп бара. Дошман самолеты күренә калса, тизрәк агачлар арасына яшеренергә уңай булсын дип, кызылармеецлар юлның ике ягыннан пар-пар тезелешеп баралар.

Юл ат, арба, машина эзләре белән тулы. Җәяүлеләр дә күп үткән булса кирәк: дымлы комда солдат итекләреннән, хатын-кыз ботинкаларыннан калган эзләр дә ярылып ята. Бу юл – бүгенге мәхшәрнең бердәнбер телсез шаһиты. Ике туганның бер үк эзгә басканын бары ул гына белә. Ә шулай да ул бу сәгатьтә нинди мәкерле тыныч һәм нинди буш.

Урман, үз-үзен тыңлагандай, хәрәкәтсез һәм тып-тын. Кояш чыккан вакыт. Мәһабәт төз наратларның очлары җылы нурга манчылып, рәхәт бер талгынлыкка бирелгәндәй, шылт та итмичә, тик кенә торалар... Берәм-сәрәм очраган усакларның көмеш яфраклары, таң сулышыннан уянышып, сөенә-сөенә уйнаган шикелле, җилфердәшәләр... Ачык урыннарда, җиргә таба сыгыла төшеп, хәрәкәтсез ак томан ята. Үлән эченнән узсаң, шунда ук итекләрнең йөзләре ялтырап чыга һәм эзләр, яшькелт-кара тасмадай, артта сузылып кала. Үсемлекләрнең исле пары борынны кытыклый һәм үпкәләргә сыланган кебек була. Озак килүгә дә, йөкнең авырлыгына да карамастан, тән ниндидер бер җиңеллек, күңел исә шул җиңеллектән гамьсез бер рәхәтлек тоя...

Ротаның арткы рәтендә кызылармеец Зариф, алдан баручы иптәшләренең тигез генә тирбәлгән аркаларына карап, салмак кына атлап бара. Аның йөзендә тыныч ваемсызлык. Бары тик кысыла төшкән күзләре генә аның эчке уйларына йотылып баруын күрсәтә.

Бу иртәнең җылы тынлыгы, урманның өлкән гамьсезлеге каядыр якында гына мәрхәмәтсез сугыш, кан һәм үлем барлыгын онытып торырга мәҗбүр итә, гүя сөттәй ак томан ул дәһшәтләрне үз эченә яшерә һәм кешедән ераклаштыра. Бу тыныч һәм сөенечле хисләр белән сулый торган табигатьтә кеше ничектер, үзе дә теләмәстән, алданучан була.

Чыннан да, Зариф кая барганын һич онытмаса да, хәзерге минутта иң гади, шул ук вакытта күңеленең һәркайчан сагынып теләгән уйларына йотылган иде: менә киң кырлары, зәңгәр урманнары белән гел хыялында яшәгән туган иле, һәр читән казыгына кадәр таныш авылы, сәке йөзлегендәге киртләчләренә кадәр күзе алдыннан китми торган өе, исенә төшергән саен тавышы ишетелгәндәй тоелган хатыны, ниндидер сөйкемле гадәтләре белән йөрәгендә сакланган баласы... Урам күпере... басу юлы... иген кыры... Тулы, тыгыз башакларын күтәрә алмыйча җиргә иелгән бодайлар... Быел нинди мул уңыш иде!.. Хәзер инде көн-төн ашлык сугалардыр.

Менә Зарифның колагына кайдадыр якында гына ашлык суккыч машинаның гөрләве, эре көлтәләрне тартып алып йоткан чакта үкереп куюы ишетелгән кебек булды.

Ул: «Кайда сугалар икән?» – дип уйларга өлгерә алмады, командирның:

– Һава! – дип кычкырганы ишетелде. Рота минут эчендә юлның ике ягына, агачлар арасына яшеренде.

– Менә сиңа молотилка! – диде Зариф, бер агач төбенә ятып, һәм алдануына башын селкеп куйды.

Самолет ераклашты. Лейтенант команда бирде булса кирәк, алда яткан кызылармеецлар ашыгып тора башладылар. Зариф та урыныннан кузгалды. Ләкин ул бер адым да атларга өлгермәде, үзеннән биш-алты метр гына читтә өч-дүрт яшьлек кыз баланың басып торганын күреп, ихтыярсыз тукталды. Баланың берәр якын кешесен күрергә теләп, тирә-ягына каранды, ләкин якында һичкем барлыгы сизелми иде. Зариф бик гаҗәпләнеп янә балага карады; бала чыннан да ялгыз иде. Ул үзе биеклек кенә бер куак янына баскан, кечкенә кулына берничә бөртек каен җиләге учлаган, шуны кабарга хәзерләнгән җиреннән туктап, зур соры күзләре белән Зарифка исе китеп карап тора. Озак елаудан аның күз төпләре шешенгән, түгәрәк битендә яшь юллары калган... Ләкин хәзер тынычланган, нинди хәлдә булуын оныткан, ахрысы – аяк астындагы җиләкләрне җыярга керешкән. Аның өстендә зәңгәр сукнодан җәйге пальто, башында фетрдан тегелгән кара шапочка, аны кызыл тасма белән ияк астыннан китереп бәйләгән; аякларында озын сары оеклар белән сары ботинкалар һәм бер аягында галошы бар, икенчесен төшереп калдырган, ахрысы.

Зариф бу баланың дошман явыннан качып баручылардан югалып торып калганын бик тиз төшенә, һәм аңарда кузгалган беренче теләк – баланы тизрәк күтәреп аласы килү булды. Шул ук вакытта ул ротадан аерылып калырга һич ярамаганлыгын да уйлап алды. Беренче хәрәкәте аның ротасы артыннан китү өчен юлга таба борылу булды. Ләкин ул, бер адым да атламастан, кинәт балага таба кире борылды, ашыгып аның янына барды да җитез генә күтәреп алды.

Бала куркуыннан:

– Әни! – дип кычкырып җибәрде һәм, җиләген йомарлаган кулы белән Зарифның битеннән этәреп, аякларын селкеп еларга кереште.

Зариф, баланы кысып тоткан килеш, аяк астында аунаган чыбыкларга, агач төпләренә абынмас өчен сикерә-атлый, ашыгып юлга чыкты. Шундый кыска вакыт үтүгә карамастан, рота шактый ераклашкан иде инде. Зариф, сыңар кулы белән иңендәге мылтыгын уңайлый төшеп, кызу-кызу атлый башлады.

Бала елап арыган, күрәсең; тиз арада аның елавы тавышсыз үксүгә әйләнде. Зариф кесәсеннән бер шикәр кисәге чыгарып, тузанын өргәләп, балага тоттырды. Бала башта башын

селкегән булды, аннары шикләнеп кенә буш кулы белән шикәрне алды һәм йомарлап күкрәгенә кысты.

Зариф йомшак тавыш белән:

– Аша, аша! – диде һәм баланың аркасыннан сыйпап, сөеп куйды. Балага шул җитә калды: ул үксүеннән туктады, тынычланган кебек булды һәм, Зарифның кулында акрын гына селкенеп, тирә-ягына каранып бара башлады. Зариф баланың юка киеме аша йомшак тәнен, җылысын, тәмле исен тоя иде. Ниндидер бер ләззәтле сагыну белән шул йомшак тәнне, шул тәмле бала исен тагы да ныграк тоярга, ничектер үзенә сеңдерергә теләгәндәй, ул баланы акрын гына кыса, аркасыннан сыйпый... Һәм аның йөрәге төбеннән әйтеп биреп булмый торган сөенечле бер ярату хисе җылы дулкын булып күтәрелә бара иде. Зарифның да бит өч яшьлек Фәридәсе бар. Зариф та бит әти, һәм, бәлки, шушы минутта ул үз баласы белән бу бала арасында аерма тоймыйдыр, киресенчә, бу балага биргән мәхәббәтен һәм назын үз Фәридәсенә биргән кебек тоядыр. Ул, баланың йомарлаган кулын тотып, кипкән иреннәренә тидереп алды. Акрын, назлы гына:

– Әтиең, әниең бармы? – дип сорады, һәм аның тамак төбе кытыкланып, күзләре дымланып китте.

Бала ачык тавыш белән җавап кайтарды:

– Әнием дә бар, әтием дә бар... безнең әле тагын кәҗәбез дә бар. Бәтиләре ап-ак.

Зариф елмаеп, балага күтәрелеп карады:

– Шулаймыни? Кара син, ап-аклар икән... Ә әтиең кайда соң?

– Китте.

– Кая китте?

– Белмисеңмени? Фронтка, – диде бала һәм аз гына тынып торганнан соң исенә төшкәндәй, – ул лейтенант,—дип куйды.

– Шулаймыни? Менә син нинди акыллы, әтиеңнең кем икәнен дә беләсең. Ә...

– Зариф кинәт сүзен бүлде. Ул: «Әниең кайда?»—дип сорамакчы булган иде, ләкин баланың исенә төшермәс өчен, тыелып калды.

Бала Зарифка тәмам ияләшеп өлгерде, күрәсең. Ул, тарсынмыйча, әүвәл бер кулындагы ике бөртек җиләген капты, соңра икенче кулындагы шикәрен суыра башлады.

Кинәт бөтен урман эчен дәһшәтле гөрселдәү каплап алды. Җир буйлап тетрәү йөгерде һәм һава дулкыныннан агачларның башлары селкенешеп куйдылар. Кайдадыр якында гына артиллерия атышы башланды. Зариф та, бала да бераз вакытка сүзсез калдылар. Ниндидер бер шомлы тынлык аларның эчләренә урнашкан кебек булды... Бала куркуыннан акрын гына

калтырана башлады. Зариф аны үзенә кыса төште, һәм аңа икесенең дә йөрәкләре бергә типкән кебек тоелды.

Бераздан, бала елаган тавыш белән:

– Әни! – дип куйды.

Зариф акрын, сабыр тавыш белән:

– Елама, кызым, хәзер әниең янына барып җитәбез,—диде һәм үз тавышы үзенә баз эченнән килгәндәй тонык, саңгырау булып ишетелде.

Бала, Зарифка сыена төшеп, бер кулы белән аның муеныннан урап алды. Зариф, белмим баланы юатыр өчен, белмим үзенең эчке бер уеннан:

– Без кая барабыз? – дип сорап куйды.

– Әбиләргә кунакка, – диде бала җитди генә.

Зариф ихтыярсыз елмайды.

Шул арада алар юлның икегә аерылган җиренә килеп җиттеләр. Уңга аерылган юл белән рота китеп бара, сулдагысы исә якындагы станциягә илтергә тиеш. Биек һәм сирәк үскән наратлар арасыннан станция янындагы йортларның түбәләре дә күренә иде... Зариф хәзер чыннан да аптырашта калды. Нишләргә? Дөресен әйткәндә, ул һич туктамастан ротасын куып җитәргә тиеш. Ләкин кулында сыенып утырган бала аны ике юл чатында тукталырга мәҗбүр итте. Баланы ут эченә кадәр алып барырга мөмкин түгел. Ул соңгы өмет белән, хәтта чакырып, тирә-ягына каранды. Ләкин һичберкемнең килгәне яки китеп барганы күренми иде. Берничә секунд ул бөтен акылын җигеп уйланды. Хәтере ялгышмаса, аңа рота китеп барган юлдан бер тапкыр үтәргә дә туры килгән иде, һәм бу юл будка яныннан тимер юлны кисеп үтәргә тиеш кебек иде. Ул станция белән будка арасын эченнән исәпләп алды һәм балага күтәрелеп карады. Бала, Зарифның нәрсә уйлаганын сизенгән шикелле, зур булып ачылган күзләре белән аңа бик җитди карап тора. Бу караш Зарифның икеләнүен өзде; ул үз-үзенә катгый рәвештә: «Өлгерермен!» – диде һәм, баланы кулында ипли төшеп, йөгерә-йөгерә станциягә таба китеп барды.

Менә станциянең платформасы күренде. Аның алдында кызыл эшелон тора, ул хәзер кузгала булса кирәк —кешеләрнең ашыгып вагоннарга менүләре күренә.

Зариф станциягә килеп җитте, йөгереп платформага чыкты һәм тирә-ягына карарга өлгерә алмады, кара киемле ябык бер рус хатыны:

– Балам! – дип кычкырып, Зарифка ташланды.

Бала:

– Әнием! – дип, бөтен гәүдәсе белән хатынга сузылды, һәм Зариф баланың үз кулыннан киткәнен сизми дә калды.

Төнлә белән олы юлны немец бомбага тоткан вакытта баласын югалтып, соңыннан аны эзләп-эзләп тә таба алмаган ананың шушы минуттагы хәлен аңлатып бирү мөмкин булмас иде. Ул йөрәгенә сыеша алмаган шатлыгыннан сүзсез, бары ыңгырашып баласының кулларыннан, битеннән, чәченнән, күзләреннән үбәргә кереште.

Баланың кулыннан шикәре төшеп китте. Кемнәрдер алар янына җыела башлады.

Зариф баланы тапшыруга тирән итеп бер сулады, тирдән елтыраган маңгаен кулының сырты белән сыпырып куйды һәм ана белән баланың кавышу күренешенә бары соклану тулы караш кына ташлый алды. Бәлкем, шул секундта аның ана белән балага назлау сүзе әйтәсе, үзе-нең исә мактау һәм рәхмәт сүзе ишетәсе килгәндер. Ләкин ана беренче тетрәнүеннән айнырга өлгермәс борын ук, Зариф тимер юл буйлап йөгерә-йөгерә китеп тә барды.

Хатын, баласын күтәргән килеш, аның артыннан омтылып нәрсәдер кычкырды. Зариф артына карап бары кулын гына селкеде. Хәзер аның башында бер генә уй иде: ничек итеп ротаны тизрәк куып җитәргә, ничек итеп командиры алдына барып басарга һәм нәрсә дип әйтергә?

Менә алда тимер юл аша үтеп барган рота күренде. Зариф, мылтыгын иңеннән кулына алып, тагы да кызурак йөгерә башлады. Бәхеткә каршы, рота тимер юлдан ерак түгел бер агачлык ышыгына барып туктаган иде.

Ниһаять, Зариф килеп җитте. Аз гына читтәрәк папирос тартып торган, озын буйлы, чандыр гәүдәле командиры алдына барып басты, һәм кулын чигәсенә куеп:

– Иптәш лейтенант!.. – диде дә, тынын ала алмыйча, туктап калды.

Командир, Зарифның тирләп кызарган йөзенә текәлеп карап:

– Иң элек тынычланыгыз! – диде.

Бу сабыр тавыш Зарифны чынлап та тынычландырган кебек булды. Ул тирән генә итеп бер сулап алганнан соң, сүзләрен артык бутамыйча, кайда һәм ни өчен юк булып торуын әйтеп бирде.

Командир шактый дәшми торды. Зариф менә хәзер каты шелтә алам дип селкенергә дә куркып тора иде. Ниһаять, командир, папиросын җиргә ташлап, итегенең очы белән аны озак кына изгәләде, аннан акрын тавыш белән сорап куйды:

– Баланы кемгә тапшырдыгыз?

– Әнисенә...

Шул минутта ротадан бер-ике йөз метр уңга, агачлар арасына, снаряд төшеп шартлады. Һавага төтен, туфрак, агач ботаклары күтәрелде. Командир икенче папирос чыгарып ашыкмыйча гына кабызды, соңра алдында һич кузгалмыйча басып торган Зарифка:

– Сез зур изгелек эшләгәнсез, – диде. – Моның өчен мин сезгә рәхмәт белдерәм!

Зариф гаҗәпләнүдән күзләрен йомгалап алды. Командир моны күрде булса кирәк, аның җитди чырае, таң шәүләсе төшкәндәй, яктырып, йомшарып киткән кебек булды.

– Мин әйткәнне аңладыгызмы?

Зариф, дулкынлануыннан иреннәрен кысып, башын гына селекте.

– Инде хәзер урыныгызга барыгыз! Ярты сәгатьтән соң рота, агачлыкны үтеп, ачык җиргә чыкты һәм, цепька таралып, алдагы ут позициясенә таба юнәлде.

Бу – чын сугыш кыры иде. Биредә үлем никадәр әрсез, рәхимсез булса, тереклек шулкадәр үз-үзенә ышанучан, бирешмәс, мәгърур була белә. Биредә кеше бер алмаз бөртегенә әйләнә. Ул, күзгә күренмәс дәрәҗәдә кечкенә булуына карамастан, олы алмазның бөтен сыйфатларын үзендә саклый. Ул каты... Һәм ул нурлар чагылдыра.

Зариф снаряд шартлавыннан йөгергән һава дулкынының йөзенә бәрелүен сизә. Ул колагы төбеннән чинап, сызгырып үткән һәр пуля турында уйлана; гүя, ул пуля тисә, бары тик чеметеп кенә алыр кебек.

Чыннан да, Зариф, беренче мәртәбә сугышка керүенә карамастан, үзендә аңлавы читен булган бер тынычлык тоя иде. Күңелендә аның кояшлы иртә тынычлыгы, хыялы исә шул иртәнең нурлы матурлыгы белән тулы. Менә ул ирексездән муенын сыпырып куйды. Гүя шунда баланың кул җылысы йогып калган иде.

*1941*

### Ана һәм кыз

Җәй башының шифалы яңгыры, тузанлы юллар өстеннән тыпырдап, җитез генә явып үтте... Иртәнге яшь кояш та таулар шикелле күкнең түренә сузылган кара-зәңгәр болытлар өстеннән ялтырап килеп чыкты. Аның яктылыгы шундый мул, нурларының түгелүе шундый дәртле, җитез иде, хәтта кояш үзе дә бу юмартлыгыннан тынычлыгын җуеп, урынында тик тора алмыйча тибрәнә һәм бер кечерәйгәндәй, бер зурайгандай булып күренә иде. Аның әйләнәсендәге аксыл якты күк, алтын тузанында аунаган үтә күренмәле юка ефәкне кемнәрдер йөгерә-йөгерә җәйгән шикелле, һаман ачыла бара, һәм ераклашкан болытларның күкрәве аның өстен сыйпап, тигезләп үткәндәй тоела иде... Яңгырның соңгы тамчылары җиргә төшеп бетәргә өлгермәс борын, салават күпере дә калыкты. Аның бер башы тау итәгендәге сыек ак томанга

төренгән иген кырына терәлгән, икенче башы, киң тугай аша дугаланып, Сакмар өстенә төшкән иде.

Рәхилә, ашыкмыйча гына килеп, урамга караган кечкенә тәрәзәне ачты. Өйнең бүрәнәләренә терәлеп үскән миләш агачының яфракларыннан берничә эре тамчы тәрәзә төбендәге гөлләр өстенә коелды. Бәбкә үләннәре өстендәге, энҗе бөртекләре шикелле, нур чәчрәтеп уйнаган тамчыларның яктылыгы, яңгыр исе белән аралашып, өй эченә иңгәндәй булды... Кинәт кергән һавадан өй түрендәге агач караватның ак чыбылдыгы җилфердәп куйды һәм аның эченнән хәлсез бер тавыш ишетелде:

– Кызым...

Рәхилә, тәрәзәдән борылып, агач караватянына килде һәм акрын тавыш белән:

– Нәрсә, әни? – диде.

– Чыбылдыкны күтәр... Менә шулай...

Чыбылдык эчендә, ике мендәр өстендә, үтә ябык авыру ана ята.

Ул кансыз юка иреннәре белән көчәнеп елмаерга тырышты, яртылаш ачык күзләрендә, әйтерсең кояшның бер бөртек нуры төште, аз гына җылылык белән елтыраган кебек булдылар. Ул, көрсенеп:

– Менә Алланың рәхмәтле яңгыры, – диде, һәм аның авыру күкрәгеннән сәламәт вакытындагы тавышы чыгып куйды.

Ана күптәннән каты авыру һәм ул бу урынга инде яңадан тормаска ятканлыгын яхшы белә. Ләкин тыныч җан белән үлемне көткән бу авыру анада соңгы сулышыннан аерылу минутын кичектерү теләге бик көчле: ул улын көтә. Бердәнбер улының фронттан кайтуын, менә шул кечкенә ишектән иелә төшеп керүен, елмаеп янына килүен, «Әни!» дип дәшүен күрергә тели иде. Бу гади сагыну гына түгел, бу – үзеннән соң каласы тормышның дәвамын күрергә тырышу, һәр тамчы каны белән йөрәге аша үткән ана мәхәббәтен соңгы тапкыр актыгына кадәр улына бирү теләге иде. Ул белә: ана белән ир бала арасындагы мәхәббәт бервакытта да андый ачыклык һәм юмартлык белән тышка чыга алмый. Әгәр менә ир булып җитешкән улы һәрвакыттагыча буйсынып башын игән, тартынып сүзсез торган оялчан кыяфәте белән каршында басып торса, ул бары бер сүз – «балам» дип үрелеп, аның маңгаеннан үбәр иде...

Ананың күңеленә шик киләме?.. Каты сугышның күп корбаннар алуын, кемнәрнеңдер газиз уллары, сөйгән ирләре, кадерле якыннары сугыш кырында торып калуын ул белә. Ләкин аңарда улын күрү ышанычы шундый көчле ки, һичбер нинди шик аның күңеленә кереп урын ала алмый иде. Гүя аның улы нинди генә хәтәр хәлләрдә калмасын, күпме генә ут эчендә

йөрмәсен, барыбер исән-сау кайтачак. Бу – шулай, бу – көннең якты, төннең караңгы булуы кебек бәхәссез... Һичшиксез, аның газизе кайтыр, кайтырга тиеш!

Андагы бу ышаныч аның якыннарына да күчкән иде. Кызы Рәхилә, туганы белән төрле хәл булуын исендә тотса да, күңеле төбендә шактый тынычлык тоя. Бигрәк тә ана белән һәр көн туганы турында сөйләшү аның исән-сау кайтуын ничектер уйланусыз, пошынусыз көтәргә гадәтләндерде. Гүя ул фронттан, ут эченнән түгел, ә елдагы гадәте буенча күрше шәһәрдән, институттан каникулга кайтырга тиеш. Шулай да Рәхилә, уйланган минутларында бу гамьсезлекне сизеп, үз-үзеннән риза булмыйча, ихтыярсыздан тынычсызлана башлый иде.

Бүген июньнең егерме сигезенче көне... Туганы аның һәр елны шушы числоларда яки июль башларында институттан кайта торган иде. Әнисенең, туганнарының сөеп, сокланып карауларына каршы ул һаман бер сүз белән,—гүя аңардан шуны гына сорыйлар, – җавап кайтара иде:

– Әни, зачетларымны башкалардан элек биреп бетердем, сезнең янга кайтырга ашыктым.

Былтыр исә ул институтны тәмам бетереп кайтырга тиеш иде. Ләкин өйгә, туганнары янына шундый зур шатлыкның бәйрәмен бергәләп үткәрер өчен кайтасы вакытта, фронтка китеп барды. Ә өйдә аның бу кайтуын көтү әле һаман аларның йөрәкләрендә саклана. Һәрхәлдә, ана бүген, моны исенә төшереп, сүз кузгатмыйча калмас.

Кечкенә өй эче яңгыр белән юылып яшәргән көннең җылы яктылыгыннан киңәйгән кебек... Миләш агачының яфраклары аша төшкән кояш нурлары, өйнең идән-стеналарын эре-эре челтәрле бизәкләр белән чуарлап, тибрәнеп уйныйлар. Өстәлдәге графинның түгәрәк бөкесе, ачык шкафның тар шүрлегендәге киртләчләренә кыстырган балкашык башлары бу шаян, йөгерешкән нурларны үзләренә җыялар, һәм үзләре дә кечкенә кояшчык шикелле тирә-юньнәренә күз камаштыргыч яктылык чәчеп балкыйлар... Куе-җиңел, хуш исле һава, өй эченә берьюлы мул булып керергә теләгәндәй, тәрәзәнең читләренә җыелган ак пәрдәне күтәреп-күтәреп куя һәм һәрнәрсәне иркәләп, сыйпап йөргән кебек тоела.

Ананың бүген кәефе яхшы. Бу шифалы һаваны сулавы аңа җиңел, рәхәт; зәгыйфь тәнендә, никадәр хәлсезләнгәнен сиздереп, ниндидер бер җылымса талгынлык йөри.

Рәхилә, кул эшен алып, тәрәзә янына утырды. Ул авыру анасы белән үзе башлап сөйләшүдән тыела. Ул шулай әнисеннән читтәрәк, аерым бер нәрсә турында да артык уйланмыйча, сүзсез утырырга гадәтләнгән иде. Аның уйлары, аяз күктә өзек-өзек аккан вак болытлар шикелле, акрын, сиздермичә, шәүләсез агалар.

Өй эчендә нурлы тынлык... Ачык тәрәзәдән батыр шаулап зур кара корт килеп керде. Өй эче бер минутка аның көчле бызылдавы белән тулды. Ләкин кортка урын тар, кызыксыз күренде

булса кирәк, өй эчен бер әйләнде дә кире ачык, иркен һавага чыгып очты. Өйдә янә тынлык урнашты.

Ниһаять, ана башлап дәште:

– Кызым!

– Нәрсә, әни?

– Хәсәнемнең соңгы хаты килгәнгә күпме булды инде?

Рәхилә аз гына уйланды:

– Хәзер, әни... Унында алган идек... ике атна тулып узды.

Ана көрсенеп куйды:

– Озак... нигә язмый икән?

– Ул яза булыр, тик хәзер бит почта озак йөри.

Ана дәшмәде. Ул сәламәт вакытындагыча айнык тере булып ачылган күзләре белән көн яктысына карап ята. Тәрәзәдән төшкән яктылыктан аеруча сары булып күренгән йөзендә анның җитди тынычлык һәм нәрсәдер хакында уйлануы сизелә. Гүя кәефе яхшы, акылы ачык вакытта таркау уйларын җыярга, әйтәсе сүзләрен хәтеренә төшерергә тырыша.

Менә ул кызына текәлеп карап алды һәм янә сабыр гына сүз башлады:

– Кызым, сиңа сүзем бар.

– Тыңлыйм, әни...

– Хәсәнемне күргәч, мин күп тормам.

– Әни, нигә алай дисең?.. Хәсән кайтуга син терелерсең...

– Юк, кызым... Хәсәнем кайтканчы торсам, бик шөкер инде. Тик менә куанычымнан әйтәсе сүзләремне онытырмын дип куркам.

– Әни, ул кайткач, без бергә-бергә бик озак торырбыз әле.

Ана хәлсез-ялкау гына елмаеп куйды. Бу елмаюда гүя яшь баланың уйланмыйча сөйләнүенә соклану һәм ул сүзләрнең чынлыктан никадәр ерак икәнен ачык белү сизелә иде. Ләкин кызының ихлас күңелдән юатуы аңа ошады булса кирәк – ул, җиңел генә көрсенеп:

– Кем белә, Ходай кушып, бәлкем, терелеп тә куярмын әле, – диде. – Шулай да, кызым, исемә төшкәндә кайбер сүзләремне әйтеп каласым килә.

– Тыңлыйм, әни.

Ана бер генә секунд дәшми торды. Кипкән иреннәре өстеннән теленең очын йөртеп алды. Соңра акрын гына, сүз араларында кыска-кыска гына тыныш ясап, сөйләргә керешә:

– Алты кыз баладан соң мин бер ир бала күрдем... Ул бик яшь иде әле, без өй эчебез белән ятим калдык. Әтиең, мәрхүм, аны күз алмасы кебек саклап үстерергә васыять әйтеп

калдырды. Менә без аны барыбыз да бергәләп үстердек... Тәрбияләдек... Укыттык. Син, ул укысын, кеше булсын дип, йортның бөтен мәшәкатен үз өстеңә алдың, мине карар өчен шушы яшеңә кадәр иргә чыкмый тордың... Инде минем беренче васыятем шул, кызым: Хәсән балам бервакытта да апаларын-сеңелләрен онытмасын, мине якын күргән кебек, аларны якын итсен... Кулыннан килгән ярдәменнән ташламасын. Бигрәк тә сине туган анасы кебек күрсен, синең күрсәткән хезмәтләреңне бервакытта да онытмасын...

– Хәсән туган җанлы бала, әни... Ул тарафтан тыныч бул. Үзең беләсең, ул безнең өчен үлеп тора иде бит.

– Әйе, Хәсәнем әтисе мәрхүмгә охшаган. Әтиең мәрхүм бик ипле, бик йомшак күңелле кеше иде. Бервакытта да беркемгә дә авыр сүз әйтмәде. Беркем белән дә сүзгә килеп, бозылышып тормады. Әйтәсе юк, мәрхүм бик сабыр холыклы, чыдам кеше иде... Хәсәнемнең әле үз башына дөнья көтә башлаганы юк. Менә исән-сау кайтыр... эшли башлар...

Шушы минутта Рәхилә почта таратучы Маһирәнең тәрәзә каршысыннан үткәнен күреп калды. Әнисенең нәрсә сөйләгәнен онытып, үз-үзенә һич исәп бирмәстән, урыныннан торып, ашыга-ашыга ишеккә таба юнәлде. Гадәттә, тирләгән сипкел битле Маһирә, бу йортта бик көтелгән, килгән саен бик якты йөз белән каршы алынган кеше булганга күрә, туп-туры өйгә кереп, кычкырып исәнләшә һәм:

– Менә, Хәмидә җиңги, улыңның үз кулыннан алып китердем, – дип, алып килгән хатын ананың күкрәге өстенә куя иде.

Аның һәр килүе бу сагышлы моңсуга, авыру тынлыкка төренгән кечкенә өй өчен чын бәйрәм була иде. Һәм Рәхилә, Маһирәнең килгәнен күреп, бервакытта да каршы чыкмый, алдан ук дусларча елмаю белән, ишектән күзләрен алмыйча, кергәнен көтеп тора иде.

Бүген ул ни өчендер каршы чыкты.

Капкадан кереп өлгергән Маһирә Рәхиләне күрү белән:

– Әһә, Рәхилә апа, күңеле сизеп, көтеп торган икән,—дип, көр тавыш белән кычкырып куйды. Иске күн букчасыннан бер бәйләм хатлар чыгарды һәм алдан ук билгеләп куйган бер ак конвертны җитез генә алып Рәхиләгә суздың.

Рәхилә ак конвертны кулына алды, ләкин шунда ук кире бирәсе килеп куйды. Адресны язган кул һич таныш түгел һәм конверт бик юка иде. Ләкин шик юк: конверт аның исеменә иде. Ул, эчендә хаты барын белергә теләгәндәй, бармаклары белән капшап карады. Соңра ниндидер бер шомлы шикләнү белән ашыгып конвертны ачты. Конверт эченнән урталай бөкләгән кечкенә саргылт кәгазь чыкты. Аның сул почмагында бик үк ачык төшмәгән штамп иде.

Рәхилә бик тизлек белән – хәтта шундый тизлек белән, әйтерсең йөрәге тибүеннән туктап тора иде – кәгазьне укырга кереште:

«...нчы танковый полк штабы шушының белән сезгә хәбәр итә ки, танк йөртүче сержант Хәсән Гыйльметдин улы Ишаев 1942 елның бишенче июнендә Ватаныбыз өчен немец-фашистларга каршы каты сугышта батырларча һәлак булды. Күмелгән урыны Курск өлкәсе, Рельски районы Костровка авылы янында, туганнар каберендә...»

Рәхилә кәгазьне ахырына кадәр укый алмады, каты итеп сул кулына йомарлады һәм, кинәт кенә борылып, өй ишегенә таба китте. Куанычлы хәбәр килү шатлыгын уртаклашуны көтеп торган Маһирә Рәхиләнең болай кинәт борылып китүеннән аптырап калды һәм, артыннан кычкырып:

– Рәхилә апа, бәй, нигә бер сүз дә әйтмәдең, кемнән соң, Хәсәннәнме? – диде.

Рәхилә китеп барышлый, гүя Маһирәгә түгел, һавага ташлагандай, бары:

– Әйе, – дип кенә куйды.

Ул кемнәндер кача кебек иде. Маһирәнең: «Йә, нәрсәләр язган соң, тукта әле?» диюеннән котылыр өчен, тиз генә өйалдына кереп югалды. Инде өй ишегенең тоткасына тотынгач, ул ирексездән туктады. Өйгә, ана янына керү аның өчен шундый шомлы, шундый авыр, газаплы иде, әйтерсең ул хәзер менә баштүбән тирән бер бушлыкка егылырга тиеш. Ничектер кинәт бөтен тәне хәлсезләнгән, күз аллары караңгыланган кебек булды... Ләкин ул бернәрсә дә уйлый алмый иде әле, һәм аның кулы, «керергә кирәк» дигән карардан түгел, ә үзлегеннән ишекне ачты. Өйгә керүгә ул, ананың карашы белән очрашмас өчен туп-туры алдына карап, тәрәзә янына узды. Кызының кергәнен көтеп яткан ана тиз үк:

– Кем бар иде анда? – дип сорады.

– Мәрфуга җиңги. Иләк сорап кергән.

Ни өчен Рәхилә болай дип җавап бирде – ул һичбер вакытта да әйтеп бирә алмас. Әнисен алдау уе аның башына һич килгәне юк иде; бу шулкадәр көтелмәстән, уйламастан һәм шулкадәр табигый әйтелде ки, Рәхилә ихтыярсыз янә эченнән әле генә әйткән сүзләрен кабатлап куйды. Ана исә, хуҗа булып:

– Үткән бер алуларында ертып керткәннәр иде, әйтеп бирер идең, – диде.

Рәхилә дәшмәде. Әнисенең бу ялганны чынга алуы аны бер минутка нииндидер һәлакәттән коткарган кебек булды. Ләкин ул үзен һаман ялангач хәлдәге кеше сыман тоя, йөрәге аша өшү, калтырау йөри, һәм ана бер дикъкать белән караса, бөтенесен аңлар төсле... Чыннан да, Рәхилә баскан урыныннан кузгалырга курка, ул үз хәлен аңларга көчәнә, каядыр югалган уйлау куәтен табарга тырыша. Бәхетсезлек үзенең бөтен мәрхәмәтсез чынлыгы белән аның

аңына барып җитмәгән кебек... Ул иң гади сорауларга җавап биреп маташа: «Хәсән үлгәнме?» – «Әйе, үлгән». – «Хәсән инде кайтмасмы?» —«Юк, кайтмас». – «Чынмы бу?.. Чынмы бу?..»

Сүзе бүленгән ана:

– Кызым, син мине тыңлыйсыңмы? – ди.

Бәлкем, бу аның икенче дәшүедер. Рәхилә күзләрен йома:

– Әйе, әни...

– Менә, кызым... Нәрсә әйтмәкче идем соң? Хәтерләрем бик таркау шул... Әйе, менә, Алла боерса, кайтыр... Эшкә керер... Укуын бетергәннән соң аның беренче башлап эшләве генә бит әле... Яшь, тәҗрибәсез... Кемнәр белән очрашмас, кемнәр белән бергә булмас... Кешенең төрлесе – яхшысы, яманы була... Шуңар күрә, кызым, ныгытып әйтеп каласым килә: берүк эшендә гадел була күрсен...

Һәм ана ашыкмыйча гына улының эштә, тормышта ничек булырга, үзен ничек тотарга тиешлеген сөйли. Рәхилә исә, кыймылдарга куркып, анасына кырын басып тора һәм күзләрен ачарга көче җитми. Менә Хәсән аның сул кулында... Юк! Хәсән үзе биредә шикелле... Рәхиләнең аңын бер секундка томан каплады һәм аның йомык күзләре алдына бик ачык булып туганы Хәсән килде: гүя ул шушы ак конвертны тотып ишектән килеп керде. Рәхиләнең колагына аяк тавышы, ишекнең ачылганы ишетелгән кебек булды... Туганы ни өчендер яланбаш... Ләкин ник бер үзгәрсен... нәкъ әүвәлгечә, ябык, нечкә озын буйлы... Тик йөзе генә, студент вакытына караганда, шактый олыгайган... киң маңгаена салгаланып кара чәче төшкән... Кечкенә күзләре куаныч белән елтырыйлар, ул тарсынып елмая, гүя кинәт, көтмәгәндә килеп керүеннән уңайсызлана төсле (ул шулай һәркайчан кызлар кебек оялчан иде)... Иреннәре аның кыймылдыйлар, ул нәрсәдер әйтә шикелле, тик тавышы ишетелми... Һәм менә кулындагы ак конвертны әнисенә суза...

Рәхилә куркынып күзләрен ачты, башын селкеп куйды, һәм аңына кайту белән башына килгән беренче уй «Ник элек әни үлеп, соңыннан бу хәбәр килмәде? Ни өчен бу гаделсезлек?» дигән уй булды.

Ул инде хәзер ананың сүзләрен тыңлый алмый, ул сүзләрнең һәртөрле мәгънәсе югалды, тик утлы күмергә акрын гына өргән җил шикелле, йөрәгенең чыдамаслык әрнүен генә үстерә, көчәйтә... Һәм Рәхилә зур булып ачылган күзләре белән тирә-юненә хәлсез ялварып карана. Ана исә һаман сүзен дәвам иттерә:

– Инде миннән соң, кызым, аның белән син каласың. Син аны карап үстердең, үзең аның белән бергә үстең. Сез бик дус идегез. Хәтерендәме, ул, «Рәхилә апай!» дип, артыңнан калмыйча ияреп йөри иде... Инде, кызым, сиңа васыятем шул: бервакытта да аның белән араң бозылмасын,

исемегез кешеләр теленә гайбәт булып кермәсен. Син олы була бел. Минем урынга каласың... Ана бул... Бервакытта да ярдәмеңнән, акыллы киңәшеңнән ташлама... Ул бик яшь бит әле... Син инде аңардан күзләреңне алма... Кызым, ник дәшмисең?

Рәхилә әнисенә таба атлады. Кинәт ул үзендә шундый хәлсезлек – әйтерсең тәненнән бөтен канын суырганнар – шундый бер хәлсезлек тойды... Тезләре акрын гына сыгыла кебек... Менә хәзер әнисенең аяклары өстенә ава, күкрәгеннән ярсу ычкына: «Ах, әни!» – ди, ләкин яшьләренә буыла һәм сүзсез генә, бөтен тәне белән калтыранып елый, елый да елый... «Ах, аңа үзе һәм әнисе шундый кызганыч, алар шундый бәхетсезләр, шундый ялгыз-бәхетсезләр...

Юк, Рәхилә аумады. Бу – берничә секунд башының томан эчендә йөзүе иде, бу – тау кебек газапның бик төптән күтәрелеп бугазга килүе иде. Рәхилә аны кире йота алды, ул турайды, ул тирән-тигез генә сулады, акрын-тыныч кына:

– Ярый, әни! – диде.

Һәм ана үз нәүбәтендә кызына ихтирам тулы күзләре белән карап:

– Рәхмәт, кызым, мин сиңа ышанам! – диде.

Алар арасында тынлык урнашты. Рәхилә, бу сүз бүленүдән файдаланып, тышка чыгарга ашыкты. Ул ананың Хәсән турында яңадан сөйли башлавыннан котылырга, аз гына вакыт ялгыз булырга, ичмасам, бер тулы итеп һава суларга кирәклекне тоя иде. Ләкин ул туп-туры чыгып китәсе урынга, әүвәл өстәл янына килеп, ни өчендер буш стаканны кулына алды, китә башлагач, яңадан борылып, аны кире урынына куйды, соңра ишеккә таба китте.

Ишектән чыгуга, ул чак кына апасы Хәлимә белән бәрелешмәде. Аның алдында җирдән калыккан шикелле, ашыгып килүдән кызарган, еш сулыш алудан күкрәкләре бер күтәрелеп, бер төшеп һәм бөтен тәненнән эссе бәреп торган апасы Хәлимә басып тора иде. Рәхилә, аның борчылулы сорау белән текәлгән күзләрен күрүгә, кулыннан тотып, үзеннән калдырмыйча, тизрәк йорт алдына алып чыкты.

– Син нәрсә, берәр нәрсә ишетеп килдеңме?

– Маһирә, хат бар, диде.

– Йә?

– Син хатны уку белән бик үзгәргәнсең. Маһирәгә бер сүз әйтмичә өйгә кереп киткәнсең...

Рәхилә каты итеп иреннәрен кысты.

Хәлимә аның кулын кинәт кенә тартып куйды:

– Йә, әллә миннән дә яшерер идегезме?

– Акрын, синнән беркем дә яшерми.

– Нигә әйтмисең соң, хат кемнән?

– Хат... фронттан.

– Хәсәннәнме?

– Апа, сабыр бул... Хәсән үлгән...

Хәлимә, чак ишетерлек итеп:

– Үлгән? – диде, артка таба ава башлаган кебек булды, ләкин кинәт әче кычкырып, бөтен гәүдәсе белән алга, ишеккә таба ташланды:

– Әнием, әнием...

Рәхилә стена булып Хәлимәнең алдына басты, кулы белән каты итеп иңбашыннан тотып алды һәм көч белән җиргә таба иде.

– Тукта...

Бу минутта Рәхиләнең туры гәүдәсе тагы да үсә төшкәндәй булды. Менә ул күкрәген алга таба чыгарып басып тора, һәм моңарчы күренмәгән ниндидер бер көч, мәрхәмәтсез усаллык булып, аның йөзенә калка. Йомыла төшкән күзләрендә хәтәр бер коры чаткы кабына... Ләкин бу һич таныш булмаган кыргый көчнең кинәт шундый олы булып тууы апасын бик үк куркытмасын өчен (бу хәле аның үзенә дә шомлы булып тоела), ул тыелырга тырыша, тик тыелу аңа зур авырлык белән бирелә. Ачулы тавышында эчке калтырану сизелә, ул акрын сөйләргә тырыша.

– Нишлисең син? Бер кайгы җитмәгәнме сиңа? Берьюлы ике кайгы булсын дисеңме, аз гына уйлыйсыңмы син? Әйтүең белән үтерер идең бит. Белмисеңмени, ул ишектән күзләрен алмыйча аны көтә? Юк, әни моны белергә тиеш түгел. Ишетәсеңме?..

Хәлимә Рәхиләнең кискен кушуына чарасыз буйсынды. Ул хәлсезләнеп бөгелде, башын кулларына салды, ничектер кечерәеп калды... Һәм, тәмам ихтыярын югалткан бала шикелле, үксеп-үксеп еларга кереште.

– Апа, җитәр дим, ишетәсеңме, җитәр дим.

Хәлимә тыела алмый, елавы һаман көчәя бара. Рәхилә, борчылып, тирә-юненә карана. Читән буйлап күрше хатынның чишмәдән менеп килгәнен күрә, тиз генә Хәлимәне иңбашыннан тотып, селкеп ала:

– Тукта дим. Әнә Сабира җиңги безгә таба килә. Яхшы түгел, тыела бел. Бала түгелсең бит.

Хәлимә тыелырга тырыша, йомарлаган кулын авызына куя, үксүен чыгармас өчен, бармакларын тешли... Алар икесе дә күрше хатынга аркалары белән борылып торалар. Тыныч, үзара сөйләшеп торалар кебек... Һәм күрше хатын, бу ике туганның шушы минутта

башларыннан нәрсә кичергәннәрен һич белмәстән, акрын гына алар яныннан үтеп китә. Рәхилә белән Хәлимәгә исә аның якынлашуы, узуы һәм ераклашуы бер гомер булып тоела.

Күрше хатын ераклашуга, Рәхилә йомшак кына дәшә:

– Апа, бәгырем, бар, кайт.

Хәлимә, суларга һава җитмәгәндәй, башын күтәреп:

– Хәсән туганым, Хәсән туганым, син кайда? – ди һәм янә үкси башлый.

Рәхилә Хәлимәнең чәчләреннән сыйпый:

– Апа, бәгырем, чыдыйк, бик авыр булса да чыдыйк. Бер безнең башка гына төшкән хәсрәт түгел бу... Апа, бәгырем, тыңла мине, бар кайт, балаларың белән бул, аларны сөй, тынычлан.

Һәм, култыгыннан алып, ашыкмыйча, сакланып кына капкага таба илтә. Хәлимә буйсынып атлый, хәлсез башын Рәхиләнең иңбашына сала, елавыннан туктый.

Рәхилә Хәлимәне тынычландырыр өчен уйлап, ләкин үз-үзенә әйткәндәй:

– Сугыш бу... – ди.

Хәлимәне капкадан озату белән Рәхилә өйгә, энисе янына ашыга... Өйдә тынлык. Өйдә җан иясе юк шикелле... Тик ачык тәрәзәләрнең ак пәрдәләре генә салмак җилфердәшә. Рәхилә сакланып кына агач карават янына килеп энисенә карый. Ана йоклый. Ялгыз калган сабый бала шулай иркә, йомшак һаваның назлап сөюеннән йоклап китүчән була... Әйе, авыру ана бала тынычлыгы белән йоклый. Саргаеп кипкән кечкенә йөзендә аның —әйтерсең уйларын, газапларын ниндидер сихерле кул сыпырып алган – тыныч гамьсезлек.

Рәхилә, чебен кунып борчымасын өчен, акрын гына ак чыбылдыкны төшерә һәм аяк очы белән генә басып кире өйдән тышка чыга. Ишегалдының түренә узып, бакча рәшәткәсе буендагы яшел чирәмгә утыра.

Гаҗәп, Рәхилә үзендә елыйсы килү тоймый. Ә ул ялгыз калгач тыела алмам, елармын дип уйлаган иде. Бәлки кайчан да булса бер елар, һичшиксез елар... Ә хәзер... Юк, бик тырышып караса да елый алмас иде. Яшьләре аның эчендә кибеп бетте һәм күңелендә тыныч бушлык, аз гына моңсу тыныч бушлык урнашып калды. Әмма моңсу бушлык төбендә, кайдадыр бик тирәндә, кагылырга хәтәр сызлавыклы бер төер ята. Рәхимсез ачу-нәфрәт төере бу! Һич шик юк ки, Рәхилә менә шушы минутта бәдбәхет дошманны үз кулы белән рәхәтләнеп буар иде, буар иде һәм... җиңеләеп калыр иде. Сугыш бит бу, үлем өчен түгел, тормыш өчен сугыш!

Хәсән!.. Әйе, Рәхилә аны карап үстергән иде. Янә үстермәсмени? Әгәр үз баласы булмаса, апаларының, сеңелләренең балаларын карап үстерер. Бер Хәсән урынына ун Хәсән үстерер!

Юк, бу минутта кайгысы бик зур булса да, Рәхилә елый алмый... Кулы тойган җир, аркасыннан сөйгән кояш, күзләренә караган чәчәкләр тыныч булырга кушалар, сүзсез, бары үзләренең шушында, аның әйләнәсендә булулары белән юаталар. Чыннан да, Рәхилә салкын-тыныч. Тик чигәсендә аның әле үзе күреп өлгермәгән ике бөртек чал чәче елтырый...

*1942*

**Бер генә сәгатькә**

Авылдан ике километр ераклыкта сөзәк сырт буйлап тимер юл үтә. Авыл очындагы Галимҗан абзый йортының тәрәзәсеннән карасаң, нәкъ каршыда карт юкә агачлары ышыгына яшеренгән кечкенә кызыл кирпеч станция бинасы һәм сарыга буяган кызыл түбәле җыйнак каралтылар күренә. Станциядән ике якка сузылган берничә рәт юллар кайчан буш була; тик теге яки бу тупиктагы ялгыз вагон, онытылып калган шикелле, моңаеп тора... Кайчак исә ул юлларга озын-озын эшелоннар килеп туктый. Күп вакытта вагоннарның ишекләре ачык була, һәм аннан кешеләр сикерешеп төшеп, арлы-бирле йөри башлыйлар. Кайвакытта исә, вагоннар ябык була һәм алар җепкә тезгән уенчык вагоннар төсле булып күренәләр: гүя, аларның кара тәгәрмәчләре бик юка, җиңел һәм чак җиргә тиеп, хәзер тәгәрәшеп китәргә торалар. Кара паровоз еректан, чабыш айгыры шикелле, бик сылу, дәртле, кыю булып күренә һәм, пошкырган саен, һавага бер-бер артлы тезелешеп киткән кечкенә ак болытлар тарата.

Галимҗан абзыйның хатыны Мәрьям абыстай өйнең кечкенә тәрәзәсеннән шул күренешкә – карт юкәләр ышыгындагы тәбәнәк кызыл станциягә һәм аңардан ике якка сырт буйлап «көмеш дилбегә» төсле сузылып киткән юлга карап торырга ярата иде. Элек аның мондый гадәте юк иде. Ул ара-тирә авылның башка хатын-кызлары белән бергәләшеп станция каршысына йомырка, сөт, май алып бара, пассажирларга алып килгән нәрсәләрен татарча мактап-мактап сатарга тырыша һәм, тубалы, шешәләре бушап калса, күтәренке кәеф белән тизрәк өйгә, карты янына кайтырга ашыга иде. Кыскасы, станциягә, поездларга күптән ияләшкәнгә күрә, аларны бар дип тә белми һәм тәрәзәдән карап тору теләге бервакытта да күңеленә килми иде.

Инде сугыш башлангач, өч улы шул кечкенә станциядән, кызыл вагоннарга утырып, кояш батышына таба фронтка киттеләр. Мәрьям абыстайның исәбенчә, алар кайчан да булса шул ук юл белән, шундый ук вагоннарга утырып, шушы кечкенә станциягә кире кайтып төшәргә тиешләр иде. Һәм менә ул күңеле моңсу сагыш белән тулган яки бер дә сәбәпсез эче пошкан минутларда тәрәзәдән тимер юл буена карап торырга гадәтләнде. Күп вакыт станция буш була, бер яктан да поезд килгәне күренми. Мәрьям абыстай йөрәге төбеннән күтәрелергә

маташкан өметсезләнүне басарга тырышып, акрын гына сулап, тәрәзәдән китә. Кайвакыт исә ул сырт буйлап станциягә таба килгән озын эшелонны күрә. Сырт өстеннән караган кояштан кечкенә кызыл вагоннарның зур кыек күләгәләре авыл ягына таба төшкән, һәм бу бер-берсеннән тигез яктылык белән аерылган кыек күләгәләр яшел чирәм өстеннән бик кызу куып баралар, ә рельслар буйлап җиңел кара тәгәрмәчләрдән калышмыйча чуар яктылык йөгерә. Менә күкрәген киерә төшеп барган паровозның кечкенә җиз трубасыннан кинәт ап-ак пар ишелеп-ишелеп һавага күтәрелә, аннан артка таба кызу гына йөзеп китә, поезд өстендә һавада чак сизелерлек вак кына якты дулкыннар тирбәнеп кала... Ә бераздан Мәрьям абыстайның колагына сузып кычкырткан гудок тавышы килеп ишетелә. Бу тавышны ул салкын кан белән тыңлый алмый, бу тавыш аның йөрәгенә төшә, һәм ул, сихерләнгән кеше шикелле, поездан күзләрен аера алмый. Ул аның станциягә килеп җитүен, вагоннарның тавышсыз, салмак кына бәрелешеп туктауларын, поездан кешеләрнең төшүен һәм авыл юлына кемнең дә булса килергә чыгуын көтеп, күзләренә җәелгән яшь томаны аша озак карап тора. Өч улының кайсысы булса да, кайчан да булса бер, килгән поездан төшеп, авыл юлына чыгар бит! Ул бит, шушы тәрәзәдән карап тора торгач, авылдашларыннан берничә кешенең фронттан кайтуларын беренче булып күргән дә иде.

Бүген исә Мәрьям абыстайның кәефе бигүк әйбәт түгел иде. Аның бөтен тәне авыраеп, башы томаланып тора һәм кул-аяклары хәлсез яналар. Ләкин ул, кәефе ничек булуына карамастан, иртә торырга гадәтләнгән. Карты белән килене Камилә кыр эшенә йөргәнгә күрә, ул һәр көн, алардан иртәрәк торып, үзләрен ашатып-эчертеп озату хәстәренә керешә. Камилә торып, су китереп, сыер савып кергәнче, аның казан асты ягылып, бәрәңгесе пешеп, самовары куелып өлгергән була. Бүген дә шулай, кәефе начар булуга карамастан, килене белән картының тышкы эшләрне бетереп керүләренә чәй урынын хәзерләп куйды. Өстәлдә җиз самовар үзалдына, бары үзе өчен генә моңланган шикелле, акрын гына шаулап утыра, олы табак белән китереп куйган бәрәңгедән, ашыйсы килүне котыртып, җылы бу күтәрелеп тора.

Менә Галимҗан абзый, кулларын угалап, өстәл артына кереп утырды. Бер олы кайнар бәрәңгене алып, мул итеп тозлап, авызын тутырып капты. Соңра кәефләнеп кысылган күзләре белән Мәрьям абыстайга карап:

– Карчык, нигә болай бик боексың? – диде.

Мәрьям абыстай икеләнеп җавап бирде:

– Әллә тагы, үзем дә белмим, башым авырта.

Галимҗан абзый карчыгының сүзләренә артык игътибар итмәде. Ул бары:

– Бирешәсең, карчык, бирешәсең! – дип кенә куйды.

Мәрьям абыстай картына дәшмәде. Ул үзендә картаеп өлгергән кешеләрдә еш була торган, сөлек шикелле бөтен хәлен суырган авыр бер бушлык тоя иде. Уй юк, бернинди сизү юк, тик күз кабакларын авырайткан гәүдәне һаман урынга сөйрәгән хәлсезлек кенә бар. Бу саңгырау хәлсезлек аның бөтен әгъзаларына, ниндидер бер чирнең ашыкмыйча килүе төсле, акрын гына җәелә бара һәм колаклары эчпошыргыч бер тоныклык белән туктаусыз шаулап тора иде.

Карты белән киленен эшкә озаткач, Мәрьям абыстай иренеп кенә чәй урынын җыештырырга кереште. Килененең ун яшьлек кызы Зәйнәп кызу-кызу гына идәнне себерде дә каядыр чыгып йөгерде. Мәрьям абыстай ялгыз калды, һәм бу ялгызлык аңардагы авыр бушлыкны тагын да тирәнрәк, тагын да саңгыраурак иткән кебек булды. Аның бары урынга гына ятасы килә иде. Ул хәтта, гадәте буенча, тәрәзәгә барып, тимер юл буена карарга да ирենде. Чәй урынын җыештырып бетүгә, мич буендагы сандык өстенә менеп, аркасын мичкә терәп, бөрешеп кенә ятты. Күпме-азмы ятканнан соң, ул йокыга талган кебек булды. Ләкин бу таза йокы түгел иде. Аның йомык күзләре алдында ниндидер танырга мөмкин булмаган күренешләр һәм кешеләр томан эчендә, еракта йөзәләр, ә колакларында, бик ерактан ишетелгән буа тавышы шикелле, тонык кына гөжләү шаулый. Ләкин аның акылы тәмам оеган һәм сизгерлеге тәмам сүнгән иде.

Менә бервакытны аның колагына:

– Әни! – дигән тавыш ишетелде, ләкин аңына барып җитмәде, тик гәүдәсе генә сискәнеп куйды. Күпмедер вакыттан соң бу тавыш якында гына, нәкъ колагының төбендә, бик ачык булып ишетелде:

– Әни!

Мәрьям абыстайның бөтен тәне буйлап кискен калтырау йөгерде, ниндидер бер саташулы төштән котылырга теләгәндәй, ихтыярсыз башын чайкап куйды һәм авырайган күз кабакларын ачты.

Аның өстенә иелеп, кече улы Гомәр елмаеп карап тора иде. Мәрьям абыстайның күзләрендә бер секундка саташулы курку кабынган кебек булды. Гомәр, һаман елмайган килеш, тыныч кына:

– Әни, курыкма, бу мин, – диде.

Мәрьям абыстай, терсәкләренә таянып, урыныннан күтәрелергә тырышты. Аның иреннәре кызу-кызу кыймылдый башлады: әллә ул шатлык авазы белән кычкырырга тели иде, әллә кызу гына пышылдап, берәр дога укымакчы иде. Тик ул чак ишетелерлек хәлсез тавыш белән бары:

– Улым, йа Алла, Гомәрем, синме бу?! – дип кенә әйтә алды.

Гомәр, әнисенең ике кулыннан йомшак кына алып, аны урыныннан торгызды:

– Мин инде, әни, мин. Әллә күзләрең начар күрәме?

Мәрьям абыстай, хәлсезлектәнме, әллә сүз таба алмау җәфасыннанмы, улына сыенып, акрын гына елый башлады.

Шул арада ишек бусагасында Зәйнәп күренде. Ул бер генә секундка тукталды һәм өй эчен яңгыратып:

– Абый! – дип бер кычкырды да яшен тизлеге белән ишектән кире тышка атылды.

Тын өйдә көтмәгәндә кыска гына яңгырап куйган Зәйнәп тавышы Мәрьям абыстайны, ниһаять, йокылы-уяулы хәлдән тәмам чыгарды. Аның бөтен авыру хәлсезлеге кинәт өстеннән коелып төшкән кебек булды. Ул, күзләрен сөртә-сөртә, берьюлы кайткан җан терелеге белән сөйләнә башлады:

– Менә рәхмәт яугыры! Төшемме бу дип торам. Поезд кычкырганын да ишетми калганмын лабаса.

Соңра ул нәрсәдер эшләргә кирәклекне кинәт исенә төшергән, ләкин тәгаен нинди эш икәнен ачык кына белмәгән кеше шикелле ашыгып ишеккә таба китте, кире борылып янә улына килде.

– Балам, утырыр идең, аякларың арыгандыр... Ходаем, әтиең дә китеп өлгерде. Булмаса, артыннан барыйм әле. Колхоз ихатасында түгел микән.

Ул янә ишеккә таба китә башлады, ләкин Гомәр аны туктатты.

– Әни, син йөрмә. Зәйнәп мине күрде бит. Ул әти артыннан йөгерде булса кирәк.

– Шулаймы?! Ходаем, зиһеннәрем таралып китте. Төшемме дип торам. Үзем көтә идем бит, көтә идем, йөрәгем сизә иде. Йа Раббем, догаларымны бушка куймадың, инде Шакир белән Фатихымны гына күрәселәрем калды.

Шул арада тыштан кызу атлаган аяк тавышлары ишетелде һәм, ишек ачылып, Галимҗан абзый белән килене Камилә һәм Зәйнәп килеп керделәр.

Галимҗан абзыйның йөзе җыеп ала алмаслык тоташ бер елмаюга әйләнгән; ничек кенә тыныч булырга тырышмасын, аның да ирennәре агарган һәм акрын гына калтыраналар...

Ул, ике кулын сузып, каршысына күтәрелгән улына таба атлады.

– Улым, Гомәр!

– Саумы, әти!

– Бәрәкалла, бәрәкалла. Куаныч белән күрешер көннәр бар икән.

Камилә дә каенесе белән ике куллап күреште. Ул чак ишетелерлек итеп:

– Гомәр! – диде дә соңра: – Исән кешеләр бер кайталар! – дип үксеп елап та җибәрде.

Зәйнәп исә, янә: «Абыем!» – дип кычкырып, Гомәрнең муенына ташланды. Галимҗан абзый, артында торган урындыкка утырыр-утырмас кулларын күтәреп, битен сыйпагандай итте дә килененә карап йомшак кына:

– Килен, балам, елама! – диде. – Менә берсе кайтты, синеке дә кайтыр. Хәбәре юк-югын, ләкин бит әле еларга да сәбәбе юк. Сабыр бул! Улым, бөтенләйгәме?

– Юк, әти, вакытлы гына...

– Алай, бөтенләй үк түгел икән, ә! Һем-м, күпмегә соң?

– Мин бик азга.

– Шулай да ике айгамы, бер айгамы, күпмегә?

– Юк, әти... мин бик аз вакытка, бары бер генә сәгатькә!

Бу хәбәрнең тәэсире барысына да шундый булды ки, гүя ул Гомәрнең авызыннан чыкмады, ә кайдандыр, стена аша килгән ят, ямьсез бер тавыш булып ишетелде, һәм алар бу тавыштан ничектер барысы берьюлы кинәт катып калдылар. Галимҗан абзый улына кызганыч елмаю белән, ышанмыйча карый, Мәрьям абыстай исә, бөтенләй таңга калып, бернәрсә аңламаган кыяфәт белән, күзләрен зур ачып, улына текәлгән иде.

Гомәр хәлне төшендерергә ашыкты:

– Безнең эшелон станциядә, әти... Без госпитальдән фронтка китеп барабыз. Поезд бераз торасы булганга, мине менә сезнең белән күрешеп чыгар өчен бер генә сәгатькә җибәрделәр.

Галимҗан абзый, әйтергә сүз таба алмаган шикелле:

– Азрак, улым, азрак, азрак, – дип мыгырданып куйды. Соңра исенә төшкәндәй: – Син, Гомәр, булмаса, иртәгә икенче поезд белән китәрсең, – диде.

– Һич булмый, әти, мин үзебезнең поездга өлгерергә тиешмен!

Бу катгый сүзләрдән соң барысы да бераз вакыт нәрсә әйтергә дә белмичә аптырап тордылар. Алар шундый көтмәгәндә очрашу шатлыгы белән шундый тиз, кинәт аерылышу авырлыгын бер үк вакытта аңлау, тоюдан гаҗиз иделәр. Алар бу бер-берсе белән сыеша алмый торган ике капма-каршы хиснең кайсын чынга алырга, кайсына ышанырга, кайсысы белән бу минутта яшәргә кирәклекне белмиләр иде. Камилә үзе дә сизмәстән елавыннан туктады. Мәрьям абыстай яңадан хәлсезләнде, әлеге бушлык аны янә үз эченә йота башлады. Тик бары Зәйнәп кенә, бернинди китүне белергә дә, ишетергә дә теләмичә, үзенең яңгыравыклы тавышы белән:

– Юк, юк... Китмисең, абый, китмисең! – дип кычкырып, Гомәргә тагын да ныграк сыена төште, аның муенына нечкә беләкләре белән тагын да ныграк уралды.

Галимҗан абзый алдына, бер ноктага төбәлеп карап торганнан соң башын күтәрде, карчыгы белән килененә карап алды һәм тавышын күтәрә төшеп:

– Йә, нәрсә мәрткә киткән шикелле катып калдыгыз? – диде. – Кешенең минутлары санаулы... Килен, самоварыңны тизрәк өлгерт! Анасы, нәрсәң бар, хәзерлә!

Камилә каенатасының сүзеннән төртеп уяткандай сискәнеп куйды һәм уңган килен өлгерлеге белән, ике кулы түгел, дүрт кулы бар төсле, өй эчен бер итеп эшләргә кереште. Ул иң элек Зәйнәпне читкә чакырып алып, колагына нәрсәдер әйтеп, каядыр йөгертте. Соңра самоварны җилтерәтеп алып идәнгә куйды, су өстәп, коры чыралар белән ут салып җибәрде. Учак алдына кечкенә тимер таган белән таба куеп, аның астына ут якты. Чоланнан өч-дүрт савытны берьюлы күтәреп, май, күкәй, сөт алып керде. Кечкенә сандыгын ачып актарына, аннан ниндидер төеннәр, чүпрәкләр чыгара башлады.

Мәрьям абыстай да үзенчә нәрсәдер эшләргә тырыша иде. Ләкин ул, улыннан ерак китәргә курыккан шикелле, һаман өстәл тирәсендә әйләнә, яки кулына алган әйбере белән баскан урынында туктап кала, нәрсә эшләргә кирәклеген оныткан кебек, уйланып тора һәм, бер улына, бер картына карап, акрын тавыш белән:

– Ходаем, мунча да кереп өлгермәс микәнни! – ди.

Галимҗан абзый, башын селкеп:

– Эх, карчык, карчык! – ди һәм үзе торып чәй урынын хәзерләргә керешә.

Гомәргә әнисенең бу гаҗизлегенә карау бик авыр иде. Аның йөрәге әнисен кызганудан сызлана башлады һәм күңеленә ихтыярсыз: «Юкка үзләренә күрендем», – дигән уй да килеп куйды. Ләкин ул күптән түгел генә нинди ашкыну, дулкынлану белән үзләренең станциясенә якынлашкан иде, ничек үтенеп командирыннан бер генә сәгатькә булса да авылга җибәрүен сораган иде, ничек ашыгып, тирләп-пешеп, йөгерә-атлый кайткан иде һәм хыялы кадерле күрешү минутларын уйлау белән тулы, йөрәге күпме шатлыклы хисләр татуны сизү белән бәхетле иде. Ул, әтиемне, әниемне, бөтен туганнарымны шатландырырмын, бәхетле итәрмен, дип уйлады. Хәзер исә бу шатлык уйный башларга өлгермәгән музыканың кинәт өзелеп ыңгырашуы кебек, бу бәхет елмаерга өлгермәгән кояшның кара болыт артына яшеренүе кебек иде. Бигрәк тә әнисенең зәгыйфь йөрәген шундый капма-каршы тойгылар утына салуда үзен гаепле дип белү аның өчен авыр иде. Шуңа күрә ул күңелендә булган янә бер кадерле теләген – яратып йөргән кызы Заһидәне күрәсе килүен әтисе белән әнисенә сиздерүдән куркып утыра. «Заһидәне телгә алсам, бары аның өчен генә кайткан булып күренермен», – дип уйлый иде ул. Тик җиңгәсенең Зәйнәпне чакырып алып, каядыр йөгертүе аңарда бер өметле сизенү тудырды. Уңган җиңгәсе яратышып йөргән егет белән кызны күрештерү чарасын, әлбәттә, күрергә тиеш иде.

Менә төрле хәбәрне һәркемнән элек ишетеп, һәр урында бөтенесеннән алда килеп өлгерүче авыл малайлары һәм кызлары ишек төбенә җыела башладылар. Кыюрак малайлар түргә узып:

– Исәнме, Гомәр абый! – дип кул биреп күрешәләр һәм, башка әйтер сүз тапмыйча, кире ишек төбенә китәләр. Анда алар арасында кызу бәхәс бара.

– Күрдегезме? Гомәр абыйның медале бар!

– Медаль түгел, орден ул.

– Орден сиңа, медаль! Медаль әнә шундый түгәрәк, ак була.

– Ә минем түгәрәк орден да күргәнем бар.

– Бар, пычагым.

– Ышанмасаң, Гомәр абыйның үзеннән сора.

– Кая тыгыласың, аякка бастың ич.

Мәрьям абыстай Гомәрнең кесәсеннән өстәлгә бушаткан шикәрен балаларга:

– Менә, балам, Гомәр абыегызның күчтәнәче! – дип өләшә башлады. Балалар сөенешеп елмаялар, ләкин шикәрне, оялган сыман, тартынып алалар, кыюсыз гына:

– Рәхмәт, түти! – дигән булалар һәм тизрәк учларына йомалар. Арттарак торган балалар кысылышып алга чыгарга тырышалар.

Мәрьям абыстайның шулай улым кайтты дип балаларны сөендерергә тырышуыннан Гомәр әнисенең үзенә булган мәхәббәтен аеруча бер тирәнлек белән сизеп алды һәм ана мәхәббәтен мондый тулылык белән сизү аның өчен кинәт бик авыр булды. Кайтып кергәч, беренче тапкыр диярлек ул күңеле нечкәрүен тойды һәм күзләренә килмәкче булган яшьләрен тыяр өчен, ашыгып, маңгаен ышкырга тотынды.

Менә Камилә кайнап чыккан самоварны җитез генә өстәлгә алып куйды. Өстәл өсте, кунак табыны шикелле, май, каймак, тәбә, Мәрьям абыстайның саклап тоткан балы, Камиләнең сандык төбеннән чыгарган прәннекләре, тәлинкә тутырып телгән икмәк һәм эреле-ваклы чынаяклар белән тулы иде. Гомәр, тансык аш итеп, катык та сорап алды.

Мәрьям абыстай һаман сыеның ярлы булуына өзгәләнә:

– Ичмасам, тавык та суеп өлгертә алмадык! – ди.

Галимҗан абзый шаяртып:

– Борчылма, карчык, хәзергә менә йомыркасын ашый торсын, икенче кайтып, боерган булса, тавыгыңны да ашап китәр, – дигән була һәм Гомәргә карап күз кысып куя.

Ахырда барысы да чәй эчәргә утырдылар. Гомәрне кыстау, аның ашау-эчүе турында сорашу белән җанлы сөйләшү башланды. Бу сөйләшү менә хәзер алда торган аерылышуны

оныттырган кебек булды. Аларның табыны бәхетле гаиләнең кайчандыр менә шулай барысы бергәләп, гөрләшеп утырган чакларын хәтерләтеп җибәрде.

Гомәр фронтта башыннан кичергәннәрне кыска гына сөйләп алды. Мәрьям абыстай сугыш хикмәтләрен, улының күргәннәрен таңга калып, тагын да хәтәррәк нәрсәләр ишетеп куркырга торган кыяфәт белән тыңлый иде. Гомәр сакланып кына ничек, нинди шартларда яралануын сөйли башлагач, ул берничә тапкыр, үзалдына гына: «Йа Раббем, йа Раббем», – дип куйды. Ахырда чыдамады, калтыранган тавыш белән:

– Әй улым, улым, ничек исән калгансың! – диде.

Гомәр, тыныч елмаеп, гади генә:

– Әни, менә үзең күрәсең ич, тап-тазамын! – ди. Галимҗан абзый да улының ашыкмыйча, сабыр гына сөйләвен, сүзләренә искитәрдәй төс бирмәвен һәм, һәрнәрсәнең асылын белгәндәй, һәркемгә туры карап, тыныч елмаюын күргәч: «Малай башка-а!» – дип уйлап куйды. Аның улы белән җитдирәк мәсьәлә турында сөйләшәсе килде һәм, сакалының очын бармаклары белән тибрәткәләп, салмак кына:

– Соң, улым, англичаннарның фронтта эшләре ничек бара? – диде.

Мәрьям абыстай картының бу сүзләрен ишетүгә кабынып китте:

– Тапкансың сорашыр нәрсә, әгелчәннәр, имеш. Нигә кирәк ул сиңа... Башка әйтеп калыр сүзең юкмыни?

– Тик кенә утыр әле син!

– Гомәр бит айлап торырга кайтмаган, ата кеше син, файдалы киңәшләреңне бирер идең.

– Мишәйт итмә дим мин сиңа! Гомәрнең безнең киңәш белән йөрисе калмаган.

Мәрьям абыстай рәнҗеп еламсырый башлый:

– Гомерем буена шул кирәксез сүзләре белән миңа аркылы төшеп җанымны кыйнады. Миңа улларым кадерле, минем җаным бары алар өчен генә көя. Фатихымның ике елдан бирле хәбәре юк. Шакирым хәзер кайда, исән-саумы? Шулар турында сораштырырга иде. Ә син, карт тиле, әгелчәннәр кайгысын кайгыртып утырасың.

Галимҗан абзый улына карап: «Менә аңламаган кеше белән нишлисең инде!» – дигәндәй, берничә тапкыр башын селкеп куйды.

Гомәргә әтисе белән әнисенең болай бәрелешеп алулары бик таныш иде. Галимҗан абзый, газета укыштыргалаганга күрә, халыкара хәлләр һәм тышкы сәясәт турында үзенчә фикер йөртергә, җай чыкканда шул хакта сөйләшеп алырга ярата. Мәрьям абыстай исә, чын ана буларак, гаиләнең эчке сәясәте турында гына уйланудан һәм балалары кайгысын гына кайгыртудан уза алмый. Элек укудан кайткан вакытларында да әтисе халыкара хәлләр турында,

әнисе аның шәһәрдә ничек торуы, ашау-эчүе турында бер-берсен бүлгәләп сорашырга керешәләр һәм ахырда бер-берсе белән бәрелешмичә калмыйлар иде. Мондый вакытта Гомәргә һәр икесен дә канәгатьләндерерлек һәм килештерерлек сүз табарга кирәк була иде.

Хәзер дә ул шулай булырга тырышты:

– Әни, син юкка безнең өчен артык борчыласың. Мин менә исән-сау, бик азга булса да, сезне кайтып күрдем. Озакламый бөтенләй дә кайтырмын. Әти бит кайчан сугыш бетәр дә, кайчан барыбыз да җиңү шатлыгы белән өйләребезгә кайтырбыз дип сорамакчы була.

– Хак сүз, хак сүз!

– Союзниклардан рәт чыкмады, әти. Карга карганың күзен чукымый инде ул... Әле менә безнең армия немецларны пыр туздырып куарга тотынгач, күз буяр өчен генә дигәндәй, кыймылдый башлаган булдылар. Хәер, алардан башка да инде без Гитлерның муенына петляның тазасын салдык. Үзең беләсең, бу петля хәзер көннән-көн буыла бара!

– Шулаймы, бирсен Алла! Халык шул петляның тизрәк буылып бетүен көтә, улым, бик көтә. Аягына яңа баскан баланың да телендә хәзер бер генә сүз: кайчан сугыш бетәр икән, ди.

– Инде озак көтәсе калмагандыр, әти, менә күңел үзе озакламый бетәсен сизеп тора кебек... Әйе...

Гомәр кул сәгатенә карап ала.

– Миңа кузгалырга вакыт җиткән икән, әти, рөхсәт итегез...

Мәрьям абыстай сискәнеп куя:

– Ходаем, шулай бик тизмени?

Камилә ашыгып:

– Гомәр, тагын берне генә ясыйм әле, – ди һәм Гомәрнең чәшкәсенә үрелә.

Галимҗан абзый үзалдына әйткәндәй:

– Әйе, санаулы минутлар тиз үтә, – ди.

Гомәр урыныннан кузгала. Ул бу минутның барысы өчен дә никадәр газаплы, авыр булуын ачык күрә һәм юатыр өчен нәрсә генә әйтсә дә ясалма булып тоеласын яхшы сизә, ләкин әйтмичә булдыра алмый: тыштан ничек тә тынычлыгын сакларга тырышып, тик үзе дә сизмәстән тавышын күтәрә төшеп, әйтә:

– Бик зур рәхмәт сый-хөрмәтегезгә, әйе... Сезне бик сагынган идем, бик яхшы булып калды. Инде тиздән бөтенләй кайтуымны көтегез!

Мәрьям абыстай елый башлый:

– Газиз йөзләреңне күргән кебек тә булмадым.

– Әни, бәгырем, юкка...

Галимҗан абзыйның да йөзе караңгылана:

– Карчык, сабыр бул!

Нәкъ шушы минутта ишекне киң ачып, Мәрьям абыстайның агасының улы, былтыр фронттан агач аяк белән кайткан Шәрифулла килеп керә. Ул, кочагын ачып, туры Гомәргә таба бара:

– Һо, Гомәр, туганым! Кая, җанкисәгем, бер әп итеп күрешик әле! – Һәм Гомәрне кочаклап, ике яңагыннан да үбеп ала. – Молодец, молодец! Менә исән-сау кайткансың. Рәхмәт, туган! Ә миңа хәбәр итми торалар. Юк, мин әйтәм, каным коелган җирләрдән кайткан туганымны, төшкән килен шикелле, каршы алырга тиешмен. Шулай бит! Мәрьям түти, бәгырем, нигә елыйсың? Шатлык бит бу, бәйрәм бит бу!..

Мәрьям абыстайның яшьләре мөлдерәп коела. Ул сүзен чак әйтә ала:

– Әй Шәрифуллам, китә бит, китә!

Шәрифулла аптырап, ышанмыйча, Гомәргә карый.

Гомәр ни өчендер көчәнеп елмайган була.

– Шулай, Шәрифулла абый, безнең эшелон станциядә тора. Азрак булды, нишлисең...

Шәрифулла катгый рәвештә:

– Не смеешь, брат, не смеешь! – ди, чалбар кесәсеннән ярты баш аракы чыгарып, шап иттереп өстәлгә куя. Ул үзе, бераз эчеп алганга күрә, кызмача. – Без болай шаяруны яратмыйбыз. Кайткансың икән, торырга тиешсең. Точка!

– Шәрифулла абый...

– Юк, юк, ишетәсем дә килми. Әйдә, утыр! Син, брат, минем команданы тыңларга тиешсең! – Һәм чәшкәне тутырып аракы куя.

– Шәрифулла абый, син бит үзең армиядән кайткан кеше. Приказны үтәмәскә ярыймы?.. Менә миңа бер сәгать вакыт бирделәр. Бер сәгатьтән мин барып җитәргә тиеш. Бу минем өчен приказ.

Алар берничә секунд бер-берсенең күзләренә туры карап торалар. Ахырда Шәрифулла, уң кулын күтәреп:

– Да, – ди, – приказ – закон! Җизни, син аңлыйсыңмы, приказ – закон! Старшина Сәлимов дөрес әйтә. Ул китәргә тиеш! Ну, Гомәр, аякларың җиңел булсын! Яңадан әйләнеп кайтырга...

Чәшкә белән аракыны суза. Гомәр аракыны ала.

– Мин дә шулай дим, Шәрифулла абзый. Сугышкан кадәр сугышасы калмады. Менә күп тә үтмәс, әйләнеп чыккан кояш шикелле, яңадан кайтып килербез.

– Әйе, әйе, кайтасың, обязательно кайтасың! Мәрьям түти, бәгырем, мәрҗән яшьләреңне юкка түкмә! Кайтам, ди, ишетәсеңме, кайтам, ди.

Мәрьям абыстай сүзсез, акрын гына елавыннан тәмам кечерәеп кала. Яшьләре аның, ана йөрәгендә изге бер чишмә ачылган шикелле, туктаусыз агалар. Бу яшьләрдә газаплы хәсрәт ачысы юк, бу энҗедәй саф яшьләрдә тик ана мәхәббәтенең мәңге суынмас җылысы гына бар. Ашыгып Гомәрнең юл капчыгына оекбашлар, сөлге, яулыклар һәм азык-төлекләр салып йөргән Камилә дә үкси башлый, эшеннән бер генә минутка да туктамыйча йөри-йөри үкси. Галимҗан абзый, ихтыярын җигеп, тыныч-сабыр булырга тырыша, тик карлыга төшкән тавыш белән:

– Амин, Шәрифулла, амин! – ди.

Гомәр аракыны беткәнче эчеп куя.

– Әти, әни бәгырем, сез минем өчен артык янып көймәгез! Шәрифулла абый менә бик тиз аңлады. Сез дә аңларга тиеш. Мине фронт көтә. Гитлерның эшен бетерәсе бар.

Гитлер дигән сүзне ишетүгә Шәрифулланың күзләрендә хәтәр бер ут кабына:

– А, мин ул Гитлерны! Мин аны җан җиреннән кысып, бөтен дөньяга акыртыр идем! – Һәм алга сузган кулын, тешләрен шыкырдатып, шундый көч белән кыса ки, бу минутта кайдадыр Берлинда утырган Гитлер тынычлыгын җуеп, урындыгы өстендә шуышып куярга тиеш иде кебек.

Ишек төбендә балалар күбәя. Күрше хатын-кызлар җыела башлый. Күрешүчеләр, сорашучылар, Мәрьям абыстайны кызганып кайгыручылар һаман арта бара. Бу хәл Гомәрне шактый уңайсыз хәлгә куя. Ул соңга калудан чынлап курка башлый һәм тизрәк китәргә ашыга:

– Әти, сез мине озата барырсыз бит?

– Әйе, улым.

– Ә син, әни...

Мәрьям абыстай улының әйтеп бетергәнен көтмичә, балалар шикелле:

– Мин дә, мин дә, – ди һәм кинәт туган җанлану белән ашыгып киенә башлый.

Гомәр исә: «Ә син, әни, борчылып йөрмә инде», – димәкче булган иде, дәшмәде.

Ахырда алар: юл капчыгын иңбашына асып Гомәр, иске эшләпәсен кырпу бүрегенә алыштырып кигән Галимҗан абзый, кара сатин тышлы билле бишмәтен киеп, кечкенә мамык шәлен беләгенә салып Мәрьям абыстай, Камилә килен, Шәрифулла тышка чыгалар.

Гомәрне бала-чагалар, хатын-кызлар һәм кайбер авыл агайлары урап алалар. Барысы белән дә бер үк вакытта исәнләшү һәм саубуллашу башлана. Гомәр хатын-кызларның уллары яки ирләре турында «очратмадыңмы?», «ишетмәдеңме?» кебек сорауларына кыска гына булса да тынычландырырлык җавап бирергә тырыша. Агайларның төрле яхшы теләкләрен, мактап

әйткән сүзләрен игътибарсыз калдырмыйча тыңлый. Шул ук вакытта ул кешеләрнең башлары өстеннән тирә-ягына каранып кемнедер эзли. Ләкин ул юк, ул күренми...

Гомәр беренче тапкыр җиңгәсенә сорау белән карады. Камилә өзгәләнеп:

– Зәйнәпне йөгерткән идем бит. Нишләп һаман юк икән? Кырга ук китеп бардымы икәнни?! – диде.

Гомәргә җиңгәсенең бу кадәр аның өчен өзгәләнүе кызганыч иде. Ул, күрешер өчен ике кулын сузып, акрын гына:

– Җиңги, борчылма, – диде. – Бик зур рәхмәт сиңа... Күп итеп сәлам әйтерсең!

Соңра Шәрифулла абыйсы белән үбешеп күрешә һәм кискен генә борылып, иңбашындагы капчыгын рәтли-рәтли юлга таба атлый. Аның артыннан Галимҗан абзый һәм вак-вак кына кызу атлап Мәрьям абыстай, янә бала-чагалар ияреләр.

Авылдан чыгуга, алар артыннан колхоз председателе җибәргән җиңел тарантаска җигелгән туры ат килеп җитте. Кузлага председательнең ундүрт яшьлек улы Әдһәм утырган. Ул кызу юыртып килгән атны кинәт туктатып:

– Галимҗан абзый, утырыгыз! – диде.

Соңга калудан куркып, ләкин хәлсез әнисен кызганып, акрын барырга мәҗбүр булган Гомәр өчен бу атның көтмәгәндә куып җитүе бик урынлы булды. Ул әтисе белән әнисен тарантас түренә утыртып, үзе кузлага менеп артка карап утырды. Менә хәзер генә аның алдында туган авылы тоташы белән ачылды. Бер караш ташлау белән ул авылның бөтен тыкрыкларын, таныш өй түбәләрен, авыл каршындагы сөзәк тауны, тау астындагы вак куаклыклар арасыннан боргаланып, яшеренеп аккан кечкенә елгачыкны, аның чәчәкле тар тугаен һәм авылның ике очыннан башланып киткән тигез, киң иген кырын күреп алды. Аның өчен туган җирнең бу күренеше – йөргән юлларында күп очраткан, күреп күнегелгән гадәти генә бер күренеш иде. Ләкин җәй башының яшь, тансык, сөйкемле матурлыгы белән балкыган шушы тау битләре, шушы кырлар аңа атасы йорты кебек үк үтә таныш, аеруча якын иде. Ул бу җирләргә карау белән кайда нинди юл үткәнен, нинди сукмакларның кая алып баруын, кайда нинди чокыр, нинди куаклык, ничек дип аталган басу, печәнлек барлыгын бик ачык хәтеренә төшерде, күпме генә читтә йөрсә дә, аларны бервакытта да онытмаячагын аңлады, һәм аның күңеленә кешенең торып киткән җирләренә кайтып, йөргән эзләренә яңадан басып йөрүе үз гомерендә кабатлана торган нәрсә икән дигән уй килде. Янә үткәннең бер кадерле хатирәсе аның исенә төшмичә кала алмады. Әнә шул тау итәгендәге куаклар арасында, печән чапкан вакытларда, ул һәм Заһидә ничек бер-берсе белән очрашырга теләп йөриләр иде. Кызык, алар аулакта очрашкач бер-берсенә сер сынатмаска тырышалар, әйтергә дип күңелләрендә саклап йөрткән сүзләрен әйтә

алмыйча, һич кирәге булмаган нәрсәләр турында сөйләшеп маташалар, инде Гомәр үзен тыя алмыйча кинәт Заһидәне ирексезләп үбәргә тырышса, бер-берсенә үпкәләшеп аерылыша торганнар иде. Ул вакытта алар, берсе икенчесенең йөрәгендә нәрсә ятканын бик яхшы сизеп торсалар да, бер-берсенә «сөям» дигән сүзне әйтә алмыйча калдылар. Тик Гомәр фронтка китеп, хат язышa башлагач кына, алар үзеннән-үзе туган кыюлык белән мәхәббәтләрен бер-берсенә ачканнар иде. Шуңа күрә дә «сөям» диюен язган хатларыннан гына укып белгән, ләкин ничек итеп, нинди караш, нинди тавыш белән бу сихри сүзне әйтүен ишетмәгән, инде минеке дип йөрәге белән тойган, ләкин үзенеке булуына күзләре белән күреп ышанмаган Заһидәсен аның гаять күрәсе килә иде. Хәзер дә ул ераклаша барган авыл очына, Заһидә күренмәсме дип, һаман карый бара, ләкин юл буш, авылдан ашыгып килүче күренми иде.

Кызу юыртып барган туры ат тиз арада аларны станциягә китереп тә җиткерде. Тарантастан төшеп, алар платформага чыктылар. Станция каршында озын эшелон тора һәм аның алдында бик күп хәрби кешеләр арлы-бирле йөриләр.

Гомәр әтисен-әнисен ияртеп үз вагонына якынлашуга, аларны солдатлар сырып алдылар. Гомәрнең иптәшләре, Гомәр белән бик үз булуларын күрсәтергә тырышып, куштанланып, шул ук вакытта бераз көнләшкәндәй дә булып, сөйләнә башладылар:

– Черт возьми, Сәлимовка нинди бәхет чыкты!

– Безнең Сәлимов молодец ул! Бер уңайдан да файдаланмыйча калмый.

– Ничә әйтсәң дә – старшина! Уңган халык!

Бу сүзләрне алар, башлыча, үзләре дә уйламастан, Гомәрне әтисе белән әнисе күз алдында күтәрер өчен әйтәләр һәм халык уртасында бераз каушап, югалып калган карт белән карчыкка да шундый ук куштанлык күрсәтеп, якын итеп, ләкин ниндидер бер сөйкемле балаларча тәкәллеф белән кул биреп күрешәләр:

– Исәнмесез, дядька!

– Исәнмесез, бабушка!

– Улыгызны күреп бик шатлангансыздыр?

– Хәзер инде исән-сау бөтенләй кайтуын көтегез!

Гомумән, киң илнең төрле якларыннан җыелган һәм кайсыдыр шәһәрләрдә, авылларда шундый ук карт әти-әниләре калган бу солдатлар чал кергән түгәрәк кара сакаллы, таза бәдәнле Галимҗан абзый белән ак йөзле, кечкенә буйлы Мәрьям абыстайга олы кызыксыну һәм эчке уйчанлык белән карыйлар иде. Гүя алар да менә шулай әти-әниләре белән бәхетле күрешү минутларына ирешүне өмет итәләр һәм хәзерге минутта шул күрешүне күз алларына китереп, шуның сагынычлы куанычын тоеп торалар кебек. Гомәрне әйләндереп алган түгәрәк эченә,

көтмәгәндә, юан гәүдәле, кыска муенлы, бик шома итеп кырынган түгәрәк битле бер майор килеп керде. Гомәр аны күрү белән корыч чыбык шикелле җитез тураеп, үкчәләрен бер-берсенә бәреп честь бирде. Майор көр тавыш белән русча:

– А, старшина Салимов, килеп җиткәнсез икән! —диде.

– Так точно, товарищ майор!

– Бик вакытлы... Ә, кадерле папаша белән мамаша да озата килгән икән! – Ул карт белән карчыкка ихтирам йөзеннән, ләкин тигез дәрәҗәле үз кеше булырга тырышып, кул биреп күрешә. Гади генә итеп: – Здравствуйте, папаша! Ну, как поживаем? – ди.

Галимҗан абзый дәрәҗәле кешенең бу игътибарына каршы тиешле ихтирам белән җавап бирә:

– Слау бух, товарищ!

Майор янә, улларын күрү куанычын уртаклашып, берничә җылы сүз әйтә, күрешүнең бик кыска вакытлы булуына тәэссеф белдерә.

– Ничава, товарищ, ничава, – ди моңа каршы Галимҗан абзый, сабыр гына. – Вайна бит, знаем!

Бу сүзләрне ишеткәч, майор, кашларын күтәрә биреп, чын соклану белән Галимҗан абзыйга беравык карап тора, аннан, дәртләнеп, сугышның тиздән бетәчәген, Совет Армиясенең дошманны һичшиксез тар-мар итәчәген сөйләп китә, бер уңайдан армиягә, Гомәр кебек, менә дигән егетләр үстереп биргән ата-аналарга рәхмәт тә әйтә һәм иң ахырда, бер авыз русча сүз белмәгән Мәрьям абыстай өчен генә булса кирәк, Гомәрнең аркасыннан кагып, үзенчә татарчалап:

– Улан якши, улан якши! – дип куя.

Мәрьям абыстайның күңеленә бу сүзләр аеруча ошады. Аның ана йөрәге улы турындагы һәрбер сүзне, улына булган һәрбер карашны ычкындырмыйча аулап тора иде. Сүзләр аның өчен аңлаешлы булмаса да, ул бу кешеләрнең нинди тавыш белән сөйләүләреннән, аларның күз карашларыннан Гомәргә булган дуслык, якынлыкны ачык сизә, күңеле аның бу кешеләргә карата рәхмәт белән тула, эченнән: «Иптәшләре, Ходайга шөкер, әйбәт кешеләр икән!» – ди һәм улының киләчәк гомере, саулыгы өчен тынычлану тоя.

Ахырда алар яныннан кызыл фуражкалы станция начальнигы үтеп китә. Бераздан паровоз, нечкә трубасыннан еш-еш ак пар чыгарып, дәртләнеп шаулый башлый. Менә эшелон буенча төрле урыннан: «Вагоннарга!» – дигән команда ишетелә. Гомәрләр тирәсенә җыелган солдатлар, ашыгып, вагоннарына таралалар. Поезд кузгалыр алдыннан аерылышуның иң соңгы минутлары, гадәттә, кешеләр өчен аеруча авыр була. Бу вакытта кешеләр сүзсез калалар һәм,

аерылышуның никадәр газаплы булуын бөтен йөрәкләре белән сизсәләр дә, паровозның тизрәк кычкыртуын көтәләр. Гүя кеше, үз-үзенә исәп бирмәстән, тизрәк шул аерылышу газабыннан котылырга тели. Гомәр дә, Галимҗан абзый да, Мәрьям абыстай да, бер сихерле көч тарткан шикелле, алга, эшелон очына сүзсез карап торалар. Ниһаять, паровоз озын итеп кычкырта һәм, көч җыйгандай, бераз бик куәтле шаулап тора. Соңра поездны акрын гына урыныннан кузгата... Бирешмәскә тырышкан вагоннар сыкранышып рельслар өстеннән тәгәри башлыйлар. Кемдер вагон ишегеннән:

– Сәлимов, без киттек! – дип кычкыра.

Гомәр бу очрашу дәвамында беренче тапкыр бик җитди чырай белән:

– Йә, әти! – ди һәм әтисенә ике кулын суза. Галимҗан абзый улының кулларын тота төшә.

– Хуш, улым! Алла хәтәр-хәвефләрдән үзеңне сакласын. Яңадан исән-сау күрешергә язсын! Хатларыңны еш яза тор.

Соңра Гомәр әнкәсенә карый. Ул, татар улларына хас тыйнаклык белән, бары күрешмәкче генә булган иде. Ләкин әнисенең шундый бер тирән газаплы мәхәббәт белән сүзсез караган яшь тулы күзләрен очраткач, ирексездән алга омтылып, аның кечкенә, җиңел гәүдәсен күкрәгенә кыса. Берничә секунд дәвамында ул нәкъ йөрәге турында әнисенең җылы сулышын тоя, аның хәлсез тавыш белән пышылдап күкрәге эченә әйткәндәй: «Улым, улым!» – диюен ишетеп кала, ләкин поезд тавышыннан башка сүзләрен аера алмый... Ниһаять, ул, әнисеннән сак кына аерылып, ераклашып барган вагон артыннан йөгерә. Иптәшләре, кул биреп, аны вагон эченә тартып алалар. Инде вагон ишегенең кырыена бөтен гәүдәсе белән туры басып артына караганда, аның йөзе гаепле сыман, кичерү сорагандай, елмая, кысылып караган күзләре дымланып ялтырыйлар төсле.

Поезд кызулый. Вагон тәгәрмәчләре рельс ялгаулары өстеннән тигез тавыш белән сугып үтүләрен ешлата баралар.

Мәрьям абыстай улының бөтен сыны күренеп барган вагон ишегенә йотлыгып карый. Ләкин аның күз аллары томанлана. Вагоннар, бер-берсе белән кушылып, бик кызу алга шуган тоташ бер кызыл стена булып күренә башлыйлар. Гомәр шул тоташ кызыллык эчендә югала. Ахырда бу кызыллык, сыегаеп, чуар бер шәүләгә әйләнә, һәм поезд кире артка таба чапкан шикелле була.

Авылдан станциягә таба йөгерә-йөгерә Заһидә белән Зәйнәп киләләр. Заһидә өстендәге җәйге пальтосының югары төймәләрен ычкындырган, башындагы ак яулыгын кулына алган...

Аның кыска калын толымнары сүтелә төшеп, чәч бөртекләре җилдә очкалыйлар, кыр җиленнән һәм кояштан янып каралган киң маңгаена, борын очына тир бөртекләре чыккан.

Ул поездның киткәнен белә. Ул аның тавышын ишетте. Кызыл эшелонның сырт артына яшеренүен күрде. Гомәрне алып киткән поездның ак төтеннәре, вак болытлар булып, станция өстеннән акрын гына йөзеп үтәләр —ул шуларны да күреп бара. Ләкин бара, Гомәрнең китүен, аны күрми калуын бик яхшы белсә дә, юри тукталырга теләмичә, тыеласы килмәгән бер ярсу белән аскы иренен тешләп һаман бара. Бу баруда үз-үзенә хисап бирмичә, чынлык белән килешергә теләмәү тискәрелеге сизелә иде. Чыннан да, аның Гомәре шундый көтмәгәндә кайткан иде, аның Гомәре шундый тиз китеп тә барды. Ул, Заһидә, аны күрми дә калды. Болар бар да дөрес бит! Ләкин ни өчен дөрес?.. Ни өчен дөрес?

Менә аларга станциядән кайтып килгән туры ат очрады. Галимҗан абзый, кызларны күрүгә, атны туктатырга кушты. Зәйнәп йөгереп әбисе янына килде. Заһидә тарантастан шактый читтә туктады. Галимҗан абзый аңа карау белән кызның йөрәгендәниләр кайнаганын бик яхшы сизеп алды. Ул, йомшак тавыш белән ата булып, бары:

– Кызым, Заһидә, утыр безнең янга! – диде.

Заһидә әүвәл башын селкеп куйды, соңра кискен генә бары бер сүз ташлады:

– Кайтмыйм!

Галимҗан абзый артык сүз әйтүнең урынсыз икәнен белә иде. Ул кузладагы малайның аркасына акрын гына төртеп куйды:

– Әйдә, балам, кузгал!

Алар кузгалып киткәч, Заһидә янә бераз бара төшеп, юл буена чирәмгә утырды. Ул беркемгә үпкәләми дә, беркемгә ачуланмый да иде. Хәтта сөйгәне Гомәрне күрми калуның никадәр үкенечле булуы турында да юньләп уйламый иде. Ул бары йөрәге төбеннән күтәрелгән, бөтен тәне буйлап йөргән тиле ярсуны баса алмыйча газаплана. Ул янындагы үләннәрне йолкып-йолкып ала, аларны тешли яки калтыранган бармаклары белән бик вак итеп өзгәли. Янә ул һаман бугазына күтәрелгән төерне кире йота алмаудан гаҗиз иде. Ул тырыша, ачу белән башын селкеп куя, аскы иренен тешләп тора, ләкин юк – төер һаман бугазына килә. Ахырда ул башын кинәт тезләре өстенә сала һәм һичбер нинди тыелусыз, юка пальтосы аша түгәрәкләнеп, тыгызланып торган иңбашларын калтырата-калтырата, елап җибәрә.

Икенче көнне Галимҗан абзыйның йортында гадәттәге тормыш, үз ярлары эченә кайткан елга кебек, акрын гына ага башлады. Ләкин бу тыштан гына шулай иде. Асылда өй эче Гомәрнең күзгә күренмәс рухы белән тулы кебек, һәм кешеләр, көндәлек эшләрен эшләп,

тыштан бернәрсә хакында уйланмыйча тыныч кына йөргән төсле күренсәләр дә, шул рухның әсирлегеннән чыкканнары юк иде. Аларның күңел күзләре алдында Гомәрнең җанлы кыяфәте һаман басып тора, башларыннан аның турында уйлау чыкмый, өйнең җиһазлары, Гомәрнең үзен үзләрендә саклаган кебек, аның булуын, аның кайда утыруын, нәрсәгә тотынуын искә төшереп торалар. Инде Гомәрнең өстәл өстендә онытылып калган портсигары барысына да, бигрәк тә Мәрьям абыстайга, бик серле мәгънәгә ия булган хикмәтле бер нәрсә булып күренә. Портсигар турында сүзләр күп була һәм аның онытылып калуын бөтен күрше-тирә белән Гомәрнең исән-сау әйләнеп кайтуына юрыйлар. Мәрьям абыстай һәркемгә бер тапкыр күрсәтеп чыкканнан соң, бу зат нәрсәне каядыр, һич кеше күзе төшмәслек җиргә яшереп куя.

Галимҗан абзыйның гадәтендә хыяллану булмаса да, ул да улы турында уйланудан туктамый иде. Гомәр аңарда, ике елдан артык вакыт эчендә бары бер генә сәгатькә күренеп китүенә карамастан, бик яхшы тәэсир калдырган иде. Ул аңа бое-сыны белән өлгереп җиткән, акылга утырган, холкы күркәм булып камилләшкән чын ир-егет булып күренде. Исән-сау кайтса, үзенә тиң торырлык, гаиләсенең яхшы исемен сакларлык, бәхетле тормыш төзи алырлык кеше булуына ышанасы килде. Шул уңай белән ул Заһидә турында да уйланып куйды.

Камилә килендә Гомәрнең кайтып күренүе сүнеп барган өметләрен яңадан тергезде. Ике елдан бирле хәбәре булмаган ире Фатих исән-саудыр төсле булып тоелды. Аның да шулай көтмәгәндә кайтып керүенә ышанасы килде, һәм Камилә ятса да, торса да, өзелеп сагынган Фатихын ничек каршы алуы, нинди сый-хөрмәт күрсәтүе, нинди назлар белән куштанланып сөюе турында уйлаудан тыела алмый иде.

Мәрьям абыстай исә, бичара, Гомәрнең һәр сүзен, һәр карашын, һәр хәрәкәтен күз алдыннан һич югалтмаска тырыша, улының җанлы кыяфәте тирәсендә әйләнеп йөргән шикелле, һаман аны тулырак беләсе, ачыграк итеп күрәсе килә. Шуңа күрә дә вакыт-вакыт Мәрьям абыстайга улы турында нәрсәнедер белми калгандай, ниндидер сүзен хәтерләп бетермәгәндәй тоела. Ул Галимҗан абзыйдан сорашырга бераз шүрли, ләкин килене Камиләне бер дә тынычлыкта калдырмый. Һич көтмәгәндә ул:

– Килен балам, Гомәрем ничә чынаяк чәй эчте әле? —дип сорап куя.

Яки бераздан борчылып:

– Килен, Гомәрем катыкны яратып ашадымы икән? – ди.

Яки уйланып йөри-йөри дә:

– Килен, Гомәр нәрсә диде әле? – дип, Камилә һич хәтерләмәгән нәрсәне белергә тырышып азаплана.

Шулай да вакыты белән аның әрнеп эче поша башлый. Гүя Гомәр кайтмаган да һәм ул аны күрмәгән дә шикелле булып тоела. Мондый минутларда Мәрьям абыстай сүзсез уйчанлыкка төшә, хәлсез бушлык аны янә акрын гына йота башлаган кебек була. Шундый минутларның берсендә ул картыннан кыюсыз гына:

– Син, кичә Гомәрнең кайтуы төш идеме, әллә өн идеме? – дип сорый.

Галимҗан абзый карчыгына кызганып карый, ләкин йомшак кына елмая һәм дәртләндерергә теләгәндәй:

– Өн иде, карчык, өн иде! – дип кычкырып куя.

Мәрьям абыстай, юату ишеткән бала кебек, тынычлана. Ул, өй түре тәрәзәсенә барып, тимер юл буена карый. Менә аның каршында карт юкәләр ышыгына яшеренгән кызыл түбәле станция, сарыга буяган җыйнак каралтылар һәм станциядән ике якка сырт буйлап еракка, бик еракка сузылып киткән тимер юл... Станция буш... Көмеш дилбегә шикелле ялтырап яткан тимер юл тыныч... Авылның кырыеннан ук киң иген кыры башлана. Яшь, сылу арышларның салмак кына баш чайкавы, кара күләгәләрнең бер-берсен куып йөгерешүе шикелле, тимер юл аша үтеп, якты офыкка китеп югала. Күк аяз. Ерак кырлар түрендә күгелҗем сыек томан. Бу томан эчендә исәпсез күп энҗе тузаны йөзгән шикелле, җем-җем килеп, күзләрне кытыклап тибрәнә... Һәм күңел әнә шул нурлы томан артына китеп югалган яшел кырлар түреннән ерактагы поездның дәртле кычкыртып килеп чыгуын тоеп тора.

Мәрьям абыстайның иреннәре акрын гына кыймылдыйлар:

– Кайтыр күз нурым, кайтыр!

*1944*

**Ялгыз каз**

Немецлардан азат ителгән бер авылда бер каз күрдек. Гаҗәпләнмәгез, тере каз иде. Башы соры, муены белән түше ак, канатлары янә соры – безнеңчә ала каз була. Җитмәсә үзе ана каз икән...

Әгәр безнең солдатлар Калинин урманнарында тәвә кошын очратсалар, бу кадәр гаҗәпләнмәсләр иде: меңләгән авылларны фашистлар коллыгыннан азат итеп, безнең беренче тере каз күрүебез иде. Шулай булды шул, Рәсәй казы немец илбасарларының ач аппетитларын котырткан майлы калҗа булды. Әйтерсең казлар өстенә үләт явы килде – аларны йөзләп-меңләп кырдылар, күп районнарда аларның нәселе дә калмады.

Шуңа күрә нindидер могҗиза белән бу авылда сакланып калган бердәнбер ала каз безнең солдатларда зур кызыксыну тудырды. Барысы да аны бик тиз күреп алдылар. Һәркем, аз гына

булса да тукталып, аңа сокланып карый торган иде. Олырак яшьтәге солдатлар исә, аның тирәсенә җыелып, тыныч тормыш турындагы истәлекләрен бер-берсенә сөйләргә яраталар иде.

Ала каз үзе дә акрынлап безнең солдатларга ияләште, тора-бара беркемнән курыкмас, качмас булды, ә кайберәүләр белән хәтта дуслашып та өлгерде... Соңра ул кинәт кенә безне ташлады, безне онытты, китте бездән...

Ничек булды соң бу?

Ала казның хуҗасы ялгыз торучы Маша исемле бер хатын иде. Машаның ире фронтта, ә җитеп килгән бердәнбер кызы шәһәрдә эштә иде. Машаның әнә шул ялгыз казыннан башка янә ике бәрәнле ак кәҗәсе һәм янып торган кып-кызыл мәһабәт әтәч җитәкчелегендә биш тавыгы да бар. Болар барысы да ялгыз Маша өчен йорт байлыгы гына булмыйча, аның күңелен юаткан гаилә дә иде. Алар арасында татулык зур, ә Машаның яратуы һәм кайгыртуы барысына да тигез төшә. Ләкин җәй көннәрендә бу гаиләгә гел генә бергә булырга, чүкердәшеп бергә вакыт үткәрергә туры килми. Һәр көн ак кәҗә ике бәрәнен ияртеп иртән иртүк көтүгә китә, аның артыннан Маша үзе, күршеләренә казы белән тавыкларын карый торырга кушып, кыр эшенә юнәлә. Биләмдә йөреп өйрәнгән кызыл әтәч тә тавыкларын ияртеп күбрәк урамда яки кеше абзарлары артында йөрергә ярата... Йортта бары ала каз гына кала. Ул көн буена ялгыз, һәм кичкә кадәр аның тавышы чыкмый. Йә ул ишек төбендә башын сыртына салып йоклап ята, йә йорт алдында бәбкә үләнен ялкау гына йолкып әрле-бирле йөренә, тагаракка салып калдырган суны килеп борыны белән шапырдатып ала, яисә кая барырга белмәгәндәй, бәрәңге бакчасына кереп китә дә, түтәлләр арасыннан муенын сузып, башын әле бер якка, әле икенче якка кырын салып, нәрсәдер көткәндәй, озак кына каранып тора.

Бу җәйге озын көндә берүзе калып вакытын үткәргән ялгыз каз нәрсәләр турында уйлый, күңелендә аның нинди моңсу, нинди сагыш ята? Кем әйтә алсын, аның кайгысын кемнең тыңлаганы бар? Әмма бичара казның ялгызлыктан эче бик поша булса кирәк, һәм бу бер дә гаҗәп түгел.

Менә яз килде. Дәртле кояш кытыклап уяткандай, табигать тирләп, көлеп күзен ачты. Бөтен җан ияләрендә эшлекле хәрәкәт, куанычлы ыгы-зыгы башланды. Җир өсте көннән-көн үсә, куера барган яшь үлән белән түшәлде һәм кояшка карап йөзләрен ачкан хуш исле нәфис чәчәкләр белән бизәлде. Ул чәчәкләргә, билен буган, аякларына сары итекләр кигән яшь кияүләр төсле, уңган чая бал кортлары килеп кундылар... Ак, сары, кызыл-чуар купшы күбәләкләр, туй вакытында яшь килен тирәсендә куштанланып йөргән кызлар шикелле, бал корты белән кавышкан чәчәк әйләнәсендә уйнаклап-талпынып очалар. Сылу сыерчыклар, назлы

сандугачлар, иркә кәккүкләр, туйга чакырылган җырчылар кебек, су буендагы куе тирәкләрдә туктаусыз сайрап торалар. Җитез сабан тургайлары, такмаклап биюче егетләр сыман, нурлы һавадан төшмичә, сайрый-сайрый, сызгыра-сызгыра җилпенәләр.

Бу туйда берәү дә ялгыз түгел, һәр җан иясенең ише бар. Һәр җан иясе ана була, бала үстерә. Әнә кайбер кошлар инде симез кортларны сыртларыннан тешләп ояларында чыр-чу килгән зур авызлы, ялангач башлы чебиләренә ташыйлар. Менә Машаның ак кәҗәсе берьюлы ике бәрән китерде. Бәрәннәр, аяклары җиргә тияргә өлгермәс борын, ишегалдын бер итеп сикереп, чабып йөри башладылар. Карт кәҗә, «тапкач, баланың шундыен табарга кирәк!» дигәндәй, горурлы мактану белән дөньяга карый, тик масаеп сакалын гына сыйпап куймый. Әнә тавыкларның җыйнавына берәү булса да, үз-үзенә исе китеп йөргән тәкәббер әтәчләре бар. Ә ала каз ялгыз, аның үз ише юк. Ул күкәй дә сала, бала да чыгара алмый. Башкаларның бәхетле яшәүләрен, үзенең шундый аяныч хәлен сизгән казның эче пошмыймы соң? Һичшиксез, эче поша, йөрәге яна торгандыр.

Маша эштән кайткач, кичен, ишек төбенә утырып, кәҗәсен, тавыкларын янына җыеп ашата. Ала каз да шунда була. Тик ул сөйләнүдән бушамый. Әрсез тавыклар аның тирәсендә бәргәләнеп йөреп, бер-берсенең авызыннан өзеп орлык чүплиләр, ә ул һаман сөйләнә. Дәртсез тавыш белән, муенын җыерып, мескен булып сөйләнә, үзе әледән-әле килеп Машаның аякларына ышкына. Гүя ул озын көн буена ялгыз булуыннан, беркемнең дә аңа сүз катмавыннан, башкалар үз ишләре, балалары белән гамьсез чүкердәшеп вакыт үткәргәндә ул күңелсез авыр уйларга чумып, эч пошудан үзен кая куярга белмичә аптырап йөрүеннән, кыскасы, үзенең бәхетсезлегеннән зарлана.

Маша аңа кызганып карый, сөеп, юатып дәшә:

– Җитәр инде, юләр, җитәр! Ач каласың ич! – ди. Соңра итәгенә алып башыннан сыйпап сөя һәм кулыннан ашата башлый.

Әнә шулай ялгыз казның көннәре бертөсле генә үткән чакта, бу авылга безнең часть – фашистларны куып алып киткән фронт артыннан ияреп баручы аерым тәэминат ротасы кереп урнашты. Асылда сугыш үзе бу авылны читләтеп узган иде һәм немецлар киткәннән соң шактый вакыт узгач кына аның урамнары, халык тарафыннан зарыгып көтеп алынган безнең гаскәрләр белән тулып, җанланып китте.

Авылның кинәт болай бертөсле кешеләр белән тулып китүе – немецлар вакытында «идән асты» хәлендә яшәгән ала казда борчылулы кызыксыну тудырды. Ул, хәтәр бер эш көткәндәй башын кырын салып, җитди чырай белән үткән-сүткәннәргә карап тора башлады. Ләкин никадәр сак һәм җитди каранмасын, бу солдатлар кырык беренче елның җәендә авылга кинәт

«хальд, валд, һау, һау» дип ямьсез, ят тавышлар белән кычкырып шаулап килеп кергән, муеннарына элгән кара саплы автоматларыннан тиктомалга уңга-сулга пуля сиптергән, кызарып бүртенгән чырайлы, акайган күзле солдатларга һич тә охшамыйлар иде. Бигрәк тә авыл кешеләре һәм хатын-кызлары теге вакытта ул солдатлардан котлары алынып качкан булсалар, хәзер бу солдатлар тирәсенә үзләре төркем-төркем булып җыелалар, сөйләшәләр, көлешәләр иде. Каз үзе дә, кайчандыр бик куркытылган булуына карамастан, ничектер йөрәге төбендә тынычлык тоя, гүя ул да кемнең кем булуын сизенә иде.

Машаның да өенә өч солдат урнашты. Аларның берсе итекче, икенчесе тегүче, өченчесе Иван-повар иде.

Ала каз ишек төбеннән китмичә бу өч солдатны җентекләп күзәтә башлады. Чамасыз озын, очлары орчык очыдай тырпаеп торган кара мыеклы итекче кечкенә өстәле, күн төпле урындыгы, калыплары һәм бер бәйләм иске ботинкалары белән чоланга урнашты. Урнашу белән ул үзенең эшенә кереште. Авызын тутырып вак кадаклар каба да, чүкеч белән шуларны берәмләп ботинка төбенә кага башлый. Какканда авызын әле бер якка, әле икенче якка кыйшайта һәм кара мыегының очлары әле бер колагына, әле икенче колагына тия язып кала... Ул бер дә күтәрелеп карамый һәм бер-ике тапкыр тартып беткән тәмәке төпчеген сүндермичә казның аркасына да ташлады. Тик бер генә кат башын күтәреп:

– Что, гусак?! – дип куйды.

Итекче казга ошамады.

Тегүче дә әллә нинди сәер кеше иде. Ул күзлеген киеп ала да, бөкрәя төшеп, аягы белән бер машинаны әйләндерә башлый. Әйләндерә-әйләндерә, ә машина һич урыныннан кузгалып китә алмый. Аның да бу «мәгънәсез» тырышуын карап тору каз өчен кызык түгел иде.

Иван-повар исә бөтенләй башка тәэсир калдырды. Менә ул – киң, таза гәүдәле, янып торган шома битле —ак калпак, ак алъяпкычтан җитез атлап ишектән килеп чыкты. Чыгу белән казны күреп алды һәм туктала биреп:

– Эхи, каз! – диде, соңра бөтен бите белән җәелеп елмаеп: – Исәнмесез, иркәм! – дип дәште.

Ала каз да, җавап биргәндәй, кыска гына:

– Ког! – дип куйды.

Алар бер-берсенә беренче караштан ук ошадылар. Повар казга сокланып, каз исә поварга ышанып карый. Менә повар казны муеныннан йомшак кына тотып күтәрә һәм:

– Җиңелсең, иркәм, җиңелсең, яхшылап ашатасы бар үзеңне, – ди.

Каз, поварны аңлагандай, җанланып сөйләнә башлый.

– Кый, кый, ког, ког! – ди һәм Машага назланып өйрәнгән гадәте буенча поварның аяклары арасыннан бер-ике тапкыр ышкылып үтә.

Шулай итеп, алар дуслашып та китәләр.

Безнең часть бу авылда озак торасы булганга күрә, Машаның бәрәңге бакчасы артына, ачык җиргә тактадан җәйге кухня ясадылар.

Иван-повар көн дә иртә белән кухняга киткәндә, ала каз да аның артыннан ияреп бара. Үз тиңе белән бергә баргандай, ава-түнә атлап, туктаусыз сөйләнеп бара. Хис белән сөйли кебек, акрын сөйләгәндә муенын җыера, тавышын күтәргәндә муенын да бөтен озынлыгына сузып җибәрә. Иван, дустына игътибарсыз булып күренмәс өчен:

– Ә, шулаймыни? Кара син аны! Дөрес лыгырдыйсың, дөрес! – дигән була.

Кухняга килгәч, ул аңа калган ботканы такта өстенә салып бирә, каяндыр табылган немец каскасына су да салып куя. Каз ботканы ашый, суны эчә, ә аннан тамагы туеп хушлангач, яшел чирәм уртасына чүгәләп, борынын канаты астына тыгып, озак кына йоклап та ала. Торгач, поварның барлыгын белергә теләгәндәй, кухня ишеге төбенә килеп карый. Шуннан соң кухняның хуҗасы сыман муенын сузып, кырын-кырын каранып әрле-бирле йөренә башлый. Аның файдасы да тими түгел – бер генә этне дә ул кухняга якын җибәрми.

Аш өләшкән вакытларда исә ул котелок күтәреп килүче солдатларны башын текә тотып, дәртләнеп кычкырып каршы ала.

– Кыйгак, кыйгак! – ди. Үзенчә «рәхим итегез!» диме инде, – белмим!..

Солдатлар да җавапсыз калмыйлар, ерактан ук көлешеп дәшәләр:

– Ә, повариха иптәш, аш өлгердеме?

– Йә, бүген нәрсә белән безне сыйлыйсыз?

– Менә син булыша башлаганнан бирле аш бик тәмле булып китте бит әле!

Ә кайбер шаяннары:

– Иван, син моның башына ак калпак кидерер идең! – диләр.

Кайчак исә каз тирәсенә солдатлар җыелалар. Иван-повар да кухня эссесеннән тирләп-пешеп, аз гына һава алырга дип чыккан була. Ул түгәрәк уртасына басып, казга карап үзенең поварлык осталыгы турында кәефләнеп сөйли башлый:

– Мин, – ди, – элек ресторанда эшләгәндә кош итләреннән иң нәфис, иң затлы ашлар әзерли идем. Әйтик, кыздырылган күркә яки җимеш белән тутырган тавык бик шәп булып чыга иде. Ә менә бу сары аякның ите инде, үзегез беләсез, иң мактаулы симез итләрдән санала. Әйтик, мичтә пешерелгән әче кәбестә белән, никадәр симез булса да, җиңел ашала. Янә, мае

агып торган койрык төбе изгән бәрәңге боламыгы белән, керәнләп бик шәп төшә... Нәрсә, дөрес түгелме әллә, чекерәеп карап торасың?!

Чыннан да каз, башын кырын сала биреп, Иван-поварга һәм аның кулындагы зур, үткен кухня пычагына бик дикъкать белән карап тора. Гүя ул поварның нәрсә турында сөйләвен төшенә кебек, ләкин аңарда повар кулындагы зур пычактан һәм аның менә хәзер керәнләп ашардай булып сөйләнүеннән курку сизелми. Каз үзенең дөньяга нәрсә өчен яратылуын белә төсле һәм шул ук вакытта хәзер үк йолкынып мичкә кермәсенә дә нык ышана. Ул поварның мактавын раслагандай:

– Ког! – дип куя.

Повар:

– Ә шулаймы, дөрес әйтәмме? – ди һәм казның борыныннан тотып ала. Каз артка тартылып ычкына, аннан муенын сузып, батыраеп, кыйкылдап поварга һөҗүм итә. Повар кулларын бутап казның муеныннан эләктерергә тырыша, ләкин аның муены елан җитезлеге белән боргалана, бер озыная, бер кыскара, поварның әле бер ботыннан, әле икенче ботыннан эләктереп, борып ала. Ахырда повар каршы тора алмыйча кача башлый, каз исә аның артыннан кухняга кадәр куып китә... Солдатлар рәхәтләнеп, шаулап көлешеп калалар.

Соңра алар кич белән бергәләп өйгә кайталар. Көн буе бергә эшләп арыган ике дус шикелле, повар кулларын артка куеп, каз салмак кына ава-түнә атлап сүзсез генә кайталар.

Шулай итеп, безнең солдатлар аларны һәрвакыт икесен бергә күрергә өйрәнделәр.

Озын фронт юлында кайчан шулай берәр хайван (күбесенчә этләр, яки хуҗасыз калган кәҗә, тай кебек йорт хайваны да) хәрби частька ияләшеп, ияреп китүчән була. Чөнки солдат җан иясен фронтта башка һичбер җирдә яратмаган шикелле ярата, һәм хайван үзе дә моны сизә булса кирәк; шуның өстенә ул солдатлар тирәсендә һәрвакыт тук булып йөри. Табигый инде, ялгыз каз да, һәрбер солдаттан иркәләп карау, яратып дәшү сизеп торганга күрә, шулай безгә бик нык ияләште. Ала каз чыннан да бик үзгәрде, элекке кебек буш калган өй тирәсендә көн буена ялгыз моңаеп, бер җанлы тавыш ишетергә һәм сүз кайтарырга мохтаҗ булып йөрми инде. Аңа дәрт керде, ул көрәеп, матурланып китте.

Ләкин көннәрдән беркөнне ала каз поварга иярмәде, кухняга бармыйча өйдә калды. Бу хәл поварны шактый гаҗәпләндерде. Иртәнге ашны өләшкәннән соң, ул кызыксынып, өйгә кайтып килде. Ала каз исән-сау һәм элеккечә өй ишеге төбендә ялгызы басып тора иде. Повар аны чакырып карады, бераз үпкәләп, шелтәләп тә алды, ләкин каз аның сүзләренә һич колак салмады; ул ни өчендер тын һәм уйчан иде.

Ул көнне кухняга килгән солдатлар да казның юклыгыннан аптырап калдылар, һәркайсы поварлан:

– Иван, озын муенлы ярдәмчең кайда? – дип сорый торган булдылар.

Иван-повар ала казның кинәт болай үзгәреп китүен берничек тә төшендерә алмады. Ә казның болай үзгәрүенә бик җитди бер сәбәп бар иде ул да булса, мич артыннан вакыт-вакыт ишетелеп куйган нечкә бер таныш тавыш иде. Бу шундый җанга якын тансык тавыш казның йөрәгенә төште, ул берьюлы бу тавыш белән сихерләнде һәм дөньясын онытып, ишек төбеннән беркая китмичә, бары шул нечкә тавышның ишетелүен генә көтеп тора торган булды.

Маша төшке ашка кайткач, мич артына кереп, нәрсәдер актарына башлады. Мич артыннан чыр-чу иткән нечкә тавышлар һәм бу тавышларны басып берәүнең «кор-кор» диюе ишетелде.

Каз бичара «инде ни күрәм!» дип тын алырга да куркып тора иде.

Менә берзаман мич артыннан озак вакыт ояда утырып чырае агарган кара тавык яман кабарынып, Машаның аяк тирәсендә әйләнә-әйләнә, «кор, кор» дия-дия килеп чыкты. Машаның алъяпкычында тавыкның чебиләре иде. Ул аларны йорт алдына чыгарып, яшел чирәмгә җибәрде.

Ләкин каз ни күзе белән күрсен, яшел чирәмдә тавык чебиләре түгел, ә каз бәбкәләре иде. Менә алар биш бәбкә нечкә тәпиләренә чак басып, әле алга, әле артка таба чайкалып торалар. Алар шундый кечкенәләр, борыннары үтә күренерлек шундый юка һәм якты сарылар, түп-түгәрәк башларының ике ягында, тамызып куйган ике сумала тамчысыдай, кара күзләре елтырыйлар, ә канатлары шундый кечкенәләр, әйтерсең юри генә ябыштырып куйганнар. Алар барысы да йомшак сары мамыктан гына әвәләп ясалган кебекләр һәм аз гына җил иссе исә хәзер очып китәрләр төсле... Алар көн яктысына карый алмыйча башларын боргалаган булалар, нечкә генә тавыш белән:

– Ти, ти, ти, пип, пип! – диешәләр.

Бу күренештән ала каз тәмам таңга калды. Ул бәбкәләргә карап бөтен барлыгы белән йотылган, һич айный алмаслык булып сихерләнгән иде. Бичараның йөрәгендә бу могҗизалы күренештән нинди хисләр уянды икән? Ничек итеп, нинди хәрәкәт, нинди тавыш белән ул аны белгертә алсын! Әгәр каз кеше кебек булса иде, һичшиксез, бу минутта аның ике күзеннән сөенеч яшьләре мөлдерәп агып киткән булыр иде.

Каз түгел, без дә бу эшкә гаҗәпләндек. Дөрес, тавык астында каз бәбкәсе чыгарып булуын без белә идек, ләкин менә каз йомыркаларын Маша кайдан алган – монысы безнең өчен табышмак иде. Бөтен районга берүзе торып калган ала казның чебиләнерлек йомырка салып

бирүе мөмкин түгел, чыннан да каян табылган ул йомыркалар? Иван-повар – ярый әле ул каз турындагы бөтен хәбәрне белеп тора – аш өләшкәндә безгә бу хәлнең серен сөйләп бирде. Шулай, яз башында немецлардан азат ителгән авылларына кире кайтып баручы бер эшелон колхозчылар якындагы станция аша үткәннәр. Йорт-җирләреннән аерылып торуга карамастан, аларның үзләре белән бергә саклап алып кайтып килгән мал-туарлары да, кош-кортлары да булган икән. Уңган Маша менә шулардан каз йомыркаларын алып та калган инде. Машаның бәхетеннән, йомыркалар барысы да яраклы булып, әнә кара тавык утыра торгач, һәркайсыннан берәр бәбкә дә дөньяга борынлап чыкты.

Инде ала каз шул бәбкәләрне күргән көннән алып Иван-поварны да, кухняны да, безнең барыбызны да ташлады, ничектер безне күрмәс һәм сизмәс булды.

Ул көннәр буена бәбкәле кара тавык тирәсендә әйләнеп йөри башлады. Тавык бәбкәләрне уяу саклый, казны түгел, тавыклардан берсен-бер якын җибәрми. Һаман кабарынып, туктаусыз коркылдап, тирә-ягына ялт-йолт каранып кына тора. Шуңа күрә каз читләтеп кенә карап йөрергә мәҗбүр, әмма үзе тавыкның бәбкәләргә чын ана булмавын сизенә булса кирәк... Чыннан да, тавык бәбкәләрне су буена илтми, рәхәтләнеп йөздерми, чумып уйнарга, башлары белән суга кадалып, койрыкларын текә күтәреп торырга өйрәтми, ә үлән йолкып ашарга өйрәтәсе урында җир тибеп, җыен юк-бар нәрсә чүпләргә кыстап маташа. Юкка гына бәбкәләр зәгыйфь, аңгыра булып үсмиләр. Казның моңа бик эче поша, ахрысы – кайчак ул үлән йолыккалап, бәбкәләрне үз янына чакырып карый. Ләкин бәбкәләр ишеткәнче, кара тавык зәһәрләнеп килеп җитә. Бәлкем каз юньсез тавыкка кирәген биргән дә булыр иде, тик бәбкәләр хакына ул чигенә.

Вакыт үтә. Ничек кенә булмасын, бәбкәләр үсәләр. Менә аларның сары мамыклары агара башлады, койрыклары очына нечкә генә каурыйлар чыкты, муеннары да шактый озыная төште. Алар инде тавыкның канаты астына сыймыйлар, таралышып яталар, йөргәндә дә һаман тавыктан читтә, үз башларына йөриләр. Тавык үзе дә элеккечә бәбкәләр тирәсендә янып-көйгән ана булган булып йөрми инде. Ул хәзер артык кабарынып та, туктаусыз коркылдап та маташмый. Тик шунда үзалдына тибенеп, бәбкәләр кая китсәләр, шулар артыннан ияреп йөргән була.

Ә беркөнне исә барыбыз да менә мондый гаҗәп бер вакыйга ишеттек: Маша иртә белән торып тышка чыкса, ала каз да, бәбкәләр дә юк ди... Кара тавык үзе гомердә бәбкәләре булмагандай кызыл әтәч янында куштанланып йөри, имеш. Маша, билгеле, курка кала. «Ах, урлаганнар икән, казларымнан яздым!» дип уйлый, ләкин шулай да ашыгып эзләргә тотына.

Менә бервакытны елга буена эзләп барса, ни күзе белән күрсен, ала каз биш бәбкәне ияртеп, су уртасында акрын гына әрле-бирле йөзеп йөри, имеш. Башын текә күтәргән ди,

әйләнә-тирәсенә гаҗәп җитди чырай белән масаеп карана ди, әйтерсең дөньяның шаһы булган, шундый горурлык ди үзендә... Машаның чакыруын колагына да элми икән, бары тик су эченнән сап-сары булып күренгән сыңар тәпиен генә селтәп куя ди.

Ничек бу хәл булган – тавык үзе бәбкәләрне ташлап киткәнме, яки туктаусыз күзәтеп йөргән каз ахырда чыдый алмыйча аларны булдыксыз ана кулыннан тартып алганмы – әйтүе читен. Һәрхәлдә, үсеп килгән ап-ак кына каз бәбкәләренең кара тавык белән һаман ишегалдында, һаман тирес өемнәре тирәсендә пычранып йөрүләрен күрү кызыксыз иде; инде алар ала казга ияреп су буена төшеп киткәч, табигатьнең кечкенә бер хатасы төзәлгән кебек булды.

Төш вакытында ала каз беренче тапкыр су күргән юеш бәбкәләрен ияртеп йортка кайтты. Аны күрергә дип барыбыз да җыелыштык... Ябыштырып куйган шикелле урыннарыннан купмый торган күзлекле тегүче белән кара мыеклы итекче дә чыкканнар иде. Хәтта, кухняда кызу эш вакыты булуга карамастан, аш чүмечен күтәреп Иван-повар да чабып килеп җитте.

Чыннан да, ала каз танымаслык булып үзгәреп өлгергән иде. Кая ул элекке шикелле һәркем белән үз булып, яхшатланып маташу! Муенын җирдән күтәрми, әле берәүгә, әле икенчегә сузылып:

– Ыссс, ыссс! – дип кенә тора.

Тик Маша белән Иван-поварны гына бәбкәләренә якын җибәрде... Иван-повар куанычыннан чыдый алмыйча:

– Әй, җан дускаем, семьялы булдыңмыни?! – дип кычкырып, җитез генә казны ике кулы белән күтәреп алды да баш түбәсеннән үбеп куйды. Каз да җиргә төшкәнче поварның борын очына төртеп алырга өлгерде. Бу тамашадан бәбкәләр дә бик яман шаулашып алдылар: янәсе, ала каз алар өчен хәзер чит түгел һәм аның белән болай шаяруны яратмыйлар.

Озак карап торганнан соң итекче дә, ниһаять, мыегын уңга-сулга сыпырып, бер бик мәгънәле сүз әйтеп ташлады:

– Мин, – ди, – моны ата каз дип торам, ул, хәерсез, ана каз икән ләбаса!..

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Шулай итеп, немецлар явыннан япа-ялгыз торып калган ала каз, Иван-повар әйтмешли, семьялы булып алды. Әгәр ала казның гомере булса, киләсе язга инде үзе йомырка салыр, үзе утырып бала чыгарыр. Машага байлык, ә аңа бер көтү бәбкәле, тигез бәхетле тормыш килер.

Хәзер исә без торган урамга яңа ямь керде. Айлы тын төндә урам чирәмендә бәбкәләрен тирәсенә җыеп ала каз утыра. Берәр кешенең якынлашкан аяк тавышын ишетүгә ул башын күтәреп тавыш бирә башлый. Йоклап яткан бәбкәләр дә борыннарын җылы канат асларыннан

чыгармыйча гына «пипелдәшеп» куялар... Аяк тавышлары тына, урам янә көмеш нурлы тынлыкка чума һәм каз тавышлары үтеп китүчене азат ителгән авылда яңадан туып килгән тормышның җанлы сулышы, куанычлы авазы кебек озатып кала.

*1944*

**Кем җырлады?**

Ватан сугышының дәһшәтле көннәреннән берсе иде.

Көзге караңгы төндә кечкенә генә җимерек станциядә ике эшелон очрашып, янәшә туктадылар. Боларның берсе тылдан фронтка яңа хәрби часть алып баручы эшелон, икенчесе фронттан тылга яралылар төяп кайтучы санитар поезды иде. Эшелоннар икесе дә, бик озын булып, гел кызыл вагоннардан торалар. Тик санитар поездының гына паровозга якын очында бер-ике классный вагоны бар, ә калганнары исә кечкенә чуен мичләр куеп җылытылган теплушкалар иде.

Станция дигән нәрсәнең үзе дә, бер генә бер каралтысы да юк – бар да җимерелеп беткән. Тик юллар буенда берничә кат юан бүрәнәләр түшәп һәм балчык өеп эшләнгән зур гына землянка ялгызы калкып тора... Бөтен станциясендә ник бер генә тычкан уты җемелдәсен — әйләнә-юнь морҗа эчедәй кап-кара. Ләкин еракка күз ташласаң, сугыш барган якта, кайдадыр офык артында ук, күк чите буйлап сузылган кандай кызыл шәүлә тибрәнә. Янамы анда берәр зур авыл, туплар атышы шулай чагыламы – моннан карап белеп булырлык түгел.

Бөтен әйләнәдә фронтка якын җирләрдә генә була торган үле тынлык хөкем сөрә. Хәтта эшелоннар башындагы ике кап-кара паровоз да тып-тын тора, әйтерсең казаннарын сүндереп, аларны ташлап киткәннәр... Эшелоннарны томалап куйганнар диярсең, берсеннән-бер көлгән, сөйләшкән тавыш та ишетелми, төшеп-менеп йөрүче дә күренми. Тик араларыннан узганда, туктала биреп колак салсаң, бер яктагы кызыл вагоннардан ара-тирә каты хырылдау, икенче яктагы теплушкалардан авыр ыңгырашу ишетелеп кала. Берәүләр соңгы тапкыр йокы туйдыралар, икенчеләр бер күз йомарга гаҗиз булып яталар, күрәсең.

...Теплушкаларның берсендә түбәнге сәкедә каты яралы яшь лейтенант – татар егете ята. Егетнең хәле авыр, уң аягы аның тездән югары киселгән, ә санитар поезды юлга чыккач, аңарда гангрена башланды. Менә бер тәүлек инде ул, ни йоклый, ни уяна алмыйча, ярым һушын югалткан хәлдә ята. Вакыт-вакыт ул аңына килә, шул чакта авыр газаптан талган күзләрен ача, янында басып торган ак халатлы шәфкать туташын күрә, аның салкын кулын маңгаенда тоя. Бер мәлгә егет үзен җиңеләеп киткәндәй хис итә, хәтта уң аягы бар, ул кычыта кебек тоела аңа... Ләкин бу хәл озакка бармый, тагын бөтен тәне буйлап ут тарала, күзләрендә бизгәк чаткысы кабына.

Бераздан егет күз кабакларын акрын гына йома һәм, һушын югалтып, яңадан эссе томан эчендә йөзә башлый. Яткан урынын да, туташның кагылуын да, хәтта шприцның очлы энәсен дә ул инде тоймый...

Шулай үлем тырнагыннан ычкына алмыйча газапланып ята егет. Врачларның өметләре аз, гангренаның никадәр хәтәр нәрсә икәнен алар яхшы беләләр. Бигрәк тә юл шартларында авыруның хәлен җиңеләйтү бик читен эш иде.

Бу кечкенә станциягә килеп туктагач, күпмедер вакыттан соң, егет тагын бер мәлгә һушына килде. Талган, инде бу дөньядан китә башлаган күзләрен ачты, вагон эченә сибелгән зәгыйфь сары яктылыкны, шул тонык яктылыкта басып торган ак халатлы шәфкать туташын күрде. Тышта вагон стенасына ышкылып кына яуган көзге вак яңгырның әкрен генә кыштырдавын ишетеп алды. Кара янып кипкән иреннәрен хәлсез ялап куйды —эчәсе, бик эчәсе килә иде аның...

Шәфкать туташы моны аңлады, алюмин кружкадан аңа бер йотым су эчерде. Егетнең рәхмәт әйтерлек хәле юк иде, ул бары аз гына җылына төшкән күзләрен туташка күтәреп, кара керфеген генә сирпеп куйды.

...Әллә шул чакта, әллә чак кына соңрак, егетнең колагына каяндыр җыр ишетелде. Татарча җыр!.. Егет, өне катып, тынып калды. Нәрсә ишетә ул, кемне ишетә? Йа Хода, аның Таһирәсе җырлый түгелме соң? Шул ич, шул, Таһирә тавышы! Кайда ул?.. Егет, үзен белештермичә, яткан җиреннән кинәт бер омтылып куйды. Шунда ук аның күз аллары караңгыланып китте, башы хәлсезләнеп, мендәр читенә авып төште. Шәфкать туташы, куркынып, тизрәк аның кулын алды, пульсын капшады. Әмма егет һушыннан язмады, дөресрәге, һичнәрсәне, һичкемне сизмәс булса да, җырны ишетүдән туктамады. Яңадан бөтен дөньясы эссе томанга йотылса да, җыр... җыр калды.

Ә бу җыр чынлыкта бар иде, ул янәшәдәге эшелонның бер вагоныннан килә иде. Әгәр теплушка белән кызыл вагонның ишекләре бер-берсенә капма-каршы туры килгән булсалар, ишек яңагына сөялеп, кулларын шинель җиңнәренә тыгып җырлап торучы кыз, ихтимал, үзе дә күренгән булыр иде. Ләкин теплушканың аз гына ачык ишегеннән ут яктысы кыздан читкәрәк, кызыл стенага тар гына сары юл булып төшкән иде.

Күзгә күренмичә, берничә адымда гына җырлап торган кыз ялгызы гына булса кирәк, чөнки бүтән беркемнең дә тавышы-мазар ишетелми иде. Ихтимал, ул төнге дежурда торадыр, шунлыктан, ахрысы, иптәшләренең татлы йокысын бозарга теләмәгәндәй, ничектер тыелып, әкренрәк җырларга тырыша кебек... Әмма аның иркен, матур, аз гына калынрак күкрәк тавышы төнге тирән тынлыкта бик ачык булып ишетелә иде.

Кыз, үзенең ниндидер яраткан көен эзлиме, бер җырны башлый да, бетермичә икенчесенә күчә, бераз җырлагач, туктап тынып тора, аннан тагын акрын гына башлап китә. Үзенә күбрәк ошаган кайбер көйләрне озаграк та җырлап куя, әмма ул кем дә булса мине ишетәдер дигән уйны күңеленә дә китерми иде, әлбәттә.

Искиткеч таныш, якын тавышны ишетеп, беренче тирән тетрәнүдән соң егетнең рухи хәлендә гаҗәеп бер үзгәреш туды: ул җырлаучының кем булуы белән кызыксынмас булды. Күрәсең, аның сүнеп бетмәгән аңы могҗиза булуына – Таһирәнең кул сузымы гына җирдә җырлап торуына ышана алмады. Хәер, кем җырласа да барыбер түгелмени, тик җыр булсын, җыр туктамасын. Татар җыры, Таһирә җыры, туган ил җыры... Аһ, моңнардан да кадерлерәк һәм ләззәтлерәк нәрсә булырга мөмкинме соң?!

...Һәм вагон стенасына ышкылып кына яуган вак яңгыр аша әкрен-ачык ишетелгән җыр, күктән иңгән ак канатлы фәрештәдәй, егетне ут эчендә яткан җиреннән сак кына күтәреп, каядыр еракка, татлы хыял дөньясына алып менеп китте. Аның хәтта тәне, һавада йөзгәндәй, җиңеләеп калды, акылы ничектер бердән яктырып китте, сизгерлеге искиткеч үткенләште. Җырны инде ул хәзер моң итеп кенә ишетмичә, гаҗәеп ачык сурәтләр тезмәсе итеп тә күрә иде.

...Менә кыз әкрен генә башлап, аннан тавышын күтәрә төшеп, сузып кына җырлый:

Сарман буйлары, ай, киң ялан,

Печәннәре җитәр бер заман шул,

Печәннәре җитәр бер заман...

Һәм егетнең күз алдына үтә ачык булып, әллә кайларга кадәр җәелеп яткан чуп-чуар чәчәкле болын килә. Үлән башларын, чәчәкләрне селкетеп, йомшак кына җил исә, имеш. Каяндыр, тургай сайрауларына кушылып, чалгы янаган тавышлар ишетелә кебек, йомшак җил кибеп яткан покосларның хуш исен китерә кебек, тик егет печән чабучылар ягына нигәдер борылып карый алмый, имеш. Ул да булмый, аның күз алдына бормаланып киткән тар гына болын юлы килә. Хәтта бер мәлгә егет үзе дә ике рәт үлән арасындагы тәгәрмәч эзеннән, җылы туфракка яланаяк баса-баса, китеп бара кебек, ә каршысына киез эшләпә кигән, таяк таянган ак сакаллы бер бабай килә кебек.

Күпмедер вакыт узгач, кызның тагын моңлы җыры ишетелә:

Кояш бата, айлар калка,

Бик ямансу шул чакта...

Һәм егетнең күз алдына үзләренең шәһәрдәге кечкенә өйләре килеп баса. Эңгер-меңгер вакыты, имеш. Өйдә әнисе ялгызы гына икән. Менә ул, ак яулык бәйләгән кечкенә карчык, ут кабызып, бисмилласын әйтә-әйтә, тәрәзә пәрдәләрен төшереп йөри, тәрәзә төбендәге гөлләрнең

кипкән яфракларын чүпләп-чүпләп ала, имеш. Өстәлдә яңа гына кайнап чыккан самавыр тора икән. Әнисе аның институттан кайтканын шулай чәй әзерләп көтә, имеш.

– Әнием, әнием! – ди егет, эченнән үксеп, һәм аның йомык күзләреннән сыгылып терекөмештәй кайнар яшь бөртекләре кипкән иреннәренә акрын гына тәгәрәп төшәләр. Шәфкать туташы кулын аның маңгаена куеп, иелеп, нидер сорый шикелле, ләкин егеткә гүя Таһирәсе дәшкән кебек тоела.

Шул чакта кыз, тирән бер сагыш белән:

Инде кемнәргә карармын

Өзелеп сагынганда... –

ди.

Һәм егет ике куллап Таһирәсенең башын күкрәгенә кыса, имеш, йөзен аның күперенке чәчләренә куя, имеш, иреннәрен аның җылы, йомшак муенына тидерә, имеш:

«Бәгырем, бәгырем, күз нурым! Нигә алай дисең, нигә елыйсың? Без мәңге, мәңге бергә ич!»

Һәм кыз, башын аның күкрәгеннән алмыйча, назланып, зарын әйтә кебек:

Сагынам үзем, юлда күзем,

Саргайды нурлы йөзем...

. . . . . . . . . . . . . . . . . .

Юк, юк, бүтән аерылу юк. Инде без бергә, дустым, мәңге бергә!.. Менә алар җитәкләшеп, ашыга-ашыга, Идел тавына менәләр, имеш. Тау бик биек икән, туктап-туктап тын алалар, кулларын җибәрмичә, сүзсез генә бер-берсенең күзләренә карап, бәхетле елмаялар, тагын кузгалып китәләр... Ниһаять, менеп җитәләр, йа Хода, нинди киңлек, нинди киңлек, нинди чиксез нур һәм ямь дөньясы бу туган җир! Шундый җиңел, шундый рәхәт аларга! Менә алар, тотынышкан хәлдә кулларын киң җәеп, таудан күтәреләләр һәм пар аккоштай елгалар, кырлар, урманнар өстеннән шул чиксез нур дөньясына очалар, очалар...

. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . .

Кыз җырлавыннан кайчан туктады, каршыдагы эшелон кайчан тавыш-тынсыз гына кузгалып китте – егет моны сизмәде. Ул инде яңадан аңына килә алмады. Ә икенче көнне санитар поезды тагын бер җимерек разъездга җитеп туктады. Кызыл теплушкадан егетнең үле гәүдәсен носилкага салып чыгардылар да юлдан ерак түгел бер калкулык өстендәге ялгыз нарат төбенә илтеп күмделәр. Күмеп беткәч, туфрак өеменең башына кечкенә фанер кадакланган казык утыртып куйдылар. Фанерга кара буяу белән егетнең исеме, фамилиясе, туган һәм үлгән

еллары язылган иде. Күмүчеләр, башларыннан салып, кабер әйләнәсендә бераз тынып тордылар да аннан барысы берьюлы вагоннарына таралдылар.

Поезд китте, ялгыз кабер торып калды.

Кинәт җил исте, биек нарат, эре яңгыр тамчыларын җиргә коеп, салмак кына башын чайкады. Күктәге салынкы соры болытлар, кемгәдер юл ачкандай, икегә аерылдылар. Шунда ук зәңгәр ачыклыктан, бәхилләшергә соңга калгандай, ашыгып кояш карады. Нарат төбендәге кабер өсте, әйтерсең егетнең җирдә калган, үлмәгән һәм мәңге үлмәячәк якты хыяллары белән кинәт нурланып балкыды.

Караңгы төндә каршы очраган эшелонның вагон ишегенә сөялеп, ялгызы гына моңаеп җырлаган кыз исә чыннан да бу егетнең сөйгәне Таһирә иде.

*1956*

**Ялгызлык**

...Шушы елның февраль аенда мин Казаннан ерак түгел Бөреле совхозына барып чыккан идем. Бу зур һәм бай бер хуҗалык, биредә нәселле кроликлар һәм кара төлке, кеш, чәшке кебек кыйммәтле җәнлекләр үрчетәләр. Совхозга минем беренче генә килүем түгел, моннан биш-алты ел элек килеп, мин биредә берникадәр вакыт торып киткән идем инде. Шуңа күрә совхоз үзе дә, аның кешеләре дә миңа бераз таныш иде.

Директорның иркен бүлмәсендә совхоз хәлләре турында сөйләшеп утырган чакта, мин шул танышлардан берсен искә төшереп сорадым:

– Әйтегез әле, Николай Михайлович, сезнең хатын-кызлардан бер белгечегез бар иде, исеме, ялгышмасам, Тамара... Тамара... Ничек кенә үзе?

– Тамара Сергеевнамы?

– Әйе, Тамара Сергеевна. Бармы ул ханым, эшлиме хәзер дә?

– Ә сез аны беләсезмени? – диде директор, минем соравыма каршы.

– Элек килүемдә ул миңа үзенең төлкеләрен күрсәтеп йөргән иде. Сезнең кара төлкеләр фермасында баш зоотехник иде шикелле ул... Дөресме?

– Дөрес, шулай... Ләкин хәзер юк ул бездә, китте бездән, күптән китте инде.

Николай Михайлович моны ничектер эчке бер кызгану белән әйткән кебек булды, һәм мин моңа, билгеле, игътибар итмичә калмадым, шунлыктан тагы да кызыксына төшеп сорадым:

– Ни өчен китте? Нинди сәбәп аркасында? Әгәр сер булмаса, бәлкем...

– Юк, сер түгел, – диде Николай Михайлович, минем сүземне бүлеп. – Ләкин аның китүенең сәбәбен бер сүз белән генә әйтеп бирү дә читен. Үзенә күрә бер вакыйга булды ул.

– Шулаймыни? Алайса сөйләгез әле! Гафу итегез, болай үтенеп, мин сезнең вакытыгызны алмыймдыр ич?

– Зарар юк, конторада эш сәгате бетте, иркенләп сөйләшеп утырырга була хәзер, – диде ул, көлемсерәп.

Чынлап та, кышкы көн сүнеп бара иде инде. Бүлмә эченә сыек караңгылык акыртын гына иңә башлады, шулай да ут кабызырга иртәрәк иде әле. Николай Михайлович, үзе әйткәнчә озаклап сөйләшергә җыенгандай, иркен креслосының артына ята төште, өстәлдә яткан «Казбек» тартмасыннан үрелеп ашыкмыйча гына папиросын алды. Бу кырыкларга җитеп килгән таза, мәһабәт кеше моннан ике-өч ел элек кенә шушындагы белгечләрдән күтәрелгән директор иде. Аның белән беренче тапкыр гына очрашып сөйләшүем булса да, ул миңа ошап өлгерде. Фасон тотып маташмый, ягъни директор икәнлеген белдереп тору кайгысыннан азат, һәрвакыт үзенең табигый хәлендә, ләкин табигый хәленә аның бәйсезлек һәм үз-үзенә ышану хас булса кирәк, һәркем белән бертөсле, алдына килүченең йөзенә күтәрелеп карарга һәм сүзенә җавап бирергә иренми, кыскасы, чын кеше һәм әйбәт директор булырга тиеш.

...Менә ул миңа ике сәгать чамасы вакыт диярлек кеше язмышы турында сөйләде. Белмим, бик мавыктыргыч итеп сөйләдеме, әллә вакыйгасы бик гыйбрәтле идеме, ләкин мин хикәянең башыннан ахырына кадәр бер тапкыр да аның сүзен бүлмичә тыңлап утырдым.

– Сез беләсезме икән, – дип сүзен башлады Николай Михайлович, – Тамара Сергеевна безгә кырык беренче елның көзендә Ленинград тирәсендәге бер совхоздан үзенең җәнлекләре белән күчеп килгән иде. Бик йончып, бетеренеп килеп җиткән иде ул... Сугыш аларны тиз килеп баса, хәтта совхозның күп җәнлекләрен ирекккә чыгарып җибәрәләр... Тамара Сергеевна соңыннан шул җәнлекләренең таралмыйча совхоз ихатасына кире борылып-борылып кайтуларын сөйләгән иде... Бары җәнлекләрнең иң тазаларын гына берничә вагонга төяп, хатын-кыз, бала-чагаларны утыртып, Тамара Сергеевнаны шуларга баш итеп тизрәк ашыктырып озаталар. Тамара Сергеевнаның ире Ленинградта бүленеп кала, китәр алдыннан алар хәтта күрешә дә алмыйлар, кыскасы, мәхшәрдән качу була бу... Өч тәүлек юлны, тупиктан тупикка күчә-күчә, өч атна киләләр, җәнлекләренең яртысы ачтан кырыла, үзләре дә ачыгып, керләнеп, бетләп бетәләр. Тамара Сергеевна өчен аеруча зур бәхетсезлек тагын шул була – юлда бердәнбер кызы чирләп үлә. Өч яшьлек баланың кечкенә мәетен каядыр юл буенда күмеп калдыралар.

...Әнә шулай килеп җитәләр алар безгә... Ләкин сугыш, үзегез беләсез, кешене ташка әверелдерде. Кешенең, бәлкем, атна эчендә чәче агаргандыр, әмма бәгыре аның, тирән сызланудан соң, эретеп койган чуен шикелле катып калды. Шуңа күрә үз башыңа төшкән хәсрәт

турында сөйләү юк, елау юк, барысы да бик тирән яшерелгән, тик нидер өзелеп теләү, нәрсәгәдер теш кысып омтылу бар... Ленинградтан килүчеләргә карап, моның шулай икәнлегенә ышанмыйча мөмкин түгел иде.

Тамара Сергеевна бездә дә кара төлкеләр фермасында баш зоотехник булып эшли башлады. Аның авторитеты үзе белән бергә үк ияреп килде: югары белемле, зур хуҗалыкта эшләп тәҗрибә алган яшь белгеч иде ул... Шуның өстенә ул чын-чыннан Ленинград кешесе иде. Ленинградта туып үскән, шунда укыган, шунда тормыш башлаган... Өс-башы да аның бүтәнчәрәк, йөреш-торышы да бүтәнчәрәк, сөйләшүе, хәтта көлүе дә бүтәнчәрәк, кыскасы, зур культура мәркәзеннән килгән кеше, әйтик, безнең ише район халкыннан үзенә генә хас ниндидер бер нәфислек, пөхтәлек һәм әдәплелек белән аерылса, бу яшь ханым да күпләрдән шулай аерылып тора иде. Ул чын, яхшы мәгънәдә, ягъни тышкы калыбы белән генә түгел, эчке җаны белән дә интеллигент кеше иде. Мин хәтта әйтер идем, бу «интеллигентлык» аңардан ничектер менә нәфис бер ис шикелле аңкып тора кебек иде. Дөрес, безнең шартларда хуш ис акрынлап бетте, һәрхәлдә, безнең борыннар сизми башлады, әмма асылда ул барыбер шундый ук культуралы, әдәпле, нечкә җанлы хатын булып калды.

Без аның Бөреле совхозында утырып калуына һич ышанмый идек. Хәер, ул үзе дә моны яшерми иде. «Сугыш кына бетсен!» – ди торган иде ул, вакыт-вакыт тирән көрсенеп, һәм артыгын әйтеп торуны кирәк тә санамый иде. Гомумән, ул башта бик аз сөйләшә иде, гүя бөтен уе аның магнитка тартылган компас теле кебек шул туган шәһәренә, анда калган якын кешеләренә төбәлгән иде. Сүзсез йөрәгендә күпме сагыш, күпме борчылу таш булып ятканлыгын аның җитди-моңсу кара күзләре үк әйтеп тора иде. Бигрәк тә блокадада калган Ленинградтан бер хәбәр дә килмәү, иренең язмышы билгесез булу аны бик изә иде шикелле. Тик күп айлар үткәч кенә һәм эш дигән шифалы дәрьяга башаягы белән чумгач кына, ул, үзенең хәле белән килешкәндәй, бераз тынычланган кебек булды. Анда да, сүз чыккан саен, Ленинградын сагынды, кире шунда кайтып, яңадан искечә яшәү турында хыялланды. Өмет, өмет! Менә нәрсә кешене яшәтә бит!

Ниһаять, көтә торгач, Ленинград блокададан азат ителде, ахырда сугыш та бетте, һәм Тамара Сергеевнаның тормышына тулы ачыклык та керде. Иренең фронтта, әти-әнисенең блокада вакытында һәлак булулары беленде. Бүтән туганнары да кайсы кая таралып беткәннәр икән. Шулай итеп, сугыш Тамара Сергеевнага иң авыр бәхетсезлек – ялгызлык бәхетсезлеген китерде. Иске өметләр сүнде, инде яңасын кем кабызыр?

Шулай да без аны үзенең Ленинградына кайтып китәр дип уйладык, ләкин ул ни өчендер китәргә ашыкмады. Туздырылган оясын кайтып күрәсе килмәдеме, яки кинәт туган бушлык

аркасында дөньясына кул селтәдеме, белмим, нәрсәдер, әмма яшь ханым күләгә төсле безнең арада һаман йөри бирде. Сүзе юк, өне юк, кечкенә бүлмәсен белә дә фермасын белә, калганы гүя аның эше түгел!

Биредә шуны әйтергә кирәк: әле сугыш бетмәс борын ук безнең җәнлек тиреләрен Америка сатып ала башлаган иде. Сугыштан соң затлы мехларга сорау тагы да артты. Ләкин Американың бик еш мода алыштырырга яраткан хатын-кызларына мехның йә ачыграк төслесе, йә тоныграк төслесе кирәк була иде. Без, билгеле, бу таләпкә яраклашырга тиеш идек. Ләкин ничек итеп? Җәнлек бит кулдан эшләнми, үзе кебек җәнлектән туа. Аның төсен бик аз гына үзгәртү дә гаять катлаулы, нечкә эш. Менә шул эшкә Тамара Сергеевна кереште. Бик әһәмиятле нәрсә иде бу безнең өчен... Әйтергә кирәк, бер-ике елдан соң Тамара Сергеевна өметле генә нәтиҗәләргә дә иреште, ягъни аның ихтыяры белән безнең төлкеләр йә ачыграк, йә тоныграк төсле булып үсә башладылар...

Мин биредә бу эшнең махсус якларына керешеп тормыйм, әгәр кирәксә, анысын соңыннан сөйләрмен, ә хәзер тизрәк төп вакыйгага барып җитәсем килә. Билгеле инде, бу зур уңыштан соң Тамара Сергеевнаның дәрәҗәсе тагы да үсте, кадере тагы да артты. Бу аның үзенә дә, һичшиксез, зур юаныч, зур канәгатьләнү китергәндер. Ләкин ул безнең арада, оясыз кәккүк шикелле, һаман ялгыз иде.

Кырык сигезенче елның җәендә ул, ял алып, ниһаять, Ленинградка кайтып китте.

Озатканда барыбыз да, моның бөтенләй китүедер, кире безгә кайтмас инде дип, аңа һәртөрле уңышлар, бәхетләр теләп калдык. Ул үзе дә, ачыктан-ачык әйтмәсә дә, шундыйрак ният белән кайтып китте шикелле. Озаткан чакта ул, дымланган күзләре белән кызганыч елмаеп, безгә: «Хушыгыз, дуслар, әгәр күрешмәсәк, яманат белән искә алмагыз!» – дип китте. Моны инде чынлап та бөтенләйгә саубуллашу дип аңларга кирәк иде.

Ләкин... ялы тулуга, Тамарабыз кире кайтып төшмәсенме! Сез, бәлкем, ялдан кайтмыйча калырга ярамый бит диярсез. Дөрес, әмма эвакуацияләнгән кешеләргә үзләренең торган җирләренә бер тоткарсыз кайтып китү хокукы бирелгән иде, шуңа күрә Тамара Сергеевна Ленинградтан кечкенә бер гариза кисәге җибәрсә, шуның белән эше дә бетә иде. Ләкин ул кайтты, Ленинградтан Бөрелегә кайтты. Ни өчен, ни сәбәп? Үзе ул безгә бары:

– Сездә аяз көннәр күбрәк, шуның өчен кайттым,—дигән булды.

Асыл сәбәбен төпченеп сорашу, әлбәттә, читен иде, берәү дә моңа җөрьәт итмәде.

...Кайтты һәм яңадан үзенең фермасында, үзенең кыргый сылу төлкеләре арасында эшләп йөри башлады.

...Айлар үтә, еллар үтә, рәхимсез вакыт кешегә бирелгән гомер йомгагын акрын гына сүтә бара. Тамара Сергеевна безгә килгәндә егерме алты-егерме җиде яшьлек нәфис хатын иде, инде менә утыз бишкә дә җитеп килә. Кара чәчләрендә сирәк кенә ак җепләр дә күренгәли башлады, күз төпләрендә вак кына челтәр дә пәйда булды, яңак сөяге астына беренче сызык та ятты. Ләкин шулай да ул яшьлек гүзәллекләрен җуеп бетермәгән иде әле. Гәүдәсе һаман шулай җыйнак-сылу, хәрәкәт-йөреше җиңел, бите чиста, кара күзләре якты, иреннәре тулы, саф... Ләкин барыбер инде ул – көзге чәчәк, тагын берничә ел – һәм ул сабагында шиңәчәк.

...Бу әле кешенең, ничек дип әйтим, тышкы ягы, тышкы яктан булган үзгәреше генә. Ә аның эчендә нindирәк процесс бара? Бу кадәресе тагы да катлаулырак һәм газаплырак түгелме?

Менә хәзер мин сезгә аның бездән китүенә сәбәп булган вакыйганы сөйлим. Чыннан да, уйлап карагыз: гаепле идеме ул, әгәр гаепле булса – нидән гыйбарәт аның гаебе?

...Илле икенче елның җәй башында Тамара Сергеевна тота да Петр Котов дигән бер егет белән тора башлый. Кешеләр арасында еш кына була торган бу хәл шулай да күпләрне бик гаҗәпләндерде. Иң элек бу «кушылуның» алдан бернинди билгесе булмады, кинәт көтмәгәндә килеп чыкты ул... Совхоз поселогы кечкенә җир, биредә кешенең һәр адымы күз алдында, ялгыз кешеләрнең бер очрашып сөйләшүләре дә хәзер үк халык теленә кереп китә... Ә Тамара Сергеевна эшен шундый шома йөрткән булса кирәк, бары җәйге иртәләрнең берендә ул, Петр Котов белән үз квартирасыннан чыгып, поселок урамыннан икәү янәшә атлап киткәч кенә кешеләр ни булганын белделәр. Белделәр... һәм хәйран калдылар. Ләкин көтелмәгән яңалык булганы өчен генә түгел... Мәсьәлә җитдирәк иде.

Кем соң ул Петр Котов? Нәрсәсе белән, нинди кешелек сыйфатлары белән ул Тамара Сергеевнага яраган, аңа тиң була алган?

Иң элек шуны әйтергә кирәк, егет Тамара Сергеевнадан нәкъ сигез яшькә кече иде. Хәер, тол хатыннарның үзләреннән шактый яшьрәк ирләргә тормышка чыгулары очрый торган хәл, моның ахыры ни белән бетә торгандыр, ләкин, һәрхәлдә, гаептән саналмый. Бу очракта да, чырай сытыбрак булса да, килешергә туры килә... Инде егетнең бүтән якларын алып карыйк: ул безнең ремонт мастерскоенда слесарь булып эшли иде. Урта кул слесарь, күбрәк фермаларга барып, водопровод трубалары төзәтеп йөри. Белеме шул биш-алты класс тирәсендә булгандыр. Хәер, яхшы кеше һәм итагатьле ир булыр өчен профессиянең әллә ни зур әһәмияте юк. Безнең район җирендә, әйтик, врач кыз белән шофер егетнең өйләнешеп, матур гына торуларын кайчагында күрергә була. Ләкин һәр очракта да бу шулай дип әйтүе читен, әлбәттә. Биредә, газетчалап әйткәндә, уңышны тәэмин иткән нәрсә – кушылучыларның аң һәм культура дәрәҗәләре бертигезрәк булуыдыр, ахрысы... Хуш, бу җәһәттән безнең Петя Котов ничегрәк иде

соң? Мисал өчен, Тамара Сергеевна белән янәшә куеп карасак, без аны ниндирәк кыяфәттә һәм сыйфатта күрер идек?

Күз алдыгызга китерегез: кичкырын клуб алдында егерме биш-егерме алты яшьлек чибәр егет басып тора. Өстендә аның кызыл майка өстеннән генә кигән кара пиджак, тез башлары чыгыбрак торган кара чалбар, аякларында көрән брезент ботинкалар. Ашыкмыйча гына папиросыннан «алкалар» җибәрә һәм, чабак сагалаган чуртан шикелле, кызлар күзәтә. Теләсә кемгә ташланырга тормый ул, сайлап кына дәшә, простой ферма кызлары белән эре сөйләшә, аларга ни әйтсә дә ярыйга саный, ә культурныйрак туташлар белән сүз башлый калса, аларга инде «сез үзегез», «без үзебез» дип сайрарга тотына, бөгелгәләп тә ала, кулларны да матур гына уйнаткалап куя. Мондый «нечкә» кыланышларны ул каяндыр отып алырга өлгергән иде инде, күрәсең, безгә килгәнче урыннан урынга еш кына күчеп йөрүләр аның өчен бушка китмәгән. Күпме-азмы шомарган егет! Шулай да кызлар аның тирәсендә үзләрен, утка пешүдән курыккандай, сак тоталар иде.

...Иптәшләре арасында Петя бозык яки начар холыклы егетләрдән саналмый иде. Әтәчләнеп, кешеләргә бәйләнеп йөрми, юктан да тавыш куптарырга тормый, йодрыгы белән масаймый, теле белән мактанмый, кыскасы, тупаслыкны егетлеккә санап, скандаллар герое булып йөрүчеләрдән түгел иде. Ул хәтта аз сүгенә дә иде (ә бу әшәкелек бер категория яшьләр арасында шактый таралган чир бит), бик ачуы килгән чакта гына, дүрт юллык шигырь әйткәндәй, рифмалап сүгенеп җибәрә торган иде. Эчү белән дә артык мавыга иде дип әйтеп булмый аны, тик получка вакытларында гына салгалый иде. Бусы инде традициягә хөрмәт. Слесарь булсын да, получкада эчмәсен, имеш!

Егетнең максаты нәрсә, нинди интереслар белән яши ул, – әйтүе читен. Нәрсәгә булса да омтылышын ул бервакытта да сиздермәде. Гомумән аз сүзле егет иде ул, акылын эшләтергә яратмый иде шикелле, карасу шома йөзендә берни юк дияр идем, тик кеше әйткән пустяк сүзгә дә көлеп җибәрергә әзер тору гына бар. Сез тагын аны томана, мокыт нәрсә икән дип уйлый күрмәгез, һич алай түгел. Киресенчә, егеттә мин-минлек тә Аллага шөкер, кирәк урында үзен тәкәббер тота да белә, кыюлык та җитәрлек (бигрәк тә хатын-кыз тирәсендә), ә инде берәрсе аңа кагыла калса, егет сүзен дә таба, йодрыгын да иснәтә белә. Так что, бу юаш икән дип, бармагыңны авызына тыга күрмә!.. Ләкин характеры белән ваемсыз, пошыну белмәс, нибарына канәгать булып яшәүче бер кеше иде ул. Андый кешенең тормыштагы кагыйдәсе: «Әйдә, ярар!»

Әмма ул төскә-башка бик чибәр егет иде. Урта буйлы, бик төз, җыйнак тыгыз гәүдәле, көч үзендә яман булырга тиеш, беләкләрендәге таштай мускуллары буын-буын калкып тора. Кашлары куе кара, керфекләре озын, борыны туры, ияк очы чокырлы, ә тешләре – үлчәп

эшләнгәндәй тип-тигез дә ап-ак... Ялкау гына атлап йөри ул, гүя көче-куәте тамырларына кургашын булып таралган.

Менә шундый егет иде безнең Петя Котов. Һәм шушы егет белән хөрмәтле Тамара Сергеевнабыз ачыктан-ачык тора башлады. Чыннан да, хәйран калдырырлык һәм уйландырырлык хәл бит бу!

Сезне, бәлкем, ничек итеп алар табышканнар да кушылып киткәннәр дигән сорау борчый торгандыр. Бу кадәрәсе безнең шартларда читен эш түгел. Мондагы халык барысы да бер җиргә тупланган, барысы да бер хуҗалыкта эшлиләр, хәтта таптап йөргән сукмаклары да бер үк... Шулай булгач, Тамара Сергеевна белән Петяның күптән бер-берсен күреп йөрүләре бик табигый. Аннан Петя еш кына аның фермасына тегене-моны төзәтергә барып йөри иде, ихтимал, шул чакларда карап торырга болай зарарсыз, тыйнак кына күренгән аз сүзле чибәр егет яшь ханымның күңелен җилсетеп куйгандыр. Шуның өстенә мастерскойда эшләүче егетләрнең тулай йорты Тамара Сергеевна торган өйнең күршесендә генә иде. Бу да әледән-әле бер-берсенең күзенә чагылырга бер сәбәп. Аннары, ничектер юллары туры килеп, берничә тапкыр төнлә клубтан да бергә кайталар, һәм, ниһаять, егет, үз инициативасы беләнме, әллә чакыру буенчамы, Тамара Сергеевнаның өенә дә керә. Бер керә, ике керә һәм озак та үтми шунда торып та кала. Күп кирәкмени, итәгеңә утлы күмер төшсә, кабынып китәргә... Сез аңлагыз, күпме еллар ир назы күрмичә яшәгән хатынның хәлен! Йә, аның, дым эчкән туфрак шикелле, сагыш белән тулы йөрәгенә нинди генә орлык төшсә дә, ул тиз генә тамырланып китмәс идемени?

...Билгеле, күпләр, аеруча хатын-кызлар, Тамара Сергеевнаның бу эшенә бары бер яктан гына карадылар: янәсе, аңа яшь, таза ир кирәк булган, һәм китте шушы хакта селәгәй агызып гайбәт чәйнәү... Белмим, хатыннар, бәлкем, мәсьәләнең бу ягын нечкәрәк аңлый торганнардыр, ләкин минем өчен, хәер, бер минем өчен генә түгел, ә Тамара Сергеевнаны якыннан белгән күпләр өчен мәсьәлә тирәнрәк һәм катлаулырак иде. Хәзер дә исемә төшсә ачуым килә: ир кирәк булган, имеш! Әйтегезче, зинһар, ә кемгә ир кирәкми? Кемгә хатын кирәкми? Кешеләр балигъ булгач та шул турыда уйлый, кайгырта башламыйлармы соң? Тамара Сергеевна гарип хатын түгел бит. Ни өчен һәркемгә яраган нәрсә аңа ярамый? Ни өчен табигать тарафыннан һәр җан иясенә бирелгән теләктән ул гына мәхрүм булырга тиеш? Ханжалар карашы бу... Киресенчә, гомеренең иң матур чакларын тол үткәрергә мәҗбүр булган сау-сәламәт хатынның үзенә иш табып ир белән тора башлавына сөенергә генә кирәк иде.

Ләкин, кабатлап әйтәм, мәсьәлә тирәнрәк һәм катлаулырак... Ялгызлык, әйе, ялгызлык! – менә нәрсә, минемчә, аңлатса кирәк Тамара Сергеевна кичергән тирән йөрәк фаҗигасен... Юк, аңа ир генә түгел, кеше кирәк булган, дус кирәк булган. Кемнеңдер гел янында булуын теләгән

ул, кемнеңдер аның тормышына кереп урын алуын теләгән ул. Шуның белән кешеләр арасына чыгасы, үзенең бүтәннәр кебек үк ишле-парлы булуын күрсәтәсе килгән аның... Ә бу нәрсә хатыннарга бик хас теләк, алар кушылган кешеләрен яшереп тотарга яратмыйлар... Һичшиксез, Тамара Сергеевна семья җылысын сагынган, шул турыда күп хыялланган булырга тиеш. Беләсезме, хатын-кыз йөрәге һәрвакыт кем турында булса да кайгыртып торуны ярата бит ул. Ир дигән кешенең күлмәгенә төймә генә тагып бирсә дә, юаныч таба ул. Ниһаять, аның яңадан ана буласы килгәндер, бала өмет иткәндер, һәм, һич шик юк ки, ул, Тамара Сергеевна, мәхәббәткә сусаган йөрәгенең бөтен кайнар дәрте белән егетне яратып киткән булырга тиеш.

...Бик табигый хисләр, бик аңлаешлы теләкләр ич болар. Ничек шуларны күрмәскә мөмкин ди? Безнең секретарь әйтмешли, просто кабахәтство бу!..

Соң, белә идеме Тамара Сергеевна үзе хакында йөргән шул алама гайбәтне? Әлбәттә, белгәндер, хәле шундый аның, белмичә калуы мөмкин түгел... Ләкин ул аңа һичбер нинди борчылу, уңайсызлану яки кәефсезләнү кебек нәрсә күрсәтмәде. Гүя берни юк, бар да нормаль, бар да тәртиптә. Петя Котов белән кешеләр арасына чыгып йөрүдән һич тартынмый иде, аның белән култыклашып киносына да бара, бакчасына да чыгып утыра. Кайчак бергәләп шәһәргә дә барып кайталар. Әлбәттә, яңа гына кияүгә чыгып, бәхетен тапкан яшь кыз шикелле үзеннән-үзе сөенеп, очынып тору юк аңарда. Ул тыныч, ул басынкы, ул үзен күптәнге ир хатыны кебек тота. Һәм аның Петяга булган мөнәсәбәтендә егетне үзенә чын ир, якын кеше итеп күрсәтергә тырышуы сизелә иде... Ул бераз ябыга, суырыла төште, күз төпләре уелып, моңсу-тыныч карый торган күзләре зурайган кебек булды, ә акыллы йөзендә аның нидер көтүне чагылдырган бер дә югалмас җитдилек күренә иде.

Ләкин ничек кенә булмасын, әмма аларга караган саен ихтыярсыздан күңелне бер сорау борчый иде: ничек итеп Тамара Сергеевна бу Петяны үзенә тиң итә алды икән, нәрсә уйлап ул аның белән тормыш итә башлады икән? Үзе белән егет арасында никадәр тирән чокыр ятканлыгын, егетнең бер ягы белән дә үзенә лаек булмаганлыгын ничек күрмәде икән?

...Юк, күргән булырга тиеш, һичшиксез күргән булырга тиеш. Тамара Сергеевна кебек акыллы, сизгер хатынның кеше танымавына ышанып буламы соң! Алайса эшнең сере нидә?

Петя Котов кебек егетләрнең гадәттә кешене, бигрәк тә хатын-кызны, алдата торган бер сыйфатлары була. Алар, ягъни Петя кебекләр, үзләренең әнә шул ваемсызлыклары, беркатлы простойлыклары белән ничектер кулга ияләшердәй җәнлек кебек күренәләр. Әгәр аларны кулга алып, үзеңә буйсындырсаң, алардан менә дигән кеше ясап булачак. Бозылмаган яшь күңел – язылмаган чиста кәгазь, диләрме әле? Янәсе, бозылмаган яшь күңелгә бары изгелек белән яхшылыкны гына язып барырга була... Бичара хатын үзенең шушы яшерен хыялларына ирешер

өчен, яраткан Петясын кеше итәр өчен шактый тырышып карады. Хәтта кайбер нәтиҗәләргә дә ирешкән кебек булды. Моңарчы общежитиедә керле урын өстендә аунаган Петябызга мамык куна башлады. Иң элек, Тамара Сергеевнаның якын кешесе булып киткәч, аның беркадәр дәрәҗәсе күтәрелде, өлкәнрәк абзыйлар, совхоз җитәкчеләре аңа, Петр Васильевич, дип дәшә торган булдылар... Егет үзе дә эреләнеп, олы сымаграк булып китте, йөзенә аның төче елмаю астына яшеренеп кенә «шаярмагыз минем белән» дигән масаю чыкты. Дөрес, өлкәнрәк кешеләргә ул моны күрсәтмәскә тырыша, ләкин ничек кенә тырышмасын, бик әйбәт тәрбиягә эләккән песи шикелле үз-үзеннән тук канәгатьләнүне беркая да куя алмый – кыяфәт үзе үк кычкырып тора... Егетнең өс-башына да бераз культура йокты: майка өстеннән күлмәк киеп йөри башлады, пиджак-чалбары үтүкләнгән, чистартылган булды, моңарчы тузгытып йөрткән чәчләрен дә матур гына итеп тарап куярга өйрәнде... Ашау-эчү ягы да үзгәрмичә калмады. Хәзер инде егетебез төшке ял вакытында мастерской күләгәсендә коры икмәк күшәп утырмый, ә көн дә Тамара Сергеевна биреп җибәргән завтрак – май яккан күмәч, пешкән йомырка, кайнаган сөт белән сыйлана... Болары әле кеше күзенә чагылган кадәресе генә, ә яраткан хатын янында ул нинди тәрбия, нинди ихлас кайгырту күрмәгәндер?

Шулай, дус кеше! Ләкин, кызганычка каршы, бу үзгәрешләр бары тышкы яктан гына иде шул. Ходай егеткә күктән көткән бәхетне җирдән табып бирде. Инде аңа шул бәхетенә ике куллап ябышырга, Ходаем, кире ала күрмә, дип ялварып кына торырга кирәк иде; Тамара Сергеевна кебек кешене бит ул көндез чыра яндырып эзләсә дә яңадан табачак түгел! Ләкин Петя, дурак, өстенә ауган бу бәхетнең әһәмиятен дә аңламый, кадерен дә белми иде булса кирәк. Чөнки ул үзенең характеры белән дә, гадәтләре белән дә һич үзгәрмәде диярлек. Элеккечә ваемсыз, мәнсез ул; аның өчен үгез үлсә – ит, арба ватылса – утын, һаман шул «әйдә, ярар!» дигән принцип белән селкенеп йөрүче кеше булып кала бирде. Тамара Сергеевна белән кушылуына ул чираттагы «җиңү» һәм вакытлы бер эш итеп карады. Гәрчә шундый дәрәҗәле, матур, интеллигент хатынның аны тиң итүенә борынын күтәрсә дә, бу бары: «Күрдегезме, мин кемне эләктердем», – дип мактанудан гына гыйбарәт иде. Шуңа күрә бичара хатынга тиешле хөрмәт тә юк, аның кем икәнен аңлау да юк, аның яхшы исемен, абруен сакларга тырышу да юк. Ул гынамы әле!

...Менә Петя иртәнчәк мастерскойга килә. Сүлпән генә эшкә тотына, йокысы калгандай киерелә-сузыла, әледән-әле яңак сөякләре шытырдаганчы исни... Беләсез инде, мондый чакта яшьләрдән кайберәүләр (Петяның үз ишләре) шаяртырга яраталар, бер дә тарсынмыйча, «ничегрәк соң?», «алайракмы, болайракмы?» дигән төсле, күңелдән уйларга да оят сораулар бирәләр. Ә Петя нишли шул чакта? Берәү булса, кызыксынучыларның авызларын мәңге

ачылмаслык итеп томалар иде, ә ул, ишәк, тегеләрнең әйткәннәрен раслагандай, мәгънәле төче итеп елмая, бик туры китереп әйткәнне ишетсә, «черти-и!» дигән булып башын гына чайкап куя... Бөтен бәла шунда, минемчә, Петя Котов гомумән интим мөнәсәбәтнең никадәр изге-яшерен булырга тиешлеген, якын кешеңнең намусын, чисталыгын саклау белән бәйләнгән булуын аңлаудан ерак тора иде. Һәм аның әнә шулай үз ишләренең пычрак шаяртуларына кинәнүен күргәннән соң, Тамара Сергеевна очрый калса, аңа каравы әллә ничек авыр да, уңайсыз да булып китә иде. Бичара хатын өчен чеметтереп күңел әрни, шул ук вакытта аңа ачу да килә иде. Ихтыярсыздан, әлеге гайбәтчеләр сүзе күңелгә килмичә калмый иде.

Ә Тамара Сергеевна – горур хатын, һаман элеккечә башын текә тотып, иренен кысып йөри бирә. Гүя беркемдә, бернәрсәдә эше юк, бары фермасын да өен, кара төлкеләрен дә Петясын гына белә. Хәтта, мин әйтер идем, аның горурлыгы соңгы вакытларда көчәя төште, әйтерсең горурлык аның өчен һәртөрле начар сүз, яман карашлардан саклый торган бердәнбер калкан иде... Әмма шулай да бу акыллы хатынның җаны тыныч булмаска тиеш иде. Ул әллә егетнең ни уйлап масаюын, аңа, үзеннән сигез яшькә олы хатынга, ничегрәк каравын, ниһаять, аның иң кадерле, иң яшерен хисләрен ятларга фаш итүен сизмәгәндер дисезме? Юк, сизгәндер, Петя аның өчен табышмак түгел ич! Һәм горур ханымга вакыт-вакыт бик хурланырга да, әрнеп сыкранырга да туры килгәндер, әлбәттә. Ләкинниләр генә кичермәсен, бөтенесен дә ул, бердән, үзенең әнә шул горурлыгы, икенчедән, яшерен өмете белән җиңәргә тырышты булса кирәк... Әйе, бик гаҗәп иде болар барысы да безнең өчен, әмма вакыйга үзе ахырда бу сәер төенне чишеп бирде безгә!

...Сүз бит Тамара Сергеевнаның ни өчен бездән китүе турында башланган иде. Тыңлагыз, бу аяныч вакыйганың соңы бик гыйбрәтле.

Шул елның көзендә (ә алар – Тамара белән Петя —җәй башында кушылганнар иде) бер механикны Ленинградка алты айлык курсларга җибәрергә кушып, безгә главкадан язу килгән иде. Менә шул хәбәрне ишеткәч тә, Тамара Сергеевна тиз үк директорга килеп җитте. Ул бик үтенеп директордан курска Петр Котовны җибәрүен сорый башлады. Директор коры гына «карарбыз» дию белән чикләнгәч, ул парткомга да кереп сөйләште. Аңардан «Ни өчен ул хәтле Петяны җибәрәсегез килә?» дип сорагач, Тамара Сергеевна, мескен, хәтта уңайсызланып та калды. Асыл теләген әйтергә кыймыйча, шунлыктан дулкынланып, ул Петяның яхшы слесарь, әйбәт кеше булуын, тик аңа уку җитмәвен исбат итәргә кереште. Хәер, ни өчен дип сорау урынсыз да иде, болай да хатынның теләген аңларга мөмкин иде. Әгәр курс бүтән бер шәһәрдә булса, ул, бәлкем, бу кадәр ялварып сорамаган да булыр иде. Ләкин Ленинград бит, аның туып

үскән шәһәре! Йә, ничек ул үзенең Петясын шунда җибәреп, укытып-йөртеп кайтарырга теләмәсен ди?

Әлбәттә, совхоз җитәкчеләре каршында Петя Котов курска җибәрер өчен бик үк лаеклы кандидатлардан түгел иде. Аңардан куда шәбрәк егетләр бар иде. Ләкин Тамара Сергеевнага хөрмәт йөзеннән, аның телдән әйтә алмаган изге теләген аңлап дигәндәй, Котовны курска җибәрергә булдылар.

...Китәр көннәр якынлашкач, Петя мастерскойдагы иптәшләре алдында болай дип мактана икән: «Беләсезме, егетләр, минем Тамара миңа целый список төзеп бирде: менә, имеш, син, дустым, шуларның барысын да күреп кайтырга тиешсең. Эрмитаж, Смольный, Петергоф, Зимний, тагын әллә нинди дворецлар, әллә нинди музейлар —барысын да тезгән. Ә театрларны әйткән дә юк... В общем, агартырга уйлый мине Тамарочка...» Бу юлы егетләр сүзне уенга бормыйлар, киресенчә, вәт шундый хатының булса иде дип сокланалар, син, тиле, Тамара Сергеевнаның кадерен бел, диләр, тик арадан берсе генә шаяртып: «Ә рестораннарны күрсәткәнме?» – дип сорап куя. Петя, гәрчә чәйханә буфетыннан юньлерәк җирне күрмәгән булса да, эре генә җавап бирә: «Аларын мин үзем дә табам...»

Ниһаять, безнең асыл егетебез, яңа пальто, фетр эшләпә киеп, Ленинградка китеп бара... Хәерле юл!

...Көннәр, атналар узалар, совхозда җәнлекләр үрчиләр, Петя берәүнең дә төшенә кереп борчымый. Бердәнбер борчылып торучы һәм сагынып көтүче – мескен Тамара Сергеевна. Башта егеттән кешегә күрсәтмәслек кыска-кыска гына кайнар «мәхәббәт» хатлары килә, аннан сирәгәя бара, ахырга таба онытылганда бер генә килә башлый. Хатларында «мәхәббәт» акрынлап сүрелә, аның каравы акча теләнү көчәя. Тамара Сергеевна, билгеле инде, акчасын да җибәреп тора, соңгы көнгәчә озын-озын хатларын да язып тора.

Ләкин ул, Петя киткәннән бирле, ни өчендер гел боек йөрде, әлеге нидер буласын көткән киеренке җитдилек аның йөзеннән бер дә китмәде. Гомумән, мин аның, Петя белән бәйләнгәч, җәелеп бер, хәсрәтсез дигәндәй, елмайган чагын күрмәдем.

Менә бер заман Петя Котовның кайтыр көннәре дә килеп җитте, һәм шул чакта бөтен совхоз халкын таңга калдырган гадәттән тыш вакыйга булды: язгы төннәрнең берендә Тамара Сергеевна совхоздан югала. Бу ни хәл бу? Икенче көнне Тамара Сергеевнаның күршесендә торучы хатын совхоз директорына бер конверт китереп тапшыра. Конверттан записка һәм бер кечкенә хат чыга. Записка Тамара Сергеевнадан булып, анда түбәндәге сүзләр язылган:

*«Хөрмәтле Иван Петрович!*

*Мин совхозны ташлап китәргә мәҗбүрмен. Сәбәбен шушы записка белән бергә салган хаттан аңларсыз. Әлбәттә, минем болай «качып» китүем ярый торган эш түгел, мин моны беләм, ләкин аңлагыз, бүтән чарам юк минем... Әгәр бер генә көнгә калсам да, сез барыгыз да мине юатып, үгетләп, кыстап биредә калырга, шулай итеп хурлыгым белән килешергә мәҗбүр итәр идегез. Мин моны булдыра алмыйм... Берничә көннән ул кайтырга тиеш... Шуңа күрә артык бер көн дә тормыйча китәргә булдым. Аңлагыз мине, кичерегез...*

*Мине эзләмәгез, яңа җиргә урнашкач, үзем хәбәр итәрмен.*

*Хушыгыз!*

*Тирән хөрмәт белән Т.В.»*

Ә кечкенә хат Петя Котовтан. Ул менә нәрсә яза:

*«Исәнме, Тамара!*

*Син мине бик көтәсеңдер инде, сагынгансыңдыр инде бик. Конечно, аңлыйм мин моны... Үземнең дә теге, ни, понимаешь, бик күрәсем килә. Ну вот нәрсә, Тамара, син ачуланма миңа... Мин ялгыз кайтмыйм бит, то есть, өйләнеп кайтам... Яраттым бит бер җирән шайтанны!.. Конечно, моны белү сиңа авыр булыр, ну ничево, дөньяда ир бетмәс. Без бит синең белән болай, шаярып кына дигәндәй тордык, ә миңа чынлап өйләнергә вакыт. Так что, син ачуланма и безнең араны өзелгәнгә сана.*

*Конечно, мин сине онытмам, ну мин хәзер бүтәнне яратам. Кем икәнен әйтмим, кайткач, үзең күрерсең. Менә шул. Барысы өчен дә рәхмәт. Минем сиңа шактый бирәчәгем бар шикелле, но анысын акрынлап түләрмен.*

*Да, тагын сиңа шуны әйтеп куям: без кайткач, кара аны, миңа бәйләнеп, бузить итеп йөрмә, яме!*

*Ну, пока, исән бул! Сиңа бәхет телим.*

*Сәлам белән Петр К.»*

«Бузить итмә» дигән сүзнең астына Тамара Сергеевна үз кулы белән өч тапкыр сызып куйган.

Йә, ничек, абзыкаем? Лач итеп төкердеме хам күпме яхшылык күрсәткән хатынның нәкъ бәгыренә? Качу түгел, беренче очраган ботакка асылынырсың!

Шул кичне без, совхозның җитәкчерәк кешеләре, директор бүлмәсенә җыелдык. Барыбыз да бик борчылышкан идек, ачулы идек. Ләкин, мәет чыккан өйдәге шикелле, сүз таба алмыйча утырдык. Ни әйтәсең? Әлбәттә, эш ташлап качу һич тә ярамый, закон белән дә тыела ул, әмма бу очракта беребез дә Тамара Сергеевнаны гаепләргә җөрьәт итә алмадык. Хәтта директор да, шактый коры һәм кырыс кеше, нинди дә булса чара күрү турында авызын ачмады; тик ул

әледән-әле: «Ах, бу хатыннар, хатыннар», – дип үрсәләнде, бер-ике тапкыр авыз эченнән генә сүгенеп тә куйды, аннан, ант иткәндәй йодрыгын төйнәп, Петя Котовны кайту белән, бер көн тотмыйча, совхоздан куарга сүз бирде.

...Менә шулай китте бездән Тамара Сергеевна. Әйтерсең төште дә югалды... Шунсы гыйбрәтле тагын, бу вакыйгадан соң кешеләр ничектер бер уңайсызлану хис иткән кебек булдылар, әйтерсең ялгыз хатынның язгы төндә каядыр китеп югалуы аларның «каты йоклаулары» аркасында гына килеп чыкты... Аннан... акрынлап барысы да онытылды, тик менә сезнең кебек кызыксынып сорашучы очраган чакта гына искә төшереп сөйли торган бер вакыйга булып калды.

Николай Михайлович сүзеннән туктады, һәм без караңгы иңгән бүлмәдә озак кына тын калып утырдык. Була шундый вакыйгалар, алар күңелдә күп кенә уйлар тудырсалар да, ни өчендер төпченеп сорашасы килү теләген кузгатмыйлар. Вакыйга бик ачык булганга күрә генә түгел, ә акылга зур йөк булып төшкәнгә күрә шулайдыр инде ул... Ләкин бер сорау күңелне һаман тырнап тора: Тамара Сергеевна табылдымы, кайда ул?

– Әйе, табылды, – диде Николай Михайлович, кулына яңа папирос алып. – Без башта аны туган-үскән якларына китеп бармадымы икән дип уйлаган идек. Ләкин хәбәр ерак Себердән килде. Ул Иркутск өлкәсендәге зур бер җәнлекләр совхозына барып урнаша һәм яңадан зоотехник булып эшли башлый. Яхшы специалист бит ул... Былтыр Ленинградтагы халыкара аукционда аның үстергән төлкеләре югары бәя алдылар.

Мин тагын нидер сорамакчы булган идем дә, дәшмәдем. Әйткәнемчә, кеше язмышы турында кайчак эчтән генә уйлану яхшы.

*1957*

## Туган туфрак

### I

Кларaның бабасы, мәрхүм, аңа еш кына: «Клара бәбкәм, безнең Каракошны бер кайтып күрер идең, ата-бабаңның туган туфрагы бит ул!» – дип әйтә торган иде. Бабасының бу сүзләренә каршы Клара, ни әйтергә белмичә, уңайсызланып кала торган иде. Әллә кайдагы ул «туган туфрак» дигән нәрсә аңа билгесез, ят иде, шуңа күрә бабасының сүзләре аңарда бернинди теләк тә, кызыксыну да уятмый иде. Гомумән, Клара, чын шәһәр кызы булганлыктан, авыл җирен өнәп бетерми иде. Нәрсә ул авыл? Азрак күрергә туры килде аңа мактаулы авыл җирен. Салкын, пычрак көзләрдә барып, бәрәңге казып йөрде. Чыланды, күшекте, тыгыз өйләрдә тараканнардан җирәнә-җирәнә кунып ятты, өс-башы тузып, үзе керләнеп бетте һәм бөтен

кайгысы – тизрәк шул «бәрәңге базыннан» котылу турында гына булды. Бернинди кызык та, матурлык та тапмады ул анда.

Ничек кенә булмасын, бабасының «туган туфрак» дигәнен Клара ихтыярсыздан элек үзе барып йөргән әнә шул Питрәчнең көл балчыклы бәрәңге җирләре белән бертөслерәк итеп күрә иде. Шунлыктан ул авыру картның: «Кызым, кайтып бер күрер идең», – дигән сүзләрен һаман колагы төбеннән үткәрә килде.

Ә бабасы үзенең Каракошын, шунда үткәргән гомерен еш кына сагынып исенә төшерә торган иде. Бала чагын, егет вакытларын, каз өмәләрен, туйларын, җыеннарын, ярминкәләрен – барысын да кызык итеп, тәмле итеп, көрсенеп һәм юксынып сөйләп утырырга ярата торган иде. Клара, карт кешенең хәтере өчен генә аны тыңлаштырса да, барыбер үзенчә уйлый иде. «Боже мой, – ди иде ул эченнән генә, – хәзерге авылның коты юк, ә иске авыл нинди булгандыр инде ул?..» Аның укып белүе буенча, иске авылның бер яме дә, бер кызыгы да булмаган. Иске авылда бары хәерчелек, караңгылык, наданлык, вәхшилек кенә булган. Байлар ярлыларны изгәннәр, крестьяннар гел ач утырганнар. Йә, моның нәрсәсен сагынасың? Дөрес, аның бабасы, сөйләвенә караганда, таза гына тормышлы булган (Клара исәбенчә, середняк булырга тиеш), аты булган, сыеры булган, иген иккән. Әмма шулай да хәзерге вакытта иске авылны сагынып утыру һич килешә торган эш түгел инде. Политик артталык, наданлык бу... Кайчакта Клара, артык түзә алмыйча, бабасының сүзен дә бүлә иде: «Куй инде, бабакай, мактама инде син иске авылны. Йә, сезнең шул Каракошыгызда элек мәктәп булганмы, клуб, радио, электр булганмы?»

Юк, аларның берсе дә булмаган. Хәер, мәчет катында кечкенә мәдрәсә булган, әмма ләкин электр да, клуб та булмаган. Хәтта бабасы малай чагында керосин лампасы да булмаган. Чыра яндырганнар. Бабасы әйтә, кышкы кичләрдә, бөтен өй эче кул эше белән утырганда, миңа шәмдәлгә кыстырган чыраларның күмерен сулы ләгәнгә өзеп төшерергә кушалар иде, ди. Махсус кыскычы була торган иде, шуның белән бик тырышып чыра башын өзеп утыра идем, ди... Менә сиңа иске авыл!

Әмма шуңа да карамастан бабасы үзенең Каракошын һаман сагына иде. Әледән-әле Кларага әйтә торган иде: «Кайтып күр, кызым, гомер иткән нигезебез шунда, ерак бабаларыңның каберләре шунда, сиңа якын түгелмени алар?» – ди иде. Аннары Каракошның яланнары, таулары матур, имеш, халкы бик әйбәт, кунакчыл, имеш, гомумән, ягы белән үк бөтенләй башка: хозур, ямьле, җанга ягымлы, имеш.

Ә менә Кларанын әтисе, шул авылда туып үскән булса да, Каракошны сагынып бер дә телгә алмый иде. Бәлкем, эченнән генә сагынгандыр, ләкин тыштан бервакытта да күрсәтми иде.

Әтисе аның алдынгы кеше шул, капитализм чорындагы авылны сагынып, мактап сөйләүнең килешмәгәнлеген бик яхшы белә ул.

Инде менә үткән көз Кларанның бабасы каты авырудан соң үлеп тә китте. Сиксән елдан артык дәвам иткән гомер өзелде. Барысын да – сагыну-юксынуларын да, җыр-әкиятләрен дә бабай үзе белән бергә кабергә алып китте.

Хәзер инде гаиләдә Каракошны телгә алучы да юк, «туган туфрак» дигән сүз үзе үк бөтенләй онытылырга тиеш иде. Ләкин, ни гаҗәптер, Клара, бабасы үлгәннән соң, аның әйткән сүзләрен исенә төшергәли башлады. Каракош та әледән-әле күңеленә килгәли торды. «Бабакаемның гомер иткән җире, безнең «туган туфрагыбыз», миңа ул кайтып күрергә кушып калдырды бит», – дип уйлана торган булды.

Ахырда, эчке бер тынычсызлану белән уйланып йөри торгач, Кларада бабасының туган авылын кайтып күрү теләге туды. Ничектер менә, бабасы алдында бурычлы кебек ул, әгәр аның васыятен үтәмәсә, җаны бервакытта да тынычланмас шикелле... Мөмкинчелеге бар, әтисенең хәле иркен, аның теләгенә каршы төшмиләр – шулай булгач, эш нидә? Бер елдан ул институтны бетерергә тиеш, аннары инде үзең теләгән җиргә барып йөрүләр авыр булачак.

Клара әнә шулай уйлады һәм, җәйге каникул вакытында тиз генә җыенып, ерак Каракошка китеп тә барды.

**II**

Клара туры Каракошның үзенә түгел, ә Каракоштан күчеп утырган Зиреклебаш авылына кайтырга тиеш иде. Чөнки аларның кайтып төшәрлек бердәнбер якын кардәшләре Зиреклебашта тора иде. Дөрес, Каракошның үзендә дә кардәш-ыру күп булырга тиеш, ләкин бабасы үлеп киткәч, алар ничектер билгесез булдылар да калдылар.

Инде Клара хәтерендә онытылмыйча сакланганнардан иң якыны – бу Хәмдия җиңгәчәсе, ягъни бабасы белән бертуган Мөхәммәтша дәдәсенең карчыгы була. Дәдәсе күптән вафат, Хәмдия җиңгәчәсе Зиреклебашта Рәхмәй атлы уртанчы улы белән тора. Рәхмәй инде Кларага тудык абый була. Аның күз төбәп кайткан якыннары әнә шулар иде.

Клара кояш баер алдыннан гына кечкенә бер станциягә килеп төште. Поезд ике генә минут торды да китеп тә барды. Аз-маз гына төшкән халык таралып бетте, һәм Клара, ак чехол кидергән чемоданын күтәреп, ялгыз калды. «Неужели телеграмманы алмадылар икән?» – дип борчыла башлады ул. Ләкин шул арада, әллә кайдан гына калкып, аның каршысына соры плащ, кара кепка кигән, чыбыркы тоткан, кечерәк буйлы чандыр гына бер егет килеп басты.

– Клара?! Синме, Клара? – диде ул, гаҗәпләнү катыш сөенеч белән кызга текәлеп.

– Әйе, мин, – диде Клара, егетнең кыяфәтенә тиз генә күз салып: Рәхмәй абыйсы дияр иде, егет ничектер яшь, малай сыман күренә; ул түгелдер дияр иде, эндәшүе бик үз, якын булып ишетелде. Шулай да бу ак чырайлы, соры күзле егетнең авыз читендә тирән сызыклар күреп һәм шуңардан аның бик үк яшь кеше булмавын чамалап, Клара кыюсыз гына сорады:

– Сез... Рәхмәй абый буласызмы?

– Нәкъ үзе, нәкъ үзе! – диде Рәхмәй абыйсы һәм, чыбыркысын култык астына кыстырып, ике кулын күрешергә сузды.

– Исәнме-саумы? Әйдүк, хуш киләсең!

Ул Кларaның кулын тотар-тотмас күреште дә тиз үк чемоданга үрелде. Ат янына киттеләр. Биле сыгылыбрак торган тарантаска яңа чапкан печән тутырып, өстенә чуар палас бөкләп салганнар. Рәхмәй абыйсы ике куллап паласны суккалап алды.

– Әйдә утыр, сеңелем! Менә аласыңмы? Ул гүя күтәреп утыртмакчы да иде, ләкин Клара үзе җиңел генә менеп утырды. Печәнне бераз кайтаргалап, чемоданны Клара янына кырын утырткач, Рәхмәй абыйсы кучерга сикереп менде дә дилбегәне тартты.

– Кузгалдык, бахбай!

Йомры гына туры ат кырын-кырын борылды да, юлга төшеп, вак адымнар белән юыртып китте. Клараның гомерендә беренче мәртәбә диярлек ямь-яшел сусыл печән салган тарантаска утырып, атта баруы иде. Бик рәхәт булып тоелды аңа бу нәрсә. Җир якын, үләннәр якын, аттан тир һәм каеш исе килә, юк, бу әтисен йөрткән «Волга»дан поэтичныйрак иде. Әллә каян гына килеп бабасының: «Бар иде лә бәнем атларым, җигеп кенә чыга идем чаптарын», – дип җырлавы исенә төшеп куйды. Әйе, бабасы мәрхүм дә кайчандыр бу юллардан менә шулай чапкан печән өстенә утырып, авыз эченнән генә җырлый-җырлый юырттырып узгандыр... Әлбәттә, узгандыр...

Рәхмәй абыйсы, артына борылып аңа, бөтен бите-күзе белән дигәндәй, елмаеп карады.

– Һәй, Клара, Клара! Син икәнсең инде ул Клара, ә?

– Әйе, Рәхмәй абый. Клара дигән кызый мин булам инде, – диде Клара, ничектер сагышлы һәм рәхәтле көрсенеп.

– Бик якын туганнар бит без, уйласаң, Клара аккошым! Беләсеңме шуны?

– Беләм. Бабакайның братының улы буласыз бит сез! Шулай бит?

– Син миңа пләмәш буласың, канатым! Ник дисәң, синең атаң белән мин ике бертуган малайлары булабыз. Безнеңчә әйтсәк, тудыклар... Ә күрешкәнебез юк, вәт тамаша? Бик ерак киттегез шул, ерак киттегез!.. Их-ма!.. Яле, бәләкәчем, кызурак атлале!

Туры ат, сүзне аңлап, башын кага-кага, тырышыбрак юыртырга тотынды. Клара ихтыярсыздан пошынып уйлады: менә беренче күрешүдән үк аңа туганлык хисен ничек сөенеп һәм юмартланып күрсәтәләр. Ә ул хәзергәчә мондый хисне үзендә сизмичә килде. Ниндидер Рәхмәй атлы «тудык абый» аның өчен әллә бар, әллә юк иде.

Җиде чакрымдагы Зиреклебашка караңгы төшеп, тәмам күз бәйләнгәч кайтып җиттеләр. Бер йортның җил капкасыннан кереп туктагач, тарантасны кемнәрдер сырып алдылар, кемнәрдер Кларяны култыклап төшерделәр, нәфис кулын тотып-сыйпап күрештеләр. Аннары өйгә алып керделәр.

Кечкенә өй эче бер мәлгә бала-чага һәм хатын-кызлар белән тулып китте. Күрше-тирәдән керүчеләр дә бар иде, ахрысы, һәрхәлдә, шактый югалып калган Клара бу ыгы-зыгы эчендә кемнең кем булуын тиз генә аера да алмады. Тик ул үзе тирәсендә бертуктаусыз бөтерелеп, шатлык-иркәләү сүзләре чәчкән какча гәүдәле хатынның кем икәнен бусагадан атлау белән үк танып алды: бу – Хәмдия җиңгәчәсе иде. Гаҗәп җиңел сөякле, куштан һәм татлы телле булып күренде ул Кларага.

Шулай да бу беренче кич Клара өчен томанлырак булып калды. Кемнәрнең нәрсә әйткәнен дә, үзенеңниләр кичергәнен дә соңыннан ачык кына хәтерли алмады. Дөрес, аны чын ихластан куанып, зурлап каршы алдылар, юынганда кулына комганнан җылы су салып тордылар, астына йомшак көрпә салып, түргә утырттылар, бик тәмле токмач белән сыйладылар – әмма болар барысы да аңа сәер, кызыклы төш шикелле генә булып тоелды.

...Күпмедер утыргач, аны өйалдындагы махсус юып җыештырылган ак чоланга кертеп, озынча түшәк җәйгән агач караватка яткырдылар. Мамык түшәккә менеп баткач та, аның юлдан талчыккан тәне май кебек эреде дә китте һәм, уйланып ятуына карамастан, ничектер һични сизмичә үзеннән-үзе сеңде дә куйды. Болай эреп, томанга әйләнеп дигәндәй, йокыга китүне аның әле беркайчан да татыганы юк иде.

Ә иртәгесен аны күз кабакларын кытыклаган ниндидер җылы яктылык, борынына кергән ниндидер тәмле хуш ис йокысыннан уятты. Күзләрен ачкач, ул шактый биектә салам кыекны күрде: чоланның такта түшәме юк, имеш, ә кояш нурлары аның күзенә ике кыек арасындагы такта ярыкларыннан төшә икән. Югарыдагы аркылы киртәгә икешәр-икешәр бәйләп быелгы каен себеркеләрен элгәннәр, ә бүрәнә стенага мәтрүшкә бәйләмнәре асып куйганнар. Борынны кытыклаган бу гаҗәеп хуш ис шулардан тарала икән.

Клара, күзен ачкач, тагын «ак» чоланның шүрлегендә һәм чөйләрендә аңа исемнәре дә билгеле булмаган әйберләрне – йон кабасын, тәрәш таракны, каен тузыннан теккән кечкенә тубалны, кипкән шомырт белән тулы агач шаваны күрде. Бу әкәмәт нәрсәләр аны бик борынгы

бер заманга кайтаргандай итте. «Странно, но мило!» – дип уйлап куйды ул эченнән генә һәм шуларның барысына да сокланып, йомшак урыныннан кузгалырга иренеп, озак кына карап ятты.

...Өйалды тып-тын, һичкемнең кергәне-чыкканы ишетелми иде. Клара ихтыярсыздан: «Әллә тормаганнар инде», – дип уйлап алды, хәлбуки хуҗалар кадерле кунакның йокысын кызганып, өй тирәсендә чуалмыйлар иде. Югыйсә алар әллә кайчан торганнар, күптән үк иртәнге чәйләрен эчкәннәр, эшләренә таралганнар, хәтта балалар да күптән инде урамга чыгып киткәннәр иде.

Клара, ниһаять, торып, киң билбаулы ефәк халатын гына киеп һәм яланаякларына ак танкеткаларын элеп, чоланнан чыкты. Ишегалдына чыгар өчен чалышаебрак торган тышкы ишеккә баруга, чыбык-чабык күтәреп килгән җиңгәчәсе очрады.

– Ә, Иркә туташ, тордыңмы, якты күзем? – диде ул, җыр әйткәндәй көйләбрәк. – Хәзер, хәзер сөлге белән комган чыгарам, чирәмдә генә юынырсың!

Клара аптырый калды: «Нигә Иркә туташ? Әллә аның чын исемен яратмаганнармы? Әллә озак йоклаган өчен көлеп әйтәләрме?» Ләкин соңыннан төшенеп алды: юк, көлеп түгел икән, ә чын ихластан аны кадерләп, сөеп дәшү икән бу... Иркә туташ! Нинди матур, нинди ягымлы! Карагызчы, авыл кешесе дә шулай әйтә белер икән?!

Ишегалдына чыккач, Клара хәйран булып тукталып калды: йортның киртәсеннән кул сузымы җирдә генә иген кыры башланып китә. Очы-кырые күренмәгән бу күкрәп үскән иген шулкадәр якын, хәтта башакларның бер-берсенә ышкылып кыштырдаулары ишетелә.

Клара киртә буена килде дә, уңга-сулга салмак кына чайкалып, акрын гына шаулап утырган бодайлар галәменә карап тора башлады. Ул да булмый, аның колагына якында гына нәрсәнеңдер пошкырып куюы ишетелде. Караса, ни күрсен: киртә буенда гына казыкка бәйләгән бер яшь сарык кетер-кетер чәчәкле үлән кимереп йөри... «Ах, душечка, ах, җаным! – диде Клара, тәмам нечкәреп. – Килче, килче миңа, матурым!..» Сарык, башын текә генә күтәреп, авызындагы үләнен чәйнәүдән туктап, аптырау-курку тулы күзләрен Кларага төбәде. Юк, бу төпсез, хәйләсез, бары җан калтыравын гына чагылдыра алган якты күзләргә озак карап торуы мөмкин түгел иде.

Шул арада җиңгәчәсе сөлге, сабын һәм комган күтәреп чыкты.

– Иркә туташ, кил әле мондарак! – диде ул, ишек төбеннән читтәрәк яткан зур ак таш янына чакырып.—Үзем салып торырмын.

Клара, җиңгәсенең комган тотып көтеп торуын күргәч, уңайсызланып, кызарып китте.

– Юк, юк, мәшәкатьләнмәгез! Мин үзем, мин үзем...

– Һәй, аппагым, аякларыңа чәчрәтерсең бит.

– Юк, юк! Мин юына беләм бу нидән... савыттан.

Җиңгәчәсе ирексездән көлемсерәп куйды.

– Ярый инде алайса, – диде ул, комганны таш өстенә куеп. – Ипләп кенә юын, мин тизрәк чәемне хәстәрлим, булмаса.

Һәм ул ашыгып өйгә кереп китте.

Клара юынган арада ашыга-ашыга Рәхмәй абыйсының хатыны кайтып керде. Бу яшь җиңгәчәй – Мөнирә җиңгәчәй була инде. Таза гына, сылу гына гәүдәле, үзеннән-үзе елмаерга торган сөйкемле чырайлы, матур кара кашлы, кара күзле яшь хатын иде ул... Фермада сыер сава икән, әле шуннан ашыгып кайтуы.

Ул туп-туры Клара янына килде дә, күптәнге ахирәтенә дәшкәндәй, бик гади, үз итеп:

– Йә, Клара, әйбәт кенә йоклап тордыңмы? – дип, кулын аның аркасына салды.

– Рәхмәт, Мөнирә җиңгәчәй, бик әйбәт, бик тыныч йокладым.

– Ярый инде алайса. Безнең ни... синең кебек тансык кунакка чоланнан башка урыныбыз да юк.

– Әйтмәгез. Чоланыгыз йоклар өчен прекрасный урын икән, гел чәчәкләр исе аңкып тора!

– Син бигрәк! – диде Мөнирә, көлеп. – Ал, дидем әнкәйгә шул кипкән үләннәреңне, кунакның күзенә чүп коелыр, дидем. Алмады бит... Йә, әйдә керик, иркәм!

Шул арада болар янына урамнан ике яшь кенә бала тупылдашып йөгереп килде. Зуррагы – биш-алты яшьләрендәгесе – малай, ә кечкенәсе өч-дүрт яшьлек кызчык иде. Аларны бүген, кунак апалары килү уңае белән, пөхтә итеп киендергәннәр. Малайның өстендә ике сәдәпле ак күлмәк, бау белән иңбашына аскан кыска балаклы кара чалбар. Ә кызчыкны нәкъ курчак төсле итеп киендергәннәр: чәчен, ике кечкенә толым итеп, кызыл тасма белән үргәннәр, ике кулына да вак кына кызыл мәрҗәннән беләзек кидергәннәр. Аңа карагач, сөенеп елмаймыйча мөмкин түгел иде.

Кларaны тагын шул гаҗәпләндерде: алар шактый әрсез-чая булып чыктылар. Авыл балалары да димәссең. Шунда ук, апаларына сарылып, такылдый да башладылар.

– Апам, бу минем алма апам!

– Юк, синеке түгел, минем апам!

– Тимә, тимә, минеке!

Клара, чүгәләп, икесен ике кулы белән кочаклап алды.

– Менә сез нинди икәнсез! Матур икәнсез, акыллы икәнсез! Йә, синең исемең ничек?

– Алмас! – диде малай, авыз тутырып, батыр гына.

– Ә синеке, күбәләгем?

Кызчык башын кырын салды һәм акрын гына:

– Алсу! – диде.

Клара аларны, сөеп, күкрәгенә кысты. Балалар тагы да иркәләнебрәк аңа сыендылар.

– Йә, йә, килешми болай, апагызның өстен буярсыз, – диде әниләре һәм башларыннан этәреп кенә читкә тибәрде.

...Барысы да җыйнаулашып өйгә керделәр. Карт җиңгәчәсе Кларaны өтәләнеп каршылады.

– Әйдә, Иркә туташ, әйдә, күз нурым! Карының да бик ачыккандыр инде синең, уятырга җәлләдек, юлдан соң туйганчы бер йокласын, дидек... Әйдә, уз әле, уз, кереп утыр әле әнә шунда!..

– Хәзер, Хәмдия җиңгәчәй, чәчемне генә тарап алыйм.

– Ә ярый, ярый, тара! – диде җиңгәчәсе, тагын үзе шунда ук килешеп.

Клара, түбән каратыбрак стенага элгән, башына кәгазь чәчәк кыстырган, чебеннәр шактый «бизәп» өлгергән көзге каршына басып, кыска коңгырт чәчләрен, бер кулы белән тузгыткалап, тарарга кереште. Бу минутта нигәдер барысы да, эшләреннән калып, Кларага карап тордылар. Клара аларның үзенә, үзенең нечкә, зифа буена, затлы матур киемнәренә, гомумән, шәһәр зәвыгын, шәһәр нәфислеген аңкытып торган чибәр туташ булуына сокланып карауларын сизде. Бу аңарда горурлык һәм өстенлек тойгысы уятты. Әмма шул ук вакытта үзе белән алар арасында никадәр тирән аерма барлыгын, үзе яшәгән җиңел, гамьсез тормышның аларда юклыгын, хезмәтнең әле нәрсә икәнен белмәстән, үзенең алар күрмәгән ганимәтләр белән файдалануын, ләкин аларның, шушы аерманы сизгән хәлдә дә, аны әнә ничек якын туган итүләрен ул эчке бер уңайсызлану белән хис итмичә кала алмады.

...Ул чәчен тарап бетерүгә, барысы да тагын хәрәкәткә килделәр. Тагын түргә узып утырырга кыстый башладылар. Ләкин Клара, кереп утырганчы, иң элек стена буенда торган чемоданын алып урындыкка куйды да, ачып, бүләкләрен чыгара башлады. Карт җиңгәчәсенә ул яшел сатин күлмәклек белән ак батист яулык бирде, яшь җиңгәчәсенә бик матур ефәк күлмәклек бирде (аларның моңарчы каладан яшь киленгә бүләк җибәргәннәре юк иде әле), Рәхмәй абыйсына дип китергән ике якалы күлмәкне дә галстугы белән бергә чыгарып сузды, балаларның берсенә – малайга – чиккән үзбәк түбәтәе кидерде, ә кызчыкка бик матур кызыл туфлиләр тоттырды. Аннары ул күчтәнәчләрен – шоколад-конфетларын, тартмалы печеньеләрен, чәйләрен, шикәрләрен чыгарып өстәлгә салды. Барысы да искиткеч куандылар. Карт җиңгәчәсе, кәнәфигә утырып, озын итеп дога кылды. Яшь килен дә, әнкәсенә ияреп, тиз

генә битен сыпырып алды, әмма үзе, бик уңайсызланган хәлдә, ни әйтергә белмичә, рәхмәт тулы күзләре белән Кларага карап тик торды. Балалар исә бүләкләрен әниләренә сузып: «Әни, кара, әни, кара!» – дип сикергәләргә тотындылар.

– Бик тә зурладың, бик тә сөендердең безне, Иркә туташ! – диде карт җиңгәчәсе. – Рабби Ходам, әти-әниеңә озын гомерләр бирсен, сезгә бакый рәхәт бәхетләр насыйп итсен! Амин!

Клара күңеле тулудан бер сүз дә әйтмәде, яшьләремне тыя алмам дип курыкты ул...

...Ахырда, түргә кереп утыргач, аның алдына таба өеп майлаган әче коймак китереп куйдылар. Шуның өстенә тагын самавырдан алып дүрт күкәй, агач тустаган белән пешкән каймак куйдылар. Болар бар да аның өчен генә...

– Иркә туташ, рәхим ит әле, рәхим ит! Коймактан җитеш, кайнар чакта, – диде җиңгәчәсе һәм коймакның майлыракларын астан өскә әйләндереп салды да бармакларын ялап куйды. Ул кыстаудан һич туктамый иде, Клара алдына әле эремчекле маен, әле кәрәзле балын этәрә генә тора. Яшь җиңгәчәсе ал чәчәкле, калай борынлы чәйнектән кечкенә чынаякларга чәйне куе итеп ясый да зур кашык белән сөт өсте салып бирә иде... Шушы чәй Кларага аеруча ошап китте...

...Клара өчен биредә һәрнәрсә яңа, сәер, кызыклы иде. Менә өй эче. Ап-ак зур мич, кечкенә тәрәзәләр. Тәрәзә төпләрендә эреле-ваклы савытларда чыра кадап сабакларын бәйләгән гөлләр... Тәрәзә яңакларында – кызыл башлы озын сөлгеләр, кашагаларда – ак челтәр... Түр почмакта пыяла капкачлы карсак кына кара шкаф; шүрлекләрендә төрле төстәге, төрле иштәге савыт-сабалар; түбәсендә ниндидер катыргы кенәгәләр һәм тузган китаплар... Мич катыннан өйне икегә бүлеп сузылган бүлмә тактасы буенда күпертеп, пөхтәләп җыештырылган иске генә тимер караватъ. Аннары менә кулдан гына эшләнгән, текә артлы агач кәнәфи, шомарып-саргаеп беткән, калын аяклы таза урындыклар, киҗеле ашъяулык япкан шундый ук гади өстәл, өстәлдә патша башлары белән бизәлгән җиз самавыр... Тагын нәрсә? Менә яңа «ходиклар», калаена Кремль манарасы төшерелгән... Менә календарь...

Баймы-ярлымы бу – Клара ул кадәресен белми иде, ләкин өй эче аңа тулаем бик борыннан үзгәрмичә сакланып килгән шикелле күренә иде. Кем белә, менә бу әкәмәт самавырдан бабасы гына түгел, бәлкем, бабасының әти-әниләре дә чәй эчкәннәрдер әле. Һәрхәлдә, монда искесе, яңасы бергә иде.

Чәйдән соң Клара, чоланга кереп, өстен алыштырып чыкты. Җиңсез ак кофточка һәм киң итәкле чуар юбкадан ул нечкә билле чегән кызына охшап киткән иде.

...Инде авылны күрергә кирәк. Яшь җиңгәчәсе ашыгып фермасына китте, карт җиңгәчәсе өй эшләренә тотынды, Кларага иптәшкә Алмас белән Алсу калды. Көзге алдында тагын бер әйләнгәч, ул балаларны ияртеп урамга чыкты.

Аларның өе иң кырыйда иде. Капка төбеннән кечкенә авыл буеннан-буена ап-ачык күренеп тора. Урам киң, тип-тигез, куе бәбкә үләне белән түшәлгән, нәкъ уртадан, кара еландай, юл сузылып киткән.

Авылның утырган җире гаҗәп матур иде, монда кечкенә авыллар тирәсендә генә очрый торган ниндидер үзенә бер ямьлелек бар иде. Каршыдагы өйләр артыннан ук яшь урман башлана. Урамның түбән очы яшел чирәмлеккә барып чыга һәм шуннан ерак та түгел, ялгызы гына утырган мәһабәт биек тау күренеп тора. Ә бирге очта, менә киртәләр яныннан ук, иген кыры башланып китә. Ничектер барысы да – урманы да, тавы да, кыры да – кул сузымы гына җирдә, һәм атлап чыгу белән үзеңне табигать кочагында күрәсең! Клараны аеруча менә шушы якынлык сокландырды да. Ялан күрер өчен машинага утырып әллә кая чабасы юк икән монда...

Иң элек аның әнә шул каршыда гына торган урманга барасы килде.

– Алмас акыллым, – диде ул биш яшьлек «егеткә»,—урманга илт әле мине. Алып бара беләсеңме?

Һи, Алмас алып бармыймы соң! Ике дә уйламыйча: «Әйдә, апам!» – диде дә тыпыр-тыпыр алдан йөгереп тә китте. Клара, кечкенә Алсуны җитәкләп, аның артыннан иярде. Каршыдагы йортның киртәсе буеннан үтеп, бер йөз-йөз илле адым китүгә, алар урманга барып та җиттеләр.

Нәкъ урман авызында аларга юкә бәйләме күтәреп чыгып килүче бер бабай очрады. Бабай базык кына гәүдәле, түгәрәк йөзле, мыексыз, ап-ак сакаллы иде. Ул, тукталып, Кларага дәште:

– Исәнме, кызым?

– Исәнмесез, бабай!

– Безнең мондагы кызларга бер дә охшамагансың, кайдан син үзең?

– Мин шәһәрдән, бабай!

– Шәһәрдән? Өфедән алайса?

– Юк, Казаннан...

Бабай бәйләмен җиргә куйды.

– Казанна-ан?.. Бик ерактан килгән кунак икәнсең, алай! – Ул бераз башын селкеп торды. – Кемгә кайттың соң син, рәхмәт төшкере?

– Менә Рәхмәй абыйларга, – диде Клара.

– Ә, Рәхмәйләргә... Ябалак Хамматшаның Рәхмәенә була инде алайса!

Клара дәдәсенең ябалак булуын белми иде, әлбәттә, бу яңалыктан бераз аптырый калды. Бабай тагы да төпченебрәк сораша башлады:

– Соң син үзең, канатым, кем кызы буласың?

– Мин... мин, бабай, ни, Кәбир кызы булам.

– Кәбир? Кайсы Кәбир?.. Кем Кәбире?.. Нигә мин белмим икән аны?

– Бабай, сез аны белмәссез. Әтием минем авылдан бик күптән киткән. Бәлкем, әтиемнең әтисен, минем бабамны беләсездер?

– Кем ул бабаң?

– Мөхәммәтҗан. Каракошта торган ул.

– Мөхәммәтҗан! Тукта, тукта, Хамматшаның бертуган агасы Хамматҗанмы?

– Әйе, Мөхәммәтша дәдәмнең агасы.

– Ә-ә, әнә ничек икән! Һе, чулай Хамматҗанны белмәскә соң, безнең кодабыз бит ул, чулай Хамматҗан! Минем анайның бертуган энесенең, Әптел дәдәйнең уртанчы кызын синең әбиең Гайшә тутай белән тудык бәлеш Усман малаена биргәннәр иде. Пыкрауда туйлары булды. Бабаң белән әбиең дә кодалар булып килгәннәр иде. Әмма егет тә кеше иде яшь чагында бабаң! Бөеренә таянып, бер җырлап җибәрсә, кунакларның һушын ала иде. Исән-сау гынамы соң әле Хамматҗан кода, рәхмәт төшкере!

– Юк, бабай, үлде инде ул! Былтыр көз...

– Үлде? Иһи-һи...

Бабай, чүгәләп, җитди-моңсу кыяфәт белән дога укырга кереште. Шул чагында Клара, бу изге күңелле картка садака бирергәме, юкмы дип, кат-кат уйлады, бер-ике тапкыр беләгенә элгән кечкенә сумкасын да ачмакчы булды, ләкин комсомолкага андый эшнең ярамаганлыгын уйлап, ахырда садака бирү ниятеннән кайтты.

Бабай авыз эченнән генә: «Урыны җәннәтнең түрендә булсын, амин!» – дип, битен ашыкмыйча гына сыйпады да кире торды.

– Һай гомерләр, гомерләр! – диде ул, үзалдына башын селкеп. – Берәү килә, берәү китә, шулай ул бу дөнья!.. Инде менә сезгә калды тормышлар... Сылу кыз булып үскәнсең, бәбкәм, Алла тәүфыйк бирсен үзеңә!

– Рәхмәт! – диде Клара, нигәдер калтырый башлаган иреннәрен көчкә тыеп.

Бабай бәйләмен алырга дип иелде һәм шул чакта Кларага сыенып торган Алсуны күреп, аның башыннан сыйпады.

– Һи, минем кошчыгым! Исемең ничек әле синең?

– Алсу! – диде бала, акрын гына.

– Әй-һәй-һәй, нинди матур икән! Үзең Алсу, әнкәң чәчәктер инде синең, эткәң кем икән соң? – дигән булды бабай, кызчыкны тагын бер кат сөеп, аннары бәйләмен җирдән күтәрде: – Юлыгызны бүлдем, барыгыз инде, үскәннәрем.

Бу очрашу бик дулкынландырды Кларaны. Аерылып киткәч тә һаман: «Нинди ягымлы кешеләр, нинди яхшы күңелле кешеләр!» – дип уйланды ул. Моңарчы бер җирдә дә әле аның мондагы кебек йомшак мөгамәлә, якты чырай күргәне, мондагы кебек шигъри тәмле итеп сөйләүне ишеткәне юк иде. Гаҗәп иде бу! Әллә аңа карата гына шулай микән? Үзара, бәлкем, алай ук түгелләрдер. Тормышны бик мәкерле нәрсә дип әйтәләр бит! Бер төчесен, бер әчесен каптыра, кешеләрне әледән-әле маңгайлары белән чәкәштергәли генә тора, диләр. Әмма шулай да кешеләргә изгелек хас булырга тиеш. Бик борыннан аларның йөрәкләренә салынган орлык булырга тиеш бу... Инде тормышлар яхшыра һәм бәхетләр тигезләнә барган саен, ул орлыклар тулысынча шытып, барлык кешеләрнең дә үзара мөнәсәбәтләре менә шулай якты, җылы булып китмәсмени?

Кларaның дулкынланган күңеленнән ихтыярсыз әнә шундый уйлар кичеп үтте. Аңа рәхәт иде, гүя бабай аны «туган туфракның» саф суына манып алды, ул рухи баеп, пакьләнеп киткәндәй булды.

Урманга керделәр. Монда торганы яфраклы агач иде: каен, юкә, усак, чаган, карама, элмә – танып та бетермәссең, ләкин бер генә дә ылыслы агач юк. Шуңамыдыр, урман эче ничектер нурлы иде, әледән-әле хисапсыз чәчәкләр белән чуарланган кечкенә аланчыклар ачыла гына тора иде. Бу күренештән Кларaның башы әйләнеп, кайсы аланчыкта тукталырга, кайсы чәчәккә үрелергә белмичә, ул әле уңга, әле сулга кереп китә, аннары тагын иске урынына килеп чыга иде... Ул тик балаларны югалтудан курыкты. Алсуны бер дә кулыннан ычкындырмады, ләкин Алмас тәмам аның теңкәсен кортып бетерде. Малай, урман җәнлеге шикелле, каядыр китә дә югала иде. Клара кычкыра, эзли, кечкенә Алсу елый башлый, ә җен малай, берни булмагандай, әллә кайдан гына килеп чыга да: «Әйдә, апам!» – дип, йә җиләк тулы берәр уйдыклыкка, йә оясы белән утырган бөрлегәнлеккә ияртеп алып китә иде. Менә бит ул нинди! Ә җиләк-бөрлегәннәрне ашап кына бетерерлек түгел. Сумка элеп чыкканчы, чиләк күтәреп килгән булсачы?.. Ахырда, урманны шактый айкап йөргәннән соң, бер дә күрмәгәндәй зур кочак чәчәк җыеп, кайтырга чыктылар.

Кайтсалар, Клара ни күрсен: «Рәхмәй абыйсы лапас астында баштүбән салындырып аскан сарыкны тунап ята. Җирдә табак, комган, Мөнирә ире янында басып тора. Балалар туры шунда йөгерделәр, Клара, карамаска тырышып, тизрәк өйгә узды. Казан тирәсендә булашкан җиңгәчәсеннән ул куркынган бала сыман:

– Җиңгәчи, Рәхмәй абый сарыкны нигә суйды? —дип сорады.

Җиңгәчәсе, көлемсерәп:

– Әй, Иркә туташ, гомердә бер кайткан кадерле кунак бит син безгә, – диде. – Синең өчен тәкә дә суймагач, ярыймы соң!

Клара, ни әйтергә белмичә, бераз сүзсез торды, аннары рәхмәт әйтәсе урында, ихтыярсыздан:

– Ничек инде кызганмыйча? – дип куйды.

Җиңгәчәсе аны бөтенләй башкача аңлады.

– Әйтә күрмә, аккошым! – диде ул, кулын селтәп.—Кызганып торырга тагын... Аллага шөкер, актыгы түгел әле, быел сигез бәрәнебез булды. Игелеккә язсын!

Шулай да Клара күңелсезләнеп калды. Аның өчен дип кенә берни сизмичә кетер-кетер үлән кимереп йөргән яшь тәкәне тотсыннар да суйсыннар, имеш! Бу авыл кешесе җан иясен нигә бер дә кызгана белми икән? Үзләре шундый яхшы күңелле кешеләр, ә хайван суярга куллары бара. Менә аша инде хәзер шул... мескен тәкәне! Үз күзе белән күрмәгән булса, тагын бер хәер иде.

Шул арада Мөнирә җиңгәчәсе зур табак белән тәкәнең итен, үпкә-бавырын кертеп чыкты, ә Клара, бер эш булсын дип, чәчәкләр көлтәсен кәнәфигә таратып салды да яңадан тигезләп, матурлап җыйды. Аннары карт җиңгәчәсеннән бер тар муенлы чүлмәк сорап алды да, шуңа су салып, чәчәкләрен тутырып, зур букетны нәкъ өстәл уртасына бастырып куйды. Җиңгәчәсе дәшмәде инде, аш өлгергәнче торып торсын, диде, ахрысы. Шәһәр кызының юанычы чәчәк икән, әйдә бер кинәнсен!

Аш сосар алдыннан гына аларга кара күн фуражка кигән таза, чибәр генә бер яшь кеше килеп керде. Аны: «Әйдүк, Хәсән, мактап йөрисең!» – дип, якты йөз белән каршы алдылар. Ләкин ул ашка калып тормады, бер чүмеч тутырып салкын су эчте дә китәргә ашыкты. Эшкә әйтер өчен генә керүе икән. Берсекөнгә авылның бөтен картын-яшен печәнгә чыгарабыз, ди, ике-өч көндә кибәнгә куеп бетерергә кирәк, йә һавалар бозылып китәр, ди. Аннары игеннәр дә тәмам өлгереп килә икән, алдагы атнада, насыйп булса, ура башларбыз, ди.

Җиңгәчәсе егетнең бөтен әйткәннәрен хуплап торды, тик ахырдан гына:

– Һәй, Хәсәнкәем, әйткәнеңне дә көтмәс идем,—диде, – кунагым бар бит!

Егет елтыр кара күзләре белән Кларага туры гына карап алды да көлемсерәп:

– Кунак кызга да тырманың җиңелен әзерләп куярбыз, – диде.

Клара егетнең сүзеннән бигрәк, туры карашыннан уңайсызланып кызарды һәм башын горур гына читкә борды. Ә җиңгәчәсе шунда ук егеткә ташланды:

– Һи, мут күз! Иркә туташымны колхоз эшенә чыгарып имгәтер идеңме әллә? Булыр синнән, денсездән...

– Курыкма, тәтәй, имгәнмәс, утырып, ныгып кына китәр, – диде егет һәм тамак кырып куйды.

«Вот какой нахал!» – диде Клара эченнән, гадәтенчә бик ачуы килгәндәй итеп, ләкин нигәдер чынлап ачулана алмыйча.

Шуннан соң ул егетнең тыныч кына болай дип әйтүен ишетте:

– Хәмдияттәй, мин сине артык кыстамыйм, кунакны ялгыз калдырып булмый, канешно, аны гына беләбез... Үз җаеңа карарсың тагы, эш синнән качмас... Ярый, мин киттем. Хушыгыз, туташ!

Клара, борылып, аңа чак кына башын иде, ә җиңгәчәсе кинәт урыныннан кубып:

– Тукта, тукта, Хәсәнкәем, кая ашыгасың? – диде.—Тәкә суйган йортка кереп, ит капмыйча китсәң, языгы кемгә булыр?

Һәм табактан бер тәлинкәгә зур гына ит кисәге, берничә бәрәңге салып, өстәлгә китереп куйды. Бригадир, нишлисең инде дигәндәй, иңбашын җыерды да, утырып, итне мул гына тозлап, турамыйча-нитмичә, тотып ашый да башлады.

– Ай-һай, Хәмдияттәй, тәмле пешкән дә соң бу яшь тәкә! – диде ул, умырып капкан саен башын чайкап... Ахырдан гына бер бәрәңге кабып җибәрде, аннары майланган бармакларын итегенең кунычына ышкыды да, торып, өйгә бәрәкәт теләп, рәхмәт әйтеп чыгып та китте.

Ниһаять, бар да ашка җыелдылар. Балаларны казан ягына сәкегә урнаштырдылар – кунак барында аларның урыны шунда икән.

Җиңгәчәсе зур агач табак белән аш сосып китерде. Өреле шулпага катык тугылап ашадылар – Кларага бик ошады авылча «симез» токмач белән шулпа... Шулпадан соң җиңгәчәсе һәммәсенең тәлинкәсенә тутырма дигән нәрсә салып чыкты. Бусы – тәкәнең үпкә-бавырыннан, дөге белән бергә эчәккә тутырып, шулпада пешерелгән казылык иде. Клара, аны капкач, телен йотардай булды – гаҗәп тә тәмле иде ул! Шунда ук кечкенә блокнотына, бу тутырма дигән хикмәтнең ничек эшләнүен сорашып, язып та алды. Янәсе, Казанга кайткач, үзе пешереп, өйдәгеләрне бер сыйлаячак.

Аннары коштабак белән калҗалап тураган ит килде. Җиңгәчәсе аның өстенә суганлы, борычлы кайнар өре салып җибәрде – һәм өйгә әчкелтем хуш ис таралып китте.

Шуны әйтергә кирәк, баягынак Кларaның кәефен боза язган тәкәне кызгану хисе хәзер каядыр югалган иде инде... Ашаганда тере тәкә аның күз алдына килеп җанын борчымады. Хәер, табын яны гел сүз белән узды, һәм Кларaның уе бөтенләй башка нәрсәләргә китте. Менә

хәзер генә ул туганнары белән якыннан танышты. Рәхмәй абыйсы гади колхозчы икән, бригадир кая җибәрсә, шунда эшләп йөри икән, ләкин болай селкенеп йөрүдән туйдым, ди, колхозыбызның хәзер үз машиналары булачак, берәр комбайнга басарга исәпләп торам, ди. Председательләре аңа вәгъдә биргән икән инде.

Мөнирә җиңгәчәсе, әйткәнебезчә, фермада сыер сава. Клара ни өчендер аны тирә-якка даны таралган алдынгы сыер савучыдыр дип уйлаган иде. Ләкин алай ук түгел икән, газетада рәсеме чыкмаган икән әле... Җиңгәчәсе, акланырга теләгәндәй, сыерларыбыз вак, ди, югыйсә тырышабыз инде, ди. Шулай да ферма тактасына гел язылып бара икән.

Клара аларның көнкүреш хәлләре белән дә, читләтеп кенә булса да, кызыксынып карады. Карт җиңгәчәсе ике сүзнең берендә «Аллага шөкер» дип тора. Ипи кайгысы китте, ди, түбәбездән су үтми, ди, мал-туарыбыз бар, ди, аяк-кулыбыз сау, ди. Аннары аның читтәге ике улы белән бер кызы да онытып бетермиләр икән, чәй-шикәрлек карчыкка килгәләп тора икән.

Гомумән, ул бик азга да шөкер итәргә өйрәнгән, ахрысы. Чөнки сугыш башланган елны ирennән калып, берсеннән-берсе яшьрәк алты баласын бик зур авырлык белән үстергән. Ә нужа азның да кадерен белергә өйрәтә икән ул...

Әле дә менә, сүз чыккач, гади генә бернәрсә итеп сөйләп алды:

– Шулай, сугыш вакытында, яшь ярымлык Һәдиямне күтәреп, стансага икмәк эзләп бардым, – дип башлап китте ул, тирләгән битен тастымал очы белән сөртә-сөртә. – Икмәкне таптым, кайтырга чыктым, бер беләгемдә бала, икенчесендә – ашъяулыкка төреп элгән ике зур каравай... Кайта-кайта кулларымның чистый хәле бетте бит, өзелеп төшәләр дип торам... Нишләргә инде?.. Күп тә калмады югыйсә, ә баралмыйм гына бит, хет ташла да кит... Шуннан, Һәдиямне юл кырыена утыртып калдырдым да төенемне бер җир буе алга илтеп куйдым. Аннан баламны килеп алдым. Тагын төенемне алга илтеп куйдым, тагын баламны кире кайтып алдым... Шулай итеп, әле ипекәемне, әле балакаемны күчерә-күчерә, көч-хәлгә кайтып егылдым!

Клара шактый сүзсез калып утырды, әллә нишләтте аны бу кечкенә хикәя, әйтерсең бәгырен туңдырып җибәрде. Ләкин моның сәбәбе җиңгәчәсен яки юл буенда утырып калган баланы кызганудан гына түгел иде (кызгану бу очракта бик зәгыйфь хис ул), ә дөреслекнең кайвакытта никадәр рәхимсез булуын аңлаудан, кешеләрнең шуңа тыныч карый алуларына хәйран калудан иде. Гаҗәеп бит! Җиңгәчәсенең сүзендә ник бер сыкрану ишетелсен! Булган да узган – бары шул гына! Җитмәсә, әле Кларaны юатып маташа: «Синең, Иркә туташ, исең китмәсен, – ди. – Һи, аныңише генә хәлләр кем белән булмады, – ди. – Адәм баласы әрсез бит ул, көлдә аунар —көнен күрер, – ди. – Һәдиям дә менә, шөкер, фызу бетерде, калада шкатурчы

булып эшли, үзебез дә, колхозыбыз тернәкләнгәч, күкәй эчендәге сары кебек тора башладык», – ди.

Әлбәттә, Кларaның үзеннән дә күп нәрсәләр турында сораштылар. Ләкин Клара өчен үз хәлләрен ачык кына сөйләп бирү шактый читен мәсьәлә иде. Аерма бик зур, тормышлар бөтенләй икенче төрле, теләкләр дә, юанычлар да башкача иде. Сөйләсә, ихтыярсыздан шул аерма ачылачак, ничектер мактану булып чыгачак. Ә аның бу кешеләр алдында мактанасы, шәп, рәхәт торулары белән ялтырап күренәсе килми иде. Шуңа күрә ул күбрәк бабасы турында, бабасының Каракошны ничек сагынуын, ничек аңа туган якларны бер кайтып күрергә әйтә килүен сөйләп утырды.

Сүз ахырында, иртәгә Каракошка барып кайтырга булдылар. Җае да чыгып тора икән – Рәхмәй абыйсы, бригадир кушуы буенча, шунда барырга тиеш.

**III**

Икенче көнне, иртәнге чәйдән соң, Рәхмәй абыйсы әлеге биле сыгылыбрак торган тарантаска Алмас белән Алсуны утыртып, шул ук бәләкәй атта кызу гына ишегалдына юырттырып килеп керде. Балаларны төшереп, печән өстенә чуар палас чыгарып җәйделәр, ике мендәр салдылар.

Иң элек Хәмдия җиңгәчәсе – кызыл эчле тирән галошлардан һәм эре чәчәкле шәльяулыктан, туйга баручы кодача төсле, бисмилласын әйтеп, иплэп кенә тарантаска менеп утырды. Аның янына чажлап торган ефәк плащтан, каурый кадаган бик килешле күк эшләпәдән Клара менеп урнашты.

Кузгалып киттеләр. Балалар әниләре янында елашып калдылар. Шулар гына Кларaның йөрәген бераз сыкратып алды...

...Авыл урамының түбән очыннан барып чыккач, сулга борылып, тау итәгеннән киттеләр. Ялгыз утырган тау шактый биек һәм мәһабәт иде. Таулар Кларада һәрвакыт ихтыярсыз соклану уяталар. Гүя алар, дөньядан югары күтәрелеп, түбәндәге тормышка бәйсез бер горурлык белән, тын гына карап торалар. Алар бик күп хәлләрне күреп беләләр һәм эчләренә җыеп баралар төсле... Нинди генә тауны күрмәсен, Кларaның шуңа менәсе, шуның түбәсеннән дөнья өстенә карап торасы килә иде.

– Җиңгәчәй, бу нинди тау? – дип сорады ул, калкына биреп.

– Бу безнең Чабылтавыбыз, – диде җиңгәчәсе.

Моны ишетүгә, Кларaның исенә бабасы кылт итеп төште. Мәрхүм бабасы еш кына: «Чабылтау, Чабылтау», – дип сөйләнә иде. Шушы икән инде ул Чабылтау! Бабасы малай

чагыннан ук бу тау тирәсендә күп йөргән булырга тиеш. Шунда аларның җирләре, шунда печәнлекләре булган шикелле... Клара бу хакта сорагач, җиңгәчәсе:

– Әйе, аккошым, каенатамнарның Корысазлык дигән печәнлекләре шушында иде шул, – диде.

Кучерда ат тотып барган Рәхмәй абыйсы борыла төшеп:

– Корысазлык бездән сулда кала, күрсәтермен әле,—диде.

Һәм бераз киткәч тә, ул сирәк-мирәк кенә нечкә каеннар үскән, ә урта бер җирен яшел таллык каплаган зур гына уйсулыкка чыбыркысы белән төртеп күрсәтте.

– Әнә шунда инде Корысазлык. Борын аның уртасында түмгәкле күл булган, диләр. Хәзер ул күл юк инде, кибеп бетте... – Һәм Рәхмәй абыйсы боларга кырын утырып, Клара өчен кызык бернәрсә итеп, сөйләп китте: —Элек заманда бу сазлыкка торналар күп килә торган булганнар... Торна ул оясын түмгәк өстенә ясый икән. Бала чыгарганда, шул түмгәккә атланып утыра икән, аягы бөкләнми, имеш, аның... Бервакытны Хәнәфи дигән карт, сазлык яныннан үтеп барганда, түмгәк өстендә утырган торнаны шәйләп алган, ләкин торна икәнен танымаган... «Кемнең чикмәне анда ята?» – дип уйлаган карт. Шуннан тиз генә ыштанын салган да, бер чыбык сөйрәп, суга кереп киткән бу... Түмгәккә якынлашкач, «чикмәнне» эләктереп алыйм дип, чыбыгын торнага төртүе булган, торна, сискәнеп: «Тар-тар!» – дип кычкырып җибәргән... Моны ишеткәч, карт, тураеп, күкрәгенә сугып: «Шаярма, тар-тар түгел, Хәнәфи абзаң булыр бу!» – дип әйткән, ди...

Көлештеләр, ә җиңгәчәсе: «Һи, заманнар, картлары да балалар төсле булган», – дип, бер көрсенеп куйды.

Юл, Чабылтауны әйләнеп, көньякка табан борылгач, Клара алдында гаҗәеп күренешләр ачылды. Бу ялгыз тау үзе дә гаять зур биеклек өстендә утыра икән. Шушы биеклек өстеннән кайсы якка гына карасаң да, җәелеп яткан аксыл иген кырлары, яшел үзәннәр, күгелҗем урманнар, бөдрә куаклыклар белән капланган озын чокырлар, якында һәм еракта утырган тагы да ниндидер мәһабәт таулар күренә иде. Рәхмәй абыйсы юл буенча диярлек шуларның әле берсен, әле икенчесен күрсәтеп барды: «Ә-әнә теге Өзектау инде! Шуннан уңга таба китсәң, безнең Зирекле буена барып чыгасың. Әнә нәкъ каршыбызда Әркәсле яланы... Сулга карасаң, әнә анда Имәнлек башланып китә... Бабакаеңнан ишеткәнең дә бардыр әле».

Әйе, дөрес, Клара боларның барысын да бабасыннан ишеткәне бар иде. Шуңа күрәдер инде хәзер аңа бу кырлар, бу таулар, бу урманнар электән үк таныш төсле булып тоела иде. Хәтта берара аның күңеленнән: «Тукта, мин үз күзләрем белән дә боларны кайчандыр бер күрдем түгелме соң?» – дигән гаҗәеп сәер, шул ук вакытта ничектер бик якты, ләззәтле сизенү

кичеп үтте. Бик ышанасы килде шуның чын булуына! Ләкин... юк, күргәне юк, әлбәттә. Әмма шушы ачык сизенү тәэсиреннән ул ихтыярсыз авыз эченнән генә берничә мәртәбә: «Туган туфрак, туган туфрак!» – дип кабатлап куйды.

Гел юырттырып бара торгач, алар ахырда ак маңгайлы тәбәнәк таулар өстенә килеп чыктылар. Түбәндә кечкенә елгачык, шул елгачык буйлап сузылып киткән Каракош авылы җәелеп ята.

Ике тау арасындагы текә юлдан атны тыя-тыя гына түбән төштеләр һәм чуерташлар өстеннән сырланып аккан инешне кичеп, бер тыкрыктан авылның зур урамына барып керделәр... Менә сиңа Каракош!

Тәҗрибәле күз бу авылның кайчандыр бик зур булуын һәм бик тыгыз утырганлыгын чамалар иде. Төп урамның бер очыннан икенче очын күреп булырлык түгел... Тагын янәшә сузылган һәм аркылы кисеп узган урамнар да бар. Кыскасы, искечә әйткәндә, элек бу өч-дүрт мәхәлләле бер авыл булган булырга тиеш. Хәзер исә, өстеннән давыл узгандай, ул бик сирәкләнеп, тузгып калган иде. Заманында Каракоштан өч-дүрт кечерәк авыл бүленеп чыккан. Аннары елдан-ел акрынлап, йорт-җирләрен бетереп, читкә китүчеләр дә күп булган... Колхозлашу елларында мондый зур авылдан читкә сөрелүчеләр дә аз булмагандыр, һәрхәлдә, Каракош башыннан күп хәлләр кичкән булырга тиеш.

Ләкин Клара боларның барысыннан да хәбәрсез иде, билгеле. Авыл аңа шактый табигый һәм тыныч-имин булып күренде. Хәер, асылда Каракош хәзер шундый иде дә.

Авыл уртасына җитәрәк алар урамга буй салынган, такта белән япкан таза гына йортның капкасына килеп туктадылар. Бу – Кларага әллә кайсы яктан, әллә ничек кенә кардәш тиешле Сәйфетдин абзыйның йорты иде. Капканы өстенә ак күлмәк, башына кара кәләпүш кигән кәкрерәк аяклы хуҗа үзе ачты.

– Һай, бәрәкалла! Әйдәгез, хуш килдегез! – дип каршы алды ул кунакларны.

Ат ишегалдына узып, кунаклар тарантастан төшәргә өлгермәделәр, өйдән шәһәрчә диярлек киенгән, кечкенә буйлы, йөзгә бик сөйкемле яшь хатын һәм буйга-сынга таза гына егет ашыгып чыктылар. Болар Сәйфетдин абзыйның улы белән килене иде...

Хәмдия җиңгәчәсе Клараны терсәгеннән этәребрәк:

– Менә Иркә туташны сезгә күрсәтергә алып килдем, – диде. – Хамматҗан дәдәбезнең внукасы була инде. Каладан кайтты.

– Һи-и-и, шулаймыни? – диде Сәйфетдин абзый, тәмам шаккатып. – Хамматҗан абзыйның шундый внукасы бармыни? Машалла! Күз генә тия күрмәсен, алтын алма булып җиткән икән! Әйдүк, әйдүк, ике күзем, түребездә бул!

Барысы да аның белән бик куанышып күрештеләр. Аеруча Клараны күрүенә яшь килен бик шат иде шикелле – ничектер беренче караштан ук ул аңа, үз тиңен очраткандай, бик җылы, бик якын итеп карады. Аннары кунакларны өйнең түр ягына алып керделәр. Өй эче тәмам шәһәрчә дип әйтерлек иде. Биредә никель карават та, шифоньер да, китаплар тулы этажерка да, хәтта зур радиоалгыч та бар иде. Чебеннең әсәре дә юк, үзе чиста, үзе рәхәт, салкынча... Күренеп тора, шәһәр тәртибен алып килгән кешенең кулы хуҗа монда...

Яшь килен, биленә кечкенә алъяпкыч буып, аш-чәй хәстәренә кереште. Ире дә аңа, кушмастан, булыша башлады... Хикмәт шул яшь килендә түгелме икән?.. Картлар үзара хәл-әхвәл сораша башладылар, Сәйфетдин абзыйның карчыгын сагынып исләренә төшерделәр, ул күптән вафат икән инде.

Хуҗа бер чыккан арада, Клара җиңгәчәсеннән акрын гына: «Бабакайлар йорты еракмы, кайчан барабыз?» —дип сорап куйды. «Ерак түгел», – диде җиңгәчәсе; шуннан, Клара бик үтенгәч, алар чәйгә хәтле барып килергә булдылар.

Урамга чыккач, җиңгәчәсе Кларанны югары очка таба алып китте һәм, бераз баргач та, ике йорт арасындагы иркен генә бер буш урын каршында тукталды.

– Менә шушы була инде бабаңнарның утырган җирләре, Иркә туташ! – диде ул, кабер өстенә килгәндәй, тавышын акрынайтып.

Клара берни аңламыйча әүвәл алга, аннан тирә-ягына каранды. Нәрсә соң бу?.. Урамнан алып инешкә төшеп җиткәнче алабута, кычыткан, әрекмән басып бетергән буш җир җәелеп ята. Ник бер агач, ник бер таш, ник бер каккан казык күренсен! Бу урында кайчан да булса кемнәрнеңдер йорт-җир белән дөнья көтеп яшәүләрен күз алдына китерүе дә бик читен иде. Клара, тәмам аптыраган хәлдә, ни әйтергә белмичә, шактый сүзсез тынып торды. Җиңгәчәсе, аның хәлен аңлап булса кирәк, җиңелчә көрсенеп әйтеп куйды:

– Бетте шул инде, нигез дип әйтерлеге калмады...

– Ә кая булды соң мондагы йорт, бабакайдан калган йорт? – диде Клара, нигәдер бераз сабырсызланып.

– Соң белмисеңмени, бабаң бит, сезнең янга киткәндә, йортын сакау Хисамига сатып китте!

– Беләм. Ишеткәнем бар... Ну, ә ул Хисами кайда соң монда?

– Хисамимы? Хисами сугыш беткәч тә сафхузга күчеп китте... Йортын да шунда күчерде... Бик әйбәт тора, диләр... Күркәсенә чаклы асрый икән... Ишетмәдегезмени?

Клара башын гына чайкады... Һәм алабута, кычыткан баскан буш җиргә карап тора башлады. Шушы икән инде... «нигез»!.. Бернинди кызгану-фәлән кебек нәрсә хис итмәде Клара

үзендә, тик алдануы өчен кәефе генә азрак кырылды... Бер генә дә күрер нәрсә калмаган ич! Хыялы белән дә ул биредә нәрсәләр булганын күз алдына китерә алмый иде... Юк, билгесез, ят бер урын икән бу аның өчен... Ләкин шулай да ул уйламыйча булдыра алмады: әгәр бабасы үзе бу ташландык урынны кайтып күрсә, нишләр иде икән? Түзмәс иде, елар иде, һичшиксез елар иде... Туган җирем, гомер иткән җирем, дип, шәһәрнең дүрт стенасы эчендә гел сагынды да утырды бит!

Инде китәргә дә ярыйдыр. Шулай да Клара, нидер исенә төшереп, җиңгәчәсеннән сорады:

– Бабакай: «Бакчабыз бар, бакчабызда зур каен үсеп утыра», – дип сөйли торган иде. Кайда ул?

– Каенмы?.. Ә әйе, бар иде шул, бар иде... Кистеләр. Каенын да, барысын да кистеләр. Хуҗасыз калгач ни...—Җиңгәчәсе башындагы яулыгын алгарак тартып куйды.—Бабаң картайды, – диде ул, сузып кына... – Малайлары таралышып беттеләр. Карчыгы үлде. Ялгыз нишләсен ул монда?.. Барысын сатты да китте...

– Җиңгәчәй, син бу йортны яхшы беләсеңдер инде?

– Һи, белмичә соң! Мин бит шушы йортка килен булып төштем. Минем Хамматшам бабаңнан аерылып чыкмаган иде әле... Туебыз бик тә күңелле, бик тә шәп узды... Вәлиулла абзый, мәрхүм, туй капкадан килеп керүгә, мылтыктан атып җибәрде. Ул халык, мин сиңа әйтим, ул бала-чага!.. Мине җитәкләп ак киез өстеннән генә өйгә алып керделәр... Һи, сөйләсәң, Иркә туташ, исең-акылың китәр. Үтте инде... үтте. Аллага шөкер, менә хәзер үзем дә киленле булдым. Тик Хамматшам гына күрмәде.

Шулай элекке нигездән бер таш кисәге дә калмаган буш җир өстендә анысын-монысын искә төшереп бераз сөйләшеп торганнан соң, алар акрын гына кузгалып, Сәйфетдин абзыйларга кайтып киттеләр.

Яшь киленнең тәртипле, матур, мул табыны әзер иде. Биредә инде күп сыйлар өстенә тагын быелгы җир җиләгеннән кайнаткан варенье да һәм баллап катырган чәкчәк тә бар иде.

Чәйне озаклап, тәмләп эчтеләр. Сәйфетдин абзасы белән җиңгәчәсе сөйләшеп рәхәтләнделәр генә. Әллә кайчангы хәлләрне искә төшереп, әллә кемнәрне телгә алып беттеләр. Кем белән ни булган, кем кая киткән, ул анда ничек тора, кемнең баласы кайсы шәһәрдә кем булып эшли, кемнең улыннан яки кызыннан күпме акча килгән, ә кем бер тиен дә җибәрми – барысын да санап чыктылар. Клара бернәрсәгә гаҗәпләнде: Каракоштан дөньяга сибелгән кешеләр гаять күп икән... Ерак Көнчыгыш, Себер, Урта Азия, Урал, Мәскәү, Ленинград, Киев,

Баку —кая гына барып чыкмаганнар алар! Тагын шунысы кызык – кайда гына булмасыннар, ниндидер нечкә җепләр аларны Каракош белән һаман бәйли икән әле.

Чәйдән соң яшьләр авыл буйлап бер йөреп кайтырга дип чыгып киттеләр. Хәмдия җиңгәчәсе үзе кушты: «Сания килен, барыгыз, Иркә туташка авылны күрсәтегез, казаныңны үзем карармын», – диде ул яшь киленгә.

Сания үзе дә, аның ире Зиннур да Клара өчен бик кулай кешеләр булып чыктылар. Алар икесе дә Каракош мәктәбендә укыталар икән. Сания үзе шәһәр кызы икән, педагогия институтын бетергәч, аны шушы авылга җибәргәннәр... Клара башта ук аның авыл кызы булмавын сизенгән иде. Инде белгәч, ул аңа үзе ишедәй бик якын булып күренде.

Зиннур инде төп Каракош егете иде. Ул эше белән дә, укуы белән дә Саниядән түбәнрәк тора шикелле – Клара шулайрак сизде... Аннары егет үзенең кечкенә хатынын бик ярата иде булса кирәк. Ничектер менә хуҗасына бик ияләшкән юаш ат шикелле тота иде ул үзен Саниясе янында.

Алар Кларины урам уртасыннан түбән очка таба алып киттеләр. Авылның хәл-әхвәлен аз-маз сөйләп бардылар. Әлбәттә, киләчәген күбрәк сөйләделәр, чөнки алар яшьләр, чөнки Каракошның киләчәге, үткәненә караганда, һичшиксез, матуррак булырга тиеш. Бу ышаныч, бу теләк бигрәк тә шәһәрне ташлап килгән Саниядә нык сизелә иде. Гүя аңа шунсыз монда яшәү мөмкин дә түгел!

Дөрес, Каракошның хәзергә әле ерактан килгән кунакка мактап күрсәтерлек әллә нәрсәсе юк. Күп нәрсәләр яңа башланган яки планда гына икән әле... Хәер, бу гаҗәп тә түгел, чөнки ярты халкы таралып беткән Каракош, озак еллар бер урында таптанып торганнан соң, яңарак кузгалып, югары үрмәли башлаган иде.

Кларага колхозның былтыр гына салынып беткән яңа идарәсе белән гаражын күрсәттеләр. Рәшәткәләп алган иркен ихата эчендә зур, матур йорт. Алты тәрәзәсе урамга карап тора. Бер башында китапханә икән... Клара: «Ә клубыгыз бармы?» – дип сорагач, Сания аңа бер генә сүз белән җавап бирде: «Булачак!»

Идарә артындагы яшел чирәмгә салынган ике ишекле кызыл кирпеч гараж да болай зур гына, чибәр генә кебек иде. Зиннур әйтә, монысы, ди, идарә машиналары өчен генә, ди, ә колхозның барлык машиналары өчен авыл читендә зур сарай салынып ята, ди.

Бер уңайдан Кларага идарә каршында торган мәчетне дә күрсәттеләр. Клара гаҗәпләнә калды: мәчетнең тәбәнәк кенә манарасы белән кәкрәйгән ае да бар, имеш! Ничек сакланган ул! Ләкин бик тә искергән, тузган инде. Түбә такталарына яшел мүк чыккан, бүрәнәләре тәмам караеп беткән. Тәрәзәләре яшькелт зәңгәргә әйләнеп, карасу төшкән күзләрдәй, дөньяга күрмичә

карыйлар төсле... Мәчет Кларада ятсыну һәм шомлануга охшаган ниндидер бер авыр хис уятты. Ә бабасы аның мәчет катындагы мәдрәсәдә укып йөрүен сөйли торган иде. Анысы хәзер юк, күрәсең. Әйе, бабай заманындагы нәрсәләр акрынлап менә шулай тузып, череп, юкка чыгып беткәннәр яки бетеп баралар икән инде... Алар урынына әнә бабай күрмәгән, бабай белмәгән яңалары туа...

Мактаулы Каракош! Клара үзенчә бик кызыксынып, сынап карый аңа. Монда беренче күзгә ташланган нәрсә — авылга каршы яклап тезелеп киткән таулар иде. Бабасы: «Каракошкайның таулары киртләч-киртләч, киртләчләре бетә кар киткәч», – дип җырлый торган иде. Чынлап та, бу ак маңгайлы текә тауларны вак ерганаклар агып һәм кәҗәләр таптап, аркылыга-буйга сырлап бетергәннәр икән. Таулар Кларага ни өчендер тәбәнәк һәм боек күренделәр.

Авыл үзе бик чуар. Өйләрнең искергән-тузганнары да күп, ишелергә торганнары да бар; нигезен яки түбәсен яңартып җибәргәннәре дә шактый гына, өр-яңадан салынганнары да очрый... Әгәр Клара урынында берәр дөнья күргән олы кеше булса, ул, бу өйләргә карап, авылның үткән тарихын да, бүгенге хәлен дә китаптан укыган шикелле укыр иде.

Авылда яшеллек тә аз икән. Агач бакчалары юк диярлек, тик кайбер йортларның гына тәрәзә алларында сирень куагы, киртә буйларында ялгыз каен яки шомырт, яки миләш агачы үсеп утыра. Әмма һәрбер йортның койрыгында сузылып киткән бәрәңге җире бар. Клара өчен кызыклы түгел ул бәрәңге җире. Хәер, аны шагыйрьләрнең дә мактап җырлаганнары юк әле. Авыл кешесенең үзе өчен генә кадерле ул... бәрәңге!

Шулай карап уздылар Каракошның зур урамын. Очраган бер бала, алар белән исәнләшеп, авызын ачып калды. Ишегалдында йөргән агай яки җиңги дә туктап, каз шикелле башын кырын салыбрак карап калды. Чөнки безнең Кларабыз бик сылу кыз иде, бик чибәр киенгән иде. Шуңа күрә инде һәркемнең күңеленә: «Кемнеке булыр бу, кайдан кайткан, ниләр алып кайткан?» – дигән уйның килмичә калуы һич мөмкин түгел иде.

Авылдан тип-тигез тугайлыкка барып чыктылар. Алда – буа, буада – иске тегермән, ә тегермәннән ары ферма каралтылары күренә. Ямь-яшел тугайда көтү-көтү ап-ак казлар утыралар.

Яшьләр фермага барып тормадылар, чөнки анда буш абзарлардан башка берни дә юк, маллар – көтүдә... Авыл артына, чирәмлеккә күтәрелеп, шуннан ашыкмыйча гына кайтырга булдылар.

Монда җире дә, һавасы да бүтәнчәрәк икән – ничектер дала исе аңкый. Бөрчекләнеп торган кара туфрак, эсседән кипкән сирәк үлән һәм ефәк чуклы кылганнар... Кылганнар... Гел бер якка таба селкенеп торалар икән бу... кылганнар. Казан тирәсендә юк бит алар.

Сания, иелеп, җиргә учлам-учлам ябышып үскән вак кына зәңгәр чәчәкле бер үләнне йолкып алды да Кларага:

– Мәгез әле, иснәп карагыз! – дип сузды.

Клара үләнне алып борынына китерде һәм хәйран калды: үлән искиткеч хуш исле иде.

– Нәрсә бу?

– Ислекәй... Ислемай үләне, – диде Сания.

Ислемай үләне! Клара аны тирән итеп, кат-кат иснәде һәм бер мәлгә исереп киткәндәй булды. Чиксез дала аның күз алдына килде. Бабасының яшь малай чагын, шушы ислемай үләннәрен җыя-җыя йөгереп йөргән чакларын ап-ачык күргәндәй булды... Кинәт шулкадәр ерак үткәнгә кайта алу әллә ничек шомлы да, әйтеп бетергесез татлы да булып тоелды аңа... Айнырга теләп, ул башын кат-кат чайкап куйды.

Сания тагын ак әремне дә уып иснәтте. Монысыннан да дала эссесе, дала исе аңкып тора иде. Клара ихтыярсыздан: «Әтием бу исләрне ничек оныта алды икән?» – дип уйлап куйды. Ә менә бабасы онытмаган иде, сагына иде. Әгәр ул исән булса, Клара бу үләннәрне алып кайтып, аңа иснәткән булыр иде.

Көн бик эсселәнеп китте, шуңа күрә яшьләр артык юанмыйча өйгә кайтырга ашыктылар. Хәтта авылдан читтәрәк тигез чирәмлектә утырган зур таш мәктәпкә дә кереп тормадылар, тик Сания генә бу мәктәпнең районда иң зур, иң бай мәктәп булуын сөйләп алды. Алар шунда укыталар икән инде...

Кайткач, тагын чәй эчтеләр. Аннары каклаган ит, яңа бәрәңге турап һәм күкәй калҗасы салып пешергән бик тәмле аш ашадылар. Ниһаять, көн сүрелгәч, Сания белән Зиннурны берсекөнгә Зиреклебашка кунакка чакырып, юлга чыктылар.

Авылны чыкмас борын Рәхмәй абыйсы атын беразга гына кибет алдында туктатты. Җиңгәчәсе кибеттән, зур бер яулыкка барысын бергә салдырып, чикләвек, йөзем, кипкән өрек кебек нәрсәләр алды. Күлмәгенең тирән кесәсеннән кулъяулыкка төргән акчасын чыгарганчы, Клара барысы өчен түләп тә өлгерде. Аннары ул тагын бишбылтырдан бирле сатылмыйча яткан краб консервысын да, тозы өстенә чыккан селедканы да алмакчы булган иде дә, җиңгәчәсе моңа бик каршы төште. «Акчаңны әрәм итә күрмә, бездә андый нәрсәләрне ашаучы юк»,—дип, тәки алдырмады. Шуннан соң Клара Рәхмәй абзасына, көчләп дигәндәй, илле сумлык акча бирде.

Рәхмәй үзеннән дә өстәп ике шешә акны, бер шешә кызылны алды. Шуларны кучер астындагы печәнгә әйбәтләп яшергәч, утырышып, авылдан чыгып киттеләр.

Кояш баер алдыннан гына Чабылтау итәгенә килеп җиттеләр. Кайтышлый сүз аз булды. Җиңгәчәсе, тирбәлеп килә торгач, оеп китте. Рәхмәй абыйсы башта колхоз эшләре турында аны-моны сөйләнеп килде-килде дә аннары ул да тынды. Клараны бу сүзсезлек, бу юл талгынлыгы бер дә ялыктырмады, киресенчә, ул аңа риза иде, чөнки ул да, үз эченә йотылып, үз уйларын уйлап кайта иде.

Тау итәгенә җиткәч, барысы да җанландылар. Җиңгәчәсе калкынып:

– Мәшалла, кайтып җитәбез түгелме соң? – диде.—Һи, көтү дә кайтып бара икән ләбаса!

Чынлап та, алда, Корысазлык ягыннан юлга таба көтү чыгып килә иде. Рәхмәй абыйсы атын кызулата төште, һәм алар тузан, йон, сөт исе аңкыган көтүнең нәкъ алдыннан уздылар. Шул чакта Клара бик сәер бернәрсә күрде: җирдән, кәҗә-сарыклар арасында, әллә нихәтле сыерчыклар кайтып килә. Нәкъ менә көтүгә чыккан йорт кошлары шикелле очмыйча, җәяүләп, йөгерә-йөгерә кайтып киләләр. Бу гаҗәп сәер, кызыклы күренештән кәефе бик килгән Клара кычкырып ук җибәрде.

– Җиңгәчәй, карале, көтүдә сыерчыклар!

– Ә, ие шул! Бала очыргач, көтүдән калмыйлар инде алар.

– Нигә, ни өчен?

– Нигә дип, мал тирәсендә аларга азык табыла. Мал белән бит чебен дә корт та ияреп йөри... Шуларны чүплиләр инде бу Алла кошлары!

«Удивительно!» дип уйлап куйды Клара эченнән. Аңа ничектер берьюлы күңелле, рәхәт булып китте.

Рәхмәй абыйсы, артына каерылып, кояш баешына карап алды.

– Иртәгә дә аяз булмакчы икән, – диде ул, башын кагып. – Бик әйбәт. Печәнчеләргә мач килә.

Клара, кинәт җанланып:

– Җиңгәчәй, минем дә печәнгә барасым килә,—диде. – Миңа барырга ярыймы?

– Ник ярамасын! Ярый, бик ярый, аккошым! Үзем алып барырмын, – диде җиңгәчәсе, ничектер Клараның бу теләген шунда ук куәтләп.

– Көлмәсләрме?

– Юк, нишләп көлсеннәр, Аллам сакласын! Менә кызларыбыз белән танышырсың... Кызларыбыз бик куштаннар, кунак итеп, үзеңне урталарына гына алып йөртерләр.

Рәхмәй абыйсы кисәк кенә көлеп куйды:

– Хәсән, бригадир, нибуч кунак дип тормас!

– Ә мин кунак булып түгел, эшләргә барам! – диде Клара, эре генә башын чөеп.

– Әйе, әйе, эшләргә инде, печән җыярга, – диде җиңгәчәсе, бала көйләгәндәй итеп. – Бергә барырбыз. Мин үзем дә бик яратам печән эшен, Иркә туташ!

– Барабыз, җиңгәчәй, барабыз! – диде Клара, чын-чыннан рухланып, һәм аны кинәт ниндидер бер канатлану, җилкенү биләп алды. Һич уйламаганда, аның менә хәзер үк әнә шул Чабылтауга менәсе, шуннан дөнья өстенә бер карыйсы килде. Ул атны туктатырга кушты: «Мин тауга менәм!» – диде. Җиңгәчәсенең аптырап: «Һай, Иркә туташ, каян уйладың әле, кояш та баеп бара, ялгыз куркырсың ич!» – диюенә карамастан, ул тарантастан төште дә ашыга-ашыга тауга таба китте.

Тауны менү читтән караганда гына ансат булып күренә икән ул. Иң элек тау, менә башлагач, шактый биек булып чыкты, аннары югарырак күтәрелгән саен ул текәрәккә әйләнә барды. Кларның әледән-әле аягы тая башлады, хәтта ара-тирә артка таба шуып та киткәләде. Ләкин һичнигә карамыйча, үлән төпләренә аягын ныграк терәп, тазарак үскән сабакларга тотынып, иелә-бөгелә һаман күтәрелде. Ахырда, азаплана торгач, Чабыл башына менеп җитте... Туктады, тирән сулап, бермәл тын алып торды.

Тау түбәсе – ап-ак ташлык, үлән бик сирәк, урта бер җире чокыраеп тора. Монда сәер бер тынлык хөкем сөрә. Әллә нинди генә шунда, түбәндәге тормыштан аерылу хисен уяткан, бушлык халәтенә якын бер тынлык иде бу... Бу тынлыкта бары җилнең акрын гына исүе ишетелеп тора кебек...

Клара түбә уртасынарак атлады. Кояш баеп өлгергән иде инде... Ләкин бөтен әтраф бик якты иде әле, шунлыктан иң ерак офыклар да ачык күренә иде. Клара тантаналы бер киеренкелек кичергән хәлдә тирә-як дөньяны карарга кереште. Никадәр ерак җирләр ачылган иде аның күз алдында! Бик-бик еракта күгелҗем томанга өртелгән ялгыз таулар күренә, чиксез киңлекләргә сибелгән, әле тегендә, әле монда җиргә ябышып яткан авыллар күренә, җептәй сузылган юлларны да бик ачык аерып була. Хәтта юлларның теге яки бу төшендә, бөтерелеп сузылган тузанга карап, машиналар чабуын да шәйләп була иде. Һәм әнә шул таулар, кырлар, авыллар аша, ниндидер бер пәһлеванның зур адымнары шикелле, тимер челтәр баганалар әллә кайлардан килеп, әллә кайларга узып китәләр...

Клара озак кына Каракошны эзләде. Кайда ул, нигә күренми? Ниһаять, түбәндәге ике тау арасыннан ниндидер бер авылның читен күреп алды. Ул ерак та түгел иде. Клара чамалап карады: хәзер генә алар кайткан юл нәкъ менә шул ике тау арасыннан килеп чыга икән. Димәк, Каракош шунда. Тик ул тоташы белән күренми, әлеге ак маңгайлы тәбәнәк таулар аны каплап

торалар. Әмма Каракошның бер генә читен күрү дә Клара өчен күңелле булып китте, ничектер менә авылдан аңа җанлы бер җеп сузылган кебек булды. Каракош аңа да якын икән ләбаса!

Аннары тирә-якка күз йөртеп, акрын гына артына борылды. Кинәт аның күзенә нидер көзгедәй уйнаклап-чагылып китте. Шуны эзләп түбәнгә карагач, ул тау итәгеннән авылга таба кешеләр төялгән өч атның китеп баруын күреп алды. Менә шул алдагы атта баручы кешеләрнең баш өсләрендә нидер җылык-җылык уйнаклап куйгалый... Нәрсә бу?.. Ах, чалгылар түгелме соң? Әйе, әйе, чалгылар шул! Арбага ике яклап тезелешеп утырган егетләрнең бастырып тоткан чалгылары ара-тирә әнә шулай чагылып-чагылып киткәли икән!.. Печән чабучылар кайтып баралар. Арттагы атларга, тырмаларын югары күтәреп, хатын-кызлар төялгән... Бу күренеш Кларaны аеруча сөендереп җибәрде. Иртәгә бит ул үзе дә печәнгә чыгачак. Менә шулай, үзе кебек кызлар белән бергә, аякларын салындырып, арбага утырган килеш, тырмасын күтәреп болынга барыр, болыннан кайтыр!.. Теге кем, Хәсән дигәннәре: «Кунак кызга тырманың җиңелен әзерләп куярбыз!» – диде бит... Мут күз! Шәһәр кызының кулларын үзенчә кызгана торгандыр инде. Тукта, күрсәтер әле ул аңа үзенең кулларын!

...Менә Зиреклебаш. Карасана, яп-якында гына икән ул. Бөтен өйләре, каралтылары, ишегаллары, көтүдән таралган маллары, кичке эшләрен бетереп йөрүче кешеләре белән, уч төбендәге шикелле, ап-ачык күренеп тора. Ә-нә иң кырыйда Рәхмәй абыйларының өе. Ә-нә капка төбендә моннан бармактай гына күренгән Алмас белән Алсу тауга карап торалар бугай. Исләре китеп, Клара апаларын күзәтә торганнардыр инде алар. Уңган җиңгәчәсе кай арада кайтып, учагын ягып та өлгергән – морҗаларыннан аксыл төтен акрын гына һавага күтәрелә... Кунакчыл өйнең сый-хөрмәт төтене бу... Юк, алай гына түгел, туган туфрак төтене бу... Бар икән ул туган туфрак дигән кадерле җир! Һәм Клара үз гомерендә беренче тапкыр моның буш сүз генә булмавын аңлап, шуңа искиткеч сөенде. Беренче тапкыр, бик табигый рәвештә, туган җиренә, туган халкына, телдән генә сөйләнә торган түгел, ә кан тамырында йөри торган чын якынлык-мәхәббәт хис итте ул... Һәм бөтен хисләрдән дә изгерәк, көчлерәк бу хис аның яшь йөрәген әйтеп бетергесез куанычлы бәхет белән тутырды.

Ул, башыннан эшләпәсен алып, йөзен кичке тау җиленә куеп, күзләрен дым каплаганчы чиксез киңлекләргә карап торды. Аерыласы килми иде аның бу тын биеклектән, бу яңа, тансык хисләр дулкыныннан...

*1959*

**Матурлык**

*(Бер карт әдип авызыннан)*

Күптән, бик күптән булган вакыйга, әмма бүгенгедәй күз алдымда: без, өч шәкерт, бер атка утырып, өяз мәдрәсәсеннән авылыбызга кайтырга чыктык. Дөресрәге, Гыйлемдар белән без икәү бер авылга – Чуаркүлгә кайтабыз, ә Бәдретдинне юл өстендәге Ишле авылында калдырып китәргә тиешбез. Тагын шуны да әйтим, безне ялкау гына юыртып алып кайткан күк алаша Гыйлемдарларныкы иде. Без авылда алар белән күрше генә торабыз. Шул сәбәпле Гыйлемдар белән мине алырга бер язын безнең ат килсә, икенче язда алар аты килә торган иде.

Ә Бәдретдин безнең очраклы юлдашыбыз. Дөрес, без мәдрәсәгә бер вакытта җыелабыз, бер вакытта таралабыз, ләкин моңарчы аның белән бергә кайтырга туры килгәне юк иде әле. Бәдретдин кешегә бер дә йөк булырга яратмый иде. Укулар беткәч тә ул базарга килгән авылдашларының берсенә ияреп китә дә бара, яки ялгыз үзе генә утыз чакрымдагы авылына җәяүләп сыптыра торган иде. Бу юлы инде без аны, үзебез сорап дигәндәй, бергәләп кайтырга күндердек.

Бәдретдин безнең мәдрәсәдә иң ярлы шәкерт иде. Аңа авылыннан бернинди дә ярдәм килми иде. Тик Ишледән базарга килүче берәрсе бик сирәк кенә аңа әнисенең киндер чүпрәккә төреп җибәргән тары ипиен яки берәр йомарлам маен кертеп чыга торган иде. Бәдретдин шуны да бик кыенсынып: «Нигә инде бу? Әнкәйгә әйтегез, мин ач түгел, үзеннән өзеп җибәрмәсен!» – дип алып кала иде. Һәм шул майны ул ни өчендер без белән чәнчеп ашый иде. Шәкертләр аңардан: «Нигә алай итәсең?» – дип сорасалар, Бәдретдин көлгән булып кына: «Без белән ашагач, озакка җитә ул!» – дип җавап бирә торган иде.

Илдә чыпчык үлми дигәндәй, безнең Бәдретдин дә, бик интегеп, ачка киселеп булса да, укуын әнә шулай алып бара иде. Һәм бик яхшы укый иде ул. Хәер, бу күп сыналган нәрсә: рәхимсез нужада торып укыган ярлы шәкерт гадәттә бик сәләтле булып чыга. Башкача аңа мөмкин дә түгел. Бай шәкерт, әйтик, туң күчән булса да, мәдрәсәдә теләсә күпме ята ала, ә ярлы шәкерт, начар укыдымы, беренче кыштан ук мәдрәсәдән очарга мәҗбүр була... Аннары, ярлы шәкерт бик яхшы укыса гына үзенең матди хәлен дә беркадәр җиңеләйтә ала.

Менә безнең Бәдретдингә дә, ул замандагы тел белән әйтсәк, истикамәтле вә иҗтиһатлы шәкерт булганга күрә, байлар иганәсеннән ара-тирә ярдәм тия иде; начар укучыларның дәресләрен хәзерләшкән өчен дә аңа аз-маз тама иде, хәлфәләргә дә ул булышкалый иде, аннары авыру-сырхауларга догалыклар, Аятел Көрсиләр күчереп тә азрак бакырлар төшергәли иде. Кыскасы, эшсез тормый иде шәкерт. Ләкин эшне дә, ярдәмне дә ул үзе бервакытта да сорап алмый иде. «Мин бит ярлы, миңа ярдәм итү сезнең вазифагыз» дигән әрсез мескенлекне без аның йөзендә беркайчан да күрмәдек.

Табигате белән үк ул, ничек дим, шундый тигез, сабыр холыклы бер егет иде. Ялагайлана да белмәс, масая да белмәс, яхшы белән яхшы, ә яман белән алыш-биреше юк – андыйлардан үзен ничектер бөтенләй читтә тота белә иде. Тагын шунысы кызык, никадәр генә ярлы булмасын, ул берәүдән дә бернәрсә дә сорарга яратмый иде. Гадәттә, шәкертләр аңардан гел анысын-монысын сорап торалар, чөнки аның үз кулы белән ясаган каеш тупсалы, әрҗә сыман сандыгында мәдрәсә тормышы өчен кирәк бөтен нәрсәсе – энәсе дә, җебе дә, уймагы да, безе дә, пәкесе дә, эскәге дә, көзгесе дә, төрле каләмнәре дә, кәгазь-дәфтәрләре дә, хәтта җилем белән балавызы да саклана торган иде. Ничек җыйгандыр ул аларны, ләкин һаман шул ярлылыгым кешегә йөк булмасын дип, тамагыннан өзеп булса да, тырышкан, күрәсең инде. Дөрес, ул калын-калын дәрес китапларына бик мохтаҗ иде. Ләкин булган кадәресен бик пөхтә тышлап, битләре керләнмәсен өчен көмеш кәгазьдән тоткыч ясап, кадерләп кенә саклый иде.

Ул заманда, ягъни революция алды елларында, шәкертләрнең яңа әдәбият белән мавыгуы искиткеч көчәйгән иде. Икмәк шикелле үк зарури бернәрсәгә әйләнеп киткән иде безнең өчен әдәбият!.. Һәрбер шәкерт төпләп алган калын дәфтәренә җыр күчерә, шигырь күчерә, хәтта романнардан өзекләр дә күчерә. Ике шәкертнең берсе шигырь яза. Бик күпләр Сәгыйть Рәми белән тилерә. Аңа иярәләр, аңа охшарга тырышалар, аны яттан сөйләп йөриләр... Дөрес, безнең барыбыз өчен дә бөтенесеннән өстен, бөтенесеннән якын – Тукай иде, иң күп күчерелгән, иң сөеп укылган да Тукай иде.

Шигырь чире безнең Бәдретдингә дә йоккан иде, ул да яза иде, ләкин язганын бервакытта да күтәреп, очраган берәүгә укып йөрми иде. Аны сорап та укырга күндерүе читен иде. Инде укый калса, аның әйберсе башкаларныкы төсле зар еламыйча гына язылган, күбрәк табигать күренешен гади генә сурәтләгән яки үзенчә берәр тормыш фәлсәфәсе әйтергә тырышкан кыска гына шигъри парча булып чыга торган иде.

Әнә шундый сәер генә, серле генә һәм сөйкемле генә бер егет иде безнең Бәдретдин шәриктәшебез!

Ярый, сүз озынга китте, без бит әле өчәүләшеп читән тарантаста хозур гына авылыбызга кайтып барабыз. Юл такыр, тузан юк, күк алаша, эченә кату төшүдән «горт-горт» иткән тавыш чыгарып, үз көенә салмак кына юырта... Күптән түгел, май урталарында, беренче җылы яңгырлар явып узган иде. Хәзер бөтен нәрсә дәррәү кузгалып, күтәрелеп, үсеп бара: арышлар сабакка сузыла башлаган, бодайлар куе булып, кучкыл-яшел булып, егетләр мыегыдай, сызылып кына чыгып килә; сөрелмәгән чирәмнәрдә яшь үлән былтыргы корыган үләнне басып, каплап та киткән, кайберләре инде чәчәкләрен дә ачарга өлгергән... Юл буенда әнә эт эчәгесенең беренче ал «кыңгыраулары»... Әйтәсе дә юк, табигатьнең иң саф, иң садә, иң ямьле чагы!..

Безгә, кыш буе мәдрәсәдә кибеп яткан шәкертләргә, бу чиксез иркен, якты, җылыкай дөнья искиткеч тансык иде, шифалы-рәхәт иде, без аны иснәп тә, сулап та, күзләребез белән күреп тә туя алмый идек. Баштарак без әледән-әле тарантастан төшеп, аякларыбыз җирнең җылысын бер рәхәтләнеп татысын дигәндәй, чирәмгә кереп киттек, йөгерештек-куыштык, иелеп чәчәкләр өздек. Бәдретдин тау юасы тапты, аны өзеп чәйнәдек. Мин безнең авылда «тәмлекәй» дип йөртелә торган, сабагы дүрт кырлы, озын гына бер үсемлекне җыеп алдым. Аны да, тиресен суеп, ашап карадык. Бәдретдин әйтә, моны башкортларда «кияү камчысы» дип йөртәләр, ди, чөнки очындагы менә шушы бөреләре зәңгәр чәчәк булып ачылгач, ул чынлап та чуклы камчыга охшап китә, ди.

Ә безнең Гыйлемдар, озын сыйрак, гел йомран эзләп чапты, туктап, ике учын кушлап сызгырып та карады, ләкин хәйләкәр җәнлек шәкерт сызгырганын сизә иде ахрысы, оясыннан чыгып, колакларын торгызып, арт тәпиләренә утырмады.

...Юл буе безне тургайлар сайравы озатып барды. Гүя менә төпсез нурлы аяз күктән өстебезгә сихри бер моң тибрәнеп-чыңлап, өзлексез явып торды. Ә беләсезме, тургай сайравының сихере нәрсәдә?.. Иң элек, сынаганыгыз бардыр, тургай сайраганда җир өстенә җиңелчә генә уйчан-моңсу бер тынлык җәелә. Әйтерсең барлык табигать, барлык җан иясе, әдипләр әйткәнчә, сөкүт калып, тәмам мөкиббән китеп, бары аны гына тыңлый, аны тыңлап сөенечле, сагышлы, ләззәтле бер рәхәткә чума... Икенче сихере шунда ки, тургай сайраганда дөнья ничектер искиткеч җәелеп, киңәеп, яктырып киткәндәй була. Әнә шул югарыда кечкенә кошчык талпынган күкнең үзе шикелле үк, җир йөзе дә иксез-чиксез булып, гаҗәеп тын, нурлы булып тоела башлый...

Белмим, бу вакытта бүтән кошлар сайрый торгандырмы – игътибар иткәнем юк, әмма бер кошның тавышы, бөтен җир өсте тургайлар сайравыннан өзлексез чыңлап торса да, безне сискәндереп, колагыбызга килеп керә. Бу – кәккүк! Кешеләрнең исләренә ниндидер бик мөһим нәрсәне төшерер өчен табигать тарафыннан яратылган күзгә күренмәс сәер кош!.. Юлдан шактый читтә торган күксел урман яныннан узганда, без аның да тынып калырга мәҗбүр иткән кисәтүле тавышын ишеттек.

Шулай кәефләнеп, күңелле генә кайта торгач, без, ниһаять, кызыл ярлы тауларга каршы тигез үзәнлектә сузылып утырган Ишле авылына да якынлаштык. Юлга чыккач та Бәдретдин безне, Ишледә туктап, чәй эчеп чыгарга чакырган иде. Без, билгеле, кыстатып тормадык, шәриктәшеңә кереп, чәй эчеп, күңел ачып чыгу шәкертләр өчен табигый бер низам инде ул.

Авылга җиткәндә генә Бәдретдин, дилбегәне үзенә алып, атны олы юлдан уңга каерды да бәбкә үләне түшәлгән җир өстеннән генә иң арткы урамга таба алып китте. Һәм озак та үтми,

шул урамның иң читендәге, бүтән йортлардан аерылыбрак, ялгызы гына торган бер өйнең каршысына безне китереп тә туктатты.

Без фәкыйрь кешеләргә керәсебезне белеп килә идек, әмма бу кадәр ярлы хуҗалыкны күрербез дип һич тә көтмәгән идек. Хәер, моның хуҗалык дип атар җире дә юк иде. Шыр кырда утырган бәләкәй генә ялгыз өй үзе искереп-тузып, яртылаш җиргә кереп беткән. Салам түбәсе череп, каралып, тирескә әйләнә башлаган. Әйтерсең шуның авырлыгыннан өйнең кайбер бүрәнәләре бүселеп чыккан, ишек-тәрәзәләре кыйшайган, ә тәрәзә пыялалары тора-тора инде яшькелт-зәңгәр төскә кергән... Капка юк, койма юк, тик урам яклап та кыр яклап кына ике рәт киртә сузылган... Ишегалдын кыр үләне басып киткән. Анда чикерткәләр тыз-быз сикерешәләр. Димәк, бернинди аяклы мал да юк.

Без инде хәйран булып, гаҗәпләнеп калуыбызны Бәдретдиннең үзенә ничек тә сиздермәскә тырыштык. Арба эзе төшмәгән ачык ишегалдына узып, түбәсе чыбык-чабыклар белән ябылган иске генә бер читән абзар алдында атыбызны туктаттык. Өйдән кечерәк буйлы, ак чырайлы, җирән сакаллы, арык-өшән генә бер абзый чыкты. Аның өстендә киндер күлмәк, тез башларына зур ямаулар салынган киҗеле ыштан, башында мескен бүрек, аякларында тула оек белән тузган чабаталар иде. Ул, тарантас янына килеп, бары: «Улым!» – дип кенә Бәдретдин белән күреште, аннары безгә дә шулай сүзсез генә ике кулын сузды һәм шунда ук ат башына барып, аны тугара да башлады...

Бәдретдин сандыгын күтәреп өйгә ашыкты. Өй ишегендә бер хатын күренде, ләкин ул ни өчендер тиз генә кире борылды. Бу – Бәдретдиннең әнисе булгандыр инде, тик менә аның ишектән чыгар-чыкмас кире чигенүе безне бераз гаҗәпләндерде.

Атны тугарып бетүгә, Бәдретдин өйдән чиләк белән су, чүмеч һәм тастымал күтәреп чыкты. Чирәм өстендә генә чиләктән бер беребезгә су коеп юынып алдык. Күңелгә: «Комганнары да юк, күрәсең», – дигән уй килде. Һәм без бернәрсә күрмәгән, белмәгән булып кыланырга яки ваемсыз гына сөйләнергә ничектер сүз дә, сәләт тә таба алмый идек. Ләкин Бәдретдин үзе тыныч иде, һәрхәлдә, оялу-уңайсызлану кебек бернәрсә дә сиздерми иде.

Юынып беткәч, сәлам биреп, өйгә кердек. Бәдретдиннең әтисе бер читтәрәк торган килеш безне бик гади генә: «Әйдәгез, шәкертләр!» – дип каршы алды.

Караңгырак кына өй эче дә тышкы ягы кебек үк искереп, тузып беткән икән инде. Ләкин күпме генә искереп-тузып бетмәсен, аның бүрәнәләре тома балавыздай сары-көрән иде әле, тапталып, кырылып ашалган идәне дә чип-чиста иде... Өйнең бөтен түрен иңләп, өстенә киез җәелгән зур сәке тора, ике урындык, бер эскәмия, мич буенда тагын бер бүкән тора – менә

җиһаз дигәне бары шул гына. Мич алды иске генә чүпрәк чаршау белән бүленгән, анда кемнеңдер озын гына итеп чыра телүе ишетелә.

Өйгә кергәч тә безнең иң элек күргән кешебез сәке түрендә, стенага терәлеп, текә генә утырган бер бабай булды. Бабай Хозыр Ильяс төсле ап-ак сакаллы, ап-ак күлмәк-ыштаннан иде. Бары тик башындагы беленгә әйләнгән түбәтәе генә аның күксел-кара иде.

Без бабайга күрешер өчен кулларыбызны суздык. Бабай селкенмәде. Бәдретдин ашыгып әйтеп куйды:

– Бабакай, шәкертләр синең белән күрешергә телиләр.

– Ә, шулаймыни, бәрәкалла! – диде бабай, аз гына җанланып, һәм безгә кипкән, зур каты кулларын сузды. Күзләре ачык булса да, ул дөм сукыр иде.

Без утырышып дога кылдык һәм, шәкертләрчә кулларыбызны тез өстенә куеп, бер мәлгә тынып калдык. Безнең үзебезгә сүз башлавы, билгеле, кыенрак иде, аннары нидер менә телебезне һаман бәйләп тора иде. Ләкин, гаҗәп хәл, хуҗалар үзләре дә сүзсезләр иде. Гомумән, бу өйдә сүз бик аз сөйләнә булса кирәк – ничектер бик тиз без шуны сизгәндәй булдык. Бабай, үзенең эчке дөньясына киткәндәй, текә каткан килеш тып-тын утыра. Бәдретдин әрле-бирле йөренә, нидер әйтмәкче дә шикелле, ләкин сүз таба алмый кебек... Әтисе башта мич буендагы бүкәндә безгә бераз шаккатып утырды да, аннары, торып, сәке кырыена чәй урыны әзерли башлады. Иске генә киҗеле ашъяулык китереп җәйде, мич кашагасыннан кайсы замазка белән ябыштырылган, кайсының сабы кителеп төшкән өч кенә чынаяк алып куйды, кыска гына чалгы пычагы, чүпрәккә төргән ярты ипи, тустаган белән сөт китереп куйды. Шуннан соң тагын бүкәненә барып утырды. Бәдретдин үзенең сандыгыннан бер-ике уч шикәр алып, шуны ашъяулык уртасына салды.

Бераздан чаршау эченнән әкрен генә: «Булды, улым!» – дигән сүз ишетелде. Бәдретдин, кереп, самоварны алып чыкты. Бу самоварның да борын һәм колак төпләре кургашын белән ямалып беткән иде.

Бәдретдин безгә сәкегә менеп утырырга кушты. Без, менеп, аякларны бөкләп утырдык. Шуннан соң алдыбызга өчаяк белән йомырка тәбәсе килде. Без әле ашка сузылмыйча хуҗаларның утырганын көтә идек. Ләкин бабай да урыныннан кузгалмады, абзый кеше дә бүкәненнән тормады. Шул чагында Бәдретдин, йомшак кына, чаршау эченә дәште:

– Әнкәй, чәй ясарга үзең чык инде.

– Әткәң соң? – диде чаршау эченнән әнисе, акрын гына.

– Әткәйме?.. Юк, син үзең яса инде безгә, – диде Бәдретдин, ничектер бик ихластан үтенгәндәй итеп.

Чаршау эче бераз тынып торды, аннары киндер күлмәк өстеннән шундый ук киндер алъяпкыч буган, оек-чабаталы хатын ситсы яулыгының читләрен битенә тартып һәм башын иеп кенә чыкты да самовар артынарак килеп утырды.

Аңа күтәрелеп карагач та минем йөрәк әллә нишләп китте. Дөресрәге, яшермичә әйтим, бер чиркану тойгысы йөрәкне өшетеп җибәргәндәй булды: бичара хатынның бөтен битен-күзен кайчандыр кичергән рәхимсез чәчәк зәхмәте тәмам бозып бетергән иде. Өстенә карап, моны сурәтләп торуы авыр, ничектер тел бармый, ләкин шулай да сул күзенең бөтенләй кысылып, ә уң күзенең иләмсез зураеп калуын әйтмичә булдыра алмыйм, чөнки шушы яшь пәрдәсе аша караган кашсыз-керфексез күзендә бичараның бөтен эчке җаны чагылырга гына тора кебек иде. Әйтерсең бу һич йомылмас яшьле-моңсу күз аның шәрәләнеп калган бердәнбер күңел көзгесе!

Аны күреп беренче чиркану һәм кызгану тойгысын кичергәч тә күңелгә иң башлап шундый уй килде: ничек итеп Бәдретдин бу бәхетсез әнисен чакырып алырга һәм безгә күрсәтергә җөрьәт итте икән?.. Без бит гадәттә кешене куркытырлык ямьсез яки гарип туганнарыбызны ятлар күзенә күрсәтмәскә тырышабыз. Хәтта әниебезне дә, әгәр ул менә шушындый булса, үзебез чакырып алып күрсәтергә кыймас идек, уңайсызланыр идек, оялыр идек. Бәдретдин бу кыен хәлне бөтенләй күрми, аңламый микәнни? Әллә күрсә, аңласа да бик тирән яшерә беләме?

Ә җиңги шул арада чынаякларга чәй ясап, йөзен самовар артына яшерә төшеп, безгә сузды. Без башларны күтәрмичә генә, сүзсез генә чәебезне эчәргә тотындык. Бәдретдин безне кыстап:

– Йәгез әле, шәрикләр, ни бары белән ашап кына эчегез, ашап кына! – диде, һәм аның тавышында мин көткән уңайсызлану яки оялу ник кенә бер ишетелсә иде!

Йомырка тәбәсен капкалап, икешәр чынаяк чәй эчкәч, без чәшкеләребезне капладык. Бәдретдин, сыеның ярлылыгыннан булса кирәк, үзалдына, сиздермәскә тырышып кына, бер сулап куйды. Аннары кисәк кенә аягүрә басты да:

– Булмаса, мин сезгә үземнең китапларымны күрсәтим әле, – диде һәм тәрәзә башына ясаган кечкенә шүрлектән бер өем китапларын алып безгә бирде. Без бер эш чыкканга куанып, шуларны карый башладык. Монда яңа әдәбияттан ике-өч роман, дүрт-биш шигырьләр мәҗмугасы, иске әдәбияттан шактый тузган «Бүз егет», «Тутыйнамә», «Ләйлә вә Мәҗнүн», «Каһарман катыйль» кебек китаплар һәм гарәп, фарсы телендә берничә дәреслек бар иде. Без күбрәк вакыт үтсен өченгә бу китапларның кайсы укылган, кайсысы укылмаган, кызыкмы-түгелме – шул турыда сөйләшкәләп, карап чыктык.

– Минем бит әле сезгә, шәрикләр, тагын бер күрсәтәсе нәрсәм бар, – диде Бәдретдин һәм, яңадан торып, шүрлектән кечкенә генә скрипкә алды. Бу кулдан гына ясалган, буялмаган, хөрти генә бер скрипкә иде.

Без гаҗәпләнеп сорадык:

– Кайдан бу синдә?

– Үзем мәтәштергән булдым инде, – диде Бәдретдин һәм скрипкәнең тонык кына тавыш чыгарган кылларын көйләргә тотынды. Аның кубыз уйнавын, мандолина чирткәләвен без белә идек. Әмма скрипкә!..

– Әй, Бәдри, нигә моңарчы яшердең? – дидек без.—Мәдрәсәдә Сәгыйть скрипкәсен алып, үзеңнән уйнаткан булыр идек бит!

– Оста барда кулың тый! – диде Бәдретдин, тыйнак кына елмаеп.

Ул айлар буе кул тимичә яткан скрипкәсен шактый озак азапланып көйләде. Шул чакта мин аның әнисенә күтәрелеп карадым: ана үзенең шәкерт улына шундый бер бәгырьгә төшәрлек тирән мәхәббәт белән, бәхет-сөенеч белән сихерләнеп, эреп, мөкиббән китеп карап утыра иде ки, мин хәтта йөрәгем-тәнем белән әллә ничек тетрәнеп куйгандай булдым. Аңлыйсызмы, күз алдыгызга китерә аласызмы – гүя бу зураеп ачылган сыңар күздәге өнсез караштa, бер адәм затына гына түгел, бөтен җан иясенә хасниндидер менә үзе эшләгән могҗизага таң калу һәм шуңа чиксез куану, шуның белән әйтеп бетергесез горурлану ап-ачык чагылып тора иде: ул тапкан бит бу баланы! Ул имезгән бит аңа күкрәк сөтен! Ул шушы сөлек кебек егетнең әнисе бит! Шәкерт әнисе, гыйлем иясе булачак кешенең әнисе... Ихтыярсыздан йөрәгем үкси башлап, мин тизрәк башымны түбән идем.

Бәдретдин, маташа торгач, ахырда скрипкәсен көйләде, иңбашына терәде, җәя сыман смычогы белән сызгаларга тотынды. Скрипкәнең тавышы бик зәгыйфь иде, чеби тавышыдай көчсез-нечкә иде, ләкин бу минутта безнең күңелләргә ул да бик ягымлы, бик тансык иде. Бәдретдиннең уйнавын барыбыз да шылт та итмичә, тып-тын калып тыңлап утырдык. Бу ярлы өйнең һавасында ук ниндидер бер авыр сагышлы моң —мәңгелек моң йөзә кебек иде. Текә генә катып утырган ап-ак бабай ни уйлый, бүкәне өстеннән бер генә дә кузгалмаган абзый кеше ни кичерә – моны белүе һич мөмкин түгел иде. Тик шушы моң эчендә, томан аша караган тулы ай төсле, Бәдретдиннең әнисе үзенең сүзсез шатлыгы белән яктырып утыра. Нинди язмышлар бәйләгән бу кешеләрне, нинди серләр саклана алар арасында?

Бер-ике көй уйнагач, Бәдретдин, ниһаять, әнисенә дәште:

– Әнкәй, сиңа нәрсә уйныйм?

Әнисе бер мәлгә балаларча кызарып, шул ук вакытта куанычыннан тагы да балкыбрак китте, ләкин кайтарып сүз әйтә алмады.

– Әнкәй, син шушы көйне ярата идең бит! – диде Бәдретдин һәм «Салкын чишмә»не уйный башлады. Аның сүзләре, сүзләреннән дә бигрәк, шулкадәр гади, табигый, җылы-якын итеп дәшүе минем соңгы шикләремне дә чәлпәрәмә китерде. Әнисе өчен уңайсызлану дигән нәрсәнең әсәре дә юк икән Бәдретдиндә!.. Кайда ул уңайсызлану! Берәүне дә күрмичә, бары әнисенә, әнисенең әнә шул башта безне чирканырга мәҗбүр иткән шадра, чалыш, акайган күзле йөзенә генә карап, ул скрипкәсен уйнады. Аның бу аз гына моңсу уйчанлык, яшерен генә кызгану белән өртелгән җитди-җылы карашында, әнисен өзелеп ярату гына түгел, аны беткәнче аңлау, кадерләү, юату сизелеп тора кебек иде. Белмим, болай карый алыр өчен күңелләрдә нинди генә тирән мәхәббәт дәрьясы ятарга тиештер инде?! Әллә бу шулай бик ямьсез ана белән бик матур бала яки, киресенчә, бик матур ана белән бик ямьсез бала арасында гына буламы икән? Соңгысы, ихтимал, еш очрый торгандыр, әмма беренчесен ишеткән дә, күргән дә юк иде.

Шулай да безгә кузгалырга вакыт иде инде. Бәдретдин уйнап туктагач, без хуҗалардан дога кылырга рөхсәт сорадык. Абзый кеше ямаулы тез башларын ышкып куйды, ә Бәдретдин, бабасына үрелеп:

– Бабакай, шәкертләр бездән фатиха бирүебезне сорыйлар, – диде.

Бабай башын какты, һәм без кулларны күтәрдек.

...Күк алашаны җигеп, капкасыз-коймасыз, кыр үләне басып киткән «ишегалдыннан» урам уртасындагы тигез юлга чыктык. Бәдретдин һәм әтисе безне озатып, киртә буенда янәшә басып калдылар. Юк, алай гына түгел, алар белән бергә безнең артта авыл читендәге иң фәкыйрь йорт, бу йортның безгә билгесез ниндидер тирән сере —бәхетсезлегеме, фаҗигасеме, әллә без аңлаудан гаҗиз бөек бер өмете-бәхетеме – торып калды.

Кояш баюга таба борылган иде инде. Ә шулай да тургайлар, көн яктысыннан туя белмәгәндәй, тагын да биеккәрәк менеп, тагын да сузыбрак, ярсыбрак берөзлексез сайрыйлар да сайрыйлар. Дөнья киң, киң, киң, әләләләләүү! Җире-күге тын, буш, моңсу... бик моңсу миңа!.. Берни эшли алмыйм үзем белән: самовар артыннан гына улына карап утырган ана күз алдыма килә дә эчемнән тагын үкси башлыйм... Кемгәдер йодрык селкеп, кычкырасым килә: ямьсез түгел бит ул, матур бит ул, матур, матур Бәдретдиннең әнисе!

*1964*

## Төнге тамчылар

### I

Апрель киче. Юеш, җылы, томанлы. Караңгы, тын урамнарда тып-тып тамчылар тама. Күңелгә нидер әйтмәкче, нәрсәнедер искә төшермәкче була бу тамчылар... Тып-тып... Нәрсәне икән соң, нәрсәне генә оныттың икән лә син, кеше?

Нәкъ шундый караңгы, җылы кичләрнең берсендә Хәлил Ишмаев Ләйлә ханымның Ленинградтан кайту хәбәрен ишетте. Кайда, кем алдында диген!.. Эштән кайтып керсә, боларда Зәйнәп исемле хатын Мәрвәр ханым белән кухняда сөйләшеп утыра. Менә шул хатын, аны күргәч исенә төшердеме, әллә кызыклы хәбәрне юри аның алдында әйтер өчен көтеп утырганмы, ләкин ничек кенә булмасын, Хәлил кереп өстен салырга да өлгермәде, бу кычкыра биреп әйтеп тә куйды:

– Әй-й, Мәрвәр җаным, оныта да язганмын лабаса, миңрәү түгел диген инде син мине!.. Теге ни... Ләйлә Ленинградтан кайткан бит!

– Кайсы Ләйлә? – диде Мәрвәр ханым, гадәтенчә исе китмичә генә, ә Хәлил пальтосын элеп маташкан җирендә бер мәлгә тынып калды.

– Соң теге, әлеге Гайшә апаның сеңлесе, доктор Үзбәковның балдызы була инде... Беләсең инде син аны, бик яхшы беләсең... Ләйлә туташны!

– Ә-ә! – дип сузды Мәрвәр ханым һәм ни өчендер башын каккандай итте. – Кайчан кайткан?

– Әле күптән түгел булса кирәк, үзем дә кичә генә ишеттем... Ул бит, җаным, Ләйләне әйтәм, анда бик зур кешедә кияүдә ич. Әллә латыш, әллә яһүд шунда. Гел заграницага йөреп тора икән. Ә Ләйлә үзе бер дә үзгәрмәгән, ди, һаман шулай карлыгач кебек сылу да, чибәр дә, ди... Ә өстен күрсәң, баштанаяк заграничный, ди, җаным! Соң шулай булмыйни, ире ни бит, әллә яһүд, әллә латыш...

Мәрвәр ханым аның сүзен бүлде:

– Ә озакка микән?

– Белмим, җаным, белмим. Торыр әле, торыр, беренче кайтуы бит. Йөрер әле Казан хатыннарын шаккаттырып, шуның өчен генә кайткандыр да әле, җаным!

Мәрвәр ханым авыз эченнән генә нидер мыгырданып куйды да шунда ук алгы якка ваемсыз гына кычкырып әйткән булды:

– Хәлил, ишеттеңме, Ләйлә кайткан ди әнә...

Хәлил тиз генә җавап кайтара алмады. Бу гади-ваемсыз сорау юри аны сынар өчен бирелгән мәкерле сорау иде. Үзенең шушы секундта ни кичерүен ул сүзе белән генә түгел, тавышы белән дә сиздермәскә тиеш иде. Ләкин... ләкин кеше күпме генә качарга, яшеренергә, ялганларга өйрәнмәсен, әмма тормышның кайбер минутларында аптырап, югалып кала икән ул.

Нәкъ шундый хәтәр бер минут кичерде Хәлил дә... Ләкин дәшми тору озакка китсә, тагын да хәтәррәк буласын сизеп, ул исе китмәгәндәй:

– Шулаймыни? – дип кенә куйды да, вакыты юк кешедәй ашыгып, ясалма эшлекле-салкын кыяфәтен сакларга тырышып, тизрәк үзенең кабинетына узды.

...Калын портфелен урындыкка ташлады, ишекле-түрле бер-ике тапкыр йөреп алды, аннары язу өстәле янына утырып, башын йодрыклары белән учлады... Ләйлә кайткан... Ләйлә кайткан... Ләйлә, Ләйлә! Йа Ходa, нигә бу көтелмәгән хәбәр, бу кечкенә факт, чоңгылга төшкән таш кебек, кинәт аның бөтен җанын шулхәтле сискәндереп җибәрде соң әле?.. Күптән киселгән сынык бит инде ул, күптән онытылган иде бит инде! Аңардан башка да узды бит гомер, уза иде бит әле, чәнчелгере!.. Ә ул кайткан... Нигә, ни өчен? Әлбәттә, аның өчен, Хәлил Ишмаев өчен түгел инде. Ләйлә өчен Хәлил юк ул, юк, күптән төтенгә әйләнеп таралган, беткән, юкка чыккан кеше... Кайткан икән, шәһәр таптап йөрер дә кире китәр. Сорашып та тормас... Сукмаклары да аларның очрашмас, юк, очрашырга тиеш түгел! Бәс, шулай булгач, яшел эшләпәңне батырыбрак ки дә, алдыңа карап кына, үз юлың белән йөри бир!

Яшендәй китереп суккан бу хәбәрдән соң бер көн узды, ике көн узды, өч көн дә узды шикелле... Кафедра мөдире профессор Хәлил Ишмаев институтка барды, институттан кайтты, тып-тын аудиториядә башларын салындырып, йокы белән көрәшеп утырган студентларга мең дә беренче кат лекциясен сөйләде, тагын каядыр керде, нидер эшләде, аннары, арып, авыр портфелен сөйрәп кайтырга чыкты. Кайткач, Мәрвәр ханымның ашын ашады, чәен эчте, нәрсәдәндер зарлануын тыңлаган булып утырды. Соңыннан иренеп кенә газеталар караш-тыргалады... Бөтенесе дә гадәт буенча гына, акылдан тыш, теләктән тыш эшләнә иде. Әмма ни генә эшләмәсен, әлеге хәбәр, тып-тып тамган тамчыдай, аның миенә өзлексез бернәрсәне тукып торды: «Ләйлә кайткан!» «Ләйлә кайткан!» «Кайткан... кайткан!..» Юк, моны... моны аңлый белергә кирәк, дуслар! Әгәр кешенең, очрашу-күрү түгел, исенә төшерүдән дә катгый рәвештә тыелган беренче иң газиз, иң саф мәхәббәте менә шулай, күктән иңгәндәй, кинәт әйләнеп кайтса, әйтегезче зинһар, ул кеше нишләргә тиеш? Аңлагыз, сүз сөяп куйган бүрәнә турында түгел, ә тере кеше турында бара. Сүз, ниһаять, исемле, дәрәҗәле, олы яшьтәге кеше турында бара... Чынлап та, менә ул үзенең еллар буенча тырыша-тырыша тапкан бик кадерле тынычлыгын бозмас өчен, көчләнеп-азапланып булса да, хатын итеп яшәгән Мәрвәренең каһәренә юлыкмас өчен ни эшләргә, нинди калыпка керергә, нинди сабырлык һәм чыдамлык күрсәтергә тиеш?

Моннан егерме җиде ел элек Хәлил Ишмаев педагогия институтын бетереп килгән чагында доктор Максут Үзбәковның энесе мәрхүм Мисбах белән танышып, бик дуслашып

киткән иде. Алар Чехов урамында торалар иде. Менә шул Мисбах янына барып йөргәндә, Хәлил доктор Үзбәковның уналты-унҗиде яшьлек балдызын күрде. Бер күрде, ике күрде, аннары ничектер бик табигый рәвештә танышып та киттеләр, сөйләшә, көлешә, уйный-шаяра да башладылар. Кызның исеме Ләйлә иде. Гаҗәп, кайчагында кешенең исеме үзенә ничектер бик туры килеп, бик килешеп тора. Гүя менә бу кыз да ак күбәләк кебек нәфис, җиңел, нечкә җанлы булганга күрә Ләйлә исемле иде. Ләйләдән башка бүтән бер исем дә аңа һич туры килмәс кебек иде. Һәм, әйтерсең ак күбәләккә охшаганга күрә дә аңардан чәчәкләр дөньясына хас табигый садәлек, назлы-нәфис сөйкемлелек аңкып тора иде. Хәлил аңа җитеп килгән, инде гашыйк булырга ярый торган кыз итеп карарга да курка иде. Ә ул кыз тотты да үзеннән ун-унике яшькә олы, карап торырга әллә ни матурлыгы да, маһирлыгы да булмаган, киресенчә, Тәкәнеш якларыннан ияртеп килгән, пединститут та кырып-юып бетерә алмаган «гыйбадлыгы» күзгә бәрелеп торган Хәлилгә чәчәк йөрәген ачты да куйды. Хат аша искиткеч бер самимилек һәм батырлык белән үзе ачты ул... Мондый кыюлыкны, мондый тирән ышануны, мондый һичбер исәп-хисап белән бәйләнмәгән керсез, хыялый мәхәббәтне бары унҗиде яшьлек кыздан гына көтәргә мөмкин иде. Һәм Хәлил өчен бу мәхәббәт диңгез төбеннән табылган саф энҗе бөртеге кебек гаҗәеп бер байлык иде, ак итә, пакь итә, яктылыкка илтә торган гомерлек бәхет иде. Хәлил моны бөтен йөрәге белән сизде, аңлады һәм үзе дә сөенеп, дәртләнеп, рухланып Ләйлә туташны чын-чынлап яратып китте. Соңыннан бу хәлне сизгән-белгән кешеләр дә моңа бер дә гаҗәпләнмәделәр, киресенчә, алар балалыктан яңа чыгып килгән япь-яшь кызның акылга утырган, сабыр-басынкы егеткә мәхәббәт тотуын, шуның канаты астына керергә теләвен хуплап каршы алдылар... Хәзер инде Хәлил шул ак күбәләкнең нечкә мәхәббәтен куркытмыйча сак кына ике учына алырга тиеш иде.

Ләкин аның куллары, әллә бәхетенә, әллә бәхетсезлегенә каршы, богауланып өлгергән иде инде. Хикмәт шунда Ләйлә туташны күргәнчегә кадәр үк ул шушы Мәрвәре белән шактый якынаеп йөри башлаган иде. Тынгы белмәс активист, сизгер-уяу, сүзгә оста, өркетергә ярата, кыскасы, яшьләр арасында бик ялтырап йөрүче кызларның берсе иде ул... Аның шактый югары урыннарда утырган ишле туганнары да шул заманның (ягъни теге заманның) бик гайрәтле кешеләре иде. Аларга курку катыш хөрмәт белән карамыйча мөмкин түгел иде. Менә Хәлилне дә, ни сәбәптәндер, кызның шул туганнары да бик кызыксындырды. Дөрес, бу кызыксынуда ачык билгеләнгән нindидер яшерен исәпләр юк та кебек иде, әмма шулай да андый шәп кешеләрнең сеңелләре белән яратышып йөрү, ә киләчәктә, бәлки, туганлашып та китү ихтималы аны ихтыярсыздан мавыктыра иде. Ничектер менә шул кешеләр арасына керсә, аның алдында киң мәйданнар ачылып китәр кебек иде. Шуңа күрә дә ул Мәрвәр тирәсендә яратучы булып,

ягъни яратам дип үзен ышандырырга тырышып, башта бик егетләнеп, бөтерелеп йөрде. Әмма Ләйләне күргәч, бу тырыша-тырыша үзен котыртып йөрүләр кинәт җимерелде дә куйды. Баксаң, чын мәхәббәт тә, чын якынлык та юк икән, бары коры мавыгу да үз-үзеңне алдап маташу гына булган икән.

Әйе, эш узмаган иде әле. Чая кызга кагылмаган-тимәгән, хәтта өйләнешик дигән сүзне дә ычкындырмаган иде әле ул. Чигенергә мөмкин иде, бик мөмкин иде. Ләкин кем җәтмәсенә эләгүен егет, бичара, бер дә аңламаган икән шул. Кыз монның чигенергә чамалавын сизеп алгач та, һич ялварып яки тарткалашып тормыйча, егеткә бары шуны гына әйтте: «Бел, мин синең чын йөзеңне фаш итәчәкмен!» – диде. Фаш ителү! О, бу, иң гөнаһсыз кешенең дә котын ала торган, гаять куркыныч сүз иде. Ә бит бергә яратышып йөргәч, егетнең кызга төрле уйларын яки шикләрен әйткән чаклары да булгандыр. Хәер, әллә ни хәтәр сүз әйтмәсә дә, төймәдән дөя ясап булмыймыни?! Моның мисаллары күз алдында бит. Юк, институтны тәмамлап, аспирантурада калырга өметләнеп йөргән чакта гына «фаш ителеп» куйсаң, беттең дигән сүз! Алла сакласын!..

Кыскасы, Мәрвәр әнә шул бер янавы белән Хәлилне бөкте дә салды. Кая ул чигенү! Песи булды егетең, бөтенесеннән ваз кичеп, тизрәк Мәрвәр итәгенә капланды. Әйе, ул заманда, теләсәң, «мәхәббәтне» дә кешедән буып алырга була иде.

Ә Ләйлә берәүгә бер сүз әйтмичә кинәт кенә Ленинградка китте дә барды. Аның ниләр кичереп, нинди хәлдә китүен Хәлил күз алдына китерергә дә курка иде. Ак күбәләк, әйтерсең кара мунча тирәсеннән иркен кырга очты... Көн яктысында эреп югалды... Тик күпмедер вакыт узгач кына аның Герцен институтында укуы ишетелде, аннары инде, фин сугышы алдыннан булса кирәк, Зәйнәп ханым әйткәнчә, бер яһүдкәме әллә латышкамы, һәрхәлдә, зур дәрәҗәле инженер кешегә иргә чыгуын сөйләделәр. Ул кеше, имеш, безнең чит илләр белән сәүдә алып бара торган оешмаларда эшли. Сугыш вакытында Ләйлә үзе дә ире белән кайсыдыр илдә торган, шунда совет хезмәткәрләренең балаларын укыткан, имеш. Булыр, төшеп, югалып калыр өчен яратылмаган иде ул. Бәхетен, һичшиксез, табарга тиеш иде.

...Күп еллар узды, күп җилләр исте, күп сулар акты... Күпме кешеләр тормыш юлында очрап, тиеп-кагылып үттеләр, онытылдылар, эзсез югалдылар. Әмма ләкин Ләйләне Хәлил бервакытта да онытып бетерә алмады. Гел генә күз алдында тормаса да, күңеленең әллә кайсы гына почмагында яшеренеп кенә ул яши бирде. Тик Хәлил үткәннәрне бик сирәк кенә исенә төшергән минутларда ак күбәләк шул яшеренгән урыныннан гүя терелеп чыга иде дә, кунарга чәчәк эзләгәндәй, аның хыял күгендә тын гына талпына башлый иде. Йа Хода! Нindидер әйтеп биргесез үкенечле һәм татлы сагыну Хәлил йөрәген әрнетеп, телгәләп җибәрә иде. Югалган

бәхет, онытылмаган мәхәббәт, соңга калган үкенү, зарыгып сагыну – менә шул газаплары белән ләззәтле иде бу минутлар! Әйе, бары тик минутлар!

Ә Мәрвәр белән бергә аның егерме биш ел гомере узып та китте. Гаҗәпләнерлек берни дә юк – тордылар, хәтта әйбәт тордылар. Мәрвәре күптән инде бик тырыш, бик уңган хозяйкага әверелде, кызыл кисеп, активист булып йөрүләре әллә кайчан бетте, ләкин сизгер уяулыгы нәкъ элеккечә калды, һәм шушы көнгә кадәр ул Хәлилне һәртөрле ялгыш адымнардан, ата күркә шикелле саклап килде. Тормышлары да үзләре теләгән эздән тәгәрәде. Институтны бетергәч, Хәлил татар теле кафедрасында аспирант булып калды... Гәрчә ул татар телен яратып бетермәсә дә һәм аның киләчәгенә зур өмет багламаса да, гыйльми дәрәҗәгә ирешер өчен, бернигә карамыйча гомерен шуңа багышлады. Акрынлап аспирантураны да бетерде, кандидатлык диссертациясен дә яклады, ахыр килеп, бик тырыша торгач, татар теленең зур, сары портфельле профессоры да булып куйды... Кеше үзенең түшәменә җитте бугай. Ул канәгать, язмышыннан да, тормышыннан да канәгать. Аңардан: «Вөҗданың сафмы, намусыңа каршы берәр нәрсә эшләмәдеңме, үкенмисеңме, газапланмыйсыңмы?» – дип сораучы юк. Хәер, кем сорасын? Ят кеше түгел, ул үзе дә үткәненә борылып карарга, күңелендә казынырга яратмый иде.

Ләкин ни өчен соң егерме биш ел буена күренмәгән бер хатынның бары шушы шәһәргә кайтып килүе аны кинәт сискәндереп җибәрде? Нигә әле ул аның күптән мәрткә киткән күңелен төртеп уятты, күптән сүнгән хисләрен, онытылган уйларын яңадан кабындырып, дөрләтеп җибәрде? Күрәсең, хикмәт монда бер Ләйлә ханымда гына түгел. Күрәсең, кайчандыр яшь кенә кызыйга булган мәхәббәттән тыш, аның эчендә озак еллар буенча ниндидер бүтән кичерешләр дә акрынлап җыела килгән. Ленинградтан кайткан ханым исә, кинәт искән язгы җилдәй, әнә шул эчендә боз катлавы сыман туңып яткан кичерешләрен эретеп, кузгатып җибәрүче генә булды, ахрысы... Нинди вакытта диген! Тып-тып язгы тамчылар тамган апрель кичләрендә бит, җитмәсә!.. Ах, Ләйлә, Ләйлә!

Шулай да беренче өермә бөтерелеп, йөгереп узды шикелле. Бераздан Хәлил дә исен-акылын җыеп өлгерде. Аның эчендә ниләр купканын берәү дә, хәтта соңгы көннәрдә аеруча уяу йөргән Мәрвәре дә сизмәде. Чын хисләрен гомере буена яшереп тотарга өйрәнгән гадәте Хәлилгә бу юлы да бик нык ярдәм итте – ул һаман җитди-йомык кыяфәтен бик оста саклаучы, олы, таза гәүдәсен текә тотып, ашыкмыйча гына йөрүче шул ук профессор Ишмаев булып кала бирде. Инде акылын җыеп, бераз тынычлангач, бу көтелмәгән исәрләнүен үзе үк хөкем итәргә тырышып карады: «Йә, нәрсә булды соң әле, нигә бу кадәр мин зиһенемне җуйдым, диванага әйләнә яздым, тиле шәкерт!» – диде ул, үз-үзен шелтәләп... Ләйлә ханым кайткан, имеш! Кайтса соң? Күптән, һай, күптән югалган Ләйлә бит ул аның өчен! Кайтса да, китсә дә аңа хәзер

барыбер түгелмени?.. Юк, болай ярамый, килешми, оят!.. Онытырга кирәк бу кысыр хәсрәтне, күңелдән йолкып атарга кирәк бу мәгънәсез яну-көюләрне... Үткәнгә кайту юк ул, юк!

Шулай диде аңа айнык акылы. Шулай качарга теләде ул һәртөрле вәсвәсәдән... Бөтенесен – җилкенү-талпынуларын, газаплы уйларын салкын акылы белән әнә шулай буарга тырышты. Әмма ләкин бер генә теләген ул һичничек тә җиңә алмады. Бу аның Ләйләне күз кырые белән генә булса да бер күреп каласы килү теләге иде. Әйе, бернинди максатсыз, бары тик коры кызыксынудан гына, үзенә насыйп булмаган Ләйләсен бик тә күрәсе килә иде. Нindирәк икән ул? Кайчандыр күбәләктәй җиңел-сылу кыз хәзер кырыктан узган хатын булгач нинди кыяфәткә керде икән? Бер күрүдә таный алыр идеме икән ул аны? Бик нәфис, бик чибәр иде бит ул, шайтан алгыры! Керфекләре кара, ә күзләре якты-соры иде, шунлыктан кара каймалы булып күренәләр иде ул күзләр. Озаграк карап торсаң, шул күзләрнең төбендә акрын гына эреп югалган шикелле тоя идең үзеңне... Хәзер ничек икән? Саклândымы икән аның кара каймалы якты күзләре, нурда югандай бик чиста көрәнсу йөзе, җиргә тияр-тимәс кенә йөргән камыштай нечкә, зифа гәүдәсе?.. Хәер, әнә күргән хатыннар аны бик сакланган, хәзер дә шундый ук сылу-чибәр дип әйтәләр. Гаҗәп түгел. Ул бит явызлыгыннан чыбыктай кибә яки ваемсызлыгыннан камырдай күперә торган хатын булмаска тиеш иде. Нәфислекне бик нечкә тоя торган гаҗәп сизгер җан бар иде аңарда... Юк, күрәсе иде үзен, ничек тә күрәсе иде. Шушында, шушы шәһәрдә генә йөри ич ул, кайтып төшкән җире дә моннан ерак түгел – Чехов урамында гына югыйсә!

Ләкин махсус барып күрү турында сүз дә булырга мөмкин түгел. Мәрвәр ханым сизә калса, утыз сигезле башмаклары белән бөтен саф хисләреңне таптап изәр. Яшьлекнең гөнаһсыз бер хатирәсе бу, кеше күңеленең нечкәреп бер сөенүе, үткәннәре турында сагышлы бер уйлануы дип тормас. Карт алаша, күрсәтермен мин сиңа Ләйләне, закон минем якта дип кенә җибәрер.

Димәк, очраклы туры китереп кенә очрашу турында хыялланырга мөмкин. Ләкин вакытлы гына кайткан кешене алай очрату, ай-һай, бик шикле шул! Кайда йөри, нинди урамнардан йөри ул, кайларда була, кемнәргә керә? Берәр күзәтүче ялларгамы, яки үзеңә якынрак чат башында сагалап торыргамы?.. Һе, кызык булыр иде бу: яшел эшләпәсен өч яктан яньчеп кигән, култык астына зур портфелен кыстырган мәһабәт профессор чат башында басып тора. Ә үткән-сүткәннәр аның ни өчен басып торганын гүя белеп, мыек асларыннан гына көлеп узалар. Көт, профессор, көт, бәхетеңнән каршыңа... Мәрвәрең килеп чыкмасмы?

Шулай да Хәлил эшкә барганда да, кайтканда да һәрбер ят хатынга игътибар беләнрәк карап уза башлады. Бәлки, шуларның берәрсе «ул» булып чыгар. Өмет, өмет! Бер генә чаткысы да кайчан кешене тилегә сабыштыра: тукта, әнә «ул» килә түгелме соң? Әнә тагын «ул»! Бер-бер

артлы әллә ничәү!.. Хәлил хәсрәтле итеп әче елмая: егерме биш ел буена аның Ләйләгә охшаганрак бер генә хатынны да күргәне булмады.

Ә өмет дигәнең аны һаман каядыр дәшә, каядыр өстери иде. Кай кичләрен ул, эштән кайтышлый, сагаеп кына Үзбәковлар торган урамга да барып чыккалады. Монда «аның» очравы бик мөмкин бит!

...Чехов урамы. Апрель киче. Тып-тып төнге тамчылар тама... Тәрәзәләрдә ут, пәрдәләр төшерелгән... Әнә каршы якта ике катлы агач йорт, шуның югары катында Үзбәковлар тора. Ике якка ачылмалы парадный ишек, сары баскыч югарыга алып менә. Моннан егерме биш ел элек шул баскычтан аңа каршы Ләйлә йөгереп төшә иде... Күпме хатирәләр! Китап битләре арасында кипкән чәчәктәй саклаган хатирәләр!

...Ике тапкыр ул каршы яктан гына доктор квартирына карап узды. Тәрәзәләре якты, челтәр пәрдәләр корылган, түшәмнән асылынган өч чатлы люстра да күренә... Докторның бөтен семьясы өйдә булса кирәк. Ләйлә дә шулар арасындадыр инде. Йөри микән, утырып тора микән, әллә берәр яры чыгып китәргә җыена микән?.. Бу нәрсә аңа бик ихтимал төсле булып тоелды. Театрга яки кинога дип чыгуы мөмкин ләбаса. Нинди шәп форсат булыр иде бу. Һәм, Хәлил кичегүдән курыккандай, ашыгып урам аша чыкты да, гәүдәсен туры гына тотып, салмак кына атлап, докторларның парадный ишеге яныннан узып китте. Бераз барып, кире борылды, тагын парадный ишеккә кырын гына карап узды. Ләкин ишекнең ачылырга исәбе юк иде. Ун тапкыр, егерме тапкыр узсаң да ачылмас, ахрысы бу, таза ишек... Өйнең якты тәрәзәләре югарыдан урамга һавалы, ваемсыз карыйлар, гүя түбәндә юеш тротуар таптап йөрүчене күрмиләр дә, белмиләр дә алар... «Бу нинди балалык!» – диде Хәлил, үз-үзенә ачуы килеп. Олы башы белән түбәнсенеп йөрүенә кинәт хурланып куйды. Болай урам таптаганчы, туп-туры гына керергә иде дә: «Ләйлә ханым, мин сезне күрергә килдем», – дип әйтергә иде. Кем гаеп итәр иде? Бер дә гөнаһсыз, бик табигый теләк ич бу! Ләкин юк, мөмкин түгел, җан-теләкләргә кемдер салган богау бар... Һәм шул богауның авырлыгын соңгы көннәрдә аеруча нык сизгән Хәлил, Үзбәковлар өе яныннан берничә тапкыр узгач, башын түбән иеп кенә үз квартирына таба атлады. Кирәкмәс, булмас, йөрүдән мәгънә юк, диде ул киткән саен, ләкин барыбер Чехов урамына кичләрен барып чыкмыйча түзә алмады. Тагын батыраеп килгән булды, челтәр пәрдәле тәрәзәләргә карап узды, туктап төнге тамчылар тавышына колак салып торды, аннары үз-үзеннән оялып, юашланып, башын түбән иеп кире кайтып китте.

Бер кайтуында күңеленә әллә ничек кенә Дәрдмәнд сүзләре дә килде:

Агарды чәч,

Куарды баш,

Сары юллар сызылды,

Өмидләр, кем...

Өмидләр, кем...

Дәригъ, бер-бер өзелде!

Әмма язмыш рәхимле икән. Кичләрнең берсендә аңа, ниһаять, Ләйлә ханым белән очрашырга туры килде.

**II**

Ул көнне университетның гыйльми советында чит шәһәрдән килгән бер егет кандидатлык диссертациясен яклады. Профессор Хәлил Ишмаев оппонентларның берсе иде. Диссертацияне яклау күптән килгән тәртип һәм кагыйдә буенча үтте. Булачак яшь галим кирәк дәрәҗәдә әдәп һәм тыйнаклык саклап, кирәк дәрәҗәдә генә бәйсез һәм кыю булырга тырышып, бераз гына дулкынланып һәм бераз гына масаеп, диссертациянең кыскача эчтәлеген сөйләп чыкты. Оппонентлар да коры рәсмилеккә беркадәр җылы хәер хаһлык кушып, күбрәк мактап, азрак тәнкыйтьләп, кыскасы, бөтен шартын китереп, диссертация турында үз фикерләрен әйттеләр. Ахырдан булачак галим өлкән галимнәргә түбәнчелек белән үзенең рәхмәтен белдерде, тиешле вәгъдәләрен бирде, аннары гыйльми совет членнары шар салып, егетебезне бик хаклы рәвештә кандидат ясап куйдылар.

Шуннан соң инде максатына ирешкән бәхетле егет, күптән килгән йола буенча, үзенең оппонентларын һәм утырышта булган кайбер якын кешеләрен «Казан» ресторанының аулак бер бүлмәсенә кичке ашка алып китте. Әзер табынга унбишләп кеше утырды, тамада итеп мондый мәҗлесләрнең берсеннән дә калмый торган бик борынгы кандидат Кәли иптәшне сайладылар. Кәли иптәш аягүрә басты, тамагын кырды, көлдерергә теләп нидер әйтте, көлүче булмагач, пычак сырты белән шешә муенына сукты һәм коньякларны, столичныйларны рюмкаларга салырга кушты... Монда инде яңа кандидат, яшь килендәй, баштан ук алдына карап, тыйнак кына утырырга тиеш иде, чөнки хәзер аның исеменә мактау сүзләре китәчәк. Һәм чынлап та рюмкалар күтәрелгән саен, мактау сүзләре егетнең бик дөрес уйлый белә торган өметле башына ява гына торды.

Мондый мәҗлесләр Хәлилгә бик таныш иде. Ул моның шикелле «юу» мәҗлесләрен котылгысыз бернәрсә итеп санарга һәм анда артык сөенмичә-көенмичә генә чыдап утырырга күнеккән иде инде. Чамалап кына эчү, чамалап кына ашау, чамалап кына сүз кыстыру һәм ахырдан шулар бәрабәренә, килеп, мәҗлесне бизәп утыруы өчен рәхмәт ишетеп китү – менә аның күнеккән гадәте шул иде.

Ләкин бүгенге мәҗлескә ул башта ук күңеле тартмыйча килде. Кәефе начар, җаны тыныч түгел, йөрәгендә ниндидер бер суырылмас сызлавык утыра кебек... Ни калган миңа монда дип, эче пошып, хәтта үкенеп тә куйды. Шулай да хуҗа егет бик зурлап каршы алгач, өстәлнең түренә үк узып, алдына карап, сүзсез генә утыра бирде. Мәҗлес башланды, яшь кандидат хөрмәтенә тостлар күтәрелде. Һәм, гаҗәп хәл, моңарчы бик сакланып кына эчә торган Хәлил бу юлы, кеше рәтеннән, салган бер рюмкасын эчеп бетерә барды. Шулай эчеп, бераз җиңеллек табарга уйлады, ахрысы... Ләкин исерү алып килгән бу җиңеллек гадәттәге ваемсыз, кәефле җиңеллек түгел иде. Ничектер болытлардан ачыла башлаган күктә тулы ай күренгәндәй, аның да бераз яктыра төшкән хыял күгендә... Ләйләсе акрын гына калкып чыкты. Һәм аңа шул җитте, шул минуттан ул барысын да онытып, үз эченә йомылып, бары Ләйлә турында гына уйланып утырды. Бу кызыксыз, шау-шулы мәҗлестә, ялгызлыкка бирелеп, Ләйләне генә уйлап, Ләйләне генә сагынып утыру аңа гүя ниндидер моңсу, хәсрәтле бер рәхәтлек китерде.

...Ул тагын һәм тагын эчте, исерә башлавын бик ачык сизсә дә, юри тыелырга теләмәде. Чөнки эчкән саен акылын-җанын буып торган тышаулардан үзен бушана барган шикелле тойды. Уйлары гаять ачыкланып, тирәнәеп, үткенләнеп киткәндәй булды. Мәхәббәт турында, язмышлар турында, заман һәм кешеләр турында тирән фикерләр, әче хакыйкатьләр күңеленә килде. Ләкин монда аларны әйтерлек сылтавы да, кешесе дә юк иде, алар барысы да хәзергә, эсседә кузгалган умарта күчедәй, аның эчендә генә кайный иде.

Ахырда ул үзенең шактый нык исерүен аңлады. Мәҗлес әле кызып кына барса да, кузгалырга вакыт җиткәнлеген чамалады. Ә бераздан ул үзен ничек тә айнык тотарга тырышып урыныннан торды һәм тотлыга биреп, кайтырга рөхсәт итүләрен сорады... Мәҗлестә утыручылар аңа бик сәерсенеп карадылар, шунда гына аның исереп киткәнлеген сизеп алдылар, ләкин шулай да гаҗәпләнгән булып: «Профессор, бу ни эш бу?.. Сөйләмәгез әле, Хәлил Кәримович, утырыгыз әле, утырыгыз, сездән башка мәҗлеснең яме китә бит!» – дип кыстарга, юмаларга тотындылар. Профессор, артык сүз ычкындырмас өчен, бары кулын күкрәгенә куеп, башын гына чайкады, мәҗлес хуҗасының кулын кысып, аркасыннан какты һәм, гәүдәсен аеруча текә тотып, ишеккә юнәлде. Аны кемнәрдер түбәнгә кадәр озата төштеләр, пальтосын, эшләпәсен кидерделәр, портфелен кулына бирделәр. Кемдер аңа: «Хәлил Кәримович, озатып куйыйм сезне булмаса!» – дип тә карады, ләкин ул елмаеп кына башын селекте дә үз аягы белән ашыкмыйча гына чыгып китте.

Чыккач та ул аулак урамга борылды. Мондый кыяфәттә үзәк урамнан кайтуның хәтәр булуын яхшы белә иде, әлбәттә. Булган икән шул, шактый күп булган икән, хәерсез! Күпме генә туры барырга тырышмасын, аяклары әледән-әле чалыш-чолыш атлап киткәлиләр иде.

Әмма аның акылы гаҗәп ачык, үткен иде, бик кыю, бик кызу эшли иде. Моңарчы эчендә генә кайнаган уйлары хәзер, ялгыз калгач, атылып чыгарга гүя юл эзлиләр иде. Һәм менә ул, ниндидер бер ярсулы рәхимсезлек белән, үзенең үткән тормышын, эшен, гамәлен тәнкыйтьләргә тотынды; искиткеч батыраеп, үз-үзенә ачы хакыйкатьләрне ярып әйтә башлады.

Йә, ничек яшәдең син моңарчы, профессор Хәлил Кәримович Ишмаев? Профессор! Син, егерменче елларның ахырында Бөгешле авылыннан җәяүләп чыгып киткән чабаталы йолкыш малай, менә кем булдың бит! Молодец! Дан сиңа, дан! Ләкин әйт, ничек ирештең син моңа? Акылың, талантың бик зур булып, башка галимнәр белән гадел рәвештә ярышып, фән дөньясына үз буразнаңны ерып килеп кердеңме? Шундый чын галим булып күтәрелдеңме син? Йә, әйт, курыкма!

Әйе, хакыйкатьне әйтмичә булмый... Син, иптәшкәем, болганчык авыр бер заманда, күп кенә укымышлы ирләр нахакка сөрелгәннән соң, бушап калган урынга килеп утырдың. Сиңа беркем белән бәхәсләшергә дә, нидер исбат итәргә дә, үзеңнең ниндидер принципларыңны, карашларыңны яклап маташырга да туры килмәде. Хәер, дөресен генә әйткәндә, алар синдә беркайчан да булмады да. Син баштан ук үзеңнән өстеннәргә буйсынып, алар авызына карап, алар әйткәнне генә кабатлап килдең. Конъюнктурага яраклашып нәрсәнедер мактадың, нәрсәнедер яманладың, каһәргә юлыккан кешеләрне тизрәк гаепләргә ашыктың, хаклыгына үзең дә ышанмаган теорияләрне яклап мәкаләләр язган булдың... Ә асылда, бу минеке дип, горурланып, кулыңа тотарлык бер җитди, төпле хезмәтең дә юк синең!

Ни өчен болай булды соң бу? Ни өчен ул, ташу өстендәге йомычка шикелле, җиңел генә чайкалып акты да акты? Үзе генә гаеплеме ул моңа? Әйе, аның яшисе, эшлисе, үсәсе-күтәреләсе килә иде. Иленә һәм халкына ихлас күңелдән хезмәт итәсе килә иде. Әмма ләкин ул елларның кырыс шартлары аны, аны гына түгел, бик күпләрне әнә шулай ирекле кол итте; мөстәкыйль фикерләүне, шәхси намусны үз кулың белән буарга мәҗбүр итте. Бер ише кешеләр, җан саклауны, хәвеф-хәтәрсез яшәүне бөек идеаллар хакына дигән сылтау белән аклап, ихтыярсыз курчакка, обывательгә әверелде. Менә фаҗиганең тамыры кайда!.. Замана үзгәрде, кеше язмышы белән уйнау бетерелде, кешегә намусы кушканча яшәргә, иҗат итәргә мөмкинлекләр туды, ә шулай да теге еллардан канга сеңеп калган коллык зәхмәте һаман чыгып беткәне дә юк. Кем әйтмешли, эчкә кереп оялаган куян һаман калтыранып утыра әле. Шуны озын колагыннан сөйрәп чыгарырга көчең җитми, батырлыгың җитми синең... Кызганыч бәндә син! Кукыраеп йөрүче буш куык син!

...Хәлил ниндидер бер урам чатында тукталды. Кулын тирләгән маңгаена куйды, күзләрен йомды һәм бераз вакыт тик кенә тынып торды. Якында гына нәрсәдер тып-тып тама.

Хәлил газап тулы күзләрен ачты. Йа Хода, яз ич бу, яз! Ләйлә ич бу, Ләйлә! Тамчылар шуны тукыйлар бит аңа: ак күбәләгең яз булып, яшәрү булып, яңару булып кайтты, диләр!..

Хәлил тирән итеп бер сулады, кулы белән йөзен иягенә чаклы сыпырды, аннары кисәк кенә кузгалып, чалыш-чолыш атлый-атлый китеп барды. Ул болай ашыгып кая баруын, нишләргә теләвен ачык кына белми иде, ләкин бара торгач, аяклары үзләре аны бер киң урам чатына китереп чыгардылар. Бу – Чехов урамы иде. Каршы чатта биек цемент баганада бик якты булып электр яна. Аңардан өч-дүрт метрда гына газета-журнал киоскысы тора, Хәлил, бу таныш чатны күргәч, тукталып калды һәм, үзенең ни хәлдә булуын исенә төшереп, бераз куркып-борчылып та куйды. Ләкин киң урам буш иде, тын иде. «Йә, менә килдең, – диде Хәлил, башын салындырып. – Йә, ни күрдең, ни таптың? Кем көтә сине монда, исерек җүләр!» – Һәм оятыннан, хурлануыннан кая таба барырга белмәгәндәй, каршы чатка таба атлады. Барып җитәрәк кенә, тротуар буенда торган киоскының икенче ягыннан бер ханым килеп чыкты да Хәлил яныннан кызу-кызу гына үтеп китә башлады. Хәлил аны күз кырые белән генә күреп өлгерде. Әмма үзенә һич исәп бирмәстән, бөтенләй танымыйча-нитмичә, гүя актыккы өметен сынар өчен генә ул ят хатынга дәште:

– Ләйлә... Ләйлә ханым!..

Ханым ишетте. Ишетү генә түгел, артына борылып карады һәм кинәт тукталып та калды. Башта, куркуыннан булса кирәк, аз гына артка чигенгәндәй итте, аннары күпмедер вакыт өнсез калып, Хәлилдән күзләрен алалмыйча карап торды. Тик шуннан соң гына ул, артык гаҗәпләнүдән пышылдап:

– Хәлил абый!.. Хәлил абый, сезме бу? – диде, ниһаять.

Хәлил дә үз күзләренә үзе ышанмыйча өнсез катып калган иде. Берьюлы айнып киткәндәй булды ул, ләкин шул ук вакытта бөтен зиһене чуалып, бөтен реаль чынлыкны югалтып, ниндидер галәм бушлыгына чумгандай хис итә иде үзен. Тик иреннәре генә: «Ләйләмени бу, Ләйлә шушымыни, төш кенә түгелме, йа Рабби! – дип әйтергә тырышкандай, кыймылдыйлар иде. Шуңадыр инде Ләйләнең сүзләре дә аңа каяндыр бик ерактан килеп ишетелгән шикелле булды. Күпмедер секунд үткәч кенә ул, телгә килеп:

– Әйе, бу мин, мин, Ләйлә! – диде, бер үк вакытта көләргә дә, елап җибәрергә дә әзер торган чырай белән.

Тагын алар, бер-берсенә карашып, бер мизгел тынып калдылар. Шул чагында Хәлил, үзенең чын хәленә кайтып, исерек булуын исенә төшерде, һәм шуны сиздерүдән гаять куркып, арты белән киоскыга таба аз гына чигенә төште. Ләкин аны-моны сизеп өлгермәгән Ләйлә ханым, чын шатланудан яктырып:

– Менә нинди көтелмәгән очрашу! Просто гаҗәп! —диде һәм Хәлилгә кулын сузды.

Хәлил, түбәнчелек белән башын иеп, аның кулын кысты.

– Нинди җилләр ташлады сезне бу якларга?.. Шулай соң гына... – диде ханым, инде тынычлана төшеп.

– Болай... кичке прогулкага чыккан идем, – диде Хәлил, тотлыгыбрак, һәм, шулай дигәч кенә, кулында портфеле барын исенә төшерде. Ләкин ханым моңа игътибар итмәде булса кирәк.

– Килмисез дә, күренмисез дә, – дип сөйләнеп китте ул. – Ничек диләр әле, алты яшәр кайтса, алтмыш яшәр күрешә килер диләрме?.. Ә сез үзгәргәнсез, Хәлил абый, бик нык үзгәргәнсез... Сәламәтлегегез ничек соң? Ничек кенә торасыз?..

– Рәхмәт, зарарсыз, – дип кенә куйды Хәлил.

Ләйлә ханымның үзен бу кадәр тиз кулга алуы һәм шулкадәр гади, табигый сөйләшүе аны тәмам хәйранга калдырды. Әйтерсең бу ханым аңа беркайчан да мәхәббәт хаты да язмаган, әйтерсең аулак урамнарда, башын аның күкрәгенә салып, матур хыялларын сөйләп тә утырмаган, курка-калтырана чәчәк иреннәреннән дә үптермәгән, кыскасы, алар арасында берни дә – өзелеп яратышу да, әрнеп аерылышу да булмаган. Әйе, гаҗәп бу, бик гаҗәп!

– Мәрвәр ханым ничек соң, исән-саумы? – диде Ләйлә ханым, шундый ук эчкерсез табигыйлек белән.

«Бусы бигрәк тә инде», дип уйлады Хәлил, ачынып, һәм теләр-теләмәс кенә җавап бирде:

– Рәхмәт, тап-таза!

Ул үзе, исерек булуын сиздерүдән һаман әле куркып, сорашырга яки ни дә булса әйтергә кыймыйча азаплана иде. Бары томанланган күзләрен Ләйлә ханымнан аера алмыйча, гүя белергә, танырга, танып күңеленә сеңдереп калырга теләгәндәй, аңа тик йотылып карап тора иде. Әйе, бу ят хатын, бөтен килеш-килбәте, хәтта өс-башы белән дә ят хатын... Бөтенесе бик модный, бик затлы, бик бай... Әйе, мондый байлыкка һәм, ихтимал, югары бәхеткә ирешкән хатын үткәннәрне оныта, онытмаса, аларга салкын, битараф карый аладыр шул!..

Ләкин шул ук вакытта бу – Ләйлә. Дөрес, шактый нык үзгәргән, әмма матур булып үзгәргән Ләйлә бу... Ничектер буйга үсә төшеп, бераз тулыланып киткән. Кыз чагындагы самими нәфислегенә үзен бик карый белә торган хатыннарга гына хас нәзакәтле гүзәллек өстәлгән... Хәзер аны гамьсез ак күбәләккә түгел, ә горур аккошка охшатырга мөмкин булыр иде... Ә йөзе шул ук тулы иренле, бик чиста йөз, күзләре дә шул ук кара каймалы якты күзләр... Ах, аныкы буласы иде бит, аныкы буласы иде бу зифа сын, бу нәфис йөз, бу якты күзләр!

Ләйлә ханым, Хәлилнең бу кадәр йотылып карап торуыннан борчыла башлап, як-ягына җәһәт кенә каранып алды да ашыгып әйтте:

– Нигә без чат башында басып торабыз әле. Әйдәгез безгә, апалар ятмаганнардыр әле, мине көтәләрдер... вакытыгыз булса, сез дә кереп чыгарсыз.

Хәлил, авыр гына көрсенеп, башын чайкады:

– Юк, Ләйлә, бүген мин сезгә бара алмыйм, мөмкин түгел.

– Алайса мине озатып куегыз.

– Рәхәтләнеп! – диде Хәлил, ничектер ашыгыбрак, һәм үз хәлен онытып җибәрдеме, кинәт кузгалуы булды, Ләйләгә таба чайкалып та китте. Ләйлә ханым читкә тайпылып өлгерде. Соң дәрәҗәдә гаҗәпләнеп, ул Хәлилгә карады.

– Ни булды сезгә, Хәлил абый?

– Зарар юк, ул болай гына, – диде Хәлил, кызганыч елмаеп. Тиз генә тураймакчы булды, ләкин гөнаһ шомлыгына каршы, бер тотрыклылыгын югалткан гәүдәсе тагын чайкалып китте дә, ава язып, аркасы белән киоскыга сөялде. Бары менә хәзер генә Ләйлә ханым, аның агарган йөзенә, азрак кан җәелгән күзләренә һәм өс-башының да бик үк тәртиптә булмавына игътибар итеп, эшнең серен сизеп алды.

– Сез исерек бит, Хәлил абый! – диде ул, коты алынып. Куркынып тирә-ягына каранды, аннары тавышын әкренәйтеп, йомшаграк булырга тырышып әйтте: – Ходаем, сез исереп килгәнсез ич, сезгә кайтырга кирәк, сез кайтыгыз, Хәлил абый...

Әле эшне төзәтергә була иде. Моның өчен аз гына вакыт тынып тик кенә торырга кирәк иде. Шул арада исен җыеп, ныгып өлгергән булыр иде ул. Ләкин җүләрләр белән исерекләр һәрвакыт ашыгалар. Хәлил дә тизрәк акланырга, бөтенесен әйтеп калырга ашыгып, каршысында ташлап китәргә ничектер кыймыйча басып торган Ләйлә ханымга кинәт ике кулын сузды да:

– Ләйлә!.. Ләйлә бәгырем, ...бәгырькәем! – диде, иңрәп-ялварып. – Мин көттем, егерме биш ел буена мин сине көттем... Мин эзләдем, кайтуыңны ишеткәч тә, кичләрен шушы урамга килеп, сине эзләп йөрдем... югалган бәхетемне эзләдем мин... Кичер мине, ташлама мине, Ләйлә!.. Ләйләм!..

– Юк, юк, Хәлил абый! – диде Ләйлә ханым, артка чигенеп һәм агарынып. – Сез ни сөйләгәнегезне белмисез, сез ни хәлдә булуыгызны белмисез!.. Оят ич, килешми ич болай... Гафу итегез!..

Һәм ул кисәк кенә борылды да йөгерә-атлый китеп тә барды. Хәлил күзләрен йомды, сыны каткандай күпмедер вакыт хәрәкәтсез басып торды.

...Тып-тып тамчылар тама. Тып-тып төнге тамчылар тама. Беркемең дә юк, юк синең, беркемең дә юк, юк синең!..

Хәлил бер-ике адым алга атлады, аннары нәкъ каршысында торган салкын цемент баганага маңгае белән сөялде дә, калтыранып, үксеп җибәрде.

Икенче көнне ул айныган иде инде.

Бөтен газапларыннан, куркыныч-хәтәр уйларыннан, сүнми килгән соңгы мәхәббәтеннән, күптән югалган Ләйләне эзләп йөрүеннән – барысыннан да айныган иде. Кинәт купкан өермә тиз генә үтеп тә китте. Хәзер инде бу берәүгә дә эчен ачмый, чын сүзен әйтми торган шул ук салкын, йомык, горур профессор Хәлил Ишмаев иде.

Иртәнчәк ул, Мәрвәр ханым тирги-тирги чистартып биргән пальтосын киеп, зур портфелен кыстырып, кафедрасына китте. Мең дә беренче тапкыр аудиториягә керде, мең дә беренче тапкыр татар теленең морфологиясе турында лекциясен укып чыкты. Кеше үзенең күпме еллар буе таптаган сукмагына яңадан кайтып төште. Аның фикеренчә, бу такыр сукмактан чыгу мөмкин түгел, чыгарга соң иде инде.

*1964*

**Җиз кыңгырау**

*(Хикәя-истәлек)*

Минем китаплар шүрлегендә тавыш-өнсез генә җиз кыңгырау тора. Кайчандыр, моннан бик күп еллар элек, туйга яки кунакка барган чагында ул кара дугага тагылган килеш ат башында йөри иде. Хәзер кара дуга да юк, кара дуга белән җигелгән ат та юк, хәтта дилбегә тотып утырган хуҗа үзе дә юк, ә менә җиз кыңгырау ничектер торып, сакланып калган... Әллә нидә бер мин аны кулыма алып, әкрен генә селкеп карыйм. Җиз кыңгырау шунда ук, телгә килгәндәй, дәртле тавышын чыгара: «Зың-зиң, зың-зиң!..» Нәкъ менә кара дугада чактагы шикелле чыңлап, яңгырап китә. Гаҗәп, вакыт дигәнең дә көчсез икән бу җиз кыңгырау алдында, вакыт аны әз генә дә, ичмасам, үзгәртә алмаган. Ул элеккечә яшь, дәртле, моңлы һәм ниндидер бер могҗиза белән мине күз ачып йомганчы кырык ел артка, яшүсмер чагыма күчерә дә куя.

**I**

Әйе, яхшы хәтерлим, егерме дүртенче елның җәе иде бу. Нигъмәтулла абзыйкайларның яшел чирәмле иркен ихатасына килеп керсәм, ишек төбенә тарттырып куйган җигүле ат тора. Озын яллы сары ат җиз кыңгыраулы кара дуга һәм эшлияле камыт белән читән тарантаска җигелгән. Тарантасның артына салындырып чуар палас җәелгән, палас өстенә ике мендәр дә кабартып куелган. Моны күргәч тә мин: «Абзыйкайлар каядыр кунакка барырга җыенганнар икән», – дип уйладым, һәм аулак өйдә калу мөмкинлеге мине шунда ук куандырып та җибәрде.

Аулак өй безнең ише малай-шалайлар өчен үзенә күрә бер хөрлек инде ул... Шулай уйлап, өйгә кердем; керсәм, абзыкай белән җиңгәчәй өсләренә киенгәннәр, чыгып утырырга гына торалар. Җиңгәчәйнең өстендә киң итәкле озын кәшимир зәңгәр күлмәк, яшел камзул, башында көмеш тәңкәле тар гына калфак, калфак өстеннән чәчәкле яулык ябынган, юка шәлен иңенә салган, аягында сары читек белән кара галош. Нигъмәтулла абзыкай кыек якалы сатин күлмәк өстеннән яңа көрән пинжәген кигән, шундый ук көрән чалбардан, балакларын читек өстеннән салындырып төшергән, аягында өр-яңа галошлар. Башында шактый ямьшәйгән күк эшләпә, эшләпәсенең бер кырыеннан кара кәләпүшенең чите күренеп тора.

Мине күргәч, абзыкай гаҗәпләнүеннән кычкырып дәшә куйды:

– Пәрәмәч, син кайдан?

– Дәүләкәннән, – дим мин, авызны ерып.

– Ничек килдең, үзең генәме?

– Үзем генә. Рәхмәтулла абзыйга утырып килдем.

– Шулаймыни? Кара син! Һе, кунакка кайттым диген... Ә без менә Абзанга чыгып китәргә торабыз.

Мин ни әйтергә белмим. Нигъмәтулла абзыкай озак уйлап тора торган кеше түгел иде. Ул шунда ук җиңгәчәйгә карап әйтә куйды:

– Син! Шәкертне үзебездән калдырмыйк.

– Теләсә, – диде җиңгәчәй.

– Безнең белән барасыңмы, бәбкәм?

– Кая соң?..

– Абзанга инде... Туйга барабыз.

– Туйга?! Белмим шул, – дидем мин, шактый икеләнеп.

– Йә, нәстә тагын «белмим». Барабыз, вәссәлам! Туйдан тукмак та калмый.

– Туктале син, – диде җиңгәчәй. – Әхтәмнең өстен карыйк, кала кунагы, йөзенә кызыллык килмәсен.

Җиңгәчәй дөрес әйтә иде. Мин өйдән туйга барасымны белеп чыкмадым. Дөрес, минем өс-башым болай бик хөртидән түгел. Бик яңадан булмаса да пинжәк, чалбар, аякта ботинка, тик арбада кырык чакрым килеп, алар шактый таушалган һәм тузанланган иде... Җиңгәчәй минем өс-башымны күздән бер кичереп чыкты да:

– Алмашка күлмәгең бармы? – дип сорады.

– Бар, – дидем мин, кулымдагы төенчекне селкеп.

– Булды болай булгач, – диде Нигъмәтулла абзыкай, сүзне тизрәк бетерәсе килеп. – Ә Абзанга баргач, син аңа күлмәген каталап бирерсең*.

– Синең гел шул ордым-бәрдем булыр инде, – диде җиңгәчәй, сукраныбрак, аннары мич кашагасыннан миңа канат алып бирде: – Бар, өстеңдәге тузаныңны бераз чистарт.

Мин ишегалдына чыгып, башта пинжәгемне салып, аны канат белән чистарттым, аннары чалбарыма тотындым. Үзем чистартам, ә үзем эчемнән генә уйланам: барыргамы-юкмы бу туйга?.. Әлбәттә, туй бик күңелле, бик кызык нәрсә инде ул... Минем башкорт туен да, үзебезнең Каракош туен да күргәнем бар. Хәтта әткәйнең сеңелесе Сәрвәр апаны биргән чакта кайнеш булып, җизнидән пәке дә алганым бар. Үзеңә якын кешенең туе башка инде ул, андый вакытта өстеңә яңа кием дә тектереп кидерәләр, кулыңа әзрәк акча да бирәләр, кыскасы, берничә көн эчендә кинәт үсеп киткәндәй, күрше-тирә малайларының күзләрен яндырып, һаваланып йөри бирәсең. Ә бу туйда мин кем булып йөрермен? Монда, минем белүемчә, җиңгәчәйнең сеңелесен, ягъни Нигъмәтулла абзыкайның балдызын бирәләр. Аларга бит мин кода тиешле кешенең малае гына... Ничек каршы алырлар, ничек карарлар миңа, ят халык арасында арбаның бишенче тәгәрмәчедәй буталып кына йөрергә туры килмәсме?! Аннары аулак өйдә калу да бик кызыктыра бит әле. Бусы да сирәк эләгә торган бер хөрлек... Нишләргә соң?.. Әллә бармыйча калырга микән?..

Ул арада өйдән җиңгәчәй белән Нигъмәтулла абзыкай киҗеле ашъяулыкка төргән ике зур төенчек күтәреп чыктылар. Чыгуга, абзыкай миңа кычкырды:

– Йә, шәкерт, булдыңмы?

Мин, торып калырга бер сылтау тапкандай, ашыгып сорадым:

– Ә Зөләйха кайда соң?

– Зөләйханы апакае Өфегә алып киткән иде шул,—диде абзыкай.

Әйтәм җирле ул күренми. Зөләйха өйдә булса, бәлки, калып та булыр иде. Хәзер нишлисең инде, бармыйм дип кәҗәләнә башласаң, абзыкай йә тузып китәр, аның талканы һәрвакытта коры була.

Төеннәрнең берсен, печәнне кайтарып, кучер астына тыгып куйдылар. Аннары җиңгәчәй палас япкан мендәр өстенә киң итәкләрен җыештырып менеп утырды. Икенче төенчекне ипләп кенә үзенең алдына куйды – изәргә ярамый торган нәрсәдер, ахрысы... Абзыкай кучерга бер иске сырма салды.

– Кил, утыр, синең урының шушында булыр, очып төшмәссеңме? – диде ул миңа.

---

* Мин бала чакта авылда үтүк дигән нәрсә юк иде. Керне юан уклауга урап, сырлы зур бәләк белән тәгәрәтә торганнар иде. Безнең төбәкләрдә шуны катлау диләр. – *Ә. Е.*

Мин, алгы тәгәрмәчкә басып, кучерга менеп утырдым. Шуннан соң абзыкай, күн бияләйләрен киеп, каеш дилбегәне кулына алды да, бер аягын читкә салындырып, җиңгәчәй кырына утырды һәм авыз эченнән генә: «Тапшырдык», – дип, атын капкага таба борды. Җиз кыңгырау күңелле генә чыңлап куйды. Капкадан чыккач, абзыкай эшләпәсен күз өстенә тарта төште, җайлабрак утырырга теләгәндәй, селкенгәләп алды, аннары: «Яле, малкай!» – диде дә дилбегәсен кагып җибәрде. Сары ат кызу гына юыртып китте. Җиз кыңгырау, бердән дәртләнеп, «зың-зиң, диң-диң» килеп, көмеш чыңлавын сибәргә тотынды. Нигъмәтулла абзыкай авыл урамыннан матур һәм кызу юыртып узарга ярата иде. Хәзер дә ул ат чапмасын, ә юырттырып кына барсын өчен дилбегәсен ике куллап нык кына тартып тотты, атка нидер дәшкәндәй итте, һәм сары ат, аның кулын тоеп, озын яллы матур башын аккоштай кырынрак бөгеп, кыска аякларын күз иярмәс тизлек белән юлны типчегәндәй, вак-вак кына алыштырып, йомры янбашын тибрәтә-тибрәтә юргалап кына элдерергә тотынды. Урамдагы малайлар уеннарыннан туктап, ишегалларында йөргән агайлар башларын борып, җиткән кызлар ачык тәрәзәләрдән сузылып безгә карап калдылар. Бер-ике эт тә, каяндыр атылып чыгып, ат аягына ташланганнар иде дә, ләкин тавышларына бик тиз буылып, читкә тайпылып калдылар. Без Каракошның озын урамын әнә шулай кешеләрне сокландырып, этләрнең ачуын китереп, матур һәм шәп кенә узып киттек.

Авылдан кырга чыккач, абзыкай дилбегәне миңа бирде. (Бу аның гадәте, авыллардан узганда гына ул дилбегәне үзе тота.) Ат та шунда ук, дилбегәнең кем кулына күчүен сизеп алды булса кирәк, юргалап баруыннан туктап, гади юыртуга күчте. Мин, тарткалап, суккалап карасам да, аны барыбер тыңлата алмадым. Каяндыр болыты белән вак чебен иярде, һәм сары ат башын селкә-селкә ялкау гына бара башлады. Нигъмәтулла абзыкай тарантас артына киерелеп ята төште дә, тургайлар сайравына кушылгандай, «ихи-хи-хи!» дип бер сузып куйды.

Без Сынны юлы белән барабыз. Көн бик тын, бик эссе. Ике якта да яшь игеннәр йокымсырап, оеп утыра. Иген арасыннан күзгә күренмәс чикерткәләрнең иренеп кенә чырылдавы ишетелә. Юл буендагы эт эчәгесенең кыңгырау чәчәкләре тирәсендә ак, сары, чуар күбәләкләр талпына. Ара-тирә иген арасыннан берәр кошчык пырылдап күтәрелә яки кәкре томшыклы карчыга тычкан эзләп түбәннән генә, канат какмыйча йөзеп кенә үтеп китә... Үр менәбез... Сары ат йомшак юл тузанына тып-тып басып кына атлый. Абзыкай башта нииндидер бер көйне исенә төшерергә теләгәндәй әкрен генә сызгырырга тотынды. Аннары күзләрен яртылаш йомып, тавышын калтырата төшеп, башта авыз эченнән генә сузып, тик соңгы сүзләрен генә ачык әйтеп җырлый башлады:

И-и-и... яланнары сарылай кәрешкә-ә-ә-ү,

Тырышлыклар кирәк лә һәр эшкә-ә-әү.

Мин ул чагында бик нечкә күңелле идем, бик тиз тәэсирләнә идем, шуңа ачуым да бик килә иде, ләкин нихәл итим? Менә абзыкайның сузып җибәрүе белән үк минем күземә мөлдерәп яшьләрем дә килде. Әллә нинди шунда эчтәге бөтен нәрсәне бик төптән кузгата торган, бер үк вакытта бөтен җан иясен – адәмнәрне, кошларны, чәчәкләрне, бөҗәкләрне әрнеп кызганырга һәм өзелеп сөяргә мәҗбүр итә торган көй иде шул бу дәдәм көе! Һәм ул аны киң сулыш белән гаҗәп иркен, тирән, моңлы итеп җырлый белә иде. Җырлап бетергәч, тургайларны да үзенә кушылырга чакыргандай, тавышын тибрәтә-тибрәтә дәртләнеп бер «үлү... лү... лүү» дип сузып җибәрә иде. Һәм тургайлар, чынлап та аңа кушылгандай, тын, якты кырлар өстендә тагы да талпыныбрак, исеребрәк сайрарга тотыналар иде кебек.

Менә хәзер дә ул җырын әнә шулай әллә кайларгача җәелеп китәрлек итеп сузып бетерде дә, үзе дә шуңардан әсәрләнеп булса кирәк, кәефләнеп бер көлеп куйды. Җиңгәчәйгә таба борыла төшеп, кычкырып дәште:

– Ни әле син, якты көнем, уйга калдың? Әллә минем кияү булып яныңа кергән чакларым исеңә төшеп киттеме?

– Тилермә, – диде җиңгәчәй, сабыр гына елмаеп.

Мин дә, күземнән китеп бетмәгән яшьләрем аша елмаеп, аларга борылып карадым. Абзыкай кәефе килгән чакта җиңгәчәйне гел менә шулай көлеп шаяртырга ярата. Ә җиңгәчәй бер дә үпкәләргә тормый, күп вакытта сөйкемле-уйчан гына елмаеп, ачусыз гына җавап кайтара. Мондый чакларда алар миңа бер-берсен бик аңлыйлар, бик канәгатьләр һәм бәхетлеләр төсле булып күренәләр. Мин шуңа бик сөенәм, үземә дә ничектер җиңел, рәхәт булып китә.

Гомумән, мине, ундүрт яшьлек малайны, ул чакларда бәхет нәрсә ул, ярату нәрсә дигән сораулар бик борчый, бик уйландыра башлаган иде. Кешеләр ашыйлар-эчәләр, яталар-йоклыйлар, көн дә торып нужа куалар, ә бәхетлеме алар, яратышу дигән нәрсә бармы алар өчен – моны һич сизеп булмый иде. Бигрәк тә гади авыл кешеләренең бәхет һәм мәхәббәт турында уйларга вакытлары да юк, аларны кирәк диеп тә белмиләр шикелле тоела иде миңа.

Ярый, сүз бик озынга китте, без бит әле Абзанга туйга барабыз. Сынны авылын күптән уздык, инде Ивановка дигән зур рус авылына җитеп киләбез. Ивановканы үткәч, Абзанга да ерак калмый.

Яхшы атта җиңел генә барсак та, шактый җилектерде. Көн эссе, юлда бер дә урман-фәлән юк, гел ачык кырдан барабыз. Сүз бетте, барыбыз да тындык. Абзыкай ат юырткан уңайга талгып, азрак черем дә итеп алды. Мине дә вакыт-вакыт йокы басып киткәләде, ләкин кулда

дилбегә булгач, бирешмәдем, кыңгырауның күңелле генә чыңлавын, юл буендагы чикерткәләрнең ялкау гына чырылдавын тыңлап, үз уйларыма йотылып бара бирдем.

Ивановканың ике-өч чакрымга сузылган урамын узганда, Нигъмәтулла абзыкай уянып күзен ачты.

– Бәй, Ивановканы үтәбезмени? – диде ул, гаҗәпләнеп, һәм эшләпәсен күтәрә төшеп, тураебрак утырды.

Капка-койма буендагы таза балтырлы яланаяклы апайлар, ап-ак җитен башлы малайлар, эскәмияләрдә текә генә утырган зур картузлы рус агайлары безне кызыксынып озатып калалар. Монда абзыкайның «знакомнары» да бар икән. Шуларның кайберләре белән ул, баш кагып:

– Ә, Митрофан агай, сәлам!

Яки:

– Ә, Ягур Иваныч, здрастуй! – дип исәнләшеп узды.

Тегеләр иренмичә картузларын күтәреп, башларын кат-кат селкеп калдылар. Арадан берсе тагын:

– Князь кая китеп бара? – дип тә кычкырды.

– Туйга инде, туйга! – диде абзыкай, көлеп. – Свадба гүләем!

– Көлмә шул тикле, тиле кебек! – диде җиңгәчәй, ничектер бераз уңайсызланып.

Ләкин көлмәслек тә түгел икән шул. Нигъмәтулла абзыкай Ивановка урамыннан кыңгыраулы атта узып, менә дүртенчеме-бишенчеме балдызының туена бара, имеш. «Знакомнар» моны белеп бетергәннәр инде.

...Инде Абзанга да җитәбез шикелле... Алдагы сыртны гына менәсе калды. Шуннан Түреш буенда утырган авыл күренергә тиеш.

Бер сай чокырны чыккач, абзыкай миңа, юлдан читкәрәк борып, атны туктатырга кушты. Мин, ахрысы, кисәгрәк бордым, тарантас кинәт чалышаеп китте.

– Һәй, шәкерт, – диде абзыкай, тиз генә сикереп төшеп. – Җиңгәчәңне өстемә аудара яздың бит...

Мин нибары тик кызардым гына... Эчкәрәк узып, чирәмгә төштек. Тураеп, киерелеп, бераз сөякләрне яздык. Тузаннарны кактык, үләннең чистарак җиренә кереп, аякларыбызны ышкыдык.

Абзыкай, авыз эченнән генә сөеп, сары атның ялын тараштыргалады, тирләгән муенын сыпыргалады, тәртәсен селкетеп, аркалыгын тартып карады. Җиңгәчәй тарантастагы мендәрләрне каккалап, күпертебрәк куйды... Шулай бераз селкенгәләп алгач, яңадан утырышып, кузгалып киттек.

Сыртны менүгә, алдыбызда Түреш буе ачылды һәм ерак түгел Абзан да күренде. Нигъмәтулла абзыкай дилбегәне миннән алды, гадәтенчә, эшләпәсен күзенәрәк төшерде һәм: «Әйдәле, канатым!» – дип бер кагып җибәрүе булды – сары ат озын яллы муенын текә генә бөгеп, йонлач бәкәлләрен вак-вак кына алыштырып, томырылып юырта да башлады. Җиз кыңгырау, тәңкәләр сипкәндәй, дәртләнеп еш-еш кына тагын да чыңларга тотынды. Кырлар уянып киткәндәй булды, тургайлар гүя сискәнеп тагы да югарырак күтәрелделәр.

Минем бик кечкенә чагымда Иске Абзанда булганым бар иде. Анысы бик зур авыл булган, диләр. Мин аны белмим, хәтерләмим, тик зур кара тараканнан куркып елавым гына истә калган. Бусы моннан берничә ел элек кенә шул авылдан күчеп утырган Кечкенә Абзан. Барлыгы утызлап кына йорт булыр. Өйләр барысы да яңалар, тазалар һәм бер яклап кына утырганнар. Каршыларында гына буйдан-буйга киртә тоткан иген басуы башланып китә. Каралты-куралары, бәрәңге бакчалары болынга таба караган. Болын тип-тигез, чып-чуар чәчәк кенә, Түреш үзе күренми дә, аның кай тирәдәнрәк акканын бары яшел талларга яки биек, карт тирәкләргә карап кына чамаларга була... Бик күңелле, бик сөйкемле җирдә утыра икән бу Кечкенә Абзан. Мин үзем нигәдер менә шушындый иркен, матур табигатьтә утырган кечкенә, җыйнак авылларны күбрәк яратам.

Без менә шул авылга шәп кенә юырттырып, дәртле кыңгырау тавышы белән сәламләп килеп кердек... Авылның икенче очына җитәрәк, урам башын такта, эчкәре башын салам белән япкан йортның урыс капкасын безгә бер дәү, таза абзый ачып ук тора иде инде. Бу туй буласы йорт – җиңгәчәйнең этиләре, ягъни кода бабайлар йорты. Капканы ачып торучы – җиңгәчәйнең агасы Хөбәйбулла кода иде.

Ишегалдына килеп керүгә, безнең тарантасны хуҗалар сырып алдылар. Куе чал төшкән түгәрәк кара сакаллы, базык бәдәнле, йомры, сөйкемле генә карт – кода бабай, аның янында ап-ак чырайлы, юка гәүдәле карчык —кодагый әби иде. Тагын бик куанышып безнең тирәдә бөтерелүче ике җиткән кыз – җиңгәчәйнең сеңелләре —миңа кодачалар. Шушы кодачаларның кайсындыр (ихтимал, әнә теге оялыбрак, арттарак торганындыр, мин әле ачык кына белмим) кияүгә бирәләр – менә шуның туе булачак инде.

Нигъмәтулла абзыкай тарантастан егетләрчә тиз генә төшеп, башта ике куллап, иелә биреп, бабасы һәм әбисе белән күреште, аннары көлә-көлә балдызларының аркаларыннан кагып, алар белән күрешә башлады... Җиңгәчәйнең төенчекләрен алдылар, үзенә тарантастан төшәргә булыштылар... Билгеле, шунда ук миңа да игътибар итеп өлгерделәр. Кучердан җиргә төшүемә, кода бабай:

– Кара, бу Әхмәтҗан коданың улы түгелме соң? —диде, куанычлы гаҗәпләнгәндәй.

– Әйе, шул үзе инде, кече кодагыз Әхтәм, – диде җиңгәчәй.

– Бәрәкалла, бик кадерле кунак алып килгәнсез икән, рәхмәт төшсен! Әйдүк, шәкерт, әйдүк! – диде кода бабай, миңа ике кулын сузып.

Бу хәтле зурлап дәшүне ишеткәч, мин шактый каушап калдым, кызарып киттем. Бигрәк тә яшь кодачаларның күзләрен елтыратып миңа кызыксынып карауларын күргәч, бик уңайсызландым, әллә ничек менә үземне котсыз, килбәтсез, ә өс-башымны ярлы, начар итеп тойгандай булдым. Алар миңа «каладан килгән кунак» дип карыйлар инде. Ә минем кай җирем генә каланыкына охшаган соң?! Талчыбыктай нечкә, озын бер малай гына ич мин... Шулай кызарып, уңайсызланып кына мин, кода бабай, кодагый әби, Хөбәйбулла кода белән күрештем, әмма кодачаларга кул сузарга көчем җитмәде.

Ыгы-зыгы килеп, исәнлек-саулык сораша-сораша күрешеп беткәннән соң, безне өйгә чакырдылар. Хөбәйбулла кода атны, йөгәненнән алып, туарыр өчен лапаска таба атлатты. Кодачалар чирәмгә тиз генә таз белән комган чыгардылар, рәшәткә башына озын сөлге элеп куйдылар. Абзыкай дәртле тавыш белән:

– Ягез, балдызлар, кайсыгыз уңганрак, безне юындырыгыз әле, – диде.

Ә мин һаман уйланам: бу ике кодачаның кайсысын бирәләр икән. Шушы түгәрәк йөзле, соры күзле, тулырак гәүдәлесенме, яки әнә теге озын кара толымлы, коңгырт күзле, нечкәрәк буйлысынмы? Тулырак гәүдәлесе яшькә олырак кебек – бәлкем, шунысындыр. Алай дисәм, нечкәрәк буйлысы ничектер уйчанрак кебек, үзен ул эрерәк, җитдирәк тота да төсле... Безгә комганнан суны да түгәрәк йөзлесе салып торды, ә тегесе аз гына юанды да тизрәк кереп китте. Шуннан соң безгә бүтән күренмәде дә һәм юрарга урын да калмады: шул озын толымлы, нечкәрәк буйлы Сәлимә дигәнен кияүгә бирәчәкләр икән инде.

Иртәгә туй киләчәк һәм никах укылачак икән. Бүген исә шуңа соңгы зур әзерлек бара. Әнә аш өенең тәрәзәләре ачык, ишеге ачык, мичен көненә икешәр ягудан тәмугка әйләнгән эссидә хатын-кыз кайнаша. Зур сәке өсте туп-тулы табак-савыт, тәпән-чүлмәкләр, мичкә тыгар өчен әзерләп куйган табалар... Ничәмә төрле туй ашлары пешмидер бүген анда!

Өйнең урам башында да шул ук тамаша: кызлар тәрәзә башларына кашагалар сузалар, тәрәзә араларына чиккән башлы озын сөлгеләр эләләр, өйнең бөтен түр башын алып торган сәкегә киез, паласлар җәяләр. Чирәмгә чыгарып, су бөркеп юдырылган, сөртелгән гөлләрне кире кертеп үз урыннарына куялар. Кыскасы, тавык та чүпләп бетмәс кызу эш бара.

Безгә чәйне дә бакчадагы каен төбенә чыгарып куйган өстәлгә әзерләделәр. Чәй янына кода бабай үзе генә утырды, башкаларның вакыты юк. Кода бабайның өстендә ике генә сәдәпле ап-ак күлмәк, кара камзул, башында яңа кәләпүш. Мин аның шушы бик пакь булып күренгән

кыяфәтенә һәм түгәрәкләп кырыккан чал сакаллы алсу, тыныч йөзенә кызыксынып, хәтта сокланып карыйм. Ул миңа бик күпне белгән, бик акыллы, сабыр, кешеләргә мәрхәмәтле бер карт булып күренә. Ничектер менә, ул дөньяда бик гадел торгандыр, бернинди дә начарлык эшләмәгәндер һәм берәүне дә урынлы-урынсыз рәнҗетмәгәндер дип ышанасы килә. Ашыкмыйча гына чәй ясый-ясый, ул миннән әткәй-әнкәй турында сорашты: «Әхмәтҗан кода ничек, тазамы, авырмыймы? Хәкимә кодача сау-сәламәтме? Ярый, ярый, бирсен Алла! Әнкәең —бик әйбәт, бик сабыр акыллы хатын, тик, бичара, бала хәсрәтен күп күрде. Ничәү әле, сигезме-тугызмы баласы үлеп китте бит?.. Туган берсен Ходай ала торсын әле, йә, ана кеше өчен моңардан да авыр хәсрәт бармы соң?! Син инде аның уннан берсе буласың, Хак Тәгалә үзеңә гомер бирсен, әткәң-әнкәңә картайган көннәрендә игелегеңне күрергә насыйп итсен».

Ахырдан минем үземә дә: «Укыйсыңмы? Бик яхшы, уку кирәк, укуда хәзер бар өмет!» – дип әйтеп куйды. Мин моны үземчә дөрес аңладым шикелле: заманасы шундый, укып кына чын кеше булырга мөмкин дип әйтүе иде бу аның... Әйе, минем япь-яшь кенә башымны иң нык уйландырган мәсьәлә дә шул инде, шул!

Чәй янында озак утырмадык – вакыты ул түгел. Иң элек җиңгәчәй торып, чоланда гына өстен алыштырып, аш өенә кереп китте. Бераздан Нигъмәтулла абзыкай белән Хөбәйбулла кода да, кабык арбага ат җигеп, каядыр китеп бардылар. Мин ялгызым бер эшсез калдым. Өй тирәсендә хәзер җыен хатын-кыз гына – миңа нишләргә соң? Кунакка килгән җиреңдә үз ишең булмаса, шактый читен икән ул...

Мин шулай рәшәткә буенда ялгыз басып торган чагымда ике яшьрәк хатын өйдән каршыдагы ак келәткә түшәк-ястык, чыбылдык-чаршаулар ташый башладылар. Ни өчен, кем өчен бу дип уйларга өлгермәдем, келт итеп башыма килде: ак келәткә кыз урыны әзерлиләр. Кияүне кыз янына шунда ябачаклар... Юк, миңа бу тирәдән китәргә кирәк иде. Ераккарак, аулаграк җиргә, һәм мин абзарларга таба уздым да шундагы арт капкадан болынга, Түреш буена чыгып киттем.

Башта, уйланып барудан, ахрысы, ничектер тирә-ягыма күтәрелеп карарга да онытканмын. Күпмедер җир киткәч, үземне бил тиңке куе үлән эчендә күреп, гаҗәпләнгәндәй тукталып калдым. Алдымда шау чәчәктән торган тип-тигез болын җәйрәп ята... Шушымыни инде ул Түреш буе?.. Хәйран калмаслык та түгел икән шул!

Мин үзем дә Дим буенда үскән малай, болыннарны күп таптаганым бар, әмма моның кебек тоташ чып-чуар чәчәкле, ерып йөри алмаслык куе үләнле, тын-якты болынны беренче күрүемдер. Күңелгә кинәт нур тулды, күзгә хәтта сөенеч яшьләре килде, һәм шул чакта табигатьнең кешегә газиз ана кочагыдай никадәр якын-кадерле булуын, кешенең аңа мең төрле

җепләр белән бәйләнгән булуын, алай гына да түгел, кешенең бөтен хыялы-өмете, эше-гамәле шушы җылы, якты, тере сулышлы табигатьтән яралган булуын ихтыярсыз аңладым, тойдым, белдем шикелле... Болар берсе дә яңа нәрсә түгел кебек, әмма кеше йөрәгенең табигать белән мондый гомерлек тирән якынлыгын кинәт бик ачык хис итүе дә, минемчә, еш булмый торгандыр.

Үлән каплап киткән иске арба эзенә төшеп, мин юри миңа сузылгандай ышкылып, сыгылып калган ал, кызыл, күк, сары чәчәкләрне учым белән сыпыра-сыпыра, болын түрендә кара-яшелләнеп торган агачлыкларга таба киттем. Барып җиттем. Бер карагай төбендә тукталдым. Менә елгачык үзе дә. Киң түгел икән, ярлары якын, ләкин тирән генә күренә. Суы зөбәрҗәттәй яшькелт, бик чиста; күләгә урыннарда караңгыланып китә, кояшлы җирләрдә җем-җем уйнакларга тотына, ә шулай да, үз дәрәҗәсен белгәндәй, ашыкмыйча уйчан тыныч кына агып ята. Чыккан җире дә, барып койган урыны да ерак түгелдер инде бу тын-сөйкемле елгачыкның, әмма гомере аның хыял җитмәс озын булырга тиеш. Күңелнең нечкәргән чагы иде, карап тордым да шагыйрь сүзләре белән үзенә дәштем:

– Әй, агым су, ни уең, ни хәсрәтең бар синең?Ниләр күрдең, ниләр беләсең син?.. Синең буйларыңда кызлар туалар, кызлар үсәләр, үсеп җиткәч әнә кияүгә чыгып китәләр. Син аларның бит-башларын, ап-ак тәннәрен югансың, зарларын, серләрен ишеткәнсең. Ни юрыйсың син аларга, ни телисең? Тормыш әллә нинди, тормыш бик серле, кызларыңны нәрсә көтә – алар үзләре дә белмиләр... Син аларга бәхет юра, син аларга чын мәхәббәт телә, әй, агым су!

Ә агым су ага, миңа «әйдә» дигән сыман, бөтерелеп-уймакланып ага да ага. Мин ихтыярсыз аңа ияреп киттем. Яр кырындагы тар гына сукмак бормаланып куе таллыклар арасыннан, гөлҗимеш, карлыган, зелпе куаклары яныннан уза, тип-тигез, ачык, якты аланлыкларга килеп чыга... Шулай агым суга ияреп йөреп, шактый вакыт уздырып, ниһаять, авылга таба борылдым.

Җәйге озын көн күптән инде төшлектән авышса да, кояш баерга ерак иде әле. Кайтып керсәм, өйдә хәрәкәт тагы да көчәйгән кебек – көн үтә, ә эшнең очы-кырые күренми, ахрысы. Яшь кызлар, яшь киленнәр тыз-быз йөриләр, өйдән нәрсәдер чыгаралар, нәрсәдер кертәләр, селкәләр, кагалар... Кайсы кое янында нидер чайкап-чайкап юа, кайсы рәшәткә буенда комлап-катыклап самавыр, поднос агарта. Кар базының капкачы бертуктаусыз шап-шоп ачыла да ябыла – аннан өйгә чүлмәк-чүлмәк сөт, май, каймак ташыйлар. Аш өенең ачык тәрәзәсеннән мунча эссесе килеп тора – мичнең ничәнче ягылуыдыр инде, җиңгәйләр урак өстендәге шикелле янып, кызарып беткәннәр.

Лапас астында Хөбәйбулла кода белән Нигъмәтулла абзыкай түбән салындырып аскан бер зур сарыкны тунап яталар. Бая алар ат җигеп көтүгә киткән булганнар икән, менә шуннан бер кысыр сарыкны алып кайтып суйганнар. Мин килгәндә тунап бетереп торалар иде. Кода бабай да килеп карады. Хөбәйбулла кода үткен пычак очы белән сарыкның кабырга арасын берничә җирдән телеп җибәрде – кара ите юк диярлек, торганы май гына.

– Сөбеханалла, – диде кода бабай, башын селкеп.—Җыйган икән майны үзе дә, ризыкка язсын.

– Хәзрәтләрнең эченә тимәсә ярый инде, – диде Нигъмәтулла абзыкай, көлеп.

– Тимәс, ашап өйрәнгән халык. Сигез капканчы, симез кап, дигән борынгылар... Каклаган ит белән җиңел үтәр, иншалла.

Кода бабай киткәч, Нигъмәтулла абзыкай комганнан җылы су белән кулларын юды да, җиргә чүгәләп, учына яшереп кенә тәмәке көйрәтергә тотынды. Хөбәйбулла кода да аның янына чүгәләде.

– Туйны кемнәр күтәрешә? – диде Нигъмәтулла абзыкай.

– Әхмәтсафа абзыйлар, Сабирҗан җизниләр, Галекәйләр... шул үзебезнең якыннар инде.

– Сәләхи абзыйлар?

– Юк, алар катнашмый.

– Пәрәмәч, ник?.. Бик якын туганыгыз лабаса.

Хөбәйбулла кода авыр гына сулап куйды.

– Туган да бит, һәркемнең үз исәбе, кияү... Әтәй дә, мин дә әйтеп карадык югыйсә. Быел елыбыз авыр, туй кебек зур мәшәкатьне күтәрә алмыйбыз, ди... Анысы инде берәүгә дә җиңел түгел дә бит, туганлык хакына күтәрәләр. Ә үзебезне әйтмим дә инде... Туй үткәрүнең нәрсә икәнен беләсең, кияү, әнә өсәкләребездә канат белән сыпырып алырлык та бөртек калмады. Ләкин җәл түгел, бетсен, тик баш кына сау булсын, ие!.. Сәләхи абзый бик карун кеше ул, ипиен дә иләтмичә генә салдыра, ә үзенең ындырында сукмаган эскерте тора... Әмма ләкин хикмәт анда гына түгел, хикмәт бүтәндә. Аларның да бит безнең Сәлимәдән олырак җиткән кызлары бар. Мәфтуха... Менә Сәлимә китә, ә Мәфтуха калып тора әле... Шуны бер дә күтәрә алмыйлар, кияү, көнчелек ашый үзләрен...

– Алай икән, – диде Нигъмәтулла абзыкай, сузып кына. – Хикмәте бар икән шул... Кайнагай, теге ни, Сәлимә балдыз, мин әйтәм, Мәфтуханың юлын кисмәгәндер бит?..

– Алла сакласын! – диде Хөбәйбулла кода, ашыгып.—Андый нәрсә буламы соң?! Язмыш эше, кияү, язмыш эше. Берәүнең дә монда гаебе юк.

– Аптырап кына әйтүем инде, әллә Мәфтуханың да ул егеттә өмете булдымы икән дип кенә...

– Өмет... өмет, ни, һәрбер җиткән кызда була инде ул... Әмма нишләмәк кирәк, язмыш!.. Хәзерге яшьләрне беләсең, үзләре бер-берсен табалар. Мунчаклап китереп булмый.

– Дөрес инде анысы, кайнагай, дөрес... Һай, Мәфтуха!.. Әйтәм җирле, ул сездә күренми.

– Чакырдык, бик чакырдык үзен, – диде Хөбәйбулла кода, ачынып. – Инәкәй үзе барып чакырып карады, юк, килмәде, чәкчәк пешерешергә дә килмәде. Әтәсе, Сәлахи абзый, инәкәйгә әйткән, үзебез туйны күтәрешә алмагач, Мәфтуханы да җибәрә алмыйбыз дигән. Йә, шул да булдымы сүз?! Әлеге дә баягы, көнчелек... көнчелек ашый адәм баласын!

– Хәерле булсын! – диде Нигъмәтулла абзыкай, тәмәкесен җиргә басып. – Кызлы йортка кырык ат бәйләнер дигәннәр. Мәфтуха да утырып калмас әле, насыйбы табылыр.

Алар чүгәләгән җирләреннән тордылар.

– Кызлы йортлар күбрәк, егетле йортлар әзрәк шул хәзер, – диде Хөбәйбулла кода, көрсенеп. – Канатлар чыкты егетләргә, еракларга оча башладылар... Их-ма, дөньясы!

Аларның бу кыска гына сөйләшеп алулары миндә шактый күңелсез уйлар кузгатты. Менә туй, бәйрәм, зур шатлык булырга тора, ә баксаң, аның эчендә дә әнә нинди каршылыклар, ризасызлыклар бар икән... Гаҗәп бу тормыш!

Ниһаять, кич тә булды. Тузан, сөт исе аңкытып көтү кайтты. Сыер, сарыкларны капкадан ук туры абзарга куып кертteләр. Җиңгәчәй белән кече кодача, чиләк күтәреп, шунда ук сыерларны саварга киттеләр. Эш бер дә бетәр кебек түгел иде, ләкин кода бабай, күз бәйләнгәнче халыкны ашатырга кирәк, дип, кичке ашны тизрәк ашыктырырга кушты. Ике җиргә – берсен бакчадагы кечкенә өстәлгә, икенчесен, зур торыпша җәеп, ишегалдының тапталмаган чирәменә табын әзерләделәр. Барлык эшләп йөрүче кызлар, җиңгиләр, апайлар, арган аякларын сузып, чирәмдәге зур табынга урнаштылар. Бакчадагы кечкенә табын кунаклар белән хуҗалар өчен генә – без шунда утырыштык.

Безнең табынга графин белән бал да килде. Бу туйга дип әчеткән бал инде, бүген шуны ничегрәк булган икән дип эчертеп карыйлар. Кода бабай беренче башлап Нигъмәтулла абзыкайга салып бирде. Ул балның остасы —стакан кырыннан әз-әзләп кенә эчеп, авызын чәпелдәтеп торды да:

– Булган бу, – диде. – Әчүе дә җиткән, кыркуы да юк, ширбәт кенә... Әмма үзе, борыч салгандай, авызны яндырып бара. Шәп булган бу, шәп!

– Инәйнең балы беркайчан да начар булмый торган иде, – диде җиңгәчәй дә.

– Һи, минем әби, минем әби бишенче кызын бирә шул, ничек итеп аның балы начар булсын ди. Күз яшьләрен тамыза-тамыза койгандыр әле ул аны.

Кодагый әби көләргә итте, көлә алмады, күзләренә яшьләре килгәндәй булды, ләкин аларны да күрсәтмәде, тик тирләгән битен генә яулык очы белән сөртеп куйды.

Кода бабай балны миңа да салып бирде. Мин, эчимме икән, юкмы икән, эчсәм килешер микән дип, шактый аптырауда калдым. Кода бабай шуны сизгәндәй:

– Йә, йә, шәкерт, аз гына эчкәннән гөнаһ булмас,—диде.

Яртылаш кына эчтем, һәм чынлап та бал гаҗәп тәмле иде. Башта куәтен дә сизмәдем, тик соңыннан гына ул әкренләп бөтен тамырларыма җәелгәндәй булды.

Шуның тәэсиреннәндер инде, мин, өстәл тирәсендә барган сүзләргә колак салмыйча, кинәт Сәлимә кодачаны исемә төшереп, аның язмышы турында уйлана башладым. Минем бит әле аны юньләп күргәнем дә юк. Йөрми, чыкмый, менә безнең табынга да утырмады. Ярәшелгән кызлар бик оялчан булалар дип ишеткәнем бар, сизгер җәнлек шикелле, кеше күзенә күренергә бер дә яратмыйлар, имеш... Әйе, Сәлимә кодачаны да хәзер никахтан ярты гына тәүлек вакыт аерып тора, иртәгә ул кыз чагының соңгы сызыгын үтәчәк, икенче тормышка керәчәк, кеше кешесе булачак. Ни уйлый ул, ниләр кичерә, үзен ничек тотарга мәҗбүр – менә шуны белер өчен генә мин аңа хәзер бер тутырып карар идем. Күңелемнән генә: «Мин сине кызганам, мин сине көнлим, әмма сиңа бик күп, бик күп бәхет телим», – дип әйтер идем.

**II**

...Аш ашап, чәй эчкәннән соң, безгә ятарга куштылар. Мине, кунак дип, түр өйгә яткырмакчы булганнар иде, ләкин мин туй мәҗлесе өчен шулкадәр тырышып юган-җыештырган җиргә кереп ятарга бер дә теләмәдем. Рәхмәт Нигъмәтулла абзыкайга, ул гадәттәге өлгерлеге белән: «Йә, мондый кичтә кем өйдә ятсын, без шәкерт белән печәнлектә йоклыйбыз», – диде. Кунакларның атлары өчен лапас башына күп итеп печән китереп өйгәннәр икән, без шул әле кибеп тә өлгермәгән хуш исле печәнгә палас җәеп, ике мендәр ташлап менеп яттык. Нигъмәтулла абзыкай башын мендәргә кую белән гырлап йоклап та китте. Мин алай тиз генә йоклап китә алмадым. Ишегалдында һаман кешеләр йөри, көлгән, сөйләшкән тавышлар ишетелә, лапас эчендә арбага бәйләгән безнең сары ат ашыкмый гына үлән кетердәтә, ара-тирә авыр гына сулап та куя, салдырылган авызлыгын әледән-әле чылтыратып ала. Ә аяз күктә миңа туп-туры карап тулган ай тора. Юк, тормый, китеп бара. Юк, китеп бармый, тора. Әллә тора, әллә китеп бара?! Ә тулган айга җитез-тере генә бер йолдыз ияргән... Ул да тибрәнә-тибрәнә... тибрәнә-тибрәнә... Мин йоклап китүемне сизми дә калдым.

Төшемдә кояш чыкканын күрдем. Бер биек кенә калкулык өстеннән еракгагы кара-зәңгәр офыкка карап торам, имеш. Менә бервакытны шул зәңгәр караңгылык әкрен генә сыеклана-сыеклана алсуланып яктырды. Озак та үтми, чыгып килгән кояшның нечкә кавын телемедәй сары кырые күренде. Бераздан ярты калач хәтле булып чыкты бу, аннары, чыга торгач, түп-түгәрәк ут шарына әйләнеп, җирнең читенә үк чыгып утырды. Менә бер заман аның әйләнәсендә әллә никадәр алтын кыршаулар чайкалып уйнакларга тотынды – һич карап та булырлык түгел, һәм шул чакта мин дә күзләремне кытыклаган җылы яктыдан уянып киттем. Баксам, кояш шактый күтәрелгән, кечерәйгән, кызган, һәм мине: «Тор, малай!» дигән төсле, бик әйбәтләп пешерә дә башлаган. Ишегалдында шул ук кешеләр мәш килеп йөриләр – кайчан ятып, кайчан торганнардыр, Ходa белсен!

Лапастан төшүгә, мине коедан су чыгарып торган кече кодача күреп алды. Оялчан гына елмаеп дәште:

– Әхтәм, кил, салкын су белән юын!..

Үзе, рәшәткә буена тиз генә барып, чиләгеннән комганга су салды да мине көтеп тора башлады. Мин килеп комганга үрелгәч, ул ашыгып: «Юк, юк, үзем», – диде һәм бик теләп миңа су салып торды. Аннары сөлге бирде.

Кече кодача!.. Миннән ничә яшькә олырак икән? Бу инде теге кияүгә китәчәк кодачаның сеңелесе, кода бабайларның төпчек кызлары. Менә апасы китә, ә ул шуны гүя үзенең иң зур шатлыгы итеп, канатланып, бөтерелеп йөри. Аңламыйм мин бу кызларны. Кияүгә чыгу алар өчен дөньяның иң зур бәхете микәнни? Сакланып кына сорыйм:

– Апаңны... кызганмыйсыңмы?

Кече кодача миңа бик гаҗәпләнеп карый:

– Нигә?

– Сезне аералар ич.

– Һии, – дип көлде кодача. – Аерсалар ни, ерак китми әле. Күрешә торырбыз.

«Ә син кайчан кияүгә чыгасың?» – дип сорыйсым килде минем, ләкин тыелып калдым. «Әдәпсез», – дияр, гәрчә бөтен кайгысы кияүгә чыгу булса да.

Ләкин шулай да минем аңардан егет турында бераз сорашасым килде.

– Кияү кем инде?

– Кем булсын, кеше! – диде кече кодача, мине үчекләгәндәй.

– Алаша түгел икәнен мин дә беләм, – дидем, үз нәүбәтемдә шаярткан булып. – Мин синнән, кайдан, нинди егет ул, дип сорыйм.

– Түбән Абзаннан, Фазылҗан малае Шакирҗан... Йә, белдеңме?

– Чибәр егетме?

– Чибәр, күргәч гайрәтең чигәр, – диде кече кодача, шаркылдап.

Нигәдер аның минем белән гел уйнап кына сөйләшәсе килә.

– Юк, мин чынлап сорыйм, – дидем мин, көлмәскә тырышып.

– Мин дә чынлап әйтәм. Ихлас, чибәр егет, тәтәй өчен бик тә чибәр...

– Йөреп өйләнештеләрме?

– Ничек... йөреп?

Мин азрак уңайсызланып киттем: әллә юри аңламаган була инде, пәри кыз!

– Ни... теге... алдан танышып, яратышып йөрделәрме дим?

– Ә-ә! – диде кече кодача, күзләрен хәйләкәр генә кысып. – Каян белим, аны кешегә сиздермиләр ич.

– Син бит сеңелесе, белгәнсеңдер әле.

– Белсәм ни, тәтәйнең гайбәтен сатарга мин юләр түгел лә.

– Өйләнешкәч, гайбәт булмый инде ул хәзер.

Кече кодача аз гына уйга калды һәм беравык миңа сынагандай карап торды. Аннары кисәк кенә:

– Ә син кешегә әйтмәссеңме? – дип сорады.

– Кемгә әйтим, мин бит монда берәүне дә белмим.

Кече кодача, тирә-ягына ялт-йолт каранып алды да, миңа иелә биреп, шыпырт кына әйтте:

– Мин алар арасында хат йөрттем.

– Шулаймыни? – дидем мин, бик кызыксынып. Аннары аптырабрак сорадым: – Хатны ничек йөрттең соң? Ул бит икенче авылда.

– Булса соң... Түбән Абзан аръякта гына... Болынга кичке уенга без моннан, ә алар теге яктан төшәләр. Менә шул чакта Шакир җизни... әем лә, ул чакта җизни түгел әле... шыпырт кына миңа хат төртә иде. Ә мин тәтәйнекен аңа...

– Алар үзләре бер дә очрашмыйлар идемени?

– Ник очрашмасыннар, очрашалар иде. Ләкин бит гыйшык сүзен телдән әйтеп булмый, хатка гына язып була... Син, шәкерт башың белән, шуны да белмисеңмени? – диде кече кодача, мине тәмам үтерердәй итеп.

Мин комачтай кызарып киттем: юк икән шул әле, гыйшык тотуның серләрен белмим икән әле мин... Ләкин дәрәҗәне саклар өчен, эре генә әйткән булдым:

– Хатны танышыр өчен башта гына язалар, ә танышкач барысын да телдән сөйләшәләр.

Кече кодача, «тиле син» дигәндәй, тагын шаркылдап көлде.

– Әйттең сүз! Аларга нигә танышып торырга, алар болай да бер-берсен би-ик күптән беләләр. Ә менә егет хат язмаса, аның яратуын кайдан беләсең? Вәт әйтеп кара!

Чынлап та шулай, күрәсең... Минем бит үземнең дә бергә укыган Әминә исемле кызга «танышыйк» дип «гыйшык» хаты язып караганым бар, тик ул, юләр, тоткан да хатны әнисенә биргән, ә әнисе минем әнкәйгә әйткән: «Малаең иртәрәк аза башлаган түгелме, Хәкимәттәй?» — дигән. Ай-һай, шул чактагы хәлемне белсәгез иде, оятымнан пәрәме җир тишегенә керердәй булдым... Әмма шулай да яратуыңны аңлатыр өчен барыбер хат язу кирәк икән, акка кара белән язмыйча торып кызларны ышандыруы читен икән. Менә кече кодача миңа нинди сабак биреп куйды бит әле...

...Тагын аңарданниләрдер бик сорашасым килә, ләкин шул арада аш өеннән кемдер аны кычкырып дәште, һәм кече кодача, кәҗә бәтиедәй уйнаклап, йөгерә-йөгерә китеп тә барды.

Җиңгәчәй миңа ак сәдәпле кара сатин күлмәгемне каталап бирде. Мин, лапаска кереп, шул күлмәкне кидем, өстемдәге пинжәк белән чалбарымны сыпыргалап кына чистарткан булдым, аягымдагы ботинкаларны печән белән сөрткәләдем. Менә кала кунагы туйга әзер дә!

Бакчадагы әлеге кечкенә өстәлдә майлы коймак белән ашык-пошык кына чәй эчтек. Берәүнең дә озаклап утырырга вакыты юк, хәтта сөйләшү дә юк, санаулы гына сәгатьләр калды. Җомгадан соң хәзрәтләр килергә, туй килергә тиеш.

Ләкин миңа болай көязләнеп, туй көтеп, эшсез йөрү бик уңайсыз иде. Йомыш-фәлән кушучы да юк һәм, күрәм, минем монда хәзергә кирәгем дә юк. Әйләндем-тулгандым да, эш белән әвәрә килгән хуҗаларның күзләреннән бераз югалып торыйм дип, тагын болынга чыгып китәргә булдым. Китәр чакта гына түр өйнең ачык тәрәзәсеннән Сәлимә кодачаны күреп алдым. Ул тәрәзә төбенә куйган көзге алдында озын кара чәчләрен тарап утыра иде. Аның тирәсендә җиңгәчәй һәм тагын өч-дүрт кыз чуала. Үзара нидер сөйләшә-сөйләшә кызның әйберләрен — күлмәген, яулыгын, калфагын, тасмаларын, тагын әллә нәрсәләрен карыйлар, барлыйлар, куялар, кыскасы, кәләшне киендерергә әзерләнәләр. Бу кызларны «ястыкчы кызлар» дип йөртәләр икән. Алар, туйга әзерлек башланган көннән алып кызны кияү куенына керткәнчегә кадәр гел кыз янында булып, бөтен эштә аңа ярдәмләшеп, булышып торалар икән. Белеп кушканнар аларга «ястыкчы кызлар» дигән шундый кызыклы исемне!.. Мин кодачаның түбән иелгән йөзенә бераз гына карап тордым. Әйтергә кирәк, бу тип-тигез кояш карасы төшкән бик чиста, чибәр йөздә моңаю, уйлану яки хәсрәтләнү кебек һичнәрсә сизелми иде, бары үз эшенә бирелгән җитдилек һәм беркадәр тынычсызлану, пошыну гына чагыла иде сыман... Менә ул, минем онытылып карап торуымны сизеп алды булса кирәк, кисәк кенә башын күтәрде дә, нечкә

кашларын җыерып, бик сәерсенеп, гаҗәпләнеп калды. Мин, тотылган карактай, гаять уңайсызланып, кызарып киттем һәм тиз генә борылып, ак-караны күрмичә, китеп тә бардым. Шуннан соң инде мин аны бөтенләй диярлек күрмәдем дә.

Бүген төнлә болынга бик мул булып чык төшкән икән, әле дә кибеп беткәне юк. Үләннәр юеш, ямь-яшел, чәчәкләрдә энҗе бөртегедәй түгәрәк тамчылар җемелди, Түреш өстендә ефәктәй юка гына ак томан тибрәнә. Көн тымызык, эссе-бөркү. Бөтен әйләнәдә тын гына, әмма өзлексез бер хәрәкәт сизелә. Үлән сабакларында ниндидер бөҗәкләр әрле-бирле ашыгып йөриләр, кайбер чәчәкләргә күбәләкләр ябышып сеңгәннәр дә, аерылырга теләмичә, бары канатларын гына җилпеп куялар, ә кайбер зуррак чәчәкләр эченнән төклетуралар, тузанга баткан йонлач тәпиләрен көчкә сөйрәп, ава-түнә чыгалар. Ләкин шулай да бу тын хәрәкәттә, колак салыбрак тыңласаң, тонык кына гүләү, нечкә генә безелдәү өзлексез ишетелеп тора.

...Барам, туктыйм, колак салып торам. Тагын кузгалып китәм, тагын туктыйм. Үлән арасында мәш килгән хисапсыз кортларга, бөҗәкләргә озак кына карап торам. Аннары күтәрелеп, ерактагы күксел киңлекләргә бер гаҗәпләнеп карыйм, йа дөнья, нинди киң, нинди иркен син! Әмма шушы чиксез, нурлы иркенлектә, шушы иркә, назлы, йомшак табигать кочагында мин үземне нигәдер бик ялгыз тоям. Күңелемне ниндидер сәбәпсез сызлану, моңаю гел биләп тора кебек... Бөтен җанымда әллә нинди бер тирән кичереш бара... Нигә соң ул алай?!

Минем ундүрт яшьлек чагым. Мин күп уйланам, бик аз беләм. Тормыш нәрсә, бәхет нәрсә, мәхәббәт нәрсә ул?! Бигрәк тә мәхәббәт дигән серле ут, оят булса да әйтим, минем йөрәгемә үрмәли башлады. Тиздән шуның кабынып китәсен ничектер йөрәгемнең бөтен тамырлары белән тоеп торам, әмма мин әле аны һич аңлый алмыйм. Чынлап та, нәрсә соң ул рәхимсез һәм котылгысыз мәхәббәт?.. Кызны ярату, кызны теләү генә микәнни ул? Кыз үзе дә шулай егетне яратырга теләп тора микәнни?.. Бары шул гынамы ул мәхәббәт?.. Менә бал корты чәчәккә килеп кунды – чәчәк сыгылып төште. Бәлки, бу да мәхәббәт галәмәтедер. Бәлки, егет белән кыз да бер-берсен яратырга теләгәнгә күрә генә, бал корты белән чәчәк төсле, бергә кушыла торганнардыр. Ләкин мәхәббәтнең башымы бу, әллә ахырымы – һич аңлый алмыйм мин моны... Егет белән кыз үзләре моны аңлыйлар микән? Нинди максат хакына, нинди өмет, нинди хыяллар белән алар кушылалар икән?.. Менә мин дә, вакыты җиткәч, өйләндерегез дип әйтермен, әмма бу мине куркыта. Миңа мәхәббәт кирәк, мәхәббәт телим мин, мәхәббәт бирегез миңа!.. Ә нәрсә ул – мин аны белмим, белмим...

Әйе, бу минем ундүрт яшьлек чагым. Мин гел нидер көтеп яшим. Хыялым бары киләчәктә генә... Киләчәк мине дәшә, чакыра, әллә ниләр вәгъдә итә, ләкин мин беләм, бу әле якты, томанлы рәшә генә, аңа әле барып җитәсе бар... Нәрсә ачылыр ул томан артында – миңа

билгесез, мин күрмим әле аны. Менә шушы билгесезлек мине гел борчып, үртәп, җанымны ничектер ләззәтле сыкратып тора да шикелле... Күңелдә әледән-әле өмет белән өметсезлек чиратлашып туа, вакыт-вакыт үземне, кешеләрне, җирдәге бөтен җан иясен өзелеп кызгана башлыйм, берәүгә дә афәт килә күрмәсен иде, берәү дә бу якты дөньядан мәхрүм булмасын иде дип тели-ялвара башлыйм. Ләкин шуның артыннан ук миндә искиткеч бер көч, дәрт, өмет кабына ки, мин бөтен дөньяны ал да гөл итеп, бөтен кешеләрне тигез, шат, бәхетле итеп, үземне исә бәхетнең җиде кат күгендә итеп күрә башлыйм. Өмет, өмет, өмет!.. Мин аңа ышанам, мин аңа табынам, мин аның өчен диңгезләр кичәргә, таулар аша сикерергә әзер торам... Менә нинди тиле, хыялый «бала» чагым бу минем!

Мин кайтканда, бөтен әзерлек эше беткән иде булса кирәк. Иртәнге яктагы шикелле арлы-бирле чабып йөрүләр күренми диярлек. Хәрәкәт басылган, зур бер тантана алдыннан гына була торганча, нәрсәнедер шауламыйча, кабаланмыйча сабыр гына көтү сизелә. Ачык тәрәзәләрендә әкрен генә ак пәрдәләр җилфердәгән өйгә һәм бер чүп әсәре калдырмыйча себерелгән ишегалдына чын бәйрәм төсе кергән. Эшләп йөрүче хатын-кызлар да өсләрен алыштырып, киенеп-ясанып куярга өлгергәннәр. Ишегалдында яңа кешеләр – ир уртасы агайлар һәм көяз егетләр дә күренә: болар туй каршы алырга килгән якын кардәш-ыру булса кирәк.

Ак келәт алдында ястыкчы кызлар кайнаша. Кызны киендереп-бизәндереп ак келәткә күчергәннәр инде. Ә лапас астында иярле ат тора – никах укылгач та кемдер, шул атка атланып, егеткә хәбәр итәргә чабачак.

Егетнең авылы ерак түгел, моннан өч-дүрт чакрымда гына, Түреш аръягында. Туй җомгадан соң килергә тиеш. Мәчет тә шул ук авылда (Кечкенә Абзанның үз мәчете юк). Кода бабай белән Нигъмәтулла абзыкай аның атында җомгага киткәннәр инде. Димәк, күп көтәсе калмаган.

Таза гәүдәсенә озын кара казаки, зур башына бәләкәйрәк кәләпүш кигән Хөбәйбулла кода бер өйгә кереп, бер йортка чыгып, һаман нидер кайгыртып, тынычсызланып йөри.

– Әхтәм кода, – диде ул, миңа бер үткәндә, – син тагын китеп югалма инде. Шушында гына бул!

Әллә ничек кызык та, уңайсызрак та булып китте миңа: «кода» дип бик зурлап дәшә һәм бер үк вакытта балага әйткәндәй югалмаска да куша.

Озак та үтми, кода бабай белән Нигъмәтулла абзыкай сары атта җомгадан кайтып керделәр. Шунда ук өйдә, ишегалдында хәрәкәт көчәеп китте. Ак келәт алдындагы ястыкчы кызлар тыз-быз килә башладылар. Капка төбенә бала-чага җыелды... Ул да булмый, икенче атта чалма-чапан кигән хәзрәтләр дә килеп керделәр. Кучерда утырган кара сакаллы абзый атын

өйнең нәкъ баскычы төбенә китереп туктатты. Муллалар тарантастан ашыкмыйча гына төшеп, сәлам бирделәр:

– Әссәламегаләйкем!

Кода бабай, Хөбәйбулла кода, Нигъмәтулла абзыкай өчесе беравыздан бик тайяр рәвештә сәламнәрен алдылар:

– Вәгаләйкүм-әссәлам! Хуш килдегез, хәзрәтләр!

– Туйлар мөбарәк булсын!

– Амин, шулай булсын. Әйдәгез, рәхим итегез! Юл биреп, муллаларны өйгә уздырдылар. Алар кереп утырырга һәм дога кылырга да өлгермәгәннәрдер, каяндыр еpактан, ап-ак арыш кырлары түреннән «зиң-зиң» чыңлаган кыңгырау тавышлары ишетелде. Бу тавыш ерак һәм әкрен булса да, капка төбендә торучы бер егет яман кычкырып җибәрде:

– Туй килә-ә!

Әйе, туй килә, туй! Бар да капкага ташланды. Мин дә урамга йөгереп чыктым. Ләкин атлар күренмиләр иде әле, тик кыңгырау тавышлары гына отыры дәртләнебрәк, ашыгыбрак яңгырый-көчәя бара иде. Бөтен капкалардан йөгерешеп хатын-кызлар, бала-чагалар чыкты. Алар белән бергә, «кайда, кемнәр килә?» дигән төсле, ялт-йолт каранып, койрыкларын үрә бастырып этләр атылып чыктылар. Юл буенда йөргән тавыклар, алдан ук керер тишек эзләгәндәй, муеннарын суза-суза читән буйларына йөгерештеләр...

Ниһаять, авыл очындагы сай чокырдан бер пар ат атылып килеп чыкты, аның артыннан икенче пар ат, аңардан кала ялгыз ат җиккәннәре килеп чыга тордылар. Ничәү үзләре? Бишәү, юк алтау икән... Һай, киләләр, агай, һай, киләләр дә соң! Җирең генә чыдасын!

Капка төбендәге бала-чагалар, чебиләр шикелле, читкә сибелделәр. Ишегалдына беренче пар ат шаулап килеп керде. Кучердагы егет, ишегалдын уратып, атларын баскыч төбенә үк китереп туктатты. Тарантастан, хатыны белән, кара сакаллы, таза гына бер абзый – баш кода төште. Аларны кода бабай һәм башкалар: «Әйдүк, хуш килдегез, рәхим итегез!» – дип, зурлап каршы алдылар. Беренче атлар кузгалгач, икенче пар ат ишек төбенә килеп туктады. Бусыннан егетнең эти-әнисе – төп кода белән кодагый төштеләр. Төп кода – озын, җирән кеше – ир уртасы гына икән әле, күрәсең, беренче малаен гына өйләндерә торгандыр... Аларны аеруча зурлап каршы алдылар. Шулай итеп, атлар ишек төбенә килеп туктый тордылар, китә тордылар, ә төшкән кунакларны каршы алып, ирләрен түр якка, хатыннарын уртадагы салкын якка кертә тордылар.

Кунакларны каршы алып беткәч, хуҗалар да өйгә керделәр. Мине дә, билгеле, онытмыйча кунаклар янына чакырдылар. Без кергәндә зур сәкенең түренә, бөкләп салган

юрганнар өстенә хәзрәтләр һәм кодалар менеп утырганнар иде инде. Калган кунаклар да, дәрәҗәләренә карап, хәзрәтнең ике ягына тезелешеп утырдылар. Минем урыным сәке кырыендагы тәрәзә янына туры килде. Кода бабай да, урындык алып, хәзрәтләргә каршы утырды. Урын җитмәгән кайберәүләр (кызның яшьрәк туганнары) ишек төбенә чүгәләделәр.

Түрдә тыныч кына көтеп утырган чалма-чапанлы, ак сакаллы карт хәзрәт зәгыйфь кенә тавыш белән:

– Йә, утырышып беттегезме, җәмәгать? – дип сорады.

Кода бабай түбәнчелек белән генә:

– Ие, хәзрәт, барыбыз да әзер, – диде.

– Алайса башлыйбыз.

– Аллага тапшырдык, хәзрәт! – диде кода бабай.

– Изге сәгатьтә! – дип куйды төп кода.

Өйдә, өйдә генә түгел, тышта, хәтта урамда да тантаналы тирән бер тынлык урнашты. Иң мөһим, иң киеренке вакыт җитте – бөтен кеше җитди уйчан, аз гына моңсу бер кыяфәттә оеп калдылар. Хәзрәтнең никах укуы хатыннар ягына да ишетелсен дип, ак пәрдә корган өй ишеген чак кына ачып куйдылар. Ул якта да шылт иткән тавыш юк иде.

Шуннан соң хәзрәт аз гына тынып торды, бөгелә төште һәм күзләрен йомыбрак, зәгыйфь-моңсурак тавыш белән әгузе-бисмалласын әйтеп, ашыкмыйча гына никах укый башлады. Кешеләр уйлары белән каядыр бик еракка киткәндәй, алларына гына карап, һичбер селкенмичә тыңлап утыралар. Минем нигәдер кинәт кенә күңелем тулып китте, ирексездән күз төпләрем кымырҗый башлагандай булды... Кемдер бу минутта миңа бик кызганыч булып тоелды, ләкин кем – кызмы, әти-әниләреме – үзем дә белмим. Тәмам аптырадым инде бу калтыравык күңелнең һич юкка да нечкәреп китүенә...

Никах укылып бетте, хәзрәт һәм аның артыннан барлык кунаклар берьюлы кулларын күтәреп, озак кына дога кылдылар. Мин дә, кулларымны кушырып, нидер укырга тырышып карадым, ләкин ни сәбәптәндер бөтен белгән догаларымны онытып җибәргәнмен, бары өзек-өзек сүзләрне генә кабатлап, ахырдан «бәхет телим, бәхет телим» дип битемне сыйпап куйдым.

Дога кылып бетүгә, башта кода бабай торып хәзрәткә, икенче муллага һәм мәзингә кәгазь акчалар сузды. Тагын озын гына итеп дога кылдылар. Аннары Хөбәйбулла кода, аның артыннан Нигъмәтулла абзыкай торып садака бирделәр. Нәкъ шул чакта иярле атка атланган бер егет, тасыр-тасыр чабып, капкадан чыгып китте: кияүгә никах укылуын хәбәр итәргә.

Садака бирү, дога кылулар беткәч, кунаклар алдына ике-өч кулдан тәлинкә-кашыклар тарата башладылар. Кече яктан ике зур миски белән аш керттеләр. Нигъмәтулла абзыкайны оста

табынчы дип әйтә торганнар иде. Менә ул, егетләрнеке сыман сылу гәүдәсе белән табын каршына басып, бик әйбәтләп бисмилласын әйтеп, иң элек никах укыган хәзрәттән башлап, бөтен кунакларга да аш салып чыкты.

Аштан соң ике таба бәлеш, бәлештән соң зур табакларда өеп туралган ит чыгардылар. Кунаклар шуларның барысын да сүзсез генә, күңел биреп, бик тырышып һәм яратып ашадылар. Тик һәр аштан соң хәзрәтләр, өлкән кодалар ашны олылап, өйгә бәрәкәт-муллык теләп, мактау сүзләре әйткәләп куйдылар.

Бушаган табакларны кире чыгаргач, агач тустаганнар белән өрек суы бирделәр. Кунаклар салкын ширбәтне шул савытлардан гына кашыклары белән алгалап капкаларга тотындылар.

Менә бер заман урам буйлап бик кызу сиптереп килгән кыңгырау тавышы ишетелде. Кунаклар бу тавышка аз гына колак салгандай булдылар, ләкин беркем бер сүз әйтмәде. Әдәп һәм тынычлык саклап, алларына карап кына ашый-эчә бирделәр. Кем килә, ни өчен килә – гүя аларның моңарда эшләре юк. Ә бит кияү килә, кияү!.. Тик Хөбәйбулла кода гына ашыгып урыныннан торды да, сак кына басып, өйдән чыгып китте.

Ул да булмый, төпкә озын яллы кара ат, мичәүгә тимеркүк җиккән тарантас ишегалдына бик кызу гына килеп тә керде. Мин дә, бөтен әдәп-кагыйдәне онытып, тизрәк тәрәзәгә борылдым. Пар ат ак келәт алдына шып итеп туктады. Атларны бик көязләп җиккәннәр – ялларына ал, кызыл тасмалар үрелгән, калын кара дугада куш кыңгырау, тәңкәле йөгән, тәңкәле эшлия, эшлиянең каеш чуклары ике яктан асылынып тора... Тарантастан дүрт егет төштеләр. Егетләр барысы да карадан киенгәннәр, барысының да башларында кара кәләпүш, аякларында ялт иткән итекләр. Егетләрнең берсе култык астына, сары яулыкка төреп, бәләкәй генә гармун да кыстырган... Ләкин боларның кайсысы соң кияү тиешле? Әһә, әнә берсенең башында сай гына кырпу бүрек икән, кулында кечкенә саквояж... Шулдыр инде кияү дигәне, һичшиксез, шул!.. Калганнары – кияү егетләре.

Аларны келәт ишеге төбендә ястыкчы кызлар сырып алдылар. Аз гына ыгы-зыгы килгәннән соң, егетләр, кулга-кул тотынышып, киек казлардай тезелештеләр. Алдан – баш кияү егете, аңа тотынганы – кияү үзе, калганнары – кияү егетләре. Шулай тезелешкәч, алар келәт ишегенә килделәр. Келәт ишеген тотып торучы бер җитү кызмы яки яшь хатынмы, башын чөебрәк егетләргә нидер әйтте. Баш кияү егете аңа нәрсәдер дип җавап кайтарды. Тагын кара-каршы нидер әйтешеп алдылар. Әйләнәдә тыңлап торучы ястыкчы кызлар дәррәү генә көлештеләр. Шуннан соң теге кызмы яки хатынмы келәт ишеген ачып җибәрде һәм егетләр эчкәре уздылар.

Шушы минуттан минем дә бөтен күңелем-уем келәт эченә күчте. Бу вәкарьле, дәрәҗәле, йомык-салынкы картлар җыелган никах мәҗлесе минем күземә бөтенләй күренмәс булды. Бөтен хикмәт, бөтен кызык хәзер тегендә, ак келәт эчендә. Кияү егетләре, ястыкчы кызлар анда нишлиләр, нәрсә сөйлиләр, кияү үзен ничек тота, кыз ни хәлдә – шуларны минем үлеп күрәсем, ишетәсем килә. Ләкин мин менә шушы табында, шушы хәзрәтләр янында әдәпле, инсафлы, тыйнак бер шәкерт булып утырырга тиешмен. Кагыйдәсе шундый – кузгалырга ярамый... Ә олылар тыныч, олылар, берни булмагандай, гамьсез генә чәйләрен эчәләр, тик ара-тирә язмышлар, тәкъдирләр, гомерләр турында бик мәгънәле сүзләр әйткәләп куялар. Никадәр ерак та соң бу хыялый яшьлек белән акыллы картлык арасы, уйласаң!..

Ниһаять, мәҗлес бетте, хәзрәтләрне озаттылар, карт кодалар, хәл алыр өчен, утырган җирләрендә генә мендәргә таяндылар, ә кайбер яшьрәкләре тәмәке тартырга абзар артындагы бәрәңге бакчасына киттеләр. Мин дә, мәҗлес бетүгә, тизрәк ишегалдына чыктым. Кияүне китергән пар атны лапас астына тарттырып, тезгеннәрен чишеп кенә баганага бәйләп куйганнар. Ак келәтнең ишеге ябык, анда кияү үзенең егетләре белән генә чәй эчеп утыра. Келәт янына беркем бармый, хәтта ул якка карамаска да тырышалар. Бары кияү белән кызны карарга куелган бер елгыр яшь хатын гына озын чәч үргеченә таккан чулпыларын чыңлатып, тыз-быз кергәләп-чыккалап йөри. Минем белүемчә, кыз әле үзе дә бу минутта чыбылдык эчендә генә утырып тора, кияү егетләре ашап-эчеп киткәч кенә ул кияве янына чыгачак.

...Нишлим, кая барыйм икән дип аптырап торган чагымда, мине Нигъмәтулла абзыкай үз янына дәшеп алды. Ул тирләгән, күлмәк якасын чишеп җибәргән, кулындагы зур чиккән яулык белән һаман битен-муенын сөрткәли.

– Син беркая да китеп югалма, – диде ул миңа. – Хәзер кодалар белән кунакка китәбез.

– Нишлим мин анда? – дидем мин, тискәреләнеп.

– Менә тиле. Син дә кунак бит, кодалар белән йөрерсең.

– Кирәкми, йөрисем килми, – дидем мин, отыры үҗәтләнеп.

– Күп сүләнмә, – диде абзыкай кискен генә. – Монда калып нишлисең?.. Ярамый, килешми...

«...Ярамый, килешми» – бу сүзләр мине ничектер сискәндереп, айнытып җибәргәндәй итте. Ни өчен дип мин, абзыкайдан гына түгел, үз-үземнән сорарга да оялдым, тик бер нәрсәне бик яхшы аңлап алдым: юк, ярамый, ярамый бу тирәдә йөрергә!

Озак та үтми, кунак өйнең ишек төбенә кыңгыраулы атлар килеп туктады һәм кодалар чыгып шуларга утырыша башладылар. Нигъмәтулла абзыкайның да аты җигүле иде, без шуңа өчәүләшеп утырдык... Билгеле булганча, кыз ягының якын туганнары чиратлашып «туйны

күтәрешәләр». Никахтан соң менә шул туйны күтәрүчеләргә йөрү башлана. Без хәзер кода бабайның бертуган энесе Әхмәтсафа абзыйларга барабыз икән.

Барасы җир ерак булмаса да, кодаларны атта гына йөртәләр. Пар атлар, алар артыннан ялгыз атлар тезелешеп, артык кызуламыйча, урамны салмак кына бер әйләнеп, хуҗа йортына барып керәләр. Анда кунакларны бик зурлап каршы алгач, ирләрне бер табынга, хатыннарын икенче табынга кертеп утырталар.

Табыннарга аш-су килә, чирекләр белән бал килә, мәҗлес башлана. Бу инде эчке мәҗлесе, күңел ачу мәҗлесе. Монда аракы да була икән, ләкин аны ачыктан-ачык табынга куймыйлар. Яшьрәк кунакларны ымлап кына мич артына чакырып алалар да шунда гына кырлы стаканга салып бирәләр. Буеңа сеңдер, картларга сиздермә!

Мәҗлес башлангач та кияү егетләре үзләренең кара һәм тимеркүк җиккән пар атларында ишегалдына чаптырып килеп керделәр. Аларны да хуҗалар зурлап, шаулап каршы алдылар. Гадәт буенча, алар, кияүне кәләш янында калдырып чыккач, менә шулай кодаларга кушылып, мәҗлестән мәҗлескә йөриләр. Тик һәр көнне иртән иң элек кияү янына кереп, кодачаларның коймагын ашап, чәй эчеп чыгалар.

Кияү егетләре килгәч, мәҗлес бердән җанланып китте. Дәртле, шат күңелле егетләр сәкегә менеп, аяк бөкләп утыруны белмиләр дә. Хуҗаларга каршы торып җырлау, җор-шаян сүзләр әйтү, мәҗлесне көлдерү – менә аларның бөтен эшләре шул. Шуның өчен дә алар кияү егетләре!

Кыз ягының яшьрәк туганнары – Хөбәйбулла кода, Нигъмәтулла абзыкай, тагын бер кара мыегын тәкә мөгезедәй бөтереп куйган чандыр кеше – гел аяк өсте торып, кунакларны сыйлыйлар. Әле берсе, әле икенчесе бал тулы стаканны кодаларның әле берсенә, әле икенчесенә җырлап бирә. Җырны күбрәк Нигъмәтулла абзыкай белән әлеге тәкә мөгезедәй кара мыеклы кеше алмашлап җырлыйлар. Кайчагында исә икәүләп, билләреннән тотынышып һәм көй уңаена чайкала биреп, җырлап җибәрәләр. Кара мыеклының тавышы калынрак, Нигъмәтулла абзыкайныкы нечкәрәк, бергә кушылгач, гаҗәеп матур, ягымлы килеп чыга. Һәр җыр артыннан күңелләрне дәртләндереп җибәрердәй берәр кушымта әйтеп куялар:

Атлый-йөгерә килә күк юрга,
Безнең лә дуслык китсен күп елга.

Шулай үткәзеп җырлаганнан соң, кунаклар бер шаулашып алалар:

– Һай, ирләрнең асыллары!

– Рәхмәт, афәрин, мең яшәгез!

Кияү егетләренең берсе кыстырып йөрткән кечкенә гармун да тик тормый. Егет аны бер тезе өстенә генә куеп, җәя бөккәндәй ике якка да тигез генә тартып, уйнап җибәрә. «Баламишкин», «Эрбет», «Сәфәр» кебек кыска көйләрне гаҗәп шәп сиптерә, парин!.. Көй уңаена иңбашларын да дәртле генә сикертеп тора, җитмәсә. Аңа карап, кунакларның да йөзләре, аяк-куллары ничектер үзлегеннән хәрәкәткә килә башлый. Ә бию көен тартып җибәргәч, шунда ук берәр җиңел сөякле абзый бөеренә таянып, башын чөя биреп, уртага чыгып та баса һәм читеге белән идән тактасын «чаш-чош» ышкый-ышкый текә генә йөзеп тә китә. Аннары урта бер җирдә, иңбашларын уйнатып, вак-вак кына тыпырдап тора башлый. Кунакларның моңа бик тә кәефләре килә, барысы да шаулап көләргә, ә кайберләре исә әтәч кагынган шикелле терсәкләрен җилпеп: «Һайт сине, әйт шуны!» дия-дия такмакларга тотыналар.

Әнә шулай, әле озын көйгә сузып, әле гармун тартып, җырлап та биеп дәвам итә бу туй мәҗлесе... Миңа да бик күңелле иде, мин хәтта зурлар рәтенә кереп, үземнең малай гына булуымны да онытып җибәрдем.

Мәҗлес бетеп, кунаклар таралганда таң сызыла башлаган иде инде. Кодаларның күбесен туй күтәрүчеләр, бүлешеп, үзләренә алып киттеләр, ә төп кода белән башкода кыз йортына кайттылар. Анда аларны салкын итләр, әчегән бал белән чәй табыны көтә иде. Мин күргән-кичергәннәрдән бик арыганга күрә, чәйгә кереп тормыйча, мыштым гына лапас башына үрмәләдем. Лапаска үтешли, аш өенең ишеге төбендә басып торган кече кодачаны, тагын берничә кызны күрдем. Алар нәрсәдер көтәләр иде, ахрысы, миңа дәшмәделәр. Мин, нигә болар йокламыйлар икән дип, гаҗәпләнебрәк уздым.

Үткән төннән җыелмыйча калган хуш исле печәндәге урынга менеп ятуым булды – бөтен талчыккан тәнем рәхәткә чумгандай изрәп оеп та китте. Ләкин чү! Бу нинди тавышлар? Башымны кисәк кенә күтәреп, колак салып тора башладым: нечкә кыңгырау тавышына кушылып кызлар көлүе ишетелде, ул да булмый, сыздырып гармун уйнап җибәрде. Әнә нәрсә икән ул. Кияү егетләре, пар атларына ястыкчы кызларны утыртып, урам әйләнәләр... Әнә алар киттеләр, буш, тын авыл өстенә тәңкәләр чәчкәндәй, җыр, моң сибә-сибә киттеләр.

Мин изелгән мендәремә тизрәк капландым – йөрәгемне кинәт нидер бик авырттырып, телеп узды. Нигә мин алар белән бергә түгел, нигә мин алар кебек түгел?! Кызлар, кызлар, ни өчен минем берүземне генә калдырып киттегез? Малай гынамыни әле мин сезнең өчен?..

Сызланып, сискәнеп күпме йоклаганмындыр, белмим, менә бер заман кемнеңдер аягымнан кат-кат тартуын сизеп уянып киттем. Күземне ачсам, лапаска менә торган баскычта җиңгәчәйнең башы! Бите кып-кызыл, чәче юеш, маңгаенда, борынында сыпырып алырлык тир бөртекләре.

– Әхтәм, бар тизрәк мунча кереп чык, дәдәң киенә калды, – диде ул миңа.

– Әй лә, бармыйм, йоклыйм әле, – дидем мин.

– Юк, бармыйча ярамый, – диде җиңгәчәй, – сансызлык була ул... Туйда озак йоклап ятмыйлар, кайткач йокыңны туйдырырсың.

Берни эшләр хәл юк, тордым да, чалбар белән ботинкаларымны гына киеп, мунчага киттем. Туй уңае беләндер инде, сипләп яңартылган мунча курчак өе кебек иде. Кечкенә тәрәзәсенә ак пәрдә корылган. Чишенә торган мунча алды чип-чиста, агач чөйләргә кызыл башлы сөлгеләр эленгән, киң сәкегә зур ак җәймә ябылган... Шул сәкедә ычкырлы кызыл ыштаннан гына Нигъмәтулла абзыкай, тезләренә таянып, тәмәке тартып утыра. Какча тәне кара янган, беләк һәм күкрәк мускуллары таштай беленеп тора, сукса – җенеңне өзәр!

– Әйдә, шәкерт! – дип каршы алды ул мине. – Кияү мунчасында бер юынып чык.

Кияү мунчасы?! Их, ниләр генә күрсәтми бу туй миңа! Хәер, минем бу хакта ишеткәнем бар иде инде. Иртән иртүк, кеше-кара аякка басканчы, кияү белән кызны мунча кертеп чыгаралар. Гадәттә бу җаваплы эшне берәр уңган-җитез, тәҗрибәле хатын башкара. Ул мунчаны өлгертә, мунчаны карый, саклый, ә вакыты җиткәч, келәт ишеген әкрен генә шакып, яшьләрне мунчага дәшә. Моның өчен аңа, билгеле, кияүдән зур гына бүләк тә тия.

Яшьләрне шулай кеше күзеннән яшереп кенә кертеп чыгаргач, мунчаның парын-суын яңартып дигәндәй, башта кодаларны, аннары безнең ише кунакларны кертә башлыйлар. Мунча туйда иң зур сыйлардан санала.

Мин чишенеп эчкәре уздым. Мунча әле май кебек җылы иде, чиста иде, казанында һәм зур агач кисмәктә суы җитәрлек иде, хәтта мич авызында чуен белән селтесе дә тора иде. Идәндә ялт иткән зур таз белән җиз комган, тәрәзә төбендә исле сабын. Ләүкәдә яшь каеннан бәйләгән ике себерке ята, ахрысы, шулардан мунча эченә җиңел генә, тәмле генә бер хуш ис таралган...

Өстемә тагын берәрсе килеп кермәсен дип ашыкканга күрә мин, чабынып-нитеп тормыйча, кечерәк бер табакка кайнар суны таманлап кына салып алдым да, ләүкәгә менеп, каткан чәчемне юарга тотындым.

Мунчадан чыккач та мине ак келәткә, кияү янына чакырдылар. Башта җиңгәчәй килеп әйтте:

– Хәзер бар инде, кияү белән күрешеп чык, – диде.

Мин аптырабрак калдым, ничектер тез буыннарым да хәлсезләнебрәк киткәндәй булды. Кияү янына керү бик зур эш булып тоелды миңа... Шул ук вакытта бу бик кызыктыргыч та иде,

моңарчы минем хыялым гел шул кияү белән кыз тирәсендә әйләнде бит. Шулай да җиңгәчәйдән икеләнеп кенә сорадым:

– Ярар микән соң, җиңгәчәй, мин бит әле бик яшь, малай гына.

– Син инде егет исәбендә, үзең кунак кеше, – диде җиңгәчәй. – Керергә кирәк.

– Ә нишләрем соң мин анда?

– Кияү белән күрешерсең, никах белән котларсың... Син бит кала шәкерте.

Ул да булмый, безнең янга кече кодача очып килеп җитте. Мин аңа тагы да бер гаҗәпләнеп карадым: апасының кияүгә чыгуына бу кадәр дә исереп, шатланып йөрер икән сеңел дигәнең!.. Килеп җитүенә, мине тотарга теләгәндәй кулын сузып:

– Әйдәгез инде, әйдәгез җизни янына, сезне көтәләр,—диде ул, кабаланып.

Көтеп үк торалар микәнни дип, борчылып уйладым мин эчемнән генә һәм, каршы әйтер сүз тапмыйча, лапас түбәсеннән пинжәгемне алып, каккалап кидем дә кече кодача артыннан иярдем.

Көн яктысыннан келәт эченә килеп кергәч, башта бернәрсә шәйли алмыйча тордым. Ягымлы хатын-кыз тавышы: «Әйдәгез, рәхим итегез!» – диде һәм: «Менә монда утырыгыз», – дип, бер буш урындыкны күрсәтте. Мин утырдым. Шуннан соң гына тирә-юнемне ачыграк күрә башладым. Келәт эче иңеннән-иңенә зур, чуар чаршау белән бүленгән булып чыкты, ләкин хәзер аны, көн яктысы төшсен дип, ике якка тартып куйганнар. Сул яклап бүрәнә стена буена эре чәчәкле ситсы чыбылдык корылган. Чыбылдык эчендә караватъ... Менә шул чыбылдыклы карават янына гына кызыл чүпләм эскәтер япкан кечерәк өстәл куелган. Өстәлдә бармак төртер урын юк: тәлинкәләрдә өем-өем төрле камыр ашлары, эреле-ваклы савытларда бал, май, чәкчәк, конфетлар, чирек белән әчеткән бал, нәкъ уртада таба белән коймак... Өстәл әйләнәсендә дүрт егет утыралар. Ә өстенә күпертмә иңбашлы яшел сатин күлмәк, аягына сары читекләр кигән, күкрәкчәле ак алъяпкыч бәйләгән, ак батист яулыгын колаклары өстеннән генә кыстырып куйган, бер егерме биш-утызлар тирәсендәге чибәр хатын кунакларын аягүрә кыстап-кыстап сыйлый... Кияү белән кыз янына куелган хатын инде бу, – үзе бик алчак, җор булса кирәк, теле-телгә йокмый, гел нидер әйтеп, көлдереп кенә тора.

Минем күзем, билгеле, барысыннан элек чыбылдык авызында гына утырган егеткә төште. Шушы кияү үзе! Нәкъ үз өендә яңа гына урыннан торган хуҗа сыман утыра: кыек якалы сары сатин күлмәгенең изүен чишеп җибәргән, кара кәләпүшен арткарак этәргән, кулындагы кызыл башлы озын сөлге белән тирләгән, кызарган муенын-битен әледән-әле сөрткәләп ала... Мин аңа карадым да каттым, башымда әллә никадәр сораулар туды: кем ул, кемнең баласы, нинди кеше, яхшы егетме, белеме бармы, яратып өйләнгәнме, бәхетлеме?.. Заманның кемне үз,

кемне үги итүен бик нык сизә башлаган чагым, шуңа күрә кемнең кем булуы мине үтә кызыксындыра иде. Сүз дә юк, бу кияү – чын авыл егете. Байданмы, ярлыданмы – ул кадәресен ачык белмим, һәрхәлдә, кода бабайларның үзләре кебек таза тормышлы кешенең баласы булырга тиеш дип уйлыйм. Ул инде бик яшьтән түгел, ким дигәндә бер егерме бишләрдә булыр. Кызыл Армиядә хезмәт итеп кайткан дип ишетеп калган идем, димәк, күпме-азмы чарланган егет!

Ул түгәрәк йөзле, киң генә маңгайлы, кысыграк күзле, туры гына борынлы, борын төбендә бер чеметем генә мыегы да бар. Юк, болай сөйкемле генә, Сәлимә кодача яратырлык егет, минемчә... Бәхетлеме ул? Хәер, бу бик балаларча уйлау инде. Бәхетле булмыймы соң! Әнә киң битендә елмаю катып калган, хәтта ашаган чагында да язылмый ул. Кысык күзләре аз гына түгәрәкләнеп, ничектер хәрәкәтсез карыйлар. Ул күзләрдә ниндидер хәйран калу, ис китү, хәтта бераз миңгерәүләнеп калу да сизелә кебек... Өстеңә шундый бәхет аугач ни, миңгерәүләнерсең дә шул!

Мин утыргач, күпмедер ара авыр гына тынлык булып алды. Ахырда кияү телгә килеп, теге хатыннан йомшак кына сорады:

– Бу егетне кем дип беләбез инде?

Хатын, шуны гына көткәндәй, гаҗәп бер өлгерлек белән:

– Бу инде, кияү, Нигъмәтулла баҗаңның агасы Әхмәтҗан коданың улы Әхтәм була, – диде. – Безгә кече кода, кала шәкерте, зур кунак!

– Ә-ә! – дип кенә сузды кияү моңа каршы. Мин уянып киткәндәй булдым. Бурлаттай кызардым. Әлеге шул «кала кунагы», «кала шәкерте» дигән сүзләре белән тәмам җелегемә үттеләр инде. Өфедән түгел мин, Бәләбәйдән дә түгел, ә Дәүләкән дигән зур бер авылдан гына... Дөрес, Дәүләкән ул волость үзәге, аның бик шәп базары була, ярминкәсе була, анда зур-зур таш тегермәннәр бар, станция белән элеватор да бар, ләкин шулай да аның беркайчан да кала булганы юк әле. Мин үзем дә шәкерт түгел, укучы (урта мәктәпнең 7 нче сыйныф укучысы) — «шәкерт» сүзе бездә күптән төшеп калды инде, аны хәзер кода бабай шикелле картлар гына әйтәләр. Ә монда шуны белепме, әллә белмичәме, тоталар да йә «шәкерт», йә «кала кунагы» диләр. Үзләренчә миңа куштанланып, зурлап дәшүләреме соң бу?! Әллә шулай исемләгәч, үзләренә күңелле буламы? – Янәсе безнең туйда, малай гына булса да, кала кунагы да бар бит әле!..

Шул арада уңган хатын мине бик юмартланып кыстарга тотынды:

– Ягез әле, кече кода, балдан, майдан, коймактан рәхим итегез. Ягез, йә, тартынып тормагыз, кияү ашларын авыз итегез!

Шулай диде дә алдыма, стакан тутырып, әче бал да куйды.

Кылт итеп исемә төште: котларга кирәк ләбаса! Моңарчы кияүгә шаккатып утыру аркасында мин аны онытып та җибәргәнмен. Нишләргә хәзер! Әлбәттә, «кала шәкерте» була торып, миңа мокытлык, җебегәнлек күрсәтергә һич ярамый иде. Ахырда, үземне беркадәр кулга алып, бал тулы стаканны күтәрә төшеп:

– Сезне ни... никах белән котлыйм, ие, – дидем мин, тотлыгып кына.

Барысы да шуны көтеп кенә утыргандай беравыздан:

– Ә, рәхмәт, рәхмәт, кода, рәхмәт, шәкерт, – диештеләр. Кияү егетләре, тышаулары бушагандай, шактый җанланып та киттеләр. Алар барысы да тазалар һәм көязләр иде. Кәләш куенында яткан иптәшләренә җылы дуслык, куштанлык күрсәтеп, шул ук вакытта аңа ничектер яшерен бер кызыксыну-көнләшү белән дә карап, ләкин моны берәүгә дә сиздермәскә тырышып, күбрәк табынчы яшь хатынга уен-көлке әйткәләп кенә утыралар.

Хәер, минем уем аларда түгел, башкада иде: ни өчен табында яшь кәләш үзе юк – шуңа бик гаҗәпләнеп утырам. Хикмәт нәрсәдә икән? Әллә аңа, гомумән, кияү егетләре янына чыгып утырырга ярамыймы икән? Алай дисәң, кияү кырында гына эчелеп бетмәгән чынаяк тора, өлеш тәлинкәсендә ашала башлаган сыныклар ята. Болар анык булырга тиештер бит, югыйсә кияү белән янәшә кем утырсын?! Димәк, Сәлимә кодача мин керә башлагач кына торып, чыбылдык эченә качкан. Ни өчен бу? Ни өчен ул ундүрт яшьлек малайдан кача. «Кала кунагын» санламыймы, өнәмиме, аңа юри күренәсе килмиме? Юк, мондый хәлнең булуы мөмкин түгел, бу мине соң дәрәҗәдә кимсетү булыр иде. Ышанмыйм, юк, ышана алмыйм. Әмма нәкъ менә шушы минутта мин кинәт бик ачык итеп, эчке бер калтырану белән эшнең серен аңлап алгандай булдым: Сәлимә кодача миннән ояла! Миннән, ундүрт яшьлек малайдан, оялып кача! Йа Тәңре, ул минем хәлемне аңлаган, ул минем артык сизгер, артык тиз җәрәхәтләнүчән йөрәгемне аяган!..

Әмма соң ул, кодача, минем күз алдымнан качса да, хыялымнан кача аламыни?! Менә ул нәкъ каршымда, чыбылдык эчендә генә утыра. Мин хәтта аның чыбылдыкны аз гына төртеп торган тез башларын да шәйлим шикелле... Тез башларын гына түгел, бөтен кыяфәтен – сөрмәле күзләрен дә, хуш исле чәчләрен дә, уйчанлана төшкән, әмма бәхетле көлемсерәгән йөзен дә, ничектер үсебрәк киткән нечкә-сылу гәүдәсен дә ап-ачык күреп торам кебек... Юк, ул минем хыялымнан барыбер качып котыла алмый, котылу мөмкин түгел!

Ишегалдында кыңгырау тавышлары ишетелде, кодаларны тагын берәрсенә мәҗлескә алып китә торганнардыр. Тышта хәрәкәт көчәйде, кешеләрнең йөргән, сөйләшкән тавышлары ишетелә башлады. Кияү егетләре дә, сыйлаучы хатынга рәхмәтләр әйтеп, кияүгә, дусларча

шаярту белән, кәләше янында күңелле вакыт үткәрүен теләп, урыннарыннан кузгалдылар. Алар да хәзер кодалар белән бергә мәҗлескә китәргә тиешләр.

Келәттән чыккач, егетләрнең берсе, үз иткәндәй, минем җилкәмә кулын салып, сорады:

– Йә, Әхтәм, безнең белән йөрисеңме? Бу дуслык ишарәсе миңа бик ошады, ләкин шулай да:

– Белмим шул, – дидем мин, икеләнебрәк. – Алай ярыймы соң?

– Һи, ник ярамасын, – диде егет, бер дә исе китмичә. – Син дә кунак вет, бергә-бергә йөрү күңеллерәк булыр.

Белмим, бәлки, бу кагыйдәгә сыеп та бетмәгәндер (мин бит кыз ягыннан туйга катнашучы), ләкин Нигъмәтулла абзыкай да, җиңгәчәй дә миңа ярамый дип әйтмәделәр. Шулай итеп мин кияү егетләре белән бергә, аларның пар атларына утырып, мәҗлесләргә йөри башладым. Атлар шәп, егетләр шәп, билләреннән алышып, аягүрә генә баралар, юлда берәр җәяүле күренсә, «һайт!» дип бер кычкырып кына салалар. Мине алар, бу шәкерт очып төшә күрмәсен дигәндәй, урталарына алып кына йөртәләр иде.

Мин инде ничә җирдә мәҗлестә булуыбызны сөйләп тормыйм, бик озынга китәчәк. Әмма берсен, гомерлеккә күңелдә уелып калганын тулырак итеп сөйләмичә булдыра алмыйм.

Туйның өченче көнендә иң соңгы мәҗлес тагын кыз өендә булды. Шушы мәҗлес белән кыз ягында туй төгәлләнә, кодалар да, кияү белән кыз да, кызны озата баручы җиңгәләр дә моннан китәләр, туй кияү ягына күчә... Соңгы озату мәҗлесе булганга күрә, бирегә кызның бөтен агай-энесе һәм тирә-як күрше-күлән дә җыелган иде. Өйгә генә сыйдырып бетерерлек булмагач, үз-тирә гадирәк кунаклар өчен бакчага да бер табын әзерләнгән иде.

Өйдәге түр табынга, билгеле, кодаларны, кияү егетләрен, кызның өлкән туганнарын һәм кайбер мөхтәрәм кунакларны утырттылар. Шул «мөхтәрәмнәр» арасына, гөнаһ шомлыгына каршы, мин дә эләктем. Бакчада гына торып калмакчы булган идем дә, Хөбәйбулла кода үзе чыгып мине чакырып кертте, янәсе, минем урыным монда түгел, тегендә... Һай, эләкмәгән генә булсам иде!.. Башта ук бу мәҗлес минем өчен зур газапка әверелде. Бөтенләй хур була, оятка кала яздым. Кыска гына арада ниләр уйлап, ниләр кичерергә туры килмәде миңа...

Эш менә нәрсәдән башланды. Табынга кунаклар утырышып беткәч тә, ике кеше зур тәпән белән койган бал күтәреп керттеләр. Тәпәнне сәкедән читкәрәк, бер урындык өстенә куйдылар. Нигъмәтулла абзыкай, һәрвакыттагыча беренче табынчы, кәләпүшен егетләрчә кырын салып тәпән янына басты. Аңа кечерәк өлеш тәлинкәсенә куеп, бер стакан бирделәр. Нигъмәтулла абзыкай тәпәннең өстен ачты, чүмеч белән бер шөбердәтеп коеп карады, аннары кунакларга карап әйтте:

– Хөрмәтле кодалар, туебызның иң зур сые – кыз балы табынга килде. Сезнең рөхсәт белән шуны рәхим итеп башлыйк.

Шулай диде дә балны, чүмеч белән стаканга салып, иң элек кияүнең атасы төп кодага сузды. Төп кода: «Рәхмәт, котлы булсын киленебезнең балы» дип, иплап кенә стаканны алды да бетергәнче эчеп куйды һәм тәлинкәсенә өч сумлык акча салып, стаканны кире кайтарды. Аңардан соң табынчы стаканны тутырып башкодага сузды. Башкода да, рәхмәт әйтеп, балны бетергәнче эчте дә күпмедер акча салып, стаканны тәлинкәсе белән кире бирде. Шуннан соң инде Нигъмәтулла абзыкай стаканны рәттән йөртә башлады. Табынның түр очында утырган беренче кунакка, аннан икенчесенә, өченчесенә – шулай күчә-күчә китте кыз балы. Һәм эчкән бер кунак тәлинкәгә акча салып кире кайтара торды... Менә шушы хәлне күргәч, мин тәмам коелдым да төштем. Стакан миңа да килеп җитәчәк бит, мин дә акча салып кайтарырга тиешмендер инде. Йоласы шулай икән аның, ә йоладан котылу юк. Нишләргә? Минем кесәмдә бер генә тиен дә акчам юк лабаса! (Мин бит туйга эләгәсемне белеп өйдән чыкмадым.) Менә кайда ул хурлык! Әгәр минем кем булуымны, кайдан килүемне белмәсәләр иде —беләләр шул, барысы да бик яхшы беләләр. Белү генә түгел, «кала кунагы» кыз балына күпме төшерер икән дип көтеп утыра торганнардыр әле... Мин хәтта уттай яна башладым. Уйларым, читлеккә эләккән кош кебек, бәргәләнергә тотынды: нишләргә, нишләргә? Әллә мыштым гына чыгып сызаргамы!.. Юк, мөмкин түгел, барысы да күрәчәкләр, беләчәкләр, эчләреннән генә көләчәкләр. Ә стакан якынлаша, отыры якынлаша...

Миңа җитәргә ике-өч кенә кеше калды. Булмый, булмый күрәсең инде бу хурлыктан котылып... Соңгы өмет белән Нигъмәтулла абзыкайга карыйм, аңа ничек тә миңа бирмә дип ымлыйсым килә, ләкин ул минем якка сыңар күзен дә төшерми, ичмасам! Балны бутап-бутап стаканга сала, мактап-мактап кодаларга суза, әйтерсең изге бер эш башкара. Шулай да ахыр чиктә генә миңа бер күз ташлап алды шикелле, ләкин мин аның карашын тотарга да, аңлашырга да өлгермәдем, билгеле.

Ниһаять, минем чират та килеп җитте. Нигъмәтулла абзыкай, бөтен табын ишетсен дигәндәй, кычкыра биреп, бал тулы стаканны миңа сузды.

– Йә, шәкерт, иплап кенә тот әле кодача тәтәңнең ширбәтен!

Стаканны ничек кулга алуымны, иреннәремә ничек китерүемне белмим, барысы да йокыдагы кебек эшләнде шикелле, тик бер нәрсәне бөтен тирем белән сизеп торам – кунакларның күзе миндә генә... Маңгаема салкын тир бәреп чыкты, ә үземә бик эссе кебек... Күпмедер эчкәч, берни күрмичә, калтыранган стаканны кире сузуым булды, нәкъ шул мизгелдә Нигъмәтулла абзыкайның бик ачык итеп әйткән сүзләре ишетелде:

– Шәкерт акчасын миңа биреп куйган иде, – диде ул, тыныч кына, һәм түш кесәсеннән бер сумлык кәгазьне чыгарып, кунакларга күрсәтә биреп, тәлинкәгә дә салды.

Бу шулкадәр вакытлы һәм табигый килеп чыкты ки, кодалар төрле яктан:

– Һай, афәрин!

– Муладчина! – дип куйдылар.

Ә миңа... миңа ни, яшем тәгәрәп төшмәсен өчен бары иренемне тешләп, башымны гына түбән ияргә калды. Юк, оялудан түгел бу, җиңеләеп китүдән, сөенечтән, рәхмәттән генә... Нигъмәтулла абзыкайга рәхмәттән. Мин дә адәм баласы, сизгерлеккә бик мохтаҗ адәм баласы!

Ә мәҗлес кызганнан-кыза бара. Кыз балын акча салып авыз итү бетте, хәзер инде табында берничә стакан йөри. Нигъмәтулла абзыкай тирләгән-кызарган, чиккән зур яулыгы белән һаман сөртенеп тора, үзе бертуктаусыз сөйләнә, көлә, кайчак нечкә сары мыегының очын хәйләкәр генә бөтереп тә куя. Аңардан җыр көтәләр,—ул моны белә, тик җаен гына көтә... һәм, менә, турая биреп, тамак кыргалап алды да, пинжәк чабуын кайтара төшеп, әз генә калтыравык нечкә тавышы белән сузып җырлап та җибәрде:

Утырдым ла көймәнең, ай, түренә,

Карадым ла суларның төбенә.

Су төпкәйләрендә һич кара юк,

Хак язганны күрми чара юк.

Мәҗлес шундук тынып калды. Җыр һәркемнең йөрәген учлап алды. Кеше, мәрткә киткәндәй, сагышка, хыялга чумды. Кемгәдер яшьлеге кайтты, кемнеңдер заяга узган гомере күз алдыннан кичте, кемнеңдер күптән онытылган ярасы ачылды, әмма барысын да нindидер бер искиткеч ләззәт-шашыну биләп алды.

Җыр бетүгә табын, аз гына өнсез торганнан соң, дәррәү хәрәкәткә килде. Әллә шатлыктан, әллә исәрләнүдән тыела алмыйча яман шауларга, көләргә тотындылар, кемдер сүз таба алмыйча: «Эх-х, Нигъмәтулла-а!» – дип өзгәләнеп кычкырып куйды... Кемдер шунда ук яңадан җыр башлады – уздырырга теләп, тагы да ныграк исертергә теләп, дәртләнеп, кабынып җырлый башлады. Кайсылары җырга кушылды, кайсылары үз стаканын хөрмәт иткән кунагына сузып: «Кодакаем!», «Абзыкаем!» – дия-дия, аны үтереп кыстарга тотынды. Кемдер миңа да стаканын төртте, атамны мактарга, анамны мактарга тотынды... Балдан, җырдан, шау-шудан минем башым әйләнде, һавага чыгасым килде, һәм, ыгы-зыгыдан файдаланып, урынымнан мыштым гына кузгалдым.

Чыксам, ишегалдында да кунаклар, тыз-быз йөргән хатын-кызлар. Ак келәтнең дә ишеге ачык. Ул тирәдә дә нindидер хәрәкәт сизелә... Мин тукталып тормыйча абзарларга таба уздым

да арт капкадан гына болынга чыгып киттем. Яраттым мин бу Түреш буен. Тынлыгына, иркенлегенә, чәчәкләренә, бөҗәкләренә ияләшеп өлгердем. Монда ялгыз йөрү рәхәт, барысы да – якты-йомшак тынлык та, иркә-оялчан чәчәкләр дә сине әкрен генә, сөеп кенә юата кебек, уйларың-хәсрәтләрең үзлегеннән тына-басыла, ә ялгызлыгың үзе бер рәхәт, тансык юанычка әйләнә... Әйләнә дигәннән, минем башым чынлап та әйләнә шикелле... Әллә башым түгел, күз алдымда дөнья әзрәк әйләнәме?.. Алай дисәң, әнә-ә тегендә, кечкенә елгачык буендагы карт тирәкләр тик кенә, тын гына утыралар төсле. Алардан да ары, тау итәгендә кечкенә авыл да үз урынында бик нык утыра кебек... Ләкин шулай да, күз алдында бернәрсә селкенмәсә дә, бу чиксез дөнья үзенең кырлары-болыннары, таулары-сулары, авыллары-шәһәрләре белән йә уңга, йә сулга әкрен генә чайкаладыр төсле. Тик кенә тору мөмкин түгелдер инде ул. Һәм күңелгә гаҗәеп сәер бер уй килде: әгәр дә мәгәр, мин әйтәм, дөнья болай чак-чак кына түгел, ә кинәт бик нык йә уңга, йә сулга чайкалып китсә, ни булыр иде икән? Җирдәге бөтен нәрсәнең асты өскә килер иде бугай... Алла сакласын! Юк, мин моны теләп, юрап әйтмим, тик уйнап кына, малай башым белән хыялланып кына әйтәм. Ә бәлки нидер сизенептәдер...

Бу туй арасында вакыт дигән нәрсә бөтенләй онытылып, буталып бетте. Бүген нинди көн, кайсы число – һич хәтерли алмыйм. Июль башы – шуны гына беләм. Кояшның зураеп, бик әкрен генә бата торган чагы. Әнә ул җир өстенә сузылып яткандай иренеп кенә сырт читенә төшеп бара...

...Шактый киткәнмен икән, кире борылдым. Ниндидер кызыкны күрми калырмын төсле, ашыгыбрак атларга тотындым. Шул ук арт капкадан гына ишегалдына кайтып кердем. Өй тирәсе гү-ү итеп тора, ишегалдында да, урамда да җигүле атлар тора, ә ак келәтнең ачык ишегеннән егетләр һәм кызларның җырлаганы ишетелә. Ахрысы нәрсәгәдер әзерләнәләр, нәрсәдер булырга тиеш.

Лапас яныннан узганда, күземә ике кеше чагылды. Бәлки игътибар итмичә узып та киткән булыр идем, ләкин караңгылана төшкән лапас эчендә берәүнең багана төбенә сәер генә чүгәләп утыруы мине туктата калды. Кем ул, нишләп утыра?.. Мышык-мышык борын тарткан тавыш та ишетелеп куя. Әллә елый инде шунда?.. Якынрак атлап, чынлабрак карасам, багана төбенә чүгәләп, башын учлап утырганы Хөбәйбулла кода булып чыкты, ә аның янында тик кенә басып торган кара кәзәкиле, озын кеше кемдер – анысын танымадым. Хөбәйбулла коданың иңбашлары селкенеп-селкенеп куя, мыгыр-мыгыр нидер сөйләнә, үгезнекедәй калын тавышы сынып-сынып китә:

– Ух, Шәмсетдин абзый-й, белмисең, китә, йөрәк парәм китә! Тагын бер күгәрченебезне оч-очырабыз-з... Бишенчесен озатам бит, Шәмсетдин абзый, бишенчесен. Ят кулларга китеп бетәләр шулай, ох-ый!

Дәү, таза кешенең әллә кайдан гына сыгылып чыккан саран күз яшьләре!.. Мин ник күргәнемә үкенгәндәй, йөгерә-атлый китеп бардым. Каршыма җиңгәчәй очрады. Туктатып сорадым:

– Җиңгәчәй, нәрсә бар монда?

– Тиздән туй китә, – диде җиңгәчәй.

– Сез дә китәсезме?

– Без дә җиңгәли озата барабыз... Син инде монда калырсың, акыллым, яме! – дип өстәде җиңгәчәй, йомшак кына.

– Ярый, – дидем мин, тиз генә килешеп. Кияү ягы өчен мин ерак кеше – мин моны аңлый идем. Тик туй киткәннән соң бушап, боегып калган йортта ялгыз каңгырап йөрүнең миңа никадәр авыр буласын гына уйлый белмәгәнмен.

Җиңгәчәй ашыгып келәткә таба китеп барды, ә мин, рәшәткә буенарак узып, тынычрак урыннан ишегалдында барган тамашага карап тора башладым.

Бу вакытта кияү егетләре келәттә җырлый-җырлый чаршау-чыбылдыкны чишәләр, ә озата баручы җиңгәләр кызның урын-җирен җыялар иде. Кияү йортына баргач, шул ук кияү егетләре чаршау-чыбылдыкны яңадан корып, җиңгәләр кыз урынын җәеп куячаклар икән, йоласы шундый, имеш.

Менә келәт ишеге төбенә кабык арба җиккән ат килеп туктады. Шул арбага кыз артыннан барасы әйберләрне чыгарып сала башладылар. Ике егет өр-яңа яшел сандыкны ике башыннан күтәреп чыгардылар. Алар артыннан кызлар зур-зур төеннәрне чыгарып салдылар. Төеннәр өстенә зур гына җиз тазны каплап куйдылар. Җиз комган белән ак самоварны да төеннәр арасына ипләп кенә утырттылар... Барысын да шулай чыгарып, өеп бетергәч, йөкне озын бау белән аркылыга-буйга нығытып бәйләделәр. Шуннан соң бу арбада барасы егет атын бер читкәрәк тарттырып куйды.

Биредә бөтен эштә билгеле бер тәртип булса кирәк. Мин, әйберләр чыгып беткәч, алар артыннан ук кияү белән кыз да чыгар дип көткән идем, ләкин алай булмады. Хәзер өй баскычы төбенә кыңгыраулы пар атларны берәмләп китерә башладылар. Халык та шунда җыелды. Беренче атка шактый мәлҗегән баш коданы ике ягыннан култыклап чыгардылар да, зурлап, юатып, тарантаска ипләп кенә утырттылар. Чирек күтәреп чыккан берәү шунда ук аңа стаканга салып бал сузды... Башкоданың аты кузгалгач та аның урынына икенче пар ат килеп туктады.

Монысына төп кода белән кодагый менеп утырдылар. Төп кодага да бал салып бирделәр. Шулай итеп баскыч төбенә атлар бер-бер артлы килә тордылар, калган кодалар да утырышып, ишегалдыннан урамга чыга тордылар. Кодалардан соң кызны җиңгәли озата баручылар атларына утырдылар. Туй килгәндә алты ат булса, хәзер урамда унике җигүле ат тезелешеп торалар иде.

Бары менә шуннан соң гына келәт алдына кияүнең кара һәм тимеркүк җиккән пар атын китерделәр. Шунда ук келәт алдын ястыкчы кызлар һәм егетләр сырып алдылар. Мин дә, күрми калмыйм дип, рәшәткә буенда яткан ташка бастым. Менә берзаман Хөбәйбулла кода сеңелесен (бишенче күгәрченен) таза беләкләрендә келәттән күтәреп чыгарды да тарантаска, күпертеп салган мендәрләр өстенә ипләп кенә утыртты. Кызның өстендә ак чүченчәдән җәйге җилән, башында ак ефәк шәл иде. Шул шәле белән ул, күзләрен генә калдырып, битен каплаган – мин ни теләп тә аның йөзен тагын күрә алмадым... Кыз янына кара җиләннән, кырпу бүректән кияү эре генә менеп утырды. Кияү егетләренең берсе дилбегә тотып, икенчесе, гармунын тезенә куеп, кияү белән кызга каршы кучерга урнашты, ә өченчесе тарантас артына басты. Егет, кулларын сузып, дилбегәсен какты, атлар кузгалдылар, озатучы кызлар, егетләр, бала-чагалар, тарантаска орына-сугыла, шау-гөр килеп, барысы да капкага юнәлделәр. Мин дә, агымга эләккән йомычка шикелле, кысыла-кысыла халыкка иярдем.

Кияү атлары урамга чыккач, туй кузгалды. Иң алдан башкоданың пар аты, аның артыннан төп коданыкы, аннары кияү атлары, алар артыннан калганнары тезелешеп киттеләр. Иң арттан гына кыз әйберләрен төягән ялгыз ат, төеннәр өстенә каплап салган җиз тазы белән ялтырап, чаба-чаба китеп барды. Дәррәү кузгалып киткән атларның кыңгырау тавышлары кечкенә авылны тәмам күмеп, бөтен Түреш буйларын яңгыратып җибәрде. Әйе, бу искиткеч бер тамаша иде. Капка төбендә өелешеп калган егетләр һәм кызлар ераклаша барган кыңгырау тавышларын сихерләнеп, онытылып, шылт та итмичә тыңлап тордылар. Туй китте. Туй белән бергә кемнеңдер яшьлеге китте... Тагын кемнәргә насыйп булыр икән бу кыңгырау тавышлары?!

Минем китаплар шүрлегендә тавыш-өнсез генә җиз кыңгырау тора. Ул шул Абзан туена, Нигъмәтулла абзыкайның сары ат башында, кара дугага тагылып барган кыңгырау икән, аны миңа күп еллардан соң Мәдинә җиңгәчәй биргән иде. Ул туйга катнашкан кешеләрнең бик күбесе – кода бабайлар, Хөбәйбулла кода, Нигъмәтулла абзыкай – күптән бу дөньяда юк инде. Җиңгәчәй исән әле, сиксәнгә якынлашып бара, зур калада профессор киявендә тора. Аннары тагын Сәлимә кодача белән аның кияве дә исән-саулар икән – мин моны былтыр гына ишетеп белдем... Еш кына алар турында ничек яшәделәр икән, бәхетле булдылармы икән, дөньяда бармы икән үзләре дип уйлана торган идем. Гаҗәеп бер нәрсә, күпме еллар минем хыялымда

алар, нәкъ әнә шул туйда күргәнемчә, яшь чибәр кыз белән яшь таза егет булып саклandылар. Ә бит кырык елдан артык вакыт узып китте – әйтергә генә ансат!.. Баксаң, алар үз авылларында тигез генә гомер итеп, уллар-кызлар үстереп, әби белән бабай да булганнар икән инде... Куандым да мин моңа, әллә нигә моңайдым да... Озын кара толымлы сылу кодача тик хыялда гына торып калды.

Әйе, дөньяда бөтен нәрсә искерә, туза, үзгәрә, тик менә җиз кыңгырау, ни хикмәттер, һич кенә дә бер үзгәрми. Чак кына кагылдың исә, нәкъ теге вакыттагы шикелле, көмештәй саф, нечкә дәртле тавышы белән бүлмәне яңгыратып җибәрә һәм күз ачып йомганчы мине ундүрт яшьлек чагыма – үземә урын таба алмыйча гел борчылып йөргән, нидер сизенеп көткән иртә яшьлегемә кайтара да куя. Барысын-барысын да үтә бер ачыклык белән терелтә ул минем хыялымда... Яңгырап җибәрүенә, Нигъмәтулла абзыкайның җырын ишеткәндәй булам: утырдым ла көймәнең, ай, түренә... Юк, кирәкми, искә төшермик. Иясенә калсын ул...

Хәзер инде бик күп яңа җырлар туды. Яңа гадәтләр, яңа йолалар туды. Туйларга да хәзер кыңгыраулы пар атларда түгел, ә күбрәк «Волга», «Москвич»ларга гына утырып баралар. Егет белән кызны да өч көн буена ак келәттә ябып тотмыйлар, ә туйның түренә мендереп утырталар... Әмма мәңге үзгәрми торган бер нәрсә калды: бу —кешенең яшьлеге, мәхәббәте!.. Һәркемгә килә ул, һәркем кичерә аны... Менә ни өчен җиз кыңгырау бик кадерле миңа – аның дәртле, көмеш тавышында гүя яшьлек һәм мәхәббәт саклана.

*1966*

## Бабайлар

Җәйнең яңа кояш күтәрелеп килгән бик матур бер иртәсендә мин, ашыгып, колхоз идарәсенә киттем. Беләсезме, авыл иртәсенең шундый бер чагы була: хатын-кызлар таңнан торып, сыерларын савып, көтү кугач, кырга чыгучылар төялешеп китеп беткәч, өйдә калган карт-корылар, җиңгәйләр тагын аз гына черем итеп алыр өчен ястыкларына таянгач, авыл бер мәлгә бушап, тынып тора. Капкалар ябык, тәрәзә пәрдәләре төшерелгән, ишекләр шыгырдамый, беркем кереп-чыгып йөрми, хәтта этләр дә, бер торып буталып йөргәннән соң, яңадан баскыч төпләренә бөкләнеп ятканнар, тик ялгыз кояш күтәрелеп килә, җирдән дымсу тузан исе килә, үләннәрдә кибеп өлгермәгән эре чык тамчылары җемелди – җиңел, рәхәт шул чакта буш урам буйлап атлавы...

Мин колхоз идарәсенең иске, зур агач өенә (бу берәр байдан калган өй булырга тиеш) килеп кергәндә, анда беркем дә юк иде. Ләкин өйнең идәне су бөркеп, әрем себеркесе белән бик әйбәтләп себерелгән иде инде. Бу аз гына дым һәм тузан белән аралаш әрем исе керүемә

борыныма килеп бәрелде. Гаҗәеп тәмле, хуш ис иде ул... Мин аны кат-кат борын тутырып иснәдем. Идәнгә карагач, себеркедән төшкәләгән әрем бөртекләрен дә күрдем. Безнең шәһәр җирендә табып кара мондый эссе ялан исен!.. Шул чакта йорт ягына чыга торган ишектән, чиләк-себерке күтәреп, бер чиста гына апай килеп керде. Үзе үк башлап:

– Исәнмесез! – диде.

– Бик әйбәт әле, апа, – дидем мин. – Сез генәмени монда?

– Ийе шул.

– Җыештырасыңмыни?

– Ийе шул.

– Көндәме?

– Көн дә инде, көн дә... Кичтән монда озак утыралар, иртәндә халык була. Менә шул буш арада җыештырып чыгарга тырышабыз инде... Сез кем соң?

– Мин шәһәрдән... Эш белән... Себеркегез бик хуш исле, апа!

Апа, себеркесенә карап, бер көлеп куйды:

– Чыгарып кына атасы да бит, бүтәне юк: урман ерак. Барып, каен йә булмаса артыш себеркесе бәйләп кайтырга бер дә бушый алмыйм шул, менәтерә!.. Мондагы тузанны алып бетерәмени соң бу, артышныкы кирәк, артышныкы. Моның ни, исе генә. – Шулай диде дә апа, кулындагы хуш исле әрем себеркесен, ачуы килгәндәй, мич аралыгына ыргытты.

– Председатель кайчан килә соң? – дидем мин, себерке турында тизрәк онытырга тырышып.

– Тиздән килер, чәй эчәргә генә кайтып китте.

– Җамалетдиновмы әле ул?

– Юк, Җәләлетдинов... Җәләй дип кенә дә йөртәләр.

– Алайса, мин аны шушында көтим инде.

– Көтегез, көт... Әнә бүлмәсенә кереп утырсагыз да ярый, – диде апа, куштанлык күрсәтеп.

Мин председатель бүлмәсенә уздым. Хуҗаның яңарак кына чыгып киткәнлеге әллә кайдан күренеп тора – өстәлендә тәртипсез яткан кәгазьләр, ачылып яткан ниндидер калын дәфтәр, яңа башланган «Беломор» пачкасы... Хәер, мин өстәл янына якын да бармадым, тизрәк стенадагы төрле плакат-язуларны карарга керештем. Шунда ук минем игътибарымны зур бер фоторәсем үзенә тартты. Һичшиксез, бу махсус зурайтылган рәсем иде. Анда бер унлап карт бабайлар төшерелгән. Бер дүртесе алга утырган, калганнары артка басканнар. Барысы да бик карт булсалар да, яшьләре төрлечә, кыяфәтләре төрлечә, өс-башлары да төрлечәрәк. Кайсы озын

бишмәттән, бүректән, кайсы пинжәктән, түбәтәйдән. Кайсының кулында таяк, кайсы таяксыз гына һәм барысы да диярлек мөселманча очландырып китәрелгән кечкенә ап-ак сакаллы. Шулай да алда утырганнары иң картлары булса кирәк, арыклар, бетешкәннәр, ә арттагылары җегәрлерәк, таза гына басып торалар. Барысында да шактый җитди кыяфәт, әмма чырайларында шатлык яки тантана кебек берни дә сизелми. Һәм менә шул ниндидер уңай белән фотограф алдына җыеп утыртылган бабайларның нәкъ уртасында киң җилкәле, атныкыдай зур, озынча битле, бик таза ир уртасы бер кеше утырып тора. Кулларын ике тез өстенә салып, күкрәген киерә биреп, башын артка ташлабрак, гаҗәеп бер тантаналы җитдилек саклап утыра ул, вәзирләрен янына җыйган патша сыман.

Бу рәсем миндә зур кызыксыну уятты. Нинди картлар болар, уртадагы таза кеше кем, нинди уңай белән алар җыелышып төшкәннәр? Мин инде, алгы якка чыгып, теге апайдан сорамакчы булган идем, ләкин шул чакта, авыр-салмак басып, председатель үзе килеп керде. Бу чыннан да пәһлевандай таза кеше иде. Рәсемдә утыручы да нәкъ шул үзе икән. Мине күрүгә, ул:

– Иптәш карыспандетмы? – дип, кулын сузды.

– Әйе, шулайрак.

– Кичә шалтыратып әйткәннәр иде, – диде ул, өстәле янына узып. – Әйдә утырыгыз.

Мин аның каршысына утырдым. Председатель зур, каты кулы белән озын битен бер сыпырып куйды. Аннары телефон трубкасын алып, номерын җыеп тормыйча, бер генә өрде дә кемгәдер кычкырды:

– Кадрия, аппагым, конныйны бир әле... Сиражи, синме бу? Син давай теге нигә, Әхмәдигә әйт әле, хәзер генә минем атны правлениягә җигеп китерсен. Ыңгырчак астына киез салырга онытмасын, ату суга башлаган... Давай!..

Телефон трубкасын куйгач, ул миңа күтәрелеп карады. Карашы туры, кыю һәм берникадәр үзенең өстенлеген дә сиздерә иде.

– Йә, ни йомыш? – диде ул гади генә.

– Менә сезнең эшләр белән бераз танышыйм дип килгән идем, – дидем мин, блокнотны чыгара башлап. – Сөйләшеп аласы иде...

– Сөйләшүне кичке якка калдырып торыйк... Минем хәзер печәнчеләр янына барасым бар. Теләсәгез, сез дә әйдәгез.

– Бик рәхәтләнеп...

– Булды, алайса. Печәнчеләрнең эшләрен дә күрерсез, юлда сөйләшеп тә алырбыз... Шулай бит?

– Мин моңа бик риза.

– Безнең болыннар Кама буенда. Матур җирләр, су, әрәмәлек, пароходлар уза – төшереп кенә аласы!.. Яшьләр куна ятып эшлиләр, балалы хатыннар гына кайтып-китеп йөриләр.

Беренче караштан ук председатель абзый миңа ошап куйды әле. Үзенә һәм эшенә нык ышангандай ачык сөйләшә. Хәер, алдынгылар исәбендә йөргән председательләр шулайрак була да инде ул. Куркып, тел яшереп тормыйлар. Ә бу председатель бөтен заданиеләрне үтәп бара икән, димәк, район җитәкчеләренә дә таянычы зур... Кайчагында гәзитәнең дә теше үтми андыйларга. Юлларын белеп торалар. Аннары мин гомумән таза кешеләрне яратам. Аларның ничектер ашлары да, эшләре дә таза була. Күп очракта эчләре дә таза булып чыга.

Шулай итеп, мин иптәш Җәләлетдинов турында матур уйлый да башладым. Хыялым инде язылачак материал өчен детальләр, бизәкләр дә эзләргә тотынды. Шул чакта әлеге фоторәсем исемә төшеп, иптәш Җәләлетдиновтан сорадым:

– Әйтегез әле, бу нинди рәсем, кемнәр анда?..

– Болармы? – диде Җәләлетдинов, карашын рәсемгә күчереп. – Болар безнең авыл картлары... Минем консультантлар...

Мин аңлап бетермичәрәк аңа карадым. Җәләлетдинов сүзеннән һәм минем гаҗәпләнүдән бик канәгать булгандай елмаеп куйды:

– Нигә, ышанмыйсызмы әллә?.. Әйе, консультантлар... Мин, парин, кайчагында аларны җыеп киңәш-табыш итәргә яратам... Картларда күп нәрсә сакланып ята, күпне беләләр, шуны алырга кирәк бит... Кайчак бик дильни киңәшләр бирәләр, парин!.. Йә, начармыни бу?

– Юк, бик әйбәт, бик дөрес эшлисез! – дидем мин, чын-чыннан бу эшкә сокланып.

– ...Ну бервакыт безгә фотокарыспандент килеп чыкты да, мин тиз генә үзләрен, җыеп, шушы рәсемгә төшерттем. Аннан районда зурайтып алдым. Ничава бит?

– Әйбәт, бик матур төшкәнсез!

– Менә бер память булып калды ул... Ату картларның көннәре санаулы. Китә торалар, әнә теге миннән уңда утырганы быел яз китеп тә барды...

– Алай икән... Ә бу картларның яшьләре кай тирәдәрәк... Иң олысына, иң кечесенә дигәндәй?..

– Иң олысына, әнә миннән сул кулдагы Нуриәхмәт бабайга, сиксән алты яшь инде, ә теге арткы рәттәге, сулдан иң читтәге Зарифҗан картка җитмеш дүрт булса кирәк... Картлар ничава, картлар ярыйсы...

Мин эчемнән сөенеп уйладым: менә алдынгы председатель турындагы очеркны башлап җибәрергә бик әйбәт деталь дә табылды; картларга хөрмәт, картларның бай тәҗрибәсеннән файдалана белү... Чыннан да шәп табыш бит бу!..

Шул арада теге өйне җыештыручы хатын, кереп:

– Җәләй абзый, ат килде, – диде.

– Ярый, кузгалабыз, – диде Җәләлетдинов.

– Кая, ни, Нурдидәгә әйт әле, подписка дигән кәгазьләрен кертсен.

Хатын чыгып киткәч, миңа карап сорады:

– Сез соң ничек урнаштыгыз, тамак ялгадыгызмы әле?..

– Рәхмәт, миңа төшкән җирдә чәй эчерделәр.

– Чәй генәме? – диде ул, күз кысып. – Кемгә, шул мин әйткән умартачы Хәертдин абзыйларга куйдылармы сезне?

– Әйе, шунда, умартачыга...

– Яхшы булган... Умартачының бал мичкәсе бушап тормый аның...

Җәләлетдиновның болай кайгырта белүе дә ошап куйды миңа... Мин үзем соранып йөри торган кеше түгел, аннары бик сыйланып йөрергә положение дә кушмый... Мактап язсаң – сыйлаган өчен, яманлап язсаң – сыйламаган өчен, дип, гайбәтеңне саталар.

Бүлмәгә, кәгазьләр күтәреп, озын толымлы, алсу йөзле зифа-чибәр генә кыз керде. Председатель аның белән нигәдер каш җыебрак сөйләште. Минем алда чибәр кызга юри коры буласы килгәндерме инде? – аңлавы читен шикелле... Хәер, күп кенә председательләр шикелле үк, Җәләлетдинов та үзенең кешеләре белән шулай хуҗа булып, өстен-коры сөйләшергә ярата иде – мин моны соңыннан бик ачык сиздем. Ләкин моңа мин һич гаҗәпләнмим, күреп күнеккәнмен, шулай кирәктер, шунсыз булмыйдыр дип уйларга өйрәнгәнмен.

Кызның кәгазьләренә ул кул куеп бетергәч, без кузгалдык. Баскыч төбендә безне таза кара айгыр җиккән рессорлы, биле сыгылмалы, тимерле арба көтә иде. Бу арбаның тарантастан аермасы шунда, аның кузласы юк, ләкин билне терәрлек кенә аркасы бар, үзе иркен, кыскасы, өч-дүрт кеше утырып йөрерлек бикипле нәрсә ул... Арбага утыргач та, Җәләлетдинов идарәдән ияреп чыккан кешеләргә хуҗаларча кыска-кыска гына боерыклар бирде, шуннан соң без кузгалып киттек.

Авыл чыккач та, яшь арыш басуы башланды. Арыш инде күкрәккә җиткән, агарып килә, башакларын бөгә башлаган, чайкалуы да инде салмаклана төшкән... Менә шул арышка карап, иптәш Җәләлетдинов колхозның эше, хәле турында сүзгә керешеп китте. Күпме чәчкәннәр, күпме ашлама керткәннәр, күпме уңыш көтәләр; терлек саны күпмегә арткан, сыерлар күпме сөт бирәләр; колхоз нәрсәләр салдыра, нинди машиналар сатып ала, киләчәккә нинди планнар кора. Кыскасы, нәкъ миңа кирәк нәрсәләрне сөйли председатель, авырлыкларны читләтеп, ал буяуларны куерак салып, тыйнаклык йөзеннән «мин эшләтәм боларны» дип әйтмәсә дә, бөтен

эшнең тоткасы ул үзе икәнлеген шактый сиздереп сөйли... Бик әйбәт. Мин Җәләлетдинов турында язарга тиешмен. Миңа аның шәп, яхшы председатель булуы кирәк. Мин үзем дә әле, күрерсез, аны аллы-гөлле бизәкләргә бизиячәкмен.

Шулай сөйләшеп бара торгач, без ике картны куып җиттек. Икесе дә таяк тотканнар. Юл читеннән, бөкрәя төшеп, аллы-артлы китеп баралар. Берсенең өстендә җилән, икенчесенең өстендә кулдан гына сырган җиңсез жилет сыман нәрсә, аякларында оек өстеннән генә кигән иске галошлар, башларында ямьшәеп беткән эшләпә... Куып җиткәч, Җәләлетдинов, атын юыртудан туктатып, картларга дәртле генә кычкырып дәште:

– Сәлам илнең картларына!

Бабайлар безгә борылып карадылар:

– Ә, Җәләй туган, синмени әле бу?

– Рәхмәт яхшы сүзеңә!

– Кая болай? – диде председатель.

– Менә болынга, оланнар янына китеп барабыз әле.

– Нигә анда барасыз?.. Өйдә генә ятмыйча...

– Барабыз әле, аяклар йөргән чакта... Эшләрен күреп кайтырбыз.

– Өйдә генә ятып булмый шул, – диде бабайларның икенчесе. – Тәндә җан барында...

– Менә шулай инде безнең картлар, – диде председатель, миңа карап. – Эш өсте җиттеме, таякларына атланып, болынга да, басуга да йөри башлыйлар... Әнә теге алдан барганы, Гайсә карт, бик шәп кибән куючы иде. Кибәнне шундый очлап, шешне шундый таза утыртып куя, бернинди давылларга да бирешерлек булмый. Гайсә бабай, мин әйтәм, әле хәзер дә кибән башына менәрсеңме?..

– Ник менмәскә, – диде карт, – кирәксә, менәбез аны...

– Әнә бит, – диде председатель, кәефле генә көлеп. – ...Ыштаны төшеп барса да, кибән башына менмәкче әле ул.

– Болын еракмы соң? – дип сорадым мин аңардан.

– Авылдан тугыз километр... Әле бер өч-дүрте калгандыр... – Аннары ул бабайларга карап әйтте: – Ярый, картлар, үз җаегыз белән атлый торыгыз, ә без киттек.

– Син, Җәләй туган, безне дә кара айгырыңа утыртыр идең, – диде шул чакта арттан әлсерәбрәк килгәне.

– Анысы бит, Шәйхи бабай, уставта юк, әйтелмәгән, – диде Җәләлетдинов.

– Нәрсә?

– Мин әйтәм, сезне председатель атына утыртып йөрү уставка язылмаган, менә эш нәрсәдә!..

– Ә-ә! – дип сузды бабай, әллә бернәрсә аңламыйча, әллә артык гаҗәпләнүдән.

Җәләлетдинов дилбегәсе белән атының сыртына «На-а-а!» дип бер какты да, кара айгыр, ястыктай арт санын тибрәтә-тибрәтә, кызу гына юртып та китте.

Әйтергә кирәк, Җәләлетдиновның картларга әйткән соңгы сүзләре мине дә шаккатырды. Мин дә тиз генә аңлап җиткерә алмадым аның ни өчен болай дип әйтүен... Чынлап әйттеме, уйнап кынамы, әллә ялгыш ычкындырдымы?.. Чынлап әйтүенә һич ышанасы килми, уйнап кына дисәң, калдырып, чаптырып киттек тә бардык... Бәлки, болар барысы да – «уставка язылмаган» дип әйтүе дә, чаптырып китүе дә уйламаганнан ялгыш кына килеп чыккандыр?! ...Мин аның ни эшләгәнен аңлап, уңайсызлануын, минем алда аклана башлавын көттем. Ләкин юк, Җәләлетдиновта уңайсызлануның әсәре дә юк, гүя тик бабакай, бер эш эшләгәндәй, текә утырып, тыныч кына баруын белә. Җитмәсә әле, ул миңа яңадан колхозның сыерлары, сарыклары, дуңгызлары турында мактанып сөйли башлады... Шуннан соң мин бу кешедән тәмам өметемне өздем. Аның хакта матур итеп язарга уйлаган бөтен хыялларым кинәт җимерелде дә төште. Нинди генә шәп председатель булмасын, колхозы нинди генә уңышларга ирешмәсен, мин инде аның турында һичнәрсә яза алмаячагымны аңладым, белдем. Картларга әйткән шул җансыз, тупас, казённый бер сүзе белән ул барысын да үтереп ташлады!

Каманың иркен тугайларында, ат корсагына җиткән үләнле юллардан йөрү дә, кибеп яткан печәннәрнең хуш исе дә, печәнчеләр янына туктап сөйләшүләр дә, җиңел тырмалары белән пакусларны селкә-селкә җыючы чуар кызларның матур җырларын ишетү дә – берсе дә минем кәефне инде үзгәртә алмады. Йөреп кайткач, кичкырын мин район үзәгенә җәяүләп кенә кайтып та киттем.

*1968*

## Курай

Күптән түгел Сәгыйть[*] дус миңа курай турында шушы легенданы сөйләде:

«...Бик борын заманда безнең җирләрдәге бер хан үсмер малайларны берәм-берәм чакыртып, шулардан чәчен кырдыра торган булган. Әмма чәч кырган малайларның берсен дә хан кире кайтарып җибәрмәгән —һәркайсын шунда ук үтертә икән. Шулай итеп, ханның чәчен кырган күп кенә малайлар һәлак булганнар. Ни өчен хан аларны үтерткән – моның сәбәбен

[*] Сәгыйть Агиш – күренекле башкорт язучысы. – *Ә. Е.*

берәү дә белмәгән... Менә көннәрдән беркөнне бер ялгыз хатынның бердәнбер малаена да чират җиткән: хан чәчен кырдырырга аны да чакырткан. Малай хан сараена китәр алдыннан әнисе аңа төче икмәк пешереп биргән: мә, улым, тамагың ачкач, утырып ашарсың, дигән.

Малай төче икмәкне кыстырып сарайга киткән, хан янына барып кергән һәм күп сөйләшеп тормастан ханның башын бик әйбәт юешләп, үткен пәке белән чәчен кыркып төшергән. Менә шул чакта ул гаҗәеп бернәрсә күргән: ханның башында имән бармак чаклы мөгезе бар, имеш!.. Хан да шүрәле сыман мөгезле, имеш!..

Малай эшен бетергәч, хан аңа әйткән: «Син инде минем мөгезне күрдең, ханның мөгезе бар икән дип сөйләп йөрерсең, шуңа күрә мин сине үтертәм», – дигән. «Ярый, – дигән малай, бер дә каушап тормыйча, – тик син миңа шушы икмәгемне генә ашап алырга рөхсәт ит», – дигән. Хан рөхсәт иткән. Малай төче икмәген иплəп кенә ашарга тотынган. Ул, ашыкмыйча, авызын чәпелдәткәләп, бик тә тәмле итеп ашый икән. Хан да моның ашаганын карап тора торгач, кызыгып киткән: «Икмәгең бик тәмле күренә, кая, миңа да әзрәк сындырып бир әле», – дигән. Малай чамалап кына сындырып биргән. Хан ашый башлаган һәм исе китеп, малайдан: «Нигә бу икмәк шул хәтле тәмле?» – дип сораган. Малай: «Әнием аны үзенең күкрәк сөтенә изеп пешерде шул!» – дип җавап биргән. Моны ишеткәч, хан шактый аптырап калган: «Алайса без синең белән бер ананың сөтен капкан булып чыктык, без хәзер бертуганнар булабыз бит!» – дигән. Малай дәшмәгән. Ә хан уйланып: «Бертуганны үтерергә ярамый бит әле, менә хикмәт нәрсәдә! – ди икән. – Ләкин үтертмичә дә булмый, чөнки син минем мөгезне күрдең, халыкка сөйләп йөрерсең... Инде нишләтергә сине?..»

Малай бу юлы да дәшмәгән, һаман тәмләп кенә төче икмәген ашый биргән. Шуннан соң хан, бераз икеләнеп торгач, малайга әйткән: «Ярар, мин сине үтертмим, – дигән. – Ләкин бер шартым бар. Кырда кура дигән бер көпшә үсә, син аның кипкәнен чокыр башыннан табарсың. Менә шул көпшәне кисеп ал да минем мөгез турында сөйлисең килгән саен шуңа гына өрә торган бул... Аңладыңмы?.. Мөгез турында – ләм-мим!.. Телең кычыта башлады исә, көпшәне генә сызгыртырга тотын!.. Килештекме?»

Малай: «Ярый, риза», – дигән, шуннан хан аны өенә кайтарып җибәргән.

Малайның вакыт-вакыт мөгез турында бик сөйлисе килеп китсә дә, вәгъдәсен бозмаган. Сөйлисе килгән саен, әлеге шул кырдан кисеп алган көпшәсен «гү... гү» өрергә тотына икән. Тора-бара ул көпшәнең түбән очына тишекләр дә ясаган. Тишекләргә баскалап, көпшәдән нечкә-калын тавышлар да чыгара башлаган. Шулай итеп малай төрле көйләр уйнарга өйрәнеп киткән. Хәзер инде ул ханның мөгезен сөйлисе килгәндә генә түгел, ә телдән әйтә алмаган берәр уе, хәсрәте бар чакта да көпшәсен алып уйный икән. Искиткеч моңлы-матур уйнаган ул,

кешеләр аны таң калып тыңлаганнар. Кеше теле әйтеп бирүдән гаҗиз хисләрне кузгатучы курай дигән гаҗәеп нәрсә әнә шулай туган, имеш!»

Бу легенданы яңарак ишетсәм дә, курайның үзен миңа бик яшьли күрергә һәм тыңларга туры килде. Безнең Дәүләкәнгә терәлеп кенә торган Яңа Көрмәнкәйдә курай уйнаучы бер карт бар иде – менә шул картны хәтерлим әле мин... Тик минем балалык хәтеремдә аның кураеннан бигрәк башка ягы ачык сакланган. Хикмәт шунда, Тимербай карт курайчы гына түгел, балыкчы да иде. Һәм без, Дәүләкән малайлары, Дим тугаена барган чакта Тимербай картның шундагы күлләрдә тар гына бүрәнә каекка утырып, сыңар ишкәге белән камышларны ера-ера нәрәтә куеп йөргәнен гел күрә торган идек. Ул кояштан, җилдән бакырга әйләнеп, какланып беткән, бик чандыр бер кеше иде. Балакларын тезенә чаклы сызганган, күлмәгенең алдын ыштан бөрмәсенә кыстырган, үзе һәрвакытта ачык, ә башында беләүләнеп каткан түбәтәй... Аннары тагын шул ук ыштан бөрмәсенә бәйләп, ул иске күн кыныда кечкенә үткен пычак та йөртә иде. Бигрәк тә менә шул пычакка безнең күзебез яна иде һәм, әйтергә кирәк, бу пычаклы бабайдан без әзрәк кенә курка да торган идек.

Соңыннан Тимербай карт нәрәтәгә кергән бик шәп табан һәм кара балыкларны иске кәрзингә тутырып, өстен яшел үлән белән каплап, Дәүләкән урамында, ыштан балакларын да төшермәгән килеш, сатып йөри иде.

Аннары инде, үсә төшкәч, мин аның курайда уйнавын да хәтерли башладым. Әйбәт, оста уйный идеме ул —мин әле белми идем, әмма өч-дүрт тишегеннән башка бернәрсәсе дә булмаган, эче куыш, җип-җиңел, кибеп беткән көпшәдән шундый гаҗәеп озын көйләр чыгара алуына хәйран кала торган идем. Бер могҗиза булып тоела иде ул миңа, һәм мин, кем өрсә дә курайдан шулай көй-моң чыгара аламы икән, дип, баш вата идем. Билгеле инде, минем курай дигән шул җип-җиңел көпшәне тотып өреп карыйсым килә иде... Ләкин Тимербай карт кураен юри генә, карар өчен генә дә һичкемгә тоттырмый иде. Уйнап беткәч, ул кураеның башын ни өчендер ялаштырып ала да аннары күлмәк изүеннән каядыр эчкә үк тыгып куя. Бу да мине бик гаҗәпләндерә иде.

Әмма минем курай белән чынлап торып сихерләнүем тагы да үсә төшкәч, унөч-ундүрт яшьлек чагымда булды. Беләсез, бу шундый вакыт инде – күңел кыллары үзеннән-үзе тибрәнеп, йөрәктә җыр-моң туарга гына тора! Хыялның да бик җилкенгән, әзләнгән, очынган чагы!.. Нәкъ менә шушы чакларда миңа курайны еш кына ишетергә дә туры килде.

Безнең күршедә генә Миңнегәрәй исемле башкорт тора иде. Аның ике аты бар. Шул атларын тәңкәле камыт-эшлияләр белән читән тарантаска җигеп, поезд килүгә Дәүләкән станциясенә чыга һәм поезддан төшкән кымызчыларны утыртып, Дим буе авылларына илтеп

куя торган иде. Бу аның төп кәсебе, атларын һәрвакыт таза, көр тота, ә көз җитеп, беренче кар төшкәч, шул атларның берәрсен иярләп, төлке, бүре сугарга да чыга иде. Шуның өчен генә ул ике бурзай да асрый иде. Кыскасы, бик егет кеше иде безнең күрше Миңнегәрәй агай.

Менә шул Миңнегәрәй агайга базар көннәрендә Дим буеның берничә мулласы, әйтик, Шәрип авылыннан Котлыяр мулла, Казанголдан – Исхак мулла, Япардан – Сафуан мулла гел килә торганнар иде. Бу өч мулла бик дуслар иде, ахрысы, чөнки кайчан карама, алар һәрвакыт бергә булалар иде.

Аларның базарда бернинди сату-алу эшләре юк, иртәнге якта чыгып, базарны бер әйләнәләр дә үзләре кебек тагын берничә мулланы яки бай башкортны ияртеп кайталар һәм Миңнегәрәй агайның түр сәкесендә көне буе диярлек ашап-эчеп, курай тартып, җырлашып утыралар... Ике ихата арасында тәбәнәк читән генә, ә күрше өйнең тәрәзәләре киңенчә ачык, шунлыктан барысы да – сәкедәге чирек-чирек кымызлары да, табак тулы итләре дә һәм кунаклар үзләре дә ап-ачык күренеп тора. Гомумән, башкорт муллалары ашап-эчеп утыруларын берәүдән дә яшермиләр иде. Исерә калсалар да гаеп итүче юк – мулла да кеше!

Менә шул ачык тәрәзәләрдән инде бервакыт, абзыкаем, курай белән җыр агыла башлый!.. Һәм мин шуны ишетүгә, барган җиремнән капкынга эләккәндәй, шып тукталып кала идем. Һич ычкына алмый идем мин ул татлы әсирлектән... Бөтен дөньямны онытып, ләззәтеннән, сызландыруыннан җыларга җитешеп тыңлыйм да тыңлыйм... Күз алдымда үзенең якты киңлекләре, тын түбәләре, ак тирмәләре, утрауда йөргән җылкылары белән кылганлы дала әкрен генә җәелә дә җәелә... Бик биектә бөркет салмак кына йөзә. Еракта ялгыз җайдак шәүләсе күренеп кала, әллә кайда гына әрлән сызгыруы ишетелгән кебек була... Һәм иң гаҗәбе, шул далада ак тастарлы җиңгәнең муенына корык салган бияне савып утырганын бик ачык итеп күрә торган идем. Бу шулхәтле ачык-җанлы булып күз алдына килә, мин хәтта җиңгәнең ике тез арасына янтайтыбрак кыстырган агач чиләген дә, шул чиләккә биянең ике имчәгеннән алмаш-тилмәш бәреп төшкән нечкә генә сөтне дә күргәндәй була идем... Әнә шулай әллә кайларга алып китә, хыялый итә иде мине бу башкорт курае, башкорт җыры!

Курайчыны берничә мәртәбәләр күрсәм дә, мин аның кайсы авылдан, кем икәнен белә алмадым. Аны шул муллалар үзләре базардан ияртеп кайталар иде. Аз гына кылый, аз гына шадра, озын буйлы бу агай, минемчә, бик шәп курайчы булгандыр. Бик дәртләнеп, бик рәхәтләнеп, ничектер җиңел итеп, гүя уйнап кына тарта иде ул үзенең кураен! (Аның сирәк кенә төкле ирене кураен китереп терәмәс борын ул үзеннән-үзе селкенә башлый иде инде.) Әмма шул ук вакытта ул кураеннан гаҗәп саф, гаҗәп иркен тавышлар чыгара белә һәм шуны искиткеч

озын итеп, бормаландырып суза да ала иде. Кыскасы, тәмам җелеккә үтәрлек итеп уйный иде агабыз!

Ә курайга кушылып һәрвакыт Котлыяр мулла җырлый торган иде, һичшиксез, курайчыга тиң җырчы иде ул... Авызын ачар-ачмас, иреннәре арасыннан гына бер суза башласа, тавышы киң далага да сыймас кебек... Шуның өстенә гаҗәеп моңлы-матур җырлый иде бу мулла!.. Мин аны яхшы беләм, бездә дә аның булганы бар иде. Озын кара кәзәки кигән мәһабәт таза гәүдәле, елтырап торган кызгылт-шома битле, сирәк кенә кара сакаллы бер кеше иде ул. Базардан базарга, кунактан кунакка гел бал, кымыз эчеп тә кызык сөйләп, җыр җырлап йөргән бу кешенең мулла булуына ышануы да читен иде. Елына ике килә торган гаеттан башка ул үзенең мәчетенә йөрде микән?.. Һәрхәлдә, мин аның чалма кигән чагын күрмәдем.

Озын сүзнең кыскасы, күрше Миңнегәрәй агай өенә җыелып, сәрхуш булып утыручы муллаларның җыр-курайларын миңа бер-ике җәй буена еш кына ишеткәләргә туры килде. Нәкъ менә шул чакта башкортның тиңсез бай, гүзәл, сихри җыр-моңнары минем кайрыланып өлгермәгән күңелемә гомерлеккә диярлек сеңеп калды да булса кирәк. Аннары озак та үтми мин, шактый яшь башымны алып, туган-үскән оядан, якты Дим буйларыннан ерак калага чыгып киттем. Ә бер өч-дүрт елдан соң теге муллалар да кайсы кая таралып, югалып беттеләр шикелле.

Шактый күп еллар узгач, мин үзебезнең радиокомитетта (фронттан кайтып шунда эшли башлаган чагым) тагын бер курайчы белән таныштым. Бу инде татар курайчысы иде. Шуның өстенә радиода уйнаштыра, димәк, аны күпмедер дәрәҗәдә профессиональ курайчы дияргә дә була. Ләкин якынрак танышкач, мин аның кайчандыр хуҗалык эшләрендә эшләп йөргәнен, тик соңгы вакытларда гына курайчы булып танылып киткәнен белдем. Әлбәттә, музыкага бик сәләтле кеше иде ул, кулына ни тотса, шуны уйный ала, курайга да яшьтән үк өйрәнгән, әмма болар берсе дә аның өчен төп кәсеп була алмаган. Инде аны радиога чакырып уйната башлаганнар икән, моның сәбәбе бик ачык: шәһәрдә ул бердәнбер курайчы.

Исеме аның Исмәгыйль иде. «Исмәгыйль абзый» дип эндәшә идек без аңа. Җыйнак-җиңел гәүдәле, җирән сакаллы, зур коңгырт күзле бу чибәр абзый телгә дә бик җор иде, гел уен-көлке сөйләргә ярата торган иде. Шуңадыр инде ул безнең радиокомитетка йөрүче күп кенә артистлар, җырчылар, композиторлар белән дә якыннан аралашып, ничектер җиңел генә дуслашып өлгергән иде.

Мин үзем дә Исмәгыйль абзыйны ярата идем, алюмин кураен да рәхәтләнеп тыңлый идем, ләкин ни өчендер шул чакта еш кына «Нигә бу абзый табигый курайда уйнамый икән?» дип, ихтыярсыздан уйлана да идем. Белмим, яшьтән үк тыңлап өйрәнгәнгә күрәме, миңа ясалма курайга караганда кырда үскән табигый курай якынрак та һәм тансыграк та иде. Дөресен генә

әйткәндә, күптән инде мине бер нәрсә гаҗәпләндерә: ни өчен табигый курай бездә юк, ни өчен ул, әйтик, башкортларда сакланган да, бездә сакланмаган?.. Бик сирәк кенә очраган безнең курайчылар йә тимер, йә җиз курайда уйнаганнар. Бәлки, кеше кулы белән ясалган бу курайлар теге ялан кураена караганда әйбәтрәктер, курай сәнгатендә үзенә күрә бер алга китештер?.. Ихтимал, шуның өчен дә ясалма курай табигый курайны гамәлдән кысып чыгаргандыр?.. Бу хакта мин Исмәгыйль абзыйның үзеннән дә сораган идем. Аның әйтүенә караганда, табигый курай, билгеле, безнең татарларда да булган, хәзер дә әле кайбер җирләрдә, мәсәлән, Ык буенда ялан кураенда уйнаучылар очрый, ләкин татар халкы кырда үскән курай белән генә чикләнмичә, шуның төсле итеп тимердән, җиздән дә ясарга өйрәнгән. Моның сәбәбе безнең дымсурак, салкынчарак җирләрдә уйнарга яраклы курайны табуга караганда, аны кулдан ясау ансатрак булганга күрәдер, бәлки?! Аннары тагын ясалма курайның тавышы да безнең татар колагына нәфисрәк ишетелсә кирәк.... Бу сүзләрдә, һичшиксез, дөреслек булырга тиеш.

Шуннан соң мин бер сөйләшүдә Исмәгыйль абзыйдан туп-туры сорадым:

– Ни өчен сез ялан кураенда уйнамыйсыз?

Моңа каршы ул көрсенә биреп:

– Их, Әмирхан туган, уйнамас идеммени мин, ләкин юк бит ул, ялан курае юк, – диде.

– Ә сез дөресен генә әйтегез әле: ялан кураен үзегез яратасызмы?

– Һе, яратмыйча, әлбәттә, яратам.

– Алайса табарга кирәк аны.

– Ә кайдан?.. Акчага сатылмый. Арчада үсми ул... Аның өчен генә Урал тауларына барыргамы?

– Бик кирәксә, барасың да аны...

– Мин әзер, – ди Исмәгыйль абзый, шунда ук сүзне уенга борып. – Әйдә, командировочный яздыр, иртәгә үк китәм.

– Курай сиңа кирәк бит.

– Нишләп миңа, халыкка кирәк ул... Ә халыкка кирәкне табу – сезнең эш... Чын, комитет алдында мәсьәләне күтәр, курай җыеп кайтыр өчен Уралга экспедиция җибәрик, диген.

Безнең сөйләшү әнә шулай ярым уен-көлкегә әйләнеп бетә торган иде. Әлбәттә, миңа тансык курай турында бүтән уйлаучы да юк, аннары Исмәгыйль абзыйның алюмин курайлары бар чагында башкасын кирәк дип белүче дә юк иде.

Ул шулай кысыр хыял булып калган да булыр иде, ләкин бер җәйне минем үземә Оренбург өлкәсенә, Куандык дигән җиргә кайтырга туры килде. Юлга чыгар алдыннан мин бу сәфәремне Исмәгыйль абзыйга да әйттем.

Абзый, кызыксынып:

– Куандык?.. Нинди җир, кайда ул? – дип сорады.

– Сакмар буенда, – дидем мин.

– Сакмар буенда!.. Бик тә ямьле якларга китәсең икән, туган! – диде ул сөенеп һәм әз генә көнләшкәндәй дә булып. Аннары, нидер исенә төшкәндәй, ачылып өстәде: – Карале, син шуннан миңа әлеге үзең мактаган ялан кураен табып кайтмассыңмы?.. Сакмар буенда үсәргә тиеш ул!

Аның бу үтенече миңа да ошап куйды.

– Ярар, абзый, эзләп карармын! – дидем мин ихлас кына.

– Зинһар, туган!.. Син үзең кырда үскән курайны таныйсыңдыр бит?

– Танымасам, мин аны шундагы агайлардан эзләтермен.

– Бигрәк тә яхшы!.. Тик син берничәне табарга куш инде... Түләргә туры килсә, алып кайткач, исәпләшербез...

– Анысы өчен борчылмагыз, Исмәгыйль абзый, – дидем мин, сүзне шуның белән өзеп.

Куандык!.. Кайдан бу шигъри матур исем?.. Минем сугышка чаклы да бу тирәләрдә булганым бар иде. Беренче күргәч, үзем дә куануга охшаш хис кичергән идем. Табигатьнең гаҗәеп бай, матур җирендә утыра ул Куандык!.. Кайсы ягына карама, ямь-яшел йомры түбәле биек-биек таулар... Шул таулар арасыннан бормаланып көмештәй ак, чиста Сакмар агып килә. Таулар чигенгән җирләрдә билдән дә югары куе үлән үскән тип-тигез тугай җәелеп китә. Ә таулар китереп кыскан урыннарда текә кыялар бөтерелеп аккан Сакмар өстендә таш стенадай басып торалар... Билгеле инде, бу гүзәллекне, бу байлыкны беренче килеп күргән кешеләрнең чынлап куанулары да һәм ак тирмәләрен корып утырган шушы урынга «Куандык» дип исем бирүләре дә бик табигый, бик аңлашылса кирәк. Шигъри исем үзе үк шуны әйтеп тора!

Куандыкка мин кыз туганнарыма кунак булып кайткан идем. Аларда хәзер ир заты юк, икесенең ире һәм бердәнбер энеләре сугышта һәлак булдылар. Шуңа күрә мин, фронттан исән-имин кайткан ага тиешле кешеләре, алар өчен бик кадерле кунак идем. Сый-хөрмәтне әйткән дә юк, ашап-эчеп кенә өлгер, шуның өстенә ике-өч көн саен эссе мунча, яткан урыным да ак өйнең түрендә, сиртмәле караватта гына...

...Бу сый-хөрмәттән бик тиз маемларга да мөмкин иде, ләкин мин Ходай бирмеш һәр көн йә Сакмар буена, йә тауларга чыгып китә идем. Таулар!.. Малай чактан ук калган бер комарлыгым бар – кайда гына берәр биеклек күрмим, шуңа үрмәләп булса да менәргә тырыша идем. Менә Куандык әйләнәсендәге тауларга да мин тырыша-тырмаша мендем, ниһаять!

Тау биекме?

Син менәмсең?

Мен, менә алсаң, тауга мен!

Тауга мен, күр дөньяны син,

Күр бу дөньяның ямен!

Әйе, дөньяның хәйран ямьнәре, хәйран киңлекләре ачыла икән бу таулардан!.. Әкрен генә җил уйнаган биек түбәдән мин, үземчә чамалап, әле Орск, әле Җилаир якларына озак кына карап тора идем. Аннары...

Төш түбән, йөр син түбәндә,

Күр чәчәкләр, чишмәләр,

Күр игеннәр, күр җимешләр.

Хәсрәтеңне бер китәр!

Әйе, Сакмар буена төшкәч, хәсрәт-уйлар чынлап та каядыр ага да китә. Назлы-шаян кызлар кебек бит ул җыр булып аккан Сакмар!.. Бер карасаң, чуерташлар өстеннән ак тәпиләрен елтыратып көлә-көлә йөгерә, икенче карасаң, озын толымнарын сүткән шикелле, зәңгәрләнеп-уйчанланып тын гына агып ята.

Ничөн суга сузыласың,

Тал чыбыккай, интегеп,

Ялварасың, борыласың,

Тилмерәсең, өзеләсең,

Аккан суга күз тегеп?

. . . . . . . . . . .

Әнә шулай иске шигырь өзекләрен искә төшереп, мин Куандык әйләнәсендә күп йөрдем. Әлбәттә, Исмәгыйль абзыйның курай табып кайтырга кушкан үтенечен дә хәтеремнән чыгармый идем, киресенчә, күңелгә килгән җыр, шигырьләр курайны гел искә төшереп кенә тора иде. Әмма мин үзем Сакмар тугаенда да, тау битләрендә дә, күпме каранып йөрсәм дә, аны очрата алмадым. Әллә юк, әллә эзли белмим?.. Ахрысы, танып та җиткерми торганмындыр. Иллә мәгәр бөтен нәрсә күкрәп үскән бу җылы-якты җирләрдә курай булырга тиеш бит, булмыйча мөмкин түгел!

Ахырда бу эшне, башта уйлаганча, бер агайдан үтенергә туры килде. Кешесе дә табылды. Базар көн саен Сакмар үрендәге бер авылдан килеп, минем кыз туганнарда атын тугарып торучы Хаҗиәхмәт исемле бер агай иде ул. Үзе урман каравылчысы икән... Менә бер килүендә мин шул агайдан, «базар чәен» изүен чишеп клиндер манып эчеп утырган чагында, иплә кенә сорадым:

– Әйт әле, Хаҗиәхмәт агай,供 сездә курай бармы?

– Курай? Нинди курай? – диде ул, аңлап бетермичә.

– Соң, уйный торган курай.

– Бар бугай бер-ике кешедә. Уйнаштыралар.

– Менә миңа да кирәк иде шул курай.

– Тарта беләсеңмени? – диде ул, елмаеп кына.

– Үзем өчен түгел. Бездә бер курайчы бар, шул кушкан иде. Табып китермәссеңме?.. Буш итмәм.

– Курайны бит аны, туган, сатар өчен ясамыйлар.

– Миңа ясаганы кирәкми. Кырда үскәне булса ярый... Үсәме ул сездә?..

– Үсә, күп үсә, бер колач кыркып китерергә була,—диде ул, кәефле генә елмаеп.

Аның болай җиңел генә әйтеп ташлавы мине бераз пошындырып та куйды. Колачы белән кыркып китергән курай ни төслерәк булыр икән?.. Эшкә ярый торганмы, түгелме?..

– Син, Хаҗиәхмәт агай, – дидем мин, шигемне сиздермәскә тырышып, – курайның уйнарга ярый торганын гына табып китер инде. Колачлап кирәкми, берничәү булса, шул җитәр... Сине өйрәтәсе юк, үзең дә беләсеңдер?!

– Ярар, синең өчен чагылда үскәнен генә табып китерермен, – диде Хаҗиәхмәт агай, пинжәк чабуы белән шабыр тир битен сөртә-сөртә. Аннары сыңар кулы белән генә ияген сыпырып куйды: «Аллаһе әкбәр!»

Әлбәттә, белә ул, белмиме соң?.. «Чагылда үскәнен» ди бит. Ягъни кояшка каршы тау битендә үскән курай була инде ул... Мин чамалыйм, бу курайның иң әгъләсе, өрмәс борын «Баранбай»ны суза башлый торганы булырга тиеш. Ишеткәнем дә бар, җылы туфрактан һәм эссе кояштан ярала икән ул чын курай! Шуңа күрә төпченеп тормадым, хәтта кайчан китерәсен дә сорамадым – Хаҗиәхмәт агай, барыбер, клиндерләп чәй эчәр өчен генә булса да, алдагы базарга килеп җитәчәк.

Ләкин атна арасында беркөнне Сакмардан су кереп кайтсам, өйнең тышкы бусагасында әлсерәп бер карчык утыра. Ерактан килгәнгә охшый, җирдә таягы да ята, үзе янып-көеп, тәмам бакыр төсенә кергән. Көннәре дә бу арада бик эссе тора, пешеп үләрлек... Мин ихтыярсыздан: «Кем бу әби, ни өчен мондый чакта йөри, саилче микән әллә?» – дип тә уйлап куйдым. Шул чакта кар базыннан салкын катык күтәреп, минем кече сеңел Һәммәюн килеп чыкты. Мин, аңа таба атлап, әкрен генә:

– Бу әби кем була? – дип сорадым.

– Хаҗиәхмәт агайның әсәе, Миңзифа әби, – диде Һәммәюн.

– Шулаймыни? – дидем мин аптырап, аннары карчык янына барып исәнләштем: – Исәнме, әби!

– Саумы, улым! – диде әби, ачык кына.

– Кем белән килдегез?

– Үзем генә.

– Әллә җәяү?

– Җәяү шул, – диде әби, елмаерга тырышып. Мин гаҗәпләнеп торган арада Һәммәюн әйтеп куйды:

– Әнә ул сиңа курайлар китергән.

Курайлар китергән?! Шушындый эсседә, унбиш чакрым җирдән, җәяүләп?! Бер мизгел ни әйтергә дә белмичә торгач, мин, ниһаять:

– Их, әбекәем! – дидем, ачынып. – Нигә болай азапланып йөрисең, ашыгыч нәрсә түгел бит ул. Хаҗиәхмәт агай үзе дә базар көнне китергән булыр иде!

– Улым килә алмый, печәнгә төштеләр...

– Шулаймыни?.. Җайсызрак килеп чыккан икән. Сезгә, карчык кешегә, бу эсседә йөрүләре бик авырдыр бит? Әби бер дә исе китмичә генә:

– Һи, йөрүмени бу! – диде. – Көн өстенә килеп китәбез без Куандыкка... Әле индә йөк тә була, буш кул белән килүнең бер азабы да юк. Менә әзрәк кенә хәл алам да кире китәм.

– Кире?.. Юк инде, әбекәем, бүген мин сезне җибәрмим. Хәзер менә чәй эчәрбез, аннары аш та өлгерер.

– Юк, булмый, миңа эчәргә ярамый әле, – диде карчык, кипкән иреннәрен ялап.

– Нишләп?

– Мин – ураза.

– Ураза?

– Әйе, Алла кабул итсен!

Тагын шул гына җитмәгән иде! Их, әби, әби, болай да элеп киптергән кебек булгансың бит, дидем мин эчемнән генә, ләкин үзенә әйтеп тормадым, чөнки әйтүдән мәгънә юк, һәм, килешмәс тә иде ул. Кешенең гомере буе тоткан уразасын бозып буламы соң?!

Минем карчык китергән курайларны тизрәк күрәсем килде. Аның артындарак чүпрәккә төрелгән озын бер нәрсә стенага сөялеп тора иде, шуңа ымлап сорадым:

– Шулмы инде сез китергән курайлар?

– Ийе, – диде карчык һәм борылып озын төргәкне алды. – Мә, үзең сүтеп кара.

Мин, чүгәләп, баш-башыннан бәйләгән бауларны чиштем дә чүпрәкне сүттем. Менә сиңа курайлар!.. Дөресрәге, курай булачак куралар... Җидәү икән үзләре, кайсы озын, кайсы кыскарак. Бик үткен пәке белән киселгән булса кирәк, очларында бернинди яньчелгән яки ярылган җире юк... Һәм шушы эче куыш, җип-җиңел, үтә кипкән үсемлек сабагы, кемдер ирененә тидереп, өрә башлагач та, үзенә сихри җан кергәндәй, өздереп уйнап җибәрергә тиеш!.. Гаҗәп, гаҗәп!.. Бәлки, безнең иң ерак бабаларыбыз әле үлән-тамыр җыеп туена башлаган чакларында ук бу үсемлекне өреп карарга, сызгыртырга өйрәнгәннәрдер. Бәлки, шул заманнардан ук инде сакланып килә торгандыр бу курай дигән иң табигый, иң кадерле уен коралы?! Ләкин менә хәзер аны ничек бәяләргә? Бәһасе бармы аның? Һәрхәлдә, бушка гына бирелми һәм алынмый торгандыр инде.

– Хаҗиәхмәт агай нәрсә әйтте соң? – дип сорадым мин карчыктан. Ул, билгеле, минем тел төбемне аңламады.

– Нәрсә әйтсен. Куралар әйбәт, диде, үзе дә ике көн эзләп йөрде.

– Рәхмәт инде аңа, бик рәхмәт!.. Тик, әби, мин боларның бәясен белмим бит әле... Күпме тора икән үзләре?

– Хода белсен! – дип кенә куйды карчык. Ул һаман да әле сүзнең нәрсә турында баруын аңлап бетерми иде, ахрысы... Шуннан соң мин, торып, кесәмнән утыз сумлык* чыгарып суздым.

– Аз булмасмы, әби?

Карчык сискәнгәндәй кинәт миңа ике кулын селтәде:

– Куй,кирәкми!

– Ничек инде кирәкми?.. Бушка гына булмый бит.

– Кирәкми, кирәкми! – диде карчык, кат-кат башын, кулын селкеп. – Кырда үскән кура өчен кеше акча аламыни, ошамаганны!..

– Кура өчен булмаса, хезмәтегез өчен алырга тиешсез. Хаҗиәхмәт агай вакытын әрәм итеп эзләп йөргән, сез менә җәяүләп китерә килгәнсез... Шуның өчен түлим мин, алыгыз!

– Юк, алмыйм! – диде карчык, кырт кисеп.

Мин шактый кыен хәлдә калдым. Кулымдагы акчаны карчыкка көчләп бирә дә алмыйм, кире кесәмә салсам да бик уңайсыз. Нишләргә соң?.. Карчыкны болай бернәрсәсез җибәрү һич тә ярый торган эш түгел, ничек кенә булса да аны бәхилләтергә кирәк. Ләкин ничек итеп?.. Ахырда, без, җыйнаулашып дигәндәй, карчыкны бүген китмәскә, авыз ачып, куна калырга

---

* Иске акча белән.

кыстый башладык. Карчык моңа да бик авырлык белән генә күнде. Балалар көтә, килен ачуланыр дип, һаман карышып маташты.

Балалар дигәннән, мин Хаҗиәхмәт агайның вак кына балалары күп булуын ишетеп белә идем. Шуннан күңелгә бер әйбәт уй килде: әлеге карчык баш тарткан акчаны Һәммәюнгә биреп, шул балаларга тәмле-төмледән ни дә булса, ә карчыкның үзенә чәй-шикәр алып, шуларның һәммәсен киткән чагында гына кулына тоттырырга куштым. Күчтәнәчтән инде әбиебез баш тартмас, шаять!

Кояш баегач, әби тоз тәмләп кенә авыз ачты, безнең белән утырып аш ашады, аннары бик күп итеп чәй эчте. Икенче көнне таң беленгәч үк торып, яңадан уразага керер өчен сәхәрен ашап, Сакмар үрендәге авылына кайтып киткән иде инде ул...

Санаулы көннәр тиз үтте. Минем дә китәр вакыт җитте. Юлга әзерләнгән чакта гына көтелмәгән бер мәшәкать чыкты: куралар минем чемоданга сыймый икән. Бөкләп сала торган әйбер түгел, нишләтергә үзләрен?.. Болай төреп бәйләп кенә алсаң, юлда йә сынар, йә изелер дип тә курыктым. Шуннан соң кыз туганнарның киңәше белән, май заводында әрҗә ясаучылардан тиз генә озын футляр сыман бер нәрсә эшләтеп алдым. Куралар шуңа шып кына кереп утырдылар.

Өйгә кайткач, Исмәгыйль абзыйны чакырып алып, тантаналы рәвештә дигәндәй, кураларны футлярлы-ние белән аңа тапшырдым. Абзый, үзе кушып җибәрсә дә, ышанып көтмәгән икән, күргәч бик куанды.

– Валлаһи газим, чын куралар бит болар, башкорт менә шулардан курай ясап тарта да инде! – диде ул, һәркайсын бик җентекләп карый-карый.

– Хәзер, Исмәгыйль абзый, син «тартканны» ишетәсе калды безгә, – дидем мин.

Ул әзрәк уйланып торды да ни өчендер башын кагып куйды:

– Белмим шул, белмим шул!..

Шактый гаҗәп тоелды миңа аның бу уйчан-сәер җавабы. Ничек юрарга моны дип торган арада, ул миннән кинәт кенә сорады:

– Ә күпме түләргә үзләренә?

Тагын каһәр суккан акча мәсьәләсе!.. Теге әби шикелле кырт кисеп кенә: «Юк, бер тиен дә кирәкми!» —дип әйтмәкче булган идем дә, кинәт Исмәгыйль абзыйны бераз шаяртасым килеп китте. Авыр гына сулаган булып:

– Кыйбатка төште бу куралар, Исмәгыйль абзый, һәркайсы утызар сум тора, – дидем.

Ләкин Исмәгыйль абзыйның моңа бер дә исе китмәде:

– Булыр, булыр!.. Сакмар кадәр җирдән кайткан ич алар! Нәрсә, хәзер үк түләргәме?

Мин ирексездән көлеп җибәрдем һәм теге әбинең бу кураларны иң эссе көндә, ураза килеш, унбиш чакрым җирдән җәяү китерә килеп тә бер тиен акча алмавын сөйләп бирдем.

Кечкенә бу вакыйга Исмәгыйль абзыйга шактый нык тәэсир итте булса кирәк, ул сүз таба алмагандай бераз дәшми торды, аннары, башын кагып: «Кара син, ә, изге бәндәләр дә бар икән!» – дип куйды. Шуннан соң кураларны, дөньяның иң кадерле бер нәрсәсе шикелле култык астына сак кына кыстырып, кат-кат рәхмәтен әйтеп китеп барды.

Әмма иң кызганыч, Исмәгыйль абзыйның ялан кураенда уйнаганын миңа ишетергә туры килмәде... «Белмим шул» дигән иде ул, курайларны миннән алып киткән чагында. Нидер сизенгән шикелле әйткән икән абзый кеше!.. Башта аның өен, урыны яңа төзелешкә кирәк булгач, шәһәрдән шактый еракка, каядыр Чыңгыз тирәсенә күчерделәр. Исмәгыйль абзый шуның мәшәкатенә кереп батты, ахрысы, бөтенләй күзгә күренми башлады. Аннары күпмедер вакыттан соң үзе дә каты авырып, көтмәгәндә генә үлеп киткән... Мин аның үлемен хәтта ишетми дә калдым. Кем әйтмешли, дөнья бу!..

Ләкин соңыннан инде, Исмәгыйль абзыйны искә төшергән чакта, теге курайларны ул нишләтте икән дип уйлап куйгалый идем. Бары күптән түгел генә ишетеп белдем:

Исмәгыйль абзыйдан калган барлык курайлар да Тел, әдәбият институтының музыка кабинетында саклана икән... Юри кызыксынып барып карадым. Моннан күп еллар элек Хаҗиәхмәт агай Сакмар буеның тау битләреннән кыркып алган, әнисе Миңзифа карчык җәяүләп Куандыкка китерә килгән, мин исә махсус футлярга салып алып кайткан курайлар кабинет шүрлегендә, иске газеталарга төрелгән килеш яталар. Сүтеп карагач, мин аларны таныдым. Исмәгыйль абзый һәркайсына өстән дүрт, астан бер тишек ясаган (нәкъ башкорт курае төсле итеп), кулыңа ал да сыздырып сузып җибәр!.. Әмма алар өнсезләр, сыздырып сузып җибәрердәй кешесе юк – әкияттәге теге малай кебек кешесен, кешесен кайдан табарга?!

*1970*

## Тынычлану

### I

...Көне... Иртәнге сәгатьтән үк бөркү эсселек үзен шулчаклы сиздерә дә башлар икән? Гаҗәп! Хәтта төне дә җиңеллек китермәде – суынырга өлгермәгән таш йортлардан, таш урамнардан, тузан исен аңкытып, һаман бөркелеп торды бу китмәскә килгән эсселек... Менә өч атна инде яңгыр тамганы юк. Температура көндезен утыздан артып китә, төннәрен егермедән дә төшми диярлек. Бер кат җәймә генә ябынып ятсаң да йоклап китә алмыйча азапланып бетәсең,

мендәреңнең салкынчарак җирен эзләп, аны кат-кат әйләндерергә мәҗбүр буласың. Кышкы суыктан да әшәкерәк икән ул бөркү эсселек!..

Гасыйм Сәләхович та шәрә килеш диярлек киң кроватеның читенә таянып, күзләрен дә ачарга иренеп, тик кенә утыра. Әллә ялкаулыктан, әллә хәлсезлектән? Икесе дә бардыр, ахрысы. Шулай да ялкаулыгы хәлсезлектән иде. Хәлсез булганга күрә аның кыл да кыймылдатасы килми иде. Чөнки ул бик начар йоклады, тирләде-пеште, әйләнде-тулганды – һаман да шул әшәке эсселек аркасында. Әмма сәбәп бер аңарда гына түгел иде шикелле... Төп сәбәп йөрәгендә булса кирәк – йөрәге таза түгел иде Гасыйм Сәләховичның...

Менә хәзер дә ул, кроватеннан кузгалырга кыймыйча, гүя йөрәгенә колак салып утыра. Нишли, ничегрәк «тота» ул үзен – тәндәге тере җан? Көйсезләнмиме, ялгышмыймы, хәрәкәт итүе ничегрәк? Шуны әйтергә кирәк, соңгы вакытларда йөрәге аның нәкъ менә йоклаганда яки уянгач үзен ныграк сиздерә башлады. Нидән, ни өчен?.. Бүгенгесен бөркү һава, начар йокыдан да күрергә мөмкин, ә башка көннәрдә? Бу хәл, билгеле, Гасыйм Сәләховичны борчый, кәефен боза, куркытып та куя иде. Ярамый бит болай ди ул, үз-үзенә җитди бер хәтәрне сизгәндәй, һәм, бөтен эшен ташлап, бүген үк врачка күренергә кирәк дигән карарга да килә. Ләкин шулай дисә дә ул бармый-күренми, чөнки эшеннән аерыла алмый, ә врачка бару үзе бер мәшәкать, аннары – иң гаҗәбе – йөрәк үзе дә тәмам тынычлана, «хуҗасын» бер дә диярлек борчымый башлый. Гүя «хуҗасының» эше, хәрәкәте, кайгысы аңа да күчә, ул да шуларга көйләнә, җайлаша, гүя үзен юри онытылып тора. Кыскасы, яраклаша белә йөрәк кешегә!

Тик менә кеше үзе еш кына йөрәге белән хисаплашмый. Борчый, җәберли, оныта бичараны еш кына! Сәбәпләре моның кырык төрле – санап кына чыгарлык та түгел. Гадәттә, кешенең үзен гаепләләр, «саклый белмәде йөрәген» диләр.

Әмма кеше үзе генә саклый ала микән соң аны? Иң элек кешенең үзен сакларга кирәк түгелме икән?

...Икенче атна инде, Гасыйм Сәләхович өч бүлмәле квартирасында япа-ялгыз яши. Хатыны больницада, улы Кырымга китте. Ирексездән төрлесен уйларга туры килә аңа ялгызлыкта. Бигрәк тә бүгенге шикелле иртәдән үк йөрәгенең хәлсезлеген сизеп торган чакта; ул бит бала түгел, үз хәленең җитдилеген аңлый торган кеше. Ярый, әллә ни булмасын да ди, ләкин шулай да... Һәм мондый минутларда Гасыйм Сәләховичның күңелендә хатыны белән улына карата ирексездән рәнҗү хисе уяна. Дөрес, сирәк уяна, әмма ялгызлыгын тирәнрәк сизгән һәм күңеленә төрле шомнар килгән чакта уянмыйча калмый иде. Белергә теләмиләр, тиешенчә игътибар итмиләр аның хәленә хатыны да, улы да... Эше шундый күп, киеренке, тыгыз бер вакытта аны тоттылар да ялгыз калдырдылар; хатыны Рәмзия ханым юк авыруын бар итеп

дигәндәй (белештермичә ашаса, кайчагында бавыры авырткалый иде), тикшертүләр ясар өчен спецклиникага кереп ятты, ә малае Радик, икенче курс студенты, имтиханнарын ашык-пошык биреп бетерде дә, ниндидер хөр егетләр һәм кызларга ияреп, Кырымга китеп барды. Гасыйм Сәләхович фикеренчә, клиникага кереп яту да, Кырымга китеп бару да һич тә зарури, кичектермәс эш түгел иде. Ә менә аның өчен хәзер чынлап та бик тыгыз вакыт. Уку елы төгәлләнеп килә, студентлардан имтиханнар кабул итү башланды, һәртөрле отчетлар язасы бар – бу вакытны кафедра мөдиренең урагөсте дияргә ярый. Иртәдән кичкә кадәр ул хәзер бушамаячак, ашау-эчү, яту-торуның да рәте-юне булмаячак, кыскасы, авырга киләчәк аңа. Шуны уйлап, ул хатынына әйтеп тә карады:

– Җаный, әллә бераз сабыр итеп торасыңмы?.. Нинди вакыт икәнен беләсең...

– Урын барында кереп ятарга кирәк, – диде Рәмзия ханым, өзеп кенә.

– Урын булыр иде әле...

– Ә минем көтәсем килми.

– Миңа авыр булачак бит, аңлыйсыңмы?.. Эшемнең иң тыгыз чагы.

– Син гел үзеңне генә кайгыртасың, минем сәламәтлегем турында уйлап та карамыйсың, эгоист син! – диде Рәмзия ханым, кинәт кыза ук башлап.

– Һич тә алай түгел, әнкәсе! – диде Гасыйм Сәләхович, хатынын тынычландырырга ашыгып. – Синең сәламәтлегең минем өчен дә бик кадерле. Сүз бит клиникага керүне беразга кичектерү турында гына бара. Тикшерүләр үтәр өчен генә булганда ашыкмаска да ярыйдыр инде.

– Ярыйдыр!.. Аны син беләсеңме, әллә минме?.. Аннары синең эштән бушаган чагыңны көтсәң, кабергә кергәнеңне дә сизми калырсың!.. Юк инде, җан кисәгем, клиникада урын бар чагында керәм дә ятам. Бала түгелсең, үз-үзеңне генә карый алырсың әле.

Билгеле, мондый катгый сүзләрдән соң бәхәсләшеп торуның мәгънәсе юк иде. Бигрәк тә авыру мәсьәләсендә, бигрәк тә хатының белән. Гомумән, хатынны сүз белән җиңеп булмый, юк, мөмкин түгел. Бөтен дәлилләрең аның «корыч» логикасына бәрелә дә чәлпәрәмә килә... Иң яхшысы чигенү, нервны бозмас өчен, йөрәкне саклар өчен бары тик чигенү, чигенү – калганы ник шунда чәнчелеп китми!..

Беренче мәртәбә генә түгел инде. Зуррак, җитдирәк мәсьәләләрдә дә аңа еш кына чигенергә туры килде. Гадәтенә керде дияргә ярый. Чигенсә, семьяда азмы-күпме татулык һәм тынычлык урнаша. Ә бу Гасыйм Сәләхович өчен иң зур ганимәт... Аннары ул мондый татулык урнашкан чакларда үзеннән шактый яшь, чибәр, әмма еш кына кәҗәләнергә ярата торган Рәмзиясен иркәли дә, сөя дә ала. Сирәк кенә булса да... Йә, аңа тагын ни кирәк?!

Тик шулай да әлеге рәнжү тойгысы аның күңелендә бервакытта да бетми диярлек. Яки бетеп торган төсле генә була да, берәр сәбәп чыгу белән яңадан көчәеп китә. Чөнки күп вакытта ул тынычлык хакына дөреслекне, гаделлекне корбан итеп чигенергә мәҗбүр була. Чөнки эгоизм җиңә, ә эгоизм белән килешүе бик-бик читен... Нәкъ менә бу очрактагы шикелле: Рәмзия керәм диде һәм керде дә ятты. Һичнигә карамастан... Урынсыз, мәгънәсез эгоизм түгелмени бу?! Инде хәзер Гасыйм абзаңа ике көннең берендә клиникага барып йөрү мәшәкате дә өстәлде. Рәнҗемәс җиреңнән рәнҗерсең! Ичмасам, куркуга салырлык берәр җитди авыруы булса иде! Юк, анысы да юк, үзе уйлап чыгарган шик кенә бар. Остарды кеше врачларның башын әйләндерергә!

Хатыны клиникага кереп ятканда улы Радик өйдә иде әле. Бик кызу имтиханнарын биреп йөри иде. Гасыйм Сәләхович та тынычлана төшкән иде, бөтенләй үк ялгыз түгел, өйдә сүз кушарга кеше бар, имтиханнарыннан бушагач, әнисе янына да баргалар дип ышанып тора иде. Ләкин Радик имтихан биреп бетерү белән, әтисенә бер сүз әйтмәстән, каядыр китәргә җыена да башлады. Билгеле, ата кеше аптырый калды: «Кая син болай?» – дип сорады ул улыннан. «Кырымга!» – диде малае гади генә итеп. Моны ишеткәч, Гасыйм Сәләхович бик гаҗәпләнде, хәтта ышанып бетмәгәндәй күпмедер ара сүз әйтә алмыйча торды, аннары сабырлыгын җуймаска тырышып, тагын иплә кенә сорады:

– Син, улым, әзрәк уйлап эшлисеңме моны?

– А в чем дело? – диде Радик, тыныч кына.

– Әниең больницада, минем эшем баштан ашкан. Ниткән Кырым ди ул шушындый чакта?

– Ә миңа отдыхать итәргә кирәкме-юкмы?

– Җәй озын, өлгерерсең... Ә хәзергә менә өйдә ял итәрсең.

– Ха! – диде егет, башын чөя биреп. – Көлке!.. Өйдә пенсионерлар да ял итми хәзер.

– Әниең чыккач, син дә китәрсең.

– Кая?

– Кая да булса. Әнә үзебезнең Идел буендагы студентлар лагерена.

– Юк, булмый! Мин Кырымны күрмәгән, только – Кырымга!

– Кырымны менә мин кырыктан узгач кына күрдем, – диде Гасыйм Сәләхович, тыелып кына.

Егет әтисенең бу минуттагы хәлен әллә сизми, әллә сизәргә теләми иде, шактый дорфа гына:

– Таптың чем гордиться! – диде дә бөтенләй аркасы белән үк борылды.

Гасыйм Сәләховичның эчендә кинәт дөрләп ачу кабынды. Малаеның җилкәсенә төшеп торган озын чәчләреннән урап алып, яңадан үзенә таба борасы килде. Ләкин ул тыелып калырга мәҗбүр булды – һәртөрле кискен хәрәкәт аның йөрәге өчен хәтәр иде. Шулай да ачуын сиздерерлек итеп, әкрен генә әйтте:

– Әгәр дә мин рөхсәт итмәсәм?

– Поздно, – диде егет, игътибарсыз гына. – Безнең билетлар уже кесәдә!

Радик күптән инде әтисеннән курыкмый иде. Нишләп курыксын, нишләтә ала ул аны? Берни дә эшләтә алмый, билгеле! Һәм берни дә эшләтә алмавын Гасыйм Сәләхович үзе дә бик яхшы белә иде. Кул күтәреп суга алмый ул студент егеткә, хәленнән дә килми, табигате дә сыйдырмый андый кыргыйлыкны. Үз гомерендә бер тапкыр, Радикка унберме-уникеме яшь чагында, бик ачуы килгәч, аның яңагына шәп кенә бер чәлтерәткән иде, анда да әнисе малаен кочаклап ярты көн үкерде, ә ул үзе шул эше өчен үкенеп бетә алмыйча күпме газапланып йөрде. Юк, ата-бабайлардан калган тәрбия «ысулы» бетте, онытылды, күптән юкка чыкты. Әлбәттә, Гасыйм Сәләхович хәзерге заман педагогы буларак, андый «ысулларның» бетүе белән һичшиксез килешә... Тик шулай да, үз малаең өчен генә булса да, берәр төрлесен саклау зарар да итмәс иде, бәлки. Менә Гасыймның үз атасы, мәрхүм, кыска саплы каеш чыбыркысын ишек яңагында гына элеп тота иде; әйткәнен тыңламасаң яки берәр әшәкелек эшләсәң, хәзер үк шул чыбыркысын чөйдән ала торган иде. «Әлә-лә-лә»не әйттерә иде ул зәһәр чыбыркы!.. Ләкин сыртка бик сирәк төшә иде бит, күп вакытта әтисе аны худка җибәрмичә кире элеп тә куя иде. Әмма чыбыркы бар, чыбыркыны онытырга ярамый! Нишләргә генә уйласаң да кылт итеп ул искә төшә торган иде.

Әлбәттә, хәзер чыбыркыны сагыну, Радик әйтмешли, үзе бер «көлке». Сатып алыйм дисәң дә юк ул хәзер. Тик менә аның урыны буш калды, шунысы кызганыч! Яхшы сүз, үгет-нәсихәт белән генә максатка ирешүе бик читен икән шул. «Тегенең» кебек үтемле түгел берсе дә.

Әмма... сүздән башка чара юк. Искерсә дә, үтмәсләнсә дә бердәнбер «ысул» шул гына... Гасыйм Сәләхович үзалдына озак кына уйланып торганнан соң, авыр гына сулап, малаеннан янә сорады:

– «Без» дигәнең кемнәр инде алар?

– Ну, Вовка Бобров, Гена Соловьев, Рита Козлова, Эмма Булатова, Марсель Ганеев... Вообщем, компания менә дигән!

– Студентлармы?

– В основном.

– Кем балалары соң алар болай ансат кына Кырымга очып китәргә?

– Это не имеет значения.

– Шулай да?.. Кем акчасына йөрмәкче буласыз?

– Мин синнән акча сорамыйм.

– Рәхмәт монысы өчен... Ә башкаларыгыз?

Радик аз гына икеләнеп торды, шулай да кыюланып әйтте:

– Башкаларның родительләре сорамасаң да бирәләр. Без унижения.

– Алай икән, – диде Гасыйм Сәләхович, кызара төшеп. – Күрәсең, бик байлардыр инде.

– Причем байлык! Просто понимают.

– Нәрсәне?

– Понимают наши потребности.

– Ах, шулаймыни?! Алар аңлый, мин аңламыйм икән!.. Хуш, шулай да булсын ди, ләкин бит сезнең потребностьне үтәр өчен бер аңлау гына җитми, аның өчен, хочешь не хочешь, 300–400 тәңкәңне кесәдән чыгарып та бирергә кирәк. Ә аны кайдан алырга? Ярый, минем хәлемнән килә, аңламасам да мин бирә алам. Ә башка кеше, мәсәлән, уборщица булып эшләүче берәр апа кадерле малаеның потребностен бик аңлый да, тик менә сезнең белән Кырымга җибәрергә хәленнән килми. Ул чагында нишли?

– Ялгышасың, па! Рита Козлова, биофак студенткасы, тоже уборщица кызы, ә безнең белән барачак. Вот так!

Гасыйм Сәләхович бер мәлгә аптырый калды, күңеленә шунда ук ямьсез уй да килде: «Берәр акчалы кешенең яшерен сөяркәседер әле ул юньсез кызый!» – ләкин бу уен тизрәк үзеннән куарга тырышты. Дөрес, булмый торган хәл түгел, ишеткәне дә бар андыйларны, тик бу очракта бик сак булырга кирәк иде. Онытырга ярамый, малае белән сөйләшә ул. Шулай да әйтмичә түзә алмады:

– Әгәр дә сезнең ул Ритагыз әнисе җилкәсендә шулай кылана икән, бу бик кызганыч! Бичара хатын аның өчен муеныннан бурычка баткандыр, үзе ипи белән суда гына утыра торгандыр... Юк, жестокий ул сезнең мактаулы кызыгыз! Миһербансыз!

Радик әтисенә нәфрәт белән диярлек карады.

– Син, па, абсолютно бернәрсә белмисең, син страшно артта калган кеше... Син просто невежа!

– Җитәр, малай актыгы! – диде Гасыйм Сәләхович, буыла язып. – Күземә күренмә, эзең булмасын монда!

– Яхшы, мин күренмәм, – диде егет һич исе дә китмичә һәм юри ашыкмыйча гына ишеккә таба юнәлде.

– Ләкин бел, – дип кычкырды әтисе аның артыннан. – Әниең белән сөйләшмичә торып, мин сине Кырымга түгел, Арчага да җибәрмим.

Егет ишетмәгән дә шикелле артына да борылып карамыйча чыкты да китте. Гасыйм Сәләхович, хәлсезләнеп, креслосына барып утырды. Сул кулын йөрәге өстенә куеп торды – йөрәк шактый каты тибә, ләкин авырту-чәнчү кебек нәрсә сиздерми иде. Шуңа күрә дару-мазар да кабып тормады.

Бераздан, тынычлана төшкәч, Гасыйм Сәләхович уйлана башлады. Кызганычка каршы, улының «бернәрсә белмисең» дигән сүзләрендә дөреслек юк түгел иде. Бигрәк тә тормыш мәсьәләсендә һәм хәзерге яшьләрне аңлауда... Нигә ул алай, тормыштан бөтенләй үк аерылган кеше дә түгел ләбаса!.. Бөтен үзгәрешләрне, яңалыкларны күреп тә тора шикелле... Ләкин үзе дә сизә, нәрсәнедер белеп җиткерми, аңлап җиткерми... Әйтик, кешеләрнең көнкүрешләрен... Сүз дә юк, кешеләр хәзер җиңелрәк тә, яхшырак та торалар, әмма шуның белән бергә аларның килерләре тигезләнеп беткәне юк бит әле. Аерма шактый зур, мәсәлән, профессор алган 450 – 500 сум айлыкны бик күпләр алмыйлар ич әле. Ә шулай да 70 сум ала торган вахтерның яки уборщицаның кызы сиксән сумлык импортный сапожкиларны киеп йөри... Ничек итеп моны эшләргә мөмкин? Дөньяның чыгымы күп – ничек кенә арттыра алалар?.. Баш җитәрлек түгел. Әйтәләр инде, кеше хәзер яшәргә остарды дип... Ни дигән сүз бу? Ничек аңларга ул «остаруны»? Берничә җирдә эшләүме? Хаклы һәм хаксыз премияләр алумы? Спекуляция белән шөгыльләнүме? Ниһаять, дәүләт милкен әкрен генә ташумы? Кайберәүләрнең әйтүенә караганда, «остару» дигән төшенчәгә бу «ысулларның» барысы да керә, имеш. Тик кеше кайда, кем булып эшләвенә карап, шул «ысулларның» берәрсен оста гына куллана икән. Ышансаң – ышан, ышанмасаң – юк, анысы синең эш. Гасыйм Сәләхович ул ысулларның берсен дә белми иде, әлбәттә. Бервакытта да бер тиен хәрам акча кермәде аңа. Хезмәт хакы аның һәрвакытта зур булды, иркен-мул гына яшәр өчен җитеп торды. Кайчандыр фән әһелләре халык арасында иң яхшы тәэмин ителгән катлаудан санала иде. Ә хәзер дөнья тигезләнеп бара шикелле... Һәрхәлдә, Гасыйм абзаң ашаган-эчкәнне, Гасыйм абзаң кигәнне һәркем диярлек ашый-эчә дә, кия дә. Хәтта уздырып та җибәрәләр; белеме юк, квалификациясе юк, ә машинасы бар. Әнә кая китте эшләр!

Хәерле булсын. Халыкның тормышы елдан-ел яхшыра икән, бу бик әйбәт, ул шулай булырга тиеш тә, тик әлеге хәрам «ысуллар» гына тамыр җәя күрмәсен иде. Гаять зарарлы нәрсә, кешене тәмам боза, җәмгыятьне имгәтә торган хәтәр нәрсә. Бигрәк тә яшьләргә күчә

башласа, бик начарга әйләнеп китүе мөмкин. Ә аның симптомнары юк түгел. Акча яратучы, акча артыннан куучы яшьләр студентлар арасында да бар, кызганычка каршы. Менә шушы нәрсә Гасыйм Сәләховичны аеруча борчый да инде. Чөнки аның белүенчә, яшьләрдәге акчага, малга комсызлык һич тә нужадан түгел (иске мәгънәсендәге нужа юк та ул), ә бик иртә, бик яшьли, әле кеше булып җитәргә дә өлгермәс борын, рәхәт, иркен яшәргә омтылудан гына килә. Менә үз улы белән бәхәс-талашуның бик ачык бер мисалы түгелмени?!

Әйе, улы аңа «син бернәрсә дә белмисең, па!» дигән гаеп ташлады. Ә ул бит менә утыз ел инде шул яшьләр арасында яши, шуларны укыта, тәрбияли. Нәрсәне белми соң ул? Яшьләрнең уйларын, хыялларын, теләкләрен, кыскасы, эчке рухи дөньяларынмы – шуны күздә тотып әйтәме Радик?.. Әйе, кырык ата баласының эчке дөньясын белеп бетерү гаять читен, мөмкин дә түгел диярлек. Бигрәк тә дүрт-биш ел саен алар алмашынып тора, берәүләре китә, икенчеләре килә (һәм гел генә үзгәреп килә), ә син һаман искечә каласың, һаман олая барасың, һәм табигый хәл – яшьләр гүя синнән ераклаша, син инде аларны томанлырак, ятрак итеп күрә башлыйсың. Әйе, белүләре бик читен. Әмма белмим дип әйтергә дә аның хакы юк. (Бу үз-үзенә каты һәм гаделсез хөкем чыгару булыр иде.) Иң элек аның өчен көн кебек ачык бер хакыйкать шуннан гыйбарәт ки, сугыш артыннан ук укырга килгән яшьләр белән хәзерге абитуриентлар арасында искиткеч зур аерма бар. Бөтен җәһәттән. Сугыштан соң килгәннәрнең күпчелеге буйга кечкенә, арык, өс-башлары өтек, үзләре бик күндәм, тыйнак булса, хәзер килүчеләр барысы да диярлек озын буйлы, тук чырайлы, зәвык белән киенгән, үз-үзләренә нык ышанган, таза, чибәр егетләр һәм кызлар. Тегеләрдә белем чамалы, ә дәрт-теләк бик көчле булса, боларда инде белем бик күп, шунлыктан, ахры, кыюлык та, әрсезлек тә җитәрлек. Тегеләр университет бинасына, изге бер җиргә аяк баскандай, эчләреннән дулкынланып һәм чын күңелдән шатланып керсәләр, хәзергеләр исә хис-хыялларга артык бирелмичә, бары үтеп китү турында гына борчылып, бик эшлекле кыяфәттә килеп керәләр. Дөрес, университетка керү, сугыштан соңгы елларга караганда, шактый авырлашты, каты конкурс аша үтәргә кирәк, әмма үтә алганнар инде үзләрен судагы балык кебек хис итә башлыйлар. Алар арасында бик сәләтле яшьләр дә бар – киләчәктә алардан чын фән эшлеклеләре дә, зур белгечләр дә, һичшиксез, чыгачак. Ихтимал, үзләрендә шундый көч-куәт барын сизгәнгә күрәдер дә алар бик хөр кыланалар, фикердә, сүздә хөр – менә хикмәт нәрсәдә! Гүя аларның үз башлары эшли, үз хакыйкатьләре бар. Гүя алар бөтен кыланышлары белән сиңа: «Әнә үз предметыңны бел, башкасында эшең булмасын», – дип әйтергә телиләр. Әлбәттә, мондый чакларда Гасыйм Сәләховичка бик ямансу булып китә торган иде. Ераклашу, ераклашу... шулай ук бу котылгысыз бер күренеш микәнни?! Хәтта үз балаңнан да!

Билгеле инде, ул Радикны Кырымга китүдән дә туктата алмады. Шул ук көнне клиникага барып, бу хакта сүз башлагач, Рәмзия ханым, гадәтенчә, уйлап-нитеп тормыйча гына:

– Ник тыясың, китсен! – диде. – Аңа да ял кирәк ич.

– Ләкин вакыты ул түгел бит! Син монда, мин анда ялгыз башым...

Рәмзия ханым шунда ук аның сүзен бүлде:

– Радикның ни гаебе бар соң, ул бит инде синең эшеңне эшләп йөрмәс.

– Эш андамыни, – диде Гасыйм Сәләхович, үртәлеп. – Үзем өчен әйтмим мин... Менә синең яныңа да кемдер килеп йөрергә тиеш бит әле.

– Ә мин эгоистка түгел, миңа кирәк булыр дип кенә Радикны иптәшләреннән аерырга һич тә теләмим.

– Ләкин моның авырлыгы миңа төшәчәк.

– Авыр булса син дә килмәссең... Ятармын әле шунда тол хатын кебек.

– Йа Хода! – дип куйды Гасыйм Сәләхович, ирексездән. – Ник син минем һәр сүземне кирегә тырнийсың да торасың? Менә киләм ич, тик миңа барысына да өлгерүе читен, аңлыйсыңмы шуны?

– Бик яхшы аңлыйм. Ләкин Радикны барыбер җибәрергә кирәк. Иптәшләреннән яхшы түгел, аның кай җире ким? Юк, барсын... Инде расходыннан курыксаң, акчасын да үзем рәтләп бирермен.

– Бусы тагын ни дигән сүз?

– Нигә, әллә мин белмимме?

– Нәрсәне?

– Синең саранлыгыңны... Шуңа күрә җибәрәсең килмидер әле.

– Их, Рәмзия, Рәмзия, ничек телең әйләнә! – диде Гасыйм Сәләхович тирән әрнү белән. – Аңлый алмыйм мин сине, җаный, әллә ни булды сиңа!

– Миңа берни дә булганы юк, – диде Рәмзия, гаепсез баладай елмаеп кына. – Ә менә син, дускай, чынлап та үзгәрдең... Картаясың, ахры...

– Ярый, шифаханә – сүз көрәштерү урыны түгел, китим булмаса, – диде Гасыйм Сәләхович, авыр гына урыныннан кузгалып. – Нәрсә китерим?

– Апельсин согы тапмассыңмы? Монда берәү хатынына китерде. Импортный икән... Аннары минем челтәрле бюстгалтерымны онытма әле, бик эссе була башлады. Шифоньерның уң тартмасында, өстә генә, күрерсең...

Гасыйм Сәләхович ярый-фәлән дип тормады, бары чарасыздан башын гына каккандай итте. Урамга чыккач, тел астына валидолын салды һәм иләсрәк бер хәлдә университетка таба

атлады. Әйтергә кирәк, соңгы вакытларда аңа гасабилану, нервы бозу бер дә ярамый иде. Шунда ук йөрәккә суга, башына каба, җитмәсә, хәтере дә кинәт кенә югалып торгалый. Кеше сүзен тиз генә аңламый, алдында яткан әйберне дә күрми башлый. Иртәрәк килә түгелме соң әле бу зәхмәтләр?! Аңа бит әле илле тугыз яшь кенә – хәзерге безнең заман өчен әллә ни күп тә түгел шикелле... Дөрес, өч елга якын ул фронтта йөрде, шуның михнәт-газапларын кичерде, берничә тапкыр бик хәтәр хәлләргә дә юлыккалады, ләкин шулай да, бер авыр контузияне исәпләмәгәндә, кул-аягы бөтен килеш әйләнеп кайтты. Баш та ярыйсы, йөрәк тә тап-таза иде әле ул чакларда. Тик соңгы дүрт-биш ел эчендә генә бирешә башлады. Күрәсең, еллар үзенекен итә, какшата әкрен генә кешене... Аннары безнең бу тынгысыз, киеренке заман кеше өчен шактый куркыныч бер нәрсә китереп чыгарды – стресс дип атыйлар аны. Кинәт башка төшкән зур хәсрәттән яки һич көтелмәгән берәр күңелсез эштән була диләр ул явызны. Хәтта көтелмәгән зур шатлыктан да була, имеш, хәер, анысын инде, шәт, татырга туры да килмәс. Ә менә һәртөрле ямьсез эштән туганың Гасыйм абзаңа татырга туры килгәне бар. Дөрес, алар вак стресслар иде, көчек кебекләре генә, ләкин барыбер каты «тешлиләр», каһәрләр!

Рәмзия белән бүгенге сөйләшү дә әнә шундый көчектәй кечкенә стресс иде, ә шулай да Гасыйм Сәләховичның кәефен чынлап торып бозар өчен җитә калды һәм бик авыр уйлар да кузгатты. Күпме бергә гомер иткән ир белән хатын бер-берсен аңламасыннар әле – гаҗәп бит бу... Гүя икесе ике телдә сөйләшәләр! Бигрәк тә соңгы ике-өч елда алар арасындагы каршылык, аңлаша алмау ни сәбәптәндер аеруча ешаеп китте. Гасыйм Сәләхович торып-торып аптырый: әллә бу хатыннар кырык биштән узгач, психически үзгәрә башлыйлар микән? Менә аның Рәмзиясе кебек... Ни әйтсәң, шуңа каршы төшә, һәр сүзеңне гел кирегә бора, берминди дәлилең аңа үтми дә, керми дә, юньләп тыңламый да әле ул сине! Шуның өстенә, Рәмзия аңардан унбер яшькә кечерәк, табигый инде, ул көйсезләнергә ярата, ул моны үзенең Ходай биргән хокукы дип саный, ә ир дигән кемсә, үзен яшь хатыннан ярattырасы килсә, һәрвакытта аның көенә торырга, аңа юл куярга тиеш. Гаделлекне, дөреслекне аяк астына салып булса да!

Иң аянычы тагын шул, Рәмзия ханым бөтен мәсьәләдә диярлек гел генә малае ягын каера, гел аны гына яклый. Дөресме, кирәкме, урынлымы – анда аның эше юк. Ул ана кеше, ул гына малаен аңлый, кызгана, ә син – деспот, син бары кысу, тыюны гына беләсең. Өстәвенә, җитмәсә, малае алдында еш кына көлеп тә, чынлап та, синең этиең инде шундыйрак та мондыйрак дип әйткәләп тә тора. (Әнә саранлыкны аңа таккан шикелле.) Ә малай яшь, кемнең хаклы-хаксыз булуын уйларлык акыл юк әле аңарда. Кем аның яклы, кем аңа файдалы – ул бары шуны гына белә. Табигый инде, ул күбрәк әнисенә елыша, үзенә кирәкне аның аша алырга тырыша. Ә этине

тыңламаска да була, этидән курку юк. Әнә шулай бер-берсеннән читләшә, ераклаша ата белән бала.

Аптырый иде Гасыйм Сәләхович бу хәлгә, төрлечә уйлап карый иде; әллә Рәмзиядә җиткән улын этисеннән әзрәк көнләшү дә бар микән? Үзенеке генә итәргә тырышу, үзенә генә карату?.. Буламы шундый нәрсә хатыннарда?.. Ә, бәлки, аның үзендә дә берәр гаеп бардыр, берәр төрле хаталык эшләгәндер дә, тик ул аны эш, мәшәкать аркасында сизмичә калгандыр. Хәзер инде әйтүе читен, ләкин шулай да бер эпизодны яхшы хәтерли, чөнки аңа әле күп вакыт та узмады. Радик унынчыны бетергән елны, әнисе белән шундый сүз булып алды. Дөресрәге, Рәмзия үзе башлап аңардан сорады:

– Син Радикның кем булуын теләр идең?

Гасыйм Сәләхович үзенең язу өстәлендә нидер эшләп утырган җиреннән генә бары:

– Кеше булуын, – диде.

Менә шушы сүзгә Рәмзия ханым бөтенләй күтәрелеп бәрелә язды. Яман кызып, иренә:

– Ахмак, идиот! – диде. – Мин синнән аны сорыйммыни?! Ул болай да кеше, дүрт аяклы хайван түгел!

«Хайванның ике аяклысы да була», – димәкче иде дә Гасыйм Сәләхович, ярый, тыелып кала белде. Рәмзия бит, асылда, улыбызны кайсы вузга кертәбез, кем итәбез, дип сорамакчы иде, ә ул акыллы башланып, әнә нәрсә әйтеп ташлады. Ә соңыннан Рәмзия ханым улы алдында ничә тапкыр «этиең кешегә дә санамый» дип кабатлады. Яхшы сүз дә кайчан баш казыгына әйләнә икән!

Әйе, сәер халык бу хатыннар җенесе, ике төпле, юк, өч төпле чемодан кебек, ниләр генә ятмыйдыр аның төпләрендә. Кайчагында шундый көтелмәгән берәр әкәмәт китереп чыгара, шаккатудан тәмам телсез каласың. Әнә бит Радикка акчаны да үзем табып бирермен ди! Күзен дә йоммый. Менә бу, ичмаса, «көлке!» Әйтерсең акчаны ул үзе таба!

Ярый, хәерле булсын! Барыбер хатын бик кирәк кеше, аңардан башка күңелсез, кызыксыз, әйләнәңдә шыксыз бушлык. Гаилә тормышына бер өйрәнгәч, башкача яшәү мөмкин дә түгел. Тик җайлаша, яраклаша белергә кирәк. Яраклаша белсәң, яшәп була, диләр күпне күргән агайлар!

Шул ук кичне Гасыйм Сәләхович малае алдына 250 сумны чыгарып салды да әйтте: «Менә сиңа акча, шуны җиткерергә тырыш, әйбәт кенә йөр, бәла-казага тарыма, кайда икәнеңне хәбәр итәрсең», – диде. Егет бер сүз дә дәшмәде, тик аның йөзеннән: «То-то, старик!» дигән сыман елмаю гына чагылып узды. Икенче көнне үк ул рюкзагын аркасына киеп, фотоаппаратын муенына асып, үзе кебек хөр, горур егетләр һәм аларны иңнәренә таяндырып йөртүче чалбарлы

кызлар белән бергә Кырымга – диңгез буендагы ташлар арасында кызынып ятарга китеп тә барды. Исән-сау гына йөри күрсеннәр инде, балакайлар! Исән йөрсәләр, башта акча сорап телеграммалары килер, аннары үзләре дә кояшта кара янган бәхетле кыяфәтләре белән кайтып төшәрләр.

**II**

...Көне... Булыр икән бу хәтле дә теңкәгә тигән эсселек! Өченче атнага китте бит инде, зур бер афәткә әйләнмәсә ярар иде. Игеннәр ни хәлдә икән, ялан-кырлар, болыннар? Терлекләр дә интегә торгандыр... Чакырып кына китерәсеңмени шифалы яңгырларны... Юк шул әле, юк кешедә андый кодрәт!

Ә шулай да кузгалырга вакыт, күптән вакыт. Хатыны белән малае өйдә булса, уянгач болай карават читендә изрәп, иренеп утырыр идемени?! Ә ялгыз булгач менә утыра, берәүдән дә тартынмый, уңайсызланмый —үзенә күрә бәләкәй генә бер хөрлек! Дөресен генә әйткәндә, ялгызлык ул кадәр начар нәрсә дә түгел. Күпмегәдер семья ыгы-зыгысыннан котылып торасың, әзрәк җан тынычлана, үзалдыңа уйланып була, тып-тын бүлмәдә дөньясын онытып эшләп яки укып утырып та була. Йә, начармыни ул?! Тик менә хәлсезлек кенә борчымасын иде.

Гасыйм Сәләхович ике карават арасындагы тумбочка өстендә яткан сәгатенә үрелеп карады. Сәгать тугыз иде инде. Мәлҗеп озаграк та утырган икән, хәерсез. Унда инде аңа кафедрада булырга кирәк.

Карават башыннан зәңгәр буйлы киң пижама чалбарын алып киде, аякларына артсыз чүәкләрен эләктереп кенә кухняга чыкты да, газ плитасына ут кабызып, чәй кайнатырга куйды. Ванна бүлмәсенә кергәч, башта кулы белән ияген, яңагын ышкып карады, ләкин бүгенгә ярар әле дип, кырынып тормады. Аннары краннан суны шактый гына агызып торып, битен-күзен юарга керешге. Су барыбер көткәнчә салкын ук булып килмәде, шулай да әйбәтләп юынгач, бераз хәл кереп, җиңеләеп калды. Шуннан соң яңадан кухняга кереп, тиз генә ашый-эчә башлады. Билгеле, ашау ягы аның хәзер мактанырлык түгел иде. Кичтән калган бер күкәй, искерәк булки белән ак май, бер чәшке куе гына сөтле чәй – завтрак дигәне әлегә менә шул. Аннары сәгать 12 ләрдә, ачыга төшкәч, университет буфетында ул тагын җиңелчә генә бер тамак ялгап алачак әле. Инде эш беткәч, кайтышлый, сәгать 3 – 4 ләрдә «Татар ашлары»на кереп, татарча токмач белән татарча пешерелгән ит кисәге ашап чыгачак. Тик кай көннәрдә токмач та, ит тә беткән була – ашап бетерә халык. Шуңа бераз кәефсезләнә, мыгырдана Гасыйм абзаң, ләкин башка җиргә кереп тормый, чөнки «Татар ашлары»ннан башка җирдә аңа ярарлык ризыгы юк та диярлек (хек белән дуңгызны, гафу итсеннәр, аның нәфесе кабул итми)... Кайтышлый юл өстендәге магазиннан сөт, эремчек, каймак кебек азыклар сатып ала да өендә

үзе бик әйбәтләп кенә сөтле токмач белән берәр төрле ботка пешереп ашый. Дөрес, карын канәгатьләнеп бетми бетүен, ләкин аның каравы йөрәгенә җиңел була. Аз ашасаң, күп яшәрсең, дигәннәр, имеш, безнең ерак бабайлар.

Гасыйм Сәләхович кыска җиңле саргылт күлмәген, яньчелә төшкән капрон эшләпәсен киеп һәм биге бозык иске зур портфелен күтәреп өеннән чыкканда сәгать ун тулып килә иде инде. Урамга чыгып, кояшка эләккәч тә ул аның агарган тимердәй кыздыруын тойды. Тизрәк күләгә якка күчте һәм ашыкмыйча гына урам буйлап атлады.

Бу урамнар буйлап Гасыйм Сәләхович менә утыз ел атлый инде. Шуның егерме елын кафедра мөдире буларак. Шулай уза гомер. Әмма ул үз эшеннән бик канәгать. Бөтен илгә исеме билгеле мәшһүр университет аның туган йортына әверелде дияргә дә ярый. Шунда үсте ул, шунда шактый зур дәрәҗәгә ирешәте һәм тормышын тәэмин итәрлек матди җирлекне дә, үзенә кирәк мәгънәви азыкны шунда тапты. Билгеле, төрле чаклар да булды, төрле авырлыкны кичерергә, төрле кыенлыкларны җиңәргә дә туры килде аңа. Шунсыз бер генә хезмәт тә булмый торгандыр инде безнең заманда. Шулай ук кайбер максатына да ирешә алмады: мәсәлән, күпме генә уйланса-борчылса да докторлык диссертациясен, ахры, яза алмыйча калды. Ул бит тарихчы, тарихчының эше гадәттә зур күләмле, тарих өлкәсендә чын фәнни хезмәт тудырыр һәм ниндидер яңа сүз әйтер өчен бик күп эзләнергә, тикшеренергә, уйланырга кирәк. Тарихчыдан да күп нәрсә таләп ителә хәзер. Ә ул яшьрәк, җегәрлерәк чакта, әйтик, илленче елларның башларында, тарих фәне өлкәсендә ниндидер бер торгынлык хөкем сөрә иде. Нидер көтү, тыелып тору, саклык күрсәтү хас иде тарихчыларга ул елларда. Менә ни өчен алар әзер программа нигезендә, тәкъдим ителгән дәреслекләр буенча студентларга лекцияләр укуны артыграк күрәләр иде. Җиңелрәк тә һәм хәвефсезрәк тә... Инде гыйльми дәрәҗә алыр өчен берәр хезмәт язарга кирәк булса, бу очракта да теманың отышлырагын, үтемлерәген сайларга тырышалар. Ә андый өстә генә яткан темалар һәрвакытта табыла, бар алар. (Фән әһелләре арасында «дежур тема» дигән төшенчә дә бар хәтта.)

Кыскасы, безнең Гасыйм Сәләхович та асылда әнә шул юл белән китте. Аспирантураны бетереп, университетта калгач, ул бик җигелеп һәм бик бирелеп студентлар белән шөгыльләнә башлады. Ә тора-бара кандидатлыгын яклап, ниһаять, кафедра мөдире булып алгач, инде укыту-тәрбия эшләре аның өчен төп хезмәт, төп йөк булып калды. Вакытын, көчен, акылын, хәтта сәламәтлеген дә беткәнче шуңа бирде. Үзе әйтмешли, университет белемле кадрлар әзерләп чыгаруга багышлады ул бар гомерен!

Әмма ләкин университет эчендә, шуның бер кешесе була торып, фәнни эшләрдән бөтенләй ваз кичү һич тә мөмкин түгел иде. Фәнни эшләр буенча кафедрада махсус план бар,

шунда кемнең нәрсә эшләргә тиешлеге ачык язылган һәм бу планны үтәүне тәэмин итү Гасыйм абзаң җилкәсендә, беренче нәүбәттә аңардан сорыйлар. Шул сәбәпле аңа бу очракта да, үзе утырып язуга караганда, башкаларны эшләтергә, башкалардан таләп итәргә туры килә иде. Иң мөһиме кафедра үтәсен, кафедра үтәсә аның да йөзе ак – мөдир җитәкчелек итә белгән, диячәкләр.

Хәер, ул үзе дә каләм тибрәтмичә тормады торуын. Редакцияләрнең заказлары буенча төрле даталарга карата мәкаләләр, теге яки бу темага багышланган брошюралар, чыккан китапларга рецензияләр, кыскасы, шуның кебек вак нәрсәләр шактый күп язылды. Билгеле, болар да хезмәт, әмма алар гына җитми, канәгатьләндерә алмый иде Гасыйм Сәләховичны. «Галим» дигән исемне акларлык, горурланып кулга тотарлык җитди зур хезмәте (калын китабы) юк иде аның... Һәм бу «юклык» аның җанын гел иги дә тора иде. Бигрәк тә соңгы елларда, чөнки соңгы 10 – 15 ел эчендә тарих фәне бездә дә шактый җанланып китте, бер-бер артлы яңа хезмәтләр чыга башлады; һәм аеруча күзгә ташланганы – яңа яшь галимнәр үсеп, калкып чыкты. Өлгер һәм кыю галимнәр! Менә шуларның барысын да уйласаң, чынлап торып борчылмыйча хәлең юк. Артта калу дигән нәрсә бик хәтәр, иртәме-соңмы исемеңә дә, дәрәҗәңә дә китереп суга ул!

Ә бит аның күптән уйлап йөргән теләк-хыялы да бар иде. «Татарларда эшче сыйныфының тууы һәм формалашуы» дигән темага зур бер хезмәт язмакчы иде. Шуңа дип ничәмә еллар буенча, Петр патша заманыннан алып дигәндәй, күпме материал җыйнады ул!.. Әнә калын папкаларга тутырып бәйләгән килеш ярты шкафны биләп яталар... Әмма, ни кызганыч, шуны утырып тәртипкә салырга, эшкә кертергә, бөтен бер язма хәленә китерергә вакыт та, мөмкинлек тә таба алмады. Мөдирлек йотты аны. Хәер... бу үзеңне юатыр өчен генә әйтелгән сылтау түгелме? Кешеләр икесен дә сыйдыра лабаса! Ихтимал, аңа җитди хезмәт өчен кайбер сыйфатлар, әйтик, көчле теләк, тәвәккәллек, ниһаять, үзеңне мәҗбүр итә белү җитмәгәндер. Шуның өстенә тагын фикерне эшләтү, хыялны җигү, сәләтеңне сынау – иҗатны шулар кабындыра бит инде. Ничек кенә булмасын, ул һаман сузды да сузды һәм суза торгач, иң ганимәт вакытын уздырып та җибәрде. Дәртле һәм җегәрле чагын!

...Үтте инде, булмады, дип, бәлки, тынычланырга да ярагандыр, болай да эше начар түгел иде, ләкин ул һич тә тынычлана алмады. Үкенү, кимсенү, хәтта оялу аның җанын борчыды да торды. Ә борчылу бик кирәк нәрсә икән, борчылу ахыр чиктә кешене кузгата да ала икән. Башкаларга да гыйбрәт бу!.. Кыскасы, моннан өч ел элек Гасыйм Сәләхович үзенең ял айларында беркая да китмичә, тотты да шул папкаларын сүтеп актара-карый башлады. Материал бик күп, бик кызыклы иде; борынгы лашманчылардан алып, Уралдагы чуен

коючылар, Каспийда балык тотучылар, Апшеронда нефть чыгаручылар, Донбасста күмер чабучыларга кадәр барысы да монда тупланган иде. Әмма бу хәтле материалны ничек кенә эшкәртеп чыгасы да, ничек итеп бер кулъязма хәленә китерәсе? Каян көч аласы да каян гына вакытын җиткерәсе? Мөмкин эшме бу?! Бер мәлгә яңадан күңеле сүрелеп, әллә ташларга микән дип тә уйлады Гасыйм Сәләхович, ләкин шулай да бер тотынгач аерыласы килмәде, кызганыч иде аерылуы, һичьюгы өлешчә файдаланып булмасмы дип, баш күтәрмичә утыра бирде һәм утыруның бер нәтиҗәсе булмыйча калмый ул. Менә Гасыйм абзаң да казына, уйлана торгач, шул тау чаклы материалдан йолкып алып, «Донбасста татар шахтерлары» дигән йөз кырык битлек монография сыман нәрсә дә язып ташлады. Өч ай эчендә! Соңыннан үзе дә гаҗәпләнә калды, шундый авыр башланган нәрсәне ничектер җиңел генә язды да чыкты. Донбасс бит татар кешесенә якын җир,—йөргән-таптаган, җырларына кергән җир, – бәлки, шул да ярдәм иткәндер. Нәтиҗәдә менә өч нөсхә итеп машинкада бастырылган, яңа таза папкага пөхтәләп салынган кулъязма аның өстәлендә ята! Бер дә икеләнмичә нәшриятка илт тә бир!

Әмма ләкин Гасыйм Сәләхович кулъязмасын йөгертеп илтергә ашыкмады. Нигә ашыгырга, бераз ятсын әле, күз алдында торсын, караштырыр, уйлаштырыр – кадерле, тансык бит әле ул аның үзенә дә! Ләкин анысыннан да битәр, кулъязманы кемнәндер укытып та алырга кирәк иде. Гәзитәдәге шикелле «свежий голова»дан һәм бик ышанычлы кешедән. Ягъни киңәш-күрсәтүләрен әйтерлек тә, шуның белән бергә автор теләгән аңларлык та булсын иде ул кеше!

Кем бар, кемгә ышанып бирергә мөмкин? Үз кафедрасындагы кешеләрнең берсе дә, билгеле, аның үтенечен кире какмаячак. Ләкин чынлап аны хөрмәт иткәне һәм чын сүзен әйтердәе кем булыр икән? Шактый уйланганнан соң, ул ахырда Идеал Ибәтович Шәйхиевне сайларга булды. Бу – кафедра профессоры, тарих фәннәре докторы, арада иң яшь галим һәм иң мөһиме – кайчандыр Гасыйм Сәләхович кул астында аспирантураны бетергән егет... Хәер, бу кадәресе бер яктан уңайсызрак та кебек, ләкин чынлабрак уйлаганда, моның һичбер гаебе дә юк шикелле... Шәйхиев аңа шәкерт булудан күптән узган инде, үзен бик баш иеп, бил бөгеп тә тормый ул. Әмма күңелендә аның элеккеге хәлфәсенә карата билгеле бер хөрмәт сакланган булырга тиеш. Димәк, хәерхаһлык күрсәтүенә дә ышанырга мөмкин.

Идеал Шәйхиев, гомумән, бик оригиналь шәхес. Искиткеч тырыш, басылып утыручы, бер генә минутын да бушка әрәм итмәс. (Университет китапханәсеннән хезмәткәрләр утларны сүндереп кумыйча, ул чыкмый да торган иде.) Коточкыч хәтер үзендә, тарихчы белергә тиешле йөзләрчә исемнәрне һәм даталарны ул күңелдән генә әйтә дә бирә. Башка ягы ничектер, әмма башы аның чынлап та идеальный корылган дияргә була. Уйлап карагыз, бүтәннәр утыз елда да үтә алмаган юлны Идеал Шәйхиев ун-унике ел эчендә үтте дә китте: аспирантураны

кандидатлык диссертациясен яклап бетерде, ә алты-җиде ел узуга докторлыгын яклап, әнә профессор да булды һәм үзенең моңа һич тә исе китмәде, киресенчә, шулай булырга тиеш ул дигән шикелле генә карады. Күпләр аны артык һавалы булуда гаеплиләр, хәлбуки бу аның үз-үзенә бик нык ышанудан килгән гадәти тотышы иде. Гомумән, ул аз сүзле кеше, тигез, тыныч холыклы, сүз көрәштерергә, шаулап бәхәсләшергә яратмый, әмма инде сөйләргә туры килсә, бик төпләп, дәлилләп, сеңдерерлек итеп үзенекен әйтә дә белә. Логика гаҗәп! Аның өчен фән бар, ул фәндә яши, өзлексез казына, эзләнә, өйрәнә һәм яза, күп яза. Үзәк журналларда аның мәкаләләре әледән-әле чыгып тора. (Тарихтагы тикшеренә торган төп өлкәсе – XVIII һәм XIX гасырларда Рус самодержавиесенең колониаль сәясәте, шул нигездә капитализмның үсү-җәелүе һәм бу процесска Россия эчендәге төрле халыкларның тартылуы.) Хәзер инде тугандаш республикаларда да профессор Идеал Шәйхиев дигән исемне яхшы ук беләләр. Әйе, һаваланырга хакы да бар егетнең!

Яшь галимнең бу уңышлары Гасыйм Сәләховичта ирексездән беркадәр көнчелек уятса да, ул шуңа карамастан аның өчен куана иде. Ярый, ул үзе кандидат кына булсын, фәндә зур казанышларга да ирешмәсен ди, ләкин дә бит Идеал аның шәкерте, аның кул астында шәп галим булып өлгерде бит әле Яңа бистә малае! (Шәйхиев үзе бу хакта ничегрәк уйлый торгандыр, ул кадәресен Гасыйм Сәләхович белми иде, әлбәттә.) Алай гына да түгел, Гасыйм абзаң нәкъ менә хәлфәләрчә Шәйхиевне үз урынына кафедра мөдире булып калачак бердәнбер лаек кеше итеп тә саный иде. Тик Шәйхиев үзе генә ни өчендер моңарчы мөдирлеккә бер дә омтылыш сиздермәде. Ихтимал, аңа мәшәкатьле эшкә башын тыкканчы, фән белән шөгыльләнү һәм лекцияләр укып кына йөрү файдалырактыр, шуны артыграк күрәдер, әмма Гасыйм абзый тагын үзенең беркатлылыгы белән моны шәкертнең хәлфәсенә конкурент булырга теләмәве дип кенә карый иде. Һәм, дөресен генә әйткәндә, яшь галимнең мөдирлеккә ашкынып тормавы Гасыйм Сәләхович өчен бик тә әйбәт иде. Һичьюгы тагын бер дүрт ел мөдирлектән төшмичә утырырга кирәк иде әле аңа!

Озын сүзнең кыскасы, Гасыйм Сәләхович үзенең кульязмасын Идеал Шәйхиевтән укытырга булды. Иң кулай кеше шул, әгәр баш тартмаса. Хәер, ни өчен баш тартырга тиеш?.. Юк, тартмас, күрсәтмәс ул андый сансызлыкны кафедра мөдире Гасыйм абзасына! Тик җаен-форсатын туры китереп, дәрәҗәне төшермичә генә сөйләшергә кирәк үзе белән, һәм Шәйхиев аның янына кереп, бер сөйләшеп утырганда, Гасыйм Сәләхович сүз ахырында гына сорады аңардан:

– Идеал Ибәтович, әгәр мин сезгә бер эшемне карап чыгарга бирсәм, ничек, вакытыгыз булырмы?

Һәрвакыттагыча яхшы кара костюм, чиста ак күлмәк кигән, арык кына урта буйлы, какча битле, әмма калку маңгайлы Шәйхиев үз нәүбәтендә тыныч кына сорады:

– Нәрсә ул?

– Донбасс турында... Дөресрәге, татарларның Донбасс шахталарына кай заманда бара башлаулары турында, ничек дим, тарихи бер күзәтү... Исеме дә «Донбасста татар шахтерлары» дип атала. Күләме зур түгел, вакытыгызны күп алмас дип уйлыйм.

Шәйхиев дәшми торыбрак тагын сорады:

– Минем бурыч нидән гыйбарәт?

– Сездән мин, Идеал туган, бер генә нәрсә ишетәсем килә: кульязма шушы хәлендә нәшриятка тәкъдим итәрлекме-түгелме?

Шәйхиев көлемсерәп куйды:

– Нәшрият үзенчә хөкем итәчәк.

– Әлбәттә... Сүз бары тәкъдим итеп карау турында гына бара. Мин моны үзем дә эшли алам, билгеле, ләкин сез бит нәшрият белән күбрәк эш иткән кеше, аларның таләпләрен яхшырак беләсез!

Шәйхиев бераз гына уйланып торды. Аннары:

– Яхшы, – диде һәм папканы кулына алды. – Карап чыгармын.

– Рәхмәт, туган! – диде Гасыйм Сәләхович һәм шуның белән сүз дә бетте. Шактый ук коры килеп чыкты бу сөйләшү, шул сәбәпле киңәшегез-фәлән булса дип тә сүз озынайтып тормады. Тик Шәйхиев чыгып киткәч кенә артыннан көрсенеп: «Үзенә күрә түгел егет!» – дип калды.

Ә өч көннән соң яшь профессор кульязманы китереп тә бирде. (Эшне тиз тотарга ярата иде ул.) Папканы «Дипломат» дип йөртелгән өр-яңа сай гына тартмадан чыгарып:

– Укыдым, – диде. – Минемчә, бу хезмәтегезне нәшриятка тәкъдим итәргә ярый, Гасыйм Сәләхович!

– Рәхмәт, туган!.. Биреп карыйм алайса...

– Бирегез.

Гасыйм Сәләхович әз генә сүз табалмыйчарак торды.

– Бәлки, замечаниеләрегез бардыр, Идеал Ибәтович? Мин, рәхәтләнеп дигәндәй, әзер...

Шәйхиев бик мәгънәле генә итеп елмайды.

– Сез бит миннән бер генә нәрсәне ишетергә теләдегез, Гасыйм Сәләхович? Шулай түгелме?

– Анысы шулай инде... Мин канәгать, тагын бер мәртәбә рәхмәт сезгә!

Аннары әзрәк вакытны сузар өчен генә аны-моны сөйләшкәләп утырдылар. Ә бер биш-алты минуттан Шәйхиев каядыр ашыккандай сәгатенә карап алды да, торып, баш кагып кына чыгып китте. Күрәсең, бу сөйләшү дә Гасыйм Сәләхович көткәнчә булып чыкмады. Янәсе ул бер генә нәрсә ишетергә теләгән?! Бу кадәр коры, рәсми булыр икән кеше! Бигрәк тә аның мәгънәле генә елмаюы Гасыйм Сәләховичка бер дә ошамады. Хәтта билгесез бер борчылу да тудырды.

Әмма соңыннан Шәйхиевнең «тәкъдим итәргә ярый» диюе бушка булып чыкмады. Кулъязманы нәшриятта кабул иттеләр, бик озакка сузмыйча укыдылар, ошаттылар, кемнәндер рецензия дә яздырып алдылар. Гүя кулъязма тышындагы исеме белән үк үзенә юл ачты һәм менә бер ел үтүгә, күптән түгел, дөньяга басылып та чыкты. Йөз егерме битлек, катыргы тышлы, кулга тотарлык бер китап – һәм бу китап Гасыйм Сәләховичка чын канәгатьләнү белән бергә рухи бер җиңеллек тә китерде. Ниһаять, җаны тынычланып, үзенә ышанычы артып, өметләре яңадан кабынгандай булды. Ә бит аның яшенә җиткән һәм кафедра мөдире булып торган кеше өчен моның әһәмияте кечкенә түгел – баскан урынында әле селкенмичә нык торырга була дигән сүз!

Билгеле, Идеал Шәйхиевкә дә аның ышанычы яңадан артты, яңадан ныгыды. Теге вакытта егетнең сәер елмаюына әһәмият биргән булып, юкка гына борчылган икән. Просто балалык! Асылда, дөрес бәяли белгән яшь галим, аның хезмәтен тәкъдим итәргә ярый, дип, бик дөрес, бик урынлы әйткән. Кыскасы, Гасыйм Сәләховичның рәхмәте зур аңа!

Ул эчке кичерешләрен тышка чыгармаска өйрәнгән кеше. Шулай да бу юлы аңа куанычын яшерү җиңел булмады. Сүзләреннән сизелмәсә дә, моны аның йөзеннән күрергә мөмкин иде; гадәттә сытыграк чырайлы шешенке бите ничектер язылa һәм яктыра төшкәндәй булды. Аннары китап магазинга чыккач та, берьюлы утыз данә сатып алып, шуларны кыска гына автограф белән кафедра кешеләренә һәм якын танышларына өләште. Бу да үзенә күрә шатлыгы белән уртаклашу иде. Барысы да рәхмәтләрен әйттеләр, кулын кыстылар. Ә соңрак аларның кайберләреннән ул «Бик кызыксынып укыдым», яки «Китабыгыз миңа бик ошады», яки «Бик кирәкле нәрсә язгансыз, Гасыйм Сәләхович» дигән кебек сүзләр дә ишеткәләде. Автор кеше бу мактау сүзләрен шактый ук ышанып кабул итте, чөнки аның фикеренчә, бер дә ошамаган китап турында берәү дә алай ялганлап әйтмәс, хәтта комплимент итеп тә.

...Тик иң теләгән кешесе Идеал Шәйхиевкә китабын тапшыра алганы юк әле. Китап сатуга чыккан көннәрдә генә яшь галим персональ чакыру буенча Болгариягә китеп барды. Шуннан соң өч атна чамасы вакыт үтеп китте, күптән кайткан да булырга тиеш, ә менә Гасыйм абзасына ни сәбәптер килеп күренгәне юк. Бу хәл Гасыйм Сәләховичны беркадәр гаҗәпләндерә

дә, уйландыра да, ләкин үзе башлап аның өенә шалтыратырга уңайсызлана да иде. Шәйхиев берәр ерак җирдән кайтса, кафедрага кереп, исәнләшеп, күргәннәрен кыскача гына сөйләп чыга торган иде. Бу юлы ни үзе, ни хәбәре – гаҗәп! Теләсәң ни уйла!.. Шулай итеп, Гасыйм Сәләхович үзенең зур рәхмәтен һәм хөрмәтен титул битенә язып, махсус әзерләп куйган китабын аңа тапшыра алмыйча менә күпме вакыт портфелендә саклап йөртергә мәҗбүр... Кызыксызрак килеп чыкты әле бу, хәерсез!.. Хәзер инде аның шатлыгы да, дәрте дә шактый сүрелде. Кәефе дә шәп түгел... Ләкин ул китабын барыбер тапшырыр, бүген булмаса – иртәгә!

**III**

Университетның таш идәнле караңгырак вестибюленә килеп кергәч тә, Гасыйм Сәләхович җиңеләеп бер сулап куйды. Тыштагы эсселек монда юк, һава монда салкынчарак иде. Тәненнән бигрәк йөрәге белән сизде ул моны.

Имтиханнар бетеп, студентларның таралыр вакыты җитсә дә, университет коридорларында шаулашып, ашыгып йөрүче яшьләр күп иде әле. Билгеле, аларның барысында да хәзер йә эшкә, йә ялга китү кайгысы – шуның белән мәш килеп йөриләр. Ә гомумән исә, бу коридорларның бушап торган чаклары булмый да диярлек. Менә озакламый читтән торып укучылар киләчәк, аннары университетка керергә теләүче яшь кенә егетләр һәм кызлар монда әйләнә-тулгана башлаячак, ә күпмедер вакыттан соң йөзләренә өмет, шик, каушау чыккан шул яшь абитуриентлар аудитория ишек төпләренә җыелачак. Елдан-ел кабатлана бу хәрәкәт, университет күпме яшәсә, шулчаклы дәвам итә ул! Кайберәүләр яшь кенә студент булып керәләр дә ап-ак сакаллы галим булып чыгып китәләр моннан – вакыт һәм язмышлар әнә шулай өзлексез агып һәм алмашынып тормакта бу таш бина эчендә!

...Кояшлы көн яктысыннан килеп кергәч, аеруча караңгырак булып күренгән озын коридор буйлап Гасыйм Сәләхович үзенең кафедрасына таба атлады. Очраган танышлары белән баш кагып кына исәнләшеп узды. Инде үз бүлмәсенә кереп, капрон эшләпәсен чөйгә элеп, өстәле янына килгәч, ул башта таза, иркен креслосында җәелә биреп, бераз хәл алып, тик кенә утырды. Бер-ике генә минут шулай тугарылып утыруга ул соңгы вакытларда гына ничектер гадәтләнеп киткән иде. Күрәсең, бу аның йөрәге белән бәйләнгәндер инде. Аннары гына ул эшкә күчә, уйлый һәм хәрәкәт итә башлый һәм тиз арада йөрәк тә, хәлсезлек тә – барысы да онытыла. Бары тик эш кенә кала, ә эш сыналган дәва, яшәтә ул кешене!

Алгы бүлмәдә утыручы лаборант кыз көндәге тәртип буенча бүген дә яңа гәзитәләрне аның өстәленә кертеп куйган иде. Гасыйм Сәләхович, эше бик тыгыз булмаса, аларны шунда ук караштырып чыга, инде вакыты юк икән, барысын бөкләп портфеленә тыга да, өенә кайткач, ашыкмыйча иркенләп карый.

Бүген исә ул гәзитәләрне хәзер үк ачып, күздән бер кичерергә булды. Башта, билгеле, Мәскәү гәзитәләрен карап чыкты. Алардагы кыскарак хәбәрләрне тиз генә укыштырды да үзе өчен әһәмиятле булган җитдирәк мәкаләләрне кайткач укырга дип калдырды. Шуннан соң үзебезнең гәзитәләргә күчте. Гадәтенчә, ул аларны ахыргы битеннән карый башлый – төрле яңалыклар, кызыклы хәбәрләр күбрәк шушы биттә табыла. Шулай ук бу биттә ара-тирә булгалап торган кара сызыклар эчендәге кайгылы белдерү дә аның игътибарын җәлеп итмичә калмый —кайчагында күз күргән яки колак ишеткән кешеләр дә очрап куя бу кара сызыклар эчендә. Әмма Гасыйм Сәләхович үзе үлем турында уйларга да, сөйләргә дә бер дә яратмый.

...Инде менә «Татарстан»ның икенче, өченче битләре. Чит ил хәбәрләре, хуҗалыкка караган мәкаләләр, алдынгыларга багышланган язмалар... Тукта, ә бусы нәрсә?.. «Донбасста татарлар». Гаҗәп таныш исем ич бу!.. Ә исемнән өстәрәк, ваграк хәрефләр белән бер читтә «Тәнкыйть-библиография» диеп тә куелган. Димәк, рецензия, аның китабы турында рецензия бу! Ә кем язган?.. Гасыйм Сәләхович тиз генә мәкаләнең ахырына күз төшерде: профессор Идеал Шәйхиев! Алай-й икән, хөрмәтле Идеал Шәйхиев аның китабы турында рецензия язып чыккан икән ләбаса! Рәхмәт төшкере!

Гасыйм Сәләхович гәзитәне урталай бөкләп, алдына салып, кечерәк подвал итеп басылган мәкаләне бик игътибар белән ашыкмыйча гына укырга кереште. Баш күтәрмичә һәр җөмләсен, һәр сүзен, хәтта юллар арасында әйтелмичә калганын да аңларга тырышып укыды. Кайбер төшләрен кайтадан укып карады. Ниһаять, укып бетерде һәм бик нык уйга калды Гасыйм абзаң!.. Хуш, ничегрәк аңларга бу мәкаләне? Китапка ниндирәк бәя бирә хөрмәтле рецензент? Мактыймы, яманлыймы?.. Хәер, монда артык юрап маташыр нәрсә юк та шикелле... Әгәр аның катлаулы җөмләләре белән бик фәнчә итәргә тырышып язганнарын гадиләштереп, кеше аңларлык телгә күчерсәң, түбәндәге төп нәтиҗә үзеннән-үзе диярлек килә дә чыга: ягъни «Донбасста татар шахтерлары» дигән бу әсәр чын мәгънәсендә фәнни хезмәт түгел, имеш! Менә шул. Дөрес, Шәйхиев китапны яманламый. Киресенчә, укыр өчен кызыклы, гыйбрәтле китап, ди. Тик хикмәт шунда, имеш, бу китап, башлыча, җирсезлектән интеккән ярлы татар агайларының Донбасска отхожый эшкә китәргә мәҗбүр булуларын бик тәфсилләп язган бер беллетристика сыман нәрсә булып чыккан, янәсе... Чын фәнни хезмәт булыр өчен аңа теге җитми, бу җитми, имеш, анысы онытылган, монысы ачылмаган, анализ йомшак, гомумиләштерү зәгыйфь, кыскасы, китапка карата рецензиядән әнә шуның кебек тәнкыйть сүзләрен күп чүпләргә була. Дөрес, фәннәр докторы үзенең каты хөкемен мөмкин кадәр такт саклап, аябрак әйтергә тырыша, моның өчен еш кына «хәлбуки», «безгә калса», «кызганычка каршы» кебек буфер ролен үтәрдәй сүзләр дә куллана, әмма ләкин күпме генә йомшартып

маташмасын, төп нәтиҗә һаман шул бернәрсәгә кайтып кала: Гасыйм абзаңның бу хезмәте хәзерге фән таләпләренә җавап бирүдән ерак тора икән әле... Менә шулай ул, кем, автор иптәш!

...Озак утырды Гасыйм Сәләхович алдында яткан гәзитәгә текәлеп, һәм ул бу минуттагы хәлен ничек кенә дип атарга да белми иде. Әллә авыр аңа, әллә түгел, әллә инде барыбер?! Хәер, барыбер булуы һич мөмкин түгел, чөнки рецензияне иң ышанган кешесе язган, һәм шик тә юк ки, аның зарарына язган. Әмма шул ук вакытта ул Идеал Шәйхиевкә бертөрле дә гаеп ташлый алмый иде. Менә нәрсә аны тирән бер аптырауга төшерде. Йә, ничек итеп, нәрсәдә гаепли ала ул аны?.. Икейөзлелектәме?.. Әйе, Шәйхиев кульязманы укыганнан соң менә монда язып чыккан фикерләренең берсен дә аңа әйтмәгән иде. Ләкин бит ул үзенең шулчакта биргән киңәшенә каршы да килми ич! Кульязманы нәшриятка тапшырырга да, бастырып чыгарырга яраган, хәтта әнә китапның укыр өчен кызыклы, гыйбрәтле булуын да әйткән! Кайда монда икейөзлелек?.. Юк, тагып булмый аңа бу гаепне!.. Тик шул гына, теге вакытта үзенең чын, асыл фикерләрен әйтеп торуны кирәк дип тапмаган. Ни өчен? Әйе, ни өчен, нигә яшергән? Бәлки, ул кульязманы сүтеп ташларга теләмәгәндер (кызганган Гасыйм абзасын!), ә, бәлки, әйтеп торудан файда юк, бу карттан шуннан да артыгын көтеп булмый дип уйлагандыр. Бик мөмкин моның шулай булуы... Теге вакытта аның йөзендә чагылган мәгънәле елмаю да нәкъ менә шуны раслый түгелме?!

Кинәт күңеленә килгән бу уйдан Гасыйм Сәләхович үзен ничектер бик кечерәеп калган шикелле хис итте. Нindидер мескенлек, нәүмизлек аның җанын биләп алды. Күңелендә ирексездән яшь галимгә рәнҗү хисе уянды. Ни әйтсәң дә, Гасыйм абзасы аны кайчандыр укыткан кеше бит әле, остазы, хәлфә хакы бар бит әле, аңардан башка бүтән тәнкыйть итүче табылмас идемени? Ә ул, профессор, яшь галим, бик югарыдан торып: «Җитте сиңа, абзый, иярдән төшәргә вакыт!» – дип әйтә кебек.

Хәер, ник әйтмәсен?.. Хәлфә-шәкерт төшенчәсе хәзер инде бер анахронизмга әйләнеп бара. Алар, Шәйхиевләр килә, хәтәр килә, юл бирмәсәң, күрәләтә таптап та узарлар. Нәрсә ул аерым кеше язмышы! Алар өчен иң югары максат – фән, ә фән ул һәртөрле исәп-хисаплардан өстен торырга тиеш. Йә, алар хаклы түгелме?! Юк, картайдың син, картайдың, хөрмәтле мөдир!

Гасыйм Сәләховичның хәзерге минуттагы рухи хәлен бер генә сүз белән билгеләргә була, бу – апатия. Дөньясына, эшенә, үзенә, нindидер Шәйхиевләргә – барысына да салкын битарафлык. Кызыксыз, мәгънәсез, кирәксез... Шушы минутта, шушы сәгатьтә... Аннары үтәр, иншалла, үтәр! Тик болай бөкрәеп утырмаска, торырга, хәрәкәтләнергә кирәк. Йөрәгенә дә хәрәкәт кирәк... Иң яхшысы, чыгып китеп, бераз йөреп кайту – монда хәзергә әле ашыгыч эше дә юк. Кешеләр килеп кергәләгәнче – югыйсә тегесе яки бусы килеп керер дә хәл-әхвәл

сорашкан булыр, гәзитәне укыганнары гаҗәпләнүләрен, хөрмәтле Шәйхиев белән килешеп бетмәүләрен белдергән булырлар... Юк, юк, кирәкми, Алла хакы өчен икейөзлеләнмәсеннәр! Берсенеке дә бик җиткән!

Гасыйм Сәләхович сәгатенә карап алды – унике тулган икән инде. Халыкның нәкъ мыжгыган чагы... Ул алдында яткан гәзитәне бөкләп, башкалары өстенә куйды, ләкин кеше күрмәсен дип, ахры, кире алып, өстәл тартмасына салды. Аннары барып, чөйдән калай шикелле яньчелеп каткан эшләпәсен алып киде. Ах, белсәгез иде аның бу капроннан туйганын! Юк бит электәге башка сихәтле салам эшләпә!..

Портфелен алып, кабинетыннан чыккач, алгы бүлмәдә утыручы лаборант кызга узышлый гына: «Мин клиникага киттем, бер-ике сәгатьтән кайтырмын», – диде. Кыз аның хәлен аңлагандай башын кагып: «Ярый, Гасыйм абый, ярый!» – дип калды. Ә Гасыйм абзасы инде шунда ук үкенеп тә куйды: «Нигә әле мин кая баруымны әйтеп торам?.. Сораган бер кешегә клиникага китте дияр, ә сораучы эченнән генә: «Әһә, Шәйхиев тәнкыйтен күтәрә алмаган икән», – дип уйлар... Минем кебек тә хәйлә белмәс кеше бар микән?!» Ләкин шуның артыннан ук ул үзен тиргәргә дә тотынды: «Нишләп әле мин җыен чепухага игътибар итә башладым? Хатынның клиникада ятканын белмиләрме соң... Юк белән баш ватасың, карт тиле!»

Дөрес, хатын янына барырга бик иртә иде әле. Анда сәгать дүрттән соң гына кертә башлыйлар. Хәер, Рәмзия ханым аяк өстендәге авыру, чакырткач, үзе дә чыгар. Бүген барыбер аның янына барасы көн. Аннары, кеше күп булмаса, бәлки, ул үзе дә врачка күренер. Йөрәгенең әледән-әле борчып торуыннан бер кереп зарланырга кирәктер бит инде, кешеләр әнә эчләре катса да тизрәк врачка йөгерәләр.

Гасыйм Сәләхович як-ягына каранмыйча гына озын коридор буйлап узды, кемнәрдер аңа баш иде, ул да таныса-танымаса да баш иде, ахырда менә яп-якты урамга да килеп чыкты... Ну көне... Пешерә генә. Тынны куыра... Яктысыннан күзләр камаша... Һава эретеп агызган кургашындай тик тора. Ник бер генә яфрак селкенсен! Яңгырга гына булса ярар иде! Алай дисәң, төпсез күк йөзе чалт аяз... Килеп чыкмый бит шул Ослан таулары артыннан кәҗә тиресе хәтле генә бер кара болыт!.. Ә барырга, әлсерәп булса да, барырга кирәк... кирәк... Ул трамвайга утырыр өчен университет урамы буйлап түбән төшеп китте. Тротуарның кояшка караган җирләре йомшарган, аяк батып киткәли хәтта.

Шәһәр урамында бик сакланып йөрергә кирәклеген Гасыйм Сәләхович һәрвакытта исендә тота торган иде. Бу юлы исә ул һәртөрле куркынычны онытып, бары өйрәнелгән гадәт буенча гына башын уңга-сулга борды да, ашыкмыйча гына киң, хәтәр урам аша чыга башлады. Алдыннан һәм артыннан выжлап машиналар узды, әмма ул аларга юньләп игътибар да итмәде.

Тукталышка килде, трамвайга утырды, ә трамвай аны үргә таба алып менеп китте. Бер кыз бала торып аңа урын бирде (рәхмәт төшкере!), Гасыйм Сәләхович, утырып, вагон тәрәзәсеннән урамга карады. Ул тыныч иде, ул һични уйламый иде, ул урамданиләр барын да күрми иде шикелле. Көзгедә чагылгандай күзләреннән йортлар, агачлар, кешеләр үтә, әгәр шуларның берәрсе таныш кеше булса, ул аны да, ихтимал, күрми-танымый узар иде. Ләкин шулай да бу әле аның чын хәле түгел, чын хәле аның үз эчендә, каядыр тирәндә. Иң элек ул бер генә минутка да Идеал Шәйхиевне оныта алмый. Идеал Шәйхиев гүя бер адым калмыйча аңа ияреп бара, һәм Гасыйм Сәләхович теләсә-теләмәсә дә аның турында уйланырга мәҗбүр иде. Уйланып гаҗәпләнергә һәм ирексезләп рәнҗергә мәҗбүр иде. Ничек кенә булмасын, башта чын фикереңне әйтмичә яшерү, соңыннан шуны язып чыгу бу егетлек түгел. Бу куркаклык һәм түбәнлек! Аннары ни өчен ул, Шәйхиев, менә өч атна инде кафедрага килмичә, күренмичә йөри? Намусы кушмыймы әллә?.. Юк, ул андый кеше түгел, салкын, рационалист кеше ул, намус аның өчен абстракт төшенчә генә... Хәер, килеп күренмәве яхшы да булган икән. Югыйсә Гасыйм абзасы аңа дип саклап йөрткән китабын түбәнчелек белән тапшырган да булыр иде. Ярый ходай саклаган! Әмма барыбер аларга очрашырга туры киләчәк. Ник шул чакта бәхәскә кермәскә (керүдән ни мәгънә?), сер сынатмаска, бәйсезлек, тынычлык сакларга иде. Тик шуңа көче җитсен иде аның!

...Трамвай урам чатына җитеп туктады, халык төшә башлады, ул да агымга ияреп төште. Чехов базары аша үткән чакта хатынына дип бакчачылардан бер кило виктория җиләге сатып алды. Шуны үзе белән йөртә торган салафан капка салдырды да урам ашасындагы клиникага таба атлады. Башта ул үзен кабул итә торган врачка кермәкче булды, ләкин аның врачы бүген сәгать икедән генә кабул итә башлаячак икән. Шуннан соң ул ишегалды аша гына авырулар ята торган стационарга узды һәм түбәндә утыручы сестрадан хатынын дәшеп чыгаруны үтенде. Сестра аны таный иде, шуңа күрә, вакытсызрак килгән булса да, сүзен тыңлады.

Гасыйм Сәләхович бер читтәрәк торган дерматин тышлы киң генә йомшак эскәмиягә барып утырды, эшләпәсен салып янына куйды, шактый керләнгән кулъяулыгын чыгарып, маңгаен, муенын сөрткәләде. Монда, таш бина эчендә, аз гына салкынчарак иде, тын алуы да җиңелрәк иде... Озак та үтми, соры халаттан гына Рәмзия ханым да килеп чыкты. Больница киеме кешене гадәттә авыру итеп кенә түгел, килбәтсез итеп тә күрсәтә. Авыру ирләр бу хәл белән ничектер килешсәләр дә, хатын-кызлар, бигрәк тә яшьрәкләре, бер дә килешергә теләмиләр, күрәсең. Менә Рәмзия ханым да өстендәге котсыз халатын гәүдәсенә сыланганчы урап, билен фланель билбавы белән шундый кысып бәйләгән – озын аяклары да, җәелә төшкән янбашлары да, тулы күкрәкләре дә йомры-калку булып, бик ачык беленеп тора. Кыскасы, эссе

дип тормаган, сакларга тырышкан фигурасын... Шулай ук бакыр төсенә кертеп буяган чәчләренең прическасы да һаман шул килеш, матур килеш тора икән әле... Озынчарак куллары да әнә нинди ак, йомшак – төче генә бер ис тә аңкый үзләреннән. Әлбәттә, хатынының шушылай пөхтә, чиста, чибәр булуына һәрбер җаны бар ир сокланмыйча, хәтта дәртләнмичә калмас иде, әмма Гасыйм Сәләхович Рәмзия ханымның бу котыртып торырлык килеш-килбәтенә гүя бөтенләй игътибар да итмәде. Хәер, игътибар итте итүен, ләкин гаҗәеп бер салкынлык һәм битарафлык белән генә... Гүя хатынының бу байлыклары бер дә аның өчен түгел иде. Хәтта көнләшү дә кузгалмады аңарда – кузгалырга иренде, ахрысы.

Янәшә утырышкач, Гасыйм Сәләхович, күрешергә килгән ир буларак, башлап үзе сүлпән генә сорады:

– Йә, ничек соң... хәлең?

Рәмзия ханым да, гадәтенчә, туры гына «яхшы» яки «начар» дип әйтмичә, башта әзрәк зарланып алды; үткән төнне начар йоклаган икән, шуңардан бүген менә башы авырткан. Ә хәзер?.. Ә хәзер үтте кебек... Әлбәттә, үткән булырга тиеш... Кайчан чыгасың, дип сорады ире, тезләренә таянган килеш кенә.

– Ахрысы, озак тотмаслар, – дип зарланды Рәмзия ханым. – Урын кирәк, диләр. Үзләренең берәр дус-ишләренәдер инде. Бөтен җирдә блат, җаным!

– Нигә, үзеңнең чыгасың килмимени?

– Килсә дә бит, бер кергәч барысын да белеп чыгасы иде. Кат-кат кереп булмый монда.

– Врачлар белеп чыгара торганнардыр инде.

– Сиңа шул врач сүзе генә сүз, – диде Рәмзия ханым, турсая биреп, – ә минем хәлемдә кайгың юк синең...

Гасыйм Сәләхович дәшмәде. Сүз көрәштерергә аның һич кенә дә теләге юк иде. Врачлар турында әйтү дә кирәк булмаган. Ни пычагыма?!

Менә ул көнаралаш диярлек килә, китә, ә Рәмзиянең бер генә тапкыр да аның үз хәле турында сорашканы юк. Ничек яши ул ялгызы, үзен ничек хис итә, эшендә ниләр бар? Ник бер юри генә сорап карасын! Бәлки, зарланганны көтә торгандыр. Ә Гасыйм Сәләхович зарлана алмый, һәм иң гаҗәбе – нәкъ менә хатынына зарлана алмый ул. Сәбәп?.. Моны аңлатуы да читен. Кыскасы, үзеннән күп яшь һәм шактый ваемсыз хатынын борчымаска теләп, ә, бәлки, аның алдында дәрәҗәсен төшерүдән куркып та, ул Рәмзиягә эше-хезмәте, бигрәк тә сәламәтлеге турында зарланудан һәрвакытта тыелып килде һәм шушы нәрсә ничектер ирексездән аның гадәтенә дә кереп калды. Куанычын уртаклаша ала, әмма кайгысын – юк, сөйли алмый. Ләкин бит сөйләмәсә дә сизәргә, күрергә мөмкиндер инде, кешенең йөзенә карап та! Сукыр булмаса...

Хәер, күрсә дә, бәлки, әһәмият бирми торгандыр. Кем ул ир дигән кемсә? Эш аты. Аттан да бит кәефең ничек, берәр җирең авыртмыймы, дип сорамыйлар. Селкенәме – селкенә, тартамы – тарта, тагын ни кирәк?!

Рәмзия ханым малае турында сорады:

– Радиктан хат юкмы?

– Юк.

– Бу ни эш, киткәннән бирле бер хаты юк. Син шул бала өчен борчыласыңмы әзрәк?

– Бала түгел, җиткән егет, – диде Гасыйм Сәләхович.

– Ата диген инде... Бу хәтле дә таш йөрәк булырсың икән!

– Мин аның исән-сау кайтуына ышанам, – диде Гасыйм Сәләхович, ничектер бик кистереп.

Рәмзия ханым ireннәрен кысарга мәҗбүр булды, тик бераздан гына үзалдына хафалангандай:

– Акчасы да җитмәс инде балакаемның, – дип куйды.

– Җитмәсә, телеграммасы килер, борчылма!.. Акчадамыни эш? Менә көннәр бик кызуга китте әле... – Гасыйм Сәләхович эшләпәсен алып җилпенә башлады. Бите аның тимгел-тимгел кызарып һәм бүртенеп тә киткән төсле иде. Аннары кинәт кенә сүнгән хәлсез тавыш белән: – Мин кайтыйм инде булмаса! – диде.

– Нигә, миңа бернәрсә дә алып килмәдеңмени? – диде Рәмзия ханым, аз гына көлемсерәп.

– Да... бөтенләй онытып җибәргәнмен. – Гасыйм Сәләхович артындарак торган салафан капны алып, хатынына сузды. – Виктория. Әле генә базардан алдым.

– Рәхмәт инде... Ә мин кушканны китердеңме соң?

– Нәрсә иде ул?

– Минем челтәр бюстгальтерымны?

– Нәрсә-ә?

– Бюстгальтерны, дим... Челтәрен...

Гасыйм Сәләхович һичнәрсә аңламыйча, кашларын җыерып, хатынына карап тора башлады. Бюстгальтер!.. Бик мәгънәсез бер әйбер турында сүз бара түгелме?.. Каян белсен, хәтерләсен ул аны?! Шундый бер чүпне!

Рәмзия ханымның кинәт аңа ачуы килеп китте:

– Нәрсә син, аңгыра сарык шикелле, миңа карап торасың? Бюстгальтерның нәрсә икәнен белмисеңме әллә?

– Белмим! – диде Гасыйм Сәләхович, хатыныннан күзләрен ала алмыйча.

– Нигә, студенткалар түшендә бер дә күргәнең юкмыни? – диде Рәмзия ханым, юри шаркылдап.

Гасыйм Сәләховичның йөзе, каны качкандай, кинәт агарынып китте. Әллә һава җитмәгәннән, әллә нидер әйтмәкче булып авызын ачты, нигәдер бик кызганыч итеп бер елмаеп та алды, әмма ни дә булса әйтә алудан узган бер хәлдә, авыр гына торып, бөкрәеп, ишеккә таба атлады. Аяк атлаулары бик сәер, бик кыюсыз иде аның —хәтта Рәмзия ханым да моңа игътибар итте. Ләкин ирексездән борчылып куйса да, ирен шулай да туктатып тормады.

Урамга чыккач, Гасыйм Сәләхович бик аз гына вакытка туктарга мәҗбүр булды. Ашыгырга ярамый иде аңа. Йөрәк менә тире астында гына тибә кебек, бер авырттырып кыса, бер җибәрә, бер кыса, бер җибәрә... Хәтәр иде бу... Тизрәк валидол кабарга теләп кесәсенә тыгылды, ләкин анысы да онытылып калган булып чыкты. «Өйгә, тизрәк өйгә!» – диде ул үз-үзенә һәм әкрен-сак кына атлап китте. Башы да бераз әйләнә кебек, шунлыктан ара-тирә чайкалып та киткәли иде.

Үз хәленең бөтен җитдилеген яхшы аңласа да, ул ни өчендер шушында ук врачка күренергә кирәк дип уйлый белмәде. Күңеле аны нигәдер өенә тартты. Ә бит аның кәефе иртәдән үк начар иде, эшенә баргач, Шәйхиев мәкаләсе кәефен тагы да ныграк бозды – бозу гына түгел, бәгърен тирән яралады. Шулар өстенә тагын Рәмзия белән менә бу мәгънәсез сөйләшү! Җиткән иде аңа, бик җиткән иде, кирәкми иде аңа, агудай кечкенә, әмма бик хәтәр бу соңгы тамчы!

...Көн әүвәлгечә аяусыз эссе иде. Эссе генә түгел, гаять бөркү-тынчу да иде. Һава һич селкенмичә, шылт та итмичә бөтен нәрсәне басып, изеп тик тора. Моның кебек авыр, тын, хәрәкәтсез һава бары яшенле яңгыр яки көчле давыл алдыннан гына булырга мөмкин, һәм, ныграк игътибар итсәң, көн чынлап та үзгәрмәкче иде шикелле... Әнә еракта Иделдән дә ары, тауларга охшап тик кенә торган ак читле кара-зәңгәр болытлар күренә. Юк, алар, чынлабрак баксаң, тик кенә тормыйлар икән, алар һаман кабара баргандай үсәләр, куералар һәм бик әкрен генә болай таба авышалар да иде... Әмма Гасыйм Сәләхович боларның берсен дә күрми иде, эсселеккә дә, сәер тынлыкка да бөтенләй игътибар итми иде, аның бөтен кайгысы – тизрәк өенә кайтып җитү иде.

Үз йортларына җитеп, өченче катка туктый-туктый менгәнче, ул тәмам тиргә батты, калтыранган кулы белән ишекнең ике биген азаплана-азаплана ачты, эчкә узды, шулай да кире борылып, чылбыр бикне генә булса да эләктереп куярга онытмады. Аннары үз бүлмәсенә узып, эшләпәсен һәм портфелен диванга ыргытты да, сөйрәлеп кенә өстәле янындагы күн төпле креслосына барып утырды. Аңа хәзер үк берәр дару кабу кирәк иде, ул үзе дә моны бик яхшы

белә иде, ләкин ни өчендер ашыкмады – чак кына хәл аласы, бер-ике генә тапкыр булса да тирән итеп һава сулыйсы килде. Нәкъ шул чакта каядыр бик еракта кинәт тау ишелгәндәй дәһшәтле гөрселдәп, көчәя барып, озак итеп күк күкрәде һәм нәкъ шул ук мизгелдә Гасыйм Сәләховичның йөрәгенә әйтерсең уттай кызган пычак китереп тыктылар. Кискен, көйдергеч авыртудан яман коты алынып, авызын зур ачып, креслосына чатыр ябышты, көзән тарткандай киерелеп артка каерылды, бугазыннан гыжлап әллә тавыш, әллә һава чыккандай булды, ләкин шул секундта ук гәүдәсе капчыктай бушап, күзләре сүнеп туктап та калды. Тик береаздан гына аның башы үзеннән-үзе күкрәгенә кире салынып төште. Тагын еракта отыры дәһшәтлерәк, катырак итеп күк күкрәде, якынлашып килгән давыллы яңгырның беренче кискен җиле урам агачларын сыгып, шаулатып узды, ләкин Гасыйм Сәләхович өчен дөнья тып-тын, дөнья юкка чыккан иде инде.

Ә давыл артыннан килгән бәрәкәтле яңгыр тәүлек буена бер әкренәеп, бер шәбәеп туры гына яуды да яуды. Көчле җилдән бүлмәнең урам тәрәзәсе ачылып калган иде, өйгә яңгыр шавы белән бергә дымлы салкынча һава тулды. Гасыйм Сәләхович шул рәхәт җиләстә тынычланып ял иткәндәй, үзенең креслосында, башын игән килеш, берьялгызы тып-тын гына утыра бирде.

Әле беркем дә бернәрсә дә белми иде.

*1978*